

ЛИРОН
ХӘМИДУЛЛИН

# ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР



*Истәлекләр, очерклар, документаль повесть*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2022

УДК 821.512.145-4
ББК 83.3(2Рос=Тат)6
Х26

**Хәмидуллин, Л. Х.**

Х26 Ерактагы ак җилкәннәр : истәлекләр, очерклар, документаль повесть / Лирон Хәмидуллин. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2022. – 463 б.
ISBN 978-5-298-04371-7

Әлеге китапка Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Лирон Хәмидуллинның төрле илларда иҗат ителгән XX гасырда яшәгән кайбер җәмәгать эшлеклеләре, әдипләр һәм мәдәният хезмәткәрләре турында истәлекләре һәм очерклары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-4
ББК 83.3(2Рос=Тат)6

ISBN 978-5-298-04371-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2022
© Хәмидуллин Л. Х., 2022

# I

*Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата...*

*Г. Тукай*

# САБЫЙЛАРГА ТУКАЙ СҮЗЕ КИРӘК

Балачак хатирәләренә бәйле табигать күренешләре, төрле вакыйгалар тиз генә онытылмаучан була. Сабый чакта ишетелгән тапкыр әйтемнәр, кызыклы чагыштырулы шигырь юллары да мәңге истән чыкмый диярлек. Кайбер күренеш-вакыйгаларга бәйле рәвештә әйтелгән сүзләр бик озак вакыт хәтердә саклanучан була. Бигрәк тә инде ул сүзләр тапкыр мәкаль, яисә шигырь алымында әйтелгән булса. Кеше табигате шулай яратылган. Ничәмә дистә еллар үткәч тә, яңа калыккан ай урагы күренүгә, әбиемнең тәүге тапкыр: «Ай күрдем аман белән, җаным тулды иман белән», – дип пышылдап әйткәннәре хәтергә килә.

Габдулла Тукайның күп кенә шигырь юллары да теге яки бу очрак белән һаман искә төшеп, күңелдә кабатланалар. Кар очкалап торган табигать күренешен күрүгә, шагыйрьнең:

> Кыш. Буран. Салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә,
> Җил куа карны, һаман да кар «төшәм» дип тартыша, –

дигән шигырь юллары күңелдә яңара. Җәйге бер иртәдә кырга, болынга чыксаң:

> Әйт әле, күбәләк, сөйләшик бергәләп:
> Бу кадәр күп очып, армыйсың син ничек? –

дигән күңелле юллар искә төшә.

Әйе, балачакта табигый рәвештә күңел түреңдә урын биләгән шундый тапкыр әйтемнәр тиз генә онытылмый шул. Әле искә алып киткән шигъри өзекләр һәм шуларга охшаш башка бик күп шигырь юллары һәм әйтемнәр бит, нигездә, махсус ятланмаганнар. Әйтик, аларның байтагы әле мәктәптә укый башлаганчы ук колакка кергән, хәтер түрендә урын алырга өлгергәннәр. Әнием яисә әбием берәр очракка бәйле рәвештә әйткән ич инде аларны. Бигрәк тә әнием, мәрхүмә, яшьлегендә башлангыч сыйныф балаларын укыткан тәрбияче буларак, Тукайның сабыйлар күңеленә бик хуш килгән, мәкальгә тартым эчтәлекле шигъри сүзтезмәләрен берәр эш белән барган уңайдан гына әйтеп бирер дә, «шагыйрь Габдулла Тукай шулай дигән» дип өстәп тә куяр иде.

> Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
> Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.
> . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене
Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.

Билгеле инде, бездә шагыйрьләр дә, аларның күңелгә хуш килердәй шигырьләре дә байтак. Без үскәндә, әнием дә, мәсәлән, фәкать Тукай шигырьләреннән генә үрнәкләр китермәгәндер. Мәгәр сабый бала зиһене үз тормыш-көнкүрешенә, яшәү мохитенә тәңгәл итеп кабул итәрдәй гади, төгәл сүз-әйтемнәр Габдулла Тукай шигырьләренә хасрак шул.

Балалар бакчаларында тәрбияләнүче замана балалары бездән күпкә мәгълүматлырак булып үсәләр. Ике яшьтән шундый бакчага йөргән оныгым Мансур, мәсәлән, ике телдә иркен сөйләшә, ике телдә китап укый. Хәзер инде ул – укучы, икенче сыйныфны тәмамлап килә. Мәктәптә аңа еш кына шигырь ятлаталар. Иң гаҗәбе: татарча иң җиңел ятлана торган шигырьләр – «Тукай бабай» шигырьләре. Чөнки алар иң камил эшләнешле – артык сүз дә, кирәкмәскә катлауландырылган тасвирлаулар да аларга хас түгел. (Әлбәттә, сүз башлангыч сыйныф укучылары дәресләкләрендәге шигырьләр турында бара.) Балалар бакчасына йөргәндә үк, тәрбияче Фәридә апалары, ярым көйләп:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы, –

дип өйрәтә иде. Габдулла Тукайның бу көйле шигырен бала әле дә белә, радио, телевидениедән аның сүзләрен ишетүгә кабатлый башлый. Иң куандырганы шул: әдәбият дәресләреннән соң бала өйгә кайткач та, янә китапка үрелә...

*2006, 22 апрель*

# ОНЫТЫЛМАС БЕР КӨН

*(Истәлек)*

1939 елның март ае башлары иде. Авыл өйләренең кар көртләренә күмелеп утырган чагы. Кыр-басулар өстенә ябылган апак йомшак «юрган»ны инде яз кояшы тыгызлап, боздай итеп катырып өлгергән. Шул җемелдәк кар диңгезе уртасыннан без ике ат-чанада Иске Төгәлбуга авылына кайтып барабыз. Мондый хозурлыкны, иркенлекне әле минем беренче күрүем. Җиденче яшькә чыккан малайның чатнап торган шундый кояшлы матур көндә ике авыл арасында чаптар ат җигелгән читәнле чанага утырып баруы үзе бер онытылмас хатирә ич.

Ул елларда әтием күрше авылда – хәзерге Ульяновск өлкәсенә кергән Урта Исәнтимердә эшләде. Җәйге айларда без

әбием белән икәү генә үз авылыбызда яшәсәк, көзге һәм кышкы көннәрнең бер өлешен мин әтиләр яшәгән шушы Урта Исәнтимер авылында уздыра идем. Башка елларда кыш айларында бу ике авыл арасын ничек үткәнем хәтердә калмаган. Ә бүген, басудагы кар өстендә кояш нурлары җем-җем килгән бер сихри көндә, үз авылыма кайтып барам. Сөенеч-куанычларымның чиге юк. Хәер, әтиләр дә бик күңелле гөрләшеп, алда нindидер күңелле тамаша буласы турында сөйләшеп баралар. Иртәдән бирле инде шундый хәл: берсен берсе бүлдерә-бүлдерә, Фәйзүк дигән кемнеңдер кайтуын сөйлиләр. Тегенең элекке кайтуларында кылган нindидер кыланмышларын көлә-көлә, кызык итеп искә алалар.

Менә без Иске Төгәлбуганың үзәк мәйданына килеп чыктык. Мәйдан уртасында Зур урамга чак кына яны беләнрәк борылган зур өй – яңа клуб тора. Әбием әйтүенчә, элек ул авылның иң зур мәчете булган. Авылның оч-очларындагы башка мәчетләр өстендә мәһабәт манаралар калкып утыра. Җәй көннәрендә без, ул манараларга менеп, авыл өстен һәм тирә-якны күзәткәли, яки манара эчләренә сыенган күгәрчен, чәүкәләрне кугалый идек. Ә бу зур йортның манарасы юк, шуңа күрә дә ул клуб исемен йөртәдер, дип уйлый идем мин ул заманда.

Без авылга килеп кергәндә, инде караңгы төшә башлаган иде. Шул караңгылыкта клуб тәрәзәләренең балкып, тирә-якка нур чәчеп торуы күренде. Клуб артындагы баганаларга бихисап ат-чаналар бәйләп куелган, читтәрәк бер полуторка машинасы да күренә иде. Әти дә атын бер бушрак урынга илтеп бәйләде. Анңары бергә килүче иптәшләренә: «Кереп урнаша торыгыз. Улымны әбисенә илтеп килим», – диде.

Шул сәбәпле ул кечтә клубта ни-нәрсә булганын, нинди кешенең кайтуына атлар яллап күрше авылдан килүебезне белмичә калган идем. Боларны мин икенче көнне генә ачыклый алдым. Фәйзулла Туишев дигән бик тә танылган бер артист – оста гармунчы кайткан икән. Тумышы белән шушы Иске Төгәлбуга авылыннан икән дә, авылдашларының күңелен күтәреп, тамаша кылып китәр өчен дип кайткан икән. Ул тамашаның тәмам төн урталары узганчы барганлыгын йотлыгып сөйләүләрен әле дә хәтерлим. Хәер, кеше сөйләгәнне генә түгел, артистның үз чыгышын да яхшы ук хәтерлим әле. Икенче көндәме, яисә аннан соңракмы, шул ук клубта артистның концерты көндез дә кабатланды.

Әбием һәм сеңлем Гөлфия белән ул концертны без дә тамаша кылдык. Без килгәндә, өч бура тоташтырып ялганган зур клуб эче халык белән шыгрым тулган иде. Безгә элекке мәчетнең иркен сәндерәсенә менәргә туры килде. Анда да кеше күп иде. Тик бер мәрхәмәтлерәк хатын-кыз, кысыла төшеп: «Хупҗамал абыстай, утыр җаныма», – дигәч кенә, әбиебезгә урын табылды. Сеңлем белән мин исә, башка балалар кебек, сәндерәнең алгы киртәләренә сөялеп бастык. Шулай бастык та, күпме вакыт басып

торганыбызны да онытып, хәйран калып тамаша кыла башладык. Бик ыспай киенгән олырак гәүдәле бер кеше бөтен игътибарыбызны җәлеп итте. Сәхнәдә ул бер дә тик тормый, әле бер, әле икенче гармунны кулына ала да, уйный да уйный. Бер гармунны куеп икенчесенә үрелгән араларда, халыкка мөрәҗәгать иткәләп тә ала иде.

Ул вакытта аның нинди көйләр уйнаганын, ни-нәрсәләр сөйләгәнен инде онытканмын. Дөресрәге, көй атамаларын ул вакытта да белми идем, билгеле. Миңа көйнең исем-атамасы түгел, артистның аларны гармуннарын төрлечә кыландырып уйнавы кызык тоелды. Сәхнәнең ике башындагы ике зур өстәлгә төрле-төрле зурлыктагы гармуннар өеп куелган. Артист шуларның берсен алып уйный-уйный да икенче өстәлгә илтеп куя. Шаян сүзләр әйтә-әйтә, янәдән беренче өстәл янына килә, телләре күңелне үзенә тартып, ялтырап торган гармуннарның кайсысына үрелим дигәндәй, беркадәр уйланып торгандай итә. Аннары кулга тоткан берсен былбылдай җилкендереп, чеңгелдәтеп җибәрер иде. Халык аңа гөрләтеп кул чаба. Авыл гадәтенчә, куанганын белгертеп, әче итеп сызгырып җибәрүчеләр дә очрый. Көр тавышлы ирләрнең кайберләре, залны яңгыратып: «Әйт шуны, Фәйзүк кордаш!» – дип кычкырып, артистның уенын куәтләп, аны очындырып та җибәрәләр иде. Артист исә аның саен һәвәсләнеберәк уйный башлый. Нәни генә гармунчыкларын ике кесәдән ике кулы белән берьюлы ала да, шуларны чөеп-чөеп, чеңгелдәтеп-чинатып уйнап җибәрә…

Олуг артист ул көнне, мөгаен, саф татар көйләрен генә дә уйнамагандыр. Күрше авыллардан килгән чувашларның да күңеле булсын дип, үз репертуарында чуваш көйләренә дә урын биргәләгәндер, шәт. Аның рус, чуваш көйләрен дә бик оста уйнаганлыгын еш искә алалар. Ә теге көнне элекке мәчетебезнең бер почмагында чуваш ирләре һәм хатын-кызларының өерелешеп торуын да күргән идем. Алар безнең авыл кешеләреннән башларына бәйләгән шәлләре, бөрмәле билле итеп теккән туннары белән ерактан ук аерылып торалар ич. Авыл халкы сөйләвенчә, «артист Фәйзүк» яшь чагында күрше чуваш авылы Иске Салаванда да ике-өч җәй яшәп алган. Ачлык елларда аның бабасы Мокач белән атасы шунда көтү көткәннәр. Шулай бераз хәл алгач, мал туплагач, артистның әтисе Кәбир абзый гаиләсе белән Мәләкәс шәһәренә күченеп киткән. Фәйзүк шунда оста итеп гармунда уйнарга өйрәнгән икән. Авылда, Курай урамында, Кәбирнең төпчек энесе Хөснетдин яшәп калган. Хөснетдин Беренче бөтендөнья сугышыннан әйләнеп кайтмый. Искә алынган концерт көннәрендә Фәйзулла агаларның төп йортында җиңгәсе Бәнат апа һәм аның кече улы Шәмси гаиләсе яшәгән була. Ул чорда артистның һәр елда авылга кайтып йөрүен, һәрвакыт «Бәнат тәчие» йортына төшүен мин соңрак ачыкладым. Әйе, егерменче-утызынчы елларда, авылга кайтканда, Фәйзулла Туишев һәрвакыт диярлек аларга

тукталган. Ә ул элек Иске Төгәлбугага еш кайтып йөргән. Кайткан саен, авыл клубында концертлары оештырылган. Берничә мәртәбә башка артистлар белән бергә кайтуын да искә алалар. Байтак еллар клуб мөдире булып эшләгән чордашы Нәкытдин бабай Миңлебаев шундый берничә очракны искә алды. Җитмешенче елларда очрашканда, аңа инде туксанынчы яшь иде, авылдашының тәгаен кемнәр белән кайтуын әйтеп бирә алмады. Әйе, Фәйзулла ага Туишевка багышланган истәлекләрне бик соңлап, алтмышынчы еллар урталарыннан гына барлый башлаган идем шул. Аңа чаклы әбием белән әнием сөйләгәннәр генә хәтеремдә саклана иде. Ә элекке «избач» һәм клуб мөдире Нәкытдин ага белән саубуллаша башлагач кына, ул: «Бер җырчы белән дә кайткалады инде», – дигән иде. Кем ул – исемен искә төшерә алмады.

1939 ел вакыйгаларын яхшы хәтерләүче авылдашларым сөйләвенчә, ул вакытта артист хатыны Лалә ханым белән бергә кайта. Авыл җитәкчелеге аларны клубка якында гына яшәгән Гаян апа Садриеваның иркен йортына урнаштыра. Ире Гражданнар сугышында үлеп калган Гаян апа ул елларда авылда бик абруйлы кеше иде. Колхоз оешкан елларда аңа керергә башлап гариза бирүчеләр төркемендә дә ул була. Шуннан соң төрле комитетларга сайлана. Русча иркен сөйләшә белмәсә дә, Самара өлкәсе вәкилләре төркемендә Үзәк башкарма комитет (ЦИК) утырышларында катнаша. Мәскәүдә Калинин бабай белән бер төркемдә төшкән фотосы, ил старостасы кулыннан алган зур бүләк сәгате җыйнак өенең түр диварына эленеп куелган иде. (Оныгы Гайса белән бергә уйнап үстек.) Авыл халкы телендә кушаматы да «ЦИКа Гаян» булды. Бер улы Кызыл Армиядә командир иде. (Сугыш башлангач, аның хатыны Зәйнәп апа авылга кайтты, башлангыч классларда безне укытты.)

Әйе, 1939 елгы кайтуында олуг артистны, хөрмәтләп, шушы «ЦИКа Гаян» апа өенә урнаштыралар. Сәхаб белән Шәмси энеләре гаиләләренә ул хәл белергә генә барып килгәндер, мөгаен. Бу вакытта әле артистның Бәнат җиңгәсе дә исән була. Үзләренә кайтмаган өчен, каенесенә үпкәсен дә белдерә, дип сөйләделәр. Фәйзулла Туишев дөньяга килгән, бик таушалган ул төп йортта алтмышынчы, җитмешенче елларда инде башка кешеләр яши иде. Хөснетдиннең ике улы да, Сәхаб белән Шәмси, Бөек Ватан сугышында һәлак булалар.

Мәшһүр авылдашымның сәхнәдә виртуозларча уйнавын күргәннең соңында минем дә гармун дип саташуларымны сөйләп тә бетерерлек түгелдер. (Хәер, ул көннәрдәге концертлардан соң кулга гармун алып уйнау турында авылда мин генә хыялланмаганмындыр, билгеле.) Әти, мәрхүм, минем елау-сыктауларыма түзмәде булса кирәк. Фин сугышыннан кайткач, 1940 елның җәй башында минем кулыма Самарадан өр-яңа тальян гармун кайтарып тоттырды. Шуны шыгыр-шыгыр китереп сәгатьләр буена өйдә утыруларым, яисә үзебезнең урам очы буйлап йөрүләрем

хәтеремдә калган. Әбием белән төшкән бер фотода да шул гармун минем кулда. Әмма ләкин гармунчы булып китә алмадым. Әтиләр күрше авылда эштә, мин әбием карамагында бер ялгызым: терлек-туар карашучы да, чүп-чар уташучы да дигәндәй. Биек киштәдә зарыгып көтеп утыручы гармунда уйнарга өйрәтүче генә юк. Намаздан аерылмаган кеше буларак, гармун шыңгырдатып йөрүләрем әбиемә ошап та бетмәгәндер. Гөнаһлы эштән мине үзенчә сакларга теләптер инде, гармунны ул һәрчак иң өстәге киштәгә куяр иде.

Әйе, мин гармунчы булып китә алмадым. Тиздән Бөек Ватан сугышы башланды. Әти яшьтәшләре белән бергә кабат сугышка китте. Ике ел тулмастан, аның батырларча сугышып һәлак булуы турында хәбәр килде. Ә бер яз көнендә, чәчүлек бәрәңге җитмәгәч, ул өр-яңа тальянкамны әни берничә пот бәрәңге исәбенә сатып җибәрергә мәҗбүр булды. Истәлеккә шул гармунны тотып төшкән бер фото гына калды.

Хәзер шул вакыйгаларны искә алган саен, томан эчендәгедәй булып, мәшһүр якташым Фәйзулла Туишев күз алдыма килеп баса. Ул вакытта авыл клубында аны беренче һәм соңгы тапкыр күрүем булган. 1939 елдан соң инде ул Иске Төгәлбугасына кайта алмады. Әүвәл ил өстенә бер-бер артлы ике рәхимсез сугыш килде. Бөек Ватан сугышы көннәрендә олы яшьтәге артистның яу кырындагы сугышчыларның күңелләрен рухландыру нияте белән фронтның алгы сафларында артистлар бригадасы белән йөргәнлеге мәгълүм. Шуннан соң ул җитди генә авырып китә һәм 1958 елда Казанда вафат була.

Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевның арабыздан мәңгелеккә китүенә дә тиздән алтмыш биш ел тулачак. Вафатыннан соң авылдашлары аның исемен мәңгеләштерү турында да уйланалар. Тик аңа ничек ирешергә? Бервакыт «Батрак» исемен йөртүче зур колхозга аның исемен бирү турында да сүз чыга. Ләкин кайбер җитәкчеләр «колхоз төзелешенә аның катнашы юк» дигәч, бу зур артельгә «Правда» исеме бирелә. Шуннан соң аның кайбер чордашлары «вакыт-вакыт без, аңа багышлап, кичәләр оештырыйк. Аның башкаруында уйналган көйләрне, ул тудырган җырларны туплап барып, халыкка җиткерик» дигән фикергә киләләр. Ләкин авыл шартларында андый теләккә ирешү дә җиңел түгел шул. Артист башкарган җырлар, көйләр язылган пластинкалар таралып беткән. «Артистның үзе тудырган әсәрләре дә радиодан бик сирәк тапшырыла. Һәм аларның кайчан биреләсен алдан белеп тә булмый бит», – дип зарланган иде бервакыт Фәйзулла аганың чордашы Фәтхи ага Биказаков. Хәер, шәһәрдә яшәп тә, без аның тарафыннан иҗат ителгән утызлап җыр-көйне, ялкынлы яшьлек мотивларын чагылдырган сюитасын һәм самаралылар якташлыгы буенча якын дусты саналган Гадел Кутуйга багышланган маршын радио һәм телевидение тапшыруларында бик-бик сирәк ишетәбез шул…

Әлеге «Правда» колхозы да гамәлдән чыгып, советча яшәү тәртипләре бетерелгәч кенә, 2009 елда, бөек якташыбызның исеме авыл үзәгендәге яңа мәктәп бинасында теркәлде — аңа багышлы истәлек тактасы куелды. Ул вакыйгада Ульяновск өлкәсенең губернаторы Сергей Морозов та катнашты. Шул ук елда авылда бөек артистның тууына 125 ел тулу вакыйгасы да зурлап билгеләп үтелде. Бу тантаналы бәйрәмгә Казан, Ульян шәһәрләреннән, район үзәге булган Малыклы бистәсеннән һәм күрше тирә-яктан бик күп кунаклар да килгән иде. Ульян каласыннан бу бәйрәм тантанасында Өлкә милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Рифгать Әхмәдулов, «Өмет» газетасы баш мөхәррире Исхак Хәлимов, берничә артист һәм милли оешма активисты, шул исәптән өлкә күләмендә танылган ветеран гармунчы да катнашты.

Казаннан Бөтендөнья Татар конгрессы вәкилләре буларак Миләүшә Гомәрова, шагыйрә Флёра Тарханова, Татарстан Мәдәният министрлыгы исеменнән Татар иҗат йорты вәкиле Илгиз Кадыйров, Ф. Туишев исемендәге махсус бүләк иясе, атаклы гармунчы Кирам Сатиев, гармуннарда оста уйнау белән бергә күпсанлы җырлар авторы да булган Рамил Курамшин, танылган җырчыбыз Миңгол Галиевләр килгән иде. Ул тантаналы вакыйгада минем гаиләм – мин, улым Булат һәм җәмәгатем Дания дә катнашты. Район җитәкчесе Ильяс Мөстәкыймов билгеләп үткәнчә, бу вакыйганы оештыруга этәргеч биргән бер сәбәп — минем бөек якташыма багышланган документаль повестем «Әй, гармун, гармун» була. Шуннан алдагы елларда ул әсәр «Казан утлары» журналында басылып чыккан иде. «Әй, гармун, гармун» повестем да кергән «Кичке шәфәкъ» китабын мин, шул вакыйга булыр алдыннан, авылга да җибәргән идем. Булат улым исә бу бәйрәмгә бөек якташыбызның радиокомитет архивында сакланган музыкаль язмаларның копияләрен алып кайтты. Һәм аларның кайберләре кичә барышында катнашкан тамашачыларга да ирештерелде. Авылда бу вакыйганы оештыруда актив катнашучылар урта мәктәп коллективы булды. «Өмет»тә хәбәр ителүенчә, юбилей очрашуын гамәлгә куючылар: шушы авылдан чыккан район башлыгы Ильяс Мөхетдинов, Татар милли-мәдәни автономиясенең район бүлеге рәисе Ринат Сәйфетдинов һәм авыл советы. Авылдашлары исеменнән бу очрашуны укытучы Әлфия Ибраева алып барды.

*2010*

# БЕРЛӘШЕП, АРАЛАШЫП ЯШӘҮ ЕЛЛАРЫ

*(Очерк)*

1

Революциягә кадәр татар язучылары арасында иҗади бердәмлекләр, аерым сәяси-иҗтимагый төркемнәр булмаган диярлек. Дөрес, 1907–1908 елларда берара «Әлислах» белән «Таң йолдызы» газеталары тирәсенә тартым яшь иҗатчылар үз төркемнәренә «елышырга» тырышып караганнар. Ләкин тиздән «таңчылар»ның җитәкчесе Гаяз Исхакыйның кулга алынуы сәбәпле, алар үз йөзе булырдай бер төркемгә оешып бетә алмаганнар. Ә менә егерменче елларда инде бер-берсеннән беркадәр аерылып торган, үзара «көрәш дулкыннары» уйнаткалап алган бердәмлекләр хасил була. Үзләрен сәяси яктан «уң карашлы» яки «сул карашлы» дип танучы ике зур төркем күпчелек язучыларны берләштерә.

1924 елда Фәтхи Бурнаш, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Гадел Кутуй һ. б. яшьләр «Октябрь күмәге» төркемен оештыралар. Ә Мәскәүдә яшәп иҗат итүче яшьләр Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясендә (МААП) үз секцияләрен булдыра (Мансур Крымов, Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов һ. б.). 1928 елның май аенда Мәскәүдә эшче-пролетар язучыларның I Бөтенсоюз съезды уздырыла. Гомәр Гали җитәкчелегендә анда берничә татар язучысы да катнаша. Съезддан соң Казанда татар пролетар язучылар оешмасы ТААП төзелә. Аның идарәсенә Гомәр Гали (рәис), Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Демьян Фәтхи, Габдрахман Минский һ. б. керә. Ә берникадәр вакыт элегрәк «пролетар булмаган» өлкәнрәк буын каләм әһелләре «Татар язучылары җәмгыяте»нә берләшә башлаган була. Аның идарәсенә Галимҗан Нигъмәти (рәис, Татар дәүләт нәшриятының баш мөхәррире), Кәрим Тинчурин, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбайский, Гадел Кутуй сайлана. Вакытлы матбугат битләрендә бу төркемнәр арасында җитди генә бәрелешләр, кемнең «дөрес юлдан барганын» ачыклау бәхәсләре булгалап тора.

Әлбәттә, төрле сәяси юнәлешле мондый төркемнәр, алар арасындагы низаглар СССР рәвешендә оешып килүче мәмләкәтнең башка төбәкләрендә дә һәрдаим очрашкалап тора. Мондый хәлләр Мәскәү, Петербург кебек сәяси башкалаларда аеруча күзгә ташлана. Шундый хәлләргә чик кую, сәяси агым-юнәлешләрне бер җайга салу максатыннан чыгып, ВКП(б) Үзәк комитеты 1932 елның апрелендә язучыларның һәм башка иҗат әһелләренең бердәм оешмасын – союз-берлекләрен оештыру турында карар кабул итә. СССР Язучылар берлеген оештыру комиссиясе төзелә. Аның идарәсенә Максим Горький, Александр Серафимович һ. б. керә. Казанда да шундый комиссия төрле әдәби төркем вәкилләреннән сайлана. Оештыру төркеме җитәкчеләре итеп партияле

Галимҗан Нигъмәти белән «Кызыл Татарстан» газетасы секретаре Гаяз Ризванов билгеләнә. Татарстан язучыларының I Оештыру съезды 1934 елның 25 июлендә ачыла. Мәскәүдән һәм күрше республикалардан кунаклар чакырыла. Съездда 9 кешедән торган идарә сайлана. Идарә утырышында рәислек вазифасын үтәү Кави Нәҗмигә йөкләнә.

Шул ук елның август аенда язучыларның СССР күләмендәге I съезды Мәскәүдә ике атна чамасы эшли. Анда катнашкан 500 гә якын язучы арасында Татарстаннан килгән 12 делегат һәм берничә кунак та була. Кави Нәҗми белән Кәрим Тинчурин съездда татар әдәбияты һәм сәнгатенең торышы турында нотык сөйлиләр. Бу беренче съездларга кагылышлы вакыйгаларны берничә ел элек Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин «Казан утлары» журналында һәм «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» (2004) китабында тәфсилләп язып чыкты. Язучыларның Мәскәүдә узган зур съездында төрле төбәкләрдән килгән 19 татар каләм әһеленең катнашуын да шул язмалардан укып белә алабыз.

Мәскәүдә узган съездның төп әһәмияте язучыларны бер оешмага беркетү, сәяси-иҗтимагый бердәмлек булдыруда гына түгел, билгеле. Дөньясын онытып, иҗат мавыгуына бирелеп, үз кетәгендә баш күтәрми эшләп утырган язучының тормыш-көнкүрешенә бәйле бик җитди мәсьәлә дә хәл ителә бу җыен барышында. Күпләрне борчыган, матбугат битләрендә байтактан бирле күтәрелә килгән мәсьәлә бу. 1928 елда «Кызыл Татарстан» газетасында да шул хакта язучы Сафа Борһанның күләмле генә мәкаләсе басыла. «Язучы нәтиҗәле эшләсен өчен аның тормыш-көнкүрешен җайга салу, матди хәлен кайгырту, иҗади очрашу сәфәрләрен оештыру зарур», — дип яза ул.

Беренче оештыру съездына әзерлек барышында алда телгә алынган комиссия бу мәсьәләне хәл итүгә дә җитди килгән — каләм әһелләренең тормыш-көнкүрешен кайгыртырга тиешле фонд булдыру турында хөкүмәт карарын чыгарткан икән. Шул рәвешле СССР Әдәби фонды — Литфонд оешмасы барлыкка килә. Аның хөкүмәт тарафыннан хупланган уставы шул съездда ук раслана. Литфонд оешмасының төп максаты язучыларга уңайлы иҗат итү шартларын тудырудан гыйбарәт иде. Ягъни язучы гаиләсен торак белән тәэмин итү, сәламәтлеген сихәтләндереп тору өчен, хастаханәләргә, курорт-санаторийларга юлламалар юнәтү, иркенләп, дөнья мәшәкатьләреннән котылып, иҗади мохиттә яшәп алырдай иҗат йортлары булдыру, махсус китапханәләр, клублар тоту... Язучының дөньяви һәм иҗтимагый-сәяси белемен үстерүгә булышлык итәрдәй төрле семинарлар, курслар да, махсус ачылган Әдәбият институты да шушы Литфонд акчасына яшәп килделәр. Ил буйлап һәм ара-тирә чит илләргә барып кайту өчен командировка чыгымнары да, язучының сырхаулап торган көннәре өчен «больничный» түләүләре дә шул фонд хисабыннан булды. Хәзер иҗат кешесе өчен боларның берсе дә юк инде. Литфонд,

Музфонд, Худфонд кебек оешмалар таркалу хәлендә. Иҗат әһелләренең тормыш-көнкүреш мәсьәләсе яңадан патша Россиясе чорындагы торышына әйләнеп кайтты. Бай-буржуйларга яраша белгәне яши, калганнары очын-очка ялгар-ялгамас килеш көн күрә…

«Элек ул Литфонд, Музфонд, Худфондлар ни-нәрсә исәбенә яшәгән соң? Аларны яшәтү өчен, кем акча биреп торган?» дигән сорау туа. Хөкүмәт биргән. Дөрес, хөкүмәт тә акчаны турыдан-туры үзе өләшеп ятмаган. Аны иҗат әһелләре тудырган әсәрләрне «товар»га әйләндерүче газета-журнал һәм китап нәшриятлары, театрлар һ. б. шундый оешмалар хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән бер күләмдә дәүләткә каралган керемнән чигереп, авторларның хокукларын барлаучы агентлыкка күчерә килде. Күптән мәрхүм булган әдип, рәссам, композиторларның мирасын куллanудан килгән бәрәкәтле керем дә шул кассага күчә барды. Ул агентлык исә кайсы фонд исәбенә күпме акча кергән – шуларны бүлеп бирә иде.

Литфондның Татарстан бүлеге 1934 елдан үз бурычын үтәүгә керешә. 1934–1992 еллар аралыгында Язучылар берлегенә кабул ителгән иҗат әһелләренең күпчелеге шул фонд исәбенә фатирлы булдылар, курорт-санаторийларда дәваландылар, иҗат йортларына барып ял һәм иҗат итеп кайттылар. СССРның төрле тарафларына иҗатташлары яки булачак әсәр геройлары белән очрашуларга баргалап йөрделәр. Оешмаларда эшләмәүчеләре авырган көннәре өчен акчалата уртача хезмәт хаклары алдылар. Чит илләргә иҗади командировкаларга баручылар да булды. Мәсәлән, мин Литфондта эшләгән 1967–1983 елларда Зәки Нури, Габдрахман Минский, Рөстәм Кутуй – Польшада, Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин Германиядә булып, Бөек Ватан сугышына бәйле әсәрләренә материал туплап кайттылар. Аңа чаклы Шәйхи Маннур, «Муса» романын язган вакытта, Литфонд исәбенә Берлинда йөреп кайткан иде. «Сызгыра торган уклар» романын язарга керешкәндә, Нурихан Фәттах, Монголия җирләрен аркылыга-буйга иңләп, бер ай чамасы йөрде. Яртылаш диярлек Литфонд исәбенә түләнгән туристлык юлламалары белән чит илләргә чыгып йөрүчеләрнең исемлеге исә санап бетергесездер. Алар төркем-төркем булып гарәп илләрендә дә, Төркия, Көнчыгыш Германия, Испания, Италия, Польша, Франция, Финляндия, Чехословакия, Япониядә дә сәяхәт кылып кайттылар. Кайберләре, мәсәлән, Р. Фәйзуллин, М. Галиев, М. Мәһдиев, М. Маликова, Ә. Рәшит кебек тиктормасраклары сәяхәтнамәләр язды, күргән-белгәннәрен әдәбият сөючеләргә җиткерде. Ә инде җәйләрен – көньякның диңгез буйларында, кыш айларында Мәскәүгә һәм андагы нәшриятларга якын иҗат йортларында бер мәртәбә булса да иҗат итеп ятмаган язучы бик сирәктер. Иң актив иҗат итүче язучылардан Г. Бәширов, Ш. Маннур, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Гыйлаҗев, М. Мәһдиев кебекләр андый мөмкинлек-

не дә бик актив кулланалар – җәен дә, кышын да берәр-икешәр айлык юлламалар алырга тырышалар. Шуңа күрәдер аларның иҗат җимешләре дә мул булды.

Литфонд исәбенә тотылган Әдәбият институтында яки аның карамагында эшләүче ике еллык Әдәби курсларда белем алучыларыбыз саны да ишле генә. (Татарстан Литфонды эшчәнлеге турында тулырак мәгълүмат минем 2004 елда «Казан утлары» журналының 10 санында басылган «Әдәби фонд сәхифәләре»ндә китерелә.) Шуны да искәртеп үтик: алтмышынчы-җитмешенче елларда ул әдәби курсларда укучы сакаллы шәкертләребезгә Литфонд тарафыннан түләнгән стипендия милли газета-журнал редакцияләрендә, нәшриятларда эшләүче гади редакторлар хезмәт хакыннан (110–130 сум) бик алай аерылмый иде диярлек.

Сугыштан соңгы дәвердә ел саен оештырыла килгән әдәбият атналыклары, конференцияләр, әдәби-мәдәни арадашлык бәйрәмнәре дә шул чараларда катнашкан Литфонд оешмалары ярдәменнән башка узмас иде.

## 2

Иҗат кешеләре борын-борын заманнардан бирле үзара аралашып, киңәшләшеп, фикер алышып яшәргә күнеккән. Бер-береңә теләктәш тә, терәктәш тә булу – тормыш таләбе ул. Иҗат кешеләре өчен исә үзара аралашып, фикер алышып, бер-береңнең уңышы белән танышып, бер-береңнән үрнәк алып яшәү – киләчәк уңышыңның нигезе саналырлык нәрсә. Мондый аралашулар аеруча каләм әһелләре өчен бик тә кирәк. Югыйсә үз казаныңда гына кайнап зур уңышка ирешә алмавың көн кебек ачык.

Совет хакимияте ныклап аякка баса башлаган 1920 еллар ахырына табарак ук иҗат кешеләре өчен бик файдалы булган шундый аралашуларны оештыру чаралары күрелә башлый. Иң әүвәл башкала язучылары, төркемнәргә берләшеп, әле Алтай тарафында төзелә башлаган Яңа Кузнецк (Новокузнецк) шәһәренә, әле Урта Азия белән Себерне тоташтыручы Турксиб тимер юлы төзелешенә сәяхәт кылалар. Яңа төзелешләр, яңа тормыш турында ни-нәрсәләр һәм ничегрәк язасы турында фикер алышалар, бәхәсләшәләр. Яңа оешкан милли республикалар тормыш-көнкүреше һәм халкы белән танышу чараларына да зур әһәмият бирелә. Мәсәлән, ул елларда яңа оешкан бер милли республиканың башкаласы булган Казанга гына да язучы һәм журналистлар бер-бер артлы килгәләп йөри. Шулардан иң күренеклеләре, әлбәттә, шагыйрьләр Демьян Бедный, Владимир Маяковский (Казанда ике мәртәбә була), дөнья күләмендә танылган сүз остасы Максим Горький булыр. 1928 елда Казанга килгәндә, ул татар әдәбияты тагын да югарырак иҗади уңышка ирешсен, «үссен» өчен башка милли әдәбиятлар вәкилләре белән ешрак аралашырга кирәклеге турында да искәртә. Олы трибунадан әй-

телгән бу киңәшне Татарстан хөкүмәте җитәкчеләре дә ишетә, әлбәттә. Һәм киләсе елда ук шундый бер зур чара уздыруны максат итеп куялар.

1929 елның август ае башы. Татар язучыларыннан ишле генә төркем Кавказ төбәге республикаларында, Кырымда һәм Украина Совет Республикасында яшәп иҗат итүче каләмдәшләре белән очрашу, фикер алышулар өчен юлга җыена. Төркемдә композитор Салих Сәйдәшев, артист һәм режиссёр Шакир Шамильский, «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарыннан берәр вәкил дә бар. Делегация башлыгы Галимҗан Нигъмәти, юл чыгымнарына дип хөкүмәт тарафыннан бирелгән бик зур сумманы үз чемоданына салып куйган казначы Кәрим Тинчурин, язучылар Шәриф Камал, Гомәр Гали, Һади Такташ, Зариф Бәшири, Кави Нәҗми, Мөхәммәд Гали, Гадел Кутуй һ. б. 10 августта Идел буйлап Әстерхан тарафына таба төшеп китәләр. Кырык көн дәвамында аларны Махачкала, Баку, Тифлис, Батумида, Ялта, Симферополь һәм ул чордагы Украина республикасы башкаласы булган Харьков белән Мәскәүдә күпсанлы шау-шулы очрашулар, дустанә мөнәсәбәттә уздырылган мәҗлесләр көтә.

Дагыстан Автономияле Республикасы башкаласы Махачкалада кунакларны хөкүмәт җитәкчеләре, лезгин халкының олуг шагыйре Сөләйман Стальский, авар шагыйре Гамзат Цадаса (булачак шагыйрь Рәсүл Гамзатовның атасы) һәм бу республикада яшәүче башка халыкларның мәгълүм язучылары каршы ала. Монда татар язучыларын иң гаҗәпләндергәне нәшрият эшчәнлегенә бәйле була. Һәр уңышлы әсәр биредә берьюлы биш-алты телдә нәшер ителә. Кайвакыт шул җирлектә бәхәсләр дә булгалап ала икән. Мәсәлән, нишләп кумык язучысы Абдулла Мөхәммәдев әсәре биш кенә телгә тәрҗемә ителгән дә, лак милләте вәкиле Корбан Алиевнеке алты телдә чыккан, дип... Ул чорда бу республикада балаларны алты милли телдә укытканнар.

Көн исәбе һәм очрашу-аралашулар саны буенча иң дәвамлы кунакчыллык Азәрбайҗан Республикасы башкаласы Бакуга туры килә, билгеле. Россия патшалыгына буйсындырылган дәвердән бирле азәриләрне (аларның күпчелеге үзләрен шулай дип таныта, һәм кайберләре: «Без борынгы Хәзәр каһанлыгының төп халкы булганбыз», – дип сөйли) «Кавказ татарлары» дип йөрттеләр. Димәк, Идел буе татарлары белән бу республика халкы үзен йөз ел чамасы бер дәвердә иң якын кардәшлек хисе белән танып яшәгән. Әдәбиятларыбызның борынгылыгы, Идел буе татарларының азәрбайҗан Низами Гәнҗәви, мирза Фатали Ахундов, Тукаебызның чордашы булган Сабир әсәрләре белән электән таныш булулары да бу якынлыкны арттыра төшкәндер, мөгаен. Россиягә соңрак кушылган бер өлкә буларак, аларны кулдан ычкындырмаска тырышу максатыннан, патша хөкүмәте XIX йөздә үк азәрбайҗан телендә газета чыгарырга һәм театр уеннарын оештырырга рөхсәт биргән. Россия биләмәсендәге төрки телдәге

икенче газета булган «Игенче» Бакуда 1875 елда борын төртә. Ә беренче андый газета 1870 елның апреленнән Ташкент каласында «Төркестан вилаяте гәҗите» исемендә ике атнага бер мәртәбә казах һәм шул ук тәртиптә үзбәк телендә басылган. Азәри Фатали Ахундов – Россиядә төрки телдә иҗат итүче беренче драматург. Азәрбайҗан телендә беренче театр уены тамашачыга 1873 елда күрсәтелә. XX гасыр башыннан азәрбайҗан һәм татар халкы театр әһелләре һәм драматурглары бер-берсе белән аралашып, үзара ярдәмләшеп яшиләр. Язучылар сәфәренә бер ел алданрак кына, 1928 елда, Галиәсгар Камал «Кызыл Татарстан» газетасында «Азәрбайҗан драматургы Мирза Ф. Ахундов» мәкаләсен бастырган була. Бу хәбәр дә хуҗалар күңеленә бик хуш килә. Хәер, алар да кунакларны буш кул белән каршыламый. Шул ук 1928 елда Бакуда Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте аерым китап рәвешендә басылып чыга.

Шушы җирлектә Бакудагы очрашулар бик күңелле үтә. Шагыйрьләрдән Такташ, Кутуй, Кави Нәҗми, Демьян Фәтхи чыгышларын тамашачы аеруча үз күрә. Республика җитәкчелеге С. Сәйдәш карамагына бер оркестр билгели. Берничә көн дәвамында ул оркестр композиторның үзе иҗат иткән көйләрне вә татар халык көйләрен өйрәнә. Һәм ике мең тамашачы җыелган хушлашу кичәсендә Баку театры сәхнәсеннән татар моңнары әсәрләндереп яңгырап тора.

Бу ике Каспий буе республикалары хуҗалары өчен иң олы кунак, әлбәттә инде, Шәриф Камал була. Яшьлегендә бит ул Баку тирәсендәге нефть чыгаручы промыселларда эшләүчеләр белән танышып йөргән, борынгы Дәрбәнт каласы белән Порт Петровский (хәзер – Махачкала) арасындагы бер бистәдә балыкчылар артелендә үз бәхетен эзләп караган. Шул җирлектә соңрак аның «Бәхет эзләгәндә» җыентыгына кергән хикәяләре, «Акчарлаклар» повесте языла.

Грузия башкаласы Тифлиста әдәбият сөючеләргә аеруча Такташ һәм шигырьләрен рус телендә дә мәгънәле итеп сөйләүче Кутуй ошыйлар. «Кунакларны каршы алып һәм озатып йөрүче язучылар төркеменнән Бесо Жгенти белән Такташ бик дуслашып киттеләр. Батумида без пароходка кереп киткәнче култыклашып йөрделәр», – дип искә ала шул сәяхәттә катнашкан әдип Газиз Иделле…

Гадәттә, андый аралашулардан соң, уртак хезмәт җимеше буларак, истәлек язмалары, тәрҗемә әсәрләр барлыкка килүчән. Татар язучыларының беренче зур сәяхәтеннән соң тормышка ашырылган һәм ашырылмый калган килешү-сөйләшүләр байтак була. Мәсәлән, драматурглар, театр җитәкчеләре белән очрашу барышында шул елларда сәхнәдән төшми уйналган «Сәвил» пьесасын (драматург Җәгъфәр Җаббарлы әсәре) – Казанда, ә Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен Баку сәхнәсендә кую планлаштырыла. Ләкин ни сәбәптәндер бу хыял тормышка ашмый

кала. Фәкать 40 елдан соң, 1969 елның май аенда, Татарстанда «Азәрбайҗан әдәбияты һәм сәнгате атналыгы» үткәрелүенә бәйле рәвештә, шул ук авторның «Айдын» пьесасы Казан сәхнәсенә күтәрелә алды. Ә Баку театрында Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» пьесасы һәм чак кына соңрак Шәриф Хөсәеневнең «Әни килде» әсәре сәхнәләштерелде. Соңрак елларда азәрбайҗан теленнән тәрҗемә ителгән унлап китап та дөнья күрде: берничә шигырь тупланмасы, «Азәрбайҗан хикәяләре» җыентыгы, Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» романы. Татар халкының «Өч көлтәгә бер көлтә» дигән әйтеменә туры килгәндәй, Совет хакимияте дәверендә Азәрбайҗанда чыккан китапларыбыз өчләтә-дүртләтә артыграк булса кирәк. Алар арасында Г. Тукай белән М. Җәлилнең шигырь җыентыклары, Г. Бәшировның – «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, берничә күмәк проза һәм шигырь җыентыклары бар. Грузин әдәбиятыннан татарчага беренче тәрҗемә китап 1931 елда чыга. Ул – Д. Чонкадзеның «Сурам крепосте» повесте. 1936 елда бездә «Таулар бөркете Камо» әсәре, ә 1939 елда Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» дастаны тәрҗемә ителә.

Совет хакимияте чорында украин теленнән тәрҗемә ителгән китаплар саны кырыктан ашкан. 1929 елда Харьковта Татарстан кунакларын ике Иван – Кулик белән Микитенко озатып йөриләр. Безнең язучылар Украина җиреннән күтәрелеп чыккан Н. В. Гогольның байтак әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителүен, пьесаларының кат-кат сәхнәләштерелгән булуын сөйлиләр. Т. Шевченконың да кайбер әсәрләренең татарча чыгуын, Г. Ибраһимовның 1914 елда ук аның турында «Каһарман шагыйрь» мәкаләсен язып бастыруын белдерәләр. Һәм шул чакта «Украиннардан кем татар турында язды яки нәрсә дә булса тәрҗемә итте икән?» дигән сорау да бирелә. Бу сорау әле дә сорау булып кала шикелле. Бу очракта «Өч көлтәгә бер көлтә» әйтеме безнең файдага булса кирәк. Дөрес, Украинаның бөек тарихчысы Михайло Грущевский үзенең унөч томлык хезмәтендә байтак урында татарларга карата уңай фикерен белдергән, украин халкының бер өлешенең саф кыпчак кавеменнән булуын раслап язган, диләр. Совет хакимияте дәверендә, бигрәк тә утызынчы еллардан соң, аның хезмәтләренә әһәмият бирелмәде, аны тарих фәнендә телгә алу тыелган иде диярлек. Ә 1926 елгы халык санын алу (перепись) документларында шул чордагы республика чикләренә кергән халыкның дүрттән бер өлеше чамасының үзен «по национальности – половец, по языку – украинец» дип язганлыгын искә алучылар бар. 1966 елда Киев янәшәсендәге иҗат йортында ял иткәндә, Мәхмүт Хөсәен белән миңа шул хакта тарихи эчтәлекле әдәби әсәрләр авторы Василь Земляк белән кинорежиссёр Владимир Денисенко да сөйләгәннәр иде. Ул вакытта алар Киевның борынгы тарихына багышланган кино әзерлиләр, язма хәбәрләргә нигезләнеп,

Батый ханның бер-ике кыш шул шәһәрдә яшәү мизгелләрен дә чагылдырырга ниятлиләр иде.

1929 елгы сәяхәттән соң украинчадан тәрҗемә ителгән беренче китаплар: И. Микитенконың «Намус эше» пьесасы (1932), И. Куликның «Ундүртенче трубка»сы һәм А. Корнейчукның «Эскадра һәлакәте» (икесе дә 1935 елда чыга), Т. Шевченконың шигырь һәм поэмалар җыентыгы «Кобзарь» (1939, 1953) була. Сугыштан соңгы күләмле тәрҗемәләр арасында О. Гончарның «Байрак йөртүчеләр» романы (1951, Ә. Еники тәрҗ.), С. Ковпакның «Путивльдән Карпатка кадәр» документаль әсәре (1948), И. Франконың хикәяләре һәм пьесасы (өч китап: 1951, 1955, 1958), сугыш елларында Татарстанда эвакуациядә яшәгән Л. Коваленконың «Кәләш» повесте (1985) бар.

Мәскәүдә дә Татарстан кунакларын бик җылы каршы алалар. Андагы очрашуларга шул елларда башкалада яшәүче Шамил Усманов, Афзал Шамов, Фатих Кәрими, Мәхмүд Максуд, Мәхмүд Галәү һ. б. кушылалар. «Правда», «Известия», «Литературная газета»ларда очрашу-аралашу вакыйгаларын чагылдырган мәкаләләр басыла. Гадел Кутуй белән «Кызыл Татарстан» журналисты Закир Гали дә башкала газеталарында шушы зур сәяхәткә бәйле хәбәрләр урнаштыралар. Язучылар йортында А. Фадеев, Ф. Гладков, И. Сельвинский кебек шул елларның күренекле язучылары белән һәм Галимнәр йортында Максим Горький белән очрашулар уздырыла. Шул елларның күренекле дәүләт һәм нәшрият эшлеклесе, М. Горькийның якын фикердәше Артемий Халатов кунакларны үзе җитәкләгән «Госиздат» нәшриятына чакырып та китерә. Шушы очрашуларның барысында да диярлек тәрҗемә мәсьәләләре зурдан күтәрелә. М. Горький, А. Фадеев, А. Халатов һ. б. үз чыгышларында татар әдәбиятын рус теленә кичекмәстән тәрҗемә итә башларга кирәклеге турында сөйлиләр. Тәрҗемә эшләрен оештырып җибәрүче комиссия төзү кирәклеге әйтелә. Дәүләт нәшриятында беренче чиратта Г. Ибраһимов әсәрләрен тәрҗемә итеп чыгара башларга тиешлеге турында җитди сүз була. Һәм озакламый ул сөйләшүләрнең нәтиҗәсе дә күренә. Классик әдибебезнең «Казакъ кызы» романы 1934 елда (тәрҗемәнең беренче вариантын автор кире какканнан соң ел, ел ярымнарга соңлап) дөнья күрә. Шушы очрашулар нәтиҗәсендә «Гослитиздат» та татарча берничә китап нәшер итә. Мәсәлән, Ә. Ерикәйнең «Шигырьләр» җыентыгын.

Мәскәүдә милли әдәбиятлар үрнәкләрен нәшер итү өчен оештырылган Үзәк нәшрият (Центриздат) бу елларда бик актив эшли. 1924–1933 елларда бу нәшриятта алтмыш-җитмешләп татар китабы, шул исәптән Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (1924), Ш. Усмановның «Памирдан радио» әсәре һәм хикәяләр җыентыгы, К. Нәҗминең «Яр буенда учаклар» һ. б. әсәрләре, Һ. Такташның бер поэмасы, Ф. Бурнашның дүрт пьесасы — аерым-аерым рәвештә, А. Шамовның «Рәүфә»се, Ш. Маннур-

ның – өч, М. Җәлил, Ә. Ерикәйләрнең берәр шигырь җыентыклары, Г. Нигъмәтинең 5–6 китабы һ. б. үз телебездә нәшер ителә. Шушы ук нәшриятта русчадан һ. б. телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар да дөнья күргән. Мәсәлән, Фёдор Гладковның ул елларда бик популяр булган «Цемент» (1928), «Энергия» (1933) романнары Афзал Шамов тәрҗемәсендә чыкканнар.

## 3

Татар язучыларының күмәкләп беренче тапкыр ил буйлап сәяхәт кылуына, шул очрашу-күрешүләрдән соң ниндирәк нәтиҗәле эшләр башкарылуына озаграк тукталдык. Чөнки шуннан соң андый аралашу мөмкинлекләре утыз елга кичектерелеп торачак. Әүвәл милли әдәбият вә сәнгать вәкилләрен эзәрлекләү, иң алдынгы сафта атлаучыларын күпләп юк итү чоры һәм шуннан соң ук Бөек Ватан сугышы фаҗигаләре башланып китә. Репрессияләр чорында юк ителгән иң күренекле берничә әдипнең исемен дә атап үтик: Г. Ибраһимов, Ф. Кәрими, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Г. Гали һ. б. бик күпләр. Сугыш башлангач яу кырына киткән һәм иленә кире әйләнеп кайтмаган язучыларыбыз исемлегендә дә утызлап фамилия теркәлгән. Шул исәптән М. Җәлил, Г. Кутуй, А. Алиш, Ф. Кәрим, Н. Баян, М. Крыймов һ. б.

Кабат җанлана башлаган аралашу чараларының иң зурысы, әлбәттә, 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате ункөнлеге (декадасы) булды. Бу иҗат бәйрәмендә бик күп артистлар, музыкантлар, рәссамнар катнаша. Язучылар төркеме дә бик ишле була. Яңарак кына сөргеннән кайткан шагыйрь Хәсән Туфан да башкаладагы бәйрәмгә барырга лаеклы дип табыла. Артист, музыкантларның күпчелеге шундагы зур-зур залларда үз осталыкларын күрсәтеп дан-шөһрәт казаналар. Әлегә кадәр булмаганча, Татарстанда эшләүче татар артисты Хәлил Әбҗәлиловка СССРдагы иң зур дәрәҗәле исем – Халык артисты исеме бирелә. Башкалар да шундыйрак олы дәрәҗәле исемнәргә лаек булалар. (Шуны да әйтеп үтик: башка милләт вәкилләренә, шул исәптән казах кардәшләребез артистларына андый зур исемнәр утызынчы елларда ук бирелә башлаган. Мәсәлән, казах халкының беренче опера җырчысы һәм халык җырларын оста башкаручы былбылы саналган Көләч Байсәетевага мондый зур исем 1936 елда ук бирелә. Җырчыга ул вакытта егерме дүрт яшь була.) Язучылар өчен төп бүләк – декадага әзерлек алдыннан нәшер ителгән яңа китаплар, бәйрәм көннәрендә күрсәтелергә дип сайланган сәхнә әсәрләре булгандыр, мөгаен. Декада көннәрендә аларга башлыча орден, медальләр генә бирелә. Беренче мәртәбә үз ана һәм рус телендә басылып чыккан зур күләмле «Татар поэзиясе антологиясе» һәм татар язучыларының биографиясен һәм әсәрләре исемлеген

теркәгән китаплар да бу бәйрәм өстәлен бизиләр («Татар совет язучылары», авторы Асия Гыйниятуллина).

Шушы зур вакыйгадан соң Татарстан язучылары Идел-Урал буе республикаларында яшәүче каләмдәшләре һәм әдәбият сөючеләре белән дә берничә атналык оештыралар. Башкортстан, Чувашстан һәм Мари иле автономияле республикалары вәкилләре дә Казанда, Әлмәттә һәм кайбер районнарда булып китәләр. Күмәк әдәби җыентыклар, аерым активрак авторларның тәрҗемә ителгән әсәрләре бер-бер артлы шушы автономияләр нәшриятларында дөнья күрә. Күрше республикаларда яшәгән классик әдипләрнең иҗатларын алмашып тәрҗемә итеп бастыру хәрәкәте дә җанланып китә. Шул рәвешле чуваш К. Ивановның күләмле «Нарспи» поэмасы – Казанда, Г. Тукай әсәрләренең шагыйрь Я. Ухсай тарафыннан тәрҗемә ителгән китабы Чабаксарда нәшер ителә. Татар-башкорт әдәбиятлары вәкилләре арадашлыгының иң югары баскычка күтәрелгән чоры, мөгаен, нәкъ шушы илленче еллар ахыры белән алтмышынчы елларга туры киләдер. Бу дәвердә үзара тәрҗемә итешеп чыгарылган китаплар исемлеге дә шактый зур. Шулардан фәкать бер китапны – элеккеге «халык дошманы» Х. Туфанның сөргеннән соң башка телдә тәүге тапкыр басылган «Йөрәк дәфтәрләреннән» дип исемләнгән шигырь җыентыгын (Уфа, 1960) атыйм. Башкорт кардәшләребезнең бу мактаулы хезмәте әлегә бездә беркая да теркәлмәгән, 1986 елда чыккан кирпеч калынлыгы «Совет Татарстаны язучылары» белешмәлегенә дә кермәгән.

Башкортлардан кала иң җылы кардәшлек мөнәсәбәтләре, минемчә, татар-казах әдәби бәйләнешләре җирлегендә күзгә ташлана. Безнең ата-бабалар элек-электән казах халкы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Ике халыкка да хезмәт иткән әдәбият-сәнгать әһелләребез дә ишле: журналистлар, җырчылар, акын-шагыйрьләребез... Төркестан генерал-губернаторының җирле милләт вәкилләре белән эш итүче ярдәмчесе Шаһимәрдән Ибраһимов, мәсәлән, 1870 елда казах һәм үзбәк телләрендә беренче газета чыгаруны оештыра, шунда кардәш «нугай», казах һ. б. багышлы хезмәтләрен бастыра. Шаһимәрдән чит илгә дипломат вазифасын үтәргә җибәрелгәч, 1881 елдан аның эшен «нугай морза» Хөсәен Чанышев дәвам иттерә. Шагыйрь Акмулла иҗаты да кардәш халыкларны берләштерүгә юнәлтелгән. Укымышлы яшьләребез дә казах илен үз иткән. Аның шулай икәнлеген без классик әдипләребезнең – Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Сәйфи Кудаш һ. б.ның биографиясен укып та беләбез.

1960 еллар башында Урта Азия республикаларында Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре оештырыла. Иң башлап зур бер делегация Казахстан Союздаш Республикасы башкаласы Алма-Атага юнәлә. Казах илендә туып үскән күренекле шагыйрь Нури Арслан хәтерләвенчә, Свердловскидан Алма-Атага баручы поезд «тулаем безнекеләрне генә төяп бара». Казакъ иленә килеп кергәч

тә, һәр зур станциядә кунакларны бәйрәмчә киенгән-җыенган халык каршы ала. Очрашу митинглары оештырыла. «Хуш килдеңез, бавырлар-карындашлар!» – дигән сүзләр яңгырап тора. Татарлардан ул очрашуларның иң түрендә аксакал язучылар һәм Мәхмүт Хөсәен булганлыгы күпләрнең хәтерендә калган. Трибунадан татарчага казах сүзләрен мул кушып ялкынлы нотыклар һәм шигырьләр сөйләүче «якташ шагыйрьне» җирле халык та үз итеп, алкышлап кабул итә торган була.

Гомуми очрашулардан беркадәр читкә тайпылып, бу сәфәргә бәйләнешле бер вакыйганы искә алып китмәсәм, гөнаһ булыр. Язучылар берлегендә эшләгән елларымда да, соңрак та шул хакта искә төшергәләп алучылар бар иде. Хәзер инде ул сәфәрнең шаһитлары калмады диярлек. 1969 елның көзендә илле-алтмышлап иҗат кешесен – язучы, рәссам һәм композиторларны берләштергән бакчачылык ширкәте оештырылды. Эштән кайтып чәйләр эчкәч, гәпләшеп утыручы ике-өч төркем оешыр иде. Аеруча ике шагыйрь – Нури Арслан белән Зәки Нуриның булачак бакча ихаталары кичләрен гөрләп торды. Алар алмашлап яккан учак тирәсенә ширкәтнең аргы башындагы рәссамнар да килеп чыккалый. Аеруча Лотфулла Фәттахов шунда еш килә иде. Сүз арасына да бик оста кереп китәр иде ул. Әлеге вакыйга минем күңелгә аның сөйләвеннән соң тәэсирлерәк булып сеңеп калган.

Алма-Атага сәфәр вакытында Лотфулла Хәсән ага Туфан белән бер купеда бара. «Ул аста, минем каршыда, мин өстәге киштәдә ятам...» – дип башлар иде ул сүзен. Хәсән аганың, сөргеннән кайтканнан соң, яңа тормышка ияләшеп килгән чагы. Ул төрмә, лагерьларда газап чиккән арада, җәмәгате Луиза үлеп китә. Буй җиткән кызы – Гөлинәсе-Гулясы гына кала. (Хәсән ага кызына һәрчак диярлек «Гуля» дип дәшәр иде. Балалары тугач та, Луиза белән икесе, баланы сөеп-яратып, «Гуля» дип дәшә торган булганнар.)

Сөргеннән кайткач, Хәсән ага, моңсу вакытларда юатыр сүз әйтердәй, кемнеңдер кул җылысын сагынганда кул бирердәй кешенең юклыгына боегып йөргән айларының берсендә, бер ханым белән таныша. Бик сөйкемле, ачык йөзле бер яшь шагыйрә белән. Олы яшьтәге шагыйрьнең күңеле җилкенеп куя. Аңа да бит әле, «олы шагыйрь» булуына карамастан, алтмыш яшь тә тулмаган. Һәм ул очрашу нәкъ менә шушы зур сәфәргә чыгарга санаулы атналар калганда була. «Бу сәфәргә Хәсән ага мәхәббәт утында янган чагында чыгып китә. Без, купедашлары, аның бу халәтен аңлый идек. Аның башкалар белән бик аралашмыйча, гел-гел шигырь, хатлар, телеграммалар язып вакыт үткәрүенә күнегеп беттек. Зур станцияләргә туктаганда да, ул шау-шулы очрашуларда бик катнашмый – тизрәк почта, телеграф тарафына китәргә ашыга. «Алай-болай поездан кала күрмәсен дип, мин аны еш кына озата бара идем, – дип сөйли Лотфулла ага. – Ул моңа

каршы килми иде. Почтадан тагын конвертлар ала да, вагоныбызга ашыгабыз». Ул сәфәрне яхшы хәтерләгән гәптәш шагыйрь һәм язучылар аның сүзләрен хуплап утыралар. «Ай чыга Арча ягыннан» шигыренең тәүге нөсхәсен дә шул сәфәрдә язды шагыйрь, дип өстәп куялар. Ул ашкынып хатлар, шигырьләр язган ханымның адресы да Казанның Арча кыры ягында иде, диләр. (Ул хатлардан, телеграммалардан ни-нәрсә булса да сакландымы икән бу ханымда? Шул озын сәфәрнең шаһиты рәвешендә генә булса да? Болары миңа мәгълүм түгел.)

Казахстанда язучылар күпсанлы очрашу, сөйләшүләрдә катнашалар, зур-зур мәҗлес-банкетларда да булалар. Аерым затлар дус-иш тарафыннан чакырылып, кунак-кунак уйнап та алгалыйлар. Шунда булган кешеләр тагын бер истәлекле вакыйганы еш искә төшерәләр иде. Ул вакытта Казахстан Язучылар берлегенең җитәкчесе, бәге Сабит Моканов була. Тумышы белән казах иленең төньягындагы Петропавел төбәгеннән. Татар шагыйрьләре Н. Арслан белән М. Хөсәенгә якташ... Хатыны Мәрьям дә – шул төбәк кызы, яшьли татарлар белән аралашып үскән. С. Моканов берара Оренбургта, «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә барлыкка килгән рабфакта белем алган. Ягъни икесе дә татар мохитен яхшы белә. Әдипнең вафатыннан соң зур фатирында оештырылган музеенда булганым бар. Китап киштәләрендә татар китаплары да байтак иде. Карандаш тотып, билгеләр куеп, сүз-җөмләләр теркәп укылган шундый берничә китапны кулга тотып караганым да булды. Мохтар Әүэзов музей-йортында да шундый ук хәл: эш бүлмәсендәге китап киштәләрендә татар китаплары мулдан иде, диварларга эленгән фотолардан таныш йөзләр дә карап тора. Мондый күренешне мин үз әдипләребездән Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов һәм Тәүфыйк Әйди китапханәләрендә генә очраткаладым.

Инде әлеге вакыйгага кайтыйк. Зур мәҗлес-банкетларда түр өстәлнең уртасында – ирле-хатынлы Сабит һәм Мәрьям Мокановлар, алар тирәсендә ике республика җитәкчеләре һәм төрле дәрәҗәдәге түрәләр утыра, билгеле. Бу зур өстәл тирәли – кунаклар өчен куелган табын өстәлләре. Бу мәҗлесләрне искә алучылар хәтерләвенчә, шундый утырышларның берсе тәмамланырга якынлашып килгәндә, юкарак гәүдәле, кечерәк буйлы Сәрвәр Әдһәмова кемнән дә булса рөхсәт-фәлән сорап тормастан торып баса да бар куәтенә казахның бер моңлы көен җырлап җибәрә. Халык тын калып тыңлый, аннары бик озаклап кул чабалар. Һәм кул чабулар тынып өлгермәстән, түр өстәле тарафыннан саф татарча җырлаган аваз яңгырый башлый. Баштарак кунакларның күбесе аптырап кала: кием-килеше, үзен тотышы белән әлегәчә казах хатыны булып йөргән Мәрьям бикә җырлый икән бит. Әлбәттә, хуплап, данлап, озаклап, аңа да кул чабалар. Һәм ул кичтә бу дуэт берничә мәртәбә кабатлана. Шуннан соңгы кичәләрдә дә бу күренеш булгалап ала. Ике кардәш халыкның

элекке вакытларда никадәр якын булганлыгына тагын бер дәлил ич бу!

Татар әдәбиятын рус әдәбиятыннан кала башка телгә күп итеп тәрҗемә кылучылар да казах кардәшләребез булды. Сугыштан соңгы чорда ул республика нәшриятлары һәр ел саен икешәр-өчәрдән дә ким санда булмаган күләмдә татар китапларын бастыра иделәр. Театрларында да безнең авторларның пьесалары еш сәхнәләштерелде. Бездә исә шул дәвердә егерме бишләп күләмле әсәр тәрҗемә итеп бастырылды. Революциягә кадәр бу өлкәдә өстенлек безнең якта була. XIX гасыр урталарыннан иҗат итә башлаган казах әдәбияты классигы Абай Конанбаевның икенче шигырь җыентыгы 1916 елда Оренбургта, бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә, өченчесе 1922 елда Казанда басылган. Шигырь-поэмаларының тулырак татарча җыентыклары 1947 елда М. Максуд тәрҗемәсендә һәм 1981 елда күмәк тәрҗемәдә («Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз») басылып чыктылар. Казахның беренче романы «Бәхетсез Җамал» (авторы Миржакып Дулатов) 1910 елда, Казанда, беренче повесте «Күргенде (тәрбияле) бала» (авторы М. Нурбаев) Оренбургта «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргән. «Вакыт» басмаханәсе ул елларда казахча сигез китап бастыра, дип хәбәр итә академик Ә. Кәримуллин. М. Дулатовның казах илендә зур абруй казанган, «Уян, казакъ!» дип исемләнгән шигырь җыентыгы да 1909 елда Казанда басылган. Узган гасыр башында «Яшь казакъ» хәрәкәтен оештырган, түнтәрешләрдән соң беренче Казах Совет автономиясенең җитәкчеләреннән берсе булган Сакен Сәйфуллинның тәүге шигырь җыентыгы да 1914 елда Казанда дөнья күрә.

Үзбәк кардәшләр белән арадашлык мөнәсәбәтләре башкачарак оешты. XX гасыр башында уртаклыклар күбрәк булуга карамастан, сугыштан соңгы дәвердә алар безнең әдәбиятны кимрәк тәрҗемә итте шикелле. Без дә аларның өч көлтәсенә бер көлтә белән генә җавап бирдек. Ләкин шунысы хак: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Муса Җәлил, Шамил Усманов, Гомәр Бәширов кебек күренекле әдипләребезгә игътибарлары зур булды. Тукайның кечерәк күләмле иң тәүге русча җыентыгы да иң әүвәл үзбәк кардәшләребез илендә – Ташкентта басылып чыга (1920).

Казахстанга сәяхәттән соң бер елдан Казах әдәбияты һәм сәнгате көннәре Татарстанда уздырылды. Шул вакыйгага багышлап, Казанда «Дала җыры» исемендә күмәк җыентык нәшер ителде (1964). Казах язучылары белән очрашулар республиканың төрле районнарында да үткәрелде. Күп еллардан соң казахның күренекле шагыйре Олжас Сөләйманов, ул көннәрне искә алып, болай дип сөйләгән иде. Ул декада вакытында яшь шагыйрь татар халкының данлы шәхесе Хәсән Туфан белән бер төркемдә йөри. Хәсән аганың кайбер казах акыннары шигырьләрен ят-

тан хәтерләве аны аеруча сокландыра. Казаннан ерак булмаган Шәле авылының җәйләвендә очрашудан соң, алар ниндидер бер күл буенда бик озак сөйләшеп, серләшеп йөриләр. «Җәйге матур төнне без ул вакытта аксакал шагыйрь Хәсән Туфан белән гәпләшеп уздырдык. Шунда мине иң гаҗәпләндергәне – татар илендә таңның бик иртә атуы булды. Шәле җәйләвендә аксакал белән аерылышканда, сәгать өч тулмаган иде – иртәнге шәфәкъ калыкты», – дип искә алган иде Олжас Сөләйманов бер очрашу вакытында. Олжас туып үскән Алма-Ата тирәлегендә, шулай ук безгә кардәш халыклар яшәгән үзбәк, кыргыз, каракалпаклар илендә кояш алай иртә калыкмый. Аларда җәйге иң кыска төн дә, кышкы иң кыска көн дә тугыз сәгать чамасын тәшкил итә. Безнең төбәктә алар җиде сәгатьтән артмый. Шуңа күрә дә инде Азәрбайҗан халкының бөек шагыйре Низами Ганҗәви үзенең мәгълүм әсәрендә безнең Идел буе төбәкләрен «караңгы як» дип телгә ала да. (Русчага тәрҗемәдә әсәрнең ул бүлеге «В стране мрака» дип бирелгән.)

1960 еллар белән 1980 еллар арасында Татарстанда бик тантаналы рәвештә Азәрбайҗан Союздаш Республикасы (1969), Кыргызстан (1972), Украина Республикасының Донецк өлкәсе (1972), Үзбәкстан Республикасыннан Каракалпакстан автономиясе (1981) әдәбияты һәм сәнгате көннәре, Совет әдәбияты атналыгы (1979), Идел буе өлкә һәм республикаларында Максим Горький иҗатына багышланган очрашулар (1978) уздырылды. Шул ук елларда безнең язучылар һәм сәнгать әһелләре Кыргызстанда, Донбасс шәһәрендә (1972), Каракалпакстанда (1979) булып кайттылар. Каракалпакстан язучылары белән арадашлык вакыйгаларына багышлап, Ташкентта һәм Нөкистә татар хикәяләре тупланмалары (1979), Казанда күләмле «Арал дулкыннары» исемендә каракалпак әдәбияты антологиясе (1981) нәшер ителде.

1976 елның декабрендә бер атна дәвамында Казанда бер төркем чит ил язучылары да булып китте: Венгрия, Көнчыгыш Германия, Монголия, Норвегия, Төркия, Финляндия, Чехословакия, Швеция вәкилләре. Килүчеләрнең төп максаты – татар әдәбияты үрнәкләрен чит илләрдә бастырып чыгару һәм пропагандалау буенча фикер алышу иде. Бу очрашуны СССР Язучылар берлегендә тәрҗемә әдәбият мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бюро оештырды. Чит ил язучылары белән бергә Казанга шул бюроның җитәкчесе – шагыйрь якташыбыз Вил Ганиев, СССР һәм РСФСР Язучылар берлегендә төрле республикалардагы әдәби оешмалар белән элемтә тотучы вәкилләр дә килде. Кунаклар исемлеге һәм барлык очрашу, эш тәртибе язмалары миндә сакланган. Венгрия, Норвегия, Финляндия һәм Төркиядән килүче язучыларның нияте зурдан булуы, татар әдәбиятын үз илләрендә пропагандалауга чынлап керешәчәкләре аларның бәйләм-бәйләм татар китапларын, татар җыр-моңнары язылган пластинкаларны сорап һәм сатып алуларыннан билгеле иде. Чынлап та, тиздән Венгриядә

татар әдәбияты белән кызыксыну нәтиҗәләре күренә башлады. Язучылар берлегенә татар повестьларыннан һәм хикәяләреннән торган җыентык туплап җибәрүне үтенгән хат та килде. Ул җыентыкны оештырып Венгриягә җибәрү бурычы да миңа — тәрҗемә секциясе җитәкчесенә тапшырылган иде. Венгр телен өйрәнеп, венгр һәм татар әдәбиятын тәрҗемә итәргә сәләтле булган берәүне укырга җибәрү мәсьәләсе дә шул көннәрдән соң хәл ителде. Озакламыйча бу җитди вазифаны үтәү бурычы шагыйрь Равил Бохараевка йөкләнде. Ул Венгриягә укырга җибәрелде.

1980 елларның икенче яртысыннан башлап СССРда әдәбият вәкилләренең арадашлык хезмәтчәнлеге сүлпәнәя төште, һәм озакламый ул эшчәнлек тәмам туктатылды.

Әдәбиятлар дуслыгы бәйрәмнәре, үзара аралашу, фикер алышу чаралары зурлап уздырылган елларда татар язучыларыннан Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин кебек шәхесләребез ул чараларда бик актив катнаштылар. Көн баешындагы Киев, Минск, Калининградлардан башлап, Ерак Көнчыгыштагы Камчатка, Сахалиннарда яшәүче күпсанлы милләттәшләребез белән яшәгән урыннарында очрашулар оештырылды. Анда яшәүче якташлар белән аралашкан, милләттәшләребезгә Татарстан хәбәрен ирештергән шәхесләр дә башлыча шулар булды. Шул хакта аларның байтак кына истәлек язмалары соңрак үзебезнең матбугат битләрендә дөнья күрде.

Якын киләчәктә дә бер-беребез белән шулай күрешеп, уртак уңышлар өчен бергәләшеп сөенешеп яшәргә насыйп итсен Ходам.

Соңгы сүз итеп Гази ага Кашшаф сөйләгән бер истәлекне китереп китәсем килә. Үзбәкстанда Татар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган ункөнлек бара. Шул вакытта аны һәм тагын ике-өч язучыны бер әдип үзенә кунакка алмакчы була — мәшһүр әмир Аксак Тимергә багышлап роман-трилогия иҗат иткән Сергей Бородин. «Йөзе таныш та кебек, ләкин кайда һәм кайчан очрашканыбызны хәтерләмим. Елмаеп каршымда бераз басып торгач та, бу әйтә: «Әмир Сәгыйтьҗан дустыңны әллә онытгың дамы?» — ди. Әйе, Казанга, безнең язучыларның I съездына кунак буларак килүчеләр арасында шул исемдә йөрүче дә була шул. Ул көннәрдә без аның белән бик дуслашып калган идек. Ә соңыннан бер дә очрашырга туры килмәде. Сугыш башлангач, ул Мәскәүдән Ташкентка күченеп киткән. Атасының исем-фамилиясе белән яза башлаган икән». Әйе, Сергей Бородинның әнисе татар. Биографияләрендә ул андый фактны яшерми яза. Әдәбиятка килгән елларында алган псевдонимы да анасы фамилиясенә бәйле икән. Атасы, бәлки, яһүдиләр динен тотучы караим-фәлән булгандыр. «Сәгыйтьҗаныбызның өенә килсәк — тагын бер сөенеч. Хатыны Рауза да безнең милләт кешесе икән ич. Ул Чыңгыз Айтматовның анасы белән бер шәһәрдән, Кыргызстаннан икән», — дип сөйләгән иде Гази ага.

Шундый ук тагын бер хатирәле очрашу 1970 елларда Киевта була. Безнең берничә язучы Украина башкаласында булганда, Мөхәммәд Садрины ул елларда зур данга ирешкән әдип Михайло Стельмах аерым чакырып кунак итә. Сугыш елларында алар (һәм шагыйрь Гали Хуҗи) фронт газетасы урнашкан вагоннарда берничә мең чакрым юлны бергә узганнар икән. Күпме сугыш-бәрелешләрдә катнашканнар. Безнең шагыйрьләр ул фронт газетасының татар телендәге нөсхәләрен нәшер итсә, М. Стельмах исә аның украин телендәгесен чыгарган була.

Әйе, телләр аерым, гореф-гадәтләр үзгә булса да, ул елларда без – татарлар, үзбәк, казах, украиннар, шул исәптән барлык «Кавказ татарлары» да – бер-беребезгә якынрак, үзебезчә дус, тату яшәдек шул. «Базар мөнәсәбәтләре» чорына кергәч кенә, үзара аралашуны оныта башладык шикелле.

*2009*

# ӘДӘБИ ҺӘМ ТАРИХИ БАГЛАНЫШЛАРНЫ КИҢӘЙТИК

*(Очерк)*

Совет хакимияте елларында СССРның төрле төбәгендә яшәп, төрле-төрле телләрдә иҗат итүче язучылар белән аралашу тәртибе җайга салынган иде. Чит республикаларда иҗат ителгән, күпмедер дәрәҗәдә милләтебез язмышына да кагылышы булган байтак кына әсәрләр ул елларда үз газета-журналларыбызда да басыла килделәр. Әйтик, күренекле казах шагыйре, Абай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Җобан Молдагалиевнең Муса Җәлил язмышын чагылдырган күләмле «Үлемсез җыр» поэмасы, Габдулла Тукай әсәрләренең өч басмасын казах телендә туплап чыгарган Сагынгали Сәетовның ике кардәш халыкның әдәби-мәдәни казанышлары турындагы мәкаләләре, шулай ук Абай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрь Сырбай Мәүләневнең «Җырлы Казан» дип исемләнгән күләмле очеркы, СССРның Дәүләт бүләге иясе Евгений Евтушенконың «Казан университеты» поэмасы шул еллардагы уртак казанышыбыз мисалы була ала. Бөек Ватан сугышыннан соңгы дәвердә андый әдәби багланышлар киң колач алган иде, мисалга китерердәй үрнәкләр дә бик күп.

Чит төбәкләрдә, шул исәптән байтак кына чит ил-мәмләкәтләрдә яшәп ятучы милләттәшләребезнең тормышын, яшәешен чагылдырган күпсанлы очерк вә мәкаләләр «Казан утлары», «Азат хатын» мәҗмугаларында даими рәвештә күренә тордылар. Бу өлкәдә мәрхүм Тәүфыйк Әйдинең казанышлары бигрәк тә зур булды. Ул безне казах, үзбәк кардәшләребез әдипләренең үр-

нәкләре белән даими рәвештә таныштыра торды. Ә туксанынчы еллар башында исә татар һәм төрек әдәбиятлары багланышларын чагылдырган бик җитди гыйльми хезмәте дә «Казан утлары»нда дөнья күргән иде. Шул ук елларда кардәш әдәбиятлар вәкилләреннән ике күренекле галимнең – Бөркет Исхаков белән Шерали (безнеңчәрәк итеп әйткәндә Арслангали) Турдыевның кардәш милләтләр арадашлыгына бәйле хезмәтләре дә даими рәвештә бездә һәм Казахстан белән Үзбәкстан матбугатында дөньяга чыга тордылар. Азәрбайҗан республикасында милли әдәбиятлар арадашлыгына багышлы хезмәтләре белән күренекле галим Габит ага Бабаев дан казанды.

Туксанынчы еллардагы үзгәрешләрдән соң әдәби бәйләнешләр берара тәмам тынып торды дияргә була. Үзара бәйләнешләрне ныгытуга багышланган, дөньяга чыгарга әзер булган берничә күмәк җыентыкның вакытында чыкмый калуы да – шул заман афәте. Мәсәлән, Мәскәүдә, «Современник» нәшриятында, совет дәвере татар повестьларының ике томлыгы нәшер ителергә тиеш иде. Егерменче-илленче еллар аралыгында иҗат ителгән шундый әсәрләрне эченә алган беренче томның корректурасы килгәч (ул Тольятти шәһәре басмаханәсендә басылган иде), СССР таркалу сәбәпле, ул китапларны нәшер итү туктатылды. Шундый ук бер томлык әсәрләр тупланмасы казах телендә дә әзерләнеп беткән иде. Казахстан күмәк йортыбыздан аерылып чыккач та, ул китапның киләчәк язмышын кайгыртучы булмады. Тәрҗемә ителгән әсәрләр бергә тупланып чыгарылмыйча, Алма-Ата басмаханәсендә «ятып калды». Әйе, безнең «яңа» илдә дистә ел чамасы әдәбиятлар арасындагы арадашлык мәсьәләләренә әһәмият бирелмәде. 1990 еллардан башлап әдәби тәрҗемә тармагы онытылган иде диярлек.

Фәкать соңгы елларда гына әдәбиятларның үзара багланышларын даими яңартып торган тәрҗемәче-арадашчы хезмәтенә әһәмият бирелә башлады сыман. Бу өлкәдә эшләүче яңа исемнәр калыкты. Мәсәлән, казах шагыйрьләренең кайбер әсәрләрен Флёра Тарханова, Рафис Корбан бүгенге заман укучысына тәкъдим иткәли башладылар. Күренекле әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов даими рәвештә диярлек кардәш әдәбият галимнәре һәм әдипләре белән аралашып яши. Ике тугандаш халык матбугатында да аның хезмәтләре даими рәвештә басыла тора. Мәрхүм Равил Бохараев та милләтара арадашлык өлкәсендә зур эшләр башкарып калдырды. Татар әдәбияты үрнәкләреннән кайберләрен чит илләрдә инглиз һәм венгр-мажар телләрендә бастырып тарата алды.

Бүгенге көндә татар әдәбиятын чит телләргә тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә аерым уңышларга ирешкән тәрҗемәчеләрдән Лилия Газизова, Фатих Котлы, Гәүһәр Мәһдиева-Хәсәнова, Асия Рәхимова, Булат Хәмидуллиннарны билгеләп үтәргә кирәктер. Китерелгән исемлектәгеләрнең өчесе татар әдәбияты үрнәкләрен

рус мохитенә таныту өлкәсендә байтак эш башкарган булсалар, Асия белән Фатих исә төрек телендә иҗат ителгән китапларны – үз телебездә, татарчаларын төрекчәгә тәрҗемә итеп бастыру өлкәсендә танылдылар. Асия Рәхимованың иң беренче, иң зур хезмәте – татарның мәшһүр шәхесе, «ак эмигрант» Габделбарый Батталның тарихи-иҗтимагый эчтәлекле «Казан төркиләре» китабын 1996 елда иленә кайтаруы булгандыр. Әдип һәм тарихчы Г. Батталның бу китабы 1925 елдан башлап Төркиядә өч мәртәбә дөнья күрә. Аның соңгы басмасы Истанбулда 1998 елда – авторы гүр иясе булганнан соң кырык ел үткәч басылып чыкты. Бу хәл инде әлеге китап авторы фикерләренең «үлмичә яшәве» турында сөйләүче факт буладыр. (Кызганыч ки, «Әдипләребез» исеме белән нәшер ителгән энциклопедик хезмәттә Г. Батталның Финляндия белән Төркиядә кырык ел яшәгән чорына караган иҗаты бөтенләй дә теркәлмәгән диярлек.) А. Рәхимова «саф төрек» әдипләре әсәрләрен дә актив тәрҗемә итә. 2009 елда ул Нәҗип Фазылның «Мәрхәмәт» пьесасын аерым китап рәвешендә бастырып чыгарды.

Тумышы белән төрек булган, соңгы елларда Казанда яшәгән язучы Фатих Котлы да ике милләт, ике әдәбият вәкилләрен үзара якынлаштыру, бер-берсе белән таныштыру өлкәсендә зур эшләр башкара. Аның тәрҗемәсендә Төркиядә инде берничә татар китабы басылып чыкты. Шулардан иң уңышлысы, кардәш төркиләр тарафыннан бик тә хуплап кабул ителгәне – татар халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте тәрҗемәседер. Бүгенге көндә ул китап Төркиядә биш мәртәбә нәшер ителгән. 2011 елда Ф. Котлы шул хезмәте өчен Төркиянең иң югары әдәби бүләгенә лаек дип табыла. Каләмдәшебез Ф. Котлы тәрҗемәсендә шушы елның башында Аяз Гыйләҗевнең тагын бер күренекле әсәре – «Җомга көн, кич белән» повесте да нәшер ителде.

Татар-төрек җәмгыятьләрен татар һәм төрек шигърияте үрнәкләре белән даими рәвештә таныштырып бару өлкәсендә Төркиядә яшәүче шагыйрә Чулпан Зарифның да өлеше зур. Төркиядә ул шулай ук узган гасырның атаклы шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Рәмиевкә багышланган җитди фәнни хезмәтен дә бастырып чыгарырга өлгерде. Киләчәктә дә аның шулай армый-талмый ике кардәш халык әдәбиятын берләштереп иҗат итүен теләп калам.

Башкарылган эшләрне барлап, хуплап чыгу күңелле хәл, әлбәттә. Озакка кичектермичә, киләчәктә үтәлергә тиешле эшләр турында да үз фикеремне белдереп китим.

Төрки әдәбиятлар күген балкытып алган әдип Орхан Памук исеме барлыгын ишетеп беләбез. Берничә ел элек аның иҗаты дөньяның иң мәртәбәле бүләгенә – Нобель исемен йөртүче премиягә тәкъдим ителгән иде. Ул бүләк аңа шул елда ук бирелде дә. Әсәрләре тупланмасының Мәскәүдә рус телендә нәшер ителгәнлеге турында да хәбәрләр булды. Татарча чыгарырга лаек дип

тапсак, әлбәттә, безгә аның әсәрләрен төрекчәдән тәрҗемә итү мәслихәттер. Шундый эшкә кемебез алыныр икән соң? Орхан Памукның әлеге югары бүләккә ия булуына да ун еллап вакыт үтте инде. Бездә әлегә аның бер генә әсәренең тәрҗемәсе дә нәшер ителмәде бугай.

Тәрҗемә өлкәсендә эшләүче каләмдәшләремә, саф әдәби әсәрләрне бераз читкә куеп, үзебезнең тарихны барлауга юнәлтелгән кайбер җитдирәк хезмәтләргә дә игътибар итүләрен теләр идем. Һич югы Төркиядә яшәп, төрки халыклар тарихын барлауга багышланган хезмәтләре белән танылган үз якташларыбызның шундый юнәлештәге эшләрен генә булса да үзебезгә кайтару кирәктер, шәт. Андый хезмәтләр Садри Максуди, аның кызы Гадилә (Адилә) Айда, Габделбари Баттал, Зәки Вәлиди һ. б. күренекле якташларыбыз мирасында күп ич. Болары әле – безнең чорга якын тарихка бәйле хезмәтләр. Әйтик, беренче чиратта Садри Максудиның утызынчы елларда дөнья күргән, скифларга багышлы «Эскитлар-сакалар», «Урта Азиянең төрки дәүләтләре» хезмәтләре, кызы Гадиләнең – күренекле дипломат һәм галимәнең – тарих фәнендә әле тулаем чишелмәгән, бәхәсле бер теманы яктырткан «Этрусклар (турсакалар) төрки иделәр» (1971, 1992) китабын һ. б. хезмәтләрен илебезгә кайтару зарур, минемчә. Истанбул университеты профессоры Гадилә Айданың бу китабы 1985 елда француз теленә дә тәрҗемә ителгән.

Ә безгә ул хезмәтләр бик кирәк. Совет чоры тарихчыларының төрки-татарларны фәкать Монголиядән чыккан бер надан күчмәннәр дип тасвирлавына каршы куярлык дәлилләр җитәрлек ич. Аларны да дөньяга чыгарырга бик вакыттыр. Хәзерге Испания җирләрендә җиде йөз ел яшәгән мөселман дәүләте – Кордова халифәте чорында Дон белән Идел елгалары аралыгында гомер итүче төрки халыклар тормышы белән кызыксыну бик көчле була. Испаниядән биш мең чакрым чамасы ераклыктагы бу төбәк яшәеше һәм халкы белән кызыксынган берничә экспедиция килә. Бу төбәктә яшәүчеләрнең милли чыгышына, көндәлек тормышына багышланган җитди генә истәлек язмалары тудырыла. Мәсәлән, бер галимнең дүрт китабы фәкать төркиләргә генә багышланган була. Шул хезмәтләрнең берсендә кайсы төрки кавемнең кайсы төбәктә яшәгәнлеге дә тасвирланган дип искә алалар. Билгеле, андый хезмәтләр без яшәгән чорда рус теленә дә, СССРда гомер итүче башка халыклар теленә дә тәрҗемә ителмәде. Шундый хезмәтләрнең кайберләре бүген дә Мисыр, Төркия дәүләтләре китапханәләрендә саклананалар дигән хәбәрләр бар. Рус теленә тәрҗемә итеп чыгарылганы да бар. Мәсәлән, Әбү Хәмид Мөхәммәд ибне Габдерәхим әл-Андалуси (1080–1170) Идел буе Болгар дәүләтендә дә яшәп киткән. Болгарларга күрше булып яшәгән милләтләр тормышы белән дә кызыксынган. Славяннар турында да кызыклы гына мәгълүмат туплаган булган. Аның шул вакыйгаларны чагылдырган бер хезмәте 1971 елда Мәскәүдә «Наука»

нәшриятында басылып чыккан иде («Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу»). Испаниядән килеп, төрки-татарлар тормышы белән кызыксынучы башка галимнәр дә булган. Ләкин аларның хезмәтләре әле безнең илдә тәрҗемә ителмәгәннәр.

Ә Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез язмышына һәм яшәешенә багышлы хезмәтләр соңгы елларда ешрак күренә башлады. Бу өлкәдә аеруча актив эшләүчеләрнең иң алгы сафында, әлбәттә, әдип һәм тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова тора. Каләмдәшем Айдар Хәлим дә аңардан калышмаска тырыша. Күптән түгел ул Америкада булып кайтты, анда яшәүче милләттәшләребезгә багышлап, истәлекләрен язды. Яңа оешып килүче «Түгәрәк уен» мәҗмугасы мөхәррирләре һәм авторлары да бу өлкәдә зурдан эш башларга торалар шикелле. Мәҗмуганың әлегәчә дөнья күргән саннары күңелдә шундый өмет уята. Милли телевидение вәкилләре дә соңгы җиде-сигез елда бик зур эш башкарды. Бүгенге көндә аларның архивында Польша Республикасыннан алып ерак Сахалингача таралып яшәгән татарлар тормышын чагылдырган бик бай, бик тә үзенчәлекле язмалар тупланган. Һәм шунысы куандыра: «Татарлар» тапшыруында да, «Халкым минем» язмаларында да бер генә дә мескен, бетешкән татар авылын күрмәссең. Андый мескен авыллар, шулай мескен булып яшәүче милләттәшләребез бөтенләй үк юктыр дип фаразлый алмыйм. Ләкин андыйларның азчылык булуында шигем юк. Татарның күпчелеге бүген дә «кешечә яшәргә кирәк» дип тырыша һәм шулай яшәү өчен мөмкинлеген эзли, һөнәр үзләштерә. Экраннан күрсәтелгән күпчелек авылларның, һәм ул авыллардагы йортларның төзеклеге күңелне сөендерә.

Төп хыялым, зур хыялым – киләчәктә дә үзара аралашып, бер-беребезнең иҗат үрнәкләрен алмашып, тәрҗемә итешеп яшәргә насыйп булсын. Гарәп телендә аралашучы илләр белән дә, Европаның инглиз теленнән кала испан, француз телләрендә иҗат итүче каләм осталары белән дә чын ярышка чыгасы бар әле безнең. Төрки телләрнең кайбер үзенчәлекләренә хас үзенчәлекләре һәм аерым сүз, төшенчәләр тәңгәллекләре сакланган кытай, япон телләре дөньясына да күптән үтеп керергә тиеш идек инде без. Кытай теленең борынгы «сандыкларында» халкыбызның, дөресрәге, күпчелек төрки кавемнәрнең тарихи эзе дә сакланадыр дип беләм. Шундый ук хәлне әрмән илендә дә күзәтергә була. XX гасырның егерменче елларына чаклы «дала ягы» әрмәннәре ярым әрмәнчә, ярым төркичә аралашканнар. Чөнки аларның асыл бабалары чукынган болгар, бәҗәнәк һәм кыпчак кавемнәреннән булган. Совет чорында «Советская тюркология» журналында тел галиме, Гукасян фамилияле кешенең байтак кына кызыклы хезмәтләре басылды. Күп кенә күренекле классик әдипләрнең дә ярым төркичә, ярым әрмәнчә язылган әсәрләреннән үрнәкләр дә китерелә иде Гукасян хезмәтләрендә. Совет чоры-

ның күренекле әдибе Мариэтта Шагинян да кайчандыр «Новый мир» журналында басылган истәлекләрендә Дон буендагы Ростов шәһәре янәшәсендәге Нахичеван бистәсендә яшәгән кардәшләренең үзара ярым төркичә сөйләшкәнлекләрен бәян итә. «Әниемнең апалары өйдә төркичә генә сөйләшәләр иде», – дип яза балачак истәлекләренә багышланган күләмле шул хезмәтендә бу галимә. Аш өстәлендәге ризыкларының байтагы безнең ризыкларны хәтерләтә ул язмада. Безнең галимнәргә дә әрмән теленә, борынгы әрмән тарихи язмалары сакланган мирасханәләргә әһәмият бирә башларга бик вакыттыр. Дөрес, 1960–1970 елларда Әдәбият, тарих һәм тел белеме институты галиме Искәндәр Абдуллин төрки телдә әрмән дине тәртипләренә багышлап язылган табылдык кульъязмалар турында берникадәр мәгълүмат ирештергән хезмәтен шул институтның бер җыентыгында язып чыккан иде. Әмма ләкин шуннан соң ул теманы тирәнтенрәк өйрәнүгә керешелмәде шикелле. Шушы ук темага кагылышлы бер очрашуны да искә алып китим. 1965 елның октябрь ахырларында мин язучыларның Кырымдагы иҗат йортында булган идем. «Күктүбә» дип йөртелгән борынгы бер татар авылы урынында – һава күге белән диңгез күге бергә тоташып торган, табигатьнең бик үзенчәлекле бер урынында. Берничә көннән соң безне, Кырымның тарихи урыннарын күрсәтергә дип, экскурсиягә алып бардылар. Ул сәяхәттә без Татарстаннан ике татар – ике Хәмидуллин һәм Башкортстан татары – шагыйрь Рафаэль Сафин бар иде. Әмма иң зур төркем Ленинградтан булып чыкты. Алар унике кеше, шул исәптән «Звезда» мәҗмугасы редакторы Леонид Хаустов, әдәбиятчы галим һәм шагыйрь Сергей Малахов һ. б. бар иде. Малахов «бабай» белән шул көннән дуслашып та киткән идек. Чөнки Феодосия шәһәренә килеп төшүгә күземә чалынган тарихи эчтәлекле китапны – «Звучат лишь письмена»ны мин шунда сатып алдым. Аның авторы Сергей Малаховның кияве икән. Икесе дә – Ленинград университетын тәмамлаган шәхесләр. Кияү Хакасиядәме, Тувадамы төрки гаиләдә туган галим икән. Әлеге китапта ул хәзерге Монголия җирләрендә гомер иткән тангут кабиләсе турында яза. Тангутлар үз чорына караганда бик алга киткән кабилә булган, аларның үзенчәлекле язма мирaслары бераз сакланган, дип хәбәр итә автор.

1980 еллар башында ике монгол язучысы һәм галиме белән очрашканда да, әлеге китап искә төшкән иде. Бу ике монгол Мәскәүдә, Фәннәр академиясе карамагындагы ниндидер курсларда укыганнар да, илләренә кайтышлый, «кардәш» татарлар илен дә күреп китмәкче булганнар икән. Аларга Казанны күрсәтү, ашату-эчертү кебек бурычлар Мөсәгыйт Хәбибуллин белән минем өскә йөкләнгән иде. Бер сөйләшеп утырганда, мин кайчандыр «юкка чыккан» тангутлар кабиләсен дә искә алдым. Төгәл генә җавап бирмәделәр. Әмма Монголиядә бик сирәк галимнәргә генә керергә рөхсәт ителгән мирасханә барлыгын әйттеләр. «Кытай-

лар да андагы язмалар белән бик кызыксына. Ул бик борынгы язма мирасны үзләренә алып китмәкче булалар. Әмма безнең җитәкчелек анда сакланган хезмәтләрне бирәүгә дә бирмәскә дигән фикердә тора әлегә. Үзебезнең галимнәрдән дә анда бик-бик ышанычлыларын гына кертәләр», – дип сөйләгәннәр иде.

Әйе, безнең борынгы бабаларыбыз тормышына теге яки бу рәвешле бәйле булган тарихи мираслар төрле тарафта саклана да кебек. Еллар үткән саен берәм-берәм юкка чыга барганнары да бихисаптыр, әлбәттә. Безнең буын тарафыннан барланмаган, андый барлауларга мөмкинлек булмаганлыкны истә тотып, киләчәк буын вәкилләренә мондый тарихи чыганакларның мөмкин кадәр күбрәк үзебезнең илгә кайтарылуын һәм ике дәүләт теленең берсенә тәрҗемә ителүләрен теләп калам.

*2017*

# ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР

*(Очерк)*

I

Үзенчәлекле шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә багышланган зур фотоальбомга материал туплау нияте белән 1994 елның җәендә без Оренбург якларына барып чыккан идек. Юлдашым – күренекле фотограф, күптән түгел генә «Габдулла Тукай» альбомын нәшер итүдә төп вазифаны үтәгән Зөфәр Гомәр улы Бәширов. Билгеле инде, Оренбург төбәгендә атаклы шагыйрьнең балачагы эзләрен саклаган Җиргән, Юлык авылларын да читләтеп үтмәдек. Бераз соңрак шагыйрь яшәгән Орск, Баймак шәһәрләренә, Чиләбе өлкәсендәге Балкан авылына да бардык.

Әлбәттә, сәяхәтебез көндәлегенә Оренбург шәһәре янәшәсендәге бай тарихлы Татар Каргалысына бару да теркәлгән иде. Бертуган Рәмиевләр монда бик еш килеп-китеп йөргән. Шакир Рәмиев хатыны «Гәүһәр абыстай» Оренбург кызы исәпләнсә дә, аның ата-аналарының тамыры шушы авылга бәйле була. Дәрдемәнд «зәүҗаны» Мәһүбҗамал да бу «зыялы каланы» үз иткән – узган гасыр башларында монда «Рәмия» исемендәге кызлар мәктәбен оештырышып йөргән.

Язма әдәбиятта ул авыл «Оренбург Каргалысы» буларак та мәгълүм. Монда миңа элегрәк тә булгаларга туры килгәләгән иде. Мәсәлән, 1984 елда шагыйрь Һибәтулла Салихов варислары белән очрашырга, алардан истәлекләр язып алырга насыйп булды. Каргалы авылы элегрәк заманнарда мин үскән төбәкнең

рухи-дини бер башкаласы булып торган. Безнең Бозаулык суы буендагы егермеләп татар авылы ул дәвердә рәсми рәвештә Самара губернасына буйсынсалар да, мулла-мәзиннәренең күпчелеге шушы Каргалы мәдрәсәләрендә укыган затлар була. Совет хакимияте дәверендә дә Каргалыдан чыккан укытучылар ишле иде. Сугыштан соңгы елларда Бозаулык суы башланган Иске Актау (рәсми теркәлүе – Иске Белогор) авылында безне дә шул Каргалының бер кешесе укытты. Үз исеме Мөхәммәдне балалар теленә кертмәскә тырышып, ул үзенә «Салихов абый» дип эндәшүне генә хуп күрер иде.

Бу авылның халык телендә «Сакмар буе Каргалысы» дигән исеме дә бар. Чөнки ул Сакмар буенда, Сакмар-су тамагына якын гына җирдә урнашкан. Хәзерге рәсми язмаларда ул Татар Каргалысы дип атала. Күренә ки, татар дөньясына мәгълүм өч зур Каргалының берсе булган бу авылга карата халык телендә берничә төрле исем саклана. Еникиев, Терегулов морзаларның төп йорты саналган «Бәләбәй Каргалысы» (элек ул Бәләбәй өязенә кергән) белән Татарстанның Чистай шәһәре янәшәсендәге Каргалыдан аермалы буларак, Оренбург янәшәсендәгесенең тагын бер рәсми атамасы булуын да әйтеп үтик. Унсигезенче, унтугызынчы йөзләргә караган язма документларда ул «Сәгыйд бистәсе» («Сеитов посад») исеме белән дә йөргән. Татар дөньясында бу авылга багышлап иҗат ителгән аерым хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Чулпанай Мирхәйдәр дигән берәү 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгара. Мәшһүр галимебез Риза хәзрәт Фәхретдиневнең дә Уфада яшәгәндә үк бу авылга багышлап «Сәгыйд» исемле китап (1898) нәшер иткәнлеге һәм Оренбургта вакытта «Әхмәт бай» китабын язганда (1911) аерым бүлек багышлаганлыгы мәгълүм.

* * *

Каргалы элек Оренбург—Казан юлы өстендә утырган иң зур авылларның берсе булган. Хәзер дә әле ул Сакмар елгасы буйлап өч-дүрт чакрымга җәелеп утыра. Зур урамнары Сакмар ярыннан күтәрелә башлаган сөзәк үр буйлап сузылган. Аркылы урамнар үр сыртындагы борынгы кабер ташларына таба бара. Табигый таштан корылган зират коймасы белән авыл арасыннан киң асфальт юл уза. Мәңгелеккә дип эшләнгән ул зират коймасының кайчан корылганлыгын белүче юк. Ул койма, шундый ук таштан төзелгән элекке кибет, келәтләр авыл белән бер үк вакытта корыла башлаган булса кирәк. Басу ягы табигате үрле-калкулы ялан кырдан гыйбарәт. Сакмар-суның аргы ягын тоташ урман хасил итә. Өянке, усак, каен урманы. Ул урманның зур өлеше элек бер алпавыт карамагында булган. Хәзер ул шәһәр яны урманчылыгына керә.

«Әхмәт бай» китабының «Каргалы шәһәре» бүлегендә Риза Фәхретдинев егерменче йөз башы авылын болайрак тасвир кыла: «Оренбургтан егерме чакрымнарда Сакмар елгасының уң яры буйлап сузылган бер шәһәр булыр. Халык телендә ул Каргалы дип кенә йөртелә. (Бу исем аңа шәһәр уртасыннан Сакмарга агып төшүче Каргалы елгасына нисбәтле рәвештә бирелгән.) Аның «Сәгыйд бистәсе» дигән атамасы да бар. Анда мөселманнар гына яши. Бу бистәне сәүдәгәр Сәгыйд Хәялин нигезләгән, шунлыктан шәһәр аның исеме белән дә йөри. Җаек һәм Идел елгалары буйларында башка андый саф мөселман шәһәрләре юктыр. Шушы көндә Каргалыда ун сан мәчет булып, күбесендә икешәр указлы мулла бар... Каргалының барлык әһлиясе (халкы) чама белән унөч меңдер. Укымышлысы, хәлфә вә суфиларны кертмичә, йөз ярым чамасы булачактыр. Каргалы шәһәрендә һәр гасырда үзенә күрә шөһрәтле галимнәр, аз булса да, шагыйрь вә әдипләр яшәгән. Сәгыйд бистәсен Елизавета императрица 1745 елда төзергә рөхсәт бирә... Шушы көнге Каргалыда әлегә почта вә телеграф юк, хастаханә дә юк. Моңа шәһәр исеме бирелүе башкалардан аеру ниятеннән эшләнгәндер. Оренбургта исә бу көндә йөз мең чамасы кеше яши, шуның дүрттән бер өлеше әһле ислам кешеседер», – дип язган Риза хәзрәт.

Боларга өстәп, шуны гына әйтик: патшабикә әмере чыкканчы ук, Казан төбәгеннән бу авылга берничә гаиләнең күчеп килгәнлеге мәгълүм. Алар 1743 елда Оренбург губернаторы И. И. Неплюев рөхсәте белән монда килеп төпләнәләр. Димәк, Каргалы авылы хәзерге Оренбург шәһәре белән бер үк вакытта төзелә башлый. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, ул җирдә элек-электән үк ерак бабаларыбыз яшәгән булырга тиеш. Чөнки ул безгә кардәш халыклы Урта Азия мәмләкәтләре белән Уфа, Казан төбәкләрен тоташтыручы сәүдә юлы өстендә утрак тормыш алып бару өчен иң җайлы урыннарның берседер. Шушы төбәк авыллары мазаратын хәтерләткән зират күренеше дә шул ук фикерне раслый сыман. Казан арты авылларыннан күченеп килгән мөселманнар монда каберлеккә агач утыртмый башлаганнар. Димәк ки, бирегә алар элек-электән яшәүчеләр йоласын үтәргә мәҗбүр булганнар.

Оренбург тарихчысы Сергей Попов хәбәр итүенчә, 1747 елда Каргалыда йөз җитмеш өч йорт-каралты булган, анда яшәүче ир-ат саны меңгә җиткән. Бу авылга зур сәүдәгә керешерлек бай мөлкәтле һәм аз-маз сәүдә тәҗрибәсе туплаган кешеләрне генә алырга тырышканнар. Беренче күченеп утырган ике йөзләп сәүдәгәр башлыча Казан, Вятка, Сембер губерналарыннан китерелгән. Әлбәттә, алар арасында дин әһелләре дә ишле генә санала. Мәсәлән, Каргалының икенче ахуны, соңыннан илле ел чамасы Рәсәйнең Европа һәм Себер өлеше мөселманнары мөфтие вазифаларын үтәгән Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен әл-Борындыкый нәселе монда Зөя елгасы буе Борындык авылыннан килгән була. Һәр сәүдәгәр, һәр мулла, йорт-кура һәм мал-туар тоту

өчен, үзе белән берничә хезмәткәрне алып килә алган. Аерым һөнәр осталарын чакырып китерү дә рөхсәт ителгән. Мондый мәсьәләләрне хәл итү авылның беренче старостасы Сәгыйд Хәялинга йөкләтелә, билгеле.

Патша хөкүмәте Каргалы бистәсенең оешу көннәрендә үк Урта Азия ханлыклары белән сәүдә арадашлыгын башлап җибәрү бурычын куя. Ташкент тарафына беренче зур сәүдә кәрваны 1741 елда, Оренбург һәм Каргалы төзелә башлаганчы ук, Орск кальгасыннан җибәрелә. (Ор елгасы тамагында төзелгән бу шәһәр 1743 елгача Оренбург дип аталган.) Бу кәрванны оештырып җибәрүдә Сәгыйд Хәялин да катнашкан дигән фикер бар. Шубай Арсланов белән Мансур Йосыпов җитәкләгән ул кәрван үз бурычын уңышлы үтәп чыга. Казах, үзбәк ханлыклары җирләреннән үтеп, сәүдәгәрләр Ташкент каласына барып җитә һәм бер елдан соң зур табыш белән үз илләренә әйләнеп кайта. Сәгыйд бистәсе тарихына багышланган соңгы китап авторлары – аталы-уллы Искәндәревләр раславынча («Сеидов посад», Казан, 2005), шул ук тарафка икенче зур рәсми кәрван берничә елдан соң Каргалы авылыннан чыгып китә. Кәрван башы итеп Сәгыйд Хәялинның бертуганы, сәүдәгәр Габдулла Хәялин билгеләнә. Бу кәрван да, үз бурычын уңышлы үтәп, 1749 елда Оренбургка әйләнеп кайта. Әлеге китапта китерелгән архив материалларына караганда, бу кәрван ефәк, парча, чәй ише товардан тыш, җиде пот көмеш тә алып кайта. 1750 елда шул ук Габдулла Хәялин, Надир Сафаров һ. б. катнашында тагын бер кәрван Хива ханлыгы башкаласына юнәлә. Аны шул ханлык илчесе Ширбәт озата бара. Ә бер елдан соң зур бер кәрван тагын да ераграк юлга дип чыга. Исмәгыйль Бикмөхәммәтев җитәкләгән ул кәрванга Һиндстанга барып җитү бурычы куелган була. Бу сәүдәгәрләр бик җитди бурычның бер өлешен генә үтиләр – Һиндстанга барып җитәләр, ләкин илләренә әйләнеп кайту күпләргә насыйп булмый. Чирек гасырдан артыграк вакыт үткәч кенә, кәрван башы Оренбургка кайтып егыла, юлда күргәннәренең бер өлешен язып калдыра. «Исмәгыйль ага сәяхәте» язмасын Ризаэтдин Фәхретдинев, 1903 елда Оренбургта нәшер итеп, киң җәмәгатьчелеккә җиткерде.

Әлбәттә, әлеге кәрваннарны оештырып җибәрүдә, төбәк түрәләреннән тыш, рус сәүдәгәрләренең дә өлеше зур була. Мөселманнар яшәгән җирләргә рус кешесенең аяк басуы тыелган булганлыктан, алар анда үзләре бара алмаган, билгеле. Дөя өркәчләренә өелгән мал-мөлкәтләре генә ул якларда «сәүдә кылып йөргән». Каргалы кешеләре аша эш йөртүче рус сәүдәгәрләре исемлегендә Мәскәү төбәгеннән рус В. Журавлёв, грек И. Мавродин, соңрак Казанда сәүдә өлкәсендә дан казанган Кекиннардан берәү, Урал-тау казылма байлыкларын аяусыз үзләштерүче сәнәгатьче Твердышевлар һ. б. бар.

Билгеле инде, патша түрәләре ул сәүдә кәрваннары белән әлеге ханлыкларга үз шымчыларын да даими рәвештә җибәреп

торганнар. Шундый шымчыларның иң танылганы, әлбәттә, Ян Виткевич була. Ул, Ташкент, Сәмаркандлар аша үтеп, Кабулга ук барып җиткән. Берләштерелгән Һиндстан империясен нигезләгән, европалылар тарафыннан «мәшһүр татар» дип йөртелгән Заһретдин Бабур шаһның Кабулдагы затлы сарай һәм бакчаларында булганда, бу разведчик рус патшаларын шул бай мәмләкәтне яулап алу мөмкинлекләре бар дип тә ымсындыра. Аның шуңа тартым хәбәрләре һәм күргән-белгәннәре турындагы язмалары безнең сәүдәгәрләр аша Оренбург якларына даими рәвештә җибәрелеп торган. Аңа багышланган кайбер хезмәтләрдә: «Виткевич Коръән сүрәләрен мөселманнардан яхшырак белгән, намаз гамәлләрен алардан остарак башкарган», – дип, арттырыбрак та язалар. Дөреслектә кем булган соң ул? Польшада, туган-үскән илендә, Россиягә каршы фетнәдә катнашкан бер ир-егет. Мөгаен, тумыштан ук мөселман өммәте кешесе булгандыр. Сөргенгә Казах ханлыгы чигендә урнашкан Орск каласына җибәрелгән. Шунда, имеш, мөселманча гамәл кылырга һәм сөйләшергә өйрәнә. Аннары бер сәүдә кәрваны белән Урта Азия тарафына озатыла. Тизрәк илеңә кайтасың килсә – безгә хезмәт ит, дип. Билгеле инде, чит-ят җирләрдә булганда, ул татар исемен йөрткән, разведка мәгълүматларын Орск, Оренбург, Каргалы татарлары аша хәбәр итеп торган…

Кайбер Каргалы кешеләренең мондый төр хезмәтләре, мөселман илләрендә йөргәндә сәүдә эшеннән тыш башка хезмәтләр дә башкаруы турында әлегә мәгълүматлар тупланмаган.

* * *

Унсигезенче йөзнең сиксәненче еллары башында Каргалыда өч мәчет эшләгәнлеге мәгълүм. Аннары һәр ун-унбиш ел саен диярлек берәр мәчет салынган. Сакмар буендагы бишенче мәчетне булачак миллионер Хөсәеновларның бабасы Хөсәен бай салдырган, дип хәбәр итә Ризаэтдин хәзрәт. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләр аралыгында төзелгән кайбер таш мәчет бинаалары хәзер дә исән әле. Зәки мулла тырышлыгы белән төзелгән беренче таш мәчет 1775 елда ачылган. Элеккеге агач мәчет урынына яхшы кирпечтән өч этажлы итеп 1883 елда төзелгән базар мәчете унтугызынчы йөзнең соңгы мәчете була. 1912 елгы зур янгыннан соң авылда тагын бер мәчет торгызыла.

Хәзерге көндә анда ике мәчет эшли. 1930 еллар ахырына авылның унөч мәчете дә үз вазифасын үтәүдән мәхрүм ителгән була. Күбесенең манаралары сүтелә. Мәсәлән, унтугызынчы йөз башларында таштан салынган «Кушманаралы мәчет»нең язмышы шундый. Аның манаралары 1941 елның көзендә, мәчет бинасында кавалерия полкы ашханәсе ачылганда, сүтеп ташлана. Авылның нәкъ уртасында, Муса Җәлил тыкрыгы белән Габдулла Тукай

урамы кисешкән урында урнашкан ул мәчет халык таләбе белән 1963 елда кабат ачыла. 1966 елда аңа яңа манара куела. Каргалы елгасыннан башланып, авылның буеннан-буена сузылган Тукай урамында тагын берничә борынгы таш корылма саклана әле. Соңгы елларда аларның кайберләрен төзекләндерүгә керештеләр. Сакмар очындагы борынгы бер таш мәчетне дә матурлап яңадан эшли башлаганнар. Авыл уртасында Каргалыга нигез салган Сәгыйд Ает улы Хәялинның табигый яссы таштан төзелгән йортының һәм коймасының бер өлеше дә саклана әле. Элек ул туптан атып та җимерә алмаслык нык корылма булган. Йортның бу өлешен зур кибет һәм товар сакларлык бүлмә, келәтләр биләп торган. Хуҗалар исә икенче катта, бүрәнә өйдә яшәгәннәр. Башка эре сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең йорт-хуҗалыклары да элек шул рәвешлерәк итеп эшләнгән була. Аста эре таштан төзелгән, челтәрле тимер ишек-тәрәзәле «пулатларда» кибет яки остаханәләр урнаша, өстәге бүрәнә өйләрдә хуҗалар яши. Сәгыйд Хәялин нәселенең чыгышы Саба төбәгеннән булуын да әйтеп үтик.

Авылның ярлырак өлешендә, Дунай бистәсендә, агач мәчетләр булган. Шулардан Әюб бине Ибраһим әл-Бөгелмәви имамлык иткән 9 нчы мәхәллә мәчете XIX йөз ахырында җәдидчелек хәрәкәтенә үз өлешен кертүе белән билгеле. Гани бай Хөсәенов тәкъдиме белән 1897 елда мәчет карамагындагы мәдрәсәдә җәдидчә укытырга теләк белдергән хәлфәләр өчен махсус курслар эшли башлый. Ул курсларның барлык чыгымын, шул исәптән курска килүчеләрне тулаем тәэмин итү чыгымнарын Гани бай үз өстенә ала. Каргалыга төрле тарафтан бик күп хәлфәләр яңача белем алырга дип килә. Ул курсларда татарның күренекле шәхесләреннән Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Габдрахман Сәгъди һ. б. бик күпләр укый. Ул курсларның мөдире Төркиядә укып кайткан язучы, булачак «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими була.

## II

Олуг галимебез Риза хәзрәт «Әхмәт бай» китабының Каргалыга багышланган бүлегендә: «Бу шәһәр киләчәктә үз трамвае, телефон станциясе, хастаханәсе булган тагын да зуррак шәһәргә әверелер әле», – дип язса да, ул өметләр өлешчә генә акланды. Без яшәгән гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында биредә йортларга электр уты, радио кертелә башлый, телефон линиясе сузыла. Ә медицина пункты (амбулатория) белән аптека – 1910 елларда, унбиш авыруны дәвалауга исәпләнгән төбәк хастаханәсе исә 1961 елда ачыла. Мәгәр Совет хакимияте дәверендә элекке «шәһәр» үсми, киресенчә, йортлар саны – бермә-бер, халык саны исә өчләтә-дүртләтә кими. Хәзер авылда дүрт мең чамасы кеше яши. Мондый «кимү»ләрнең сәбәпләре

һәркемгә аңлашыладыр, шәт. Ике-өч йорт хуҗасының берсе байлар исәбендә йөргән ич ул вакытта. Дин әһелләре дә бик ишле булган.

«Һәр мәчет хозурында – ибтидаи (башлангыч) вә бәгъзеләрендә рөшди (җиде сыйныфлы) мәктәпләр ачылган», – дип хәбәр итә Р. Фәхретдинев. Әйе, авылда төзелеш барган елларда ук мәктәп-мәдрәсәләргә дә нигез салына. Тәүге мәдрәсә мөдәррисләре, Каргалыга күченеп килгәнче үк, дини уку йортларына җитәкчелек иткән абруйлы шәхесләр булалар. Шундый шәхесләр арасында Габдессәлам бине Уразмөхәммәд мулла беренче булып тора. 1746 елда Каргалыга күченеп килгәнче, ул Казан артындагы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә балалар укыткан. Каргалыга күчкәндә, аңа кырык алтынчы яшь була. Белеме, тәҗрибәсе дә җитү булган бу мулланы авыл сәүдәгәрләре махсус чакырып китергәннәрдер, мөгаен. Килгәч тә, ул монда беренче мәдрәсәне ачып җибәрә. Үзе белән ияртеп кайбер шәкертләрен дә алып килгәнлектән, хәлфә-мөгаллимнәргә кытлык кичерми. Тарихтан мәгълүм ки, патша хөкүмәте җәберләвенә түзә алмыйча баш күтәргән татар – башкортлар фетнәсен оештырган Батырша да шушы Габдессәлам ахун шәкерте була.

Оста янына – оста, зыялы янына зыялы җыелыр, дип әйтә бит халык. Шигъри җанлы мулла Габдессәлам артыннан ук диярлек Каргалыга Буа тарафыннан Вәлид мулла да килә. Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминне икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәгә баш итеп билгелиләр. Вәлид ишан хәзрәтләре белән Уразмөхәммәд ахунның (псевдонимы Габдессәлам Урай) шигырь үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланган. Аларның кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә урын алганнар. Боларның мәдрәсәсенә әдәби һәм гыйльми иҗат белән шөгыльләнүгә дәрте булган шәкертләр төрле тарафтан килә башлый. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Тимәш авылыннан килгән шәкерт Габдерәхим дә Каргалыда Вәлид ишан мәдрәсәсен үз итә. (Бөгелмә өязе 1851 елдан яңа оешкан Самара губернасына кергән.) Укуын тәмамлагач, ул, үз мәдрәсәсендә үк калып, берничә ел балаларга белем бирә. Шушы җирлектә ул шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарый буларак таныла, тәүге гыйльми эзләнүләрен шушында башлап җибәрә. Утыз Имәни белән бер үк чорда Каргалыда аның яшьтәше, каһарман язмышлы Салават Юлаев та белем ала. Билгеле, ул да олуг шагыйрьләр арасында үзенең шагыйрьлек көчен сынап карагандыр. Бу ике яшьтәшнең шәхес буларак җитешүләре һәм иҗатларының чәчәк ату чоры, шөбһәсез, шушы Каргалы дәверенә туры киләдер. Габдерәхим Утыз Имәнинең Каргалы кызына өйләнүе, 1774 елда аларның монда Бәдыйгылҗамалы туганлыгы да мәгълүм. (1940–1950 елларда шушы якларда укыткан, Утыз Имәни, Һибәтулла Салихов иҗатларына һәм яшәешләренә бәйле кульъязмалар белән кызыксынган Үлмәс Беляеваның архивы хәзер кемдә сакланадыр, әйтә алмыйм.)

Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп, байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь һәм фикер иясе Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд әл-Харәзми дә 1776 елда Каргалыга килеп төпләнә. Монда аны да мәдрәсә мөдәррисе итеп куялар. Ишнияз мулланың әдәби һәм гыйльми мирасы өлешчә Казан мирасханәләрендә саклана, диелә. Каргалы авылы зиратында тулы исем-атамасы язылган гадирәк кенә кабер ташы да бар әле. Аның төрки дөньяда мәшһүр булган «Ләйлә илә Мәҗнүн» поэмасы җирлегендә шул исем белән аталган җыйнак эчтәлекле матур бер хикәя иҗат иткәнлеге, Каргалыда яшәү дәверендә – 1780 елда «Болгарда дини ышанулар» («Гакаиде Болгария») фәлсәфи хезмәтен язганлыгы мәгълүм. Бу мәгърифәтче мулланың дини эчтәлекле дәреслек кулъязмаларының булуы да билгеле.

Бер авылда бергә яшәгән Ишнияз бине Ширнияз остаз белән Утыз Имәнинең үзара аралашмаулары һич тә мөмкин түгел. Ләкин ул хакта әлегә тулы мәгълүмат юк. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ишнияз мулланың күпчелек мирасын якташлары Үргәнеч каласына алып китәләр. Андагы мирас белән безнең галимнәр таныш түгел дияргә була. Утыз Имәнинең 1788 елда ишле гаиләсен алып Бохарага чыгып китүендә дә, бәлки, Ишнияз остазның йогынтысы булгандыр. Ләкин әлегә ул хакта мәгълүмат юк шикелле. Ишнияз бине Ширнияз 1791 елда Каргалыда вафат була. Гаиләсе шунда торып кала. Варислары бүгенгә мәгълүм түгел. Каргалының беренче шагыйрьләреннән булган Габдессәлам Уразмөхәммәд (Урай), Утыз Имәни Каргалыга килгәнче үк, 1762 елда вафат булган. Вәлид мулла 1800 елда хаҗ сәфәренә китә һәм 1803 елда шунда гүр иясе була. Ләкин авылда аларның күпсанлы варислары, иҗатташ шәкертләре кала.

* * *

Мулладан – мулла, җир сукалаучыдан сукачы чыгар, дигәннәр. Каргалы халкының зыялы катламыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә ишле генә. Шулардан берничә исемгә генә тукталып үтик. Каргалы төбәгенә беркетелгән авыл муллаларына баш, ягъни ахун хәзрәтләре вазифасын да үтәгән Габдессәлам бине Уразмөхәммәднең оныгы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов – әдәбият сөючеләребезгә бик таныш кеше. Ата-бабасы кебек мулла вазифасын үтәүдән бигрәк, ул безгә классик шагыйрь Әбелмәних Каргалый буларак билгеле. Аның икенче тәхәллүс-кушаматы исә Сәгыйд бистәсенә нисбәтле була: Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әл-Сәгыйди. Бабасы вафатыннан соң дөньяга килгән бу бала бик тынгысыз холыклы булгандыр, күрәсең. Үз авылында мәдрәсә белемен үзләштергәннән соң, ул берникадәр вакыт Бохара, Истанбул кебек төрки дөньяның ул дәвердәге мәшһүр үзәкләрендә дә укып йөргән.

Шул үзәкләрдә иҗат иткән әдипләр белән аралашкан. Алар белән ярышып, шигырь вә поэмаларын язган.

Әбелмәних Каргалыйның шактый белемле, Казан галимнәре белән аралашып, аларга борынгы кулъязмалар җибәргәләп торган казах иле ханы Җиһангир белән якыннан таныш булганлыгы да мәгълүм. Бәлки, аларның бу танышлыгы Татарстан төбәгеннән чыккан беренче мөфти Мөхәммәтҗан ибне Хөсәен әл Борындыкыйның кызы Фатыйма аша оештырылгандыр. Фатыйма Җиһангир ханның җәмәгате була бит.

Танылган әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин Каргалыйны унтугызынчы йөз татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе дип атый. Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинев тә аның иҗатын бик югары бәяләгән: «Язылган шигырьләре һичбер җирдә вә гасырда йөз кызартачак түгел», — дип әйткән.

Шагыйрь 1830 еллар урталарында, илле биш яшьләр чамасында, икенче мәртәбә хаҗга барган җирендә изге туфракта ятып кала.

Ә. Каргалый белән бер үк чорда иҗат итә башлаган шагыйрь Гомәр Мөхәммәт улы Каргалыйны исә әдәбият галимнәренең дә күпчелеге искә алмаска тырышты бугай. Чөнки аның шул чорда атаклы булган өч поэмасы һәм кайбер шигырьләре мөфти-муллаларга, Оренбург төбәгендә булып, җирле халык белән аралашып киткән патша җәнаплары вәкилләренә багышланган дип санала, дип язды мәрхүм әдәбият галиме Мәсгут Гайнетдинов. Бу шагыйрьгә бәйле язмалар алдарак та булачак.

Әбелмәних Каргалыйдан ундүрт-унбиш елга соңрак, 1794 елда туган Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов Сәед бистәсе данын татар дөньясына тараткан өченче күренекле шагыйрь санала. Аның атасы Каргалыныкы, бабасы исә бу авылга Чистай өязе Такталы карьясыннан килгән кеше. (Хәзер ул авыл Аксубай районына керә.) Һибәтулла туганда, аның атасы Каргалыдан ерак булмаган Түбәнге Чебенке авылында мулла вазифасын үтәгән. (Авыл исемен шул төбәк халкы атаганча язуны хуплыйм. Бала чагымда укыткан Хөснә апам да шул авылныкы иде. Үрге һәм Түбәнге Чебенкеләр арасында элек, Оренбург каласын төзегәндә, вак таш — щебёнка чыгару базлары булган. «Матур туганда» романында Ш. Камал да ул баз-чокырларны тасвирлап үтә. Бу авыллар атамасы нигезендә шул «щебёнка» сүзе ятадыр кебек. Безнең әдәби язмаларда кабул ителгәнчә, чебенгә бәйле сүз «чебенле» түгелдер.)

Һибәтулла шулай ук Каргалы мәдрәсәсен тәмамлый. Мәдрәсәдә аның остазы шагыйрь Вәлиәтдин Багдадый була. Һибәтулла Салиховның мулла, мәдрәсә башлыгы һәм шагыйрь буларак дан казанган төп йорты — Каргалыдыр. Бу авылның Сакмар очы зиратында ишан хәзрәтләренең җыйнак кына кабер ташы сакланган. Ул 1867 елда вафат була. Кабер ташының арткы өлешенә «Дүртенче сөйгән хатыны Бибимәхтүмәнең дә кабере» дигән сүзләр дә язылган. Димәк, бу кабер ташы астында, «аркага-ар-

ка терәп», ике җан ята. Каргалыда шагыйрь нәселе вәкилләре исән әле. Аларның кайберләре – Салихов, бер ише Сәетбатталов фамилиясен йөртә. Күпчелеге укытучы һөнәрен сайлаган. Каргалыдан йөз утыз чакрымнар көнбатыштарак урнашкан Иске Белогор авылында Мөхәммәт Салиховның балалар укытканлыгы алда әйтелде. «Сугышмаган, әсир ителгән» дип, аны ул елларда бераз кыерсыттылар да шикелле. Әдәбият фәненнән укытмаса да, Салихов абый безгә кайчак онытылып дәреслектә булмаган шигырьләр сөйләве белән дә истә калган.

Һибәтулла Салиховның дүрт хатынының берсе (борынгы бабаларыбыз әйткәнчә, беренче – «алтын хатын»ы) – атаклы татар морзалары Айдаровлар нәселеннән. Элек Оренбург, Уфа төбәкләрендә бу нәселдән чыккан зыялылар бик ишле булган. «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бу токымнан берничә кеше укыта. Совет чоры татар матбугатында еш тиргәлгән Казан арты «Түнтәр авылы ишаны»ның кияве дә – шул морзалар нәселеннән. Совет чоры татар язучысы Әсгать Айдар да шул токымнан иде.

* * *

1984 елда Каргалыда Һибәтулла Салихов мирасына ия булган олы яшьтәге ике апа исән иде әле. Хәзрәтнең кызының кызы – туксан бер яшьлек Кәримә Габделлатыйпова ул җәйдә инде урын өстендә ята, авыр сөйләшә иде. «Минем әбием морза Айдаровлар нәселеннән була. Кызым Зәйнәп белән хәзер без – шушы абруйлы ике токымның соңгылары», – дип әйткән иде ул. Кәримәнең атасы Җәмил хәлфә ишан хәзрәтләренең яраткан шәкерте була. Әлбәттә, Һибәтулла хәзрәт һәм аның мирасы турындагы әңгәмәнең дәвамы пенсия яшенә җитеп килүче Зәйнәп апа белән дәвам ителде. Ул Каргалы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта иде. Илленче еллар башында Оренбург педагогия институтының татар бүлеген тәмамлаган. «Яраткан укытучым Үлмәс апа Беляева иде. Ул Каргалыга еш килеп йөрде. Иске язмаларны, китапларны укый, алып та киткәли иде. Үзем дә ул сораган иске китапларны аңа илткәләдем. Килгәндә күбрәк бездә торды... Әйе, Зөһрә әбиләрдә дә була иде...»

Зөһрә әбинең дә Һибәтулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген белә идем. Каргалы урта мәктәбе башлыгы, авылдашым Илдус Зәбиров белән сиксән дүрт яшьлек Зөһрә Сәетбатталова өендә дә булдык. Авылның Дунай бистәсе очында. Зөһрә әби җитез хәрәкәтле, зиһенле татар апа-әбиләренең берсе буларак хәтердә калган. Ләкин инде ул без килгәндә сукырайган иде. «Күзем күрми башлаганга бишенче ел була. Шул сәбәпле әле өченче ел гына биатамнан (каенатадан) калган биш-алты калын дәфтәрне Җизактан килгән бер зыялыга биреп җибәрдем. Бик озаклап дога кылып алды. Зур итеп сәдака бирде. Сукырайгач, үзем укый алмыйм. Балалар да кызыксынмый...» – дип сөйләгән иде ул.

Әйе, Утыз Имәнидән, Әбелмәних Каргалыйдан, Һибәтулла Салиховтан һ. б. Каргалы зыялыларыннан калган язма мирас белән кызыксынучылар элек күп була. Сугышка чаклы Оренбург педагогия институтында укыткан Җамал Вәзиева да, илленче еллар урталарында монда берничә көн булып киткән Нәкый ага Исәнбәт тә борынгы язма истәлекләр белән кызыксынганнар. Соңрак Каргалыда әдәбият галимнәребездән Мөхәммәт Гайнуллин, Миркасыйм Госманов һәм тагын кемнәрдер була. Җитмешенче-сиксәненче елларда Уфадан Зәйтүнә Шәрипова Каргалыга берничә мәртәбә килә. «Зәйтүнә монда ялгызы да, студентлар белән дә күп тапкырлар булды инде», — дип искә ала Каргалылар. Туксанынчы еллар башында монда Казаннан Миркасыйм Госманов шәкертләре Җәүдәт Миңнуллин, Раиф Мәрданов, Ирек Һадиевләр җитәкләгән археологик экспедиция дә булып китә. Урта Азия гыйлем үзәкләре дә Каргалының язма мирасы һәм тарихы белән элегрәк елларда бик кызыксынганнар. Тик үткәндәге ул олы мирасның әлегәчә тулы килеш бүгенге укучы кулына ирештерелмәве генә беркадәр борчу тудыра. Әйтик, Үлмәс Беляеваның үз заманында, илленче-алтмышынчы елларда Оренбург төбәгендә туплаган язмаларының бик аз өлешен генә матбугатка чыгара алганлыгы көн кебек ачык. Ул дәвердә мулла чапаны кигән галимнәр һәм шагыйрьләр турында иркенләп язып булмый, тупланган мирасны күрсәтеп бетереп булмый иде. Сакланган булса, бүген ул байлыктан иркенләп куллан да бит. Саклапдымы икән соң ул кулъязмалар — бөртек-бөртек хәреф белән чуарланган ул иске дәфтәрләр?

Зөһрә әби Сәетбатталова белән әңгәмәдән тагын шуны ачыклаган идем — күренекле радио вә телевидение журналисты Фәрит Сәйфелмөлековның бабасы да Һибәтулла хәзрәткә кардәш тиешле икән. Ә ни рәвешле кардәш — Зөһрә әби безгә аңлатып бирә алмады. Чөнки ул кеше революциягә чаклы ук Каргалыдан киткән. «Мин әле ул чакта кияүгә чыкмаган идем. Уналтым тулгач, мине ишан хәзрәт оныгына ярәштеләр. Ул чакта биатам (каенатам) Әхмәт хәлфә төп йортта яши иде…»

## III

Әлеге олуг хәзрәтләрнең һәм шагыйрьләрнең чордашлары һәм авылдашлары булган беренче мөфтиләребезне дә искә алып китү зарурдыр. Болар — Россия мөселманнары арасында иң мәртәбәле вазифаны биләүче иң тәүге мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенев, Габдессәлам бине Габдеррәхим һәм Сәлимгәрәй Тәфкилевләр. Мөхәммәтҗан Каргалы төбәгенең беренче ахуны Мөхәммәд бине Гали әл-Дагыстаниның шәкерте була. Остазы вафатыннан соң байтак вакыт үзе дә ахун вазифасын үти. Аңа шулай ук Урта Азия мөселман вәкилләре белән арадашлык итү бурычлары да йөкләнүе мәгълүм. Мөхәммәтҗан ахунның Россиягә әле буйсын-

маган чиктәш казах илендә дә абруе зур була. Мәсәлән, Оренбург генерал-губернаторы барон О. А. Игельстромның Каргалы ахунын берничә мәртәбә Кече Җүз казах түрәләре янына дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен җибәргәнлеге мәгълүм. (Мөхәммәтҗан мөфтинең яшьлектә яшерен рәвештә Бохарага барганлыгы һәм шуннан соңгы еллардагы эшчәнлеге турында 1939 елда СССР Фәннәр академиясе нәшер иткән «Исторический архив» журналында кызыклы фактлар китерелә. Борынгы документларда мөфти фамилиясенең «Гусейнов» рәвешендәге язылышы да очрый.)

Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбург губернасының бик зур мәйданны биләвен һәм, Уралның аръягындагы казах ханлыкларыннан тыш, Кавказ төбәгендәге мәмләкәтчекләр белән дә чиктәш булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасыннан алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачёв фетнәсе бастырылгач та, ул чордагы Россиянең өчтән бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша швед О. А. Игельстромны билгели. Һәм ул катлаулы, күпмилләтле биләмә белән ничегрәк идарә итәргә кирәклеге турында ике арада хатлар йөри башлый. (Ул хатларның бер өлеше 1886 елгы «Русский архив» журналында, «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.)

Патшабикә хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән, яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча, аларга дөреслекне табарга рөхсәт ителсен». Икенче хатта: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз», – диелгән.

Екатерина II белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дини карашка бәйле эзәрлекләүләргә каршы була. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан ахун белән якыннан аралашу нәтиҗәседер. Бу барон, идарә итә башлагач та, Мөхәммәтҗан Хөсәеневне киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп билгели. Ягъни әлеге ахун өлкә чигеннән көнчыгыштарак урнашкан Урта Җүз һәм Бүкәй казах ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән казахларга бәйле тарихи документларның 4 нче томында да урын ала («Собрание

документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане», 1939).

Мөселман татар-башкортлар 1773—1774 елларда Е. Пугачёв күтәрелешендә актив катнашалар. Шул ук чорда башланган Россия белән Төркия сугышы 1774 елда тәмамлана. Дунай елгасы буендагы Кече Кайнарҗа авылында төзелгән солых килешүендә Төркия хөкүмәте мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертә. Шушы җитди вакыйгалардан соң патшабикә Екатерина илдәге милли сәясәтне беркадәр үзгәртергә ниятли һәм патша хөкүмәте карары белән «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»н оештыра. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбәр...» китабының ул идарәгә багышлы өлешендә: «1192 (1778) елның 22 сентябрендә Оренбург кальгасында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла... Казыйлар һәр өч елда чиратлашып алышыналар... Бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю — Кечек Кайнарҗа килешүе шартларының берседер», — дип язылган.

Хәзрәт кулланган дата һәм идарә атамасына карата булган соравымны, бер очрашканда, мөфтият хезмәткәре, дин галиме Равил Үтәбай-Кәримигә дә биргән идем. Ул: «Мөфтият архивында шул дәвер документлары сакланмаган. Хәзер кабул ителгән датаны ачыклаучы күренми... Мәрҗани фикеренә каршы килеп булмый», — дип әйткән иде. Мөфтиятнең Кече Кайнарҗа килешүенә бәйле рәвештә ачылуын Надир Дәүләт тә «Россия төркиләренең милли көрәш тарихы» хезмәтендә билгеләп китә. Югыйсә бездә әлегәчә мөфтият оешу мәсьәләсе Пугачёв җитәкчелендәге фетнәгә генә бәйләп карала килде. Ул дәвердәге Төркия башлыкларының Россия мөселманнары язмышы белән кызыксынулары телгә алынмады.

Яңа идарәнең беренче рәисе итеп тәҗрибәле ахун Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый билгеләнә. Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбәр...» китабында: «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат, озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, Уфа янәшәсендәге үз милкендәге авылда 1823 елда вафат... Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин... һәм башкалар һәммәсе аның фазыл вә камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә бик галим буларак танылган», — дип яза. (Алда күрсәткән датасын Мәрҗани монда да кабатлый. Мөфтият 1788 дә оешкан булса, Мөхәммәтҗан ул вазифаны кырык ел чамасы гына үтәгән булыр иде.) Бу идәрә 1788 елда Уфага күчерелә, исеме-аталышы да берникадәр үзгәртелә шикелле.

Россия империясендә мөфтиләрнең дәрәҗәсе вә вәкаләте зур була. Алар үзләре теләгән вакытларда патша җәнаплары белән турыдан-туры элемтәгә керү хокукына ия булган. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен һәрчак ачык торган. Мөхәммәтҗан үз вазифасын үтәгәндә, империя белән

өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина II, аның улы Павел I һәм аның улы Александр I. Шиксез ки, Әби патша идарә иткәндә, Мөхәммәтҗан Хөсәенев аның белән танышуга чакырылмыйча калмагандыр. Павел белән Александрның тәхеткә тәгаенләнү тантаналарында катнашкан булуы да һич тә шик тудырмый. Дәүләт карамагындагы бер сәяси идарә башлыгы буларак (мөфтият Эчке эшләр министрлыгының бер идарәсе саналган), барлык мөфтиләр дә патшаларны коронацияләү тантаналарыннан калдырылмаганнар. Андый олуг мәҗлесләргә мөселман өммәтендәге иң абруйлы дип күзалланган шәхесләр дә чакырулы булган. Мәсәлән, алтын приискалары хуҗалары аталы-уллы Рәмиевләрнең шундый ике зур җыенда катнашканлыклары мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк Рәмиев 1881 елда Александр III гә таҗ кидерү тантанасына чакырулы була. Кайбер хәбәрләргә караганда, ул яшь императорга бик кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшыра. Мөхәммәтшакир Рәмиев 1896 елда император Николай II не коронацияләүдә катнаша. Ул тантанага Мөхәммәдьяр мөфтидән тыш тагын берничә мөселманның, шул исәптән Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринскийның чакырылганлыгы билгеле. Беренче мөфтиләргә шулай ук Урта Азия яисә Кавказ ханлыкларыннан килүче дәрәҗәле кунакларны Оренбургта яки Саратовта каршы алып, пайтәхеткә кадәр озата бару, ул кунакларның Россия түрәләре белән сөйләшүләрендә катнашу бурычы да йөкләнгән була.

Мөхәммәтҗан мөфти 1823 елның декабрендә вафат булгач, аның вазифасын вакытлыча үтәү бурычы Әмин казыйга йөкләнә. Әмин Дәмин улы әл-Җәбәли әт-Танавый да Зөя буенда, хәзерге Апас районына кергән Танай авылында туган. Дини идарәгә ул казыйлыкка сайлангач килә. Бер ел чамасы вакыт мөфти булып тора. Император тарафыннан яңа мөфти билгеләнгәч, тагын бер нәүбәт (өч ел) казый вазифасын үти. Шуннан соң туган ягына кайта, берникадәр вакыт Зөя өязендә ахун булып тора. 1830 елда Әмин Дәминевнең Казан университетына татар теле укытучысы итеп билгеләнүе мәгълүм. Мөфти урынына калган вакытта, аңа шактый ук четерекле вакыйгаларда катнашырга туры килә. 1824 елның сентябрендә Александр I Оренбургта дүрт көн булып китә. Император җәнапларын каршылау зур шау-шу тудыра...

* * *

Ш. Мәрҗани беренче мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле углы» булуын гына яза, кызларын искә алмый. Мөфтинең ничә хатынга өйләнүен дә хәбәр итми. Башка чыганакларга караганда, Мөхәммәтҗанның ике кызы казах хан-солтаннарында кияүдә була. Кече кызы Фатыймага багышлы берникадәр мәгълүматны Карл Фукс китабында да очратып була. Казан университеты профессоры, танылган табиб

Фукс Фатыйма һәм аның ире Җиһангир хан белән 1826 елның көзендә Казанда очрашкан.

1886 елда Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» китабының икенче томында (55–56 б.) Кече Җүз ханнары исемлеге китерелә. Һәм шунда Бүкәй хан улы Җиһангирның Оренбург мөфтие кызына өйләнгәнлеге һәм аларның дүрт улы һәм ике кызы булганлыгы бәян ителә. «Кызлары Зөләйха полковник Тәфкилевтә кияүдә», – дип тә өстәлгән. Бу полковникның бабасының бабасы генерал Котлымөхәммәд Тәфкилевнең 1731 елда Кече Җүз казах ханы Әбелхәерне Россиягә табыну килешүен төзергә күндергәнлеге дә мәгълүм. Шул көннән башлап казах халкының көнбатыш өлеше Россиягә ярым буйсыну хәлендә яши. Әбелхәердән соң идарә иткән Нургали, Ишим, Бүкәйләрне ханлыкка тәгаенләү «ак патша» киңәшенә таянып эшләнә башлый. 1800 елда хан тәхетенә Нургалинең уртанчы улы Бүкәй утыра. Император Александр I вакытында, Бүкәй хан вафат булгач, 1812 елда ханлык ике өлешкә бүленә. (Моңа кадәр инде Александр Россиягә Грузия, Финляндия, Молдавия кебек мөстәкыйль илләрне куша башлаган була. Соңрак Азәрбайҗан белән Польшаның көнчыгыш өлешен дә «руснык ы« итәргә җитешә.) Җаек (Урал) белән Эмба елгалары арасындагы кече ханлыкка Бүкәйнең өлкән улы Җиһангиргәрәй билгеләнә. Ләкин аңа 20 яшь тулмау сәбәпле, вакытлыча идарә итү бурычы Бүкәйнең энесе Шиһабигә йөкләнә.

Җиһангир 1823 елда хан тәхетен били. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне русчалаштыргач, патша фәрманында ул Җиһангир Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла. Бу хан 1826 елда Николай I не тәхеткә тәгаенләү тантанасында катнаша. Шуннан үз иленә кайтышлый, Казанда дүрт көнгә туктала. Аны озата йөрүче хан-солтаннар арасында үз мулласы – «нугай» Ает Мөхәммәт тә бар. «Ханга 24 яшь. Европалыга тартым аксыл йөзле… Чибәр кыяфәтле. Рус телендә… һәр сүзне дөрес, чиста итеп әйтә белә. Безнеңчә язуы әйбәт… Татар теленнән кала фарсы, гарәп телләрен белә…» – дип яза К. Фукс. Галимнең шушы сүзләренә таянып, без казах ханнарының элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен чамалый алабыз. Яшь ханның рус телен яхшы ук үзләштерүенә килгәндә, башта казах кардәшләрнең 1957 елда чыгарган китабына күз төшерик («Присоединение Казахстана к России», Мәскәү). Анда «Җиһангир берникадәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә», – дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында хәбәр юк. Андый хәбәрне укучыга җиткерер өчен, татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Ә Совет хакимияте чорында «иске мәдрәсәне» искә алу килешеп бетми… Бигрәк тә казах ханы турында язганда, «татар мәдрәсәсен» телгә алу килешми.

Ә аның тарихы болайрак. Оренбург каласы төзелгәч, казах халкы түрәләрен Россиягә тагын да якынайта төшү ниятеннән

чыгып, анда бер алдынгы уку йортын ачу нияте барлыкка килә. Аның өчен башта мәчет салырга кирәк була. Шәһәрдә затлы таш мәчет төзетү өчен, патша казнасыннан акча бүлеп бирелә. Мәчетне төзү, аның карамагында мәдрәсә ачу бурычы мөфти Мөхәммәтҗанга йөкләнә. Мөфти бу эшкә булачак икенче мөфти Габдессәламне тарта. 1799 елда ул аны Оренбург ахуны һәм шәһәрнең Беренче мәхәлләсе имам-хатыйбы итеп билгели. Шәһәр үзәгендә, Урал елгасыннан ерак булмаган бер калкулыкта, тиздән кызыл кирпечтән матур итеп төзелгән мәчет бинасы пәйда була. 1805 елда аның карамагында махсус мәдрәсә ачыла. Хәзергечә итеп әйтсәк, ул ябык типтагы уку йорты була. Аңа күрше дәүләтләрнең хан-солтан балалары гына укырга алына. Җиһангир солтан һәм аның кардәшләре дә шушы мәдрәсәдә белем үзләштергән булырга тиеш. Бер хезмәттә «Кыргыз-кайсак хан-солтан балалары өчен ачылган мәдрәсә» дигән сүзләр дә күзгә чалынган иде. Ул мәчет һәм мәдрәсәне тоту өчен, Екатерина II карары белән ничәдер мең сум акча да бүлеп бирелгән. (Оренбургка багышлы тарихи китапларның берсендә ул карар язмасы китерелә.) Ул мәчет карамагында соңрак, хан-солтанлыклар бетерелгәч, гади мулла балалары өчен мәдрәсә эшли. Шул ук гасыр ахырында анда күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимов белем үзләштерәчәк. Хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдева сөйләвенчә, «Коръән Алладанмы, түгелме?» язмасына этәргеч биргән ниндидер бер кулъязма да Галимҗан кулына шул вакытта килеп керә.

Мөхәмәтҗан мөфтинең кызлары... Өлкәненең язмышы әлегә ачыкланмаган. Казанга ханбикә булып килгән Фатыймага унҗиде яшь. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатыны — шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәйдән соң алар диванга утырышып, бик иркенләп гәпләшәләр. «Фатыйманың теле русча җырлап тора, бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм; нәфис киенгән: атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, ханга тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул елның көзендә Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә — Кәримә бикәгә патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы — җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкарнәй бар», — дип хәбәр итә К. Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиңдәш булырдай итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс ул хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда, мөфтият инде Уфага күчерелгән була. Димәк, аның балачагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпутның» ул вакыттагы «үз авылы»нда, Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗиттедә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә

башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербургның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге була. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә белем алгандыр, мөгаен. Казах халык шагыйре Олжас Сөләйманов та, 2007 елның көзендә Казанда булганда, шундыйрак фикер әйткән иде. Карл Фукс язмалары шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бүкәй хан Саратов губернасы чигендәге үз утарында 1845 елда вафат була. Ул вакытта инде ул, хан булудан бигрәк, Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач, ул һәм аның балалары, Чыңгыз хан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр. Патша Россиясендә кенәз дәрәҗәсе бик сирәк шәхесләргә бирелгән. Димәк, ул шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. XVIII–XIX йөзләрдә Россиядә рус милләтеннән булмыйча кенәз дәрәҗәсен алучылар күп түгел. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе дә шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Ырыс яки Арслан бәк (кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Җиһангир Чыңгыз бу дөньядан китү белән үк, Кече Җүз һәм Бүкәй ханлыклары да гамәлдән чыгарыла. Бу вакытта инде казах иленең Арал диңгезенең көньягындагы өлкәләре генә яулап алынмаган килеш кала. Алары 1880 елларда яулап алыначак...

Соңгы чор казах ханнары, бигрәк тә Бүкәй урдасы вәкилләре – кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Аларның Саратов губернасындагы утарына татарның зыялы кешеләре дә килгәләп йөргән. Шул исәптән Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ. б.ның алар белән аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озак гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары – Россия дәүләтенә хезмәт иткән Чыңгыз кенәзләр: Сәхиб, Ибраһим, Әхмәт һәм Гобәйдулла булалар. «История родов...» китабында алар да теркәлгән. Кызлары Ходжаның (Хәдичәнең?) язмышы билгесез. Зөләйха, – алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене. Аларның язмышы Оренбург белән Каргалыга да берникадәр бәйле. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре шул тирәләрдә була. Совет хакимияте дәверендә Тәфкилевләрнең Каргалы янәшәсендәге төп утарында Ленин исемендәге совхозның үзәге урнашкан иде.

## IV

Икенче мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви унөч ел дәвамында ул вазифаны үти (1825–1838). Аның Бөгелмә

өязе Габдрахман авылында туганлыгы, яшьли Каргалыга килеп укыганлыгы мәгълүм. Мәдрәсәдән соң шунда ук мулла булып кала. Бохара ханлыгы илчелеге Россиягә килер алдыннан, 1799 елда беренче мөфти аны Оренбургка ахун итеп күчерә. Анда таш мәчет төзетү бурычын йөкли. Бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергән. Бохарадан һәм соңрак Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә, ул губернатор җәнаплары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде император Александр I Оренбургка килгән 1824 елда Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә. Һәм патша әмере белән 1825 елда мөфти итеп билгеләнә. Император Оренбургта дүрт көн була. Патша җәнапларын каршыларга дип, ул шәһәргә күрше мәмләкәтләрнең хан-солтаннары да чакырыла. Аларны каршы алу, урнаштыру мәшәкатьләренең бер өлеше Габдессәлам ахун өстенә төшә. Элекке шәкерте, яңарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм аның өч бәк-солтаны белән бергә Габдессәлам дә император тарафыннан кабул ителә. Каргалы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәтнең аңа багышланган ике зур шигъри әсәре сакланган. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр II патшаны кабул итү күренешләре «Сәфәрнамаи шаһзадә Александр» (1837) дигән әсәрдә чагылыш тапкан. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казах ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадә белән бергә бара. Казах хан-солтаннары белән бергә оештырылган милли бәйге-бәйрәмнең әйдәүчесе дә мөфти хәзрәтләре була. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре кантнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнән башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе – күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөри. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха – татар нәселеннән. (Соңрак үземе, яки биографиясен әвәләүчеләрме, аның анасын «турчанка» дип язалар. Ягъни элекке Касыйм ханлыгы biләмәсендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» дип. Икенче бер рус шагыйре Константин Бальмонт та, кемгә иярептер, Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «шигъри җанлы турчанка иде» дип яза. Шигърияткә яшьли күңел бирүем дә – анам тәэсире, ди 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.) Жуковскийның анасы бер алпавытта хезмәт итә, уйнаштан тапкан улын баштарак үзе генә тәрбия кыла. Димәк, Василий аз-маз гына булса да үз ана телен дә белгәндер, шәт. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән җирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына була, билгеле. Гомәрнең Петербург архивында сакланган поэмаларын укый алган очракта, без ул вакыйгаларны тагын да тулырак итеп

күзаллаган булыр идек. Жуковскийның да шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары 1902 елда «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле язмалары белән әлегә танышып булмады…

1910 еллар башында Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Габдессәлам мөфтинең үз көндәлек кулъязмаларын табып ала. Аларны Риза хәзрәт Фәхретдиневкә илтеп тапшыра. Ул язмалар 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыгалар.

Шиһабетдин Мәрҗани Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә ни өчендер бик аз туктала. Аның кылган эшләрен бик саран тасвирлый. Гаилә әгъзалары да хәзрәтнең китабында телгә алынмыйлар. Бәлкем, Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән шулай эшләгәндер ул. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов.

Гомәр Мөхәммәт улының бу ике поэмасы – С.-Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының кулъязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы – татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр… Бу әсәрнең тагын бер мөһим яңалыгы – реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора…» – дип бәяли аларны М. Гайнетдинов. Әйе, шушы ике поэма эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак.

## V

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне – гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865–1884 елларда мөфти кәнәфиен били. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәк-морзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Сәлимгәрәйнең 1852 елда Истанбулда һәм хаҗда булганлыгы күрсәтелә. «Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кеше мәгълүм түгел», – дип яза Ш. Мәрҗани. Әлбәттә, бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер. Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Сәлимгәрәй – Уфада мөфтият бина-утарын төзеп бе-

терүе белән шөһрәт казанган шәхес. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин, карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре тәмамланмыйча, ярты юлда кала. Еш кына үз әмерен үзе бозар иде... Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчет күршесендә җирләнде. Балалары булмады» диелә «Мөстәфадел-әхбәр...» китабында.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза Котлымөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәсен Мәхмүт бай Хөсәеновка сата. Сатканда исә түбәндәге шартны куя: әлеге җирдән алынган керемнең бер өлеше элеккечә үк Каргалы мәчет-мәдрәсәләре файдасына бүлеп бирелергә тиеш, ди. Әлбәттә, андый кешеләрне Каргалы мәхәлләсеннән аерырга мөмкин түгелдер. Каргалы зиратында Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабернең саклануын да әйтеп үтү кирәктер. Урта зиратның иң алгы өлешендәге ул каберләр, борынгы төрбәләр рәвешенә китерелеп, биек таш койма белән уратып алынган. Төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова ачыклавынча, беренче кабердә шушы төбәктә зур эшләр башкарган генерал Котлымөхәммәд Мәмәш улы Тәфкилевнең хатыны ята. Ул – Тәфкилев заманында Урал-су буендагы Орск, Оренбург шәһәрләрен нигезләүдә катнашкан олуг бер шәхестер. Каргалы «каласын» нигезләшүдә дә өлеше булгандыр, мөгаен. Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабер ташы да сакланган. Ләкин икесе дә йөзтүбән капланып, яртылаш җиргә сеңгән булу сәбәпле, андагы язуларны уку мөмкин түгел иде. Фәкать Тәфкилевнең Тимәш морзага ярәшелгән кызыныкы дип уйланган таш сыртына «1215 сәнә» дип чокып язылган язуны гына укып була иде. (Бу сан хәзерге исәп белән 1800–1801 елларга туры килә шикелле.) Хәзер инде ул ташларның берсе күтәртеп куелган. Таштагы язу өлешчә укыла: кабер иясе Хәдичә бикә икән, ул илле биш яшендә – 1751 елда шушы соңгы йортына иңдерелгән. Фараз ителүенчә, ул Котлымөхәммәд морзаның беренче хатыны булган.

## VI

Оренбург төбәгенең яңа чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти урынын биләргә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Баштарак ул шул кәнәфине биләргә иң лаек шәхес саналган. Ләкин аңа каршы русның югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Ильминскийның шул хакта Синодның өлкән прокуроры К. По-

бедоносцевка язган хатлары мәгълүм. Хатларында ул Ш. Ибраһимовны «цивилизованный, энергичный», акыллы, тирән белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы, Урта Азия һәм башка шәрык дөньясының билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат, дип мактый да, нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш дигән нәтиҗә чыгара. Уңай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилевтән күпкә өстен тора. Шул өстенлеге белән ул безнең дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господь и чинов высшего управления»). Мөфти урынына безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак торучы кеше кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н. Ильминский 1885 елның 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкалада «башкорт төркеменнән булган» Мөхәммәдьяр Солтановны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә.

## VII

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнең Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетеп, укып үсәргә туры килгән иде. Мин үскән Искеавыл (Иске Белогор), аның янәшәсендәге Яңавыл (Яңа Белогор, ике уртадагы биек Актауга нисбәтле исемнәр), Аюлы, Имангол, Кондызлы картлары белән, сүз чыкканда, әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алыныралар иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Яңавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбарый Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннең соңында укуын Каргалыда дәвам иттергән. Соңгы ике-өч кышын Троицкидагы «Рәсүлия»дә үткәргән.

Каргалы һәм анда яшәүчеләр белән кызыксыну ни өчен соң әле яшьтән үк күңелдә кузгалган? Бу кызыксынуның сәбәпләрен беркадәр аңлатып китү кирәктер. Әйе, башлангыч классларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алып сөйләр иде. Түбәнге Чебенке авылында туган булса да, ул Каргалыны, аның кешеләрен дә бик сагына иде. Берничә ел шунда укыган да булса кирәк. Оренбург төбәгенең элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаровлар гаиләсен китерер иде. Әнә бит, Кәраметдин Айдаров хәзер – Сәмәрканд университеты профессоры, аның туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык буе татар авылларының соңгы ахуны Харис хәзрәт тә шул нәселдән булган.

«Аның улы Әсгать Айдар – күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнең кебек вакытта шушы

Искеавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларның җимеш бакчаларын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без аның «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз. Ул малай узган сугышта батыр булган, кызылармеецларга акларны җиңәргә булышлык иткән», — дип сөйләгән иде Хөснә апа дүртенче класс балаларына.

Унөч яшьлек Ташбай маҗаралары, чик сакчыларының дошман көчләр белән көрәше барыбызга да ошады, әлбәттә. Әсгать Айдар исеме дә мәңгегә күңелгә сеңеп калды. Каргалы белән безнең авылны берләштерүче кешеләрнең берсе буларак та, язучы буларак та. Байтак еллар үткәч кенә, Мөхәммәтхарис Айдаров ахунның шушы Иске Белогор авылында Сабантуйлар оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күпсанлы кунаклар җыелганлыгын укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр 1910—1914 еллар аралыгында «Вакыт» газетасында даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясе янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман вә урыстан ике меңләп кеше җыелган иде. Авыллардан иллеләп имам килде. Ат чабыштыру, көрәш кеби кызыклар белән Сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...» Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сахрада узган Сабан туйларында, бәлкем, минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган яшь үгез итен татып карагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыганнар. Бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә Урта Азия тарафына ургылган Кызыл Армия аны да үзе белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә, ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда, җизни бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынуын искә алган иде.

«Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казах, үзбәк авылларында укытканда да, көндез — хәлфә, кичләрен мулдакә идем. Хәзер дә шулай», — дип мактанып та алган иде Хәбибулла бабай.

Унтугызынчы йөз башы Иске Белогор авылы мулласы Әхсәнне дә Каргалы кешесе дип искә алалар. Авыл зиратындагы кабер ташында «Биләгур имамы Әхсән»нең 69 яшендә 1824 елда вафат булуы, «24 сәнә» мулла булып торуы бәян ителә. Кабер ташы язулары бик таушалган — алда китерелгән кайбер сүзләрне һәм

үлгән елын гына бераз чамалап була. Каргалыда туганмы ул, яки шунда укыган гынамы – анысы билгесез. Әмма шунысы хак: ул Каргалы кешесе саналган. Оренбург ягыннан көнбатыш тарафка юл тотучы укымышлы кешеләр һәрвакыт аларда туктала торган була. (Оренбург белән Самараны тоташтыручы «чуен юлы» фәкать унтугызынчы йөзнең соңгы чирегендә генә төзелә. Аңа чаклы Самара тарафына баручы мөселманнар Бозаулык буе татар авыллары аша йөри торган булганнар.) Җиде мәртәбә хаҗга барган Каргалы кешесе Рафик бабаның зур сәфәрдән соңгы кайтышында Әхсән мулла өендә вафат булганлыгы мәгълүм. Хаҗины бик зурлап безнең авыл зиратына җирлиләр. Кабере өстенә зур табигый таш куела. Соңрак изге кеше кабере өстенә куелган ул «изге таш» төбендә кунып чыккан кеше савыга икән дигән бер ырым тарала. Сугыштан соңгы елларда да әле ул таш төбендә кунып, савыгып китәргә ниятләүчеләр еш очрый иде. Күпчелеге – якын-тирәдәге татар, башкорт авыллары карт-корылары. Култык таягына таянып килүче хәрби киемлеләр дә күренгәләр иде. Мөсафирларны зират янәшәсендәрәк яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм авыл башындагы күпергә җиткәнче озатып та куйгалар иде. Файдасы булдымы соң дип сораучы карт-карчыкка мосафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты, шәт, тәнем дә савыгыр», – дип җавап биргән. Хаҗга йөреп «изге» исеме алган Рафик бабаның варислары Каргалыда бүген дә бар. Ерак бабалары каберенә «хаҗ кылучылары» гына хәзер юк инде. Дөнья үзгәрешләренә чаклы, алар безнең авылга килгәләп йөргәннәр. Ә изге кабердәге ул «изге таш» әле дә үз урынында, гарәп язулы дистәләгән борынгы каберташлар уртасында калкып утыра. Без аны 2006 елда гына фотога төшереп кайттык.

Иске Белогор авылының соңгы рәсми мулласы Габдулла Габидуллин бу вазифаны кырык алты ел чамасы башкара. 1926 елда вафат була. Язулы кабер ташы авыл зиратында саклана. Аның нәселе дә Каргалы белән даими рәвештә элемтәдә торган. Үзенең тумыш җире – Бозаулык буеның Сөңрән авылы. (Безнең тирә авыллары телендә – Түбән буй Сөңрәне. Бозаулык суы Иске Белогор янәшәсендәге Актау битләвеннән башланып китә.) Сугыш һәм аннан соңгы чорда шагыйрь буларак танылa башлаган Гыйззел Габид тә – шул авыл һәм шул токым кешесе. Иске Белогордагы кебек җиде-сигез сыйныфлы (рөшди) мәдрәсәсе булган Сөңрәндә мәгълүм китап рәссамы Байназар Әлмәнев тә беркадәр яшәп ала. Очрашкан, гәпләшкән мәлләрдә, без аның белән якташлык тойгыларын да белгертешми калмый идек.

Габдулла мулла үз авылларыннан соң Каргалының гали өлешле (югары белем бирүче) мәдрәсәсендә дә укыган булырга тиеш. Балалары, шул исәптән кызы Мәрьям дә Каргалыда укыйлар. Мәрьям әбинең оныгы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Шәмгунов гаиләсендә «Рәмия мәктәбе» укучыларының күмәк фотосы да бар иде. («Рәмия мәктәбе»н кайвакыт

«Рәмия мөслимия» дип тә язалар.) Белгәнебезчә, ул кызлар мәктәбе «Рәмия...»не оештыруда Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбҗамал да актив катнаша, аның тәүге җитәкчесе һәм иганәчесе була.

Бер Ходам, үзең ярлыка...

* * *

1994 елда безне, алдан сөйләшеп куелганча, Каргалы авылы сәфәрендә Мәдинә апа Рәхимкулова озата йөрде. Иң элек юл өстендәге зиратларны карап, йөреп чыктык. Һибәтулла Салихов каберенә куелган кыскача язулы таш, элеккечә төп-төз булып, үз урынында басып тора иде. Ә менә Урта зираттагы Ишнияз бине Ширнияз каберенең эзенә төшә алмадык. Мәдинә апа: «Шушы тирәдә генә иде бит», — дип берничә мәртәбә кабатласа да, шул тирәне ике-өч мәртәбә урап йөреп чыксак та, ул таш күренмәде. Кылган үләне шулхәтле биек һәм куе булып үскән — Мәдинә апа буйлап күрсәткән кечкенә ташны түгел, зурракларын да табарлык түгел иде. Ә менә очлы, өлгергән кылган орлыклары, арпа кылчыклары кебек, кадалмаган җирне калдырмадылар.

Зират тарафыннан авыл күренешен һәм кайбер истәлеклерәк, үзенчәлеклерәк кабер ташларын Зөфәр Бәширов фотога төшереп алды. Шуннан соң авыл эченә таба юнәлдек. Сәгыйд Хәялин йортының калдык нигезен дә, кушманаралы мәчет, Тукай, Җәлил урамы күренешләрен дә фотода истәлеккә калдырасы килә иде. Әле төп хуҗалары — имамнар карамагына тапшырылмаган берничә иске мәчет күренешен дә, авылның борынгы сәүдә үзәге кибет-келәтләрен дә рәсемгә алдык. Боларның барысы да бит мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь Закир Рәмиев-Дәрдемәнд заманында гөрләп үз вазифаларын үтәп торган җанлы корылмалар булганнар.

Егерменче гасыр башында Каргалыда үзләре сайлаган өлкәдә мәшһүрлеккә ирешкән, яки шуңа ирешү юлына баскан затлар да ишле генә булган. Яңалыкка омтылуы белән шөһрәт казанган Әюп хәзрәт һәм аның Дунай мәхәлләсендәге мәчете һәм мәдрәсәсе алдарак бераз искә алып үтелде инде. Икенче бер мәчет карамагындагы мәдрәсә укытучысы Гомәр Дәүләтьяров исеме исә хәзер сирәк кешегә мәгълүм. Ә бит ул заманында Оренбург төбәгенең атаклы шәхесе булган. Гомәр Габдрахман улы Дәүләтьяров балаларга хисап дәресләрен укыту белән генә чикләми, 1898 елда аның «Мөкаммәл хисаб» («Төгәл хисап») исемле дәреслеге дә басылып таратыла. Мәгәр аны илгә таныткан төп шөгыле астрономия өлкәсенә карый. Үз төбәгендә ул мөнәҗҗим буларак таныла. Мәшһүр галим Циолковский үрнәгендә Гомәр хәлфә дә үз өй түбәсендә кечерәк астрономик үзәк оештыра: күк җисемнәрен ерактан күзәтү пунктын ясый. Аның янына йолдызлар күзәтергә

төрле тарафтан кешеләр килеп йөри торган була. 1914 елның язында, аның Каргалыдагы обсерваториясе белән танышу өчен, Казаннан Садрый Максуди, Оренбургтан Закир Рәмиев, Фатих Кәрими һ. б. киләләр. Күк гөмбәзен күзәтү урынына менүче баскычта Гомәр мөнәҗҗимне уртага алып төшкән фоторәсемнәре сакланган. Г. Г. Дәүләтьяров 1930 елда кулга алына һәм «халык дошманы» буларак юк ителә. М. Рәхимкулова Гомәр хәлфәнең төп гаебе – Совет хакимияте урнашкач мулла чапанын киюдә дип белә. Зур үзгәрешләр чорында мәхәлла халкы аны мулла итеп сайлап куйган була.

Каргалы данын еракларга тараткан, Дәрдемәнд һәм аның чордашларына замандаш булган драматург Габдерәуф Хәкимбай улы Ниязбаевны хәзер фәкать театр тарихы галимнәре генә белә булыр. Ул 1881 елда Каргалыда туа, 1920 елда Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була. Соңгы эш вазифасы – Башкортстан мәгариф комиссариаты инспекторы. Г. Ниязбаев, Каргалы мәдрәсәсенең рөшди өлешен тәмамлаганнан соң, Казанда Укытучылар мәктәбендә белем ала. Узган гасыр башында шул мәктәптә укыганда, беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баса. Шәриктәшләре Гаяз Исхакый, Ильясбәк Кудашев, Гафур Коләхмәтев, Шакир Мөхәммәдьяров, Шәриф Сүнчәләйләр белән бергә татарча беренче спектакльләрне куюда катнаша. Рус классик драма әсәрләрен тәрҗемә итүдә дә көч сынап карый. Аның 1906 елның мартында кайбер пьесаларны татар сәхнәсендә куярга рөхсәт сорап Казан губернаторы исеменә язган ике хаты мәгълүм. Шул хатларында ул Н. Гогольнең «Өйләнү», «Ревизор» комедияләрен, татар драматургларының «Кызганыч бала», «Өч хатын белән тормыш», «Оят, яки күз яше» һ. б. пьесаларын сәхнәләштерергә рөхсәт бирелүен үтенә. Һәм берничә пьесаны, шул исәптән «Өйләнү»не куярга рөхсәт ала. Ул заманда мондый адым ясарга сирәк кеше җөрьәт итә алган. Соңрак ул үз туган төбәгендә һәм Урта Азия уку йортларында балалар укыта. Театр белгечләре аның биш драма әсәре язганлыгын әйтәләр. Шулардан ике әсәре – «Сәйяр» труппасы тарафыннан, берсе Оренбург татар драма театры тарафыннан сәхнәләштерелгән. «Сәйяр»дә Габдулла Кариев җитәкчелегендә куелган пьесалары «Беренче таң» белән «Борадарән Галимевләр» (автор кушкан исеме «Көчлеләр һәм көчсезләр»). Оренбургта уйналган пьесасы «Кара көннәр» дип аталган. Бу соңгы пьесаның Башкорт театры тарафыннан кабат сәхнәләштерелгән булуы да ихтимал.

Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә чордаш иң яшь каләм иясе Зәйнәп Сәгыйдә дә Каргалыда 1897 елда туган, Хәлиулла хәзрәт кызы. Зәйнәп Каргалыда кызлар мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә уку дәверендә үк халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплау белән кызыксына. Берничә дәфтәргә халык җырларын, бәет-мөнәҗәтләрне язып ала. 1914 елдан Зәйнәп Оренбургта яши, педагогик курсларда укый, татар матбугатына мәкаләләр, шигырьләр җибәреп тора. Шагыйрәнең берничә шигыре һәм поэмасы Рәмиев

байлар исәбенә чыгып килүче «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында басылалар. Зәйнәп Сәгыйдәнең 1915 елда «Шура»да басылган «Бикчәнтәй бабай дастаны» (икенче атамасы «Пугачёвка багышлы Каргалы дастаны») исемле поэмасы күпләрдә кызыксыну уята. Зәйнәп Сәгыйдә әсәрләре белән шагыйрь һәм нашир Дәрдемәнд тә таныш булгандыр, аларны үз иткәндер дип өметләнәсе килә. Дәрдемәнднең үз карамагындагы газета белән журналда басылган күпчелек шигъри әсәрләрне нәшер ителгәнче үк күздән кичергәнлеге турында берничә истәлектә телгә алына. Зәйнәп Сәгыйдә иҗатына да ул игътибар иткән булса кирәк. Бердән, күңеленә якын Каргалы кызы бит… Икенчедән, шигъри иҗатны үз иткән япь-яшь хатын-кыз буларак та кызыксындыру уятмый калмагандыр. Әйе, Зәйнәпнең һич югы үзенчәлекле поэмасын Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең үз итеп укыганлыгына чын күңелдән ышанасы килә…

* * *

Җәйге кояшның соңгы нурлары Сакмар елгасы белән Урал бергә кушылган тарафтан кыйгачлап, җир ягалап сузыла башлаганда, без борынгы Каргалы шәһәре белән хушлаштык. Оренбург архивларында еш булучы, төрле тарафтан тупланган иске китап, борынгы кулъязмалар белән эш итүче Мәдинә апа Рәхимкулова белән саубуллашып, кайтыр юлга чыктык.

*1994–2006*

# ДӘРДЕМӘНД ДАИРӘСЕНӘ КЕРГӘН ШӘХЕСЛӘР

*(Очерк)*

*Олуг шәхесебезнең тууына 160 ел тулуга багышлыйм*

1

Милләтебезнең рухи күтәрелеш чорында бу хәрәкәткә үз өлешләрен керткән шәхесләребез байтак. Дини, иҗтимагый-сәяси һәм тарихи хезмәтләре белән башка төрки халыклар арасында да дан казанган Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар тәрбиясендә үскән бер буын исә татар әдәбияты үсешенең яңа бер тармагын — заманча роман, повесть, хикәяләр иҗат итү тармагын башлап җибәргән. Әдәбият гыйлемендә «чәчмә әсәрләр яки проза, драма әсәрләре» дип билгеләнгән бу өлкәдә иң беренче уңышка ирешкән авторларыбыз арасында иң күренеклеләреннән Пенза төбәге кешеләре Муса Акъегетзадә

белән Заһир Бигиев санала. Аларның «Хисаметдин мелла» белән «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романнары бер-бер артлы 1886, 1887 елларда Казанда дөнья күргән. Татарлар арасында заманча беренче проза әсәрләре туугa рус һәм төрек әдәбиятлары үсеше дә үрнәк булган, этәргеч биргән дигән фикерләр безнең әдәбият тарихын барлаучылар тарафыннан әйтелгәләде инде.

Шул фикерне дәлилләрдәй бер мисал буларак, Дәрдемәнд һәм аның агасы Шакир Рәмиев хатларыннан берничә җөмлә китерү дә җитәдер, мөгаен. Мәгълүм ки, Закир Рәмиев-Дәрдемәнд 1880–1881 елларда Төркиядә яшәгән. Ике бертуган еш кына хат алышканнар. Менә Шакирның 1881 елда энесенә язган хатларыннан кайбер җөмләләр. «Безнең халык өстендә – чапан, башында чалмасы булмаган кешенең сүзенә игътибар итми. Халыкка һәртөрле әхвәлне аңлата торган китапларны укырга кирәк. Шуңа күрә дә фәһем алырдай китапларны, романнарны күбрәк алып кайта күр», – дип язган ул энесенә.

Шул чор зыялылары арасында ул елларда «Татарлар арасында хәзер чалмалы муллалар җитәрлек, чалмасыз муллаларга кытлык» дигәнрәк әйтем дә йөри, дип яза Фатих Кәрими бер китабында. «Чалмасыз муллалар» – киң белемле затларның халыкка файдалырак хезмәт итәчәге турында да, халыкның рухи үсеше өчен дини, гыйльми китаплардан тыш әдәби эчтәлекле хезмәтләрнең дә кирәклеге турында да шулай хәбәрләшкәннәр ул чорның зыялы шәхесләре. Муса Акъегетзадә һәм аның чордашлары тудырган әдәби әсәрләрне укып үскән икенче, өченче буын вәкилләре исә шушындый фикерләрне тирәнәйткән, баеткан әсәрләр тудырырга хыялланганнар.

Шушы ук дәвердә Оренбург шәһәрендә дә әдәби-мәдәни җанланыш, күтәрелеш күзгә чалына. 1870 елларда монда милли мәктәп-мәдрәсәләр өчен рус теле укытучыларын әзерләүче Учительская школа ачыла. 1889 елдан заманча (җәдидчә) укытуга йөз тоткан «Хөсәения» мәдрәсәсе эшли башлый. Шул чор зыялылары тырышлыгы белән Бреслин фамилияле кешенең шәхси типографиясендә татар хәрефләре булдырыла, татарча-казахча елына берничә китап басу мөмкинлеге тудырыла. Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман һәм улы Фатих Кәримов китап басу эше белән кызыксынгач, бу хыялларын эшкә ашыру юнәлешендә аларга бертуган Рәмиевләр белән Гани бай Хөсәенов беренче ярдәм итүчеләр була. Ахун гаиләсе шәһәргә килеп төпләнгәч тә, Бреслин басмаханәсеннән кул көче белән эшләүче станок һәм хәрефләр сатып алына. Һәм татар телендәге беренче китап болар тарафыннан 1901 елның март аенда басылып чыга. Ахун хәзрәтләре исән вакытта, 1902 елның июнь башына чаклы, бу басмаханәдә тиз арада 25 китап дөньяга чыккан, дип белдерә Әбрар ага Каримуллин. Дөрес, аларның күпчелеге әлегә яшь әдипләрнең башлангыч чор иҗат җимешләре – күләме дүрт-биш табактан артмаган юка китапчыклар була.

Беренче авторлар төркемендә Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев даирәсенә кергәннәр дә, сәүдәгәр Хөсәеновлар белән элемтә тотучылар да бар. Мәсәлән, Александр Пушкинның «Капитан кызы» һәм Николай Гогольнең «Борынгы алпавытлар» әсәрләрен тәрҗемә итеп тә тәҗрибә туплаган Гаяз Исхакыйның тәүге бер-ике үз әсәре Казанда нәшер ителгән булса, тагын берничәсе Оренбургта ахун Кәримов ачкан басмаханәдә дөнья күрәчәк. Гаяз мәхдүмне Казандагы укытучылар мәктәбендә укыган елларыннан (1898–1902) үз итеп күзәтеп килүче, укуын тәмамлагач, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә чакырып китерүче дип, алтмышынчы елларда Гани бай Хөсәеновны искә алырлар иде. Шул хакта аның Казандагы кодасы Садыйк белән язышкан хатларында да искәртелә бугай. Соңрак елларда бу төбәкнең кайбер шәхесләре, мәсәлән, Фатих Кәрими һәм аның якыннары белән кискенрәк мөнәсәбәттә булган Гаяз Исхакыйның да XX гасыр башында берникадәр вакыт Оренбургта яшәвен, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе булуын, кимендә ике әсәрен, шул исәптән «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ын шунда иҗат иткәнлеген таныырга тиешбез. Аның тәүге иҗат чоры әсәрләреннән кайберләренең дә яңа гасыр башында Оренбург шәһәрендәге «Кәримовлар басмаханәсе»ндә дөнья күргәннәрен әйтеп киттек. Киләчәктә дә аның кайбер әсәрләренең шул шәһәрдән чыккан, укытучылар әзерләүче уку йортында бергә укыган дусты Габдрахман Дәүләтшинның матди ярдәмендә нәшер ителәчәген дә истә тотсак, аның иҗат юлы өлешчә генә булса да шушы шәһәргә бәйле дип әйтергә хаклыбыз. Мәсәлән, авторы сөргендә чакта – 1907 елда Г. Исхакыйның «Зиндан» китабын туплап һәм кереш сүз язып чыгаручы да Габдрахман була. Дөрес, китапка кереш сүз язганда, ул үзен асраугa алган үги атасы Әхмәт бай Хөсәенов фамилиясен кулланган. Хәер, әлеге китапны нәшер итү өчен тотылган акча да шул ук Хөсәенов байныкы ич инде.

Ике гасыр аралыгында иң актив иҗат итүче һәм Оренбургка бәйле шәхесләрдән беренче урынны Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинов билидер, мөгаен. Берничә дини-тәрбияви эчтәлекле китабы элгәрерәк язылган һәм чыгарылган булса да, аның күпчелек иҗади хәзинәләре Оренбургта язылган һәм шундагы басмаханәләрдә нәшер ителгәннәр. Бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә аның дистәләгән китабы, якын туганнары булган «Кәримовлар басмаханәсе»ндә егермеләбе басылып, төрки дөньяга таралганнар. (Риза хәзрәтнең бертуган Рәмиевләрнең матди ярдәме белән нәшер ителгән китапларының гомуми саны да шактый гына.) Бертуган Рәмиевләр белән Уфада, мөфтияттә эшләгән еллардан ук дустанә мөнәсәбәттә булганлыгы турында хәзрәтнең үз истәлекләре сакланган. Моңа ул шәхесләрнең нәселе бер төбәктән – элекке Бөгелмә өязеннән икәнлеге дә, Рәмиевләрнең кайбер буын бабаларының дин әһелләре булуы да ярдәм иткәндер, мөгаен. Риза хәзрәтнең яшьтәше Дәрдемәнднең баба-

лары да бит чыгышлары белән хәзерге Әлмәт районына кергән Тайсуган авылыннан. Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә бу авылда XVIII йөз башында ук шул төбәктә танылган мәдрәсә эшләгәнлеге хәбәр ителә. 1913 елда «Шура» журналында бертуган Рәмиевләрнең шәҗәрәсе басылган. Анда аларның бабалары Габделкәримнең, яңа оеша башлаган Эстәрлетамак өязенә күченеп киткәнче, Тайсуганда мәдрәсә тәмамлагач, «шул төбәктәге бер авыл имамы» булуы теркәлгән.

Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиновның бертуган Рәмиевләр белән аралаша башлаган елларда дини, иҗтимагый-тарихи һәм тәрбияви эчтәлекле «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана» һ. б. хезмәтләре генә түгел, 1898 елда «Сәлимә, яки Гыйффәт» исемле романы да нәшер ителгән була. Бераз соңрак аның тагын бер күләмле әдәби әсәре – «Әсма, яки Гамәл вә җәза» бәяны дөнья күрә. Дөрес, ул вакытта әле бик күпләр ул әсәрләрне мөфтияттә эшләүче танылган дин вәкиле, казый Риза хәзрәт язган дип белмиләр. Чөнки ул әсәрләр әүвәл башка кеше исеме, «Гафил бине Габдулла» исеме белән басылып чыкканнар. Әмма шунысы гыйбрәтле: ул әсәрләрнең берсендә шагыйрь Дәрдемәнднең дә бер шигыре – «Үткән көннәр»е киң җәмәгатьчелеккә тәүге тапкыр тәкъдим ителә. Ул дәвердә әле Дәрдемәнд тәхәллүсе белән шигырьләр иҗат итүченең шәхсән кем икәнлеген бик күпләр, шул исәптән әлеге әсәрләр авторы да белмиләр. Уфада һәм Оренбургта даими рәвештә очрашкалап торган мизгелләрнең берсендә, зыялырак халык арасында Риза хәзрәт каләме аша үткән әсәрләр хакында әңгәмәләр куерган көннәрдә, ике автор да үз тәхәллүсләренең серләрен ачканнар булса кирәк. Әйе, мөфтият казые да ул елларда Оренбург төбәгенә еш килгәләп йөргән. Хөсәенов, Рәмиев ише байлар тарафыннан оештырылган җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрне ачу тантаналарына да, андый уку йортларын ачарга каршы килүчеләрне күндерергә кирәк булганда да, монда Ризаэтдин казыйның килүе кайбер истәлекләрдә теркәлгән.

Ризаэтдин хәзрәт «Тәрҗемәи хәлем» язмасында әдәби әсәрләр иҗат итәргә керешкән чоры турында мондыйрак аңлатма бирә: «Сәлимә...» илә «Әсма»ны галимнәр җәмәгатеннән булган затлар сөймәделәр. (Сүз, әлбәттә, дин тарафдарлары, дин галимнәре турында бара. – *Л. Х.*) Әгәр дә минем әсәрем икәнен белгән булсалар, башыма кыямәтләр кубарачаклар иде. Фәкать авторлары билгеле булмаганлыктан, беркадәр сүрелделәр», – дип яза хәзрәт.

Аның «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәре 1898 елда Казанда, «Әсма, яки Гамәл вә җәза»сы 1904 елда Оренбургта басылып чыкканнар. Хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф әтисенең бу күләмле әдәби әсәрләрен язарга керешүенең сәбәпләрен түбәндәгечә бәян итә. «Әткәйнең күп еллардан соң сөйләгән сүзләре: «Сәлимә...» белән «Әсма»ны... язуыма сәбәп роман тәртип итү генә түгел иде, бәлки күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып,

укучыларга ирештерү иде», – дип яза ул «Ризаэтдин Фәхретдин» китабында урнаштырылган истәлекләрендә (Казан, 1999).

Димәк, күпсанлы дини, иҗтимагый-тәрбияви эчтәлекле китапларында әйтеп бетерә алмаган фикерләрнең әдәби әсәр аша халыкка уңышлырак җиткерелүен аңлап эш иткән икән Риза хәзрәт. Сүз уңаенда шуны да искәртеп үтик: бөек акыл иясе әлеге алтышар, сигезәр табаклы әсәрләренең, гәрчә нәшер ителгән китапларында «хикәят» дип тамгалануына карамастан, жанр дәрәҗәсе буенча киңрәк, тулырак атамага ия булганлыгын да чамалаган. Хәзерге заман әдәбият галимнәре дә ул әсәрләрне повесть яисә роман дип билгеләү ягында. Фәкать «Әдипләребез» белешмәлегендә (2009) генә алар «хикәя» дип күрсәтелгәннәр. Күренекле әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов та Риза хәзрәт эшчәнлегенә багышланган конференциядә сөйләгән докладында ул әсәрләрне роман буларак бәяләгән иде. «Чыннан да, һәр ике әсәр дә образларның бирелеше, вакыйгаларның бәян ителеше, идея эчтәлекләре белән роман дип аталырга лаек», – дип яза ул шул конференциягә багышланган җыентык битләрендә (Ризаэтдин Фәхретдин: мирасы һәм хәзерге заман. 2003, 152 б.). Профессор Мөхәммәт Гайнуллин да: «Татар әдәбияты тарихы»ның II томында урнаштырылган хезмәтендә ул әсәрләрне повесть буларак билгели һәм, аларны бәяләп, «татар проза жанрын үстерүдә Р. Фәхретдиновның да зур өлеше бар», – дип яза.

Риза хәзрәтнең Оренбург шәһәренә күченү һәм бертуган Рәмиевләр белән аралашып яшәү мизгелләрен алдарак бәян итәрбез.

## 2

XIX йөз ахыры белән XX йөз башларында проза жанрында эшләүче язучылар саны бермә-бер арта. Оренбург төбәгенә бәйләнеше булган язучылардан бу чорда шул шәһәрдә яшәп киткән Гаяз Исхакыйны алдарак телгә алдык инде. Шул чорның шулай ук күренекле әдипләреннән булган Фатих Кәрими дә бу елларда бик актив эшли. Ике гасыр аралыгында аның «Салих бабаның өйләнүе» (1897), «Җиһангир мәхдүм» (1900) кебек күләмле хикәяләре, «Бер шәкерт илә студент» (1899) һәм «Мирза кызы Фатыйма» (1901) повестьлары нәшер ителә. Соңрак «Хыялмы? Хакыйкатьме?» повесте (1908), «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1902), «Кырымга сәяхәт» әсәре (1904) һәм Балкан сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Истанбул мәктүпләре» китабы (1913) дөнья күрәләр. Ул – шулай ук бер дистә чамасында дәреслек, ике дистәдән артыграк исемдә фәнни-популяр китап һәм тәрҗемәләр авторы да.

Әдипнең Совет хакимияте чорында башкарылган, әмма ләкин нәшер ителү барышында туктатылган тагын бер хезмәтен искә аласы килә. Әйе, ул вакыйга автор өчен уңышсыз тәмамлана.

Бүген аны да искә алып китү кирәктер. Әдипнең ул хезмәте «Рухият» фонды тарафыннан 2000 елда нәшер ителгән «Фатих Кәрими» китабындагы тәрҗемә хезмәтләре исемлегендә дә теркәлмәгән. Вакытында басылып чыкмавы сәбәпле хаклы рәвештә ул анда кертелмәгән. 1992 елда миңа Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романын басмага әзерләү бурычы йөкләнгән иде. Ул китабына олуг әдипнең Мәскәү түрәләренә атап русча язылган күләмле бер хатының тәрҗемәсен дә тәкъдим иттеләр. Шул хатында әдип алда исеме аталган шушы романны русчага тәрҗемә иткән Фатих Кәрими хезмәтеннән канәгать булмавын белдерә. Аның кулъязмасын типографиягә төшерүгә мин каршы киләм, ул әсәрне рус әдәбиятын яхшырак белүче башка кеше тәрҗемә итәргә тиеш, ди. Ф. Кәрими тарафыннан тәрҗемә ителгән бу хезмәт шул рәвешле юкка чыгарыла. Әмма без аның шундый эшкә талпынып караганлыгын истә тотарга тиешбездер, мөгаен.

Фатих Кәрими белән бер үк елларда Чистайдагы Закир ишан хәзрәтләре мәдрәсәсендә белем алган Галиәсгар Гафуров-Чыгатай да шәриктәшеннән калышмаска тырышкандыр, күрәсең. Ике гасыр аралыгында матбугатта аның исеме дә еш телгә алыначак. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң берникадәр вакыт Бозаулык шәһәре мулласы булып торган елларында ул «Тәрҗеман» газетасында хатын-кызлар хокукына кагылышлы мәкаләләр дә бастыра. Шуннан соң аның ике өлештән торган «Тутам, яхуд Яшь гомерем» повестеның беренче өлеше 1902 елда Оренбургта Кәримов ахун басмаханәсендә дөнья күрәчәк. Бу авторның Бозаулык шәһәрендә мәчет имамы булып торган дәвердә – 1898 елда җәдиди ысулда укытуга керешкән укытучылар өчен махсус курслар оештыруын да искә алырга кирәк. Дөрес, ул курсларны оештыру яңа төр мәктәпләр ачуга күп көч түккән һәм күп акча тоткан Гани бай Хөсәенов белән берлектә башкарыла. Галиәсгарның шәриктәше Фатих Кәриминең шул ук елларда Татар Каргалысы бистәсендә шул ук Хөсәенов Гани бай ярдәме белән уздырылган андый курсларны галимнәребез еш телгә ала. Ә Галиәсгар Гафуровның шундый ук эшчәнлеге исәпкә алынмый. Моның төп сәбәбе, мөгаен, Чыгатайның ул дәвердә мулла булуына бәйледер. Совет хакимияте елларында муллаларның андый эшчәнлеге дә бик сирәк искә алынды ич... Бозаулык каласының Оренбургтан ерак булмавын, Галиәсгар Гафуровның шәриктәше Фатих Кәрими, шәһәрдәше Ярулла Вәлинең бертуган Хөсәеновлар белән даими рәвештә аралашып торганлыгын искә алсак, аны да Оренбург төбәге зыялылары төркеменә кертергә хаклыбыз. Фатих Кәрими шул гасыр башында нәшер ителгән бер хезмәтендә шәриктәшенең эшчәнлеген югары бәяли. «Мулла буларак ул җәмигъ мәчет карамагындагы мәктәптә яшьләрне заманча тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. Әдәбият җәһәтеннән дә Галиәсгар әфәнденең тәкъдир итәрлек... бер кач әсәрләре бардыр. (Аларның) басылып таралулары бик матлубтыр (сораладыр)», – дип яза ул.

Галиәсгар Гафуровның икенче дус каләмдәше Ярулла Вәлиевнең дә башлангыч иҗат чоры шушы Бозаулык шәһәренә бәйле. «Ярулла әфәнденең «Мәңгелек мәсҗед», «Күз яше» исемләрендә язылып таралмыш булган ике рисаләсе (әсәре)… бик ачык вә хуш лисан (тел) белән язылмыштыр», — дип бәяли каләмдәшенең тәүге чор әсәрләрен Ф. Кәрими 1903 елда язылган бер хезмәтендә.

Әдәбият галимнәре язучы Ярулла Вәлине 1990 елларгача шушы Бозаулык шәһәре сәүдәгәре буларак кына белдерделәр. Чынлап та, ул шушы төбәкнең уртакул сәүдәгәрләре исәбендә йөргән. Әмма «Дәрдемәнд» альбомын әзерләү дәверендә табылган документларда аның Буа шәһәре янәшәсендәге Рангун авылыннан булганлыгы ачыкланды. Чыгатай тәхәллүсе белән әсәрләрен бастырган Галиәсгар мулла белән Ярулла, 1906 елгача якыннан аралашып, бер шәһәрдә яшәгәннәр. Икесенең дә беренче иҗат үрнәкләре Фатих Кәрими атасы ачкан басмаханәдә, чордашлары каләме аша үтеп нәшер ителгәннәр. Ә Рәмиевләр нәшер итәргә ниятләгән «Вакыт» газетасы мөхәррире итеп билгеләнгәч, Фатих Кәрими тиз арада өметле әдип буларак кабул иткән чордашы Ярулланы да Оренбургка чакырып китерә. Һәм бертуган Рәмиевләр белән килешеп, Ярулланы «Вакыт» газетасына хуҗалык һәм финанс эшләре өчен җаваплы кеше итеп билгеләячәкләр. Ярулла үзенә йөкләнгән бурычны бик уңышлы дәвам итеп, киләчәктә тагын да дәрәҗәлерәк үрләрне яулаячак. Бераздан соң ул Рәмиевләрнең чит ил җиһазлары белән тәэмин ителгән «Вакыт» басмаханәсен оештыруда актив катнашып, аның мөдире итеп билгеләнәчәк. Бу шәхеснең иҗаты турында сүз алдарак булыр.

Бертуган Рәмиевләр «Вакыт» газетасын чыгару хәстәренә 1905 елның көзендә, приискалардагы сезонлы эшләрне тәмамлап кайткач керешәләр. Әмма ләкин газетаны сыйфатлы итеп туплап чыгарырдай кешеләрне сайлау һәм оештыру эшләре ике-өч айга сузыла. Өч-дүрт ел элек кенә Шакир Рәмиевнең тәрҗемәчесе рәвешендә Европа илләре буйлап бергә сәяхәттә йөреп кайткан Фатих Кәрими дә ул эшкә тиз генә керешә алмый. Башка хезмәткәрләрне, шул исәптән аның урынбасарын сайлау аңа йөкләнгән була. Ул чорда әле Оренбургта андый эшне башкарырдай кешеләр булмый. Ул төбәктәге шул чор тарихын ярыйсы ук өйрәнгән Мәдинә Рәхимкулова: «Фатих Кәрими Галиәсгар Гафуровка да тәкъдим ясаган булган. Ләкин ул, башлаган эшемне ташлап китә алмыйм, дип җавап биргән», — дигән иде. Шуннан соң, бу вазифаны башкарырдай белемле, тәҗрибәле кеше буларак, Ризаэтдин Фәхретдиновны чакыру фикеренә киләләр. Ә көндәлек эшне — гадәти редактор (ул заманда әйтелгәнчә — корректор) вазифасын башкарырга Габдулла Тукай да чакырылган була дигән хәбәрләр дә бар. Әмма аның яңарак килеп урнашкан Казаныннан китәсе килмәгән. Озакламыйча Оренбургка, корректор эшен башкарырга дип, Шәриф Камал чакырып китерелә. Башкаладагы «Нур» газетасында эшләп берникадәр тәҗрибә туплаган һәм шунда ук тәүге

әсәрләре күренә башлаган Шәриф Камалның Оренбургка кайчан килеп төпләнүе әлегә архив документлары белән расланмаган. Кайберәүләр аны, «Шура» журналына «Уяну» хикәясен җибәргәч, ул хикәя Рәмиевләргә бик ошагач чакырылган, дип язалар. Хикәя 1909 елда басылып чыга. 1964 елда Оренбургта бер очрашу вакытында язучы Шакир Мөхәммәдевнең кияве Тәүфыйк ага Сабитов: «Ул хикәя монда килгәч язылмадымы икән?» – дип тә әйткән иде. Ш. Камалга чаклы «Вакыт» газетасында корректор эшен кемнең башкарганлыгы ачыкланмаган.

Ш. Камалның Оренбургта яшәгәндә иҗат ителгән күпчелек әсәрләре әүвәл «Шура»да басылып чыккан, аннары Рәмиевләр хисабына «Вакыт» нәшриятында китап рәвешендә нәшер ителгәннәр, дип әйткән иде Тәүфыйк ага. Аның исә Рәмиевләр ачкан «Вакыт» типографиясе белән бәйләнеше барлыгын миңа Оренбург кешеләре сөйләгәннәр иде инде. Әмма бу язучы киявенең анда нинди вазифа үтәгәнлекне сорашмаганмын.

Шул ук елларда «Шура», «Чүкеч» журналларында да эшләп – күренгәләп киткән Зариф Бәшири «Замандашларым белән очрашулар» китабында (1968) Рәмиевләрнең матбага хезмәткәрләренә яхшы эш хаклары түләүләрен искә ала. «Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, матбагачыларга зур жалованье бирә иде. «Вакыт» редакторы Фатих Кәрими белән «Шура» редакторы Риза казый аена йөз утыз сум алдылар. Моны күпләр «министрлар жалованьесе» дип әйтер иде», – дип яза. Шул ук елларда Рәмиевләр Оренбургның бер үзәк урамында, Шакир Рәмиев йорты белән янәшәдә, матбугат хезмәткәрләре өчен дип, аерым йорт та төзиләр. Бер этажлы, өч секцияле ул йортның ике секциясендә Ризаэтдин хәзрәтнең ишле гаиләсе урнашачак. Соңгы секциядә исә шулай ук башка шәһәрдән чакырып китерелгән Борһан Шәрәф, Кәбир Бәкер кебек журналистлар яшәячәк. (Эшкә кабул ителү документларында аларны «Рәмиевләр йортында яши» дип теркәгәннәр.)

* * *

1906 елның язында Рәмиевләр баш мөхәррирнең урынбасары вазифасын (рәсми документларда «икенче редактор» диелгән) башкару эшен Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиновка тәкъдим итү фикере белән килешәләр. Бу вакытта Риза хәзрәт яңарак кына өченче мәртәбә мөфтиятнең казые – мөфтинең төп ярдәмчеләреннән берсе вазифасын үтәргә сайланган була. Аның язучылык эшен бик тә үз иткәнлеген, елына бер-ике китап чыгармыйча калмаганлыгын истә тотып, Риза казыйны Оренбургка китерү мәсьәләсендә Рәмиевләр дә бик тырыша, әлбәттә.

Шул рәвешле 1906 елның май аенда Риза казый гаиләсе Оренбургка килеп төпләнә. Үзе «Вакыт» редакциясендә баш мөхәр-

рир урынбасары буларак эшкә керешә. Озакламыйча өлкән улы Габдрахманны да шушында эшкә алачаклар.

Фатих Кәриминең әнисенең энесен Уфадагы мөфтияттән үгетләп Оренбургка кайтару бурычын, әлбәттә инде, бертуган Рәмиевләр башкарган. Ике елдан соң, Ризаэтдин хәзрәт «Шура» журналы мөхәррире итеп күчерелгәч, «Вакыт» газетасында аның урынына улы Габдрахман калдырылачак. Риза хәзрәт, бертуган Рәмиевләр белән килешеп, кулга-кул тотынышып дигәндәй, үзенә тәкъдим ителгән һәм үз хыялында йөргән эшне бик теләп һәм яратып башкара. «Шура» журналы большевиклар карары белән ябылганчы, шунда эшли. 1918 елның февралендә аларның Дәрдемәнд белән соңгы күрешү вакыйгасы хәзрәтнең кызы Әсма Шәрәф истәлекләрендә китерелә. Югыйсә безнең матбугатта аларның соңгы мәртәбә очрашуы Дәрдемәнд бик каты авырып ятканда, 1921 елның көзендә булган дигән уйдырма язмалар да булгалады. Имеш, Риза хәзрәт, Уфадан Орск шәһәренә килеп, яшьтәшен һәм фикердәшен бик авыр хәлдә күргән. Ул заманда түгел, әле бүген дә Уфадан Орск шәһәренә бару өчен берничә төрле транспорттан файдаланырга, кимендә ике көнне сарыф итәргә кирәк. Ә 1921 елда әле Оренбург белән Орск арасындагы өч йөз илле чакрымлы тимер юл да төзелә генә башлаган була.

Дәрдемәнд белән Риза Фәхретдиновның аерылышу вакыйгаларын хәзрәт кызы Әсма Шәрәф истәлекләреннән укып китик. «Оренбургта торганда, әткәйнең ике арада самими дуслык, ихтирам саклаган кеше Закир әфәнде Рәмиев (Дәрдемәнд) иде. Закир әфәнде үзе дә безгә еш кына әткәй янына килеп, озаклап утырырга ярата иде. Оренбургтан китәргә әзерләнгән вакытта (1918, февраль урталары), Закир әфәнденең өйләренә әткәй саубуллашырга барып кайта. Күп сүзләр арасында Закир әфәнде әткәйдән сораган: «Хәзрәт, әгәр дә дөньялар тынычланып, заманчарак итеп «Шура» журналы чыгу ихтималы булса, кире кайтыр идегезме?» – дип. Әткәй, озак уйлап тормастан: «Һичшиксез, кире кайтыр идем», – дигән.

Бу аларның актык күрешүләре булган. Юлга чыгып китәр һәм өйдә калдырыр өчен дә акча кирәк булгач, әткәй кайбер китапларын «Өлфәт» китап кибетенә сата. Аннары, ат-чана яллап, Иманкол, Мәләвез, Җиргән, Эстәрлеләр аша башта үзе генә китәргә була. Шул рәвешле юл барганнан соң, 1918 елның 1 мартында әткәй исән-сау Уфага барып җиткән... Әткәйгә генә түгел, безнең бөтенебез өчен дә унике ел торган Оренбургтан аерылып китү авыр булды. Чөнки безнең анда яшәгән еллар иң бәхетле, иң күңелле еллар иде. Әткәй – «Шура»да, Габдрахман абый «Вакыт» газетасында эшләде, калганнар укуда булды», – дип яза Әсма апа атасына багышлап чыгарылган китапта (Ризаэтдин Фәхретдин. Казан, 1999).

Бервакыт миңа да күрше йортта яшәгән Әсма апа белән очрашырга насыйп булган иде. Кайберәүләрнең Дәрдемәнд белән

Риза хәзрәтнең 1918 елның февраленнән соң да очрашулары турындагы хәбәрен искә алдым. «Юк, ул буталчык елларда әткәй Уфадан беркая да чыкмады. Андый очрашулар булса, без белмичә калмас идек», — диде Әсма апа.

Шул ук истәлек язмаларында Әсма апа Шакир Рәмиев йорты янәшәсендәге йортта яшәү көннәрен дә бераз тасвирлаган. Шакир йорты артындагы зур бакча җәй дәвамында алар карамагында булган. Рәмиевләр җәй айларын шәһәрдән бик еракта урнашкан приискаларында уздырганнар.

Әлбәттә, бу елларда Дәрдемәнд, Ризаэтдин хәзрәт, Г. Исхакый, Ф. Кәримиләрдән аерымрак төбәктән — Буа шәһәреннән булган Шакир Мөхәммәдевне һәм аның хезмәтләрен дә атамый үтү килешмәс. Шакир Мөхәммәтша улы унбиш яшеннән Оренбург шәһәренә килеп урнаша. 1884 елдан шәһәрнең иң бай сәүдәгәрләре Хөсәеновлар конторасында төрле эшләр башкара. Ике гасыр аралыгында гына, бер Мәскәү сәүдәгәренә ялланып, ике-өч ел Харбин каласында булып кайта. Шакир Мөхәммәдевнең Харбинда булганда иҗат ителгән «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» әсәре генә 1901 елда Казанда нәшер ителгән. Киләсе елда ул кабат Оренбургка кайтып, Хөсәенов байлар конторасында исәп-хисап эшләрен башкаруын дәвам иттерәчәк. Калган барлык хикәя һәм повестьлары бер-бер артлы Оренбургта Кәримовлар басмаханәсендә дөнья күрәчәк. Һәм берара ул шунда «Карчыга» исемле көлке-сатира журналын да нәшер итәчәк әле. Ул 1923 елда шул калада гүр иясе дә була. Аның эш өстәлендә иганәче Хөсәенов бертуганнарның берсенә багышланган, әмма тәмамланмаган әсәре кала, диелә бер белешмәлектә. Бу чорда Шакир Мөхәммәдевнең Рәмиевләр белән бәйләнеше матбугат битләрендә бик теркәлмәгән булса да, 1960 елларда Оренбург зыялылары аның төрле җыелыш-утырышларга даими йөргәнлеген, зыялы катлау белән актив аралашканлыгын искә алалар иде. «Вакыт» газетасында да аның мәкалә-язмалары чыккалап торган.

## 3

Безнең әдәбият гыйлемендә элек Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән шәхесләрнең эшчәнлеген барлау өлкәсендә беркадәр сүлпәнлек тә сизелә кебек. Ә кайбер фактлар турында язганда, төгәлсезлекләр дә очрап куйгалый. Узган ике гасыр аралыгында шул төбәктә яшәп иҗат иткән кайберәүләрнең әдәби эшчәнлеге, әдәби талпынышлары исә күп очракта телгә дә алынмыйлар. Мәсәлән, Г. Исхакый, С. Максуди, Х. Ямашевлар белән бер чорда Казан укытучылар мәктәбендә укыган, узган гасыр башларында иҗат «җимешләре» әдәбият сөючеләргә мәгълүм булган шәхесләрдән Габдрахман Дәүләтшин-Хөсәенов (Әхмәт бай

Хөсәенов өендә тәрбияләнгән), Шакир Мөхәммәдьяров (Орск шәһәрендә туган, Дәрдемәнд кебек үк, шундагы Борнаев сәүдәгәр кызына өйләнгән), Ярулла Вәлиев (Сембер губернасында туган), Габдерәүф Ниязбаев (Оренбург янәшәсендәге Каргалы каласында туган) исемнәрен алыйк. Ул чорда бит аларның үз драма әсәрләре дә, А. Пушкин, Н. Гоголь, А. Островскийларның әсәрләреннән тәрҗемәләре дә яңа туып килүче театр сәхнәләреннән төшмичә уйналган. Газеталарда әдәбият, мәдәният темасына язган хезмәтләре даими рәвештә басылып килгән. Мәсәлән, Габдрахман Дәүләтшинның «Яшь хатын» драмасы, Совет хакимияте урнашканчы, күп кенә театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелә. Яңа хакимият чорында гына «бу буржуй»ның үз әсәре дә, тәрҗемә пьесалары да уйналмаганнар. Аның әдәби хезмәтләренең кайчандыр үзешчән сәхнәдә уйнаганда кабул иткән «Д. Таждаров» тәхәллүсе белән дөньяга чыгуын да әйтеп үтү кирәктер.

Болар төркеменә шул ук уку йортын тәмамлаган, иҗади хезмәткә бәйле еллары шул ук Оренбург каласында узган Тимерша Соловьёвны да кертергә кирәктер. Аның да берничә китабы XX гасыр башында Кәримовлар басмаханәсендә нәшер ителгән. Һәм 1918 елларгача монда ул нашир буларак та шактый танылган шәхес була.

XIX йөз урталарында иҗат иткән, Пушкинның остазларыннан саналган В. Жуковский белән таныш булган, шуның ярдәмендә өч күләмле поэмасының берсе рус телендә дә басылып чыккан бугай дип фаразланган Гомәр Мөхәммәт улы Каргалый исеме бөтенләй безнең әдәбият тарихыннан сызып ташланган. Россиянең икенче мөфтие, Оренбургтагы беренче мәчет имамы Габдессәлам бине Габдерәхим әл-Бөгелмәвигә багышланган «Тәзкирәи мөфти Габдессәлам» (1832) һәм «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837, булачак патшаның Оренбург төбәгенә сәяхәте тасвирлана) һ. б. поэмалары элекке башкала архивларында сакланган бу авторны совет чорында телгә алмауның мәгънәсен аңларга була. Ул заманда муллалар яки патшалар исеме уңай яктан телгә алынган әсәрләр хупланмады. Ә бит бу поэмаларның исем-атамасында мулла яисә патша исеме телгә алынса да, аларның төп эчтәлеге шул заман татар тормышын, татар дөньясын тасвирлауга да багышланган. Бүгенге заман татар укучысы Рәсәйнең иң тәүге мөфтиләренең берсе булган Габдессәлам хәзрәткә багышлы поэманы да, булачак император Александр II нең шушы төбәккә килеп, җирле халык белән аралашып йөрүен тасвирлаган әсәрен дә кызыксынып кабул итәр иде дип уйлыйм. Оренбург янәшәсендәге Каргалыдан чыккан Гомәр Мөхәммәт улының шул чорга багышлы өч күләмле әсәре бүгенге көндә С.-Петербург белән Ташкент мирасханәләрендә саклана, дип язды галим Мәсгут Гайнетдинов. Аларның күчермәләрен генә булса да үзебезгә кайтарырга вакыт җиткәндер дип уйлыйм.

* * *

Татар энциклопедиясенең бер томында «издатель, журналист» буларак кына теркәлгән Тимерша Салаватулла улы Соловьёвның да иҗат юлы хикәя, бәяннар иҗат итүдән башланган, дидек. Ниһаять, «Татарская энциклопедия» томнарының 5 нчесендә (2016, 328 б.) аңа багышланган мәкаләне уку өлешчә генә булса да күңелне сөендерде. Димәк, ул да искә алынган. Ә «Әдипләребез» белешмәлегенә нишләптер аны әдәби иҗатчы буларак кертмәгәннәр. Кайбер хезмәтләрен «Саллави» тәхәллүсе белән дә бастырган бу шәхеснең татар әдәбияты, татар мәдәнияте өлкәсендә хезмәтләре искә алынырга тиештер. 1900 елда Оренбургта татарча басмаханә ачкан элекке ахун Гыйльман Кәримовның өлкән кызы Гасыйманың ире, димәк ки, Фатих Кәримигә дә, Риза хәзрәт Фәхретдингә дә кияү булган бу кеше байтак еллар «Кәримовлар басмаханәсе»нең мөдире дә булып тора ич. Бу басмаханәдә йөз җитмештән артыграк татарча китап басылган дип саный китап белгечләре. Шуларның күпчелеге, минем исәпләвемчә, Казанда Учительская школада белем алган Тимерша Саллави фатихасы белән чыккан булырга тиеш. 1906 елгача ул каенагасы һәм каенишләре белән бергә «Кәримовлар басмаханәсе»н яшәтүдә катнашан. Ә 1906 елда, ул басмаханәне заманча техника белән яңарту кирәк булгач, Кәримовлар гаиләсе Мәхмүт бай Хөсәеновка мөрәҗәгать иткән. Шул рәвешле яңа ширкәт – «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» һәм яңа идарә барлыкка килә. Ширкәт рәисе итеп бу басмаханәне яңача җиһазландыру өчен күп акча тоткан Мәхмүт бай улы Хөсәен, типография мөдире буларак Тимерша кияү билгеләнә. Яңарак кына «Вакыт» газетасы мөхәррирлегенә тәгаенләнгән Фатих Кәрими исә төп киңәшче вазифасын үтәүче буларак кала. Сеңлесе, матбагачы Борһан Шәрәф җәмәгате Закирә* хәбәр итүенчә, берничә елдан соң ул ширкәттән китәчәк. Бу вакытта Фатихның энеләре Гариф белән Камил дә Оренбургта булмыйлар. Мәхмүт бай Хөсәенов акчасы исәбенә яңартылган, җиһазландырылган типография уңышлы эшли башласа да, Фатих аның идарәчелеге эшеннән канәгать булмый. «Фатих абзый, забрав свой пай, вышел из состава учредителей», – дип яза Закирә Шәрәф (Фатих Кәрими. 2000, 147 б.). Шул пай акчасына ул тиздән Кәрвансарай урамында йорт сатып алачак һәм бар көчен үз иҗади эшчәнлегенә һәм «Вакыт» газетасын нәшер итүгә юнәлдерәчәк. «Фатих абзый аерылган типографиягә яңа кешеләр кушыла. Казаннан Галиәсгар Камал әфәнде дә бөтен гаиләсе белән күчеп килә. Шул типографиянең өске катында өч бүлмәле фатирга урнаша. Тик озак тормый. Янә Казанга китәләр», – дип яза Закирә.

---

* Исем 2000 елда «Рухият» нәшриятында чыккан «Фатих Кәрими» китабында теркәлгәнчә. – *Л. Х.*

Тимерша исә, каенатасыннан калган басмаханә мөдире булудан тыш, 1906–1910 еллар аралыгында «Чүкеч» сатирик журналының мөхәррире вазифасын да үтиячәк. Мөгаен, ул мәҗмугада да аның үз сатирик вә юмористик әсәрләре дә вакыт-вакыт күренгәләгәндер.

Мәрхүм академик Әбрар ага Кәримуллин – татар телендә китап басу эшләрен төпле өйрәнгән шәхес. Бу өлкәдә ул зур мирас калдырды. Ләкин Оренбург архивлары белән якыннанрак таныш булмау сәбәплеме, яисә «Кәримовлар басмаханәсе»н яшәтүчеләрдән Фатих Кәримигә күбрәк өстенлек бирергә теләүдәнме, «Тимершаһ кияү»нең эшчәнлеген ул беркадәр күләгәдәрәк калдыра кебек. Соңгы китабында Әбрар ага Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсенең фактик хуҗасы Ф. Кәрими, нинди китапларга юл ачуны ул хәл иткән, диебрәк тә яза. Кемгәдер ялланган хезмәтче ничек хуҗасының мал-мөлкәтенә хуҗа була алсын икән? Бигрәк тә, үзе дә әдәбият өлкәсендә каләм тибрәткән, шул чор әдипләрен яхшы белгән Дәрдемәнд кебек, хуҗаның кул астында эшләгән килеш? Шушы мәсьәләгә кагылышлы бер мисалны искә төшереп үтик. Дәрдемәнднең Фатих Кәримигә язган хатлары арасында «Вакыт» басмаханәсенә бәйле бер хат та сакланган. Ул 1912 елның 22 октябрендә Орск өязеннән җибәрелгән. «Галимҗан Ибраһимовның китап кулъязмасы миндә, ала кайтырмын. Аңа Киевка 75 сум акча йибәреңез», – диелгән ул хатта.

Шул ук китабында галим, «атасы вафатыннан соң Фатих Кәрими «Кәримовлар басмаханәсе»нең төп хуҗасы булып кала», китап басу тәртибен ул гына хәл итә дигәнрәк фикер дә үткәрә. Дөрес, 1902 елның җәеннән 1906 елга чаклы басмаханә белән җитәкчелек итү Фатих мәхдүм карамагында була. Энеләре һәм Тимерша кияү ул чорда аның кул астында йөриләр. Әмма тиздән Гариф Кәримов – Мәскәү, Камиле Казан университетында укый башлый. Димәк, Оренбургтан китәләр. Кул көче кулланып эшләтелгән иске басма станок ике кеше карамагында кала. Әйе, аталары вафат булгач (1902, июнь башы), элекке йортларын, сыер, атларын сатканнан һәм Шакир Рәмиевтән 3 мең сум акча алып торганнан соң, бу типографиягә икенче искерәк станок та алына. Ләкин уңышлы эшләп китү өчен, ул чаралар да җитәрлек булмый, басмаханә зур табыш китерми. Алынган заказларны үтәү вакытлары бик еш кичектерелә, басма китапларның сыйфаты да күпләрне канәгатьләндерми. Шуның өстенә Ф. Кәримине 1906 елның башында «Вакыт» газетасы мөхәррире итеп билгелиләр. Аның үз басмаханәсе эше белән шөгыльләнергә вакыты чамалы кала. Басмаханәгә иркенрәк бина, яңарак җиһазлар алу нияте белән алар сәүдәгәр Мәхмүд Хөсәенов гаиләсенә мөрәҗәгать итә. 1906 елда «Кәримов, Хөсәенов вә шөрякәсе» ширкәте шул рәвешле оештырыла. Аның рәисе итеп Мәхмүд бай улы Хөсәен билгеләнә. Ул, нигездә, яңа җиһаз алу, китап сатуны оештыру, башка төбәкләрдә басмаханә филиалларын ачу һәм тоту (мәсәлән,

Уфада) өчен җаваплы була. Тимерша Соловьёвка басмаханәнең мөдире вазифасын үтәү йөкләнә. Шуңа чаклы да ул инде басмаханә эше өчен җаваплы булган. Абыйсына багышланган китапта Фатих Кәрими сеңлесе Закирә бу вакыйгаларны белебрәк яза. «Абый бераздан соң үз паен алып ул ширкәттән чыкты», – ди бит.

Сүз чыккач, Кәримовлар нәселенең икенче киявен – Казан матбагачылары Шәрәфләр нәселеннән булган Борһанны да искә алып үтик. 1908–1924 елларда ул да Оренбургта яшәячәк. Шул шәһәргә барып төпләнү тарихы да аның Рәмиевләргә бәйле була. «Әхбар» («Хәбәрләр») газетасында басылган бер тәнкыйди мәкаләсеннән соң Казан полициясе Борһанны 1908 елда туган ягына сөргенгә җибәрергә дип карар чыгара. Ул исә Оренбургка китә, «Вакыт» газетасына хәбәрче буларак кабул ителә. Килгән дәвердә аның «Рәмиевләр йортында яшәве» теркәлгән. (Шакир Рәмиев йорты янәшәсендә матбугат хезмәткәрләре өчен махсус төзелгән йортта.) Шул ук архив материалларында аның 1909 елда «Вакыт» редакциясе тарафыннан Иранга командировкага җибәрелүе язылган. Шул елларда Иранда шаһ хакимиятенә каршы халык күтәрелеше булып ала. Борһанның шул вакыйгаларны чагылдырган язмалары соңрак «Вакыт» битләрендә «Иран мәктүпләре» исеме белән басыла. Шуннан йөреп кайтып күпмедер торгач аны «Вакыт» газетасы баш мөхәрриренең урынбасары итеп билгеләячәкләр. «Шура» журналын чыгарырга рөхсәт алынып, Ризаэтдин хәзрәт шуның мөхәррире итеп тәгаенләнү вакыйгаларыннан соң.

Ләкин аның анда кайчан тәгаенләнүе турындагы документны тапмадым. Риза хәзрәт «Шура» журналы редакторлыгына күчерелгәч, берара ул вазифаны аның улы Габдрахман Фәхретдинов башкаруы турында гына белешмә бар. Шул чор архив материаллары белән таныш булган Мәдинә апа Рәхимкулова хәбәр итүенчә, Борһан Шәрәф Иранда бер ел чамасы булып кайткач, Фатих Кәрими сеңлесе Закирәгә өйләнә. Шуннан соң озакламыйча Борһан каенагасының урынбасары итеп билгеләнәдер, мөгаен. Оренбург зыялылары Рәмиевләрнең Борһанга карата хәерхаһ булуын искә алалар. Әйе, Борһанның ага-энеләре Казанда атаклы матбагачылар саналганлыктан, аларның бертуган Рәмиевләр белән үзара мөнәсәбәтләре яхшы булган. Шул төбәк зыялылары кулында бүген дә Борһанның бик күп изге эшләр башкарган иганәче Гани бай Хөсәеновка бәйле истәлек һәм хатларны туплап чыгарган «Гани бай» китабы булыр. Шул ук елларда Б. Шәрәф венгр галиме, атаклы сәяхәтче Г. Вамбериның ике томнан торган «Төркестанга сәяхәт» китабын да тәрҗемә итеп чыгарачак.

1917 елгы вакыйгалардан соң Борһан Шәрәф берникадәр вакыт «Оренбург мөселман бюросы хәбәрләре» газетасы мөхәррире була. Аннары «Хөсәения» мәдрәсәсе нигезендә оештырылган Халык мәгарифе институтында укыта. Шул рәвешле ул ундүрт ел чамасы Оренбург шәһәрендә яшәп, Рәмиев, Хөсәеновлар ке-

бек халык мәнфәгатен кайгыртып яшәүчеләр белән якыннан аралаша.

Шул ук Закирә сеңлесе истәлекләрендә Ф. Кәриминең элекке басмаханә ширкәтеннән киткәннән соң күбрәк вакытын өендә язу, тәрҗемәләр белән мәшгуль булуы, кичке тарафларда Шакир Рәмиевнең өч баласын укытканлыгы хәбәр ителә. Билгеле, Ф. Кәрими бу елларда өйдә генә утырмаган. Бу истәлектә аның сәгать ничәләр тирәсенә чаклыдыр «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләп кайтканнан соң кылган гамәлләре бәян ителә. Закирә ханым Ф. Кәриминең «Кәримовлар басмаханәсе» ширкәтеннән чыгу вакытын төгәл әйтми, 1906 ел вакыйгаларына бәйләп кенә язып үтә. Башка бер чыганакта Ф. Кәриминең бу ширкәттән чыгу вакыты итеп 1909 елның беренче яртысы күрсәтелгән. Мөгаен, бу вакытта инде ул «Тимершаһ кияү» белән дә басмаханә эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләрдә килешә алмагандыр. Закирә ханым да бит әнә шул ук язмасында: «Озакламыйча Фатих абзый белән эшләгән наборщиклар да мөдир белән килешә алмыйча чыгып китәләр», — дип яза. Әмма мөдир җизнәнең исемен атап тормый Закирә.

«Татар энциклопедиясе» китабының татарча 3 нче томында «1914 кә кадәр басмаханә белән Ф. Кәрими идарә итә» дигән сүзләр теркәлгән. Башка төр төгәлсезлекләр дә ул мәкаләгә хас. Әйтик, анда Ф. Кәриминең «100 гә якын китабы» үзләрендә басылган кебегрәк әйтелә. Дөреслектә аның 1918 елга чаклы нәшер ителгән китапларының берничәсе Казан, Петербургта һәм унлабы, шул исәптән 450 битле «Истанбул мәктүпләре» китабы, Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә чыккан. Димәк, бу мәкаләдә төгәлсезлекләр бар. Мәкалә авторы күрсәтелмәгән. Тимерша Саллавиның Кәримовлар басмаханәсендә тулы хуҗа булуы хакында Зариф Бәшири истәлекләрендә дә телгә алына («Замандашларым белән очрашулар», 1968). Т. Соловьёвның Якуп Мамишев иҗат иткән «Шәкертләр садасы» китабын нәшер иткән өчен судка бирелүе вакыйгасы да типография эше өчен кемнең җаваплы булуын дәлилли (кара: Татар әдәбияты тарихы. 1986, 3 т., 70 б.). Аңа чаклы әле Тимершаның Хөсәен Ямашевның «Урал» газетасын нәшер итәргә булышканы өчен җавапка тартылуы да мәгълүм. Бу вакыйгаларда фәкать Тимершаның гына җавапка тартылуы да Кәримовлар басмаханәсенең 1906 елдан башлап кем кулында булуын дәлилли сыман.

Бу шәхеснең туган авылы хәзер Кайбыч төбәгенә караган Шүшермә була. Аның атасы Салаватулланың соңрак Апас тирәлегендә яшәвен әйтүчеләр дә бар. 1920 еллар вакыйгаларыннан соң Тимершаның бер улы Казанда, икесе Мәскәүдә гомер иткән. Оренбург төбәге шәхесләрен барлаучы Мәдинә Рәхимкулованың 1980 еллар ахырында хәбәр итүенчә, Мәскәүдәге улларының берсендә Тимерша аганың зур архивы сакланган була. Анда «Шура», «Чүкеч» һ. б. мәҗмугалар төпләмәләре һәм «Вакыт» газетасы бәйләмнәре дә булган. 1993 елда, Мәскәүгә Бәшир Рәмиев белән

очрашуга барганда, мин ул кешене эзләп тә караган идем. Мәдинә апа миңа аларның адресларын, телефоннарын язып биргән иде. Тимершаның бер улының хатыны Мәрзия миңа ул ике бертуганның соңгы елларда бер-бер артлы вафат булулары турында әйтте. Архив сакланган фатир хуҗасы соңгы вакытларда ялгыз яшәде, ул вафат булганда мин Казанда, туганнарымда кунакта идем. Архив иясе үлгәч, аның фатирын башка кешеләр алган, архивы юкка чыккан, дип сөйләде. Мөгаен, шулай булгандыр да. Тимерша ага үзе 1947 елда 72 яшендә Мәскәүдә вафат була.

Энциклопедиянең русча 5 нче томында, Тимерша агага багышланган мәкаләдә дә ачыклап үтәсе бер урын бар, минемчә, «Ул Түбән Новгородта да яшәде, фәлән кунакханә мөдире булды» дигән җөмләне ачыклыйсы килә. Дөрес, бу шәһәрдә Әхмәт бай Хөсәенов зур бер кунакханә тоткан. Аннан килгән керемне «Хөсәения» мәдрәсәсен яшәтү өчен кулланган. Әхмәт бай исән чакта да, ул вафат булгач та (1906) бу кунакханәнең исәп-хисап эшләрен шул байның конторасында да эшләүче Тимерша ага башкарган. Һәм кайсыдыр елларда шул кунакханәнең мөдире вазифасын да үтәгән. Әмма ул анда даими яшәмәгән. Мәкәрҗә ярминкәсе көннәрендә генә шунда кунакларны кабул итүдә катнашкан. «Мәкәрҗә ярминкәсе»нә бәйле истәлекләрдә ул шул вазифаны үтәүче буларак телгә алына. Әйе, ул анда озаклап яшәмәгән. Белүемчә, аның вазифасы кунакханәне Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә әзерләү һәм ярминкә кунакларын урнаштыру, ашату-эчертү эшләрен күзәтүдән торган. Һәм шул эшләрне башкаруда ярдәмләшү өчен ул, гадәттә, каникулга чыккан мәдрәсә шәкертләрен үзе белән ала торган булган. Гасыйма белән Тимерша гаиләсенең бу шәһәрдә яшәве турында башка истәлекләрдә телгә алынмый. Дөрес, җәйге айларда, ярминкә көннәрендә кунакханә мөдиренең анда гаиләсе белән яшәвенә берәү дә каршы килмәгәндер. Димәк, һәр елны алар гаиләсенең анда берәр ай торып кайтуы ихтималы бар. Гаилә башлыгының шул вазифаны башкарудан киткәч, аларның ул шәһәрдә яшәп калу-калмавын ачыклау кирәктер, мөгаен. Шул хакта мин Мәскәүдәге киленнәре Мәрзиядән дә сорамаганмын. Чөнки әле аларның ул шәһәрдә яшәгәнлекләре хакында хәбәрем юк иде. Казанда яшәгән, Опера театрында ниндидер хезмәт башкарган улы турында да бик соңлап белдем. Бәлки әле, аның балаларында бабаларына бәйле истәлекләр сакланадыр.

Тимерша Соловьёв-Саллавиның китап рәвешен алган һәм әлегә барланган әдәби иҗат үрнәкләре түбәндәгеләр. Аерым дәфтәргә теркәлгән бер язмамда аның беренче китабы «Хикәят» (1900) дип кенә аталган дигәнмен. Энциклопедиядә, Марсель Әхмәтҗанов мәкаләсендә исә 4 китап исеме теркәлгән. Шуларның өчесе – әдәби эчтәлекле әсәрләр китабы: «Мужик илә мулла…» (Оренбург, 1902), «Биби – Казан» (1905) һәм «Ишан Хәдичәсе» (1906). Болар хикәяме, кечерәк күләмле бәянмы (ул заманнар-

да бәянны «озын хикәя» рәвешендә дә тәкъдим иткәннәр), әллә соң романнармы – анысы ачыкланмаган. Әсәр жанрлары энциклопедиядә дә теркәлмәгән. «Мәктәп вә мәдрәсәләрне Духовное собраниегә бирү» китабы (1908), әлбәттә, безнең темага керми. Тимерша Саллавиның үзе нәшер иткән «Чүкеч» һәм башка мәҗмугалар битләрендә дә аерым әдәби парчалары, юмор-сатира әсәрләре басылган булырга тиеш. Ләкин алар әлегә барланмаган дип беләм. Ә узган гасыр башында Оренбургта чыккан татар матбугаты тарихы тупланган архивның бер өлеше Кызыл Урда шәһәрендә саклана дигән хәбәр бар. 1925 елда Казах республикасы башкаласы Оренбургтан шул шәһәргә күчерелгән. Алар, бер вагонга төяп, монда татарча, казахча басылган китапларны, газета-журналларны да алып киткәннәр. Казах язучысы, элек Кызыл Урдада комсомол өлкә комитеты секретаре булган Торсынкулов Калаубәк ул архивның барлыгын белүе турында да сөйләгән иде. Гайнан Корманов сеңлесенең үтенече буенча, ул аннан Гайнанның матбугатта басылган ниндидер язмасын табып җибәрешкән. Безнең берничә галимгә шундый архив барлыгын сөйләгән булсам да, әлегә аның ишеген ачып керүчеләр турында ишеткәнем юк. Ә менә башкорт кардәшләрнең анда да барып җитешкән булуы ихтимал. Соңыннан Уфада яшәп иҗат иткән олуг шәхесләрдән Афзал Таһиров, Давыт Юлтый, Сәгыйть Агиш һ. б., шул исәптән «Башмагым» һәм шуның ише комедия әсәрләре тудырган Хәйбүш Ибрайларның башлангыч иҗат юлы Оренбург каласына бәйле ич.

## 4

Татар әдәбиятына багышланган хезмәтләрдә сирәгрәк искә алынган шәхесләрнең тагын берсе Ярулла Вәли буладыр. «Татар әдәбияты тарихы» тупланмасының 2 нче томында (1985) аның исеме бер урында – Мөхәммәт ага Гайнуллинның «Драматургия»-гә багышланган очеркында телгә алына. Ике гасыр аралыгында иҗат ителгән һәм китап буларак басылып чыккан проза әсәрләрен барлау, бәяләү бүлегендә исә ул автор бөтенләй дә искә алынмый.

Ә хәзер язучы Ярулла Вәли белән якыннанрак танышыйк. Элегрәк, «Татарстан хәбәрләре» газетасы нәшер ителгән кыска гомерле бер мәлдә, ул шәхес турында кечерәк бер мәкаләм басылган иде. «Татар энциклопедиясе»нең русча һәм татарча чыккан вариантларында да шул мәкаләнең сөземтәсе бирелде. Газетада әлеге мәкалә басылганнан соң, миңа Ярулла Вәлиулла улын якыннан белгән берничә кеше белән аралашырга, аның турында кызыклы истәлекләр ишетергә туры килде. Әмирхан ага Еники дә үз биографиясенә бәйле вакыйгаларны тасвир иткән соңгы әсәрләренең берсендә Ярулла Вәли исемен бик җылы итеп искә алган. Яшүсмер елларында Дәүләкәндә яшәгәндә мавыгып, йотлыгып укыган әсәрләре арасында бу язучының шактый күләмле

«Үзеңә кайту» китабы булуын да бәян итә ул. Шушы юлларны укыгач, мин Әмирхан абый белән очрашып та сөйләшкән идем. «Язучы Ярулла Вәлине күреп тә белә идегезме әллә?» – дип тә сорадым. «Юк, якыннан таныш түгел идек. Аның хәл-әхвәлен болай гына, ишеткәләп кенә беләм», – дип җавап биргән иде әдип. Ул яратып укыган «Үзеңә кайту» әсәренең жанры буенча повестьмы, романмы булырга тиешлеген, нәшер ителгән елы 1913 тирәсендәдер, дип әйтүен бер дәфтәрчеккә теркәп тә куйганмын. Әмирхан аганың: «Ул китап минем өстәл өстендә озак ятты, кат-кат укыган идем мин аны. Күршедәге бер кызга күзем төшеп йөргән чаклар иде», – дип сөйләгәне хәтердә.

Узган гасыр башында Ярулла Вәли драма әсәрләре авторы рәвешендә дә бик популяр шәхес була. Аның ике драма әсәре – «Оят, яки Күз яше» белән «Ачлык кушты»сы ул чорда эшләгән барлык театр труппалары тарафыннан да сәхнәләштерелгәннәр дияргә ярыйдыр, мөгаен. «Сәйяр» труппасында бу ике әсәр китап рәвешендә басылып чыккан яисә труппа эшли башлаган көннән үк диярлек даими рәвештә уйналган. Сәхнә тормышына, сәхнә әсәрләрен иҗат итүче авторларга багышланган гаять тә бай эчтәлекле «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында (1988, 398 б. Авторлары – Б. Гыйззәт, Һ. Мәхмүтов, И. Илялова) Ярулла Вәли һәм аның пьесалары исеме еш очрап тора. Менә 41 нче биттәге берничә җөмләгә күз төшереп алыйк. Казанда 1907–1910 елларда «Яшьләр» труппасы актив эшли. «1907–1908 елларда гына да алар Г. Исхакыйның «Ике гашыйк» һәм «Алдым-бирдем», Г. Камалның «Бәхетсез егет», Я. Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Д. Таждаровның «Яшь хатын» әсәрләрен сәхнәләштереп, шактый уңыш һәм популярлык казаналар». Искәртеп үтик, соңгы әсәр авторының чын исем-фамилиясе Габдрахман Дәүләтшин, дип, алда әйтеп киткән идек. Әхмәт бай Хөсәеновның тәрбиягә алган улы. Бер агасының байтак еллар дәвамында «Хөсәения» мәдрәсәсенең имам-хатыйбы (җитәкчесе) булганын да әйтеп үтик. (Югыйсә безнең шул уку йортына багышлы кайбер язмаларда мәдрәсә башлыгы рәвешендә Риза хәзрәт Фәхретдиновны атау очраклары да теркәлгән.) Әдәби әсәрләрен һәм тәрҗемәләрен ул үзешчән театрда уйнаган вакытта кабул иткән тәхәллүсе – Д. Таждаров исеме белән чыгарган. Кайбер хезмәтләрен «Хөсәенов» фамилиясе белән дә нәшер иткән. Габдулла Тукай Казанга килгән беренче елны аны җылы түшәк, «яхшы гына акча түләнгән» эш белән тәэмин итеп торган, үзенең «Китап» нәшриятын булдырган шәхес.

Икенче бер урында, «Сәйяр» труппасының 1910 елда Чиләбе шәһәрендәге гастроле турында язганда: «Оят, яки Күз яше» драмасы аеруча уңыш китерә» дигән җөмләне дә укыйбыз ул китаптан. Бу әсәр аерым китап буларак Оренбургта 1902 елда Гыйльман Кәримов басмаханәсендә басылып чыккан. Бу язучының аңа чаклы һәм аннан соң басылган әсәрләре дә башлыча

шушы басмаханәдә дөнья күргәннәр: «Мәңгелек мәсҗед» 1901 дә, «Әфиюн» 1906 да, «Җанлы җеназа», «Ахырзаман бәласе» һәм «Урман әүлиясы» 1907 елда һәм «Ачлык кушты» драмасы 1908 елда Кәримовлар басмаханәсендә чыккан. Бу тәртиптәге проза әсәрләренең хикәяме, повестьмы булуы әлегә ачыкланып бетмәгән. Г. Исхакый шул чорга багышланган бер хезмәтендә аның драма, хикәяләре белән рәттән «романы» булуын да искә ала. Әмма әсәрнең исемен атамый. «Әдипләребез» китабында алар хикәя буларак теркәлгәннәр. «Оят, яки Күз яше» драмасының басылып чыгу датасы бу белешмәлектә 7 елга кичектерелгән, гәрчә ул әсәр 1907 ел урталарыннан башлап берничә труппа тарафыннан сәхнәләштереп өлгергән булса да. «Шура» журналына багышлы хезмәтләрдә бу авторның тагын 1909 елда дөнья күргән «Каравыл тавы» нәсере булуы да әйтелгән. Алда хәбәр ителгәнчә – «Үзеңә кайту» әсәре башка жанрда язылган булырга тиеш.

Революциягә кадәрге татар театрлары тарихына багышланган китап битләренә тагын күз төшерик. 1908 елда басылып чыккан «Ачлык кушты»ны да шул чор театрлары үз иткән. Чөнки ул – татар кыз балаларының фаҗигале язмышын тасвирлаучы әсәр. Татар авылларында, ачлык елларында зур гаиләне ачлык фаҗигасеннән йолып калу ниятеннән чыгып, яшь кызларны Урта Азиядә гомер итүче үзбәк, төрекмән һ. б. байларына сату гадәте дә булган. Шул вакыйгаларга багышланган күләмле бер мәкаләсендә Мөхәммәт Мәһдиев тә андый гадәтнең хәзерге Татарстан төбәге авылларына хас булуын да язган иде. Я. Вәлинең «Ачлык кушты» драмасында шундый аянычлы бер вакыйга бәян ителә. Һәм, әлбәттә инде, ул әсәрне шул чор театр труппалары күтәп алган кебек була. Аны басылып чыккан елында ук сәхнәләштерә башлыйлар. Театр тормышына багышланган әлеге китаптан тагын берничә язма китерик. «Бу чорда драма әсәрләреннән Г. Исхакыйның «Мөгаллим», Г. Камалның «Уйнаш», Я. Вәлинең «Ачлык кушты», Ф. Әмирханның «Яшьләр»е аерылып тора... «Ачлык кушты» матбугатта күренү белән, Г. Камал һәм Ф. Әмирхан аңа карата зур-зур мәкаләләр язып чыгалар. Г. Камал бу драманың кыскарак булуын тели, сәхнәгә куяр өчен катлаулы эшләнгәнлегенә игътибар итә», – диелә китапның 123–126 нче битләрендә. «Әсәрне сәхнәләштергәндә әлеге фикерләр искә алына. «Сәйяр» аны Төркестаннан кайтышлый беренче тапкыр Оренбургта күрсәтә. Аннары драма Казанда, Панаев бакчасындагы Җәйге театрда уйнала» (127 б.). Бу китапның «Йомгаклау» өлешендәге нәтиҗә чыгару җөмләсендә дә Я. Вәлинең исеме Ф. Бурнаш, Г. Исхакый, Г. Камал, К. Тинчурин, С. Рәмиев, М. Фәйзи, Г. Коләхмәтев исемнәре белән бер төркемдә китерелгән.

1926 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Татар театры тарихыннан» китабында да (авторлары режиссёр В. Мортазин-Иманский һәм шагыйрь Т. Ченәкәй) Ярулла Вәли иҗаты югары бәяләнгән. «1907–1909 елларда «Сәйяр» труппасы күп кенә шәһәрләрдә

гастрольләрдә булганда «Оят, яки Күз яше»н уйнаган. Шуның белән зур уңышка ирешкән. Мәкәрҗә ярминкәсендә 1907 елда беренче мәртәбә уйналганнан соң, татар һәм рус газеталарында аңа карата хуплау мәкаләләре басылып чыга. «Татар тормышыннан алып язылган, труппаның моңарчы куелган әсәрләреннән барыннан да яхшысы» дигән сүзләр дә була ул мәкаләләрдә.

1930 елларда, чит илдә яшәгәндә язган «Шималь төрекләренең әдәбиятына бер караш» хезмәтендә Гаяз Исхакый да язучылар исемлегендә Ярулла Вәлине үзеннән соң өченче урында теркәгән. «Г. Исхакыйдан соң берничә ел соңрак әдәбият мәйданына Г. Камал чыга» диелә дә, ике бит чамасы урында әдип Галиәсгар Камал иҗаты тасвирлана. Аннары: «Шул ук чорда Ярулла Әлвәли исемле бер язучы берничә хикәя, роман һәм пьеса яза. «Ачлык кушты» исемле пьесасы шактый зур уңыш казана. Ләкин... әдәби сәләте җитәрлек булмавы аркасында язучы бик тиз арада әдәбият мәйданыннан сәүдә базарына күчеп урнаша», – дип яза автор. Шул рәвешле Г. Исхакый каләмдәше Я. Вәлинең үз дошманы Фатих Кәрими кул астында эшләгәнлеген дә, унынчы еллар урталарында бай кызына өйләнеп, «байларга ялчы булуын» өнәмәвен дә, Оренбург төбәгендәге кайбер каләм әһелләре белән даими рәвештә диярлек килешми яшәгәнлеген дә сиздереп куя. «Таң йолдызы» нәшер ителгәндә, 1907 елда ук аның Фатих Кәримине «буржуаз язучы» дип битәрләгәнлеге мәгълүм иде. Ул елларда бу ике шәхеснең бер-берсен тәнкыйтьләп язган язмалары матбугатта даими рәвештә калка торган. Ә Ярулла Вәли – шул елларда Фатих мәхдүмнең якыннары исемлегендә йөргән шәхес. Димәк, Г. Исхакыйның Ярулла Вәли иҗатына бәя биргән өлешен укыганда әлеге искәрмәне дә истә тоту хәерледер.

Г. Исхакыйның бу хезмәтендә Ярулла Вәлидән соң китерелгән язучылар исемлегенә дә күз төшереп үтик. Менә алар: әдипнең Татар укытучылар мәктәбе буенча шәриктәше, гасыр башы театрларында тәрҗемә әсәрләре даими рәвештә уйналган, шул чорның әдәби-мәдәни һәм иҗтимагый вакыйгаларына багышлап китаплар чыгарган, мәкаләләре белән катнашкан Шакир Мөхәммәдъяров, күренекле шагыйрьләр Г. Тукай, С. Рәмиев, Дәрдемәнд, М. Гафури, Н. Думави һ. б.

Алтмышынчы елларда Ярулла Вәлинең әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә Исмәгыйль Рәмиев тә игътибар иткән. Вафаты алдыннан (1969) нәшриятка тапшырган энциклопедик эчтәлекле, уртача күләмле хезмәтендә Ярулла Вәлигә милли-либерал «Вакыт» һәм «Яңа вакыт» газеталарына багышланган аерым мәкаләләре бар. Язучы һәм тәҗрибәле мөхәррир Рәис Даутов бик кыйммәтле булган ул белешмәлекне озак еллар үзендә саклады. 2001 елда гына «Әдәби сүзлек» исеме белән бастырып чыгарган иде.

Бөек әдип Г. Исхакыйның Ярулла Вәли иҗатына карата әйткән кайбер сүзләрендә, мөгаен, дөреслек тә бардыр. Чынлап та,

1913 елдан соң Ярулла Вәли язудан туктаган, яңа әсәрләр иҗат итмәгән, ахрысы. Әллә каенатасы Дәрдемәнд үрнәгендә язганнарын китап рәвешенә китерергә ашыкмаганмы? Дәрдемәнд тә бит әнә, күпме югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итеп тә, һәм кул астында иң заманча җиһазлы басмаханәсе була торып та, үз әсәрләрен китап рәвешенә китерергә тырышмаган. 1910 елда аның балаларга багышланган юка бер китапчыгы гына чыгып калган ич.

Ярулла Вәлинең шул замандагы газеталарда яисә мәҗмугаларда чыккан әсәрләре турында да әлегә берәр төрле хәбәрнең күренгәне булмады. 1913 еллар тирәсендә аның «буржуй» Закир Рәмиевнең кече кызы Зәйнәпкә өйләнүе – Исхакый язганча, «байларга ялчы булуы» иҗат итәргә комачаулаганмы? Әллә соң җилкәсенә өелгән җаваплы эшләрнең күплеге аны иҗат эшеннән аергандырмы – әйтүе кыен. Бу вакытта бит ул «Вакыт» басмаханәсенең эше өчен җаваплылыкны үз өстенә алучыларның берсе була. Ә 1917 елгы түнтәрелеш чорында ул ярты ел чамасы «Вакыт» газетасының баш мөхәррире булып та торган. Шул вакыйгаларның чагылышына бер дәлил итеп архив фондында сакланган бер телеграмма караламасын да күрсәтергә була. Ф. Кәрими аны сентябрь аенда шул чорда Чиләбе шәһәре тирәләрендәге приискасында булган Закир әфәнде Рәмиевкә юллаган: басмаханә хезмәткәрләре баш күтәрә, эш хакын икеләтә арттыруны таләп итә, Ярулла әфәнде чара күрми. «Вакыт» газетасы вакытында чыкмаска мөмкин» дигән сүзләр бар ул телеграммада. Шуннан соң озакламыйча Ф. Кәрими үз кәнәфиен ташлап китә, башка сәүдәгәрләр белән килешеп, «Яңа вакыт» газетасын нәшер итүгә керешә. Исмәгыйль Рәмиевнең «Әдәби сүзлек» белешмәлегендәге «Яңа вакыт» мәкаләсенә күз төшереп алыйк. «Ф. Кәрими вә аның фикердәшләре, әүвәлге «Вакыт» идарәсе белән килешә алмыйча аны ташлап чыкканнан соң, «Яңа вакыт» тирәсенә оешалар. Наширләре (ягъни яңа хуҗалары) – Дәминев, Галәлетдинов тиҗарәтханәсе (сәүдә йорты). Газетаның фикри юнәлешен Ф. Кәрими болай билгели: «Газета вә аның мөхәррире бер партиягә дә мөнасиб социалист түгел, ул хөр фикерле тәрәккыйчы... милләтчедер». Газета 1917 елның 1 ноябреннән 1918 нең 3 октябренәчә нәшер ителгән.

Шул ук китапның 61 нче битендә И. Рәми: «1917 елны «Вакыт» газетасы мөхәррирлеге Ярулла Вәли кулына күчте», – дип яза. Ул үзгәрешнең кайсы айда булганлыгын хәбәр итми.

## 5

Әйе, 1917 елның сентябрь-октябрь айлары «Вакыт» газетасы хезмәткәрләре өчен бик аянычлы тәмамлана. Кемнәрнеңдер коткысы белән «Вакыт» басмаханәсендә кайберәүләр үз вазифаларын башкарудан баш тарталар. Эш хакын икеләтә арттыруны

таләп итәләр. Газетада эшләүчеләрдән дә аларга кушылучы булгандыр, ахрысы. Фатих Кәриминең Чиләбе шәһәре тирәләрендәге үз приискасында булган Закир Рәмиев исеменә юлланган телеграммасында «Чара күрелмәсә, газета чыкмаска мөмкин. Аның вакытында чыгуы бу көндә бик кирәк» дигән катгый таләпләр дә куела.

Закир Рәмиевнең әмере буенча, «Вакыт» газетасы белән басмаханә хезмәткәрләренә эш хакы әле март башында гына шактый күтәрелгән була. Татарстан Милли архивында шуны раслаучы документ та сакланган. Анда, әйтик, газета хезмәткәрләренең элек алган хезмәт хакы да, март башыннан түләнергә тиешлесе дә тулы саннар белән күрсәтелгән. Ул исемлектә «Вакыт» белән «Шура»да эшләүче уналты кеше исеме теркәлгән. Тулы исемлекне китермичә, танышрак исемнәргә тукталам. Кави (гадирәк эш башкаручылар арасыннан беренче килә) – элек 85 сум алган, түләнәчәк 120 сум; Кәбир Бәкер – элек 120 сум алган, түләнәчәк 180 сум; Шәриф Камал – элек 120 сум булган, түләнәчәк 180 сум; Ярулла Вәлиев – элек 180 сум булган, түләнәчәк 250 сум; Ризаэддин хәзрәт – элек 225 сум иде, түләнәчәк 275 сум; Фатих Кәримов – элек 225 сум иде, түләнәчәк 325 сум. Калганнарга, өч айдан ким эшләмәгәннәргә, март башыннан хезмәт хакы 20 процентка арттырылачак (Татарстан архивы, 1370 ф.). Бу «калганнарга» диелгән сүз, мөгаен, «Вакыт» басмаханәсендә эшләүчеләргә карыйдыр.

Ил күләмендә барган үзгәрешләр нәтиҗәседер инде, басмаханә хезмәткәрләренең кайберләре кабат эш хакын күтәрүне таләп иткән. Һәм бу вакыйга Фатих Кәриминең эштән китүе белән тәмамланган. «Идарә белән уртак фикергә киленмәде. «Вакыт»ның минем тарафтан чыгарылган саны 1917 елның сентябрендә булды. 1917 елның 20 октябрендә «Вакыт»тан хисапны өзеп чыктым», – дип яза Ф. Кәрими шул ук фондта теркәлгән документта. Мөгаен, бу вакытта инде Дәрдемәнднең дә Оренбургка кайткан чагы булгандыр. Ни сәбәпле алар үзара килешә алмаган соң? Бу сорауга әлегә җавап юк. Әмма Фатих әфәнденең илдәге болганышлар башланган чордан үзара мөнәсәбәтләргә карата фикере үзгәрә баруын чамалардай истәлекләр бар. Мәсәлән, сеңлесе Закирә Шәрәф истәлекләрендә китерелгән кайберәүләрнең хатларыннан аны чамаларга була.

Фатих Кәриминең «Вакыт»тан китеп ун көн үтмәстән үзенә яңа ишләр табып, шулар ярдәмендә «Яңа вакыт» газетасын 1 ноябрьдә үк халыкка тарата башлавы – аның элекке тормышка карата фикер үзгәреше кичергәнлеген белдерә бугай. «Яңа вакыт»ның наширләре Дәминов белән Галәлетдиновләр, газета редакциясе аларның тиҗарәтханәләрендә (сәүдә йортында) урнаша, дип яза И. Рәмиев. Әмма ул газетаның бөтенләй башка кешеләр ярдәмендә башка хуҗалар исеменнән чыгарылуын әлегәчә күпләребез танымады сыман. Күпчелек галимнәребез әле дә

аны шул ук Рәмиевләр наширлегендә калып, фәкать исемен генә үзгәрткән газета сымаграк кабул итәләр шикелле. «Газетаның фикри юнәлешен Ф. Кәрими үзе болай дип билгели, – дип белдерә дә И. Рәмиев, баш редактор мәкаләсеннән берничә җөмлә китерә. – «Яңа вакыт» вә аның мөхәррире большевик түгел. Хәтта берәр партиядә торучы социалист та түгел. Ул хөр фикерле тәрәккый бер милләтчедер. Шул хакта үз белгәнен, үзе хак дип игътикад иткәнен яза...»

Шушы урында Тәүфыйкъ ага Сәгыйтов истәлекләреннән дә бер җөмлә китереп китәсе килә. «Фатих аганы 1905 елдан бирле якыннан беләм. Яшьлегемнән гаиләләрендә аралашып үстем... Фатих ага һичкайчан малга, шөһрәткә табынмады. Бай да, ярлы да булмады. Бөтен гомерен халыкка хезмәткә багышлаган иде», – ди ул 1970 елда язган истәлегендә.

Элекке нашир, элекке идарә белән килешмәү һәм Дәрдемәнд белән аерылышу нилектән килеп чыккан соң? Бу сорауларга өлешчә җавапны Фатих әфәнденең сеңлесе Закирә Шәрәфнең истәлек язмаларында китерелгән Сәхи Рәхмәти хатларыннан чамаларга була. Сәхи Рәхмәти – берара «Вакыт»та да күренгәләп киткән, шул төркемгә кергән кешеләр белән якыннан аралашкан шәхес. 1917 елдан соң совет чоры оешмаларында актив катнашкан кеше. Хәзер аның Закирә Шәрәфкә язган хатларыннан кайбер өзекләр китерик. «Февраль революциясенең башларында ук Фатих абзый «Вакыт»та эшләүне ташлау фикеренә кушыла. «Һава үзгәрә, дулкын якынлаша. Шуңар хәзерләнеп эшли башларга кирәк. Үз фикеремне иркенрәк язуыма идарәдә каршы карыйлар. Яңалык ишек төбенә килеп җитте», – дия иде ул... Шул арада «Вакыт» редакциясендә үзгәрешләр булып алды... «Яңа вакыт» исеме белән (яңа) газета чыга башлады. Фатих абый янәдән күңел биреп, җиң сызганып эшкә кереште. «Яңа вакыт» кызыл гаскәр Оренбургны алгач та чыгып торды. (1918 елның гыйнвар урталары була. – *Л. Х.*). Ә «Вакыт» 1918 елда чыгудан туктады», – дип хәбәр итә С. Рәхмәти ул хатында.

Әйе, хаттагы соңгы җөмләдә бертуган Рәмиевләр нәшер иткән «Вакыт» газетасының большевиклар тарафыннан 1918 елның 25 гыйнварында ябылуы турында хәбәр ителә. Ф. Кәрими киткәч «Вакыт» газетасы өч ай чамасы Ярулла Вәли мөхәррирлегендә нәшер ителгән. Байларның, буржуйларның мал-мөлкәте кичекмәстән Совет хакимиятенә тапшырылырга тиеш, дигән карарны үтәп, Закир Рәмиев белән Ярулла Вәлиев шул ук көндә «Вакыт» типографиясен дә Совет хакимияте вәкилләре кулына «тоттыралар». Шул ук карарда күрсәтелгәнчә, Дәрдемәнд яңа хуҗаларга басмаханә ике атна дәвамында тоткарлыксыз эшләрлек күләмдә акча да тапшыра. Киләсе атнада ук элекке «Вакыт» басмаханәсе Заһид Шәркый-Йосыпов мөхәррирлегендә «Мөхбир» газетасын нәшер итә башлаячак.

Яңадан Сәхи Рәхмәти хатында теркәлгән вакыйгаларга әйләнеп кайтыйк. Анда мондый җөмлә дә бар. «Аның Октябрь революциясенә карашын күрсәтер өчен «Яңа вакыт» газетасында Фатих Кәрими имзасы белән басылган баш мәкаләнең берничә җөмләсен күчерү дә җитәр. «Ниһаять, Октябрь революциясе булды. Монысы инде чын-чыннан зур үзгәреш иде. Бу үзгәрештә бөтен хакимиятне халык үз кулына алды», – диелә ул баш мәкаләдә». Әйе, чордашы кабатлап язган шушы җөмләләрне укыгач та, Фатих Кәриминең ул еллардагы фикер үзгәрешен тоясың, аңлыйсың…

1919 елның гыйнварында кызыллар гаскәре Оренбург шәһәрен икенче мәртәбә яулап ала. Атаман Дутов гаскәре шәһәрдән бик еракка һәм бөтенләйгә куып җибәрелә. Яңа тормыш башлана. «Яңа вакыт»ның элекке редакция бүлмәсендә узган бер утырышны да Сәхи Рәхмәти бик тәфсилләп искә ала. Анда катнашучылардан комиссарлар Шамил Усманов, Кәрим Хәкимов, Карип Хәйруллин, Гали Шәмигулов һ. б. белән бергә журналистлар Фатих Кәрими, Борһан Шәрәф, Заһид Шәркый-Йосыпов, Шәриф Камал, Сәхи Рәхмәти һ. б. да була. Ул утырышта Ф. Кәримине яңа заманга ятышлы, «большевистик эчтәлекле» яңа чыга башлаячак газета редакторлыгына димлиләр. Бу очракта ул: «Шул партиядә тормагач, мин бу газетага баш мөхәррир була алмыйм. Болай эшләү сезгә сәяси зыян булып чыгарга ихтимал… Сезнең гәзитәдә эшләүдән дә баш тартмыйм. Тик баш мөхәррир булып эшли алмам», – дип белдерә ул. Җыелыштагылар шуннан соң шундый ук тәкъдим белән Борһан Шәрәфкә мөрәҗәгать итәләр. Ул да бу эшкә алынмый. «Хәзерге вакытта бик күләмле бер тарихи хезмәтне эшләргә алындым, шуның белән утырам», – дип җавап бирә. Шул утырышта чыгачак газетаның биш кешелек редакция советы сайлана. Берничә большевик белән бергә ул советка Фатих Кәрими дә керә.

Ә элек ул баш мөхәррир булган «Яңа вакыт» газетасы 1918 елның 3 октябрендә үк – Дутовчылар шәһәрдә баш булган чорда чыгудан туктатыла.

Элек Дәрдемәнд даирәсенә кергән, аеруча хөрмәт ителгән Шәриф Камалның да шул ук үзгәрешләр чорында мәҗбүри рәвештә диярлек беркадәр сулга талпынышы сизеләчәк. Дөрес, бу вакыйгалар чорында Дәрдемәнднең үзенең дә мәҗбүри рәвештә 1918 елның гыйнвар ахырында ук Оренбургны ташлап китүенә дә бәйледер. Ул Совет хакимияте Оренбургны беренче мәртәбә берничә айга яулап алгач ук диярлек шәһәрдән китә һәм аңа кабат шунда кайтып яшәү насыйп булмый. 1921 елның сентябрендә Оренбургта тиф чиреннән вафат булган кызы Өммегөлсемне соңгы юлга озату вакыйгаларында катнашканнан соң, октябрь ае башында Орск шәһәрендә шул ук авырудан дөнья куя.

*2014–2020*

# II

*Дөньяда куп нэрсэ белдем*
*Син туган тел аркылы...*

*Г. Тукай*

# МИЛЛИ МИРАСЫБЫЗ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

*(Очерк)*

1

Үз милли телебездә беренче спектакль куелуга хәзер 115 ел булды. Ә татарның күренекле драматургларыннан берсе булган Мирхәйдәр Фәйзинең тууына 130 ел тула. Хәер, 1906 ел беренче рәсми милли театр тамашасы белән генә истәлекле түгел. Татар халкы, татар җәмәгатьчелеге өчен гомумән дә истә калырдай тарихи вакыйгаларга бай ел булуы белән дә кадерле ул. Нәкъ шул елда татар халкы бергә тупланып яшәгән байтак төбәкләрдә – Казан, Уральск, Оренбург, Әстерхан калаларында үз милли телебездәге төрле-төрле атамалы газеталар, журналлар басыла башлый. Шул ук елның язында эшли башлаган беренче чакырылыш Дәүләт думасына бер дистә безнең милләт вәкиле сайлана. Патша Россиясе хакимлек иткән дәвердә алар тарихта беренче мәртәбә дәүләт мөнбәренә басып татар халкын борчыган мәсьәләләр хакында ачыктан-ачык сүз әйтү хокукын алалар. Шушы җитди вакыйгаларның үзәгендә кайнап, кайбер милләттәшләребез ил күләмендә сәясәтче буларак танылуга ирешә. Аларның беренче сафында Казан ягыннан Садри Максудины, морза Сәетгәрәй Алкинны, элекке Оренбург губернасы морзаларыннан Гайса Еникиевне, актив җәмәгать эшлеклесе адвокат Ә. Г. Әхтәмовларны искә алырга кирәктер. Гайса Еникиевнең Дума трибунасыннан милли мәктәпләр язмышына кагылышлы ялкынлы чыгышы бүген дә актуаль яңгырарга мөмкин.

XIX–XX гасырлар чигенә кергән еллар татар милләтенең кабат уяну, мәдәни вә рухи күтәрелеш дәвере буларак күзаллана. Бу чорда иҗтимагый-тарихи һәм дини-рухи әдәбият белән беррәттән матур әдәбият өлкәсендә дә зур уңышларга ирешелә. Рус һәм көнбатыш әдәбияты үрнәгендә беренче драма әсәрләре языла. Татар телендә спектакльләр куярга омтылыш туа. Мондый хәл татар дөньясының башкаласы булган Казаннан тыш Әстерхан, Оренбург, Уфа, Уральск, Касыйм, Орск, Троицк, Чистай кебек шәһәрләрдә дә күзгә ташлана. С.-Петербургтагы татар җәмгыяте белән касыймлылар элек-электән тыгыз элемтәдә торган. Шуңа күрәдер татарлар арасында алар беренче булып рәсми Хәйрия оешмасын төзегәннәр. Театрлар тарихы белгече Һәнүз Мәхмүдев хәбәр итүенчә, «Касыймда... 1899–1901 елларда татар телендә беренче ачык спектакльләр куела». Казанда «шундый кичәләрнең беренчесе Казан Хәйрия җәмгыяте файдасына 1901 елның

27 гыйнварында шәһәр театрында оештырыла. Аңа дүрт йөзләп татар тамашачысы килә. Дөрес, бу спектакль әле татарлар өчен рус артистлары тарафыннан рус телендә уйнала. Әлеге Хәйрия җәмгыяте рәистәшләренең берсе, Кавказ халыклары иреге өчен көрәшкән мәгълүм шәех Шамил оныгы Заһид Шамилнең бу спектакльне «яртылаш булса да татарча куярга» тырышуы шәһәр түрәләре һәм үзебезнең «халык вәкилләре» тарафыннан кире кагыла, диелә ул көннәргә багышлы язмаларда.

Казанда татарча спектакль куярга омтылыш иң элек мәдрәсәләр өчен «урыс хәлфәләре»н хәзерләүче Татар укытучылар мәктәбе яшьләре арасында туа. 1898 елда ук алар шундый үтенеч белән югары идарә вәкилләренә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин аларга башкаладан «Театр уеннарын рус телендә уйнарга» дигән рөхсәт кенә килә. Шул рөхсәтнең дә киләчәк өчен файдасы зур була. Рус телендәге спектакльләрдә уйнау тәҗрибәсен алган яшьләр татар театрларын нигезләүче төп көчләргә әвереләчәкләр. Шундыйларның беренчеләре арасында без Гаяз Исхакый, Гафур Коләхмәтев, Хөсәен Ямашев, Шакир Мөхәммәдъяров (сәхнәдә – Ш. Җәмиров), Ильясбәк Кудашев (сәхнәдә – Ашказарский), Габдрахман Мостафин, Габдерәүф Ниязбаев (булачак драматург), Шәриф Сүнчәләй һ. б. күрәбез. Боларның күпчелеге Казаннан еракта урнашкан мәдрәсәләрдә башлангыч белем алган, киләчәктә үз мәдрәсәсенә кайтып, рус телен укытырга тиешле яшьләр була. Аларның бер өлеше Казанда «Шимбәчеләр» театраль түгәрәген оештыруда да катнаша.

XIX йөзнең соңгы елларыннан башлап Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсеннән дә Әхмәт бай Хөсәенов стипендиясе исәбенә әлеге Казан уку йортына елына дүрт-биш шәкерт җибәрелеп торган. Монда җибәрелгән икенче-өченче төркем шәкертләр исемлегендә Зәки Ишаев, Мирсәяф Туктамышев, Ильясбәк Кудашев һ. б. исемнәрен очратабыз. Казанда уку дәверендә һәвәскәр артист буларак сәхнәгә тәүге тапкыр аяк баскан шәкертләрдән И. Кудашев, Ш. Мөхәммәдъяров, Г. Ниязбаев соңыннан Оренбург төбәгендә татар театрын булдыру эшенә үз өлешләрен кертәчәкләр. Гармунда, скрипкада һәм пианинода ярыйсы ук оста уйнаучы, үз ана һәм рус телләрендә иркен сөйләшә белүче Ильясбәк Кудашев та, 1904 елда укуын тәмамлап «Хөсәения»гә укытырга дип кайткач, җиң сызганып театр түгәрәген оештыру әмәленә керешә. Үз тирәсенә Вәли Мортазин, Исхак Әлмүшев, Әхмәт Ишморатов, Габдрахман Мангушев, Нури Сакаев һ. б. сәләтле шәкертләрне туплап, репетицияләр үткәрә башлый. Шул рәвешле берәр елдан соң ул татарлар арасында профессиональ беренче театр труппасын оештыручы буларак танылачак. 1907 елның март-апрелендә Ильяс оештырган театр төркеме артистлары якташлары Ярулла Вәлинең «Оят, яки Күз яше», Александр Островскийның Ильясбәк тәрҗемә иткән «Галимлек вә наданлык» пьесаларын Оренбург тамашачысына уйнап күрсәтәләр. Һәм май аенда тәвәк-

кәлләп Бозаулык, Самара, Сембер, Казан, Чистай якларына дип гастрольләргә чыгып китәләр. Оренбургта беренче театр уеннарын оештырышуда җирле Хәйрия җәмгыяте һәм аның рәисе Газиз Мәхмүт улы Хөсәеновның өлеше дә зур була. Димәк, шул елларда баш калкытачак «Сәйяр» театр коллективын барлыкка китерешүдә сәүдәгәр Хөсәенов байларның берникадәр өлеше барлыгын да искә алырга кирәктер.

Казанга килгәч тә беренче хатын-кыз артистка Сәхипҗамал Гыйззәтуллина (сәхнә псевдонимы – Волжская) ул төркемгә теләктәш икәнлеген белдерә. Ә Мәкәрҗә ярминкәсендә исә Габдулла Кариев бу беренче артистлар төркеменә килеп кушылачак. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге милли театр труппасы ирешкән иң зур уңыш Мәкәрҗә ярминкәсе көннәренә туры килә. Спектакльләрдән кергән керем көтелгәннән дә ишлерәк була. Өстәвенә алар куйган бер спектакльне Түбән Новгород губернасы губернаторы да карый һәм хуплый. Шул ук җәйдә бу төркем артистлары сәяхәттә йөрүче «Сәйяр» театры исеме белән танылачаклар.

Татар театрының 115 еллык юбилеен үткәрүгә сәбәп булган, рәсми рөхсәт алып, беренче мәртәбә Казанда уйналган ачык спектакль артистлары да, нигездә, шушы Татар укытучылар мәктәбе шәкертләре була. Алар белән бергә ике-өч студент һәм гимназиядә укучы берничә кыз да ул уенда катнашалар. 1906 елның 22 декабрендә куелган ул спектакльнең беренче бүлегендә уйналган «Кызганыч бала» драмасында төп рольләрне «Шимбәчеләр» түгәрәгендә катнашкан өч гимназистка белән бергә Шакир Мөхәммәдъяров һәм Шәриф Сүнчәләй башкара. Икенче бүлектә уйналган «Гыйшык бәласе» комедиясендә шул ук кызлар һәм өч университет студенты катнаша…

Ильясбәк Кудашев-Ашказарский исә бу вакыйгага кадәр төгәл бер ел элегрәк, 1905 елның 3 декабрендә, Оренбургта татарча беренче спектакль куярга талпынып карый. Рус драма театры бинасы арендага алына, шунда репетицияләр уздырыла. Әмма «Оренбургская газета»ның 27 ноябрь санында ике телдә игълан басылгач, типографиядән кайтарылган афишалар таратыла башлагач, мөселманнар арасында шау-шу куба. Губернатор галиҗәнаплары хозурына, «рөхсәт итмәскә» дип ялварып, «чалмалы вә дәү корсаклы» вәкилләр килә. Тамашаны куярга рөхсәт бирмәгез, дип ялваралар. Һәм шул көннәрдә үк губернаторның «Спектакльне куярга рөхсәт ителми» дигән әмере чыга. Оренбургта яшәгән шул төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова 1980–1990 елларда шушы вакыйгага кагылышлы күп кенә материалны туплаган, шул хакта мәкалә язып бастырган иде. Аның архивында сакланган кәгазьләр арасында 1905 елның 3 декабренә билгеләнгән спектакль афишасы, газетада чыккан русча-татарча белдерү, уенда катнашырга тиеш булган яшьләрнең исем-фамилияләре һәм аларның киләчәк язмышлары да теркәлгән мәгълүмат

бар иде. 2006 елда Оренбургка барганда мин аның шул төбәк театры тарихына караган архивының хәзер кемдә булуын ачыклый алмадым. Мәдинә апада шулай ук И. Б. Кудашев-Ашказарский тарафыннан 1907 елның башында оештырылган профессиональ «Сәйяр» театры, соңрак Оренбургта эшләгән «Нур», 1915 елда барлыкка килгән «Ширкәт» театрларына бәйле бай мәгълүмат, шул исәптән ул чор артистлары фоторәсемнәре тупланган ике зур альбом да бар иде. Альбомнарның берсе бүген өлкәнең татар китапханәсе фондында саклана. Икенчесенең, егерменче еллардан башлап алтмышынчы еллар ахырынача Оренбург татар театрында эшләгән артистларның йөз-кыяфәтләрен, исем-фамилияләрен саклаган Хәдичә Таһирова-Ханская туплаган альбомының язмышы әлегә билгесез. Шуны да әйтеп китү кирәктер, Оренбургта 1919 елның башында Совет хакимияте икенче мәртәбә һәм озакка урнаштырыла. «Ширкәт» драма артистлары төркеме җирлегендә озакламыйча рәсми рәвештә теркәлгән Оренбург татар театры барлыкка килә. Аны рәсмиләштерүне Губерна башкарма комитетының мәгариф бүлегендә сәнгать тармагы өчен җаваплы Исхак Мөхәммәтҗан улы Әлмәшев башкарып чыга. Аңа чаклы Исхак «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, ә 1912 елдан Уфада оешкан «Нур» төркеменең режиссёры була, Беренче герман сугышында катнаша. Самарада оешкан махсус театр студиясен тәмамлап чыккан артистларның күпчелегенең нәкъ шушы театрга җибәрелүе дә монда ныклы җирлек булганлыгы турында сөйли. 1920 елның декабрендә ул курстан Оренбургта эшләү өчен җибәрелгән зур төркем арасында Таҗи Гыйззәт, Рифкать Фәйзи, Хөсәен Уразиков, Әсгать Мәҗитов кебек булачак күренекле шәхесләр дә бар. 1930 еллар уртасыннан Оренбург артистлары күчмә театр рәвешендә эшли башлый, 1949 елдан исә филармониягә беркетелә. Ә 1989 елдан кабат мөстәкыйль театр рәвешенә кайта. Һәм шул елда ук театрга шәһәр уртасында аерым бина бирелә. Хәзер ул театр Мирхәйдәр Фәйзи исемен йөртә. Репертуарында, татар, башкорт драматурглары әсәрләреннән тыш, рус һәм көнбатыш илләре авторлары әсәрләре дә үз телебездә уйнала. «Ширкәт»не һәм Оренбург татар театрын оештыруда актив катнашкан, аларның җитәкчесе һәм баш режиссёры булган Вәли Мортазин-Иманский 1921 ел башында Эстәрлетамакка чакырып алына. Аңа анда Башкорт драма театрын нигезләү бурычы йөкләнә. Озакламыйча ул театрда төп рольләрне башкаручылар буларак Оренбург өлкәсенең Орск төбәгеннән чыккан ике милләттәшебез – Маһибәдәр Йосыпова белән Рифкать Фәйзи танылачаклар. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» пьесасы язылып беткәч тә Орск шәһәрендә икенче мәртәбә уйналганда, Галиябану образын иң әйбәт башкаручы, оста җырлаучы уналты яшьлек кыз да шушы Маһибәдәр була. Орскидан егерме биш чакрымдагы Гайнулла авылында туган кызның театр сәхнәсен яулавы шуннан башлана… Бу авылның халык телендә «Дүрткүл» дип йөртелүен, аның Мирхәйдәр

Фәйзи җәй айларын уздырган Җүнәйдән ике-өч чакрымда гына булуын әйтеп китү дә кирәктер. Җырга оста Дүрткүл яшьләренә багышлы истәлекләр әдип көндәлекләрендә еш очрый.

Күренә ки, Оренбургның милләтчел рухлы зыялылары тырышлыгы белән ул шәһәрдәге драма театры да, 1906 елда ачылган милли китапханә дә 115 ел дәвамында эзлексез рәвештә эшләп киләләр. Бу ике оешма шул төбәктә татар телен, рухын саклауда бик зур вазифа башкара. 1980 еллар ахырында кабат оешкан барлык рәсми милли җәмгыятьләргә шулар ныклы нигез булдылар. Оешкан дәвердә «Белек», 1914–1925 елларда Исмәгыйль Гаспринский, 1925 тән соң Хөсәен Ямашев исемен йөртүче бу өлкә китапханәсе дә 2021 елның октябрендә 115 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк.

2

«Хөсәения» мәдрәсәсенең хәлфә һәм шәкертләреннән бер төркем татарча театр уеннарын оештыру хыялы белән йөргән бер вакытта, 1906 елның көзендә, бу уку йортына сәнгатькә тартым җанлы унбиш яшьлек Мирхәйдәр Фәйзи килеп керә. Ул Казан, Оренбург һәм башка төбәкләрдә чыга башлаган татарча газеталарны, китап рәвешендә дөнья күргән әдәби әсәрләрне даими укып баручы, ил-дөнья тормышы белән кызыксынып торучы яшьләрнең берсе була. Өстәвенә Орск шәһәре мәдрәсәсендә укыган дүрт кышта үзлегеннән каләм тоткаларга да өйрәнеп килә. Аерым шигъри юллар, бәетләрдән тыш, ул яңарак кына «Татар туе» исемле бер күренешле сәхнә әсәрен дә язган була. Шул пьесасын күпсанлы җиңгә һәм кодачалары алдында укып, «аларны хәйран калдыра». Әлбәттә инде, мәдрәсәгә яңа гына килеп керүенә карамастан, Ильяс хәлфә тирәсенә тартылган шәкертләргә якынрак булырга тырыша.

Мирхәйдәр гаиләдә унберенче бала булып 1891 елның 1 ноябрендә дөньяга килә. Иң кече бала булу сәбәпле, бик иркә үсә. Алар яшәгән кечкенә Күкшел авылы элекке өяз үзәге Орск шәһәреннән илле чакрымнар төньяк-көнбатыштарак, Уралтауның бер тармагы булган Гөберлә тау-калкулыклары арасында, Гөберлә суы буенда урнашкан. Утызлап йортлы Күкшел утарын булачак драматургның атасы Мостафа карт 1870 еллар ахырында нигезләгән була. Мостафа мәхдүм Чистай өязе Шахмай авылы мулласы гаиләсендә туган. (Хәзер авыл Татарстанның Яңа Чишмә районына керә.) Унтугыз яшендә, 1854 елда, ул Орск каласына килеп, бер сәүдәгәргә кулдаш булып урнаша. Шул вакытларда Хөсәенов байлар казах иленнән кайтарылган көтү-көтү мал-туарны симертер өчен иркен җир-сулыклар сатып алалар. Шуны кулда тотардай идарәче кирәк булгач та аларга «мулла баласы мишәр Мостафа»ны тәкъдим итәләр. Бертуган

Хөсәеновларның җир биләмәләре — иркен көтүлекләре идарәчесе вазифасын ул 1905 елга чаклы, чирек гасырдан артыграк вакыт үти. Мостафа ярыйсы ук укымышлы кеше булган — берничә кыш Чистайда Закир ишан, бер кыш Казанда Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган. «Тәрҗеман» газетасы чыга башлаган көннән ул аны алдырган. Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылында туган хатыны Зәйнәп тә укый-яза белүче хатын-кызлардан була. (Мостафа Фәйзуллинның үзе кичергән кайбер вакыйгаларны, Казан ханлыгы чоры бәк-морзаларына бәйле булган шәҗәрәләрен теркәп барган калын «куен дәфтәре»н Казан университеты мирасханәсенә кайтарышуда үземнең дә катнашуымны әйтеп үтим. Ул калын дәфтәр бәйләме Мәскәүдә, Мирхәйдәрнең абыйсының кызы Хәлимә апада саклана иде.)

Күренә ки, Мирхәйдәр Фәйзи заманының шактый ук укымышлы гаиләсендә туган. Ул төпле тәрбия алган, зәвык күргән яшүсмер буларак күзаллана. Төскә-биткә бик чибәр, чандыр гәүдәле була. «Һәрвакыт җыйнак, пөхтә итеп киенгән булыр иде. Сабыр холыклы, тыйнак кеше иде», — дип искә алалар аны якыннан белүчеләр. Ә андый кешеләрне мин Орск шәһәрендә яшәү чорында шактый күп очраттым. Ул яшәп киткән Юлык авылында, Баймак шәһәрендә дә берничә мәртәбә булырга туры килде. Чөнки Мирхәйдәр белән шагыйрь Дәрдемәнд, төрле чордарак булса да, бер тирәдә яшәгәннәр.

Мирхәйдәр бала вакыттан ук бик күп җирләрдә була, төрле катлаудан чыккан зыялы затлар белән аралашу бәхетен татый. Аның олы апасы Фатыйманы Малмыжның укымышлы кешесенә — Камал Мозаффаровка кияүгә бирәләр. Абыйсы Сәетгәрәй дә Малмыж өязенә караган Түнтәр авылында, Ишми ишан мәдрәсәсендә белем ала. 1901 елда ул ишан кызы Фатыймага өйләнә. Язучы Рәфыйк Шәрәфиев Балтач төбәге музейларына багышланган бер күләмле язмасында М. Фәйзинең бертуган апасы белән абыйсының Орск шәһәреннән мең ярым чакрымдагы Малмыж, Балтач, Түнтәр тирәләренә ни сәбәпле килеп чыгуларын шул төбәктә яшәүче туганнарының белмәгәнлеген бәян иткән иде. (Сәетгәрәй мулланың ике улы — Сәгыйть белән Икрам Фәйзуллиннар Татарстанда мәгълүм журналистлар иде. Малмыж, Балтач якларында Фатыйма белән Камал Мозаффаров нәселе вәкилләре дә яшәгәндер, мөгаен.) Сәетгәрәй «нилектән бу дини мәдрәсәгә килгән соң? Ни өчен нәкъ менә Түнтәргә?» дип сорау бирә автор (Казан утлары. — 1997. — № 4). Бу сорауларга җавапны шул балалар атасы Мостафа Фәйзуллинның Чистай белән Казан мәдрәсәләрендә кемнәр белән бергә укуын, кемнәргә дус булганлыгын ачыклагач кына җавап биреп буладыр, мөгаен. Һәрхәлдә, аның Малмыж кешеләре һәм шул төбәкнең иң абруйлы дин әһеле Ишмөхәммәт Динмөхәммәдев белән тыгыз элемтәдә торганлыгын алда сурәтләнгән вакыйгаларга бәйләп беркадәр аңлатып була, минемчә. Икенче бер элемтә җебе XIX йөз ахыр-

ларында Оренбургта мәгълүм мәдрәсә тоткан Шаһимәрдән хәзрәт Үтәгәневкә бәйле булырга мөмкин. Түнтәр авылыннан чыккан бу кеше 1880 елларда Оренбург төбәгендә абруй казанган дамелла Шаһимәрдән хәзрәт мәдрәсәсенең мөдәррисе була. 1889 елда үз уку йортын «Хөсәения» мәдрәсәсенә кушкач, байтак еллар шунда укыту бүлеге мөдире вазифасын башкара. Өченче бәйләнеш Түнтәрдән килеп Оренбургта сәүдә иткән Хәкимов Шакир аша оештырылган булуы да ихтимал. Шул авылның Рәфгать Зариповы әйтүенчә, Мөхәммәткамал Мозаффаров белән әлеге «бай Хәкимев» кардәш-ыру тиешле дә булганнар икән.

Сәетгәрәй абыйсы туена дип, 1901 елда ун яшьлек Мирхәйдәр дә әти-әнисе белән бергә ерак сәфәргә җыенып чыгып китә. Күкшелдән өч йөз чакрымнан артыграк булган Оренбургка башта алар ат-арбада киләләр. Аннан Самарага чаклы поезд белән китәләр. Самарадан Казан тарафына таба әүвәл зур Идел пароходында, аннан соң Нократ елгасына керүче кечерәк пароходта баралар. Ун яшьлек хисчән, зирәк бала күңелендә бу сәяхәт мизгелләренең мәңгегә уелып калуы бик табигый. Ул туйга Оренбургтан Мәхмүт бай Хөсәенов, аның конторасында эшләүче Мирхәйдәрнең уртанчы абыйсы Мәхмүтгәрәй дә хатыны белән бара. Казаннан ул туйга сәүдәгәр һәм фабрикант Габдрахман Ишморатов та ике хатыны белән килә. Ишан хәзрәтләрен олылаган, аңа дус, фикердәш булган абруйлы төрле төбәк муллалары да ул туйда катнаша.

Туйдан кайтышлый Фәйзуллиннар Чистайда тукталыш ясыйлар, шуннан Шахмай авылына сәяхәт кылалар. Соңрак Мирхәйдәр Шахмай табигатенең матурлыгы, Әхмәтҗан бабасының авыл уртасындагы ике катлы өенең нык булуы турында көндәлегенә язып куячак. Алар Мостафаның бертуганы Гобәйдә абыстай өендә дә кунак булалар. Чистайдан соң Казанга киләләр. Әхмәт бай Хөсәеновның Кабан күле буендагы өендә берничә көн кунак булалар. Шәһәрнең мәчетләрен, базарларын карап, тамаша кылып йөриләр. Әмма ул вакытта әле Мирхәйдәр шәһәрнең иске өлешенә, университет, гимназияләр тирәсенә бармаган булса кирәк. Мөгаен, Мостафа карт ул вакытта «чукынган урыс ягына» чыгып йөрүне өнәп бетермәгәндер.

1906 елның җәендә дә Фәйзуллиннар кабат Казанда, Малмыжда һәм Сәетгәрәй муллалыкка тәгаенләнгән Шода авылында булып кайталар. Яңарак кына Оренбург белән Ташкент арасында тимер юл төзелгәнлектән (ул 1905 елның ахырыннан эшли башлый), Мирхәйдәрләрнең сәяхәтенә бу юлы бераз үзгәреш кертелә. Алар башта Орскидан 140 чакрымдагы Актүбә каласына ат-арбада юл тоталар. Юлда казах халкы яшәешенә хас күренешләр белән дә танышалар. Шуннан поездга утырып Оренбурга киләләр. Искәртеп китим, киләчәктә иҗат ителәчәк «Асылъяр» драмасы сюжетының эчтәлеге дә шушы Орск – Ак-

түбә юлы күренешләренә бәйле рәвештә барлыкка килгән, дип белдерелә.

Мондый сәяхәтләр, төрле дәрәҗәдәге төрле холык-гадәтле кешеләр белән якыннан аралашу яшүсмер Мирхәйдәрнең зиһен офыкларын киңәйтә, билгеле. Язучының киләчәк әсәрләрендәге төрле холыктагы персонажларны оста тасвирлый алу сәләтен үстерә.

Оренбургта укыганда ул Мәхмүтгәрәй агасы белән Фәрихә җиңгәсе карамагында, алар өендә яши. Дәрестән кайткач та күп укый, яза. Шигырь-бәетләрен, мәкалә хәбәрләрен газета-журналларга да тәкъдим иткәли. Аларның кайберләре Тимерша Соловьёв нәшер иткән «Чүкеч» журналында, Казанда чыгучы «Әлислах» һ. б. газеталарда басылалар. Шул көздә ул көндәлегенә: «Хәлфәләр зобани төсле түгел... Бу яңа хәят мине бик тиз җәлеп итте. Башта яңа уйлар, яңа хыяллар хөкем сөрә. Шагыйрь булу, артист булу, музыкант булу кебек уйлар белән җенләнәм», — дип язып куя.

### 3

Ләкин аңа «Хөсәения» мәдрәсәсендә озак уку насыйп булмый. Күп уку, кичләр буе баш иеп язып утырулар Мирхәйдәрнең сәламәтлеген какшата. 1907 елның язында врач аңа тумыштан йөрәк авырулы булганлыгын белдерә. Йөрәк өянәгеннән саклanып, физик көч сарыф итмичә авыл шартларында яшәргә киңәш бирә. Ильяс хәлфә шәһәрдә беренче ачык спектаклен куярга рөхсәт алып, шул тамашага җыенган бер вакытта, март ае ахырларында, Мирхәйдәргә Оренбургны калдырып китәргә туры килә. Ул Орск шәһәреннән егерме биш чакрымнардагы Җүнәй авылында яшәүче абыйларына кайта. Бу вакытта инде аның ата-анасы авылдан киткән, Орскиның үзәк урамнарының берсендә төзелгән ике этажлы үз йортларына күчкән була. Мирхәйдәр берникадәр вакыт үз яшьтәшләре белән аралашмый диярлек. Хәятын биләп алган хасталык болыты кышын шәһәргә кайткач та тиз генә таралмый. Чөнки барча таныш-белеше диярлек: «Порок сердца авыруы булган кеше озак яшәми», — дип тәкрарлый. Шушы сүзләр аны гомере буе сагалап йөриячәк, буйдак булып яшәргә хөкем итәчәк.

Ә бу вакытта Орск яшьләре шау-гөр килеп театр куярга дип янып йөриләр. Бу эшкә тотынырга аларны Казан каласыннан кунакка кайткан якташлары Шакир Мөхәммәдъяров күндерә. «Әйдәгез, егетләр, шәһәрдә татар театры ачабыз», — ди. Ләкин аның тирәсенә тупланган беренче төркем «аулак өйләр»дә сөйләшеп утырулардан узмый әле. Берәр сәхнәдә театр уены уйнарга җитешә алмыйлар. Казан сәхнәсендә артист осталыгын бер күрсәтеп алган Шакирның да калага кайта-китә генә йөргән чагы туры килә. Гаяз Исхакый җитәкләгән таңчылар «фиркасе»нең

актив әгъзасы буларак, шул ук көздә аңа Казанны калдырып китәргә дә туры киләчәк әле. Һәм Мирхәйдәр Орскига кайткан көздә ул, университетта уку хыялын тормышка ашыру нияте белән, туган шәһәреннән бик еракта урнашкан С.-Петербургка барып төпләнәчәк. Орскида исә театр уены уйнарга хирысланып өлгергән яшьләр – Габдулла Мангутов, Әхмәтгали Багданов, Мәгъсүм Шәмсетдинов, өч бертуган Гобәйдуллин кебек теләктәшләре генә кала. Һәм озакламыйча шул төркемгә Мирхәйдәр дә килеп кушылачак. Оренбургта Ильясбәк Кудашов хәлфә оештырган яшьләр уеннарын бер-ике мәртәбә читтән генә кызыгып карап үткән кеше буларак, үз шәһәре яшьләре арасына ул кыю килеп керә.

1907 елда Орскиның зыялырак һәм байрак катлавы хәйрия оешмасына берләшә. Бераз акча тупланган, «Шәрык көтепханәсе» исемендә китап кибете ачуга ирешә. Аның уку залына татарча, русча һәм төрекчә басылучы газета-журналлар кайтарыла башлый. Һәркем аларны анда барып укый ала. «Шәрык көтепханәсе» үзе дә Оренбург, Казан басмаханәләренә заказлар биреп, берничә заманча китап чыгаруга ирешә. Мәсәлән, китап белгечләре Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы шушы ширкәт заказы белән 1913 елның башында Казанда нәшер ителгән дип белдерәләр. Шәһәрнең татарлар күмәкләшеп яши торган Форштат бистәсе тарафындарак урнашкан ул «кыйраәтханә»гә тиздән Мирхәйдәр дә бик теләп йөри башлый. 1911 елда Хәйрия җәмгыяте мөстәкыйль китапханә ачу өчен шәһәр уртасында иркен бер бинаны сатып ала. (Фәйзуллиннар яшәгән урам чатында урнашкан ул милли китапханә 1962 елга чаклы шәһәр халкына хезмәт итте. Совет хакимияте дәверендә Мулланур Вахитов исемен йөртте.) Себер белән иркен казах иле чикләрендәге өяз башкаласы Орскига ара-тирә рус театр төркемнәре дә килеп чыккалый. Гимназия укытучылары белән шәһәр яшьләре үзләре дә спектакльләр куйгалыйлар. (Аларда тәүге артистлык чиркануын икенче бер якташыбыз, СССР чорының күренекле язучысы Лидия Сәйфуллина да ала. Атасы ягыннан ул да Чистай өязенә бәйле шәхес.)

Шундый спектакльләрне карарга Мирхәйдәр дә иптәшләре белән баргалый. Һәм 1909 елның кышында шундый бер тамашадан соң ул «Ике Хәсән» исемле икенче пьесасын язачак. (Бер пәрдәлек «Татар туе»н сәхнә әсәре буларак кабул итсәк.) Ул пьеса яшьтәшләре тарафыннан бик хуплап кабул ителә. Чын театр уены уйнарга хыялланучы яшьләрнең тәмам тупланып җитүенә шушы пьеса зур этәргеч була. Шул яшьләрнең беренчеләре сафына кергән Мәгъсүм ага Шәмсетдиневнең соңыннан сөйләвенчә, «Ике Хәсән»не аулак өй утырышларында берничә мәртәбә уйнап, үз ишеләренә күрсәткәннәр. Ләкин әле аларга ул чакта халык алдына чыгып уйнарга мөмкинчелек бирмәгәннәр.

1908–1911 еллар аралыгында Мирхәйдәр байтак кына шигырь иҗат итә. Үрнәк, өлге итеп, нигездә, Габдулла Тукай шигъриятен сайлый. Мирхәйдәрнең шигырьләрен бу елларда Казан, Әстерхан, Троицкида нәшер ителүче газета-журналлар бик теләп бастыралар. 1912 елда ул шигырьләр Казанда китап буларак укучы хөкеменә тапшырыла. Шушы ук чорда ул Клавдия Лукашевичның «Чәчәкләр арасында» исемле пьесасын да тәрҗемә итә, һәм ул тәрҗемәне Казандагы «Сабах» китап ширкәте бастырып та чыгара. Бу пьеса Мирхәйдәрне театр сөючеләр арасында танылган беренче әсәр була. «Чәчәкләр арасында»ны ул елларда байтак кына үзешчән театр төркемнәре сәхнәләштергән. Ул пьеса сәхнәләштерелгән шәһәр һәм шәһәрчекләрнең исем-атамалары әдип көндәлекләрендә китерелә.

1911 ел Мирхәйдәрнең күпкырлы иҗатының тәмам ачылып китү елы санала. Шул елның җәендә Орскига «Сәйяр» төркеме килә. Шәһәрнең кичке уеннарында бераз сәләт күрсәткән шәһәр яшьләрен бу төркем зур сәхнәгә дә чыгаргалый. Алар куйган өч спектакльнең икесендә Мирхәйдәр дә катнаша. «Орск тарихында татарча театрны башлап уйнаучы «Сәйяр» саналса да, сәхнәдән иң беренче сүзне әйтү миңа насыйп булды. «Оят, яки Күз яше» драмасындагы Маһи булып сәхнәгә иң тәү мин кердем», – дип яза ул шул хакта. Көндәлекнең алдагырак битләрендә: «Кыштан ук театр кую уе белән репетициягә тотындык. Беркөн беребезнең, беркөн икенчебезнең өенә барып репетиция ясыйбыз», – дип тә теркәп куелган. Ләкин ни сәбәпледер ул кышта алар зур сәхнәгә чыга алмыйлар. Спектакль куярга губернатор рөхсәте соңлабрак килгәндер, мөгаен. Ә менә «Сәйяр» төркеме китеп өлгермәстән, ике-өч ай дәвамында өч зур театраль кичә уздырыла. 1911 елның 9 августында зур сәхнәдә «Югалган хатын» белән «Түләшү» пьесалары куела. 11 сентябрьдә «Бүләк өчен», «Кияү эзләү», «Кызлар шулай кызык итәләр», ә 10 декабрьдә «Яшь хатын» әсәрләре уйнала. Боларны сәхнәләштерүдә унөч ир-егет (бертуган Гобәйдуллиннар, Габдулла Хәсәнев, Гариф Галиәкбәрев һ. б.) катнаша. Мирхәйдәр исә ул пьесаларның һәрберсендә хатын-кыз рольләрен башкара. («Сәйяр» килгәч чыгарылган афишадан башлап аның сәхнә псевдонимы М. Мирфанская буларак кабул ителә.) Шушы вакыйгалардан соң Орск яшьләре һәр елда татарча дүртәр-бишәр спектакль куярга керешәләр. Спектакль куюдан җыелган акчаның күбрәк өлешен Хәйрия җәмгыятенә тапшыралар. Тәүге «артистлар» төркеменә тиздән булачак халык артисты Хәким Сәлимҗановның ике абыйсы һәм татар театры дөньясында беренчеләрдән булып мактаулы Хезмәт батыры исемен алачак артист Мифтах Әпсәләмов та килеп кушыла. 1918 елда шәһәрдә беренче мәртәбә Совет хакимияте урнаштырылгач, бу төркем шактый киңәйтелеп, яңа вазифалар йөкләнеп, «Төрек-татар яшьләре оешмасы» исеме белән йөртелә башлый. «Төрек-татар яшьләре»нең тәүге зур эше Мирхәйдәрнең «Галиябану» пьесасын кабат сәхнәләштерү була.

* * *

1911 елда Мирхәйдәр Фәйзи тиз арада популярлашып киткән, байтак театр коллективлары тарафыннан сәхнәләштерелгән «Яшьләр алдатмыйлар»ны һәм төркемдәше, фикердәше Габдулла Әмиров белән бергә «Бизәнү» комедияләрен язып төгәлли. «Яшьләр алдатмыйлар»ның тиздән китап булып басылып чыгуы һәм «Сәйяр» тарафыннан сәхнәләштерелүе Мирхайдәргә иҗади дәрт өсти.

1913 елда аның икенче шигырь китабы («Яшь күңел») Казанда басылып чыга. Шул кышта ул Орскида «Кызганыч» (1914 елда аерым китап булып басыла), «Тәкъдирнең шаяруы» драмаларын, җәй айларында Җүнәйдә яшәгәндә бер пәрдәлек «Авыл бәйрәме» исемле шаян пьесасын язып төгәлли. Бу өч әсәр дә төрле-төрле тарафларда уйнала башлый. «Авыл бәйрәме»н 1921 елда автор ике пәрдәле итеп үзгәртә һәм иң элек Юлык авылы яшьләре белән бергә үзе сәхнәләштерә. (Бу пьеса 1924 елда Казанда нәшер ителәчәк.) Мирхәйдәрнең ул елларда иҗат иткән барлык пьесалары да төрле-төрле шәһәрләрдә төрле театраль коллективлар тарафыннан бер-бер артлы сәхнәләштерелгәннәр.

Әмма ки Мирхәйдәр Фәйзи иҗат иткән, татар халкының иң олуг мирасына әверелгән әсәр «Галиябану» музыкаль драмасыдыр. Ул драманы башка кардәш халыклар театрлары да бик яратып куйды. Шушы әсәр дистә еллар дәвамында татар сәхнәсенең сүнмәс бер җәүһәре булып калды. Аны заманында барлык авыл һәвәскәрләре дә бик теләп һәм яратып сәхнәләштерә иде. Хәер, элекке СССР биләмәсендәге төрки телдә эшләүче театрлар арасында да «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне бик сирәктер. Әсәр бүгенге көннәргәчә сәхнәдән төшмичә уйналып килде.

## 4

Мирхәйдәр Фәйзи җәйге айларда авылда яшәүне хуп күргән. Авыл яшьләрен ул самимирәк, үзара аралашуда үзе кебек үк гади холыклы дип исәпләгән. Аның көндәлекләрендә бу фикерне раслаучы язмалар бик күп. Ата-анасы шәһәргә күчеп яши башлаган 1905 елдан бирле җәй айларын ул «кулак абыйлары» яшәгән бик кечкенә Җүнәй авылында уздыра. Җүнәй аның туган авылы Күкшелдән ерак булмый. Күкшел кебек үк ул да текә «маңгайлы», җәлпәгрәк түбәле Гөберле таучыклары куенына сыенып утырган. Тау белән тау култыклашкан иңкүлекләрдә бер буй булып усак, каен агачлары үскән «урман колаксалары» да очрап тора. Монда Мирхәйдәрнең бертуган абыйлары Әхмәтгәрәй, Мөхәмматгәрәй, Шакирҗан игенчелек хезмәте белән көн күрә. Алар белән бергә Мостафа картның үги анадан туган энеләре дә монда яшиләр. (Әхмәтҗан баба исеменнән алынган Әхмәтҗанов фамилиясен йөртүчеләр. Егерменче еллар ахырында алар барысы

да, кулак буларак, Магнитогорск шәһәре төзелешләренә барып эләгәчәкләр.)

Җүнәйнең калган халкы шул ук Гөберлә елгасының аргы ярында зур гына мәйдан биләп торган Дүрткүлдән була. Тау тирәләрендә монда зур-зур табигый яссы ташлар аунап ята. Авыл каршындагы шундый бер яссы ташка утырып, Мирхәйдәрнең китап укыган, ни-нәрсәләрдер язган очраклары да еш кабатланган. Тау башыннан күрше ике авыл тормышы уч төбендәгедәй күренеп торган. Тау сыртындагы ташта утырганда яисә тау итәгендәге печәнлектә эшләгәндә Мирхәйдәрнең күңеле күтәрелеп киткән яисә моңсуланган чаклары да булган. «Аның үзенчә бик матур итеп җырлавы вакыт-вакыт ике авыл өстендә яңгырап торыр иде», – дип искә алган иде Дүрткүлдә яшәүче Зәкия апа Фәйзуллина. Мандолинада да ул халык көйләрен моңлы, сагышлы итеп, бик бирелеп уйный торган була. Үзе уйнаган көйләрнең саны илледән артык булуын һәм ул көйләрнең исемлеген Мирхәйдәр соңрак куен дәфтәренә дә язып куячак.

Менә 1913 елның декабрендә Җүнәйдә узган туй күренеше язмалары. Әдип анда Гариф Галиәкбәровның туенда кияү егете сыйфатында катнаша. «Кыз (өе) янында Җүнәй һәм Дүрткүл егетләре җыелган. Кунакларны араларыннан гармунда уйнап, җырлап үткәрделәр. Сыйлар мул: каз итләре табаклап. Уен, җыр, бию. Үтә матур тавыш белән яшь кенә егетләр җырлыйлар. Берсе артыннан берсе төшеп шундый өздереп бииләр. Йа Раббым, бөтен матурлыкны авыл өстенә генә түккәнсең икән... Дүрткүлдән Хәсән Зөфәрев исемле унсигез яшьлек егетнең җырлары шундый үзәгемә үтте, шундый көчле тәэсир бирде ки. Шундый саф, матур тавышлы егетләре бар халык та бәхетле булмаса...»

Көндәлектән мондый озын өзекнең китерелү сәбәбен укучы озакламый аңлар. Мирхәйдәр Фәйзинең иң югары бәяләнгән, бүген дә сәхнә түреннән төшмәгән иҗат җимеше – «Галиябану» музыкаль драмасының автор күңелендә бөреләнә башлаган көннәргә якынлашабыз. 1913–1916 еллар аралыгында Мирхәйдәр Җүнәй белән Дүрткүл яшьләре уеннарында еш катнаша. Кечке уеннарда яшьләрнең үзләрен тиң, тигез тотуларын билгеләп үтә. Бу яшьләрнең һич кыстатмыйча җырлый алуларына, җитез итеп, тыпырдап биеп китүләренә соклануларын көндәлекләренә даими теркәп бара. Шәһәр яшьләре андый түгел, үзләрен авылныкылар кебек иркен тота белмиләр, дип зарлана. Авылга кайтканда үзенең мандолинасын һич тә калдырмавын да белдерә.

Менә 1914 елның 12 июлендә теркәлгән язма. «Мәмәшевләр яшьләр өчен зур гына мәҗлес ясады. Дүрткүлдән дә байтак егетләр, шул җөмләдән Хәсән дә килде. Гатиятулла, Хәким – оста гармунчылар, Хәсән, Шаһидулла, Хәким – шәп җырчылар, Хәмкәй, Локман, Фәтхулла – матур биючеләр... Сиптерәбез!»

Ләкин андый күңелле кичәләр уздыру көннәренә дә тиздән чик куела шул. 1914 елның августында башланган Беренче бө-

тендөнья сугышы бу яшьләрнең күбесен яу кырына озатачак. Кемнәрдер шул ерак җирләрдә гүргә керәчәк яки гарипләндереп кайтарылачак. Тиздән оста җырчы Хәсән дә иптәшләре белән хәрби хезмәткә алыначак. Мирхәйдәр Фәйзи, Хәсәнне үз атына утыртып озата барган, аның моңлы итеп соңгы җырлавын озак вакыт оныта алмаган. Озакламыйча Хәсәннең госпитальдә үлгәнлеге турында хәбәр килә. Бу хәбәрне ишеткәч тә, Мирхәйдәр бик өзгәләнә. Менә аның 1916 елның 28 октябренә караган көндәлек язуы: «Күңелемә бик якын тоелган Хәсәннең лазаретта үлгәнлеген ишетеп иңрәдем. Моңлы җаның мәңге ямьнәрдә йөзсен, дус!.. Илеңне күралмый тилмереп үлдеңме, яшь җан? Синең үлемең мине рухан газаплый... Синең матур хәрәкәтләрең, мәгъсүм кыяфәтең, саф тавышың күңелемдә кадерләп тирбәтелер, туган! Синең белән ике ел таныш булып, егерме тапкыр күрештем. Ямьле йөрешләр, күңелле утырышлар бар иде. Алар үтте, син үлдең, хуш!»

Әдипнең «Җырчы Хәсәнгә» дип исемләнгән шигыре дә бар. Аның бер өлеше шушы икеюллык белән тәмамлана:

> Мин сөямен халкымны, син — халыкның алтыны,
> Моңнар белән сызылып чыга яшь күңелеңнең ялкыны...

* * *

1914–1915 елларда Мирхәйдәрнең аерым шигырьләре матбугатта басылып чыга. К. Лукашевичның тагын бер пьесасының тәрҗемәсе «Корым тазартучы» исеме белән «Ак юл» журналында дөнья күрә. Бу ике елда Орск яшьләре җиде мәртәбә шәһәр сәхнәсендә спектакль куялар. Мирхәйдәрне иң сөендергәне — ниһаять, сәхнәдә яшь артистканың пәйда булуы. «1915 елда өч мәртәбә театр уйнадык. Камилә туташ Гомәрова Орск сәхнәсе тарихында кызлардан беренче каһарман булды», — дип яза ул көндәлегенә. Ә аннан алдарак исә шул җәйдә Җүнәй авылында оста гармунчы Вафа Әдһәмов белән очрашу-танышуы тасвир ителә. «Августның 2 се. Калага үтеп барган Юлык никрутлары белән күрешү. Вафа исемлесенең гармунны ифрат матур һәм сөйкемле кыланып уйнавы белән күңелемнең самими дуслыгын казануы... Бер елга калып, Орскидан кайтып барышында Вафа белән кабат утырыш: матур көйләр уйнавы, күңелемдә матур типлар, матур уйлар тудыруы истә» дигән сүзләр теркәлгән ул очрашу турындагы язмада.

Сугыш елларында әдипнең күңелен тетрәткән тагын бер вакыйганы искә алыйк. Дүрткүл авылында кич утырганда, сугыштан гарипләнеп кайткан берәү, йөрәк өзгеч иттереп бәет сыман бер җыр җырлый. Фаҗигале, тигезсез мәхәббәткә багышланган «Сәгадәтбану» җырын. Аның җырын тыңлагач та Мирхәйдәрнең күңеле тетрәнә. Шул җырны отып алып, күңеле моңланган

мизгелләрдә җырлый торган булып китә. 1916 елның җәендә Малмыж шәһәре бакчасында да ул «Җәмилә», «Сәгадәтбану» көйләрен моңланып җырлап утыруын көндәлегенә язып куйган. Бу җырга бәйле хатирәләр Мирхәйдәрнең энесе, Сәетгәрәй улы Сәгыйть ага истәлекләрендә дә телгә алына.

Кайбер Европа мәмләкәтләренә тиң җир-биләмәгә ия Орск өязенең бер читендәрәк урнашкан Юлык авылы һәм җырчы, оста гармунчы Вафа дусты белән Мирхәйдәр Фәйзи тагын дүрт ел чамасы вакыт үткәч якыннанрак танышачак. Рәмиев байлар төзегән Юлык мәчете карамагындагы шул ук байлар оештырган китапханәне саклап калу өчен, 1919 елның февралендә аны шунда эшкә җибәрәләр. Шул китүдән башлап аның төп эш урыны китапханә булачак. Юлык, Баймак һәм Темәс кебек алтын чыгару, алтын эшкәртү төбәгендәге эшче китапханәләрендә ул сигез ел чамасы эшләп ала. Арадан бер суык кышны – 1924 елның кышын – ул Казанда, Үзәк Шәрык китапханәсенең балалар әдәбияты бүлегендә эшләп уздыра. Мөгаен, нәкъ шул кышта аның күңелендә Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы нигезендә яңа бер пьеса язу уе да тугандыр әле. Шул фикерне дәлилләүче фактларга алдарак тукталырбыз.

Кайбер әдәбиятка багышлы җитди генә хезмәтләрдә Мирхәйдәр Фәйзинең унынчы елларда ук Башкортстан ягы авылларында йөреп, әйтик, Орскидан бик еракта урнашкан Бөре, Балтач тирәләренә барып, халык иҗаты үрнәкләрен барлаганлыгы бәян ителә. Икенче берәүләр аны вакытыннан алда, унынчы еллардан ук, китапханәче хезмәтен башкаручы дип күрсәтмәкчеләр. Кабатлап әйтергә кирәк, авторның көндәлекләрендә мондый сәяхәтләр, һәм ул елларда китапханәче вазифасын башкару очраклары теркәлмәгән. Беренче мисалда авторлар әдипнең хәзерге Киров өлкәсе белән чиктәш булган Балтач, Шодаларга сәяхәт кылуларын үз төбәкләре белән бәйләргә тырышкан булса кирәк. Ә китапханәче хезмәтен үтәүгә Мирхәйдәр, алда әйтелгәнчә, 1919 елның февралендә Орск өяз идарәсенең бер түрәсе булган Хаҗи Рәмиев тарафыннан җибәрелә. Башлыча бертуган Рәмиевләр тарафыннан оештырылган һәм шулар исәбенә тотылган китапханәне саклап калырга кирәк була. Ул тирәләрдә Гражданнар сугышы озак дәвам итә. Өязнең күпчелек төбәгендә Совет хакимияте урнаштырылгач та әле анда Зәки Вәлиди төркеменә кергән көчләр үз җәмгыятьләрен оештыру теләге белән йөри. Юлыктан кырык-илле чакрымдагы Темәс бистәчеге аларның башкаласы итеп билгеләнә. Һәм шул сәбәпле бу төбәктә ике хуҗага да буйсынмаган үзбаш төркемнәр дә барлыкка килә. Һәм алар байтак авылларда тәртипсезлекләр кыла башлагач, өяз җитәкчелеге бу якларга бер төркем үз кешеләрен җибәрергә карар кыла. Мирхәйдәрнең төп бурычы әлеге китапханәне таралудан саклап калу һәм авыл яшьләрен үз тирәсенәрәк йолыштыру була.

Орск тирәләрендә ике ел чамасы барган сугышлардан соң ваба (холера), тиф кебек зәхмәтләр көч алган була. Бу чирләр, ярлы яки бай булуга карамастан, һәркемне сагалап тора. 1918 елның кара көзендә Мирхәйдәр дә бер ай чамасы сырхаулап ала. Шәһәрнең иң күп байлык туплаган сәүдәгәре Борнаевлар нәселеннән дә бер кыз ул фаҗигадән котылып кала алмый. Мирхәйдәр белән хат, фотолар алышып, ара-тирә күрешеп йөргән Гөлсирә Борнаева ноябрь башларында вабадан вафат була. Шул хәлләрдән соң туган-ыру арасында Мирхәйдәрне яман чирләр баскан шәһәрдән ераккарак озатып тору теләге тугандыр, күрәсең. Һәм аның Орскидан йөз илле чакрымдагы, берничә үркәчле биек Ирендек таулары артындагы Юлык авылына юллануына сәбәп була, ахрысы. Һәм шул очраклы сәбәп аны Юлык, Баймак, Темәс тирәләренә дистә елларга «бәйләп» куячак.

Ул елларда булган вакыйгаларны әле алда искә алырбыз. Хәзер исә янә 1916 елның җәенә әйләнеп кайтыйк. Уфадан Орскига «Нур» театры артистлары килә. Бу театр җитәкчесе Сәхипҗамал Гыйззәтуллина белән Мирхәйдәр «Сәйяр» труппасының беренче сәфәре вакытында сәхнәдә уйнаганда танышкан була. Һәм бу юлы да ул килгән артистлар белән бергә сәхнәдә берничә роль башкара. Сәхнәгә кем рәвешендә чыгуы, ничек уйнаганлыгы көндәлек дәфтәрләрендә теркәлгән.

Шул вакыйгалардан соң ук ерак Малмыж шәһәреннән борчулы хәбәр алына: Фатыйма апасының хәле начар икән. Мәшәкатьле озын сәфәргә чыгып китәсе була. Сәетгәрәй агасының Орскига кунакка килгән улы Сәгыйть белән алар 7 июль иртәсендә юлга кузгалалар. (Сәгыйть Гәрәй улы Фәйзуллин озак еллар Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, тәрҗемәче булып эшләде. М. Фәйзинең 1957 елда нәшер ителгән икетомлык әсәрләрен туплап чыгаручы һәм әдипнең төп язма мирасын Казан университеты мирасханәсенә тапшыручы да ул булды.)

Мирхәйдәр, Малмыжда апасы йортында берәр атна торганнан соң, мулла Сәетгәрәй агасы яшәгән Шодага юл тота. (Бу авыл хәзер Татарстанның Балтач районына керә.) Әдипнең көндәлегендә Шода авылы тирәлеге күренешләрен, анда яшәүчеләрнең гореф-гадәтләрен тасвирлауга багышланган битләр байтак. Аларны көндәлек сәхифәләре итеп түгел, саф әдәби әсәр битләре кебек мавыгып укыйсың. «Кешеләрнең киенү рәвеше дә бездәгенең тәмам киресе дип әйтерлек. Хатын-кызларның да аякларында – чабата, тула оек. Күбесенең өстендә – кызыл күлмәк. Кызларның билендә – матур алъяпкыч. Кырдан кайтканда кызлар бик киенешеп кайталар... Ялтырап торган уракларын кулларына тотып, ваграк атлап, нык басып китүләрен авылның иң матур күренешләреннән санарга ярый». Шушы сүзләр янәшәсендә мондый юллар да бар: «Иген уру машиналары татар авылларында таралмаган әле, кул белән уралар. Җир өсте кызыл яулыклы абыстайлар белән тулган була».

Әмма бу авылда Мирхәйдәр күңеленә иң хуш килгәне – яшьләрнең саф сулы чишмә буенда очрашу-аралашулары, шул тирәдәге болында яшьләр оештырган уеннар була. Үзенең алардан өлкәнрәк икәнлегенә карамастан, җырларга, мандолинада уйнарга һәвәс булган яшь күңелле Мирхәйдәр дә алар уенына кушылып китә. Үзеннән күпкә яшьрәк кызлар белән дус, сердәш булу дәрәҗәсенә ирешә…

Шода авылына Мирхәйдәрнең 1923 елда килүе аеруча истәлекле. Унҗиде-унсигез яшьләрдәге бик чибәр күрше кызы Гыйлембану белән ул аеруча дустанә мөнәсәбәткә керә: аның сердәшенә әверелә. Яше утыздан ашканын онытып, ул шушы кызга тәмам гашыйк була. «Шодада көннәр бик күңелле уза. Бигрәк тә матур су буе манзарасы мине тәмам сихерләде… Гыйлембану Шодадагы көннәремнең таҗы булды. Аның белән бер күрешеп сөйләшү мең рәхәттән рәхәтрәк тоела…» Кызның күңелендә йөрткән егете барлыгын белгәч тә, теге егеткә карата бераз үч тә саклап йөри Мирхәйдәр. «Гыйлембану исеме исемә төшкәндә сөенеп, Ибрай исеме төшкәндә көенеп китәм», – дип язып куя ул көндәлегенә. Үз-үзен белештермичә гыйшык утында яна башлавын аңлагач кына ул авылдан тизрәк китәргә була. «Үзем китәм, күңелем кала… Хуш, Шода, хуш…» – дип уфтанып та куя ул. Ләкин бу авылдан киткәч тә аның йөрәге тиз генә тынычланмый әле. Гыйлембану, аңа гыйшык тотып йөрүче тегермәнче егет тиз генә онытылмыйлар. Шушы яшь кызга булган хисләренең бер чеметемен ул Шодадан киткәч язган «Сәрвиназ» хикәясендә һәм «Ибрай яры янында» шигырендә чагылдырган:

Тау башында – Сабир, Габдулла, мин,
Тау астында кызлар су ала;
Ал чиләген асып, вак-вак басып
Гыйлембану килгәч, бу бала
Алларына бәхте баскан кебек,
Күккә ашкан кебек куана, –

дип яза ул, үзе кичергән хисләрне искә алып.

Кызга гыйшык тотып, аңа өйләнергә йөргән «Ибрай»ның шигырь авторына дус булганлыгына ишарә дә бар бу шигырьнең соңгы строфасында:

Ал кулыңны, көнләштермә егетен,
Яшь Ибрайның җанын кыйнама!
Ирексездән дуслык җимерелмәсен,
Су буеның ямен буяма!

«Сәрвиназ» хикәясендә исә шушы ук мәхәббәт өчпочмагы чак кына башкачарак тасвир ителә…

* * *

Мирхәйдәр Фәйзинең туганнары, дусларының көндәлек һәм альбомнарына, аларга юллаган хат һәм фотосурәтләргә теркәлгән шигырь куплетлары да байтак. Җитмешенче елларда аларның бер өлешен мин, бер өлешен Орск шәһәре музее хезмәткәре Татьяна Черкас, күпмесендер «Орский рабочий» газетасы мөхәррире Михаил Секрет тупларга тырышып караган идек. М. Секрет Мирхәйдәргә багышлап рус телендә документаль повесть нәшер итәргә дә хыялланды. Әсәренең өзекләрен үзе редакциялəгән газета битләрендә бастырып та чыгаргалаган иде. Автор ул повесть кульъязмасын һәм бер дистә чамасы әдипнең ялгыз һәм төркемдә төшкән фотосын Татарстан китап нәшриятына да җибәрде. Ләкин кемгәдер ул әсәр ошамады, һәм кульъязманы авторына кире җибәрделәр шикелле.

Әдипнең туганнары һәм дусларының көндәлекләренә, альбомнарына яки фотолар артына язып калдырган шигырь үрнәкләре дә байтак сакланган. Алар арасында да Шода вакыйгасына бәйле бер-ике куплет бар. Мәсәлән, бер абыйсының улы, булачак инженер Искәндәр альбомына ул түбәндәге сүзләрне яза:

Икәү генә уйнадык,
Соңга калып.
Суын алып,
Биреп китте кульъяулык.
        Көянтәсен җилкәләгәч,
        Егетеннән иркәләнгәч,
        Китте теләп саулыкны;
Җырлап калдым,
Болгап калдым,
Җаныем чиккән яулыкны!

Бу (очрашу) 1924 ел, июнь 13 тә, җомга көн Шода авылында булган һәм язылган. Вакыйгасы, җыры, көе бергә бәйләнеп барды. Асылда, «Авыл кызы» урынында «Гыйлембану» тора. Үзем өчен бик сөйкемле хатирәмне синең альбомыңа теркәдем. Абыең М-Хәйдәр Фәйзи. 1924, 2 сентябрь, Җүнәй».

Шода авылында, элекке Сәетгәрәй мулла йортында, хәзер Мирхәйдәр Фәйзи тормышына һәм иҗатына багышланган музей эшли. Ул Татарстан хөкүмәте һәм Балтач районы җитәкчеләре тырышлыгы белән әдипнең тууына 100 ел тулган көннәрдә, 1991 елның көзендә ачылды. Мирхәйдәрнең өзелеп сөйгән, соңгы мәхәббәте булган, ай кебек аксыл йөзле, кара толымлы Гыйлембануга да, олыгаеп килүче әдипне ике ут арасында янарга мәҗбүр итүче Ибрайга да анда урын бирелгән.

## 5

Малмыж-Шода якларында йөреп кайтканнан соң, Мирхәйдәр Фәйзи яңа әсәр язарга керешәчәген белдерә. Менә аның 1916 елның 8 октябрендәге көндәлек язмасы: «Казан ягы авылларында йөреп кайттым. Ул яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды. Көннәрем шул хакта мәшгуль булып уза башлады».

Шушы юллардан соң берничә бит кенә арырак 28 октябрьдә әдип Дүрткүл авылы җырчысы Хәсәннең «лазаретта үлеп калуы» турындагы хәбәргә бәйле кайгы-хәсрәт сүзләрен дә теркәгән. Бу көндәлек битләрендәге язмалардан күренә ки, булачак пьеса каһарманнары Хәлил, Исмәгыйль, Галиябану образларын тудырган дәвердә авторның күз алдында Шода авылы яшьләренең тормыш-яшәеше генә түгел, шулай ук Җүнәй белән Дүрткүлдәге чордашларының үзара бәйләнешлары да торган. Кайбер әдәби хезмәт авторлары язганча, Хәлил образына төп оеткыны салучы оста гармунчы һәм җырчы Вафа Әдһәмов кына булмаган. Сәхнәдә атып үтереләчәк Хәлил артында, аңа сөялеп үк, фаҗигале язмышлы җырчы Хәсән дә тора, Шода авылы егете Ибраһим да шул тирәдә шәйләнә. Галиябану образы да ниндидер мифик бер Сәгадәтбану копиясе генә түгел. Ул образ артында Шода, Җүнәй, Дүрткүл кызлары шәүләсен дә, Орск сәхнәсендә берничә ай балкып алган «мөкаммәл кыяфәтле» Камилә туташ Гомәрова язмышы чагылышын да күреп була. (Камиләне нәкъ шушы пьесаны язарга керешер алдыннанрак кына үзе теләмәгән өлкәнрәк яшьтәге кешегә кияүгә бирәләр.) Әсәрнең тәүге исеменә карата да кайберәүләр белән бәхәскә керәсе килә. Сәгадәтбану исем-атамасын хәзерге татарчага күчерсәң, Бәхетлебану була. Бәхетлеме соң пьесада сурәтләнгән кыз? Юк, әлбәттә. Күз алдында сөйгән яры атып үтерелгән кыз берничек тә бәхетле була алмый. Миңа калса, Мирхәйдәр Фәйзи бу әсәрен язарга керешер алдыннан бәхетле кыз образын тудырмакчы булган. Әмма язып бетерү дәверендә инде ул аның язмышын үзгәрткән. Ә баштарак, пьеса исемен сайлаганда, аның күптәнге кумиры Галимҗан Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» әсәре йогынтысында булуы да бик ихтимал. Мирхәйдәр дә авыл яшьләренең үзара мөнәсәбәтләре, сөю-сөешүләре йогынтысында шушы әсәрен язарга утыргандыр. (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романын укыганнан соң әсәрләнгән Мирхәйдәрнең тиз арада мәкалә язып, аны «Идел» газетасында бастыруын да истән чыгармыйк.)

Соңгы елларда татар һәм башкорт матбугатында (бигрәк тә Башкортстандагы күршеләрдә) «Галиябану» әсәренең язылу вакыты һәм анда тасвирланган вакыйгаларның җирлеге мәсьәләсендә байтак кына хата фикерләр әйтелде һәм язылды. Имеш, ул пьеса Юлык вакыйгаларына бәйле, Юлык авылында язылган. (Алдарак язганымча, Мирхәйдәр Фәйзи Юлыкка эшкә

1919 елның февралендә җибәрелә. Ә «Галиябану» 1916 елның көз айларында языла башлый. (Шул хакта әдипнең көндәлегендә үз кулы белән язылган. 1921 елда ул Юлыкта «Кызыл йолдыз» драмасын яза.) Әле 2006 елда гына да Башкортстанда яшәүче бер татар журналисты Казанда басылган мәкаләсендә: «Галиябану» Баймак төбәге вакыйгаларын чагылдыра, әсәр шунда язылган, дигәнрәк фикер белән чыкты. Шундыйрак эчтәлекле «гыйльми язма»ларны укыгач бер сорау туа: Мирхәйдәр көндәлекләрен алып укыганмы соң бу каләм әһелләре, галимнәр? Мирхәйдәр эзләреннән йөргәннәрме? Ул көндәлекләрдә акка кара белән һәм әдипнең үз кулы белән язылган ич: «Галиябану» пьесасы 1916 елның октябрь урталарында языла башлый һәм өч айдан соң Орск шәһәрендә тәмамлана. 1917 елның башында ул Оренбургка, «Ширкәт» труппасы режиссёры Вәли Мортазин-Иманскийга җибәрелә. Вәли, үз тәкъдимнәрен язып, пьесаны авторга кире кайтара. Мирхәйдәр кулъязмага үзе кирәкле тапкан өстәмәләрне кертә һәм пьесаны тиз арада кабат Оренбургка озата. «Ширкәт» артистларына әсәр ошый, бик хуп күреп, алар аны тиз арада сәхнәгә чыгаралар. «Галиябану» Оренбург шәһәр театры бинасында 1917 елның 19 март кичендә халыкка тәкъдим ителә. Галиябану ролен татар халкының булачак күренекле артисты, мөлаем тембрлы тавышлы Сара Байкина, Хәлил ролен режиссёр Вәли Мортазин үзе, Исмәгыйль ролен Госман Садыйков бик оста башкарып чыгалар. Алар уенын халык дәррәү кубып хуплый. Шул ук елның 15 декабрендә пьеса Оренбургта кабат уйнала. 1918 елның кышында исә ул Казан сәхнәсендә куела. Ә 1922 елда Галимҗан Ибраһимовның мактаулы кереш сүзе белән Казанда аерым китап буларак басылып чыга.

«Галиябану»ның беренче мәртәбә сәхнәгә куелуын бозып күрсәткән тагын бер үкенечле фактны билгеләп үтмичә мөмкин түгел. Милләтебез абруен, данын дистә еллар дәвамында сакларга, акларга һәм пропагандаларга тиешле «Татар энциклопедиясе» китабының икенче томында шушы әсәргә багышланган мәкаләсендә театр белгече И. Илялова: «Беренче тапкыр Оренбургта аны «Нур» труппасы куйды», – дип яза. Ә бу труппага багышланган махсус язмаларда исә: «Нур» 1916 елның язында Оренбургтан китә, шул елның көзендә эшчәнлеген Уфада дәвам иттерә», – дип белдерелгән. Бу очрак та кайберләребезнең Мирхәйдәр Фәйзи иҗатына һәм мирасына карата саксыз булганлыгын күрсәтә, минемчә. «Галиябану» пьесасына нигезләнеп эшләнгән бер кино әсәре авторының никадәр саксыз эш итүе турында безнең матбугатта бер-ике кәлимә сүз булган иде инде. Мирхәйдәрнең «Галиябану» пьесасында түгел, башка бер генә әсәрендә дә хатын-кызга карата мыскыллап карау, хатын-кыз образын пычратып тасвирлау очрагын очрату мөмкин түгел. Үзе дә гомер бакый саф намуслы, чын зыялы тәрбияле шәхес булган. Әсәрләреннән дә пакьлек, сафлык нуры бөркелеп тора.

* * *

Орск шәһәре артистлары да «Галиябану» әсәрен 1917 елның 29 декабрендә автор катнашында сәхнәләштерәләр. Монда Галиябану ролен икенче бер күренекле шәхес – Башкортстанның булачак халык артисты Майбәдәр (Маһибәдәр) Йосыпова башкара. Галиябану – Бәдәрнең Орск сәхнәсендә уйнаган икенче роле. 1917 елда инде ул Идрис Багдановның «Югалган хатын» пьесасын куюда Люси псевдонимы белән катнашкан була. Соңрак та ул Орск сәхнәсендә берничә пьесада җырлы-биюле рольләрне башкара. Шул исәптән Мирхәйдәрнең «Асылъяр»ын беренче мәртәбә сәхнәләштергәндә дә Дүрткүл кызы Бәдәр-Люси баш рольне башкара. Орскида укытучылар курсын тәмамлагач, ул төрле татар һәм башкорт мәктәпләрендә берничә ел укыта. Һәвәскәр артистка Майбәдәрне 1926 елда Башкорт дәүләт театрына кабул итәләр. Тиз арада ул шул театрның йөзек кашына әверелә. (Дүрткүл халкы һәр килгән кешегә, Майбәдәр – безнең горурлык, балачагы бездә үтте, дип, мактанып сөйлиләр.)

Орск сәхнәсендә уйнаучы артистлар, рәсми рәвештә театр труппасы оештырылмау һәм махсус театр ачылмау сәбәпле, Совет хакимияте дәверендә дә үзешчән булып калалар. Шул ук вакытта Мирхәйдәр Фәйзиләр чорыннан алып 1960 елларга кадәр шәһәр халкына даими рәвештә театр уеннарын уйнап киләләр. Үз рәсми театрларын ачарга омтылган очраклары да булгалый. Большевикларга каршы көрәшкән милләт вәкилләре белән бергә колчакчыларга ияреп Себергә дип чыгып киткән Габдулла Кариев, акылга килеп, 1919 елның башында аклар кулындагы Орск шәһәрендә туктала. (Адмирал Колчакның руслардан башка халыкларга якты йөз күрсәтергә теләмәвен, «кече» милләт вәкилләрен тиздән кәкре каен башына утыртасын бөек артист әйтерсең лә алдан сизенгән.) Орскига элегрәк елларда килгәләгән, аның зыялы байларын һәм Мирхәйдәр Фәйзи тирәсенә берләшкән яшьләрне бераз белгән кеше буларак, шәһәргә килгәч тә ул монда труппа туплау эшенә керешә. Ул төбәктә сугыш афәте әле тәмамән бетмәгән бер вакытта репетицияләрне башлап та җибәрә. Шул еллардагы бу вакыйгаларны яхшы белгән күренекле артист Хәким ага Сәлимҗанов ул көннәрне болайрак тасвирлый: «Габдулла Кариев килеп төште. Килү белән, труппаны оештырып җибәрде. Бәхетемә, абыйларым да аның кул астында уйный башладылар. Кариев килгәч, халыкның театр белән кызыксынуы арта төште. Ул вакытта спектакльләр кую, театрга йөрү чын мәгънәсендә модага кереп китте. Ләкин шул ел урталарында ук Кариевны Казанга чакырып алалар. Аның урынына калган Мифтах Әпсәләмевне дә тиздән «Казан тартып ала», – дип яза Хәким ага. Бу вакытта Мирхәйдәр исә Юлык, Баймак төбәгендә халыкны мәдәниятле итү, агарту эшләре белән шөгыльләнә. Юлыкта да, Баймакта да бер-бер артлы спектакльләр куя. Җир куенынннан алтын, бакыр

ише байлыкларны чыгаручы эшчеләр арасында матбугат тарату, театр уеннары оештыру эшләре белән мәшгуль була. Шул рәвешле Орскида милли театр үз вакытында ачылмыйча кала. Ә халык саны буенча Орскидан биш-алты мәртәбәгә кечерәк Баймакта исә бераз соңлабрак булса да ул ачылачак! Бу очракта да Мирхәйдәрнең тырышлыгы җилгә очмый, нәтиҗәсен бирә.

1920 елның май аенда Самара шәһәрендә З. Солтанов белән К. Тинчурин җитәкчелегендә ачылган драма артистлары студиясенә укырга Орск шәһәре һәвәскәрләреннән унлап кеше җибәрелә. Туган шәһәрләрендә рәсми театр ачылмау сәбәпле, Маһинур Казакова, Маһинур Хөсәнова, Рифгать Фәйзи, Зиннур Садыйков кебекләр үзләренә башка театрларны сайларга мәҗбүр булалар. Әйтик, Мирхәйдәргә эне тиешле Рифгать Шакирҗан улы Фәйзи соңрак Башкорт драма театры сәхнәсендә артист һәм режиссёр буларак таныла, «Башкортстанның халык артисты» дигән мактаулы исемгә лаек була. Егерменче еллардан башлап Орск шәһәрендә «Беренче Май» исемен йөртүче татар клубы эшли, аның штатына драма артистлары эшчәнлеген оештыручы ике кеше билгеләнә. Соңгы шундый җитәкчеләрнең берсе мәшһүр шахматист Гата Камскийның бабасы, элегрәк төрле театрларда уйнаган профессиональ артист Гата Сабиров-Камский була. Ул клуб карамагындагы драма «түгәрәге»ндә дистә еллар дәвамында сәхнәдән төшмичә уйнаган, шәһәр халкы күңелен яулаган чын артистлар бар иде. Мәсәлән, җырлы-биюле рольләрне дә, җитдирәкләрен дә бертигез камил башкаручы, унҗиде яшеннән клуб сәхнәсен икенче эш урыны итеп санаучы Зәйнәп Зарипованы шәһәр халкы бүген дә сагынып искә ала. Спектакльләрдә төрле типтагы рольләрне оста башкарудан тыш, кичә-концертларны алып баручы да, Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил әсәрләрен рәвешенә китереп, артистланып сәхнәдән укучы Хөрмәт Хасиятуллин да бар иде. Ул Орскида илленче еллар сәхнәсенең күрке булды. Ләкин 1960 елда, Н. Хрущёв чорының милли мәсьәләгә караган тискәре карарлары чыккач, ул клуб ябылды. Шул рәвешле илле еллык тарихы булган Орск шәһәренең милли үзешчән театры да таркалды.

## 6

Чирек гасырлык иҗат гомерендә Мирхәйдәр Фәйзи җәмгысы 16 оригинал һәм 7 тәрҗемә пьеса авторы буларак таныла (кульъязмада сакланган әсәрләрен исәпкә алмаганда). 2 шигырь китабы, үзе җыеп туплаган «Халык җырлары» җыентыгы, кечерәк бер китаплык хикәяләр һәм 70 тән артыграк дәфтәрне берләштергән көндәлекләре дә аның шома каләме белән язылган иҗат җимешләре. Аның драма әсәрләреннән «Авыл бәйрәме» (Җүнәй, 1913 һәм Юлык, 1921), «Урал суы буенда» (Орск, 1918), «Асылъяр» (Орск, 1919), «Кызыл йолдыз» (Юлык, 1921), «Ак калфак» (1922, Темәс авылы), «Адашкан күңел» (Темәстә языла башлый,

1923 елда Уфада тѳгәлләнә) татар һәм башкорт театрлары тарафыннан һәммәсе дә кат-кат сәхнәләштерелгәннәр. «Кызыл йолдыз» белән «Адашкан күңел» пьесалары – Татарстан Республикасы күләмендә оештырылган конкурсларда алдынгы урыннарны яулап алган әсәрләр. Бу төркемдәге пьесалар һәм «Галиябану» берничәшәр тапкыр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә куела. Мондый бәхеткә сирәк драматурглар ирешә алган. Әйе, андый бәхетлеләр исемлеге элек зур түгел иде. «Галиябану» музыкаль драмасы шундый жанрдагы беренче татарча пьеса рәвешендә дә, эшләнеше ягыннан камил, төгәл, җитлеккән әсәр буларак та милли җәүһәрләребезнең тәүгеләреннәндер. Ул әсәр алтмышынчы елларгача татар сәхнәсенең сүнмәс бер йолдызы булды. Элекке СССР мәмләкәтенә кергән төрки телдә эшләүче театрлар арасында «Галиябану»ны сәхнәләштермәгәне калмагандыр. Башка бер милләт җимеше булса, андый әсәр күптән инде рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән булыр иде.

Казан университеты китапханәсенең кулъязмалар бүлегенә тапшырылган әдип мирасы арасында тагын берничә әсәрнең саклануы билгеле. Байтак еллар шул китапханәдә эшләгән, Мирхәйдәр Фәйзи тормышына һәм иҗатына багышлап рус телендә юка бер китапны нәшер итүдә катнашкан Диләрә ханым Абдуллина шул хакта миңа ниләр яза: «Архивта әлегә кадәр беркайда да басылмаган, хәтта исемнәре дә тиешенчә билгеле булмаган пьесаларның кулъязмалары бар – «Китап», өч картинада, «Чүмеч баш», бер пәрдәле көлке әсәр, «Әмәти улы Мәмәти», бер пәрдәле көлке әсәр, «Ватык көзге янында», бер пәрдәле тәрҗемә пьеса... Язучы иҗат иткән башка жанрдагы әсәрләр дә байтак». Әйтергә кирәк, М. Фәйзинең кулъязмалары, бу мирасханәдән тыш, Милли музей архивында да саклана бит әле. Анда ниләр бар икән?

Узган гасыр башында Орскида туган һәм гомерен шул шәһәрдә уздырган инженер вә фотожурналист Абдулла абый Исәнбаев Мирхәйдәрнең тагын бер пьесасы булуын сөйләгән иде. Габдулла Тукайның «Шүрәле»се җирлегендә ул егерменче елларда балалар өчен шул исемдәге пьесаны язган була. 1924 елның җәендә балалар белән аны сәхнәләштерергә дә талпынып карый. Ләкин байларга каршы көрәш барган бер заманда, онык-оныкчаларын гимназиядә укыткан «Мостафа бай баласы»ның укучылар белән эшләвен хупламаучылар табыла. Мирхәйдәр үз шәһәреннән китәргә мәҗбүр була. А. Исәнбаев әйтүенчә, ул пьесаның кулъязмасы аларда булырга тиеш икән. «Китап шкафларын актарганда килеп чыкса, мин сиңа хәбәр итәрмен», – дип вәгъдә дә биргән иде ул миңа 1971 елда. Ләкин шуннан соң озак яшәмичә үлеп китте. Ә миңа берничә хаты һәм Мостафа Фәйзуллин йортының ул төшереп җибәргән фотосурәте миндә саклана. Шул йортка истәлек тактасы куелгач төшерелгән бер фото да бар иде. Ләкин ул кайсыдыр редакциядән миңа кайтарылмады, шул газетада чыккан фотоның шәүләсе генә калды.

Алда сурәтләнгән фактлардан соң күрәбез ки – татар театры тарихына драматург Мирхәйдәр Фәйзинең керткән өлеше зур икән. Аны без икеләнмичә татар милли театрына нигез салучыларның берсе дип танырга хаклыбыз. Драматург буларак аның берничә пьесасы үз вакытында зур-зур сәхнәләрдә уйнала, уңыш казана. Илленче еллар ахырынача диярлек һәр авыл үзешчәннәре аның «Галиябану» пьесасын куймыйча калмаслар иде. Шул ук елларда Казахстанда да М. Фәйзинең ул әсәре бик популяр булды. Аны үзешчәннәр дә уйнады, кайбер дәүләт театрлары да сәхнәләштерде. Димәк ки, аның әсәрләре артистларның, күпсанлы дәүләт театрлары һәм үзешчән төркем-труппаларның яшәешенә, үсешенә дә булышлык иткән әсәрләр. Икенчедән, Орск шәһәрендә Шакир Мөхәммәдъяров башлаган эшне дәвам иттерүче, бер шәһәр театр сөючеләренең һәм үзешчәннәренең әйдәүчесе буларак та аның хезмәте хөрмәтләүгә лаек.

Мирхәйдәр Фәйзи 1928 елда Баймак шәһәрендә эшләгән вакытта вафат була. Һәм, бик хөрмәтләп, Совет хакимиятен бу төбәктә барлыкка китерүдә катнашкан шәхесләр өчен билгеләнгән мәйданчыкта җирләнә. 1994 елда, Зөфәр Бәширов белән анда булганда әле, яңа тормыш коруда катнашкан шәхесләр өчен билгеләнгән, хәзер шәһәр биләмәсендә калган ул каберлек саклана иде. Ә элекке газета редакциясе урнашкан бина каршында Мирхәйдәр Фәйзи йөзе чалымнары шәйләнгән бер һәйкәл дә тора.

*2011*

# ӘЙ ГАРМУН, ГАРМУН...

*(Документаль повесть)*

### Һәр җирдә тансык кунак

Мәшһүр гармунчы артист Фәйзулла Туишевны, мөгаен, үз вакытында сәхнәдә күрмәгән, һич югы, аның бик тә үзенчәлекле, дәртле, моңлы итеп уйнавын радио аша ишетмәгән бер генә татар кешесе дә калмагандыр. Ник дисәң, илле елдан ашып киткән иҗат гомерендә бу тынгысыз музыкантның концерт белән бармаган җире, төрле зурлыктагы чеңгелдәп торган үз гармуннарын уйнамаган сәхнәсе калмагандыр. «Фәйзулла Туишев – милләтебезнең горурлыгы, халык арасыннан чыккан чын талант», – дип язды аның турында күренекле язучыбыз Фатих Хөсни.

СССР дип исемләнгән дәүләт оешканчы ук әле ул, көмеш телле гармуннарын иңенә асып, Каф таулары артындагы Баку, Тифлисларны да, Мәскәү белән Петербургларны да, ерак Себер шәһәрләрен дә йөреп, урап чыга. Йөри-йөри җир читендәге Вла-

дивостокка да барып җитә, чит мәмләкәт шәһәре булган Харбинда да торып кайта. Болар белән генә чикләнмичә, Европаның мәдәни үзәге саналган Парижның үзендә, зыялы тамашачы алдына чыгып, татар белән рус халыкларының моң-көйләрен уйнап дан ала. Анда ул икенче бер мәшһүр якташыбыз Фёдор Шаляпин белән бергә бер сәхнәдә чыгыш ясау бәхетенә ирешкән артистларның бик сирәгедер. Фәйзулла Туишевны һәр җирдә бик теләп, яратып кабул иткәннәр. Ул җитәкләгән артистлар бригадасы Татарстанның һәм аңа чиктәш өлкә һәм республикаларның барлык татар авылларында булып кайткан диярлек. Әйе, аның җитез бармаклары күңел түрендәге халкы моңын, сагышларын бик мул өләшкән. Аның уйнау осталыгына соклануларын милләтебезнең бик мәгълүм шәхесләре Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һ. б. бик күпләр әйтеп һәм язып калдырган. Тиешле бәяне үз вакытында ук биргәннәр.

1950–1960 елларда урамда очраган һәрбер татар кешесеннән «Син гармунчы Туишевны беләсеңме?» дип сорасаң, ул кеше ике дә уйлап тормас, «беләм» дип җавап бирер иде. Кайсы як авылыннан, кайсы шәһәрдән килгән булуына карамастан.

Артистның чордашларының искә алуларына һәм сакланып калган афишаларга таянып, Фәйзулла Туишевның кайсы зур шәһәрләрдә һәм кайчан булганлыгын күз алдына китерә алабыз. Үзе туып үскән төбәктәге Сембер, Самара, Казан, Түбән Новгород һәм Идел буендагы башка барлык шәһәрләрне ул иң беренче гастрольләре вакытында ук йөреп чыга. Аңа ул вакытта әле егерме яшь кенә була. (1910 еллардагы артист кыяфәтен күзаллардай фото сакланган. Артист гитарада уйный, янәшәсендә гармуны чират көтеп тора.) Ә туган-үскән җирләреннән ерак-еракларга таралышып көн күрергә мәҗбүр ителгән милләттәшләребез исә сөекле музыкантны һәркайда да сагынып каршы алган. Мәһабәт буй-сынлы, көләч йөзле артистның шат елмаеп сәхнә түренә чыгып басуын, шундагы өстәл өстенә тезеп куелган эреле-ваклы гармуннарның берсен алып уйный башлавын түземсезләнеп көтеп торганнар. Концертны алып баручы «Фәйзулла Туишев уйный!» дип белдерүгә үк гөрләтеп кул чабулар башланган.

Хәер, Фәйзулла Туишевның гармунда уйнавын татар тамашачысы гына түгел, башка халык вәкилләре дә бик яратып тыңлаганнар. Аның уеннары аша татар халкының эчке рухын үз итеп күңелләренә сеңдерә торган булганнар. Моның шулай икәнлеген без матбугат битләрендә теркәлеп калган истәлек язмаларыннан да укып беләбез. Мәсәлән, танылган артистның 50 еллык юбилеена багышланган бер мәкаләдә Муса Җәлил болай дип язган: «Фәйзулла ага төрле милләт көйләрен өйрәнүгә һәм аларны оста уйнап бирүгә күп игътибар куя. Ул казах, үзбәк, азәрбайҗан, кавказ, чуваш, чегән һ. б. азчылык милләтләрнең хәзерге композиторлары әсәрләреннән һәм халык көйләреннән күп кенә үрнәкләр уйный. Шунлыктан Фәйзулла аганың музыка

өлкәсендәге хезмәте интернациональ төс ала...» Мәкалә СССР Югары Советы нәшер иткән татарча «Коммунист» газетасында 1934 елның 30 декабрь санында басылган.

Совет хакимияте урнашуының 10 еллыгы көннәрендә, 1927 елда, Мәскәүдә СССР халыкларының сәнгать фестивале үткәрелә. Илнең төрле төбәгеннән килгән театр коллективлары үз осталыкларын, ә концерт бригадалары үз һөнәрләрен башта таләпчән комиссияләргә күрсәтергә, шуннан соң халык алдында чыгыш ясарга тиеш булалар. Татарстаннан килгән концерт бригадасына композитор Салих Сәйдәшев, танылган җырчылар Гөлсем Сөләйманова белән Газиз Әлмөхәммәтев һәм төрле халык көйләрен бер дәрәҗәдә оста башкаручы Фәйзулла Туишев керәләр.

1940 елның мартында классик әдибебез Шәриф Камалның иҗат итә башлавының 30 еллык бәйрәме Мәскәүдә билгеләп үтелә. СССР Язучыларының Үзәк мәдәният сараенда уздырылган ул кичәгә Казаннан әдипнең иҗатташлары Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Гази Кашшаф һәм күренекле артистлар баралар. Алар арасында Ш. Камалның якын дусты, яшьтәше Фәйзулла Туишев та була. Мәскәүдә яшәүче мәгълүм язучылар һәм СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев та ул кичәдә катнаша. Әдәбият белгече, шул тантана кичендә Ш. Камал иҗатына багышлап нотык сөйләүче Гази Кашшаф соңрак язган мәкаләсендә мәшһүр гармунчы Ф. Туишевның Мәскәүлеләр тарафыннан аеруча җылы каршы алынганлыгын бәян итә. Кичәнең рәсми өлешеннән соң да артистны кабат-кабат уйнарга чакыралар. Шул кичәдә ул татар һәм рус көйләрен, кайбер композиторларның әсәрләрен баянда һәм башка төрле гармуннарда виртоузларча оста башкаруы белән дан казана. Шул хакта Гази ага Кашшаф: «Бу кечтә виртоуз гармунчы үз стихиясенде иде», – дип яза.

Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов мәшһүр гармунчы белән бергә байтак кына концертларда катнаша. «Озак еллар чит җирләрдә йөргәч, ниһаять, сөекле, дәртле, моңлы Казанга кайтты. Татар Дәүләт академия театрында Фәйзулла аганың Казанда беренче концерты булды. (Бу очракта сүз, әлбәттә, Совет хакимияте чорына караган беренче концерт турында бара.) Миңа бу концертта Туишевны тамашачылар белән таныштыру һәм кичәне алып баручы вазифасын үтәргә туры килде. «Хәзер, хөрмәтле тамашачылар, сезнең алдыгызда Фәйзулла ага Туишев» дип белдерүгә, залдагы алкышларны язып та, сөйләп тә аңлатуы кыен. Тамаша залы гөр килде, – дип яза артист, оста гармунчы белән беренче очрашу кичәсен искә алып. Һәм болай дип дәвам итә: Шул заманда ул иң зур баяннан алып, шырпы тартмасы кадәр генә гармуннарда уйнаучы бердәнбер артист иде. Беренче бүлектә ул татар егете кыяфәтендә ыспай итеп киенгән. Чиккән кәләпүш, камзул, читектән – матур сынлы, соклангыч булып күз алдына килеп баса. Бу бүлектә фәкать татар көйләрен башкарды. Ә икенче бүлектә русча киенеп, рус халык көйләрен уйнады.

Гармунда уйнау белән генә чикләнмичә, бик оста итеп биеп тә җибәрә иде. Минем аңа кадәр һәм аннан соң да Фәйзулла абзый кебек виртоуз башкаручыны очратканым булмады».

Хәким Сәлимҗановка соңрак та берничә мәртәбә Фәйзулла ага белән бергә концертларда катнашырга туры килә. Ә Мәскәүдә 1941 елда узарга тиешле Татар әдәбияты һәм сәнгатенә әзерлек көннәрендә ул башкаладан килгән кабул итү комиссиясе вәкилләре белән аралаша. «Мәскәү комиссиясе алдындагы смотрда Фәйзулла ага да катнашты. Башкала вәкилләре аның иҗатына иң югары бәяне бирделәр. Мондый оста башкаручы безнең рус дөньясында да сирәк дигән фикергә килделәр», – дип искә ала Хәким ага. Сугыш башлану сәбәпле, ул декада булмыйча кала. Шул сәнгать бәйрәмендә катнашырга дип сайлап куелган артистлар, аерым бригадаларга билгеләнеп, яу кырындагы сугышчыларны рухландырып, концерт куеп йөрергә мәҗбүр булалар. 60 яшенә җитеп килүче Ф. Туишев та шундый төркемнәрнең берсен җитәкли. Аның «фронт бригадасы»на Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая да керә. Останың көмеш чыңлы гармун телләрен тибрәтеп уйнавы сугышчыларның күңелләрен җилкендереп җибәргәндер. Туган-үскән якларыннан сәлам буларак кабул ителгәндер. Сәхнә ветеранының ике зур чемоданга тутырылган төрле зурлыктагы гармуннарын күтәреп Бөек Ватан сугышы фронтларына барып чыгуы, туп гөрселдәүләре тынып торган минутларда сугышчылар өчен ялкынланып уйнавы бик күп ветераннар хәтерендә сакланып калган.

Әйе, кайларда гына уйнамасын – фронт шартларындамы яисә кечерәк бер авылның кечкенә генә клубындамы, аны һәрчак үз итеп, якын күреп кабул иткәннәр, уйнавын бирелеп тыңлаганнар. Үзен яратып калганнар. Аның моңлы да, дәртле дә итеп төрле зурлыктагы, төрле тавышлы гармуннарда оста уйнавы кешеләрнең күңелләрен юаткан, тормышның гүзәллекләрен тоярга ярдәм иткән, сагышларын тараткан.

Кайларда, ничегрәк башланган соң олы дан-шөһрәт казанган бу артистның тормыш юлы? Кем аны шулай тәрбияләп үстергән? Кайсы төбәк җир-суының баласы ул? Истәлек-язмаларда бу сорауларга әлегә төрлечә җавап бирелә. Аңа багышлап 1939 елда «Гармунчы» повестен язган күренекле әдип Фатих Хөсни артистны Мәләкәс шәһәрендә туып үскән дип бәян итә. Соңрак дөнья күргән кайбер башка язмаларда да, «Гармунчы» авторына ияреп булса кирәк, Ф. Туишевның туган җире итеп шушы шәһәр күрсәтелгән. Ә бит Ф. Хөсни повестеның беренче бүлегендә үк, бу әсәр артистның тулы биографиясен чагылдырмый, дип кисәтә. Татарстан китап нәшриятында 1980 елда басылып чыккан күләмле «Народные артисты» китабында да «Родился в посёлке Мелекес ныне Ульяновской области» дигән сүзләр язылган. Һәм иҗади-биографик белешмә урынына әлеге повестьтан кыскача өзек китерелгән. (Ул китапта башка төгәлсезлекләр дә байтак.

Мәсәлән, танылган җырчыбыз Рәшит Ваһаповны да анда биш елга иртәрәк гүр иясе итеп күрсәткәннәр.)

Дөрес, кайбер очракларда артисит үзе дә, мөгаен, оста гармунчы булып китүенә бәйле рәвештә, яшүсмер чоры Мәләкәсен ешрак телгә ала торган булгандыр. Әйе шул, Зур Чирмешән елгасы буендагы нәкъ шушы шәһәрдә ул беренче булып кулына гармун ала. Музыкант буларак шушында «туа». Икенче бер мәшһүр якташыбыз, рус әдәбияты классигы Максим Горький да бит әнә, Түбән Новгородта дөньяга килүенә карамастан, «шәхес буларак мин Казан шәһәрендә тудым» дип яза.

## Ямьледер Чирмешән буйлары

Фәйзулла Туишевның беренче мәртәбә аяк баскан җире шул ук Зур Чирмешән елгасы янәшәсендәге Иске Төгәлбуга авылы була. Ул Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәреннән кырык чакрым чамасы үрдәрәк урнашкан. Артист туган вакытта авыл Самара губернасының Самара өязенә караган. (Югыйсә Ф. Туишевны «Сембер губернасында туган» дип хата язу очраклары да еш кабатлана.) Утызынчы елларда Иске Төгәлбуга, Урта һәм Иске Исәнтимер, Өчкаен, Әбдери, Алга, Төплистан, Зирекле Куак, Иске Җүрәй кебек бер төбәктә урнашкан татар авыллары Куйбышев өлкәсе карамагында булды. 1943 елдан алар Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районына керәләр (Төплистан белән Иске Җүрәйдән кала). Иске Төгәлбугада туган кеше буларак, миңа артистның балачак биографиясе бик тә таныш. 1939 елның март урталарында гармунчы туган авылында зур концерт куйды. Мин дә анда тамашачы булдым. Җиденче яшьтә чагымда. Ул вакыйганың кайсы көндә барганын төгәл хәтерләмим. Шунысы хәтеремдә: клуб диварларына ерактан күңелне җәлеп итеп торучы зур плакатлар эленгән. Анда чәчәкләр арасыннан шат елмаешып торучы хатын-кыз рәсемнәре һәм буйдан-буйга сузылган сигезле саны бар иде. Иске Төгәлбугада ике көн барган ул концерт, димәк, март аенда булган. Аңа күрше-тирә авыллардан да бик күп кеше килгән иде. Урта Исәнтимердә эшләгән әтием һәм аның юлдашлары да ул кичтә, берничә олауда килеп, Иске Төгәлбуга клубында Фәйзулла аганың уенын бирелеп тыңладылар.

1958 елда 74 яшендә Казанда вафат булган авылдашым Фәйзулла Туишевны башка вакытта күрмәсәм дә, аңа багышлы истәлекләрне балачактан ук ишетеп үсәргә насыйп булды. Алтмышынчы-җитмешенче елларда исә олуг артист белән бергә уйнап үскән яисә соңрак якыннан аралашкан кешеләрдән язып алган каралама язмаларым да бар. Ул елларда әле Иске Төгәлбуга авылында «Курай урамы Фәйзүге»нең балачагын яки туган-үскән төбәгенә «концерт куярга» кайтып йөргән заманнарны хәтерләүчеләр байтак иде. Сугышка кадәр мәшһүр артист туган

якларына еш кайта. Ул елларда авылда әле аның якын туганнары да исән була. Олуг артистның бер кайтуында булачак тарихчы Җәмил Гыйльманов аңа пионер галстугы да тагып җибәрә. Ул вакыйга клубта булганмы яисә мәктәп балалары белән очрашудан соңмы — ачыкламаганмын.

Чирмешән буйлары ямьле,
Ял итәргә килегез;
Эштә уңган егетләрне
Безгә килеп күрегез, —

дип җырлана халык җырында. Иске Төгәлбуга авылы да бик ямьле җирдә, Чирмешәнгә коючы елгачык буенда урнашкан. Ул елгачык бездән унике чакрымдагы Иске Җүрәй янәшәсендәге үрдә башлана да, күрше чуваш авылы аша үтеп, Иске Төгәлбуганың кыйбла башына килеп керә. Елгачык, авыл башы урамы буйлап бераз баргач, авыл эченә таба борылып ага башлый. Авылның төньяк очыннан Чирмешәнгә бер чакрым чамасы ара. Ул урында елга, дугаланып, бездән берникадәр ераклаша төшә. Елга белән ике арада күлле-баткаклы Чалу болыны, урман алды агачлыгы һәм урман колаксасы рәвешендә куерып үскән шомыртлык бар. Ә Чирмешәннән соң инде киңлеге егерме-утыз чакрымлы «Зур карурман» башланып китә. Ә озынлыкка ул урман очсыз-кырыйсыз, Зур һәм Кече Чирмешәннең буеннан-буена килеп, Биләр тарафына таба сузыла. Әбиемнең Татарстан чигендәге туган авылы Пәраугa балачакта шул тоташ нарат урманы аша атта да, җәяү дә барганым хәтердә калган.

Үз төбәгендә Иске Төгәлбуга зур тарихлы авыл санала. Ул Казаннан элекке Нугай иленә һәм Самара каласына илтүче олы юл өстендә оешкан. Кайчандыр шунда булып киткән бер галим-сәяхәтче аның борынгы тарихлы авыл икәнлеген язып калдырган. Авылның исем-атамасында да борынгы кыпчак-мишәр чалымы чамалана. Ил, ыру башы булырдай ирләрне, нәсел үгезенә тиңләп, төрле сыйфатлы буга, шул исәптән төгәл буга (нәкъ үгез) дип атауларына тарихта мисаллар күп. Әйтик, Урта гасырлар кыпчакларына нисбәтле «Кодекс куманикус» китабында да Төгәлбуга исемен йөртүче зат булуы теркәлгән. Димәк, бу авыл да кайчандыр Төгәлбуга исемле бер шәхес тарафыннан нигезләнгән була. Дөрес, хәзер яшьрәк буын вәкилләре, исем әйтелешен беркадәр җиңеләйтеп, авылны Төгәлбай дип тә атыйлар. Ләкин аның чын тарихи һәм рәсми исеме Төгәл+Буга. 1917 еллардан соңгы үзгәрешләргә кадәр анда 715 йорт исәпләнгән. Борынгырак заманда ул урман куеныдарак, хәзерге шомыртлык артында, Зур Чирмешән ярында урнашкан була. 400 еллар чамасы элек халкы, качкыннар бимазалавыннан котылыр өчен, көньяккарак күченә.

Авыл төньяктан кыйблага таба сузылган өч чакрымлы дүрт һәм берничә кыска урамнан тора. Аның як-якларында икешәр

зират, Иске һәм Яңавыл дип йөртелгән оч-очлар аралыгындагы бушлыкта бишенче, иске зур зират бар. Зур һәм Курай урамнары арасыннан агучы елгачык, урталыктагы биек буага җитәрәк, Зур күл хасил итә. Шул күл янәшәсендә унлап йортлы Күл почмагы бар. Шунда элек бәләкәй Фәйзүк бер-ике кыш укыган Күл буе мәдрәсәсе булган. Без үскәндә ул мәдрәсә биналарында фельдшер бүлмәсе, китапханә ише җәмәгатьчелеккә хезмәт күрсәтүче оешмалар эшләде. Авыл советы, колхоз идарәсе йортлары һәм ике кибет тә шул тирәгә сыешкан иде. Зур урам белән Күл почмагы чатындагы Олы мәчет клубка әверелдерелде. 1939 елда, Фәйзулла Туишев концерт куйганда, ул клуб әле мәчет рәвешен саклый, фәкать манарасы гына юк иде. Ә Курай урамы мәчете манарасы, бала-чага өстенә ишелеп төшмәсен дип, җитмешенче елларда гына сүтелә.

Сугыш алды елларында Курай урамы мәчетенең буш бинасы шул оч балаларының олылардан качыбрак уйнау өенә әверелгән иде. Ябык тәрәзә капкачлары ярыгыннан сузылган яктылык сөңгеләре сихри дөнья тудыра. Шул нурлы сөңгеләр аша сикерә-сикерә, малайлар иркен идән буйлап чабышып йөриләр, качыш уеннары уйныйлар. Куышып арыгач, текә баскыч буйлап манарага менеп китәләр. Өркетә-өркетә андагы күгәрченнәрне очыралар. Яки, Чапай батыр рәвешенә килеп, манара тәрәзәләреннән тирә-якны күзәтергә керешәләр иде. Иске Түгәлбуга бик тигез җирдә урнашкан. Якындагы дүрт-биш күрше авыл манзарасын шул мәчет манарасыннан күзәтеп торырлык. Зуррак малайлар аннан алтмыш чакрымнардагы Нурлат элеваторы да елкылдап күренә дип мактаналар иде. Ләкин аны күрү өчен бик иртә, кояш чыкканда ук торасы шул. Ә менә җилсез, тымызык көннәрдә мәчет манарасыннан ерак офык читеннән үтеп китүче поездларның куекара төтене бөркелүен шәйләп була иде. Курай урамына, классташым Өмид янына барганда малайларның ул уеннарында үземнең дә катнашкан чакларым хәтердә.

Балачакта Фәйзүк абыйларга мәчет тирәсендә уйнау, манарага менеп, паровоз төтене бөркелүләрен күзәтеп тору тыелган була, билгеле. Хәер, ул вакытларда әле Сембер белән Бөгелмә арасында поездлар да йөрмәгән. Хәтта әле «чуен юлы»ның да салынмаган чагы. Ул чор малайларының бирелеп уйнаган урыннары урам чирәмендә һәм су буйларында булган. Тавык-кошны өркетә-өркетә куе әрекмән арасында бер-береңнән качкан булып йөрү дисеңме, хәтфәдәй җәелеп үскән чирәмдә мәтәлчек атынгалап, тәгәрәшеп алулармы — берсе дә ялыктыра торган уеннар түгел. Урамда уйнап ялыксаң, кармак сабын күтәреп, су буена төшәсең. Кемнәрдер шунда су коена, кемнәрдер, бераз читкәрәк барып утырып, кармак сала. Зуррак малайлар исә күлдә балык начар чиртә дигән сылтау белән күңелне ымсындырып торган урман ягына карангалый башлый. Ике-өч малай бер фикергә килсә, ашкын сулы Чирмешәнгә таба китеп бара.

Анда чыннан да балык эре дә, еш чиртә дә. Кармакны салып, йөзеп баручы калкавычны күздән кичереп өлгермисең, ул бата да башлый. Бик уңган, җимне дөрес сайлый белгән оста балыкчылар кайвакыт берәр аршын буйлы җәен балыгын да каптырып ала. Әйе, андый бәхет һәркемгә дә эләкми. Җәеннең кайсы чоңгыл төпкелендә үз корбанын, үз ризыгын көтеп ятуын белү бик читен.

Фәйзүкнең дә керсез, ваемсыз-гамьсез балачагы баштарак менә шулай узгандыр. Яңа әшнәсе Мөхәммәтша һәм агалы-энеле Биказаковлар белән бергәләп гамьсез генә йөргән чаклары еш булган. Олыларның вак-төяк йомышын үтәүдән бушаган арада, әлбәттә. Олы мәчет янәшәсендә, Зур урамда яшәүче Мөхәммәтша белән Фәйзүк мәдрәсәдә укый башлагач дуслашалар. Шул Кәримов инде бервакыт, арада иң кечкенәләре булган Фәтхи Биказаковны үртәп: «Куян колак Биказак», – дип әйтә дә, шул әйтем Фәтхинең икенче гомерлек кушаматына әверелә. (Фәтхи картның колагы чынлап та чак кына тырпаеп тора иде шул.) Артист буларак таныла башлаган бер вакытта, егерме ике яшендә солдатка каралырга авылга кайткач та Фәйзулла башлыча шушы дуслары белән никрут җырлары җырлашып йөри. Авылдан егерме биш чакрымдагы Зирекле Куакка каралырга барганда аларга җырчы Гүләй Шәфигулласы да кушыла. Соңрак туган якларга кайтканда да гармунчы Мөбарәкша дусты белән күрешмичә китми торган була. Бервакыт алар яшьлек еллары истәлеге итеп бергә фотога да төшәләр. Балачактан аларның серләре килешкән, уй-гамәлләре уртак булгандыр, күрәсең.

Фәйзулла ага туган елларда авыл халкы дүрт мәхәлләгә бүленә. Мәхәлләләрне Кизләү, Мәләкәс мәдрәсәләрендә белем алган муллалар җитәкли. Авылның мәчет имамнарын Иске Җүрәйдәге төбәк ахуны белән Пәраудa яшәүче ишан хәзрәтләре билгеләп куя торган була. Яшел мәчет белән Курай урамы мәчетенең соңгы имамнары да ишан хәзрәтләре нәселеннән чыккан Пәрау авылы кешеләре булган. Иске Төгәлбуганың ике зур мәчете карамагында мәдрәсәләр эшли, Яңавыл очында мәктәп була. (Ул 1934 елда, яңа зур мәктәпне төзегәч ябыла. Бинасында кече кибет – «лавка» ачыла.) Мәдрәсәләрдә кичләрен кычкырып китап уку, аларны күчереп язу үзенә күрә бер мәртәбәле, изге эш саналган. Иске Төгәлбугада борынгы китапларны күчереп язу белән мавыгучылар булганлыгын олы әдибебез Нәкый ага Исәнбәт тә бер әңгәмә вакытында раслаган иде. Утызынчы елларда ул, Татарстан биләмәсеннән көньяктарак калган авылларда булып, кешеләр кулында сакланган кулъязмаларны барлап һәм халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплап йөргән. «Сезнең Төгәлбугада да булдым. Ул авылның изге җаннары Гаделша, Гобәйдуллалар күчереп язып, тамга салган кулъязмаларны соңыннан архивларда да очратканым булды», – дип әйткән иде ул.

## Курай урамы Фәйзүгә

Авылның бу урамы башкалардан соңрак барлыкка килгән. Урам исеменнән үк чамаланганча, элгәре анда эре кура-сабаклы үләннәр котырып үсә торган урын була. Зур урам артындагы елга-күлгә янәшәдән генә агып төшүче инеш буе үзәнендә хәзер дә әле әрекмән, елан көпшәсе («елан курае») ише озын куралы үләннәр өер-өер булып утыралар.

Фәйзулла Кәбир улы Туишевның туган йорты Курай урамы мәчетеннән ерак түгел. 1972 елда чордашы Фәтхи ага Бикказаков белән ул урынны карап йөргән идек. Җиргә сеңеп баручы бер иске өй янына җиткәч, ул:

— Кәбир абзыйның төп йортта калган Хөснетдин энесе яңартып төзегән ызба шушы була, — дип төртеп күрсәтте.

Хөснетдин Туктаров Беренче герман сугышында, аның уллары Сәхаб белән Шәмси — Бөек Ватан сугышында башларын салып, чит-ят җирдә ятып калган мәхруклар. Әйе, артистның авылдагы нәсел-нәсәбе Туктаров фамилиясен йөрткән. Дөрес, монда андый фамилияле ике нәсел булган. Зуррак тармаклы икенче нәсел башында Шәкүр байның бертуганы Туктар карт торган. Ул нәсел варислары бүген дә авылда һәм авылга якын тирәлектә ишле санала. Курай урамы Туктаровларыннан исә хәзер күрше чуваш авылына бәйле тармактан башка кеше юк. Хәзерге Яңа Чирмешән шәһәрчегендә Кәбир абзыйның кече сеңлесе варислары бар, ди озатып йөрүчем.

Димәк, каршыбызда торган өй чыннан да бик иске инде. Хөснетдин дә аны яңадан төземәгән, фәкать бераз яңарткан гына була. Фәйзүк туган өй элек урам башыннан икенче йорт саналган. Хәзер аларга тагын берничә йорт өстәлгән. Ә шулар артыннан авылны зур дөнья белән бәйләүче үзәк күтәртмә юл үтә. (Сиксәненче елларда ул юлга асфальт та җәелде. Авылдан дүртбиш чакрымдагы Яңа Чирмешән шәһәрчегенә Самара, Ульяннан килүче зур автобуслар шуннан үткәләп тора.)

Фәйзүкләрнең бәрәңге бакчалары авыл аша аккан елга буена төшкән. Курай урамы очына җитәрәк, ул елга капылт кына төньякка таба борыла да Зур Чирмешәнгә таба ага башлый. Яз айларында, Чирмешәнгә кушылыр алдыннан болын буйлап җәелеп, эреле-ваклы күлләр хасил итә. Җәй урталарына ул күлләрдә маймыч балыклар үрчеп чыга. Ташу китүгә, авыл уртасындагы буа яңадан буыла. Күл суы әкренләп Фәйзүкләрнең бакча башындагы борылышка кадәр күтәрелә, җәелә. Элек ул күлдә бала-чага балык тота, ир-егетләр ат коендыра, хатын-кыз басмаларга басып кер чайкый, ул керне бәләкләп куя торган иде. Илленче еллар ахырларына чаклы совет чоры авыл тормышы да шул рәвешле барды. Күл буендагы алачыкта чаң-чоң китереп тимер сугалар, иртә-кичен ике яр тарафыннан су чыпырдаган, сырлы бәләк белән кергә йомшак кына суккан авазлар ишетелеп куя.

Кыр эшеннән кайткан ир-егетләр, атларын пошкырта-пошкырта, суга кереп китәләр. Көндезләрен күл өстендә бала-чага чыр-чу килә. Курай урамы тарафындагы текә яр тирәсендә яр буе керәшәләре чыр-чулап баш очында бөтерелешәләр. Кызгылт-кара балчыкка тирән итеп уеп тишелгән түм-түгәрәк ояларында ул кошларның балалары ишетелер-ишетелмәс кенә чикылдаша. Тәвәккәлрәк малайларның йомры учлары ул ояларга үрелә башласа, керәшәләр, бер өер булып, андый батырның өстенә ябырыла. Баш очында җан өркеткеч чинау-черелдәү авазлары күтәрелә иде.

Фәйзулла агалар заманында да ул шулайрак булган. Ат та коендырганнар, бала-чага чыр-чу килеп күл өстендә йөзеп уйнарга да яраткан. Авыл гадәтенчә, Фәйзүкнең апа-сеңелләре дә, мөгаен, иртән дә, кичен дә күбрәк шул төнбоеклы күл буенда, зур-зур өянкеләр тирәсендә кайнашканнардыр. Тирәкләрдә кош сайраган, яр буйларында хатын-кызның сабыр гына моңлану, җырлау авазлары ишетелеп торгандыр. Тар басмага басып, алар юынып та алган, керләрен дә чайкаганнар. Утаудан яисә урактан кайткач, чабата белән тула оекны салып, аякны суга тыгып утыру да җанга-тәнгә рәхәт биргәндер.

Дөрес, Фәйзүкләр бакчасы башында су тирәнлеге, бәлкем, ат коендырырлык ук булмагандыр. Анда елга беркадәр саега һәм тарая төшә. Шул ук вакытта анда бала-чага рәхәтләнеп коенырлык иң шәп урын да иде. Чөнки язгы ташкын борылышның Курай урамы тарафына күп иттереп аксыл-сары ком китереп өя. Ул урынга Зур урам очы малайлары да бик теләп йөриләр иде. Ә борылыштан чак кына өстәрәк, Зур урам белән Аркылы урам башлары кушылган җирдә, күлгә саф, салкын сулы Сыза кизләве килеп кушыла. Сыза чокырында элек чишмәләр ишле була, авылның яшь киленчәкләре элек анда чәй суына йөриләр иде. Яшьрәк чакта артистның әнисе Гөлҗамал да, апа-сеңелләре дә якындагырак чишмәләрнең берсенә суга бара торган булганнардыр. Иске авыл очы бала-чагасы, хатын-кызлары ул заманда Сыза буендагы кече урманчыкка җиләк җыярга да йөргән. Авыл очында яшәгән Мокыч токымы да алардан калышмагандыр. Әйе, Фәйзүкнең бабасының халык телендәге исем-кушаматы – Мокыч. Алар – Мокычныкылар. «Мулла кушкан исеме Сафиулла иде бугай», – ди Фәтхи ага.

Без үскәндә инде Сыза буе урманчыгы беткән, тирән яр төбендә сабыр-салмак кына агып ятучы кизләү суын чыпчык атлап чыгарлык иде. Халык телендә Шалкан куагы дип йөртелгән урманчыкның булганлыгын раслап, авылның кырый урамнарындагы бәрәңге бакчалары ызаннарында анда-санда озын, төз нарат агачлары гына күренер иде. Төптән юан, озын, әмма ябалдашы бала башына кигән кәпәч кебек кечерәеп калган шундый бер карт агач Фәйзулла агаларның элекке ишегалды кырыенда да үсеп утыра иде әле.

Кечкенә Фәйзүкне дә, дан-шөһрәт казанган артистны да авылда иң яхшы белүче, ул чор вакыйгаларын яхшы хәтерләүче кеше – Фәтхи ага Биказаков. Курай урамы Туктаровларының элекке күршесе.

Иң әүвәл аның үзе белән танышып үтик. Ул Фәйзулла агадан ике-өч яшькә кечерәк. Шулай булса да, аның белән бик якыннан аралашкан кешеләрнең берсе. Чөнки аның абыйсы булачак гармунчы белән яшьтәш тә, сабакташ та була. Фәйзүк некрутлыкка каралырга кайткан көннәрдә дә бу ике яшьти бер-берсеннән аерылмый. Яшьтән чая, үткен булган Фәтхи энекәш тә һәрчак аларга иярергә тырыша торган була.

Фәтхи ага – какча гәүдәле, уртачадан кечерәк буйлы, җитез хәрәкәтле кеше. «Хәрәкәттә бәрәкәт» дип, олылар тикмәгә әйтмәгәндер. Берәр вакыйга турында сөйли башласа, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, «шулай булды бит», «әйе бит» дип, үз сүзләрен раслатып торырга ярата. Аның яшьтән үткен, чая, һәм, үзе әйтмешли, чаманы белеп кенә усал да булганлыгын дәлилләүче мисаллар җитәрлек. Гражданнар сугышы чорында аңа атка атланып, кылыч айкап ярты илне гизеп чыгарга туры килә. Мәләкәс татар атлы эскадронында кече командир да, агитатор да була. Шул сугышта уң кулын гарипләтеп кайта. Колхозларга берләшү елларында берничә артельне оештыруда катнаша. Күрше Әбдери авылында колхоз рәисе булып та эшли. Кылыч яртылай өзгән уң кул чугы белән мылтыктан ата алмасын белгән хәлдә, 1941 елның көзендә үзе теләп сугышка китә. Илле яшьтә. Мәскәү тирәсендәге сугыш мәхшәрен, әсирлек газабын узаманнарча көрәшеп кичерә. Без аралашкан 1970 еллар башында да әле ул, сиксәннән өстен яшьтә булуына карамастан, егетләрчә җиңеллек белән колхозның ревизия комиссиясе рәисе вазифасын үтәп йөри иде.

Әмма аңа иң зур дан китергән вакыйга 1920 елда Татарстан мохтариятен оештыру көннәренә бәйле. Булачак автономия чикләренә Иске Төгәлбуганың һәм аңа якын булган дистәләгән татар авылының кертелмәгәнлеге ачыклана. Яңарак кына иркле, бәхетле тормыш өчен дип төрле тарафларда сугышып, кан коеп кайткан узаман ир-егетләр мондый хәл белән килешергә теләмиләр. Берничә авыл халкы берләшеп, күкрәкләренә беренче Совет орденын тагып кайткан иң батыр ир-атларны Самарага озаталар. «Безнең авылларны да Татарстан биләмәсенә кертүгә ирешегез», – дип, наказ бирәләр. Ләкин халык теләге үтәлми. Губерна комиссарлары: «Декретка кул куелган, хәзер соң инде», – дип акланалар. Ә җирле волость ревкомы рәисе Вечкомов «Ходатайларны кулга алырга!» дигән боерык бирә. Авылларда гауга чыга. Иске Төгәлбуга бунт үзәгенә әверелә. Атка атланып, кулына чалгы алган Фәтхи Биказак аның әйдәүчесе булып таныла. «Совет өчен сугышып йөргән батырларны кулга алырга әмер бирүчене тоткарларга» – дигән халык таләбен үтәп, җирле комиссарны авыл келәтенә китереп ябып куя. Халык белән

аңлашырга дип Самарадан мөселман комиссары килгәнче, теге рәис шунда биш тәүлек утыра. Менә шундый тәвәккәл, чая, тапкыр кеше була яшь Фәтхи Биказаков. Әйткән сүзендә торучан, туры сүзле булганы өчен дә авыл халкы аны үз итә иде. Район күләмендә дә абруе зур булды.

— Фәйзүк абыйлар белән безнең ызбалар янәшә иде бит, беләсең инде, — дип сүз башлады ул беренче очрашу вакытында. — Минем абый белән яшьтәшләр алар. Ярты көнне аларда уйнасалар, тагын ярты көнне бездә үткәрерләр иде.

Курай урамы — кырый урам. Анда авылга яңарак килеп төпләнүчеләр дә ишле булган. Фәтхи ага әйтүенчә, Мокыч баба нәселе дә, Биказаковлар гаиләсе дә кайсыдыр күрше авылдан элегрәк елларда Иске Төгәлбугага күчеп килүчеләр була. Бер оя бала үстергән Биказаковлар да, «бер ызбага сыешмаган Мокыч баба токымы» да ярлылар чутында йөргән.

— Фәйзүк үскәндә алар да бик ишле булды, — ди дә Фәтхи ага бармакларын бөгә башлый: — Мокыч баба карчыгы белән — раз, Кәбир абзый, хатыны, ике кызлары, Фәйзүк — ике булдымы, яңарак өйләнгән Хөснетдиннәре — өчме, Мокыч бабаның кияүгә китәргә өлгермәгән кече кызы — дүрт булдымы. Әһә, вәт, дүрт сандык кына бар бер ызбада. Ә тавыш-тын чыгармаганнар, сыешканнар бит. Никме? Йорт башының талканы коры булган, ни дисә — шуны эшләгәннәр, — дип сөйли әңгәмәдәшем. — Аннары бит ул заманда төп йорттан тиз генә аерылып чыгу да катлаулы иде. Авыл җыены урын бирсә генә ага-брат бүленеп чыга алды. Ә җыенда утыручы авыл картлары кайсы йортта ир заты күп, шуңа өстенлек бирә. Имана кишәрлеге ишлерәк булган кешеләрне иң элек йорт-җирле итәргә тырышалар. Чөнки алардан авылга файда күбрәк тия.

Җан башларын санарга керешәбез. Фәтхи ага исәпләвенчә, Мокыч баба йортында XIX йөзнең туксанынчы елларында унике җан иясе була. Шулардан, Фәйзүкне дә санап, имана җиренә ия булырдай дүрт «душ» — дүрт ир заты чыга. Бик аз, әлбәттә.

— Староста Кумык бабаның, пример, унбиш җанның яртысыннан күбрәге ир затыннан иде. Туктар бай ызбасындагы нисбәт тагын да югарырак. Алар баемый кем баесын. Кырны тутырып иген игәләр, башак ашатып мал симертәләр. Кыш булды исә ярминкәдән ярминкәгә йөриләр. Мәләкәскә илтеп ашлык, Юхмачы базарында көр мал-туарларын сатып акча туплыйлар. Янчыклары тулгач, ярлы-ябаганың эшкәртерлек рәте булмаган җирләренә кул суза башлыйлар. Вәт бит ул ничек…

Иске өйне караганда Фәйзулла абыйларның авылдагы тормышын күз алдына китермәкче булам. Урам якка — өч, ишегалдына ике тәрәзә уелган кечерәк бура өй, иркен генә такта чолан. Ул юкарак бүрәнәләрдән сипләнгән сыер абзары, ат араны белән тоташкан. Яз-көз һәм кыш көннәрендә хатын-кызга суыкка, кар-яңгырга чыгып йөрисе түгел. Ишегалды почмагында җәйге

чорда һәм көзге-язгы аяз көннәрдә мал ашата торган урын. Ул озын, юка колгалар белән киртәләп куелган. Ул киртә янәшәсендә – бәрәңге бакчасына, су буена илтә торган җил капка.

Курай урамында ничегрәк булгандыр, белмим. Әмма, картлар сөйләвенчә, Иске Төгәлбуганың үзәк өлешендә баштарак арт бакчада бәрәңге үстерү гадәте күзәтелмәгән. Колгалар белән киртәләп алынган ул иркен урында көтү-көтү сарык асраганнар. Хәзер дә ул бакчаларны тирәнрәк казыган саен, шакмак-шакмак булып укмашкан кәҗә, сарык тизәкләре чыга икән. Бабаларымның төп нигезе янәшәсендә гомер иткән кардәшем Галимҗан, бервакыт: «Мунча өчен дип ишегалдымда дүрт метр тирәнлектә кое казыдым, шуннан һаман мал тизәге чыга», – дип зарланган иде.

Шул ук үзәк урамда Туктар байның ике тыкрык арасын биләгән утар урыны бар иде элек. Хуҗалары куылгач, утызынчы-кырыгынчы елларда ул бушлыкта алабута да иркенләп үсеп китә алмады. Җиргә мал тизәге күп керсә дә үлән тамырына үсәргә ирек бирми икән.

Фәтхи ага һәм башка картлар сөйләвенчә, авыл җыены Кәбир Туктаров гаиләсенә төп йорттан аерылып чыгарга урын билгеләгән була. Курай урамы очындагы бушлыкта. Ләкин 1891 елгы зур ачлык башлану сәбәпле, Фәйзүкләр яңа бура корып, үзгәлеккә чыгарга өлгермичә калалар. Ә ике-өч елга сузылган ул хәтәр ачлык байтак кына кешеләрнең тормышын, яшәешен үзгәртеп ташлый. Ачтан, хәерчелектән үлүчеләр дә күп була. Мокыч карт нәселендә дә андый үкенечле үзгәрешләр булып ала. Шул елларда йорт башлыгының карчыгы, Кәбир абзыйның бер кызы вафат булалар.

## «Чукынган, чучка көтә...»

Әйе, мәшһүр артист биографиясендә андый этап та бар, дип искә ала авылдашлары. Һәм, мөгаен, артист өчен иң авыр кичерешле, һич тә искә аласы килмәгән, хәтер төпкелендә генә яшеренеп ятучы бер үкенечле хатирә булгандыр ул.

Алда әйтелгәнчә, ата-бабадан килгән тәртип буенча, Мокыч бабаның төп йортының варисы кече улы Хөснетдин булган. Хөснетдиннән соң ул өй аның кече улы Шәмсетдингә кала. Сугыштан соңгы елларда ул өйдә балигъ булмаган улы белән Шәмсинең хатыны яши. Хөснетдиннең җәмәгате Бәнат апа да соңгы сугыш барганда шул килене кулында күзен йома. Егерменче-утызынчы елларда Фәйзулла ага әлеге җиңгәсе йортына кайта торган була. Унбиш чакрымдагы тимер юл станциясеннән ул һәрчак затлы тарантаста кайта икән дә, зур юлдан Курай очына борылуга: «Бәнат тәчи, чәең куй!» – дип, көр аваз сала икән. Шул авазы аның тиз арада авылның аргы очына да ишетелеп, бар халыкка сөенеч өсти торган булган, имеш.

Рәсми биографиясендә теркәлгәнчә, Фәйзулла Туишев 1884 елның декабрендә дөньяга килгән. Ләкин кайбер авылдашлары аны бер елга алданрак туган дип исәплиләр. Чордашлары Мөхәммәтша белән Фәтхи агалар да шул фикерне раслый. Узган гасыр башында писарьларча пөхтә киенеп солдатка каралырга кайтканда да ул 1883 елда туган никрутлар белән бергә йөрде, бергә комиссия үтте, дип саныйлар.

Димәк, ачлык еллары башланганда Фәйзүккә җиде-сигез яшьләр була. Берәүләр раславынча, бу вакытта инде аның Хафиз белән Җаббар исемле энеләре дә туа. Кәбир абзый гаиләсендә Фәйзүк белән Хафиз арасында кыз бала да булуын исәпләгәндә, икенче уллары чама белән 1890—1891 еллар тирәсендә тугандыр, мөгаен. Ә кечесе алар авылдан күчеп киткәч дөньяга килгәндер. Ләкин ул балаларның язмышы тиздән туачак яңа гасырның икенче яртысында яшәгән авылдашларына мәгълүм түгел.

Җирсезлектән интеккән, җир-сулары күрше мукшы, чувашлар тарафыннан даими рәвештә дауланып кысрыклана барган Иске Төгәлбуга халкының ул ачлык елларын ничек үткәреп җибәрүен күзаллау да кыен. Әйе, көтүлек җирләре юк дәрәҗәсендә, сөрү җирләре кысан. Берәрсендә ир бала туган саен авыл халкына бирелгән ул кысан җирне дә өстәмә имана-өлешләргә тагын бүләргә кирәк була ич. Бик зур авыл, халкы һаман ишлеләнә, арта тора, ә имана җирләре өлешләре елдан-ел кими, кечерәя бара. Бу хәл исә еш кына авылдашлар арасында ызгыш-талашларга китерә. Күрше-күләннең яңа туган балага көнләшеп карау очраклары да еш була. Әйе, күлмәксез-ыштансыз ир баланың күршедә тупырдап уйнап йөрүен берәрсе күрсә, сөенәсе урында көенеп, «Бу ыштансызы да имана дәгъвалап йөгерә әнә» дип сукраныр заманнар булган. Авылда ир бала туу ул заманда һәркемне «минем җир кишәрлегем кими» дигән уй-борчуга салган.

Шул ук вакытта һәр туган ир бала ата-анасына зур сөенечюаныч китерә, киләчәккә өмет өсти, әлбәттә. Бер-бер артлы ике ул тугач, Кәбир белән Гөлҗамалның да сөенеч-куанычларының чиге булмагандыр. Янәсе, артык кашык кына тумый, өстәмә сөрү-чәчү җирен дәгъвалаучы да туа бит! Әмма ләкин аларның бу өмет-шатлыкларын күк иясе генә ни сәбәпледер күрмәгән, изге догаларын кабул итмәгән икән шул. Авыл, ил өстенә зур афәт җибәргән…

Хак, нәкъ шул заманда, шул елларда Иделнең урта төбәге авылларында коточкыч ачлык башланып китә. Иске Төгәлбуга кебек кысынкылыкта утырган зур авылларда аның афәте бигрәк тә сизелерлек була. Хәллерәк авылдашларына булышкалап көн күргән, тормыш-яшәешен көч-хәл белән очын-очка ялгап килгән ярлырак катлау ул афәттән тәмам гаҗиз калган чак була. Ике-өч елга сузылган корылык, шуның нәтиҗәсе булган ачлык чорында бөтенләй җирсез калучылар да аз булмый. Андыйлар, үз өлешиманаларын сатып ашап бетергәннән соң, чит-ят җирләргә китеп, шунда сыену эзли башлый. Кайсыбер сабырсызраклары, мохтаҗ-

лыкка чыдый алмыйча, иманасын гына түгел, иманын сату хәленә җитешә. Чукынып, күрше авылларда сыену эзли башлый. Иске Төгәлбуга тарихында да андый мисаллар бар. Ата-анасы вафат булгач, күрше чуваш авылына китеп, анда яшәп калган унҗиде яшьлек Әхсән язмышы шундый фаҗигаләрнең бер үрнәге. Хуҗасы кызына өйләнеп, үз диненнән ваз кичүчеләргә өстәп бирелә торган җир өлеше алып, Карга Куак авылында ул Аксёновлар нәселен нигезләде, дип сөйли авыл картлары.

Кәбир абзый гаиләсе дә ул ачлык елларын бик авыр кичерә. Гаилә ишле, җир аз. Шул аз җирне эшкәртү, чәчү дә катлаулыга әверелә. Чәчүлек җитми, арандагы ике ат та чак басып тора, өшәнгәннәр. Карчыгы үлгәннән соң кече кызы белән генә калган Мокыч баба беркөнне бәхет эзләп чуваш авылына күчеп яшәргә ният кыла. Күрше Иске Салаван авылына барып, көтүчелеккә яллана. Бераздан Кәбир абзый да үз гаиләсе белән аларга барып кушыла. Берсе анда сыер-сарык көтүен йөртсә, икенчесе өлешенә чучка көтүе кала. Кәбир абзый чучка көтмәсә дә, авылга кайткан араларда Фәйзүкне «чучка көтә» дип үртәр өчен сәбәп табыла. Шул рәвешле, Фәйзүккә тугыз-ун яшьләреннән рәхимсез мыскыллау сүзләрен ишетеп үсү дә насыйп була. Дөресе, ярлы, мохтаҗ йортта туган һәр авыл малаеның өлешенә нинди авырлык төшә торган булса, Фәйзүк тә андый кыенлыкларны үз башыннан кичерә. Юклык, мохтаҗлыклар белән янәшә үртәлү, кимсенү кичерешләре дә яши, алар котылгысыз. Шул ук вакытта балачакка гына хас булган барлык сөенеч вә юанычлар да Фәйзүкне читләтеп үтмәгән. Бердән, ул – ата-анасының өлкән, сөекле улы. Ике кыз туганы булу өстенә, тиздән бер-бер артлы ике энесенең тууы да аңа сөенеч, шатлык кына өстәгәндер. Ышанычлы дусларың булу да зур бәхет. Читкә киткәч тә онытмаган, үз иткән дуслары була аның. Кыш айларында мәдрәсәдә укуын дәвам иткәндә берәү дә аңардан читсенми.

Әмма Иске Салаванда булганда аңа үкенү, кимсенү хисләрен ешрак кичерергә туры килгән. Баштарак ул үз авылына, дуслары янына еш кайткан. Әмма кайткан саен, күңеле сүрелә барган. Чөнки Иске Төгәлбуга бала-чагасы, аны күрүгә: «Чәч үстереп килгән монда Фәйзүк атлы чукынган», – дип такмаклап үчекли торган була. Иске Салаван халкы да аларны үз итәргә, үз арасына кертергә ашыкмый, «килмешәк тутарлар» дип чагарга гына тора. Үз яшенә күрә эрерәк буй-сынлы булган, яшьләр уенына керәсе килгән Фәйзүкне дә, кыз туганнарын да чуваш егет-кызларының өнәп бетермәве үзен еш сиздергән.

Шулай, төрле яктан каргала-тиргәлә, алар бу авылда икеме-өчме җәй яшиләр. Кимсетү, кыерсытулардан тәмам гаҗиз булган Кәбир абзый гаиләсе, Мокыч бабаны җир куенына салу белән үк, бу авылдан китәргә була. Иске Салаванда атасы өлешенә тигән җирне, кирәкмәсрәк йорт-кура әйберләрен калдырып, ялгыз ат җигүле арбага төялеп, Мәләкәс каласына карап, алар

юлга чыгалар. Кәбир абзый инде анда кайларга борын төртәсен алдан ук чамалаган була. Чөнки көтүдән арынып торган араларда ул тик ятмаган, озын кыш айларында якындагы базар тирәсендә олаучы хезмәтен үтәп, байтак кына кеше белән танышкан, аралашкан була.

### Бәхет кошын очрату

Кайчандыр Иске Салаваннан аерылып чыккан, урман эченәрәк кереп, Чирмешән янәшәсенә үк сыенган Зур Салаван элек шау-шулы базары белән данлы иде. Кыш айларында Кәбир абзый әнә шул базар кешеләренә үз аты белән хезмәт итеп йөрүчеләрнең берсе булып китә. Дөрес инде, күпчелек очракта андыйларны үз кул көче белән эшләгән вак-төякне сатучы ялламый. Базарда кибет тотучы алыпсатар сәүдәгәрләр өчен кирәгрәк була олаучылар. Кәбир абзый да күбрәк вакытта шундый кешеләр белән эш йөртә.

Халык телендә ул сату-алу җирен «урыс атнасы базары» яки «Салаван базары» дип кенә йөртәләр иде. Ул дәвердә, бәлки, берәр җирдә саф мөселман базары – җомга көн эшләүче базар да булгандыр. «Урыс атнасы базары» таң беленү белән башлана да төштән соңгарак таралып бетә. Аңа якын-тирә авыл халкы гына түгел, егерме биш-утыз чакрымнардагы Әбдери, Лабит, Төплистан, Пәрау кешеләре дә гаилә-гаилә булып ат-арбаларга төялеп киләләр иде. Чөнки монда ашлык белән эре мал-туардан кала барлык кирәк-яракны да сатарга һәм сатып алырга була. Хатын-кыз биредә кемнәрдер бәйләгән әйберләрне, кемнәндер артып калган кием-салымны да, кулдан эшләнгән йөзек, беләзек ише бизәнү әйберен дә таба алган. Хак инде, авылча тормыш-көнкүреш өчен ни-нәрсә кирәксә, барысын да диярлек алып та, сатып та булган. Иләк, чиләк, гөбе, юкәдән үрелгән, агачтан юнып, чокып ясалган, кызыл яки сары балчыктан әмәлләп киптерелгән төрле-төрле савыт-саба – барысы белән дә сату итәләр монда. Бер почмактарак әнә, үзе ясаган кашык, кәнди, коштабакларын шакылдаткалап, агач әйберләр остасы утыра. Аның күршесендә тимер кыршаулы күәс-камыр тәпәннәрен, төрле зурлыктагы гөбе, кисмәк ишеләрне ясаучы кисмәкче басып тора. Аның «арзанга сатам» дигән сүзләрен тагын да көррәк аваз белән кабатлаучы җәптәше дә якында гына. Монысының алдында ялтыравык ак калай белән бизәлгән эреле-ваклы сандыклар өеме тора. Бала учы чамасындагы кечкенәдән алып, беләк буедай зур чабаталар бәйләмен ике иңенә аскан сакаллы һәм сакалсыз, картузлы вә түбәтәйле юкә «каешы» осталары да халык арасында туктаусыз йөренәләр. Аратирә алар да: «Хан кызлары киярдәй матур чабаталар... патша уллары киярдәйләр...» – дип, үз хезмәт үрнәкләрен мактыйлар. Әйе, монда берәүләр үз һөнәр җимешен күккә чөеп мактый-мактый сата. Хуҗалык кирәк-ярагын канәгатьләндерердәй әйбер-

не эзләп тапкан кеше ала. Ата-бабаларыбыз әйтмешли, монда инде кемнәрдер алдый, кемнәрдер алдана. Һәр сатучының үз бәясен югарырак күтәрәсе килә, алучы исә арзанрак хаклысын очратмаммы дип эзләнә. Базар мөнәсәбәтләре шуңа корылган. Кемдер үзе сатасы әйберне ипләп-җайлап кына чамасыз мактый белә икән, аның сыйфатсызрак әйбере дә үтемле булып чыгачак, тизрәк сатылып бетәчәк. Сату-алу эшендә шомарган кеше андый гына хәйләне белә, әлбәттә. Мыжлап торган халык арасында чын жуликлар да буталып йөри, билгеле. Аларның төп кәсебе – икәүөчәү берләшеп, затлырак әйбер чәлдерү. Яисә берәр ачык авызын төпсез кесәле итеп калдыру.

Карурман эченә кереп, мул сулы һәм балыкка бай Олы Чирмешән ягасына ук килеп утырган Зур Салаван халкы да урман һәм елга нигъмәтләре белән сату итәргә тәмам остарып беткән. Базарның бер кырыенда фәкать алар гына сәүдә итә торган икеөч озын киштә-ләүкәләр бар. Авылның уңганнары буйдан-буйга сузылган ул ләүкәләрне һәр якшәмбедә яңа тотылган балык, яңа өзелгән җиләк, бөрлегән, карлыган, шомырт кебек ризыклар белән тутырып куярлар иде. Киштәләргә аркылы сузып салынган аршын буе җәен, беләк буе симез чуртан һәм башка төр балыклар, бармак төртүеңә сискәндереп сикергәләп, яңарак тотылганлыкларын сиздерәләр. Шул ук ләүкәләр янәшәсендә суйган тавык, өем-өем йомырка, йомарлам май, кызыл эремчек, сөт-катык ише көндәлек кирәк- яракны сатып торучы төрле милләт хатын-кызлары да кайнаша. Алар арасында башына алсу-көрән яулык бәйләгән, чуар алъяпкыч япкан, чулпы таккан Иске Төгәлбуга, Иске вә Урта Исәнтимер, Иске Җүрәй кебек якынрак авыл киленнәрен дә очратып булган.

Әйе, заманында бик данлыклы була Зур Салаван авылы базары. Аңа Самара ягы авылларыннан да, хәзер Татарстанның көньяк чик буенда урнашканнарыннан да, Мәләкәс, Ставрополь (хәзерге Тольятти) кебек шәһәрчекләрдән килеп сәүдә итүчеләр дә күп булган. Очраклы хәлдерме, юктырмы, ул төбәктәге патша дәвере зур базарлары никтер урыс, мукшы, чуваш авылларында урнашканнар. Әйтик, безнең тирә-як кешеләре Салаван базарында булмаган эре мал-туар һәм арба-чана ише кирәк-яракны кырык-илле чакрымдагы икенче чуваш авылы Юхмачыдан кайтарганнар. Пәрау төбәге халкы исә Салаваннан тыш Кузнечиха тарафы базарына да йөргән.

Авыл картлары сөйләвенчә, Салаванда Мәләкәстән килеп сату итүче кешеләр дә була. Алар башлыча базарны каймалап алган ларёкларда эш йөрткәннәр. Кәбир абзый кебек олаучылар нәкъ шундыйларга хезмәт иткән. Киләсе базарда сатыласы товарны алар атна арасында ук ташып куя торган булганнар. Тумышы белән безнең тирәдәге авылларның берсеннән чыккан Алексей Фёдоров дигән кеше белән Фәйзүкнең атасы аеруча якынлашып китәләр. Ә ул Фёдоровның Мәләкәстә зур кунак йорты да бар

икән. Атлы-арбалы бер-ике дистә кунакны кабул итәрдәй «Постоялый двор» тоткан ул. Шул кеше Кәбир абзый гаиләсен үзенә сыендыра, эш бирә. Яңа урында аларның төп бурычы: ишегалдын тәртиптә тоту, мич-учакны утыннан өзмәү, кирәк-ярак товарны үз вакытында кирәкле җиргә илтеп кую, алып кайту була.

Монда күчкән вакытта Фәйзүккә унике-унөч яшь тирәләре булган. Балалыктан чыгып, яшүсмерләр дөньясына аяк басу еллары. Һәр шәхес язмышында үзенчәлекле бер дәвер: дөньяга, тирә-як мохиткә, чынбарлыкка караш көннән-көн үзгәрә, үсә барган бик тә кызыклы бер чор. Һәм нәкъ шундый үсеш, яңарыш дәверендә барлык өмет-хыялларың белән бөтенләй бер үзгә мохиткә – шәһәр мохитенә килеп кер әле син! Билгеле, Фәйзүкнең сөенеченә һич кенә дә тиңнәр булмагандыр ул көннәрдә. Аның сөенеч-куанычлары чиктән аша. Бәлки әле, хыялда гына булса да, киләчәк бәхетле язмышы да күз алдына килгәндер.

Мәләкәс каласы ул вакытта Самара губернасының өяз үзәге санала. Аңа хәзерге Татарстанның көньяк биләмәләре дә керә. XIX йөз ахырында Мәләкәс кырык көнлек ашлык ярминкәсе һәм өч зур тегермәне белән данлы санала. Агачтан һәм талчыбыктан өй җиһазы җитештерүче остаханәләр дә эшли. Машина куәте белән хәрәкәткә китерелүче өч тегермәннең берсе татар бае Әбдүш варисларыныкы була. Мулла кушкан исем Габдулладан Абдюшев фамилиясен тудырган бу нәсел шәһәрдә 1917 елгы үзгәрешләр башланганчы үз дәрәҗәсен саклый. Каланың татарлар яшәгән өлешендә мәчет, мәдрәсә эшли. Совет хакимияте вакытында мәдрәсә җирлегендә педтехникум ачыла. (Мәләкәс татар педучилищесы Хрущёв фәрманы чыккач ябылды.) Бу мәдрәсәдә узган гасыр башында күренекле тел галимебез Латыйф Җәләй дә белем алган. Шуннан соң ул берничә ел Иске Төгәлбуга янәшәсендәге Иске Җүрәйдә балалар укыта. 1919 еллар тирәсендә кабат Мәләкәскә кайтып, әлеге укытучылар әзерләүче уку йортын нигезләүдә катнаша. Бу калада ул елларда татарча газета да берничә ел чыгып ала…

Атналарга сузылган ярминкә көннәрендә постоялый дворларда ишек-капкалар һич тә ябылып тормый, билгеле. Кемнәрдер килә, урнаша. Кемдер, гаиләсен арбасына төяп, саубуллашып китеп бара. Үз яшенә караганда буйчанрак, калкурак күренгән Фәйзүк тә эшсез тормый. Ишегалдына чыгып атасына да булыша, кирәккәндә кунакларның йомышын үтәргә дә өлгерә. Йөгереп йөргән күндәм авыл малае, таш каланың ак күмәченә авыз тидереп тамак туйдыргач та дәртләнеп, кушкан йомышларны карусыз үти. Самавыр да куя, кунак бүлмәләренә аш-суын да, башка кирәк-яракны да ташып кына тора. Җитез, зирәк һәм күндәм бу кәләпүшле малайны, мөгаен, бик күпләр үз иткән, яраткандыр. Килеп урнашкан беренче кышында ук инде ул тирә-күршедәге малайлар белән дә, кунаклар белән дә дуслашып өлгерә, аралаша башлый.

Ә ул кунаклар арасында ярминкәне бизәп, җанландырып җибәрү өчен Россиянең төрле тарафыннан җыелган һәвәскәр сәхнә әһелләре һәм цирк артистлары да була. Халык күп җыелган җирдә кәмит күрсәтүчеләрсез буламы соң! Алар дөньяны ямьләндереп, күңелләргә рухи азык бирүчеләр ич. Ачлык афәтеннән арынып, тук тормышка йөз тоткан бер вакытта аларның кирәклеге бермә-бер арта. Һәркемнең күңеле кәмит катыш җырлы-биюле уеннарга, карусельләргә тартыла.

Фәйзүк тә бөтен күңеле белән шул карусель уенын оештыручыларга, кәмитчеләргә якынрак торырга тырыша. Алар да йомышчы малайны үз итеп өлгерәләр. Чаршау корулы балаганнарына чакырып алгалыйлар, ара-тирә күмәк уенга да катнаштырып җибәргәлиләр. Монда цирк белән эстрада уеннары бергә алмаш-тилмәшләп башкарыла торган була. Шунда ук җыр, бию, мәзәк сөйләү, акробатик күренешләр бер-бер артлы алышынып торалар. Өздереп гармунда уйнаучылар да шул ук балаган артистлары рәтендә йөри.

Фәйзүк баштарак, гади тамашачыга күренмичә, берничә яшүсмер белән бергә эчтән карусель чыгырын әйләндерү хезмәтен башкара. Өстә, мәйданчыкта, бәйрәмчә киенгән бала-чага чыр-чу килә, җил куып әйләнә, уйный. Фәйзүкләр, көч түгеп, аларга андый рәхәтне тудыралар. Узган җәйдә генә көтү көтеп көн үткәргән авыл баласының, шулай итеп, күк капусы көннән-көн ачыла бара. Тиздән аңа ачык сәхнәдә күренеп китәрдәй җиңелчәрәк рольләрне дә тапшыра башлыйлар. Шул рәвешле бер-ике сезон үтеп тә китә. Хәзер инде Фәйзүк кунакханәләрнең тар бүлмәләрендә атналап, айлап яшәүче, төрле һөнәргә ия булган балаган артистларының самавырчысы гына түгел, арага кереп китәрдәй һөнәрдәшләренә әйләнә бара. Ярминкә көннәрендәге бәйрәмчә уен карарга килүчеләр аны гадирәк акробатик номер башкаручы сыйфатында да, ярыйсы ук оста итеп, такмаклап русча һәм татарча биюче буларак та күрергә күнегәләр. Аның биографиясе белән таныш кешеләр: «Фәйзүкнең беренче артистлык амплуасы – баш очына самавырлы поднос куеп, русча бию була», – дип язалар.

Билгеле, артист халкы постоялый двор бүлмәләренә хәл җыярга кайткач та тик кенә ятмый. Берише биюнең яңа алымнарын үзләштерә, икенчеләре җырлый, мәзәк сөйли, уен коралларында уйнаучылар яңа көй өйрәнә яки элекке көен камилләштерергә тырыша. Шул исәптән гармунчылар да үз уеннарын камилләштерү белән шөгыльләнәләр. Биючегә дә, җырчыга да, фокус күрсәтүчегә дә гармунчының булышып, уен тембрын үзгәртә-үзгәртә уйнап торуы кирәк ләбаса. Ял вакытларында алар да бер-берсе белән тәңгәл килеп, бербөтен образ тудыру өстендә эшлиләр. Шул сәбәпле ярминкә көннәрендә постоялый дворда һәрчак гармун чыңлавы яки моңлы бер көй уйналуы тынып тормый диярлек. Хәер, гармунны фәкать өч пошудан шыңгырдатып утыру очраклары да булгалый.

Гармунчыларның уйнауларына кызыгып карап торган әлеге кәләпүшле малайга да ара-тирә шул гармун сәдәфләренә баскалап алгаларга рөхсәт иткәләүчеләр була, әлбәттә. Тора-бара бик теләп үз һөнәрләренә өйрәтергә теләүчеләре дә табыла. Бу тормышта бит башкаларга карата хәерхаһ, ярдәмгә килергә әзер торучылар да еш очрый. Шулай булмаса, кешелек дөньясы яши дә алмас иде.

Фәйзүк зирәк шәкерт булып чыга. Көй-моңнарны да, аларны күңелгә ятышлы итеп уйнау рәвешләрен дә тиз отып ала. Тиздән инде ул өйрәтүчеләренә ияреп, иш-җәптәш булып уйнардай дәрәҗәгә җитешә. Өстәвенә әле аның җирле халык күңелен җилкендереп татарча һәм чувашча көйли алу сәләте дә ачыла. «Но, Фәйзүк, сиңа балаганнан һич аерыласы түгел», – дип, аны балаган хуҗалары башка шәһәрләргә үзләре белән гастрольләргә китәргә димли башлыйлар.

Оста гармунчы даны әнә шулай бөреләнергә керешә. Иске Төгәлбуга авылының ярлы Мокыч баба ызбасында туып үскән яшүсмер Фәйзүкне, шулай итеп, Мәләкәс постоялый дворында үзләштерә башлаган һөнәр-кәсебе олы дөньяга алып кереп китә. Очраклы бер хәл – Кәбир абзыйның мохтаҗлыктан качып, шул заман кунакханәсенә эшкә килеп урнашуы – улының киләчәк бәхетле язмышының тәүге терәге, этәргече була. Шул очраклы вакыйга Фәйзүкне тиздән олы сәнгать дөньясына алып чыга. Икенче бер очраклылык – Россия күләмендә танылган виртоуз гармунчы Уткинның нәкъ шул елларда Мәләкәскә килеп чыгуыдыр. Соңыннан Фәйзулла ага Туишев гомере буена шул остага рәхмәтле булуын белдерәчәк. Әйе, юклык, ачлык нәтиҗәсендә тук тормыш эзләп Мәләкәс каласына килеп эләккән татар гаиләсе гомердә көтелмәгән бәхетле язмышка дучар була.

Хак инде, армый-талмый эшләргә, хезмәт итәргә гадәтләнгән авыл баласы, ташны ярып чыккан язгы үлән кебек, әнә шулай һаман да яктыга һәм яхшыга омтыла бара. Җае туры килеп куйса, зур ихтирамга һәм дәрәҗәгә дә ирешә. Ә инде җае чыкмаса… әрни-сыкрый, үз йөген тарта. Балалары бәхетле булсынга дип булса да тырыша.

Фәйзулла аганы язмыш туган авылыннан кумыйча, шул Иске Төгәлбугасында калдырган булса, ул кем булыр иде икән? Әтисе Кәбир абзый кебек бер олы җанлы гаилә башлыгы, имана җирен үз вакытында чәчеп-урып, төпле генә тормыш алып баручымы? Тырышлыгы, зирәклеге һәм яшьлегендә күргән-татыган мохтаҗлыклар аны авылдашлары арасында тырыш хуҗа буларак танытмый калмас иде, әлбәттә.

Атасының зирәк акылын, гайрәт-куәтен, эзләнүчәнлеген исәпкә алганда, Фәйзүк тә һичшиксез үз мохитендә танылганрак авыл кешесе – мәчет куштаны, җыен активисты ише, үз фикере белән абруй казанганрак кеше булыр иде, мөгаен.

Дөрес, заманасына, чорына күрә Кәбир абзый да коеп куйган мәчет карты да, фәрештә дә түгел. Аның да холкының кырысрак

чаклары да еш булгалап торгандыр. Үз даирәсе таләп иткәнчә, динен дә тоткандыр. Балаларының бозык юлга басуыннан куркудан, аларга карата кайчак кырысрак та кылангандыр, Фәйзүген дә баштарак төрле ят уеннардан һәм ят уен коралында уйнаудан тыярга тырышкандыр. Ф. Хөсни «Гармунчы» документаль повестенда аны шулайрак итеп күрсәтә. Фәйзүкнең үз хезмәтенә алган беренче гармунын да атасы таптап изә, диелә ул әсәрдә. Ләкин авылдашлары башкачарак фикердә. Унбиш яшьләрдәге Фәйзүкнең гармунга чын-чынлап мөкиббән булуын аңлаганнан соң, улының ул уен коралында уйный алуына ышангач, Кәбир абзый беренче гармунны аңа үзе сатып ала, дип сөйли безнең авыл кешеләре.

Фатих Хөснинең повестенда атаны артык диндар, томана итеп күрсәтергә тырышуын замана чире дип карарга кирәктер. Әсәр бит утызынчы елларда, динне каһәрләгән чорда иҗат ителгән. Әсәрдәге Кәбир абзый образы чынбарлыкка туры килми. Чөнки андый диндар, кеше гаиләсен ачлыктан йолып калу өчен булса да, башка диндәге күрше авыл халкына барып баш иярга курыккан булыр иде. Кәбир абзый исә шуның киресен эшли. Атасы, Мокыч карт сүзенә буйсынып, чуваш авылына барып көтүчелеккә яллана. Шул рәвешле ишле гаиләсе белән авыр ачлык елларын уздырып җибәрә ала. Иске Салаванда да, Мәләкәс каласында да ул гади батрак кына түгел, үз кул көче белән көн күрергә омтылучы хуҗа буларак күзаллана. Көтү көтүдән бушаган айларда ул үз аты белән олаучы хезмәтен дә башкара. Мәләкәстә дә ул тик кенә, постоялый двордан килгән ризыкны ашап кына ятмый. Базар-ярминкәләр булмыйчарак торган мәлләрдә Әбдүш тегермәненә йөк ташый. Шул рәвешле, ике-өч йөкне тарта-тарта, ул озакламыйча үзе дә бер кешенең постоялый дворын сатып ала, үз эшен башлап җибәрә. Мөселманнар өчен үз кунакханәсен ача.

## Сәяхәтләр, юллар

Кәбир абзый үз кунак өенә хуҗа булу көннәренә ирешкәндә аның зур улы, беренче ярдәмчесе Мәләкәстән еракта була инде. Фәйзүк баштарак, уналты-унҗиде яшьләрендә, биюче һәм төрле мәзәк кыланышлар башкаручы сыйфатында Казаннан килгән төркем белән үзләрендәге уеннарда катнаша. Балаган җитәкчесе Анна Казаграндега аның чыгышлары ошый, һәм ярминкә ябылгач та ул хатын аны үзләре белән алып китә. Казанда бастырылган яңа, матур афишаларда аның исеме дә «виртоуз артист Фәйзүк Туишев» буларак беренче мәртәбә теркәлә. Шушы көннән соң «Туишев» аның псевдонимы булып китә, соңрак фамилиягә әверелә.

Алар төркеме Казанда бер кыш дәвамында эшли. Фәйзүк сәхнәгә күбрәк вакытта рус яшьләре кыяфәтендә чыгып бии,

гармунда рус көйләрен уйный. Баш очына самавыр беркетеп биюдә аеруча осталык күрсәтә. Шул сәбәпле бервакыт аны татар яшьләре урамда тукмап та китәләр. Яз башында бу төркем кабат Мәләкәс каласына юл тота. Шул ук вакытта монда Сембер каласыннан килгән цирк артистлары төркеме дә эшли. Ярминкә сезоны беткәч, Фәйзүк икенче гастрольгә шушы цирк төркеме белән чыгып китә. Алар, биеп-җырлап, цирк тамашалары күрсәтеп, Идел буе шәһәрләрен йөреп чыгалар.

Шушы гастроль вакытында булса кирәк, Сембердә торып эшләгән бер вакытта, алар төркеме арендалаган цирк бинасы һәм күпчелек җиһазлары янып көл була. Күпмедер вакыт тулы хезмәт хакы алмыйча эшләгән артистлар акчасыз калалар. Төркем җитәкчеләре шәһәрдән чыгып кача. Иң авыр хәлдә калучылар арасында яшь артист Фәйзулла Туишев та була. Ачы язмышка дучар ителгән артистны фәкать кулында калган гармуны гына коткара. Шушы вакыйгадан соң инде ул кечерәк кенә үз төркемен оештыра, ил күләмендә дан, шөһрәт биеклегенә илтүче туры сукмагына төшә.

Егерме ике яшендә, Сембердә цирк труппасы белән булган вакыйганың көзендә, Фәйзулла Туишев хәрби хезмәткә каралыр өчен дип туган авылына кайта. Иске Төгәлбугадан чыгып китүенә сигез-тугыз еллап вакыт үткән була. Ул заманда кабул ителгән тәртип таләп иткәнчә, хәрби комиссиядә каралырга тиешле һәркем туган җиренә кайткан. Чордашлары хәтерләвенчә, Фәйзүк авылга 1906 елның көзендә кайта. «Авыл писарьлары кебек киенгән иде», – дип сөйлиләр. Өстендә – затлы көзге пальто, аягында ялтырап торган күн итекләр була. «Иңендә зур гармун иде», – дип истә калдырганнар. Ул вакытта безнең төбәк авыллары некрутларын Иске Төгәлбугадан егерме биш чакрым көньяктарак урнашкан Зирекле Куак авылында комиссия аша үткәрә торган булалар. (Бу татар авылы рәсми документларда Елховый Куст дип аталып йөргәнлектән, артистның биографияләрендә дә шулай теркәлгән.) Өяз каласы Самарадан килгән рус офицерлары Фәйзулла Туишевны үзләре белән алып китә һәм күпмедер вакыт үткәч кенә «хәрби хезмәткә яраксыз» дип иреккә җибәрәләр. Ә Мөхәммәтша, Шәфигуллалар, солдат шинеле киеп, хезмәт итәргә калалар. Алар Фәйзүк кордашлары белән кабат фәкать ике зур сугыш һәм 1921 елгы ачлык вакыйгаларын кичергәч кенә кавыша алалар. Бу еллар аралыгында Фәйзулла Туишев үзе туплаган артистлар төркеме белән Россиянең барлык төбәкләрендә гастрольләрдә йөри. Халык мәхәббәтен яулый.

Театр артисты Локман Аитов «Артист язмалары» китабында Фәйзулла Туишев белән Түбән Новгород шәһәрендә очрашуын тасвир итә. «1909 елның җәе, ярминкә көннәре. Шул көннәрдә Фәйзулла Туишев концертлары да барды. Аның белән дә таныштым. Безнең халыктан да шундый гармунчы чыгар икән

дип, тәмам хәйран калдым. Чөнки мин бу көнгә кадәр Пермьдә гастрольгә килгән рус уенчыларыннан мәшһүр Пётр Невскийны гына күргәнем бар иде. Фәйзулла Туишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармуннарда зур осталык белән уйнавы, шуның өстенә тагы үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре соклангыч булды», – дип язды.

Фәйзулла аганың замандашы, күренекле әдип Гомәр Бәширов та 1992 елда язылган бер мәкаләсендә авылдашымның «халыкчан иҗаты»н югары бәяли. Милли саф көйләр башкаручыларның берсе, ди.

Республикабызның Милли музеенда Фәйзулла Туишев архивының бер өлеше һәм гармуннары саклана. Анда төрле елларга караган афишалар, концерт программалары да бар. Менә 1914 елның 17 апреленә караган бер программа. Ул рус һәм татар телләрендә аерым-аерым басылган. Анда Казан сәүдәгәрләре бинасының залында Фәйзулла Туишев катнашында концерт һәм спектакль буласы бәян ителә. Кичәнең администраторы – Ш. Әбдиев, диелгән. Бер пәрдәлек спектакльдә катнашучы Вәлишин, Исмәгыйлев, Ибраһимов, Саттаровлар янәшәсендә дә Әбдиев фамилиясе күрсәтелгән.

Озакламыйча башланган Беренче бөтендөнья сугышы көннәрендә Ф. Туишевның Оренбургта, Мәскәүдә, Петербургта гастрольләрдә булуы мәгълүм. Бу көннәрдә «Ил» газетасында аңа багышлап мәкалә басылуы хакында да хәбәрләр бар.

Гражданннар сугышы тәмамланганнан соң, артист Казанга кайтып төпләнә. Татарстанның халык артисты Хәким ага Сәлимҗанов гармунчының Совет Татарстанында оештырылган беренче концертын яхшы хәтерли. Бу концерт Фәйзулла Туишевның Себер белән Ерак Көнчыгыш гастрольләреннән соң Татарстанга 1923 елда бөтенләйгә кайтуыннан соң уздырыла. «Кабатланмас якты талант, чын мәгънәсендә профессиональ музыкант иде Фәйзулла ага Туишев. Аның репертуары гаять бай иде. Менә ул, берара чит җирләрдә йөреп, ниһаять, сөекле, моңлы Казанына кайтты», – дип башлый ул аңа багышланган истәлеген. «Татар көйләреннән бигрәк тә «Ончы Фәхри» белән «Әллүки»не тирән эчке бер хис белән башкарды. Тамаша залы гөр килде».

Гармунда гаҗәп оста уйнаучы гармунчының бөтен хәрәкәтхаләтен бик төгәл тасвир иткән ул истәлеккә инде ни дә булса өстәп тә, шуннан арттырып сөйләп тә булмастыр. Хәким ага Сәлимҗанов татар тамашачысының һәм, гомумән, татар халкының гармунчыга карата булган ихтирамын һәм мәхәббәтен бик тулы чагылдыра, минемчә. Фәйзулла Туишев концертлары, кайларда гына оештырылмасыннар, тамашачының ялкынланып кул чабулары белән ачылып китеп, аягүрә басып, артистны озаклап алкышлаулар белән тәмамланганнар. Сөйгән халкы аны һәркайда яратып кабул иткән. «Туишев, афәрин!», «Туишевка

озын гомер!» дип кычкыра торган булган. Халыкның дәррәү хуплавын күреп торган кайбер шикләнүчәнрәк түрәләр дә сабырлык күрсәтергә, мәшһүр артистның элекке сәяси хаталарына күз йомарга булалар.

Казанга кайткач артист үзе кебек оста гармунчылар әзерләргә кирәклеген дә онытмый. Милли музей архивында аның яшь музыкантлар белән дәрес уздыру вакытын чагылдырган бер фоторәсем дә саклanган.

Ерак Владивосток, Харбин якларында озаклап йөргәннән соң, артист туган җирен, туган төбәген дә бик сагынып кайта. 1923–1939 елларда ул Иске Төгәлбугада гадәттәгедән ешрак була. Артист буларак тәүге тапкыр туган авылына концерт куярга кайткан елны чордашлары төгәл хәтерләми хәзер. «Ачлыктан соңгы ел иде», – дип искә алалар. Әле Иске Төгәлбугада клуб булмый. Шәкертләрдән бушаган бер иркенрәк бинада – Уку йортында концерт куела. Аның ул вакыттагы мөдире – «избачы» Нәкытдин бабай Миңлебаев җитмешенче елларда исән иде әле. Үзе дә авылның бер дигән җырчысы булган, «Сандугач Нәкый» кушаматын йөрткән карт гармунчының ул вакытта авылга кайту күренешен болайрак тасвир иткән иде. «Фәйзүк абыйның уйнавын карарга, тыңларга дип килгән кеше мәчет янәшәсендәге ул ызбага сыешып бетмәде. «Иртәгә дә килеп уйна» дип күндердек үзен. Ике-өч көн шунда ялыкмыйча уйнады».

Берничә көннән соң авылдашларын озатырга дип Курай урамына килгән халык: «Адә, тагын кайт, Фәйзүк, шулай уйнап безне тагын сөендер!» – дип, матур теләкләр теләп калалар.

Шуннан соң ул авылга тагын берничә мәртәбә кайта. Ул вакытта әле Бәнат җиңгәсе дә, аның улы Шәмси дә исән-сау булалар. Артист һәр кайтуында үзе туып үскән өенә төшә, Бәнат тәчиендә кунак була. Бары тик 1939 елда гына авыл түрәләре Лалә ханым белән икесен зурлабрак каршы алырга ниятлиләр. Авылның күренекле кешесе – «ЦИКа Гаян» өенә урнаштыралар. Аның өе пөхтә, зур була. Гаян апа Сәгъдиева егерменче еллар ахырларыннан авылның иң дәрәҗәле кешеләреннән санала иде. Самара өлкәсеннән Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетына сайланган, мәшһүр Калинин баба белән бер өстәл артына утырып, ил язмышын хәл итешүдә дә катнашкан хатын ул. Лалә ханым белән уртак сүз таба алыр дип тә уйлагандыр колхоз рәисе Имам Мостаев. Гаян апа өенә клуб та, авыл идарәсе йортлары да бик якын, күршедә генә диярлек. Димәк, кунакларга авыл буйлап йөрисе дә түгел.

Фәйзулла Туишев бу кайтуында элекке мәчет бинасында ике көн рәттән төрле гармуннарда көйләр уйнады, авылдашларының күңелен күрде. Әйе, ул вакытта инде иң зур мәчет клубка әверелдерелгән иде. Фәкать түр башының урамнан беркадәр эчкә кереп, кыйблага йөз тотуыннан гына аның элекке мәчет бинасы икәнлеген чамалап була иде. Тамашачылар «партер» эскәмияләрендә

генә түгел, залның өчтән бер өлешенә чыгып торган киң балконына да шыплап тулган иде. «Иде» дим, чөнки авызны ачып, шул балкон киртәсеннән сәхнәдәге тамашаны йотлыгып күзәтүчеләр арасында үзем дә бар идем. Әйе, байтак кеше клубка балаларын да алып килгән – ил күләмендә танылган артистны, авылдашын күреп калсын. Авылдан кем чыкканын белеп торсын дигәннәрдер. Көндезге һәм кичке концертларга, олау-олау төялеп, күрше авыл кешеләре дә килгән иде. Бала-чаганы кызыктырып, мәчет каршында яңарак бер полуторка машинасы да тора. Димәк, кайдандыр ерактан аңа да төялеп килгәннәр. Тамашачылар арасында элекке мәчетнең бер почмагында бөрмә билле аксыл тунлы чуваш хатын-кызлары һәм ир-егетләре дә күренә. Димәк, Иске Салаван кешеләре дә көтүче Фәйзүкнең концертын күрергә һәм тыңларга дип килгән. Алар да, мөгаен, Фәйзулла абыйның уенын йотылып тыңлаган хәлдә, кайчандыр арабызга кертмәскә тырышып йөргән Фәйзүк шушымы соң? Әйе, шулдыр. Югыйсә безнең чуваш көйләрен бу кадәр оста уйный алмас иде дип сокланып торалар иде шикелле.

Шушы кайту Фәйзулла абыйның туган-үскән авылына соңгы мәртәбә аяк басуы булган икән. Шул елның көзендә үк финннар белән сугыш чыгуы, аңа ялганып ук диярлек Бөек Ватан сугышының башлануы аны туган иленнән ераклата. Ә сугыш белән бергә катлаулы авырулар һәм картлык көннәре килә. Авыр сугыш елларында артистның Бәнат җиңгәсе вафат була. Ике энесе – Сәхаб белән Шәмсетдин – ерак яу кырында ятып кала.

Соңгы елларында иленә кайта алмаса да, Иске Төгәлбуга халкы бер дә онытмый үз улын, үз авылының мактанычы саналган бөек артист Фәйзулла ага Туишевны. Татарстан халкы да Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевны һич онытмый. Дистә елга якын инде Казан каласында, Фәйзулла Туишев исемендәге мактаулы дәрәҗәгә ирешү өчен, төрле төбәкләрдән килгән гармунчылар арасында ярышлар уздырыла. Шундый дәрәҗәле исемгә лаек булучылар арасында мәшһүр артистның якташы Рөстәм Вәлиев тә бар. Күптәннән инде Татарстанның халык артисты исемен дә алган икенче бер виртоуз гармунчыбыз. Әйе, гәрчә ул Казанга Самара аша урап килсә дә, төп чыгышы буенча Иске Төгәлбуга даирәсенә кергән авылларның берсе саналган Төплистаннан була. Рөстәмнең ата-анасы шул авылдан. Үзенең дә балачагы шул җирлектә, әби-баба карамагында уза. Рөстәм татар моңын күңеленә Фәйзулла агасын тудырган туфрактан ала.

Фәйзулла Кәбир улы Туишев оста музыкант-башкаручы гына түгел, көйләр тудыручы да. Аның яшьлек елларында иҗат иткән төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр. Ә инде Казанда төпләнеп яшәү елларында иҗат иткән утызлап җыры һәм башка төр музыкаль әсәрләре аны композитор буларак та таныта.

Аның тарафыннан музыкальләштерелгән җырлардан байтагын халкыбыз яратып кабул иткән. Әйтик, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Халкыма», Сәхаб Урайский шигыренә нигезләнеп иҗат ителгән «Төзелештә», Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язылган «Дустыма» җырлары элегрәк елларда радиодан да бик еш тапшырыла иде.

Халык сүзләренә таянып музыкальләштерелгән «Кукмара» җыры да һаман онытылмый. Болардан тыш, Фәйзулла Туишев Гадел Кутуй истәлегенә багышлап марш һәм кыллы квартет өчен «Пионерлар сюитасын» (М. Юдин белән бергә) иҗат итә.

1930 елларда Фәйзулла Туишев Казанда гармун фабрикасын ачуда башлап йөрүчеләрдән була. Һәм 1933 елдан фабриканың техник советында баштарак баш белгеч, соңрак консультант вазифаларын башкара.

1944 елның февралендә Фәйзулла Туишевка «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исеме бирелә. Моннан тыш, аның башка бүләкләре һәм орденнары да бар, әлбәттә. Әмма иң зур бүләк – халкы күңелендә сакланган олы ихтирам, билгеле. Бердәнбер үкенеч – соңгы елларда мәшһүр гармунчының уены радиотапшыруларда бик сирәк яңгырый. Бәлкем, концертлардан язып алынган язмалар да юкка чыккандыр. Соңгы дистә елда безнең радиотапшырулар оешмасында андый югалтулар да булгалады бит. Әле күптән түгел матбугатта бер сөенечле хәбәр дә урнаштырылган иде. Ленинград шәһәрендә яшәп вафат булган күренекле рәссам Фәйзерахман Әминев гаиләсе Казан музеена Фәйзулла Туишев язмаларыннан унбер пластинка тапшыра. Димәк, Туишевның үзенчәлекле итеп уйнау үрнәкләре әле кая да булса сакланган булырга мөмкин дигән өмет тә бар. Ә Габдулла Тукай музеенда (Казан, Г. Тукай урамы) мәшһүр артистның төрле тавышлы, төрле рәвешле егерме концерт гармуны һәм концерт киемнәре күргәзмәгә куелган иде. Алар белән һәркем таныша, гармунда моң чыгара белүче тотып карый ала. Белгән кешеләр артист кулында иллеләп шундый гармун булган дип язалар. Аларның бер өлеше Милли музей архивында сакланадыр, мөгаен. Шунда ук бер куплет шигырь дә бар:

Туишевның кулларында гармуннары сайрый,
Сандугачка тиңдәш булып.
Ул канатсыз, оча алмый.
Тик шулай да
Җирдә яши былбылларга көндәш булып.

*2007*

# ТУКАЙНЫҢ ОСТАЗЫ ҺӘМ ОСТА МАТБАГАЧЫ

*(Очерк)*

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд XIX йөз ахырларында үз ишләре белән бер әңгәмә вакытында татар вакытлы матбугатының булмавыннан зарланып мондыйрак фикер әйтә: хәзерге заманда үз матбугаты булмаган әдәбият үсеш ала алмый, ди. Ул вакытларда әле татар телендә газета һәм журналлар нәшер итү турында күпләр хыяллана гына. Россиягә яңарак кушылган казах, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә XIX йөзнең җитмешенче елларыннан ук газеталар чыга башлауга карамастан, патша хакимияте ул чорда әле татар зыялыларына матбугат ачу иреген бирми. Кара фикерле ул чор түрәләре «надан милләт» белән идарә итүне өстен күргәндер инде. 1905 елгы халык күтәрелеше һәм татар зыялыларының илдә демократик үзгәрешләр булдыруга юнәлтелгән талпынышы гына милли матбугатка юл ача.

Әйе, шул ук елның февралендә бер төркем татар зыялылары, илдә милли тигезлек тәртипләре кертелүен теләп, патша исеменә хат та язалар. Казанда бу хәрәкәтне башлап җибәрүчеләр исемлегендә адвокат Сәетгәрәй Алкин, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан Баруди һ. б. була. Бу төркемгә яңарак кына чит илләрнең иркле һавасын сулап кайткан Рәшит Ибраһимов белән Йосыф Акчура да кергән. Боларның беренче утырышлары Әхмәд бай Хөсәеновның Кабан күле буендагы өенә «аш мәҗлесе»нә дигән сылтау белән җыелудан башлана. Шунда татар зыялылары исеменнән патша җәнапларына атап хат-петиция язу кирәклеге фикеренә киләләр. Аларның төп таләпләре Россиядәге барлык милләтләрнең дә тигез хокуклы булырга тиешлеге, татарларга Урта Азия кебек төбәкләрдә иркле сәүдә итү мөмкинлеге тудырылуы һәм татар милли матбугатын нәшер итүгә ирек бирелүе турында була. Булачак хатның эчтәлеген язу яңарак кына Париж университетын тәмамлап кайткан, төрек телендә «Сәясәттә өч юл» дип исемләнгән җитди генә хезмәт язган Йосыф Акчурага йөкләнә. Аннары ул хатка Россиядә зур абруй казанган ике-өч йөзләп кеше – бертуган Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Юнусовлар, эре фабрикантлардан Акчуриннар, Дибердиевләр дә кул куя. Ул хатны башкалага илтеп тапшыру бурычын фабрикант Ибраһим Акчурин, Йосыф Акчура һәм Рәшит казый Ибраһимов үз өсләренә алалар. 1905 елның көзендә матбугат ирege дә вәгъдә ителгән патша манифесты чыгуга татар зыялыларының әлеге хатының йогынтысы да булмый калмагандыр, шәт. (Дөрес, Совет хакимияте елларында «сәүдәгәр һәм муллалар» тарафыннан оештырылган бу хәрәкәтне искә алмаска тырышылды.)

Россиядә саф татар телендә беренчеләрдән булып башкаладагы «Нур» һәм Уральскидагы «Фикер» газеталары чыга башлый. «Фикер»нең беренче саны 1905 елның 26 ноябрендә нәшер ителә.

Аның нашире дә, мөхәррире дә Камил Мотыйгый – бөек Тукаебызның остазы һәм укытучысы була.

Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин минем күз алдыма милли азатлык һәм хөррият көннәре килеренә өметләнеп яшәгән татар яшьләренең бер вәкиле буларак килеп баса. XX гасыр башында аның исеме зыялы татарлар арасында бик тиз тарала. Милләттәшләребез оешыбрак яшәгән төбәкләрдән бер читтәрәк торган Уральск (Җаек) шәһәрендә туып үскән бу хәлфәнең даны нидән килә? Шул гасыр башында ул моңа берничә данәдә үз кулы белән чыгарган кулъязма «Әлгасрелҗәдит» («Яңа гасыр») журналын таратуы белән ирешә. Шәһәр яшьләре һәм мәдрәсә шәкертләре арасында аның кулъязма «Мәгариф» газетасы да таратыла. Шул эшләрне Камил 1903 елның башыннан ук атасы җитәкчелегендәге «Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкертләре һәм үзенең якын дус-ишләре булышлыгы белән башкара. Һәм бу эшне 1905 елгы мәгълүм патша манифестыннан соң басма газета-журналлар нәшер итүгә рөхсәт бирелгәнче армый-талмый, айлап-атналап башкарып килә. Камил Мотыйгыйның бу эшчәнлеге Габдулла Тукайның башлангыч иҗат чоры белән тыгыз бәйләнештә булганлыгы, кем әйткәндәй, безнең һәр мәктәп укучысына таныш. Кулъязма «Әлгасрелҗәдит»тә дә, 1906 елның башыннан шул ук исемдә таш басмада чыга башлаган беренче татар журналында да бөек шагыйребезнең каләм үрнәкләре еш очрый: ул анда шигырьләре белән дә, укытучысы тәкъдим иткән темаларга язылган кечерәк мәкалә вә тәрҗемә хезмәтләре белән дә теркәлгән. Кайбер әдәбият галимнәре әйтмешли, шул елларда Камил Мотыйгый белән аралашмаган, ул нәшер иткән газета-журналлар эшендә катнашмаган булса, шагыйрь әдәбият мәйданына алай тиз генә кереп китә алмаган да булыр иде әле.

Камил мәхдүм, шул елларда аралашкан шәкертләреннән өч-дүрт яшькә генә олы булуына карамастан, шактый тирән белемле, мәгълүматлы шәхес була. Ул яшьли Төркиягә китеп, Истанбул һәм Каһирәнең югары уку йортларында үз чорының олуг зыялылары укыткан лекция-дәресләрне тыңлый. Европа тарафыннан искән «җылы агымнар» йогынтысында булган яшьләр белән аралаша. 1902 елда иленә кайткач та үз милләттәшләренең аң-белемен үстерүгә булган ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерергә тырыша. 1902 елда үзе туган Җаек каласына кайткач, ул, мөхтәрәм атасы Мотыйгулла ахун хәзрәтләре тоткан мәдрәсәдә шәкертләр укыту белән бергә, бу шәһәрдә мәдәни кичәләр оештыруга да керешә.

Хәтеремдә әле, 1960 елларда консерваториянең элекке бинасында Камил Мотыйгыйның улы, опера җырчысы Хәмит ага Төхфәтуллин белән очрашу оештырылган иде. Анда ул атасының гасыр башындагы җәмәгать эшчәнлеген дә искә алды. Шул чорны чагылдырган, атасы тарафыннан башкарылган кайбер истәлекләрне дә алып килгән иде. Шул кичәдә катнашучыларга ул Камил мәхдүм туплап чыгарган газета һәм журналларны да,

аның матур итеп кулдан язган «ахшам кичәләре»нә чакыру кәгазьләрен дә күрсәткән иде. Әйе, аның өстәлендә кулъязма газета һәм калын кулъязма журнал нөсхәләре дә бар иде. Белүемчә, ул кулъязма журналның берничә санын һәм башка язма истәлекләрнең кайберләрен Хәмит ага соңыннан Дәүләт музеена да тапшырырга тырышкан. Кызы Надия апа сөйләвенчә, музейга исә тарихи мирасның бер өлешен – күренекле шәкертенең култамгасы булган нөсхәләрне генә алганнар. Әле XXI гасыр башында да ул тарихи хәзинәләрнең зур бер өлеше һәм тарихи карашка бик кызыклы фотолар Хәмит ага кызы Надиядә сакланалар иде. Соңрак ул истәлекле әйберләрнең бер өлешен, бәлки, Олы Кайбычка алып киткәннәрдер. Ул район үзәгендә ачылган музейда Төхфәтуллиннар нәселеннән булган шәхесләргә багышланган аерым бүлек оештырылуы хакында матбугатта хәбәрләр булды ич. Әмма ләкин Казанда консерватория тәмамлаган музыка белгече Надия ханым белән очрашкан елларда ул «булачак музей экспонатлары» әле аларда саклана иде. Яңа гасыр башында, Г. Тукай музеенда бер очрашу вакытында, шул ук нәселдән булган Светлана Камаева бик күңелсез хәбәр җиткерде. «Надия апа вафат булгач, Хәмит ага туплаган ул мирас юкка чыкты бит», – диде. Форсаттан файдаланып, күренекле галим Гыйлем Камай җәмәгатенең дә Мотыйгулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген әйтеп китү ярыйдыр, шәт.

* * *

1905 елның көзендә, С.-Петербургтан рәсми рөхсәт килгәнен дә көтеп тормастан, К. Мотыйгый «үз типографиясе»ндә «Фикер» газетасын чыгара башлый. Ә 1906 елның гыйнварыннан «Әлгасрелҗәдит» журналының басма вариантын нәшер итәргә керешә. Бу журналны нәшер итүгә рөхсәт тә узган көздә үк алынган була. Әмма аның һәр санын укып-тикшереп, басарга рөхсәт бирердәй цензорның Җаек шәһәрендә булмавы сәбәпле, бу эш-гамәл берничә айга сузыла. Журналның һәр санын Казан шәһәрендәге цензорга илтеп укыту мәшәкатьләре өстәлә.

К. Мотыйгый 1906 елның июнендә инде татарча көлке-сатира журналы «Уклар»ны нәшер итүгә дә керешә. Шулай итеп, берүзе татарның беренче карлыгачлары саналган өч басманы берьюлы бастырып таратуга ирешә. Бу чорда аның иң актив, иң тырыш ярдәмчесе – шәкерте Габдулла Тукай була. Ә бу басмаларның баш мөхәррире һәм әдәби, мәдәни, тарихи вә сәяси темаларга багышлы мәкалә һәм очеркларны язучы исә үзе була. Хәмит ага истәлекләренә караганда, «Уклар» журналын чыгаруда ул башлыча Тукай шәкертенә таяна, аны журналның рәсми булмаган мөхәррире итеп саный.

Моның кадәр өлгерлек, зыялылык һәм инде, әлбәттә, берничә газета-журнал чыгару өчен таләп ителгән шактый ук зур матди

байлык Камил әфәндегә каян килгән соң? Акча мәсьәләсендә, билгеле инде, беренче нәүбәттә бу төбәктә олуг шөһрәт казанган атасы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның ярдәме зур була. Тумышы белән хәзерге Кайбыч районының Кече Кайбыч авылыннан булган бу кеше, Казан артындагы Кышкар мәдрәсәсендә белем алганнан соң, кардәш казах халкы җирләрендә калкып чыккан яңа калага – Җаекка барып төпләнә. Гадәти вәгазьләр, «Мулла бәлешләре» белән генә канәгать булмыйча, XIX гасырның җитмешенче еллар ахырында казах һәм татар балаларына заманча белем бирердәй мәдрәсә ачып җибәрә. Һәм үзе белгәннәрен яшь буынга «өләшә», укыта башлый. Мотыйгулла хәзрәтнең заманы өчен ярыйсы ук белемле, зыялы булганлыгын раслаучы мисаллар байтак. Зирәк кеше булган ул. Зирәк, тырыш балалар тәрбияләгән. Моның шулай икәнлеге «Мотыйгия» мәдрәсәсенең даны елдан-ел арта, үсә баруыннан да күренә. Мотыйгулла хәзрәтнең мәдрәсәләргә хас дәресләрдән тыш әдәбият укытуга җитди әһәмият биргәнлеге истәлекләрдә теркәлгән. Үзе ул Урта гасырлар гарәп-фарсы шагыйрьләреннән, әдипләреннән тыш замандашлары иҗатына, бигрәк тә төрки телле әдәбиятка мөкиббән булган. Кавказ, Төркия төбәкләрендә басылып чыккан газета вә журналларны даими алдырып торган.

Г. Тукайга багышлы бер истәлектә бу хәзрәтнең шәкертләргә «гыйльме гаруз (шигырь төзелешен) өйрәтүе» бәян ителә. Шәкерте Г. Тукайны күз уңында тотып, үзе дә: «Госманлы (төрек) китапларыннан, бәгъзән гәзитә, журналларыннан, шулай ук рус әдәбиятыннан бәгъзе нәрсәләр тәрҗемә итә башлады... Уңайлык өчен йә «Мөхәммәдия», йә «Бакырган» кебек әсәрләрдән вәзен үрнәкләре ала иде», – дип яза хәзрәт 1914 елда. Хәзрәтнең Тукайга карата аеруча якын мөнәсәбәте, әлбәттә, аның атасы Мөхәммәтгариф белән Кышкар мәдрәсәсендә бер чордарак укуына да бәйле булгандыр.

Алдарак Камил Мотыйгыйның үз басмаханәсе булган кебегрәк фикер әйтелгән иде. Ул басмаханәнең тарихы болайрак тасвирлана. Шәһәрдә «Уралец» исемендә чыгып килүче русча газета типографиясенә унлап кеше хуҗа икән. «Уртак малның иясе юк» дигәндәй, беркөнне ул басмаханәнең бөлгенлеккә төшүе мәгълүм була. К. Мотыйгый әле моңа чаклы да казанлы Ш. Шәһидуллин, Оренбургта яңарак кына үз басмаханәсен булдырган Ф. Кәрими кебек кешеләр белән шундый ук эшне Җаек каласында да оештыру мөмкинлеге хакында сөйләшүләр алып барган була. 1905 елның башында үзләрендәге басмаханәнең кыен хәлдә калуын ишеткәч, күпмедер акча туплап, ул «Уралец» пайчылары сафына баса. Аны шунда ук бу басмаханәнең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Бу вакытта аңа шәһәрнең бай сәүдәгәрләре рәтендә йөргән каенатасы да, алыш-биреш белән көн күргән дус-ишләре дә булышлык итми калмаганнардыр, әлбәттә. Уртак типография дип тормый Камил мәхдүм, тиз генә Казанга барып, татарча

хәрефләр алдыра, хәреф җыючы ике останы да яллап, үзләренә алып кайта. Җаек каласында шул рәвешле татарча басмаханә бүлекчәсе – «Тәрәккый» барлыкка китерелә. Өстәп шунысын да әйтергә кирәк: «Уралец» газетасы журналистлары арасында да аның абруе зур була. Берара шул русча газетаның мөхәррирлек вазифаларын да ул башкара. Ә үзенә ул вакытта әле 25 яшь тә тулмаган була. (Ул 1883 елның 25 февралендә туган.)

Бакчачылар телендә «иртә шыткан тинәккә кырау сугучан» дигәнрәк әйтем йөри. Безнең очракта да шулай килеп чыга. 1907 елда Камил әфәндегә үз ишләре арасындагы көнчелек, хөсетлек шаукымнарын да, Россия шартларында иртәрәк баш калкыткан-лыктан бүтән төрле киртә вә каршылыкларны да «татырга» туры килә. Белгәнебезчә, шушы елдан элегрәк яуланган хөррият вә сүз ирегенә дә тиздән чик-киртәләр куела башлый. Патша чиновниклары К. Мотыйгый мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлардагы һәрбер мәкаләне, шигырьне энә күзе аша үткәреп, тикшереп торалар. Әйтик, аның чордашы һәм фикердәше, казах зыялысы Бәхтиҗан Каратаевның «Фикер» газетасында 1906 елның башында басылган мөрәҗәгать-мәкаләсен алар шик-шөбһәсез ничек кабул итсеннәр ди? Анда бит казах адвокаты үз халкына автономия шартлары тудырылуын таләп итә. Әгәр казах халкының таләбе үтәлмәсә, мондый хокукны безгә сугышып алырга туры киләчәк, дип белдерә.

Кайбер надан мулла-мәзиннәрне, кара байларны тәнкыйтьләп, чеметкәләп алгалаулар, Г. Тукайның «Сорыкортларга», «Пыяла баш» кебек шигырьләрен газета-журналларда урнаштырулар да эзсез калмыйлар. Камил мәхдүмгә һәм аның туганнарына карата янаулар, яман гайбәтләр тарату очраклары ешая. Аның басмаханәсен ватып-җимереп ташларга, үзен кыйнап үч алырга ниятләүчеләр дә табыла. Аңа каршы бер-берсен котыртышучы милләттәшләре саны айдан-айга ишәя бара.

Хәтта ки ерак Казанда нәшер ителүче «Бәянелхак» газетасы да шушы төркемгә ияреп «өрә» башлый, явыз ниятле кискен мәкаләләр бастыра, демократик яшьләр фикеренә киң мәйдан биргән яшь редакторны кяферлектә, дәһрилектә гаепли. Шундый шартларда Г. Тукай, остазын яклап, «Мөхәрриргә» исемле шигырен язып бастыра. Бу очракта Гаяз Исхакыйның да башлангыч чор иҗат үрнәкләренең Камил мәхдүм матбагасында дөньяга чыгуын әйтеп үтмәү килешмәстер.

Губерна хакимияте вәкилләренең күпсанлы кисәтү һәм штрафларыннан соң, ниһаять, 1906 елның ноябрь ахырларында, алты саны нәшер ителгәч, «Уклар» журналын ябу турында карар чыгарыла. Ә тагын берничә айдан соң кайбер милләттәшләренең «ярдәме белән», К. Мотыйгыйның «җитди» бер ялганын ачыклыйлар. Матбага ачарга рөхсәт сораган кәгазьләрендә ул туган елын дөрес күрсәтмәгән икән ләбаса. Нашир вә мөхәррир вазифасын башкару өчен 25 яшь чик булып торган. Дәүләт карарында

ул шулай күрсәтелгән икән. Ә «Фикер» белән «Әлгасрелҗәдит»не нәшер итәргә үтенеп гариза язган вакытта әле Камилгә егерме биш яшь тулмаган була. Мотыйгулла хәзрәт, улы үтенгәч, ялган белешмә бирә. Кемдер шул хакта губерна идарәсенә белдерә. Аталы-уллы Төхфәтуллиннарны судка бирәләр. Ә Камил мәхдүм губернатор карары белән наширлек вә мөхәррирлек хокукларыннан мәхрүм ителә.

Күп көч куеп барлыкка китерелгән басмаханәне һәм матбаганы харап итмәс өчен, ул һәм аның якыннары Җаек шәһәренең иң зур бае саналган Мортаза Гобәйдуллинга, әлеге «сорыкортлар»ның берсенә ялынырга мәҗбүр булалар. Ул наширлек вазифасын үз өстенә алырга ризалык бирә. К. Мотыйгыйның «Тәрәккый» типографиясен дә, «Фикер» газетасы белән «Әлгасрелҗәдит» журналын да берничә ай үз исеменнән исән-сау яшәтеп килә. Бу басмаларга мөхәррир итеп ул шәһәрнең элекке Хәйрия җәмгыяте башлыгын, кулъязма журналда ук Тукаебыз тарафыннан мактап телгә алынган Вәлиулла Хәмидуллинны билгели. Әлбәттә инде, мөхәррирлек кандидатурасы Камил мәхдүм белән килешеп сайланган булгандыр.

Ләкин... кара байга, сәүдәгәргә милләтнең хөрлеге, бәйсезлеге өчен көрәш кирәкми бит, акчалата керем генә булсын. Мортаза бай да, табыш тәтемәвен, чыгымнар артуын тойгач, 1907 елның урталарында әлеге газета белән журналны чыгаруны туктата.

К. Мотыйгый, эшсез калгач һәм губернаторның «Себергә сөрү» белән янауларын ишеткәч, туган-үскән шәһәрен ташлап китәргә мәҗбүр була. Мөхәррирлек эшенә тотыну мөмкинлеге булмаганлыктан, патша җәнаплары тәхетеннән бәреп төшерелгәнче, тамагын җырчы-артист буларак шәһәрдән шәһәргә йөреп туйдыра башлый. Әүвәл бер ел чамасы Саратов шәһәрендә яши. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җырларга өйрәнә. (Шулар арасында үзебезнең милләттәшебез булуын да әйтеп үтик. Әмма ләкин хәзер генә аның фамилиясен искә төшерә алмадым.)

Кече сеңлесе Галия Төхфәтуллина-Кайбицкая белән улы Хәмит аганың матур, тыңлаган саен тыңлыйсы килеп торган тавышлы җырчылар булуын искә алганда, Камил Мотыйгыйның да тавышы бигүк ямьсез булмагандыр, мөгаен. 1928 елда Казанда дан-шөһрәт казанган артист дуслары катнашында аның егерме еллык артистлык юбилее зур тантана рәвешендә уздырыла. Ә 1935 елда, пенсия яшенә җитмәвенә дә карамастан, аңа Татарстан хөкүмәте тарафыннан персональ пенсия билгеләнүен дә шул җырчы хезмәтен һәм татар матбугатының карлыгачы, беренче журналисты икәнлеген дә искә алу нәтиҗәсе булгандыр дип уйларга кирәк. Бу вакытта улы Хәмит ага Мәскәүдә яши, яңарак ачылган татар опера студиясенең җитәкчесе дә, арияләр башкарырга өйрәнүчесе дә була. (Туганы Галия Кайбицкая да шунда опера җырчысы булырга әзерләнә.)

Әмма Камил Мотыйгыйның язмышы барыбер бик аяныч тәмамлана. 1937 елның ахырында сөекле улы Хәмитне, «мулла оныгы»н Мәскәүдә кулга алалар. Элек үзенә тантаналы рәвештә билгеләнгән пенсиясен дә түләми башлыйлар. Соңгы елларда иҗат ителгән өч сәхнә әсәреннән берсе генә басылып чыга. Элекке танылган җырчы, татарның беренче вакытлы матбугатына юл ачкан олы яшьтәге кеше яшәү чыганакларыннан мәхрүм ителә. Ул һәм карчыгы, элекке «бай сәүдәгәр кызы» авыр хәлдә калалар. Шушы хурлыкларга түзә алмыйча, Камил Мотыйгый 1941 елның 26 гыйнварында үзенә үзе кул сала. Бу вакытта алар хәзерге Опера театры бинасы артындагы ике катлы искерәк йортларның берсендә яшиләр. Аның үле гәүдәсен шул йортның алам-салам тутырылган чормасыннан табып алалар…

Улының, Хәмит Төхфәтуллинның язмышы исә чак кына үзгәрәк: унҗиде елдан соң ул Казанга әйләнеп кайта, аклана. Дөрес, сугыш елларында инде ул Казанга бер кайткан була. Опера театрына җырчы артист буларак кабул да ителә. Әмма 1948 елда аны яңадан Норильск лагерена алып китәләр. Һәм ул илленче еллар урталарында гына бөтенләйгә котылып кайта. Шуннан кайткач, соңлабрак булса да, ата-бабасының мирасын барлауга керешә. Музейларга тапшырылачак газета-журнал нөсхәләренең байтагы аның тырышлыгы белән тупланган. Бәлкем, ул әле атасының әдәби иҗат җимешләрен дә барлый башлаган булгандыр. Хәтерем ялгышмаса, Хәмит ага Төхфәтуллин сиксәненче еллар башында вафат булды. Үләре алдыннан аны телевизордан да күрсәтеп алганнар иде. Ул анда, яткан килеш бер кулын өскә чөя-чөя, көр тавыш белән опералардан арияләр башкарды. Ул тарихи күренеш телестудия архивында, бәлки, сакланадыр да әле…

Алдарак без К. Мотыйгый өч сәхнә әсәре иҗат иткән дип белдергән идек. Егерменче-утызынчы елларда язылган бу әсәрләрдән «Тозак» исемлесе аерым китап буларак басылып чыга, «Шайтан өне» белән «Көрәш» пьесалары кульъязмада килеш калалар. Аның әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге Төркиядә укып кайткач та башланган. Күпсанлы көндәлек мәкалә, очерк, фельетоннары үзе нәшер иткән газета-журналларда чыкканлыкка шик белдерүчеләр юктыр, мөгаен.

«Әлгасрелҗәдит» журналында аның Төркиядән кайткач язган күләмле «Мисырга сәяхәт» юлъязмасы, кайбер хикәяләре укучыларына җиткерелә. 1903 елда С.-Петербург каласында, кырымлы И. Бораганский басмаханәсендә Камил мәхдүмнең «Бәхетле Мәрьям» романы, 1906 елда «Мөнкарыз» исемле хикәяләр тупланмасы басылып чыга. Үз мөхәррирлегендә чыккан газета-журналлар тыелгач та якын дусты Гали Мусин исеменнән нәшер ителгән «Яңа тормыш» газетасында (1907—1909) аның күпсанлы «Төш күрү», «Төш юрау» исемендә сәяси памфлетлары басылганлыгы хакында да Хәмит ага хәбәр итә.

Шушы мисаллар җирлегендә К. Мотыйгыйның XX гасыр башында ярыйсы ук актив язучы булганлыгын да танырга хаклыбыз. Әмма әлегә аның әдәби мирасы нигәдер барланмаган. Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов томнарында урын алган искәрмәләрдәге мәгълүматтан башка, XX гасыр әдәбиятына багышланган бер генә хезмәттә дә язучы Камил Мотыйгыйның исеме һәм әдәби хезмәтләре искә алынмый диярлек. Ни өчен алай эшләнә? Ул әсәрләрнең сыйнфый көрәшне чагылдырмавы сәбәплеме? Әллә соң әдәби эшләнешләре ягыннан йомшаграк булганлыктанмы? Әдәбият сөюче, укучы буларак минем, мәсәлән, боларны бик тә беләсем килә. Театр өлкәсендә Ильяс Кудашев-Ашказарский, С. Волжская, Г. Кариев, К. Тинчурин, музыкада С. Сәйдәш, С. Габәши беренче карлыгачлар булган булса, вакытлы матбугатны тудыручы Һади Максуди, Фатих Кәрими, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый һәм бертуган Рәмиевләр белән бер сафка басардай шәхес итеп күзаллыйм Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинны. Бу хезмәтемдә мин аның патша хөкүмәте төшерелгәч берничә яңа газетага нигез салуын да барлап тормадым. Алай да 1917 елның көзендә С.-Петербургта чыга башлаган иң тәүге «Ярлы халык» турында Г. Ибраһимовның бер хезмәтендәге кыска гына җөмләне китереп үтәсем килә: «Мәркәз мөселман комиссариаты төзелде, «Ярлы халык»ны бетереп, зур, җитди бер газета кую хакында ризалык-фикер алынды», – дип яза ул. Димәк, «җитди бер газета»ның – «Чулпан»ның нигезен әнә шул Камил әфәнде Петроград советы карамагындагы Мөселман комитеты исеменнән нәшер иткән газета тәшкил иткән икән ләбаса. 1917 елдан соң К. Мотыйгый Самарада һәм кабат Җаек шәһәрендә тагын берничә газетага җан өргән.

Камил Мотыйгый исеме аталгач, никтер күз алдыма Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» әсәрендәге садә, эчкерсез күңелле, тиктормас җанлы баш каһарман Дүшән килеп баса. Ул да бит, авылдашларының дөньяга күзен ачыйм, аң-белемен күтәрим дип, үз-үзен аямый көн-төн чаба, төрле кыерсытуларга дучар була, хәтәр хәлләрдә калгалый. Әмма дә ләкин үз юлыннан тайпылмый, үз җилкәсенә алган «йөген» ярты юлда ташлап калдырмый. Тормыш авырлыкларына бирешмәстән, тоткан юлын дәвам иттерә. Нигездә, бөек Тукаебызның остазы Камил Мотыйгый да шундый зат булган. Татарлардан беренчеләрдән булып газета-журналлар нәшер итәргә керешкән. Саратов консерваториясе профессорлары ярдәмендә җыр сәнгатен үзләштергән, егерме елдан артыграк гомерен татар сәхнәсенә багышлаган шәхес. Без аны шул эшчәнлеге өчен дә, бөек Тукаебызның беренче остазы булганы өчен дә онытырга тиеш түгелбез.

*2012*

# НӘТИҖӘЛЕ СӘФӘР

Совет хакимияте елларында безнең фәнни институтлар галимнәре Урта Азия республикаларында еш булалар иде. Аеруча тарих һәм әдәбият өлкәсендә эшләүче галимнәребез өчен Бохара, Сәмәрканд, Ташкент кебек зур тарихлы шәһәрләрдә булу, аларда ерак гасырлардан бирле сакланып калган бай мирас белән танышу бик тә кирәк иде. Урта Азия республикалары галимнәре дә бездә еш булдылар. Иксез-чиксез Россия җирлегендә икенче буларак ачылган Казан дәүләт университеты галимнәре белән аралашу, шунда тупланган бай мирас белән танышу алар өчен дә бик гыйбрәтле эш иде. Әмма 1990 еллардан соң, әлеге кардәш республикалар Россиядән аерылып чыккач, андый аралашулар ике дистә елга якын өзелеп торды дияргә була. Үзара килешеп, чик аша үтү тәртипләре бераз җайга салынгач кына, кабат дустанә мөнәсәбәтләр яңартылды.

Булат улым Ташкент, Сәмәрканд якларына дип юлга җыена башлагач та, мин берничә нәрсәне ачыклап кайтуын үтендем. Иң зур үтенечем, әлбәттә инде, Габдулла Тукайның йөз ел элек Ташкентта рус телендә нәшер ителгән китабына бәйле булды. 1985 елда ул китапның күчермәсен миңа үзбәк галиме Шерали Турдыев җибәргән иде. 1920 елда Ташкент шәһәрендә шундый китап нәшер ителгәнлеге турында мин Бөек шагыйребезгә йөз ел туласы көннәрдә «Азат хатын» журналында мәкалә дә урнаштырган идем. Бераз соңрак, «Габдулла Тукай әдәби музее»н ачу көннәре алдыннан, шул юка китап күчермәсен миннән сорап алдылар. Милли музейның ул вакыттагы бүлек мөдире Дания ханым Баһаветдинова аны шунда ук булачак музей мөдире Госман Хәбибуллинга тапшырган иде. Шуннан соң мин ул китапчыкны кабат күрмәдем. Госман вафат булгач, ул музейның яңа җитәкчеләре миңа андый китап күчермәсе барлыгын әйтеп бирә алмадылар.

Булат улым Үзбәкстанга барасы булгач, мин аңардан ул китапның Ташкентта саклану-сакланмавын ачыклавын үтендем. Улым ул эшне тиз арада башкарып та чыкты. Габдулла Тукай иҗатын русча чагылдырган ул китапның Галишер Нәвои исемендәге сирәк китаплар һәм кулъязмалар китапханәсендә саклануын телефоннан ук хәбәр итте. Бу атаклы мирасханә анда 1870 елдан эшли. Дөресрәге, ул инде элекке ханнар, әмирләр заманыннан бирле тупланып килгән мирасханә булгандыр. Ә 1870 елдан рәсми оешма исемлегенә кертелгән. Шундагы сирәк кулъязмалар арасында, мөгаен, безнең милләткә кагылышлы башка төр язмалар да саклнадыр әле. Әйтик, XIX йөз башында Оренбург төбәгендә яшәп иҗат иткән Гомәр Мөхәммәд-Каргалыйның тарихи эчтәлекле поэмаларының кайберләре.

Г. Тукайның «Избранные стихотворения» китабы күчермәсен Үзбәкстанда яшәүче милләттәшебез, тарих фәннәре галиме Ринат

Нәҗметдин улы Шиһабетдинов тиз арада табып бирә. Аңа безнең кабат рәхмәт сүзләрен җиткерәсебез килә.

Бу китапка кергән берничә шигырьне тәрҗемә итүче шагыйрь Валентин Вольпин була. Элегрәк Мәскәүдә яшәгән шагыйрь, Сергей Есенинның дусты. Ташкентка революция вакыйгалары алдыннанрак килгән. 1919 елда монда «Антология революционной поэзии» исемле күмәк җыентык та туплап чыгарган була. Г. Тукайның 1936 елда рус телендә нәшер ителгән «Избранные стихи» җыентыгында да аның ике тәрҗемәсе урын алган (К. Нәҗми туплап чыгарган китап. Казан, 1936). Ташкентта чыккан китапка бик җентекле кереш сүз язучы милләттәшебез Ибнеәмин Янбаев була. Касыйм шәһәрендә туган, 1916 елда Мәскәүдә сәүдә-коммерция институтын тәмамлаган шәхес. Тәрҗемәче белән, бәлки, Мәскәүдә укыган елларыннан ук таныш булгандыр. Ш. Турдыев хәбәр итүенчә, 1920 елда ул Халык мәгарифе комиссариатында эшләгән. Һәм Габдулла Тукайның әлеге китабын нәшер итүче дип тә шул комиссариат күрсәтелгән. Шунда ук «К семилетию со дня смерти поэта» дигән җөмлә дә теркәлгән. Ибнеәмин 1930 елларда кулга алына, 1955 еллар тирәсендә азат ителеп кайта, әмма озак яшәми, дип язды миңа Ш. Турдыев.

Татар-үзбәк әдәбиятлары арадашлыгын җитди өйрәнгән Ш. Турдыев язганча, 1908–1920 елларда Урта Азия милләтләре арасында Габдулла Тукай иҗаты бик югары бәяләнгән. Аның әсәрләре үзбәк, казах һәм башка тугандаш телләргә бик еш тәрҗемә ителгән. Аның иҗатына тартым иҗат үрнәкләре дә даими рәвештә матбугатта күренгәләп торган. (Шералиның 1985 елда язылган, Г. Тукай иҗатының Урта Азиядә таралуын барлауга багышланган шул хезмәтен мин, кайбер өстәмәләр белән тулыландырып, «Казан утлары» журналында да чыгардым (2016, № 4).

Г. Тукайның рус телендә чыккан иң беренче китабын нәшер иткән комиссариат турында да берничә сүз әйтеп китик. Урта Азия халыклары – Россиягә иң соңлап кергән милләтләр. «Ташкент 1865 елдан Россия составында», – дип языла хәзерге тарихи хезмәтләрдә. Ә Бохара ханлыгы җирләренең 1920 елда гына яуланганын Совет хакимияте чоры истәлекләреннән укып беләбез. Шул төбәктәге «басмачылык» хәрәкәте дә шушы вакыйгадан соң башланган ич. Ә Урал-суның аргы якларында яшәгән казах кардәшләребез исә бераз иртәрәк, XIX гасырның кырыгынчы елларында ук әлеге зур мәмләкәткә килеп «кушылган» була. Әмма бу тынгысыз, ирек сөючән халык тик тормаган. Без – зур халык, көчле халык, безгә Европа илләрендәге кебек автономия тәртипләре бирелергә тиеш, дип дәгъвалаучылар да булган. Әйтик, Казанда император университетын тәмамлаган адвокат Бәхтиҗан Каратаев 1906 елда ук «Фикер» газетасында шундый таләп куйган мәкаләсен бастыра. Европа илләрендә йөреп, төрле институт-академияләрдә күренгәләп киткән казах Алибай Җангилдин, төрмә, «Себер университетлары»н үткән Аманкилде Иманов

белән Турар Рыскуловларның таләпләре дә шуңа охшашрак була. Аларны тиз арада большевиклар фиркасенә дә кабул итәләр. 1916 ел башында патша хакимияте Урта Азия халыкларын да тыл хезмәтенә мобилизацияләү карарын чыгаргач, шул коммунистлар җитәкчелегендә казах халкы баш күтәрә. Аларга өлешчә үзбәк һәм кыргыз вәкилләре дә кушыла. Ә бер елдан соң бөтен илдә халык мәнфәгатен яклардай яңа хакимият барлыкка килә. Һәм бу хакимият Б. Каратаев, А. Җангилдин, Т. Рыскуловлар таләпләрен искә алгандай – 1918 елның 30 апрелендә үк Төркестан Автономияле Совет Республикасын оештыру карарын чыгара. Бу республика биләмәсенә хәзерге Казахстанның шактый өлеше, Кыргызстан белән Үзбәкстанның төньяк өлкәләре кергән. Башкаласы итеп Ташкент шәһәре билгеләнгән. Төрле дәүләти оешмаларның җитәкчеләре рәвешендә безнең милләт вәкилләреннән күп кенә коммунистлар да шунда җәлеп ителә. Шул җитәкчеләр төркеменә Оренбургтагы «Хөсәения», «Вәлия» мәдрәсәләренең элекке шәкертләреннән Кәрим Хәкимов, Шәһит Әхмәдиев, Габдулла Мостакаевлар да керә. Автономиянең Халык мәгарифе комиссариатын Г. Ибраһимовның шәриктәше Шәһит Әхмәдиев җитәкли. 1919 елда оештырылган Халык мәгарифе институты директоры вазифасын татар Габдулла Мостакаев башкара.

Габдулла Тукай әсәрләренең беренче русча китабын нәшер итүдә Шәһит Әхмәдиевнең дә өлеше зурдыр, мөгаен. 1910 еллардан башлап «Шура» журналында күп кенә хезмәтләр бастырган Габдулла Мостакаев та ул эштән читтә калмагандыр. Ә әлеге китапны туплап чыгарган Ибнеәмин Янбаев исә шушы ике шәхес җитәкләгән комиссариат вәкиле булган.

Ташкент якларына юлга җыенганда Булат улыма йөкләнгән тагын бер йомышым булды. 1980 елларда Үзбәкстан Фәннәр академиясенә буйсынулы бер институт нәшер иткән альманахта Салих Сәйдәшев исеме теркәлгән бер хезмәт тә басылып чыккан иде. Татбригада төркеме белән Ташкентта булганда, 1920 яки 1921 елда ул Үзбәкстанның классик әдибе, шагыйрь һәм драматург Хәмзә Хәкимзадә Ниязи (1889–1929) белән бергә бер пьесаны сәхнәләштерү вакыйгаларында катнашты, дип язылган иде ул альманахта. Булат улыма мин шул вакыйганы да ачыкларга тырыш әле, дигән идем. Безнең белешмәлекләрдә, шул исәптән энциклопедия томнарында да Салих Сәйдәшевнең Татбригада төркеме белән Оренбург шәһәрендә булганлыгы гына хәбәр ителә, Ташкент чоры искә алынмый. Булат әлегә бу мәсьәләне ачыклый алмаган. Кыска вакытлы сәфәр барышында андый эшне башкарып чыгу җиңел эш түгел. Ташкентта яшәүче милләттәшләребез аңа, әлеге альманахны табарга тырышачакбыз, дип ышандырганнар.

Әйе, әлегә тарихчы Б. Хәмидуллинның шушы сәяхәт барышында ирешелгән уңышларының берсе – Габдулла Тукайның

бер гасыр элек Ташкентта чыккан китабының күчермәсен кабат Казанга кайтару.

1920–1930 елларда безнең байтак кына шәхесләребез Урта Азиянең башка төбәкләрендә дә бик җаваплы эшләр башкарганнар. 1925–1930 еллар арасында Үзбәкстан Республикасының башкаласы булып торган Сәмәрканд шәһәрен дә ешрак искә аласы иде. Үзбәкстан дәүләт университеты да башлап шунда ачылган. Аның беренче укытучы һәм галимнәре арасында да безнең милләттәшләребез булган. «Казан утлары» журналында мин Урта гасырларның классик шагыйре Галишер Нәвои иҗатына багышлап докторлык диссертациясе язган профессор Габдрахман Сәгъди турында хәбәр иткән идем. Шул ук университетта Кәрәмәтулла Айдаров та укыткан. Аның җитди хезмәтләре исемлегендә хәзерге Һиндстан империясен нигезләгән, чыгышы буенча Алтын Урда ханнары нәселеннән (Аксак Тимернең җәмәгате ягыннан) булган Заһретдин Бабурга багышлылары бар, дип хәбәр иткән иде миңа 1984 елда бу галимнең туганы Кәримә апа. Күптән мәрхүмә булган Кәримә апа күренекле шагыйрь Һибәтулла Салиховның оныкчасы иде. (Бабур Һиндстанда зур дәүләт оештыргач, аны «Моголлар империясе» дип атаячаклар.)

Һибәтулла хәзрәтнең беренче хатыны Айдаров морзалар нәселеннән булган. Кәрәмәтулла шул нәсел вәкиле икән. «Аның үз җәмәгате дә Ишми ишан кызы иде бит. Шуңа күрә дә яратмадылар аны Казан кешеләре», – дип тә өстәгән иде Кәримә апа. Димәк, милләттәшебез К. Айдаров Совет хакимияте елларында Бабур шаһның тормыш вакыйгаларын чагылдырган «Бабурнамә» китабын һәм шигъри уй-фикерләре тупланган «Мөбәйян» җыентыгын тикшереп, Совет хакимияте чорында беренче бәя бирүчеләрдән булган. Бәлки әле, Бабурның кече кызы Гөлбәдам Бегимнең өлкән абыйсына – атасының варисына багышланган «Хомаюннамә» китабын барлаучы да ул булгандыр. Безнең галимнәребез исә Ишми ишан киявенең хезмәтләрен түгел, әлегә үзен дә искә алмыйлар. Хәер, шуның нәтиҗәседер инде, «Татар энциклопедиясе»нең татарча 1 нче томында Бабурның икенче китабы бөтенләй телгә дә алынмаган (М. Әхмәтҗанов мәкаләсе). Йөз ел үткәч булса да, шушындый галимнәребезнең исемнәрен һәм кайбер хезмәтләрен үзебезгә кайтарырга вакыттыр дигән теләк белән тәмамлыйсы килә бу язмамны.

Үзбәк кардәшләребезнең берничә гасыр дәвамында тупланган архивларына галим Мәсгуд Гайнетдиновтан соң баручы булмады шикелле. Ә анда безнең тарихка да, әдәбиятка да кагылышлы байтак мәгълүмат саклана ич. Шунда «яткан» борынгы тарихи язмаларга да нигезләнеп иҗат ителгән бер җитди хезмәтнең язмышы да күңелне бик борчый әле. Әйе, академик Әбрар Кәримуллин тырышлыгы белән чирек гасыр элек шуннан кайтарылган бик кыйммәтле тарихи хезмәтне нәшер итү мәсьәләсе дә ачыкланмаган шул әле. Европалылар тарихында да билгеле бер

урын алган, грекларның атаклы тарихчылары Геродот хезмәтләрендә дә зурлап искә төшерелгән скиф кабиләләренә багышлы ул хезмәтне Әбрар ага 1990 еллардагы таркаулык чорында китап рәвешендә бастырып чыгарырга ирешә алмаган иде. Һәм ерак бабаларыбыз тарихына багышланган ул кулъязма шул дәвердән бирле хәрәкәтсез ята. Әйе, сүз өч ел дәвамында (1958–1961 еллар аралыгында) Казан университетында укыткан һәм «Кыйссаи Йосыф» поэмасының төрле чорда язылган унҗиде вариантын тикшереп фәнни хезмәт язган галим Җәвад Алмазның скифлар тарихына багышлы бик кыйммәтле кулъязмасы турында бара. Борынгы скифларга багышлы тема – бүген дә бөтен дөнья галимнәрен кызыксындырган тема ул. Европа һәм Азия музейларында шул скифлардан калган бик затлы һәм кыйммәтле меңләгән экспонат саклана. Шушы елларда гына әле Алтай төбәге төркиләре, борынгы скиф ханбикәсенең каберен ачкан өчен ил күләмендә шау-шу оештырып, аны кабат үз каберенә җирләүгә ирештеләр. Ә без шул ук борынгы скиф бабаларыбыз тарихына багышлы җитди бер хезмәтне чирек гасыр инде сандык төбендә яткырабыз.

*2019*

## ТУКАЙНЫҢ КАН КАРДӘШЛӘРЕ КЕМНӘР?

Шушы елның апрелендә бөек Тукаебызның тууына 136 ел тулачак. Аның вафат булуына да инде йөз елдан артыграк гомер үткән. Шулай булуга карамастан әле безнең көндәлек матбугат битләрендә дә, кайбер фәнни язмаларда да аның биографиясенә кагылышлы мәсьәләләрдә төгәлсезлекләр очраштыргалап тора. Әйтик, берничә ел элек кенә Габдулла Тукай исемендәге музейда олуг шагыйребезнең туганнарына багышланган бер очрашу булып узган иде. Шушы вакыйгада катнашкан бер газета хәбәрчесенең түбәндәге сүзләре мине Тукай һәм аның туганнары турында язылган истәлекләрне кабат кулга алырга мәҗбүр итте. «Тукайның әнисе Бибимәмдүдәнең апасы Сәҗидәнең нәселе зур», – дип яза бу автор мәкаләсендә. Һәм шул нәсел варисларыннан кайберләре Тукайның иң якын кардәшләре буларак санап та кителә. Танылган бер әдәбиятчы галимебез дә Г. Тукайга багышлап чыгарылган җитди генә бер китапта (Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты. – 2018. – 14 б.) шул ук фикерне кабатлый. «Әнисенең апасы Сәҗидәгә юллаган бер хатын ул шундый юллар белән башлап җибәрә», – дип яза. Кечкенә Апуштан җиде-сигез яшькә генә өлкәнрәк булган кыз Сәҗидә ни рәвешле «Бибимәмдүдәнең апасы»на әверелде икән? Г. Тукай да бит аны «Исемдә калганнар» дип аталган биографик язмасында «бер җитеп килә торган Сәҗидә исемле кыз» дип кенә таныштыра. Г. Тукайга багыш-

ланган күпчелек истәлек китапларда да бит шагыйрьнең бабасы Зиннәтулла йортына икенче хатын булып төшкән «үги әби»нең ул кызының туган елы да күрсәтелгән. Ул Саҗидә берничек тә Мәмдүдәнең апасы була алмый.

Мәмдүдәнең туган апасы яисә агасы, энесе булганлыгы хакында әлегрәк бер генә язмада да телгә алынмады шикелле. Риф Якуповның «Архивтагы язулар ни сөйли?» (1976) дип исемләнгән хезмәтендә дә Мәмдүдәнең Саҗидә исемле апасы булганлыгы турында хәбәр ителми. Димәк, әлеге мәкалә авторы да, хөрмәтле галимебез дә Мәмдүдәнең үз анасы вафат булганнан соң Зиннәтулла баба йортына ишле баласын ияртеп килгән үги ананың яшүсмер кызы Саҗидәне аңа «апа» дәрәҗәсенә күтәргән булып чыгалар. Тукайның анасына һәм Тукайга үги булган бу әбинең кайсы авыл кешесе икәнлеге һәм Зиннәтулла мулла йортына кайчан килүе, ничә бала ияртеп килүе дә әлегә галимнәребез тарафыннан ачыкланмаган. Китап нәшриятында бер очрашу вакытында Риф Якупов ул Латифа исемле хатынның шул ук Арча төбәгендәге Наласа авылы мулласының җәмәгате булуын сөйләгән иде. Ире бу дөньядан киткәч, аны балалары белән Зиннәтулла хәзрәт үзенә алган. Зиннәтулла мулла өенә «төшкәндә» бу хатынның ничә баласы булган соң? Тукай тормышын өйрәнүче галимнәребез әлегә аны ачыкламаган. Наласа авылы мулласы тутырган «загс» дәфтәрләре белән танышмаганнар. Шуңа күрә хәзер Латифадан туган, Тукайның «Истәлекләре...»ндә искә алынганча, «үги әбинең алты күгәрчене» арасыннан кемне Тукайның кан кардәше буларак кабул итә алабыз соң? Әлегә бу мәсьәлә ачыкланмаган. Алдарак искә алынган галим дә, алар барысы да Зиннәтулла мулланың үз авылы халкын исәпкә алучы дәфтәрендә үз балалары буларак теркәлгәннәр, дип акланмакчы. Әйе, Зиннәтулла мулла аларның элекке атадан туганнарын да үз баласы рәвешендә кабул иткән, үз кулы белән рәсми теркәлү дәфтәренә язып та куйгандыр. Русчалап әйтсәң, «усыновил» була инде. Ләкин аңа карап кына Наласа авылы мулласының балалары берничек тә Тукайга кан кардәш була алмый. Ә шул ук галимебез исә икенче бер язмасында ул хатынның алты баласын да Тукайга кан кардәшләр иде дип яза.

Риф Якупов әлеге очрашу вакытында: «Атасы Наласа хатынына өйләнер алдыннан Мәмдүдәнең анасы Камилә дә шул тирәләрдә гүргә иңдерелгән була», — дип әйткән һәм архив документлары белән танышуын дәвам итәчәген сөйләгән иде. Рифтан соң ул вакыйгага бәйле архив документлары белән кызыксынучы булмады шикелле. Һәм бүген ул Наласа авылы хатыныннан туган ничә баланың Тукайның якын кан кардәше булуын белүче юк. Зиннәтулла карт вафатыннан соң авыл мулласы вазифасын үтәгән, 1912 елның кышкы айларында Тукайны өендә кабул иткән Кәшфекәбир Зиннәтулла улы Әмировның шагыйрьгә кан кардәш булуында шик юк. Ул Апуштан ике яшь чамасы гына өлкәнрәк.

Аңардан ике-өч яшькә генә өлкәнрәк Гөлчәһрә белән Саҗидә дә, мөгаен, Зиннәтулла мулланың үз баласы булгандыр. Ә өлкәнрәк яшьтәгеләре исә әбинең үз күгәрченнәре арасына килеп кергән бер чәүкәне кыерсытырга гына торучылар исәбенә керәләрдер.

Ә бит Латифа карчык балаларына кагылышлы ул документларны ачыкларга бик кирәк. Югыйсә киләсе буын «галимнәре» дә Саҗидәне һаман Мәмдүдәнең апасы дип йөртәчәкләр.

* * *

Инде Тукйның үзенә сүз бирик. «Минем... үз әбием әни кыз чагында ук үлгән булганга, бабай кайсыдыр мулладандыр тол калган бер хатынны, аңар ияреп килгән алты баласы илә алган булган», – дип яза «Исемдә калганнар» китабында (Казан, 1909). Әйе, муллалар арасында элек андый гадәтнең очраштыргалавы турында башка истәлек язмалары да бар. Кайбер төбәкләрдә ул йола рәвешен алган. Кемнеңдер остазы саналган өлкәнрәк мулла вафат булгач, мөхтәрәм иткән кешесенең балаларын ятим итмәс өчен, яшьрәк мулла аның гаиләсен үзенә ала торган була. Күренекле әдибебез Сәйфи Кудаш та бер хезмәтендә атаклы Зәйнулла хәзрәт Рәсүлевнең шулай эшләгәнлеген бәян итә. Яшьрәк чакта Зәйнулла ишан ике остазыннан тол калган ике хатынга йортка кергән дип яза. Тукайның бабасы да, бәлки, шулай эшләгәндер. Әлегә шул хакта бернинди мәгълүмат та юк. Латифаның элекке ире белән алар элек аралашканмы? Бер-берсен хөрмәт итешкәнме? Белүче юк.

Бер атадан булган Газизә апасы истәлекләрендә язылуынча, аталары вафат булгач, алар киләсе елның яз ахырларынача бергә яшәгәннәр: Мәмдүдә, Газизә һәм Апуш. Газизә – Габдулладан тугыз яшькә өлкәнрәк бала. Димәк, Латифа кызы Саҗидә белән бер чамадарак яшьтә була. 1886 елның көзенә табарак Газизәнең туган абыйсын – унбиш яшьләр чамасындагы Мөхәммәдшәрифне Гариф мулланың энесе шундук үзләренә ала. Берәр елдан соң ул, Казанда «хәрчәвнә»дә эшләгәндә салкын тидереп, вафат булачак. Ә Газизә энесе белән бергә үткәргән җиде-сигез айны болайрак искә ала: «Әтидән соң Габдулланың анасы белән тордым... Яхшы гына тәрбияләп, үз итәргә тырышты. Ләкин язын... Хәерлебанат җиңги, котыртып, мине үзләренә алды», – дип яза Газизә. Ә өчәү яшәгән чорны аерым тасвирлап тормый. Ничек яшәгәннәр? Савым сыерлары булганмы? Ничек тукланганнар? Әллә соң авыл халкы сәдака рәвешендә китергәләп торган ризык белән генә көн-төннәрен үткәргәннәрме? Газизә яза бит: әтинең туганнары, боларга сәдака күп килә дип, язга таба мине үзләренә алдылар, ди. Бәлки, шуннан соң Мәмдүдә, улын күтәреп, үз авылына кайтып киткәндер. Тукай да бабасы йортына беренче кайту вакыйгасын тәфсилләп язмый. Безнең әдәбиятта да ул чор сикертебрәк үтелә бугай. Ул чорга караган истәлекләрне укы-

ганда, Мәмдүдәнең ирен җирләгәч үк атасы өенә кайтып киткән кебек хис кала.

Тукай истәлекләрендә анасы вафат булганнан соң Зиннәтулла бабасы йортына ике мәртәбә кайтарылу вакыйгасы теркәлгән. Беренче мәртәбә өч яше тулмастан аны Сасна Пүчинкәсе авылыннан – үги атасы йортыннан кайтаралар. Шуннан соң, бабасының Өчиле авылында озак яшәмәстән, аны кемгә дә булса асрамага бирергә дип, Казанга озаталар.

Г. Тукай бу вакыйганы болайрак тасвир итә. «Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган, һәрничек мин бу гаиләгә сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, мине Казанга озаткан… Печән базарында «Асрамага бала бирәм, кем ала?» дип кычкырып белдерергә». Мәрхәмәтле гаилә табыла. Алар кечкенә Апушны сөеп-назлап тәрбияли башлыйлар. Шуннан алдагы кышта Казанга, әнисенең сеңлесе гаиләсенә тәрбиягә алынган кече Газизә дә энесенең хәлен белергә дип бу гаиләгә килә. Энесенең чиста киенеп, яшәешеннән канәгать булуын күреп, сөенеп кайтып китә. Әмма бу бәхетле көннәр дә нәни Апуш өчен бик тиз төгәлләнә шул.

Асрамага алган ата-анасы авырый башлагач, аны яңадан бабасы йортына, «алты күгәрчен» гомер иткән «оя»га кайтарып бирәләр. Бу вакытта инде аңа бишенче яшь киткән була.

Казаннан кайткач, бабасы йортында ул бер кыш чыга бугай. Аннары аны тагын чит-ят кешеләр кулына – Кырлай авылы кешесенә асрамага биреп җибәрәләр. Икенче дәвер вакыйгалары инде аның «Исемдә калганнар» китабы битләрендә бик җентекләп тасвир ителгән. Шунда ук бабасы тормышына кагылышлы хәлләрне дә тасвирлап ала. «Өчиле авылы бик кечкенә вә ярлы авыл. Шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык була… Бабайның көн күрмеше бик начар булган… Үги әбинең алты күгәрчене эчендә мин бер чәүкә булганга, җыласам – юатучы, иркәләнәм дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган. Мине эткәннәр дә төрткәннәр…»

Авылда Мәмдүдәнең үз туганнары булса, әлбәттә инде, ятим Апушны үги балалар арасында калдырмыйча, мөгаен, үзләренә алган булырлар иде. Истәлекләрдән шәйләнгәнчә, Мәмдүдәнең бу авылда якын туганнары булмаган сыман. Яки алар Зиннәтулла хәзрәттән аның оныгын сорап алырга оялганнардыр. Тукай биографиясен өйрәнүчеләр нишләптер бу мәсьәләгә кагылмаганнар шикелле.

Зиннәтулла баба йортына үз балаларын алып килгән Латифаның Саҗидә исемле кызы кем баласы? Ни сәбәпле ул гына кечкенә Апушны үз итә? Әдәбият галимнәре аны 1870 еллар ахырындарак туган кызчык буларак тасвирлый. «Авырсам, бу гаиләдә һәммәсе, җитеп килә торган кыз Саҗидәдән башкасы, «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде» дип кенә караганнар. Саҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә мине җуатканын вә сөйгәнен,

әби килә башлагач, минем белән эше юк шикелле үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм. Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә аппак бер фәрештә күренә», – дип яза шагыйрь «Исемдә калганнар» хатирәсендә.

Г. Тукай, үз истәлек язмасында ул көннәрне «үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә… мине кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә, төрткәннәр» дип, тикмәгә генә язмагандыр. Әйе, ул истәлек язмасында фәкать шушы яшүсмер кыз Саҗидә генә аңа карата мәрхәмәтлелек күрсәтүче бер җан буларак телгә алына. Ә Гөлчәһрә белән Кәшфелкәбир, ул чорда әле сабый бала булганлыктан, бәләкәй Апушны кыерсытучылар рәтенә дә, яклаучы Саҗидә сафына да кермәгәннәрдер.

* * *

2015 елның 17 май көнендә телевизордан күрсәтелгән «Мәдәният дөньясында» тапшыруында да сүз олуг Тукаебызның якыннарын искә алуга багышланган иде. Әмма ул тапшыруда катнашучылар да, нигездә, әлеге үги әби балаларын, ягъни «яңа туганнар»ны һәм аларның варисларын гына искә алдылар. Габдулла Тукайның иң якын кан кардәшләре булган ике Газизә апасы турында ул тапшыруда сүз әйтүче табылмады. Ул Газизәләрнең балалары да искә алынмады диярлек. Чынлыкта исә нәкъ шушы ике Газизә «ятим, үксез Апушны» илкүләм танылган шагыйрь Габдулла Тукай буларак тәрбияләгән кешеләр ич. Аларның ярдәме булмаса, Тукай, мөгаен, Казан арты авылларының берсендәге «уңган, белемле бер хәлфә» дәрәҗәсеннән югарыракка күтәрелә дә алмас иде. Газизә апалары тырышлыгы белән ул Уральск шәһәренә чакырып китерелә. Андагы алдынгы мәдрәсәдә укый.

Бер атадан булган кече Газизә апасы истәлекләренә күз төшерик. Мөхәммәтгариф мулланың бертуган сеңлесе булган олы Газизә баштарак кече Газизәне бу шәһәргә чакырып китерә. Шуннан соң кече Газизә, җае чыккан саен, апасы белән җизнәсе алдында чит кешеләр кулында тәрбияләнүче энесе Апушны искә ала торган була. Бердәнбер уллары вафат булганнан соң, Госмановлар гаиләсе Апушны да үзләренә алырга карар кылалар. 1895 елның кышында, тугыз яшь тулганда, Тукай шушы гаиләгә килеп сыена. Арча төбәгеннән чыккан сәүдәгәр Галиәсгар Госманов шул елның көзендә каенесен шәһәрнең иң абруйлы мәдрәсәсенә укырга урнаштыра. Россиядә яшәгән белемле кеше рус телен дә үзләштерергә тиеш дигән фикердә булып, киләсе көздә үк аны өч сыйныфлы рус мәктәбенә дә бирәләр. Бу ике уку йортын да Тукай бик уңышлы тәмамлап чыга. Мәдрәсәдә укыткан хәлфәсе Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин истәлекләреннән күренгәнчә, Тукай яшьли «Әхмәтша учитель» китапханәсеннән

Пушкин, Лермонтов, Крылов һәм башка рус әдипләре әсәрләрен алып укырга да күнеккән була. Ирле-хатынлы йорт хезмәтчеләре тоткан Госмановлар гаиләсендә аңа укудан башка эш кушмыйлар диярлек. Ара-тирә вак-төяк йомыш үтәүләрне исәпләмәгәндә.

Каһирәдәге «Әл-Әзһар» университетын тәмамлаган аталы-уллы Төхфәтуллиннарның «Мотыйгия» мәдрәсәсен дә искә алып үтик. XIX гасыр ахырларында шул төбәктә ул иң алдынгы карашлы мәдрәсәләрнең берсе була. Истәлекләрдән күренгәнчә, бу мәдрәсәдә Мотыйгулла хәзрәт алдынгырак карашлы шәкертләре алдында Шәрыкның бөек шагыйрьләре әсәрләрен дә искә төшергәләгән, «гыйльме гаруз» китапларыннан дәресләр дә биргән. Йә, әйтегез, тагын кайсы мәдрәсәнең мулласы гыйльме гарузны – шигырь төзелешенә кагылышлы китапларны укыткан? Әйе, Тукайның бөек шагыйрь булып җитешүендә бу мәдрәсәнең урыны бик югарыдыр. Димәк, шунда укырга биргән Газизә апасы белән җизнәсенең дә бу уңышта өлеше зур. Ә бүгенге әдәбият фәнендә әлегә шул Газизә апалары һәм аларның балалары һаман да бер читтәрәк кала сыман. Әйтик, 1986 елда нәшер ителгән томлыклардагы искәрмәләрдә хәтта өлкән Газизә апасының туган һәм вафат булган еллары да күрсәтелмәгән. Димәк, аны ачыкларга теләүче табылмаган. Шушы Газизәдән туган, дистә елга якын чорда шәкерт Тукай белән көн дә диярлек аралашкан ике кызның – шагыйрьнең апаларының исемнәре дә бик сирәк искә алына. Кече Газизәнең оныкчасы, республикабызның танылган архитекторы Әлфия Хөсәен кызы өлкән Газизә варислары белән элек элемтәм бар иде, дип сөйләгән иде. «Эшем бик мәшәкатьле булды. Тора-бара аралар өзелде», – дигән иде ул берничә ел элек. Өлкән Газизәнең бер оныкчасы Казанда югары белем алып, үз якларына кайтып киткәнче кече Газизәләргә бик еш килеп йөргән була. Шул чакта алар Тукайның кайбер шуклыкларын да искә ала торган булалар…

Ә бит өлкән Газизәнең варисларын Уральск халкы белгән, хәтерләгән булгандыр. Хәзергә исә аларның истәлекләре дә тупланмаган. Ә берничә ел элек әле бер журналист Тукайның өлкән Газизә апасын «усал үги җиңги» рәвешендә дә тасвирлап язып чыккан иде. Имеш, ире, Тукайның агасы үлгәч тә, шушы «усал җиңги Газизә» аны өеннән мәдрәсәнең тулай торагына куып җибәргән икән. Дөрес, бу очракта әлеге журналист та гаепле түгел сыман. Әлеге хаталы хәбәрне ул кемнеңдер истәлек язмаларыннан күчереп укучыга хәбәр иткән. Шушы күңелсез очрак та бөек шагыйребезнең иң якын, иң кадерле кан кардәшләре булган Газизә апалары белән бәйләнешләрнең ныклап өйрәнелмәгәнлеге билгесе ич.

Ә кече Газизәнең ике оныкчасы – Наилә белән Әлфия – балачактан бирле диярлек Казанда гомер итәләр. Газизә әбиләре тәрбиясен күреп үскәннәр. Ләкин нишләптер Г. Тукай тормышын өйрәнүче галимнәребез алар белән аралашмыйлар диярлек. Ата-

ларының алтмышынчы елларда бер газетада басылган истәлеген дә искә алмыйлар. Ә бит Тукай Уральскида яшәгән чакта апасының нәкъ шушы улын карашуы турында яза. Аны үзем укытачакмын, дип тә вәгъдә биргән була.

* * *

Тукайның якын кан кардәшләренең кемнәр булуын күптән ачыкларга вакыт. Ул исемлеккә һич кенә дә Латифа исемле хатынга ияреп Зиннәтулла мулла өенә килгән «алты күгәрчен»не дә кертеп булмый. Алты санының бер өлеше генә аңа туган була.

«Исемдә калганнар» китабында сурәтләнгән вакыйгалардан без әлегә Саҗидә исемле мәрхәмәтле кызчыкның төгәл кем баласы булганлыгын белә алмыйбыз. Әлегә ул да укучы тарафыннан «үги әби»гә ияреп килгән бала кебек кабул ителә. Ул өйдә, бәлки, аннан өлкәнрәк кызлар да булгандыр. Ләкин ул йортта нәни Апушны яшүсмер кыз Саҗидә кебек үз итүче башка берәү дә булмаган. Шуңа күрә дә күңеле белән һәркем аны ятим Тукайның якын туганы, фәрештәсе рәвешендәрәк кабул итә. Тукай аңа Уральскида яшәгән елларында бер-ике мәртәбә хат та язган була. Ә Казанга кайткач, хәрби хезмәткә каралу өчен Әтнәгә барганда, аларда берничә кич кунып та йөргән.

Әйе, Саҗидә апасы һәм аның варислары олылауларга бик лаек кешеләр. Аның варислары да үзләрен Тукайның кан кардәшләре исәбендә йөртергә хаклыдыр дип кабул итик.

Шушы ук үги әбидән туган Кәшфелкәбир – Өчиле авылының булачак мулласы Кәбир Әмировны алдарак Тукайдан ике яшь чамасы гына өлкәнрәк дигән идек. Димәк, туган елыннан чыгып исәпләгәндә, ул инде тәгаен Зиннәтулла мулланың үз баласы булырга тиештер. Авыруы көчәйгән бер кышның ике-өч аен Г. Тукай шушы туганының җылы өендә үткәрә. Һәм шул хакта соңрак сагынып, искә алып язып та чыга. Шулай булгач, мулла Кәбир нәселе дә шагыйрьнең кан кардәшләре исемлегендә булырга тиеш. Ләкин алар да нишләптер бик исәпкә алынмыйлар шикелле.

Ә кырыс холыклы Латифага ияреп килгән нәни Апушны «эткәләгән дә төрткәләгән» тагын берничә җанны нинди исемлеккә кертергә соң? Миңа калса, алар шагыйрьнең кан кардәшләре исемлегеннән башка бер төркемдә йөртелергә тиешләрдер. Алар бит берничә ай дәвамында, Апушны Казанга яки Кырлайга озатканчы гына аның белән бергә булганнар. Алар Зиннәтулла мулла өчен дә үги балалар. Гәрчә ул аларны, үз балаларым дип, шушы Өчиле авылында туган балаларны теркәү өчен генә дип һәр муллага бирелә торган рәсми дәфтәргә (шул чорның «загс кенәгәсе»нә) үзеннән туган балалар рәвешендә язып куйган булса да…

*2015–2021*

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ СИКӘЛТӘЛӘРЕ

*(Очерк)*

Миңа Галимҗан Ибраһимовның сөекле җәмәгате Өммегөлсем (Гөлсем) апа Мөхәммәдова белән утыз ел чамасы аралашкалап яшәргә туры килде. Ул Сәмәрканд каласыннан Казанга күчеп килгән чорда мин Татарстан Язучылар оешмасында эшли идем. Соңрак аның олуг әдипнең иҗади вә сәяси эшчәнлеген һәм гаилә тормышын чагылдырган өч документаль повестен китап рәвешенә китереп нәшер итүче мөхәррир дә мин булдым (Эзләнүләр. — 1987. — 375 б.; Олы юл. — 1994. — 271 б.).

* * *

Галимҗан Ибраһимов 1887 елның март аенда хәзерге Башкортстанның Солтанморат авылында туган. Уникенче яшендә аны әтисе Оренбург каласындагы «Вәлия» мәдрәсәсенә укырга алып килә — заманча белемле муллалар әзерләүче уку йортына. Нәкъ шул елда «Вәлия»нең башлыгы итеп чит илдә укып кайткан Мөхәммәдвәли Хөсәенев билгеләнгән була. Казан артындагы «Кышкар» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, ул берничә ел Гарәбстанда укыган. Атасы Оренбургның бай сәүдәгәре — шул төбәктә үз исәбенә яңача (җәдидчә) укытуга йөз тоткан берничә дистә мәктәп-мәдрәсә ачкан һәм тоткан, җәй айларында укытучылар белемен күтәрү курсларын оештырган Гани бай.

Яшүсмер Галимҗан бу калага килеп укыган елларны татар әдәбиятының монда гөрләп үсеш алган чоры дияргә була. Оренбургтан унсигез чакрым арада урнашкан Каргалыда яшәп иҗат иткән күренекле шагыйрьләр Гомәр Мөхәммәд белән Һибәтулла Салихов эзе суынып өлгермәстән монда Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев кебек яңа чор шагыйрьләре калкып чыга. Фатих Кәрими, Ярулла Вәли, Тимерша Саллави һ. б. әдипләрнең хикәя-повестьлары әүвәл бу шәһәрдәге Б. Бреслин типографиясендә басылса, 1901 ел башыннан биредә Фатих Кәрими атасының үз басмаханәсе эшкә керешә. Нәкъ шушы чорда Риза хәзрәт Фәхретдиннең дә башка кеше исеме белән нәшер ителгән ике мавыктыргыч әчтәлекле повесте — «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) белән «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) да укучылар күңелен җәлеп итәчәк. «Әсма» әсәре шулай ук Кәримовлар типографиясендә басылган. Ф. Кәриминең Исмәгыйль Гаспринский биографиясенә бәйле рәвештә иҗат ителгән «Морза кызы Фатыйма» повесте да 1901 елда үз басмаханәләрендә нәшер ителә. Бу әсәрләр яшьләр арасында бик тиз таралган. Яшүсмер Галимҗанның мәдрәсәдә укыган еллары нәкъ шушы чорга туры килә.

Мәдрәсә башлыгы Вәли Хөсәенев тә шәһәргә кайтып төпләнү белән үк диярлек үз типографиясен булдыруга керешә, дини һәм

гаилә тәрбиясенә йөз тоткан «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгарырга рөхсәт ала. Совет хакимияте чорында «Вәли мулла»ның бу эшләре еш тәнкыйтьләнде. «Аның тарафыннан нәшер ителгән басмалар фәкать дини юнәлешле иде», – диелде. Китап басу тарихын барлаган галим Әбрар Кәримуллин хәбәр итүенчә, «Дин вә мәгыйшәт» басмаханәсендә 1918 елгача 104 китап нәшер ителә, шулардан кырыгы гына дини эчтәлекле була. Ул типографиядә күләмле әдәби һәм иҗтимагый эчтәлекле әсәрләр дә, татар, казах шагыйрьләренең аерым җыентыклары да басылган.

Башлангыч чорда Вәли мулланың нәшрият эшчәнлегенә бәйле киңәшчесе укымышлы Морад Рәмзи булганлыгын да истә тотарга кирәк. Ул да Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң берничә ел гарәп дөньясының үзәгендә яшәп, белем өстәп кайткан шәхес. Мәдинә каласында бер чорда укыган дусты Вәли чакыруы буенча Оренбургка килә, аның нәшрият эшен җайга салышу, әлеге журналны нәшер итешүдә катнаша. Ә 1908 елда бу типографиядә аның Казан вә Болгар ханлыклары тарихына багышланган икетомлык китабы да басыла. Ләкин патша хакимияте вәкилләре ул томнарны сатуга чыгармый, юк итәргә боерык бирә. Морад Рәмзинең шул тарихи хезмәтенең сыгынтысын гына булса да бастырып чыгарсаң бүген дә зыян итмәс иде. Хәзер Кытай илендә яшәгән варисларында аның бай мирасы саклануы мәгълүм. 2015 елда шул хакта миңа аның Казанга килгән оныгы сөйләгән иде.

Әйе, Галимҗан килеп укый башлаган елларда Оренбург Казаннан кала икенче бер әдәби үзәккә әверелгән була. 1902 елда бу шәһәргә, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытырга дип, әдәбият сөючеләр арасында танылып өлгергән язучы Гаяз Исхакый да килә. Шакирҗан агасы укыган ул мәдрәсәдә Галимҗан еш була. Һәм тиздән ул Гаяз Исхакый белән аралаша башлый. Кайбер истәлекләрдә «алар дуслар булып китәләр» дигән сүзләр дә очрый. Галимҗанның соңрак эсерлар партиясе вәкиленә әверелүен дә шушы танышлыкка бәйләүчеләр бар. Әмма Совет хакимияте чорында «ак эмигрант» Гаяз Исхакый белән Галимҗан Ибраһимовны якынайтмаска тырышылды.

Г. Исхакый нәкъ менә «Хөсәения»дә укыткан елларында «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) әсәрен иҗат итәчәк. Шул ук мәдрәсәдә укыткан Сәгыйть Рәмиев белән дә дуслашып, соңрак аны Казанга ук «тартып» китерәчәк.

Атаклы мәдрәсәдә укып, ата-бабалары кебек абруйлы мулла буласы шәкерт Галимҗанның олуг әдип булып китү серләре менә шушы вакыйгаларга бәйле. Ә Совет хакимияте елларында «иске бер мәдрәсә» исемлегендә йөртелгән «Вәлия»нең элек бик абруйлы уку йорты булуы тарихи документларда теркәлгән. Анда казах иле хан-солтан балалары да белем алган. Россия мөселманнары идарәсен (мөфтиятне) оештыру карарын чыгарган патша Екатерина Икенче чорында Оренбургның Беренче мәчете кара-

магындагы бу мәдрәсәгә хөкүмәт күпмедер акча да биреп тора. (Бу гамәл, әлбәттә инде, чик буе Урал-суның аргы ягындагы казах ханлыклары хан-солтаннарын юмалау өчен эшләнгәндер.) Вәли Хөсәенев чорында инде ул, әлбәттә, Гани байдан калган мирас исәбенә яши. Галимҗанның шәриктәше һәм гомерлек дусты Шәһит Әхмәдиев тә шул хакта искә ала – яшәешебез өлешчә авылдан килгәне белән булды, калганы Вәли бай исәбенә иде, ди. Галимҗанның шәһәрдән өч йөз чакрымда урнашкан авылыннан килеме күп булмагандыр инде.

* * *

Тумыштан фикерләү сәләте булган, «Вәлия»дә уку елларында әдәби һәм тарихи эчтәлекле китаплар укуга байтак вакытын сарыф иткән Галимҗан шәкертнең иҗади үсеше гаять тә кызыклы һәм гыйбрәтле. 1907 елда беренче әдәби әсәрен – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясен – Казан матбугатында бастырып чыгару бәхетен татыган егерме яшьлек егет ун ел үтмәстән классик әдип дәрәҗәсенә ирешәчәк. Шул дәвернең иң яратып укылган әсәрләреннән саналган «Яшь йөрәкләр» романын иҗат итеп бастырганда (1912) әле аңа егерме биш яшь кенә булачак. Тагын ике елдан соң ул «Безнең көннәр» романын язып төгәлләячәк.

Шул ук 1910 еллар башында Галимҗанның берничә хикәясе һәм тел, милләт мәсьәләсенә кагылышлы мәкаләләре бертуган Рәмиевләр нәшер иткән атаклы «Шура» журналы укучыларына да тәкъдим ителә. Аннары ул хикәяләр Рәмиевләрнең «Вакыт» нәшриятында аерым китаплар рәвешендә басылып та чыгачак. «Казакъ кызы» исемендәге роман буларак 1924 елда дөнья күрәчәк әсәренең тәүге варианты да Рәмиевләр басмаханәсенә җибәрелгән була. Ул әсәр кульязмасы, «Буби» мәдрәсәсе вакыйгасына бәйле рәвештә тентүләр оештырылганда, башка язмалар белән бергә кулга алына, юк ителә.

Әдип шул елның көзендә атаклы Касыйм төбәге сәүдәгәрләре Максудовларның Киевта яшәүче бер гаиләсенең балаларын укыту нияте белән шунда чакырыла. Аны анда барырга димләүче Каюм Мостакаев була. Татарстан Милли архивының Фатих Кәримигә багышлы фондында саклanучы бер хатта әдипнең Киевтан Дәрдемәндкә тагын бер күләмле кульязма җибәргәнлеге турында хәбәр бар. Шул ук 1912 елда әлеге кульязманы алуы һәм хуплавы турында Дәрдемәндтән Галимҗанга хат килгәнлеге дә Каюм аганың истәлегендә хәбәр ителә. (1960 елларда Каюм ага Казанда яшәде. Восстания урамындагы әдип исемен йөртүче мәктәптә аның белән бер очрашу булганын хәтерлим.)

1913 елның апрелендә революцион юнәлешле бер шаулы җыенда катнашкан мөселман студентлар, шул исәптән әдипнең якташы, студент Хәлил Еникиев белән бергә Галимҗан да кулга

алына. Шунда әдипнең яңабаштан яза башлаган «Казакъ кызы» әсәренең бер өлеше дә юкка чыга. Шушы мисаллар әдипнең унынчы елларда тынгысыз рәвештә әсәрләр иҗат итү белән генә мәшгуль булуын, вакытын башка сәбәпләргә сарыф итмәгәнлеген күрсәтә.

1917 елгы революция вакыйгалары чорын Галимҗан Уфада каршы ала. «Галия» мәдрәсәсендә укыту белән бер үк вакытта ул язучы Фатих Сәйфи-Казанлы белән бергә сул эсерлар рухындагы «Ирек», «Безнең юл» газеталарын нәшер итә. Шул елның декабрендә башкорт зыялыларының үз автономияләрен төзү нияте белән оештырган корылтаенда катнаша. Ул корылтайга әдип белән бергә барган журналист Исмәгыйль Рәмиев хәтерләвенчә, Галимҗан ул милли җыенда үзен бик актив тота. Уртак татар-башкорт автономияле республикасын оештыру кирәклеге турындагы фикерен белдерә. Ә киләсе ел башында Казанда һәм Мәскәүдә уздырылган шундый ук милли җыеннарында да ул алгы сафтагылар рәтендә була. Һәм бераздан соң Мулланур Вахитов белән бергә Мәскәүдә яңа оешкан Үзәк мөселман комиссариатын җитәкли. Бердәм башкорт-татар милли автономиясен булдыруга кагылышлы җыелышларны төрле төбәктә оештыручыларның берсе була.

1918 елның июлендә сул эсерлар большевикларга каршы фетнә оештыргач кына ул илдә барган сәяси хәрәкәттән бераз читләшеп торырга мәҗбүр ителә. Казах кардәшләребез иленең көнчыгыш тарафында урнашкан Кызылъяр шәһәренә таба аңлашылмаган бер сәфәр кыла. Дүрт айга сузылган бу сәфәр 1919 елның җәйге чорына туры килә. Совет хакимияте дәверендә ул сәфәрне галимнәребез «Адмирал Колчак гаскәрләре тылына оештырылган разведка» рәвешендә бәяләде.

* * *

1919 елның көзендә Г. Ибраһимов янә Казанга кайта. Монда аңа әдәби эшчәнлеген дәвам итү мөмкинлеге тудырыла. Элек язган «Безнең көннәр» романын ул тиз арада нәшер итүгә керешә. Шул ук вакытта ул татар милли матбугатын торгызу эшендә дә җиң сызганып катнаша. «Эшче» газетасын нәшер итешүдә, «Мәгариф», «Безнең юл» журналларын нигезләүдә башлап йөрүче була. Ә 1922 елда «Татарстан» газетасына эшкә билгеләнә. «Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте»н оештыра. Әмма аның татар иҗтимагый фикерен үстерүгә керткән иң нәтиҗәле эшчәнлеге Гыйльми үзәкне җитәкләгән 1924–1927 еллар аралыгына туры киләдер. Шушы ике-өч елда ул башкалар дистә еллар дәвамында да ирешә алмаган эшләрне уңышлы башкарып чыгачак.

Менә шушындый киеренке иҗади һәм җәмгыяви эшчәнлек алып бару нәтиҗәсендә аның шәхси тормышы беркадәр «аксый

төшә» шикелле. 1915–1917 елларда Уфа шәһәрендәге «Галия» мәдрәсәсендә укытканда һәм аннан элгәрерәк аның гаилә корырга нияте булгандырмы, истәлекләрдә шул хакта мәгълүмат бик аз. Шул ук елларда «Галия»дә мөгаллимәләр курсында укучы Кызылъяр шәһәре кызы Хәдичә Фәтхуллина белән дустанә рәвештә аралашканлыгы турында гына хәбәрләр бар. Ләкин ул кыз, ил күләмендәге түнтәрелешләр башланганчы ук укуын тәмамлап, туган ягына кайтып китә. Г. Ибраһимов иҗатын һәм биографиясен барлауга күп көч куйган Афзал ага Шамов: «Аны соңрак бер муллага кияүгә биргәннәр», – дип искә ала иде. Шул Хәдичәнең Казанда яшәү чорында аның белән аралашкан кайберәүләр: «Әдип аңа соңрак үз китапларын җибәргәләп торган», – дип тә искә алдылар.

Ә 1934 елда әдип Ялтага шул Хәдичәне чакырып китерәчәк. Ул кулга алынгач та, Хәдичә янә Казахстанга кайтып китәчәк. Ә соңгы өч-дүрт елын ул Казанда яшәде, 1967 елда вафат булды.

Себер якларында йөреп кайтканнан соң, 1920–1922 елларда әдип берара Мәчтүрә исемле бер мөгаллимә белән яшәп ала. Ләкин ул ханым үзен бик ирекле тотарга яраткан. «Галимҗан аганың кырыс холкын, таләпчәнлеген кабул итә алмыйча, Уфага китеп барган», – дип искә ала иде Афзал ага. А. Шамов 1930 елларда нәшриятта эшләгәндә әдипнең берничә китабын нәшер итү чараларында катнаша. Ялтада дәваланучы автор белән даими рәвештә хатлар алышып тора. 1955 елда Г. Ибраһимовның аклану хәбәре алынгач та, әдипкә багышланган истәлекләрне оештырып бастыру, беренче өчтомлыгын нәшер итү вазифалары аңа йөкләтелгән була.

1923 елда Галимҗан Әстерхан шәһәреннән укырга дип килгән Өммегөлсем Мөхәммәдованы очрата. Әдәбиләштереп әйтсәк, аңа гашыйк була. Шул танышу озакламыйча аларны рәсмиләшеп кавышу нәтиҗәсенә китерәчәк.

XX гасырның әүвәлгерәк чорында Әстерхан төбәгеннән чыккан татар зыялылары да байтак кына була. Күренекле артистлардан Байкиннар династиясе, Зәйни Солтанов, язучылардан Газиз Иделле, Габдрахман Минский, Бари Рәхмәт, Галимҗанның шәриктәше, язучы Хөсни Кәрим җәмәгате Зәйнәп – шул өлкә вәкилләре.

Әдип сөеп, яратып «Гөлсем балакай» дип эндәшә торган булачак җәмәгате дә 1903 елның 19 сентябрендә шул шәһәрдә туган. Аның атасы Давыт Мөхәммәдов Идел белән Каспий суларында балык тоту кәсепчелеге белән шөгыльләнүчеләрнең көймә-корабларын төзүче һәм төзекләндерүче остаханә тоткан эшмәкәр була. Әстерхан татарлары арасында ул хәйрия җәмгыятен ачуда, төрле-төрле әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда танылган шәхес санала. Балаларын да шул әдәби-музыкаль кичәләргә алып баргалаган. Татар хатын-кызларыннан беренчеләр исәбендә Петербургта рәсми музыкаль белем алуга омтылган Мәрьям Искәндәрованы

Гөлсем апа еш искә ала иде. 1911 елда шәһәр күләмендә оештырылган концерттан соң, ул җырчы Давытлар өендәге мәҗлестә дә катнаша. Шәһәргә килгән башка дәрәҗәле кунаклар да алар йортын читләтеп үтми торган була. Сәгыйть Рәмиев тә шул шәһәрдә газета мөхәррире булганда алар өенең мансарда өлешендә яши. Габдулла Тукай да шәһәргә килгән беренче көннәрен Сәгыйть бүлмәсендә уздыра.

Өммегөлсем, башлангыч белемне татарча үзләштергәннән соң, шәһәр гимназиясендә русча укый. Укуын Казанда дәвам итәргә бик теләсә дә, Гражданнар сугышы дәвам итүе сәбәпле, башта хыялына ирешә алмый. Ике кыш татар мәктәбендә укыта. 1922 елда Казан университетының медицина факультетына укырга керә. «Казанга баручы пароходка утырганда бер кулымда чемодан, икенчесендә камыштан үрелгән зур сумка иде», – дип искә ала ул. Шул сумкада ризыклары, яңарак укый башлаган «Безнең көннәр» романы һәм Галимҗан Ибраһимовка тапшырырга дип бер танышлары биргән хат була.

Ул мәктәптә укыган елларында ук татар әдәбиятын, шул исәптән Г. Ибраһимов әсәрләрен дә даими рәвештә укыган була. Университетта укый башлагач та ул әдипкә тапшырырга тиешле хат барлыгын онытмый. Ләкин фатирдан-фатирга күчү вакытында ул хат юкка чыга. Галимҗанның университет студентлары белән очрашуыннан соң, ул аңа әлеге хатны югалтуы турында сөйләргә мәҗбүр була. Беренче танышу менә шул үкенү вакыйгасыннан башлана. Ә язга табарак әлеге хат иясе Казанга килә. Гөлсемнең укуы белән кызыксына. Кыз аңа унбиш кеше бер салкын бүлмәдә яшәгәнлекләрен сөйли. Язгы имтиханнарны уңышлы тапшыра алырмынмы икән, дигән шөбһәсен белдерә. Танышы аңа Галимҗан белән киңәшергә кирәклеген әйтә. Әдипнең фатирына – икенче совет йортына алар икәү баралар. Шул рәвешле икенче танышу, өчәүләп чәй эчү вакыйгасы була.

Җәйге каникул башланыр алдыннан, Өммегөлсем белән бер иптәш кызы тулай торактан китү, эшкә урнашу карарына киләләр. Хезмәт биржасында аңа, гимназияне уңышлы тәмамлаганлыгын истә тотып, бик җаваплы эш тәкъдим итәләр. «Миңа эш тиз табылды. Халык Комиссариаты Советына төрле рәсми документларны русчадан татарчага тәрҗемә итүче кирәк икән. Сынау шарты белән эшкә алырга булдылар. Юридик бүлек мөдире Ротенберг эш бирде. Күрше бүлмәдә утыручы тәрҗемәче белән таныштырды. Кирәккәндә ярдәм итәрсең, диде аңа. Беренче тәҗрибәләремне рецензент Мөхетдин Корбангалиев тә хуплады», – дип искә ала Гөлсем апа «Олы юл» китабында.

Бу чорда алар Галимҗан агасы белән шәһәр күләмендәге төрле чараларда бик еш очрашкалыйлар. Җәйнең көзгә таба авышкан бер көнендә Галимҗан алар яшәгән бүлмәгә килә. Бераз сөйләшеп утыргач та, кәгазь алып: «Син минем хатыным булырга ризамы?» – дип яза һәм шуны Гөлсемгә тоттыра. Гөлсем аптырап

кала, билгеле. Бераз тып-тын гына утыргач, әдип: «Җавапны өч көн көтәм», — дип әйтә дә чыгып ук китә. Өммегөлсем әдипнең бу тәкъдиме турында ике якын дустына хәбәр итмичә булдыра алмый, билгеле. Иң якын ахирәте саналган шәриктәш яшьтәше аңа: «Ике арада мәхәббәт булмагач, мин бармас идем», — диебрәк җавап бирә. Икенчесе, инде кияүдә булган Хәдичә исә: «Аңладым, мәхәббәт юк, фәкать үзара хөрмәт итешү генә бар, димәкче буласың… Ә Галимҗан агаң, Гөлсем, синнән олы булгач, үзеңне кадерләп, уч төбендә генә тотар. Син аны хөрмәт итәрсең, ә ул сине сөяр, иркәләр… Аның тәкъдимен кире какма!» — дип киңәш бирә.

Өч көн үтеп китә. Ә Гөлсем ни дип җавап бирәсен дә белмичә аптырап йөргәндә, төштән соңрак Галимҗан пәйда була. «Әйдә, киттекме?» — ди. Урамда, кеше арасында аңлашу җиңелрәк булыр дип, Гөлсем аңа иярә. Ә анда аларны шәп ат җигелгән затлы фаэтон көтә икән. Галимҗан агасы шәһәр урамнарын күрсәтәсе булган икән дип, кыз аның янәшәсенә менеп утыра. Атның елга порты тарафына атлыгып чабуын чамалагач, ул: «Без кая барабыз соң?» — дип сорау бирә. Галимҗан исә, елмаеп: «Елга портына», — ди.

Шул китүдән алар Иделнең аргы ягына — Югары Ослан тарафына барып чыгачаклар. Якын араларга йөрүче кечкенә пароходка утыргач кына Галимҗан агасы аңа кая барасыларын аңлатып бирәчәк. «Җитәкчеләрең белән сөйләшеп, сиңа ике атналык ял алдым. Ул көннәрне без шушындагы ял йортында уздырачакбыз. Шул арада син минем үтенечкә җавап бирергә тиешсең», — ди.

Әүвәл ун көнләп алар монда абыйлы-сеңелле рәвештә вакыт уздырачаклар. Кош-корт туктаусыз сайрашкан мондый урманны күреп үсмәгән, киң, иркен болын-басуларда йөрмәгән Өммегелсемгә мондагы табигать бик тә ошый. Идел буенда су чәчрәтеп коенулар да монда үзгә кебегрәк тоела башлый аңа. Шулай сәяхәтләр кылып аралаша-аралаша, Өммегөлсем күңелендә дә үзара ияләшү, якынлык хисләре туачак. Үзеннән күпкә өлкән кеше белән яшәргә ул ризалык бирү фикеренә киләчәк. Һәм ике атна ял иткәннән соң, алар Казанга яңа кавышкан пар буларак кайтачаклар. Шул көннәрдән башлап Галимҗан аңа һәрчак диярлек яратып «Гөлсем балакай» дип кенә дәшәчәк. Хәзерге Кремль урамындагы 21 нче йортның икенче этажындагы 33 нче санлы озынча тар бүлмәдә алар бергә яши башлаячаклар.

Иң элек аларның ничек яшәвен, тормыш-көнкүрешен күреп китәргә килүче Гөлсемнең апасы Гайшә була. Гөлсем аны үзе Әстерханнан чакырып китерә. Элек ялгызак ир яшәгән шыксызрак бүлмәне алар икәүләп тәртипкә китерәләр. Төрле урында, шул исәптән тәрәзә төбендә дә өелеп торган китапларны ике шкафка тутыралар. Апасы киткәч кенә әдип аңа: «Ул китапларның һәр төркеме аерым темага багышланган иде. Киләчәктә алай эшләмә», — диячәк.

Гайшә киткәч тә озак тормастан, Казанга әдипнең абыйсы Шакирҗан килеп төшә. Бертуганнарның капма-каршы урындыкка утырып, тезгә-тез куешып сәгатьләр дәвамында сөйләшүләре Гөлсем өчен бик кызык тоела... Шакирҗан ерак бер авылда укыта икән. Киемнәренең шактый таушалган икәнлеген күргәч тә Гөлсем аңа яңа костюм, аяк киеме алып бирәседер, бәлки, дип сүз башлый. Галимҗан аңа каршы килми, якын арада басылып чыгасы «Казакъ кызы» романы өчен керәсе керемне дә истә тотып, «балакае»ның тәкъдимен хуплый. Шакирҗан агалары исә, «алай ук кирәкмәс иде» дигәләсә дә, сөенеп кайтып китә.

Шакирҗан китеп бераз торгач, тагын бер кунакны – Галимҗанның энесе Габделхәкимне кабул итә бу яшь гаилә. Әдипнең Хәким энесе аларның төп йортында – Солтанморат авылында яши икән. Бу юлы да ике бертуган, тезгә-тез куешып, авылның барлык кешеләрен искә төшереп кич утырачаклар.

Бу кунакларның якын арада Казанга килеп китүе яңа кавышучыларны үзара тагын да якынайта төшкән кебек булачак. Бу очрашулар «Гөлсем балакай»ның киләчәк яшәешкә ышанычын тагын да ныгытачак, әлбәттә.

Галимҗан шул көздә үк бик зур эшкә тотына. 1905 елгы революция вакыйгаларында татарларның ни дәрәҗәдә катнашуын чагылдырган китап язарга алынган була. Ул китап 1925 елда ике телдә басылачак икән. Аны басмага әзерләшүдә Гөлсем дә актив катнаша. Башта ул рус телендә чыккан китап, брошюраларны туплаша, әдип билгеләгән кайбер битләрне тәрҗемә дә итешә. Беркөн эшнең барышы белән танышырга килгән обком кешесе С. Гафуров: «Бу хезмәтнең русчага тәрҗемәсен кемгә бирик икән?» – дип сорый әдиптән. Гөлсем тыйнак кына: «Миңа бирегезче», – дип тәкъдим итә. Галимҗан җәмәгатенең тәкъдимен хуплый. Ул Халык комиссариаты идарәсендә дә тәрҗемәче булды бит, эшне белә, ди. «Гөлсем башлам өлешен эшләсен. Ул текстны рецензентларга бирербез. Алар хупласа, эшен дәвам итәр», – дип төгәлли фикерен әдип. Татар һәм рус телендәге бу китаплар 1925 елда Мәскәүдә нәшер ителәчәк.

Шушы уртак хезмәт бу ике җанны бер-берсенә тагын да якынайтачак. Гөлсем дә үзен иренә тиң килә башлагандай сизәчәк.

1924 елның көзендә аларга хәзерге Мөштәри урамындагы 33 нче йортның беренче катында берничә бүлмәдән торган фатир бирергә булалар. Өстәге катта да Мәгариф комиссариатында эшләүче бер татар гаиләсе урнашкан була. Ибраһимовлар гаиләсе монда ике ел ярым чамасы гомер итәчәк. Гөлсем апа анда узган чорны «иң бәхетле айларыбыз булды» дип искә алыр иде. Ул укудан кайтып ашап-эчкәч тә, алар парлап әдипнең чираттагы эшенә тотына торган булалар. «Тирән тамырлар» романының кулъязмасын, башка шул чор хезмәтләрен бергә төгәлләп чыгачаклар. «Ул язган каралама вариантны мин укып чыга һәм акка күчерә идем», – дип искә ала иде Гөлсем апа. Шунда яшәгәндә,

1926 елның 5 ноябрендә аларның сөекле, көтеп алынган улы Рөстәм туа. Дөрес, ул туганда әтисе өйдә булмый. Яңа күчкән фатирларының бер бүлмәсендә яшәгән, өй эшләрен башкарырга ялланган Феня атлы хатын белән алар икәү генә калган булалар.

«Улыбыз туганда Галимҗан өйдә юк иде. Шул елда Бакуда узган, гарәп әлифбасын алыштыруга багышланган җыенда ул андый үзгәрешне кабул итмәүчеләрнең берсе була бит. Шуннан соң кайбер җитәкче оешмаларда аңа карата мөнәсәбәт кискен үзгәрә. Шул вакыйганы Галимҗан бик авыр кичерде. Бала туар алдыннан гына дәваланырга китәсе булды. Бу хәлеңдә сине дә алып бара алмыйм, дип гафу үтенде, – дип искә алган иде Гөлсем апа.

Улы тууы хәбәрен әдипкә дуслары хәбәр итә. Ул тиз арада юлга чыга. Кайткач та көненә берничә мәртәбә бала бишеге янында сокланып карап торучан була. «Башының формасы минеке, борыны да минекенә охшый бугай. Ә күзләре синеке – күк төсендәләр…» – дип кабатларга яраткан ул.

Ләкин мондый бәхетле көннәр бик озакка бармый шул. Тиздән әдипнең үпкәсендә яман чир булганлыгы ачыклана. Яңа елның бер аен әдип университет клиникасында дәваланып үткәрә. Аннан чыккач ул, ятагыннан тора алмыйча, атналар буе дәвалана. 1927 елның башыннан өстәге фатирдагы күршеләрендә яшәгән булачак галимә Җамал апа Вәзиева истәлекләрен дә искә төшереп үтик. Ул фатир хуҗабикәсенең әнисе әдип өйдә юк чакта Гөлсем күршесе белән бик аралашкан була. Галимҗан авырганда да аларга еш кереп йөри, Гөлсемгә булыша. Җамал апа яза: «Галимҗан мин пешергән кесәлне ярата дип, кайбер көнне ул миннән кесәл төшертә иде. Галимҗан абый үз бүлмәсендә урыныннан тормыйча ята. Икенче бүлмәдәге бала бишеге аңа күренеп тора иде. Гөлсем апаның сигез-тугыз яшьлек сеңлесе дә шул бишек тирәсендә чуала. Вакыт-вакыт ул кызчык баланы күтәрергә дип үрелде исә, Галимҗан абый шундук «Күтәрмә, балакай, егылырсың» дип кисәтер иде».

Шул чорның танылган докторы Әбүбәкер Терегуловның авыру әдип янына көн саен диярлек килүен Җамал апа да, башкалар да искә ала.

Табиблар никадәр көч куйсалар да, әдипнең хәле яхшырмый. Татарстан хөкүмәте аны дәваланырга Кырымга җибәрергә карар кыла. Аны озатып барырга тиешле бер яшь врач билгеләнә. «Бер кулга баланы, икенчесенә көндә кирәк буласы кием-салымны алып, фатирны бикләдек тә ерак юлга кузгалдык… Безне Ялта шәһәренә урнаштырдылар. Галимҗанның анда дәвалангач бераз савыккан чаклары, икәүләп кабат язу эшенә тотынган көннәребез дә, сөенечләребез дә булгалады. Хәл белергә дип, Казаннан, Уфадан язучылар да еш килә иде. Ләкин дүрт яшь ярым тулмастан, 1931 елның 21 мартында Рөстәмебезнең кинәт вафат булуы барысына да чик куйды. Ул кинәт авырый башлагач, Ялта шәһәре врачлары: «Аңа салкын тигән, аякларын җылы суда тотыгыз,

ике-өч көннән терелер», — дип юандырдылар. Бу фаҗиганең килеп чыгуында мин бүген дә үземне гаепле саныйм. Поликлиника врачларының сүзенә ышанып, Рөстәмнең дифтерия авыруыннан интеккәнен чамаламаганмын», — дигән иде Гөлсем апа бер әңгәмә вакытында.

Шушы фаҗигале вакыйга берничә айдан соң Галимҗан белән Өммегөлсемнең аерылышуына китерәчәк. Өммегөлсем башта Әстерхан шәһәренә кайтып китәчәк. Аннары Ялтага якынрак булган шәһәргә — Кырым Республикасының башкаласы Симферопольгә килеп урнашачак. Элек Галимҗан янына килгәләп йөргән Кырым Республикасы язучылары аны озакламыйча үз журналларына эшкә урнаштыралар. Ул журналда Гөлсем Мөхәммәдованың ике кардәш татар әдәбиятына багышланган мәкалә, очерклары басыла. Аңа үз әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп чыгаруны үтенүчеләр дә ишле генә була. «Әйе, тормышым җитү генә иде. Әмма җан тынычлыгы булмады. Берникадәр вакыт үткәч, Галимҗан алдына барып тезләнеп, аның гафу итүен үтенәсем дә килде. Ләкин нишләптер шул гамәлне кылырга батырчылыгым җитмәде. Чөнки ул да үзе белән очрашуга баручылар аркылы сәлам дә әйтеп җибәрмәс иде. Ә Галимҗанны кулга алу хәбәрен ишеткәч бөтенләй авыруга савышкан идем. Мин янында булсам, бәлки, андагы танышлар ярдәмендә аны коткарган булыр идем дип, үз-үземне күпме битәрләдем. Әйе, аңа чаклы әле минем күңелдә «Бәлки, кабат кушылу турында барып үтенәседер» дигән хыялый уйлар да тулгаланды... Ул хыялый өметләр дә юкка чыккач, үзенә димләп йөргән берәүгә кияүгә чыктым», — дип сөйләгән иде Гөлсем апа Әмирхан ага Еники дә катнашкан бер әңгәмә вакытында.

Әмирхан ага — хаксызга гаепләнеп төрмәгә ябылган, шунда вафат булган олуг әдип Галимҗан Ибраһимовны Сталин вафатыннан соң аклау чараларын күрүдә актив катнашкан шәхес. Шул чордагы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гомәр ага Бәширов аңа әйтә: «Иҗатын бик зурлаган Галимҗан агаңның эшен яңадан карауны үтенеп Үзәк Комитет исеменә хат язуга алынмассыңмы?» — ди. Әмирхан ага ул тәкъдимне кабул итә. Һәм берничә айдан соң аның өенә уңай җавап килә. Анда «Г. Ибраһимовның эше яңадан каралды, 1955 елның 24 сентябрь карары белән ул акланды» дигән хәбәр була.

Әлеге көнге безнең әңгәмә шул хат вакыйгаларын кабат искә алудан башланган иде.

*2021*

# ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ЯЗМЫШЫ

***(Иске чаршауларны алып ташлыйк)***

*(Очерк)*

Егерменче гасыр азагы җиткәндә, үткән тормышка яңадан әйләнеп карау мөмкинлеге тудырылды. Элек эшләнгән хезмәтләрнең байтагын хәзер «яңа иләктән иләргә» күнегеп барабыз. Шунда, кызып китеп, киләсе гасырга алып керердәй кайбер уңышларыбызны юкка чыгарырга теләк белдерүчеләр дә очраштыргалый әле. Мондый хәл бигрәк тә әдәбият, сәнгать дөньясына бәйле бәхәсләрдә үзен нык сиздерә. Дөрес, кайберәүләрнең ул бәхәсне «үз хаҗәтләрен» истә тотып башлап җибәргән булуы да ихтимал: элеккеләрдән бушаган шүрлектән урын калмасмы, янәсе. Югыйсә берничә буын әдәбият сөючеләрнең якты йолдызы булып балкыган шәхесләргә кизәнүләрне аңлавы читен. Ә инде «Җир уллары»н данлап шигърият юлына баскан өметле шагыйрь совет чынбарлыгында фәкать «Ертык тун» вакыйгаларын җырларга тиеш булды кебегрәк, дөреслектән ерак торган сүзләрне ишеткәләү авыр да, аяныч та. Бигрәк тә өлкәнрәк буын вәкилләре – бөек Такташның якты иҗатыннан рухи азык алып тәрбияләнүчеләр өчен бик авыр бу сүзләрне ишетү.

Классиклар киштәсеннән читләштерелергә тиеш табылганрак әдипләр исемлегенә Галимҗан Ибраһимовны «теркәргә» теләүчеләр дә күренгәли сыман. Ул, имеш, фәлән дә төгән, революциядән соң «үз җырын» җырламаган, яңа заманга җайлашырга бик тә тырышкан, имеш. Мондый караш бигрәк тә милләтпәрвәр әдип Гаяз Исхакый исеме вә иҗаты халыкка кайтарылган көннәрдән соң көчәя төште шикелле. Бу ике олуг шәхесне капма-каршы кую, соңгысының иҗатын вә көрәш юлын чиксез күтәрү исәбенә элеккеге «остаз»ны түбәнәйтергә тырышу очраклары күренгәли башлады. (Моның нәтиҗәсе хәтта ки олуг әдип тууына йөз ун ел тулган көннәрдә дә үзен сиздерде. Көндәлек матбугатта Г. Ибраһимов иҗатына һәм милли алга барыш эшчәнлегенә багышланган җитди хезмәтләр күренмәде диярлек.)

Ә бит бу олуг шәхесләрне бер-берсенә каршы куярга кирәкмәс иде. Алар икесе ике шартта бер үк «юнәлештә» хәрәкәт иткәннәр ич. Галимҗан Ибраһимов Гыйльми Үзәкне җитәкләгән чорында гына да татар халкының үз калыбында калып, киләчәккә барышы өчен дип күпме хезмәт куйган кеше ич. Шушы өч елда ул башкарган игелекле эш-гамәлләрне башкалар унар, утызар елда да тиешенчә эшли вә күтәрә алмастыр, мөгаен. Татар халкының киләчәк язмышын кайгыртып яшәвен, шул юнәлештәге тырышлык-омтылышларын күреп торган, шуңа бик тә эчләре пошкан кайберәүләр Г. Ибраһимовны шул вакытта ук тезгенләргә теләк белдерәләр икән, монда инде ни-нәрсәдер бар, димәк. Аның үз

милләтенең киләчәге өчен астыртын көрәш алып барганлыгын ерак Төркиягә китеп яшәргә мәҗбүр булган элекке каләмдәше һәм фикердәше Габделбари Баттал да сизенгән. Төркиядә нәшер ителгән «Казан төркиләре» китабында бу әдип: «Рус революциясе кайгылары аны да бөтереп ала, һәм нәтиҗәдә ул большевик була, – дип язды. – Тик Г. Ибраһимов «милли большевик» иде. Ягъни, Русиядә урнаша барган яңа режимга яраклашып, үз халкына, милләтенә файдалы булачагына, үз сүзләре белән әйткәндә, «татар мәдәниятен төзи алачагына» ышана иде… 1926 елда Баку шәһәрендә узган тюркологик конференциядә алфавит алыштыруга каршы торган төркем арасында була. Һәм ул – милли коммунист – Бакуда узган вакыйгалардан соң ук шик астына алына».

Бик дөрес сүзләр. Бу җөмләдә тик бер генә төгәлсезлек бар: Г. Ибраһимов ул «конференция барышында алфавит алыштыруга каршы торган төркем арасында» түгел, шул абруйлы төркемне әйдәүчеләрнең берсе булган кеше. Шушы уңайдан әдипнең хатыны, язучы* Гөлсем апа Мөхәммәдованың истәлек язмаларына мөрәҗәгать итик. 1994 елда Казанда нәшер ителгән «Олы юл» китабында ул әдипнең Бакудан бик борчылып кайтуын искә алган. «Галимҗан Ибраһимовның докладыннан соң күтәрелгән дискуссия шул дәрәҗәдә тәртәдән чыгып китә ки, нотык сөйләүчеләр кызып, ярсып берсе артыннан берсе аны милләтчелектә, пантюркизмда һәм башка төрле гөнаһларда гаепли башлыйлар. Г. Ибраһимовның Татарстан делегациясе җитәкчесе икәнлеген онытырга тырышкан иптәшләр дә була. Мәсәлән, утырыштан соң баскычтан төшеп барган делегатларны киногa төшереп алган булалар, лентадан Галимҗанны «кисеп» ташлыйлар, аның аяклары гына лентада кала. Конференциягә багышлап чыгарылган җыентыкка аның докладыда, соңгы сүзе дә кертелми».

Ә хәзер Казанда шул ук елларда уздырылган бер ябык киңәшмә кәгазьләренә куз салыйк (Альберт Мөслимовның «Рәсми әләк» мәкаләсе // Казан утлары. – 1991. – № 7). Анда бит саен диярлек Г. Ибраһимов телгә алына. Менә әлеге киңәшмәдә татар милли интеллигенциясенә «бәя» бирү өлеше теркәлгән битләрдән өзекләр. «Казан революциягә кадәр дә милләтчеләргә бай иде… Соңрак аларның бер өлеше чит илләргә чыгып китте, бер өлеше үзебезнең ил буйлап таралган иде. Ә бер өлеше Казанда калды һәм, коммунистлар битлеге киеп, үз эшләрен дәвам итә… Алар ярдәме белән Татарстан Республикасында милли карашлы затлар кабат туплана башлады. Бу хәл бигрәк тә 1926 елдан соң нык сизелә… Бу юнәлештә аеруча Г. Ибраһимов, Н. Надиев активлык күрсәтәләр. Алар «милли азатлык хәрәкәтендә» актив катнашкан зур стажлы кешеләрнең зур бер төркемен Мәгариф халык комис-

---

* Г. Мөхәммәдова СССР Язучылар берлегенә 1940 елда кабул ителгән.

сариаты һәм нәшрият органнарына эшкә урнаштырдылар. Шуннан соң алар кабат үзара берләшә, оеша башладылар. Г. Шәрәф... һәм башка милләтчеләр «Яңа китап» дигән нәшрият ширкәте кордылар. Ачыклавыбызча, әлеге ширкәт пролетариат идеологиясенә каршы көрәшүне максат итә. (Шунда чыккан китаплар исемлеге китерелә, аларга тискәре бәя бирелә.) ...Г. Ибраһимовның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китабының эчтәлеге сезгә мәгълүм инде...»

Шуннан соң «конкрет тәкъдимнәр» бәян ителә. «1. Идеология фронтындагы көрәшне туктату юнәлешендә: а) Академик үзәктә Г. Ибраһимовның янәдән эшләвенә юл куймаска. (Төрле мәгариф һәм мәдәният оешмаларында эшләүче тагын тугыз кешенең исемнәре атала һәм: «Актив милләтчеләр буларак, аларны эштән бушатырга», – дип тәкъдим ителә.); б) Академик үзәкнең эш планын... милли караштагы элементларны кысып чыгару максатында яңадан карарга, эш урыннарына марксистик яктан тотрыклы иптәшләрне җәлеп итәргә. Мондый мәсьәләне 1927 елда куярга мөмкин» диелгән ул комиссия утырышы документында.

Китерелгән мисаллардан күренә ки, «милли большевик» һәм актив җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның революциядән соңгы еллардагы иҗади һәм фәнни эшчәнлеге хәзер күзаллаган кысаларга гына сыеп бетми икән. Аның ул чордагы эшчәнлегенең асыл максаты большевикларга ярашып, ак күмәч ашап яшәргә омтылулардан бик ерак тора. Үзалдына бөек максат куеп, армый-талмый татар милләтенең киләчәге якты булсынга хезмәт итә ул. Һәм аның егерменче-утызынчы еллардагы иҗат эшчәнлегенә дә үз чорына якын килеп бәя бирергә тиешбездер. Әдәбият галиме Альберт Яхин бер чыгышында әйтеп үткәнчә, Г. Ибраһимовның революциядән соң тудырылган әсәрләрен бәяләү өчен аларны тирәнтенрәк өйрәнү зарур. Аларны бәяләгәндә элекке еллардагы карашлардан баш тарту да зарурдыр, бәлкем. Мәсәлән, «Тирән тамырлар» романындагы «уңай» каһарманнарга гына җентекләбрәк карагыз. Революциягә кадәрге татар авылында алар эчеп-тузып, канга батышканчы сугышып йөргән башкисәр егетләр. (Бу очракта, бәлки, бөек пролетар язучы Максим Горькийның «Ана» романы йогынтысы да бардыр. Чагыштырмача яшь, яңа туып килүче татар романы жанрына – егерменче елларда әле тулыр-тулмас илле «яшь» чамасы – рус әдәбияты йогынтысыннан азат түгел әле.) Әдипнең шул романының баш каһарманы Фәхри йомшак күңелле Зифа карчык хәтерләвендә «йөзендә, күзендә нур юк иде» рәвешендәрәк төсмерләнә. Димәк, автор да ул Фәхриләрне шулайрак төсмерләгән була түгелме? Мондый мисаллар китереп, мин һич кенә дә бу романның «сыйнфый» эчтәлеген инкяр итәргә җыенмыйм. Әмма шулай да аны тирәнтенрәк өйрәнү, төрле ысуллар кулланып эшкәртелгән асылташны әйләндергәләп караган кебек, төрле тарафтан карап бәяләү заманы җиткәндер дип уйлыйм. Әлбәттә, бу сүзләр әлеге бер романга гына атап әйтелми...

* * *

Элекке авыл өйләренең чуклы-бизәкле чаршаулар белән бүлгәләнүен хәтерләүчеләр бардыр әле. Әби-бабаларыбыз шулай урын-җирләрен, караңгы мич артларын чит-ят күз күрмәсен өчен дип каплап, «чаршау артына яшереп» куярлар иде. Миңа калса, бөек шәхесебез Галимҗан Ибраһимов «ызбасында» да ятлар күзеннән чаршау белән томаланып, капланып торган урыннар байтак әле. Әлбәттә инде, бу очракта аның биографик «ызбасы» күзаллана. Аның исемен һәм иҗатын караңгы гүр базларыннан халкына кабат кайтарган, мәрткә киткән «җаны»н яңадан терелткән илленче-алтмышынчы елларда әһәмият биреп җиткерелмәгән яисә заманасына күрә әһәмият ителергә тиеш булмаган күп кенә фактларга бүген күзне ачыбрак карарга, ул биографик «ак таплар» өстенә капланган «иске чаршаулар»ны алып ташларга вакыт җиткәндер кебек. Әлегәчә исә безнең алда — күпчелек әдәбият сөючеләр алдында — әдип шәхесенең бигүк ачык, тулы булмаган, фән телендә «яссы портрет» дип аталган рәсеме генә калка сыман. Аны хәзер, голографик ысул белән төшерелгән заманча портретлар эшләнгән кебек, укучы алдына тулы гәүдәсе белән китереп бастыру зарур. Ә моңа ирешү өчен аның биографиясен тирәнтенрәк өйрәнергә, элек «табу салынган темалар»ны, фактларны да тулырак яктыртып, ул шәхесне тулы канлырак иттереп торгызырга кирәктер. Һәр фикер иясенә хас булган ялгышулары, абыну-сөртенүләре, эзләнүләре белән бергә...

Туып үскән Солтанморат авылын калдырып, олы юлга аяк баскан беренче адымнарыннан ук яшүсмер Галимҗанны ниндидер бер билгесезлек биләп ала сыман. Укуын дәвам итәр өчен ул ни сәбәпле туган йортыннан өч йөз илле чакрымнарда урнашкан Оренбург каласын сайлаган соң? (Дөресрәге, андый хокук, әлбәттә, уникенче яшькә чыккан малайда түгел, атасы Гыйрфан мулла карамагында булган, аны ул сайлаган.) Һәм нишләп ул мулла улларын үзләреннән илле-алтмыш чакрымдагы Уфа мәдрәсәләренә бирергә теләмәгән? Бу чорда бит инде Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе дә абруй казанган, җәдиди ысуллы уку йортларыннан саналган була. Шунда ук «Хәсәния» мәдрәсәсе дә «эшләп тора» ич. Гыйрфан мулла да үзләреннән ерак тормаган Кыешлы авылы мәдрәсәсендә генә белем алган. Соңрак аның Троицк каласына барып чыгуы, якын туганы хәлфәлек иткән бер ахун мәдрәсәсендә бераз белемен яңартканнан соң, шунда укытырга калуы очраклы хәл диярлек. Шул хәлфә Гыйрфан анасының кардәш-ыруы булмаса, мөгаен, ул атналар буе йөк арбасында интегеп, дүрт-биш йөз чакрымдагы ерак шәһәргә юл тотмаган да булыр. Рахманкулов ахун хәзрәтләре белән якыннан аралашу бәхетенә ирешмәс тә иде. Чөнки әле ул заманда Себер тимер юлы ачылмаган чак бит. Ә менә ни өчен ул улларын анда укырга җибәрмәгән? Анысына әлегә җавап юк. Югыйсә

бит инде Галимҗаннар авылны калдырып киткән чорда Самара белән Чиләбе аралыгында поездларның гөрләтеп йөреп торган чагы. Һәм ул поездлар Солтанмораттан кырык-кырык биш чакрымнардагы Дәүләкән станциясендә озаклап тукталыш ясыйлар. Ә Оренбургача исә янә атна дәвамында ат-арбада интегеп барасы, кыр эшләрен эшләргә тиешле атларны өшәндереп, аларны кимендә ярты айга эштән аерып торасы. Һәм шуңа да карамастан Гыйрфан мулла шул юлны сайлый. Ни сәбәпле? Бәлки, аларның Оренбург белән электән килгән бәйләнешләре булгандыр? Бәлки, мишәр өммәтеннән булулары сәбәпле кайчандыр «башкорт, мишәр гаскәре»нә кергәнлектән, ул гаскәрнең төп үзәге саналган Оренбургта якын туганлык хисләрен саклаучы берәр җан иясе яшәгәндер? Бер бабалары шул гаскәрнең дин башлыгы – ахуны да булган ич. Андый бәйләнешләр әлегә һич тә ачыкланмаган. Дөрес, Галимҗан бер истәлек язмасында шәкерт елларында морза Мирсалих Бикчурин өендә булгалавын искә ала. Ләкин аның белән нинди бәйләнеше булуын искәртми. Әйе, Гыйрфан мулланың Оренбургка карата булган бәйләнешләре әлегә ачыкланып бетмәгән. Андый «вак» нәрсәләр белән кызыксынучы да әлегә булмады шикелле. (Мишәрлек мәсьәләсенә килгәндә исә – Киев төрмәсенә ябылганда, Галимҗан кулыннан нәкъ шундый тамга салынган паспорты алына.)

Шул ук Оренбург юлы өстендә, әмма авылдан нибарысы бер көнлек арада, Солтанмораттан сиксән-туксан чакрымнарда атаклы Эстәрлебаш авылы мәдрәсәсе дә бар әле. Узган гасыр азакларында анда мәшһүр шәхесләрдән Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла кебек, исемнәре мәдрәсәдән мәдрәсәгә таралган сүз осталары белем эстәгәннәр. Ниһаять, шул ук мәдрәсәне булачак яшь шәкертнең бабасы Нурмөхәммәт мулла тәмамлап, үз авылына кайткан. Һәм шул Нурмөхәммәтнең улы Гыйрфан үз улларын – Шакирҗан белән Галимҗанны никтер тагын да ераккарак, Оренбург тарафына ук олактырмакчы. Сәбәбе нәрсәдә? Мөгаен, бу сорауга бүген тәгаен генә җавап биреп булмыйдыр.

Шәкерт Галимҗан биографиясендә ниндидер бер эз калдырган икенче бер мәсьәлә хәрби уку йорты укытучысы генерал Бикчуринга бәйле. Бикчуриннар нәселе шулай ук әлеге башкорт-мишәр гаскәре төркеменә кергән. 1901–1902 елларда, «Вәлия» мәдрәсәсендә укыган чорда Галимҗанның генерал Бикчуринда кучер вазифасын үтәвенә бәйле сорау туа. (Совет чорына караган бер истәлегендә әдип шулай дип яза.) Очраклы гына бер хәлме бу, әллә соң алдагы сорауларга да беркадәр ачыклык кертергә ярдәм итәрдәйме? Мирсалих Бикчурин Оренбург төбәге морзалары токымыннан була, 1838 елда шушы шәһәрдә хәрби уку йортын тәмамлаганнан бирле патша хөкүмәте вәкилләре белән җирле халык арасында арадашчы-тылмач вазифасына бәйле эшләр башкара. Кырык елга якын үзе укыган кадет корпусын-

да һәм соңрак ачылган рус-казах махсус мәктәбендә егерме ел чамасына сузылган укытучылык эшчәнлеген дә шул ук «тылмачлык вазифасын үтәү» дип бәяләргә ярыйдыр. Чөнки аның төп эше яшь офицерларны, ягъни булачак патша чиновникларын татар, башкорт, казах, фарсы, гарәп телләренә өйрәтү була. Шушы телләрне өйрәнүдә күренекле урын тоткан мәгълүм дәреслек-хрестоматиясе дә («Начальное руководство к изучению... языков... с приложением русско-персидско-татарских слов». 1859, 1869 елларда нәшер ителгән), мәкалә-очерклары да җирле халыкның зыялы катлавы тарафыннан хуплап каршы алына. Ягъни генерал Бикчурин – гадәти бер солдафон гына түгел, үз чорының зыялы бер галиме. Бу кеше сиксән өч яшендә, 1903 елда Оренбург каласында вафат була. Һәм менә шул төрки, фарсы, гарәп телләре профессоры дәрәҗәсендәге генерал карамагында Галимҗан кучер хезмәтен башкарган, имеш.

Ләкин ул вазифаны кайчан, кай араларда башкарган соң бу шәкерт? Җәйге каникул вакытларындамы? Юк шикелле. Чөнки истәлекләрдә аның агасы Шакирҗан белән бергәләп һәр җәйдә атасына кыр эшләрендә булышканлыгы бәян ителә. Укулар тәмамлануга, аларны авылда көтеп алганнар. Алайса, ул карт генералны кыш айларында, икенде-ахшам тирәләрендә, дәресләрдән бушагач атта йөрткәндерме? Ләкин шулай соңлап ул генерал кайларга гына барды икән? Морзалар клубына да, рестораннарга да түгелдер, мөгаен. Ара-тирә шул якындагы мәчеткә йөрткәләсә генә инде.

Миңа калса, бу юрауларның барысы да уйдырма гынадыр кебек. Бергә укыган шәкертләр аның Бикчурин морза йортына барып йөргәнлеген белгәннәр. Совет хакимияте елларында шуларның берәрсе аның шунда баргалап йөрүе хакында сүз таратмасын өчен, Галимҗан әлеге морзада кучер вазифасын үтәгәнлеген белгертмәкче булгандыр, мөгаен. Ә бу морзаның бай китапханәсе исә аны ара-тирә анда баргалап йөрер өчен бер максат булгандыр дип фаразлыйсы килә. Ерак бабалары белән бәйләнеше булмаган чит-ят йортка исә бик теләсә дә ишек ачып керә алмас иде.

Галимҗан белән бер үк елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган Шакирҗан агасы да, туганнан туган агасы һәм якын әшнәсе Мохтар Ибраһимов та никтер ул дәверне бик сиран искә алганнар. Моның сәбәбе бер генә, минемчә, 1917 елдан соң тормышның һәм шуңа бәйле рәвештә дөньяга карашның кинәт үзгәрүе, кискен борылыш ясавы.

Һәм шушы үзгәреш әдип биографиясендәге икеле-микеле уйлануларга урын калдырган тагын бер вакыйгада нык чагыла. Гыйрфан мулланың Галимҗанны «Вәлия» мәдрәсәсенә урнаштыру мәсьәләсенә бәйле вакыйга бу. Истәлекләрдә һәм хәтта ки күп кенә сораулар тудырган бер романда да бу вакыйганы «кече малайның чирләшкә булуы» белән бәйлиләр. Ай-һай, шулаймы икән? Һич кенә дә ышандырмый торган дәлил, соңыннан, дөньяга

карашлар нык үзгәргәч уйлап чыгарылган сәбәпкә охшап тора бу. Имештер, ике улын да тиз арада дан-шөһрәте тирә-якка таралып өлгергән «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытырга дип алып килә дә Гыйрфан мулла кечесен, ул чирләшкә дигәч, совет чорында тасвирланганча, «бозыграк һавалы, начаррак тәрбияле» икенче бер уку йортына урнаштырып китә. Никтер моңа бигүк ышанасы килми. Һәм ышанмау өчен кайбер сәбәпләр дә бар.

Галимҗан Ибраһимов исеме кабат халыкка кайтарылганнан соң, күрше ике республика матбугатында аңа багышлы бик күп истәлек язмалары дөнья күрде. Алар бигрәк тә туган ягында – Башкортстанда дүрт-биш ел дәвамында чыга тордылар. Истәлек авторларының күпчелеге Галимҗан белән яшьтән үк таныш булган, бергә үскән, бергә укыган кешеләр иде. Хәтеремдә: ул истәлекләрнең кайберләрендә Гыйрфан мулланың уртанчы улын аеруча бер ярату белән яратканлыгы һәм кечкенәдән үк аны үзе урынына мулла итәргә өметләнүе дә тасвирланган иде.

Гөлсем апа Мөхәммәдованың «Эзләнүләр» китабын редакцияләү чорында мин шул хакта әдипнең хатынына да сөйләдем. Ул да шул ук фикерне хуплады. Ата-ананың баштагы хыялы, әлбәттә, Әхмәт ахун, Нурмөхәммәт вә Гыйрфан муллаларның варисы итеп Галимҗанны күрергә теләү була. Әмма яшь мәхдүм бу өметләрне акламый, тормышта үз юлын сайлый. Һәм үз юлын сайлау белән генә чикләнмичә, Гыйрфан мулланың язмышындагы үзгәрешкә дә төп сәбәпче ул була. Мәгълүм ки, вафатына берничә ел калганда, Гыйрфан карт муллалыктан ваз кичә.

Истәлекләрдә Гыйрфан мулланың шактый ук кырыс холыклы булуы, якыннарына карата таләпчәнлеге тасвир ителә. Аның таләпчәнлеге, әлбәттә инде, йорт эшләрен башкаручы ялчы Әхмигә һәм уллары Шакирҗан белән Галимҗанга карата гына булмагандыр. Кирәк вакытта ул башка даирәләрдә дә үз сүзендә тора алырдай абруйлы мулла булгандыр, мөгаен. Шуңа күрә дә «улың чирләшкә бугай, шунлыктан укырга алмыйбыз» дип, аны «Хөсәения» мәдрәсәсеннән борып чыгаруларына бигүк ышанасы килми. Бу вакыйганы мин башкачарак күз алдына китерәм.

Узган гасыр урталарында ук инде зыялырак катлау кешеләре арасында милләтебезнең киләчәк яшәешенә аек бер караш туа. Ул карашның асылы – яшь буынны үз чорлары таләпләренә хас килердәй рәвештә тәрбияләү, заманча белемле итүдән гыйбарәттер. Ул вакытта зыялырак затларның күңелләрендә йөргән төп фикерне Фатих Кәрими соңрак бер әсәрендә болайрак бәян итә: татарда указлы муллалар ишле генә, указсыз муллаларга кытлык хәзер, ди. Ягъни, татарга хәзер заманча белемле кешеләр күбрәк кирәк, димәкче. Яшьли ятим калып, ялан кырда йомран аулап һәм кирпеч базларында кирпеч ясап үскән, шул сәбәпле төпле белем алудан мәхрүм ителгән булачак миллионер Хөсәеновлар да моны яхшы аңлаганнар. Һәм узган гасырның сиксәненче елларында шул максаттан чыгып Оренбург каласында «Хөсәения»

мәдрәсәсенә нигез салганнар. Мәдрәсәнең төп юнәлеше яшьләргә дөньяви белем бирүдән гыйбарәт булган. Бу уку йортында чалмалы муллалар укытуга йөз тотмаганнар. Заманында бу хакта кайберәүләр тарафыннан мөфтият һәм патша чиновниклары исеменә атап шикаять хатлары да юлланылган. «Хөсәения»нең йөз шәкертеннән ун имам да чыкмый, дип зар елашканнар алар. Мәдрәсәнең заманча белемле, зыялы сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр һәм белемле мөгаллимнәр әзерләүне максат иткәнлеге исә Әхмәт бай Хөсәеновның васыятьнамәсеннән дә ачык күренә. Риза Фәхретдиновның «Әхмәт бай» китабында китерелгән мәгълүматка караганда, һәр елны мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган унике шәкерткә укуларын башка ил институт һәм университетларында дәвам иттерү өчен унике күләмле генә стипендия билгеләнгән була. Һәм байтак кына шәкерт, шушы форсаттан файдаланып, Истанбул, Бәйрут, Томск, Петербург институт вә университетларында Европа дәрәҗәсендәге белем үзләштерүгә ирешәләр.

Ләкин Хөсәенов байларны бөтенләй диннән язган, дәһри затлар итеп күзаллау да дөрес булмас. Ун сәүдәгәр, утыз эшкуарга тәңгәл рәвештә чама белән бер-ике рухани ата кирәк буласын да алар онытып бетермәгәннәр. Шулай ук үз акчаларына, үз нәселләре вәкиле Мөхәммәтвәли Гани бай улына фәкать дин әһелләрен әзерләүгә йөз токкан мәгълүм «Вәлия» мәдрәсәсен билгеләгәннәр. Ике мәдрәсәдә дә шәкертләрне асрау Хөсәенов байлар хисабына булган.

Минем фикерләвемчә, менә ни өчен Гыйрфан мулла йомшаграк холыклы зур улы Шакирҗанны дөньяви белем бирүче «Хөсәения»гә илтеп тапшыра да, үзенең ата-бабаларыннан килгән вазифаны дәвам итәргә тиешле Галимҗанны исә «заманнан артта калганрак, иске тәртипле» «Вәлия» мәдрәсәсенә урнаштыра. Әмма язмыш һәм Галимҗанның зирәк акылы аның киләчәк хыялларын чәлпәрәмә китереп ташлыйлар. Галимҗан бу мәдрәсәгә аяк баскан туксанынчы елларда ук инде Оренбург шәһәре үзенең әдип вә шагыйрьләре белән дан казанган төбәккә әверелә башлаган була. Моннан ерак булмаган Каргалы «каласында» яшәп иҗат иткән шагыйрьләр Утыз Имәни, Һибәтулла Салихов, Гомәр Мөхәммәт, Шәмсетдин Зәкиләрдән соң татар прозасының башлангыч әсәрләрен биргән Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов, Тимерша Соловьёв, Ярулла Вәлиевләрнең иҗат җимешләре дөнья күргән. Ул әсәрләр шушы төбәк халкы арасында киң таралган булган. Әлбәттә инде, менә шушы үрнәкләр Солтанморат авылының булачак мулласын юлдан яздыралар. (Узган гасыр башында унөч мең кеше яшәгән Каргалы авылын Риза хәзрәт «Әхмәт бай» китабында «саф татар каласы» дип атаган.)

«Вәлия»дә уку чорында Галимҗан шушы иҗади шәхесләрнең күпчелегенең әсәрләре белән таныша. Кайбер чордаш шәхесләр белән, бәлки, ара-тирә аралашкалагандыр да. Ә инде Мөхәммәтвәли мулла атасы Гани бай ярдәмендә Гыйльман Кәрими шәһәрдә

беренче милли типографияне дә булдыргач (1901), яшьләр арасында иҗатка омтылыш тагын да көчәйгәндер дип уйларга урын кала. Димәк ки, булачак күренекле язучы Галимҗан Ибраһимов белән аның каләмдәше вә «Вәлия» мәдрәсәсе буенча шәриктәше Шәһит Әхмәдиев күңелендә тәүге иҗат бөреләре шушы чорда бөреләнә башлаган булырга тиеш. 1930 елда Шәһит вафат булганчы алар тормышта да бер-берсенә ярдәмләшеп, бердәм булып гомер итәчәкләр.

* * *

Нәшриятта эшләвемнең соңгы елларында, мәрхүм Фәрваз Миңнуллин кушуы буенча, миңа Галимҗан Ибраһимовка бәйле мирасның тугызынчы томын тәшкил итәргә тиешле өч калын папкадагы кулъязмалар белән танышырга туры килгән иде. Ул кулъязманы мәгълүм әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Фатыйма Ибраһимова әзерләгән һәм бик тәфсилле генә «Соңгы сүз» өлешен дә язган. Бу томга Г. Ибраһимовның үз кулы белән егерменче елларда русча язган берничә автобиографиясенең татарчага күчермәләре, кайбер хатлары һәм башка төр язма истәлекләре керәчәк иде. (Ул китап «Фикер» нәшрияты тарафыннан 2000 елда нәшер ителде.) Шул папкаларда әдиптән Киев төрмәсендә чакта тутырылган сорау алу, тентү беркетмәләре күчермәләре, төрмә җитәкчелеге тарафыннан Казан жандарм идарәсенә юлланган хатлар, аннан алынган җавапларның да бер өлеше теркәлгән иде. Шунда ук 1910 елда Уфа губернасының бер идарәсе тарафыннан әдипкә бирелгән паспортның күчермә-копиясе дә бар иде.

Ләкин бу папкалардагы документлар һәм язмалар Г. Ибраһимовның 1915–1920 еллар аралыгындагы тормышын әлегә бик фәкыйрь чагылдыралар. Аеруча анда әдипнең сул эсерлар фиркасендәге эшчәнлегенә бәйле архив материалларының булмавы аяныч. Чөнки бу томга керәсе материаллар әле илдә коммунистлар партиясе җитәкчелек иткән чорда тупланганнар һәм, табигый инде, әдипнең биографиясен шул фирка таләпләреннән чыгып «дөресләргә» тырышу, яраклашу гамәлләре үзен нык сиздерә иде. Мәгълүм ки, 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соңгы бер елда гына да Г. Ибраһимов татар халкының киләчәк язмышын хәл иткән берничә зур корылтайда катнаша, сул эсерлар платформасына бәйле рәвештә анда нотыклар сөйли. Петербургта узган Учредительләр җыенында да ул сул эсерлар вәкиле буларак катнаша. (Совет хакимияте елларында бу факт та искә алынмады.) Шул ук вакытта ул җыелыш-съездлардан үз мөхәррирлегендә нәшер ителгән, сул эсерлар фикеренә өстенлек биргән «Ирек», «Безнең юл» газеталарына күләмле мәкаләләр дә җибәргәләп торган. (Шул газеталарны чыгарышуда катнашкалаган Исмәгыйль ага Рәмиев аларны искә алгалар иде.) Димәк ки, шул

чор матбугатында һәм беркетмә-документларында әдипнең актив эшчәнлегенең эзләре сакланган булырга тиеш. Һәм алар белән дә бүгенге чор укучысы да танышырга хаклыдыр дип уйлыйм.

Мәрхүм Исмәгыйль ага Рәмиев бервакыт Әмирхан ага Еники белән икебезгә Галимҗан Ибраһимовны 1917 елның декабрендә Оренбург каласында уздырылган башкорт кардәшләребезнең тарихи корылтаена озата барганлыгын тәфсилләп бер сөйләгән иде. Ул корылтай мөстәкыйль Башкорт автономиясен булдыру карарын кабул итә. Булачак автономиянең чикләрен билгеләүгә кагылышлы бәхәсләр була. Ул автономия биләмәсенә рус, татар һ. б. милләт авылларын кертмәскә кирәк дигән ахмак фикерләр дә яңгырый. «Галимҗан, трибунага күтәрелеп, башкорт, татар халкының бердәм һәм бергә булырга тиешлеген әйтте. Баймак тарафыннан килгән, шул төбәк ыруглары исеменнән «Татар авылларын кертмәскә» дип чыгып сөйләгән берәүгә каршы бик дәлилле җавап бирде. «Синең авылдан ике утар аша татар Юлыгы бар. Аны нишләтмәкче буласыз?» – диде.

Шул корылтай карарында «Безнең мөстәкыйльлекне кем таный, без шуның яклы» дигән тарихи сүзләр дә теркәлә. Мәскәүдән әүвәл ул автономияне танымау турында хәбәр килә. Омскидан исә аклар хөкүмәтенең Башкорт автономиясен рәсми тануы һәм кирәгенчә корал белән ярдәм итәргә әзер булуы хакында хәбәр алына. Зәки Вәлиди җитәкчелегендә Россиядә беренче автономия шулай туа. (Дөрес, ул җитмеш елга якын рәсми рәвештә танылмады һәм шул хакта хәбәрләр булмады диярлек.) Большевиклар Башкорт автономиясен 1919 елның мартында гына танырга мәҗбүр булалар. Абдулла Дәүләтшин җитәкчелегендәге башкорт-татар большевиклары З. Вәлиди хөкүмәтен кулга алып, Башкорт Совет автономиясен игълан иткәннән соң.

Әлеге корылтайда Галимҗан Ибраһимов, бер-ике мәртәбә җыелыш мөнбәренә күтәрелеп, кайнарланып, татар һәм башкорт халыкларының бердәм булырга тиешлеге турында нотыклар сөйли. Һәм, И. Рәмиев хәбәр итүенчә, аның төп фикере бу ике тугандаш халыкның берләшкән автономия оештырырга тиешлеге турында була. Без бүген аның анда ни-нәрсәләр сөйләгәнен белергә тиешме? Шуннан соң гына ул шәхес безнең алда тулырак ачыласы түгелме? Ә бит аның биографиясендә мондый ачыкланмаган, барланмаган фактлар байтак әле. Мәсәлән, аның 1919 елның җәй башында дүрт айга сузылган «югалып тору» вакыйгасы. Әлегә совет чорында кабул ителгән бер юрама буенча, бу айларда ул атаман Колчак гаскәрләре биләгән Себер тарафларында разведкада йөри. Атаманның Совет хакимиятенә каршы тагын ни-нәрсәләр кылырга ниятләвен ачыкларга тырыша. Ләкин гомерендә дә солдат киеме кимәгән, мылтык тотып карамаган бу кеше адмирал Колчак армиясенең нинди серләрен ачыклады да ниндирәк мәгълүматлар туплады икән соң? Әллә инде 1918 елның җәендә үзенә карата гаделсез гамәлләр кылынуын тойганнан соң, башка кайбер

зыялыларыбыз кебек, шул исәптән Габдулла Кариев үрнәгендә бертын почмакта яшеренеп, илдә кайсы көчнең җиңәсен көтеп, әдәби иҗат белән генә шөгыльләндеме икән?

1918 елның июль башында сул эсерлар партиясе җитәкчеләре Мәскәүдә бунт оештыра. Әлегәчә ил белән бергә идарә иткән большевикларны идарәлектән читләштерергә маташа. Ул фетнәнең төп сәбәбе чираттагы зур корылтайда (съездда) сул эсерларның бер җитди тәкъдиме кире кагылуга бәйле була. Шул фетнә бастырылгач та, большевиклар партиясенең Үзәк комитеты сул эсерлар партиясе вәкилләрен барлык хакимият оешмаларындагы эшеннән азат итү карарын чыгара. Мәркәзи мөселман комиссариаты большевиклары да әлеге дошмани партия вәкиле булган Галимҗан Ибраһимовны эшеннән азат итәргә кирәклеге турында карар кабул итәләр. Ләкин Мулланур Вахитов үзенең урынбасарын якларга тырыша. Галимҗанга исә эштә калу яки калмау мәсьәләсен хәл итү өчен Ленинга мөрәҗәгать итәргә кирәклеген дә ул киңәш иткәндер, мөгаен. Әдипнең җәмәгате Гөлсем Мөхәммәдованың «Олы юл» китабында хәбәр ителүенчә, Мәркәзи комитеттагы актив большевиклар төркемендә Казанлы Дулат Али (Мәхмүд Алиев), Һади Килдебәков, Минһаҗ Конов, Шәриф Манатов һ. б. була. Галимҗанны Ленин кабул итә. Мәсьәләне аңлатып биргәч, Ил башлыгы аңа «эшләгез» дип җавап бирә (94 б.). Ләкин озакламыйча Мулланур Казанга китәргә тиеш була. Большевиклар төркеме янә: «Сул эсерлар вәкиле бездә эшләргә тиеш түгел», – дип кабатларга керешә. «Шундый чиктән тыш авыр хәлдә Галимҗан Ибраһимов Үзәк мөселман комиссариатындагы эшен дәвам итәргә тырыша. Ләкин көннән-көн үзенең хәлсезләнә баруын сизә... Төрле шикләнү, шөбһәләнүләр эзсез калмый шул... «Метрополь» ашханәсенә беркетелгән булуга карамастан, ашау мәсьәләсе дә канәгатьләнерлек булмый. Тиздән ул авырып хастаханәгә эләгә. Анда егерме көн дәвалангач та сәламәтлегенең ныгып җитмәгәнлеген тоеп, ул комиссариат коллегиясенә үзен эштән бушатуларын үтенеп гариза бирә» (99 б.). Һәм шул елның көз ахырларында ул, Мәскәү большевиклары белән араны өзеп, Казан аша туган якларына кайтып китәчәк. Уфадан тагын бер айлык ял бирүләрен үтенеп комиссариатка гариза җибәргәнлеге дә мәгълүм. Шул рәвешле Галимҗан 1919 елның гыйнвар башына кадәр Үзәк мөселман комиссариатының әгъзасы булып саналган.

Туганнары хәбәр итүенчә, киләсе кышны ул Уфада уздыра. Авылдан элекке кульъязмаларын китертеп, әдәби иҗат эшен дәвам итәчәк. Ул чорда Уфада аның кемнәр белән аралашканлыгы туганнары истәлекләрендә теркәлмәгән. Шул чорга караган бер Башкортстан кешесе истәлегендә генә аның яңарак кына Уфага кайтып мөфтияттә эшли башлаган Риза Фәхретдинов белән очрашкалаулары турында искә алына. «Шура» журналының баш мөхәррире булган елларда Риза хәзрәт яңарак кына иҗат

итә башлаган яшь әдипнең байтак әсәрен хуплап кабул иткән, бастырып чыгарган була. Берничә хикәядән тыш аның милли мәсьәләләргә кагылышлы җитди генә очерк, мәкаләләре дә, Риза хәзрәтнең хуплавы сәбәпле, тоткарланмыйча, үз вакытында нәшер ителгәннәр. Мәсәлән, «Без татарбыз» (1911), «Без кем?» (1912) һ. б.

Әдип, мөгаен, нәкъ шул кышта мөфти Галимҗан Баруди белән дә аралашкан, илдәге хәл-әхвәлләр турында фикер алышкандыр. 1918 елның гыйнварында Уфада узган Милләт Мәҗлесендә оештырылган Милли идарәне сайлаганда алар икесе дә «туфракчылар» төркеменә кереп, булачак милли автономиянең үз чик-биләмәләре булырга тиешлеген яклаган булалар. Булачак автономиянең булачак җитәкчеләрен – Милли идарәне сайлаганда да алар бер үк шәхесләргә тавыш биргән булалар. Шул җыенда Г. Баруди Дини идарә рәисе (мөфти) буларак та тәгаенләнә. Ләкин шуннан соң алар бер ел чамасы очрашмаган булалар. Уфада Совет хакимияте шул язда ныклап урнаша. Һәм иң беренче чара итеп әлеге Милли идарә вәкилләрен эзәрлекләргә керешә. Шул елның 21 апрель карары нигезендә Милли идарә юк ителергә тиеш була. Февральдә үк Уфадан киткән Садри Максудидан кала башкалар вакытлыча казах кардәшләр илендәге Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә барып сыенырга карар кылалар. Шундый ук хәлдә калган казах милли төркеме – Алаш Урдачылар да шул шәһәргә китеп торырга булган. (Алаш Урдачыларның бер ишесе белән Галимҗан якыннан таныш була. Алар Оренбургта да, Уфада да бер чордарак укыйлар.) Милләт идарәсе рәисенең урынбасары, Уфаның атаклы адвокаты Ибнеәмин Әхтәмов һ. б. белән дә әдип күптән аралашып яшәгән була. 1918 елның апрелендә Милли идарә вәкилләре белән бергә Г. Баруди да Кызылъярга чыгып китә. Большевиклар кысуыннан шикләнеп, бер ел чит-ят җирләрдә йөреп, Уфага ул 1919 елның мартында гына әйләнеп кайта.

Галимҗан, менә шушы шәхесләр белән аралашкан, киңәшкәннән соң бугай, Кызылъяр каласына сәяхәт кылырга ниятли. Нинди максат куеп аның андый сәфәргә чыгып китүе әлегә ачыкланмаган. Гөлсем апа белән аралашканда да мин аңа шундый сорау биргән идем. Ул да бу вакыйганы аңлата алмады. «Галимҗан белән без ул хакта күп сөйләшмәдек», – дигән иде. Шулай да ул ике версия тәкъдим итте. «Берничә мәртәбә яза башлап та, төгәлләнмәгән «Казакъ кызы» романына бәйле сәяхәт булуы да мөмкин. Анда бит ул Себер буйлап түгел, казах авыллары аша барган», – диде.

«Шул шәһәр кызы Хәдичәне искә алган булуы да ихтимал», – дип тә өстәде Гөлсем апа. Әйе, Кызылъяр сәүдәгәре кызы Хәдичә ике кыш Уфада, «Галия» мәдрәсәсендә укыганда, алар үзара аралашканнар. Икесенең дә ялланган фатиры шәһәрнең бер үк урамы һәм бер кварталына кергәнлектән, еш кына мәдрәсәгә

бергә барып, бергә кайта торган булганнар. Хәдичә 1916 елның җәендә мөгаллимәләр курсын тәмамлап өенә кайтып киткәч тә аларның ара-тирә хат алышканлыгы турында хәбәрләр бар. Бер истәлек авторы: «Әдип аңа китапларын да җибәргәләгән», – дип тә яза. Ләкин ул вакыйганың кайчан булуын гына хәбәр итми. Бәлки, ул хәл әдип белән Гөлсем апа аерылышканнан соң булгандыр. Әйе, уллары Рөстәм кинәт вафат булгач, алар аерылышалар. Шуннан соң ике-өч ел чамасы вакыт үткәч, әдип Хәдичә Фәтхуллинаны Ялтага чакырып китерә. Аларның загста теркәлүе 1934 елның июленә туры килә бугай…

Сак кеше буларак, сәфәргә чыкканчы, Галимҗан, мөгаен, мөфтият исеменнән юл таныклыгы да алган булгандыр. Җәмәгатенең «Олы юл» китабында аның күрше авылда яшәгән туганнары Әхәт мулланың муллалык документын алганлыгы да хәбәр ителә. Патша чоры паспорты белән озын юлга чыгу куркыныч ич. Авылына кайтып, ат, арба хәстәрләве, юлчы вак сәүдәгәргә охшатып кием-салым юнәтүләре турында авылдашлары истәлекләреннән беләбез. Ә Кызылъяр шәһәренә барып җитү вакыйгалары, өлешчә генә булса да, җәмәгате Гөлсем апа китабында китерелә. Анда Кызылъярга бәйле бер генә күренеш теркәлгән. Галимҗанның элек Уфада нәшер ителгән «Тормыш» газетасы мөхәррире, хәзер Колчак армиясендә хезмәт итүче Вагыйз Нәүрузов белән бер конторада очраклы рәвештә очрашу очрагы. Әлбәттә инде, әдип, үзен танытмас өчен киез эшләпәсен баса төшеп киеп, конторадан тиз генә чыгып китә.

Ә бит шул ук шәһәрдә берничә ай элегрәк кенә большевиклар тарафыннан Уфадан сөреп чыгарылган Милли идарәбез вәкилләре эшләп ята. Анда алар, Казан-Уфа якларына әйләнеп кайткач, Идел-Урал Штаты автономиясен ни рәвешле итеп төзи башлау турында уйланып, фикерләшеп гомер итәләр. Шул уй-фикерләре тупланган, яңарак кына нәшер ителә башланган «Маяк» газеталарын ни рәвешле Идел-Урал тарафларына җиткереп тарату мәшәкатьләре белән көн уздыралар. Бу җәйдә монда Милли идарәнең иң актив вәкилләре – рәис урынбасары, сул эсер Ибнеәмин Әхтәмов, Гаяз Исхакый, Фоат Туктаров, Габделбари Баттал, Закир Кадыйри һәм башка шәхесләр тупланган була. Шул шәһәрдә алар берничә ай дәвамында «контрреволюцион» дип бәяләнәчәк «Маяк» газетасын төрле тарафка таратырга тырышалар.

Әлбәттә, Г. Ибраһимов аларның монда икәнлеген һәм ни белән шөгыльләнгәнен Уфада чакта ук белгән була. Монда килгәч тә классик әдибебезнең дә шулар тирәсенәрәк елышыр нияте булмадымы икән соң дигән «көфер» уйлар да башка килгәли. Ләкин әлегә шул хакта бернинди мәгълүмат та юк. Шунда очрашкан булсалар, бәлки, берәрсе язып та чыккан булыр иде. Шул ук вакытта Галимҗанны Совет хакимияте эзәрлекләвеннән саклау өчен махсус рәвештә язмаган булулары да ихтимал. Шушы тема-

га багышлап Афзал ага Шамов белән фикер алышкан заманнар да булды. Ул да: «Ачыклыйсы нәрсәләр бар әле», – дип кенә җавап биргән иде. Аның тарафыннан 1966 елда чыгарылачак истәлекләр китабына бу вакыйгага караган ике генә язма урнаштырылган. «Шушы ук сәяхәтне башкачарак тасвирлаган тагын бер-ике истәлек бар иде. Әлегә без аларны ул китапка кертмәскә дип киңәштек», – дигән иде Афзал абый. Ул истәлек язмалары, бәлки, каядыр сакланадыр да.

Ул вакытта шул ук Кызылъярда казах кардәшләребезнең үз автономиясен булдыру турында шул вакытта ук хыялланган Алаш Урда төркеме вәкилләре дә тупланган була. Галимҗан агабызның андагы элекке танышлары белән аралашуы турыда да әлегә бер хәбәр дә юк.

Әйе, безнең заманда Галимҗан Ибраһимовның большевиклар эзәрлекләвеннән качып ерак казах иленә барып сыенган элекке фикердәшләре белән очрашуы турында хәбәрләр булмады. Һәм репрессияләнгән олуг әдипнең аклануы чорында андый очрашуларны искә алу кирәкмәс тә иде. «Яңа патша» булырга хыялланган адмирал Колчак биләмәсенә Галимҗан агабызның «разведкага бару» версиясе аклана иде. Әлегә бу вакыйга әдипнең «разведкадан кайтышлый Чиләбе шәһәрендә урнашкан Кызыл Армия берәмлегенең сәяси идарәсенә кереп», Колчак армиясенә бәйле разведка хәбәрләрен җиткергәнлеген бәян итү белән тәмамлана.

Шул серле, катлаулы сәяхәтеннән соң Галимҗан Ибраһимов кабат Казанга килеп урнашачак. Җиң сызганып, татар матбугатын барлау, оештыру эшләренә керешәчәк. Шул мәшәкатьләрдән арынган араларда, элек башлаган әдәби әсәрләренең карамаларын кабат карап чыгып, нәшриятларга тапшырачак. Совет хакимияте чорында иң тәүге булып аның «Безнең көннәр» романы басылып чыгачак. Булачак җәмәгате Гөлсем апа Мөхәммәдова искә алганча, әдип 1918 елда Владимир Ильич Ленинга биргән вәгъдәсен дә онытмый. Казанга кайтып төпләнгәч тә, коммунистлар партиясенә кабул итүләрен үтенеп гариза бирә.

Соңгы сүз итеп шуны гына өстисе кала: олуг әдибебез биографиясенә һәм җәмәгать эшчәнлегенә караган «ак таплар» бик күп икән әле. Аның иҗатын барлауга күп көч куйган абруйлы галим Мансур Хәсәнев, күренекле әдип Афзал Шамов, Гөлсем (Өммегөлсем) апа Мөхәммәдова Галимҗан Ибраһимов исемен кабат халкына кайтару юнәлешендә зур эш башкардылар. Элек барысын да ачыктан-ачык язарга мөмкинчелек булмады. Яшерен архивлар ишеге хәзер генә теләр-теләмәс ачыла башладылар. Уйлавымча, әлеге архивларда шушы язма каһарманына бәйле күп кенә хәзинә сакланган булырга тиеш.

*1997*

# ОФЫК ЧИТЕНДӘГЕ ЙОЛДЫЗ

*(Очерк)*

Офык киң. Анда, хыялга бирелеп, күзәтеп торырдай йолдызлар да бихисап күп. Баш түбәсендә үк якты нур сибеп торганнары да бар алар арасында. Күк читеннәнрәк кенә балкып куйгалаганнары да күренгәләп китә...

1917 елгы үзгәрешләрдән соң элек изелгән, икенче дәрәҗәле халык дип йөртелгән милләтләр арасыннан да, баш өстендә калыккан әлеге йолдызлар кебек, күпчелекнең күңелен җәлеп итәрдәй гамәлләр кылган зур шәхесләр калкып чыга. Шушындый зур үзгәреш дәверендә яңа тормыш төзү хыялын тормышка ашырырга керешкән максатчан шәхесләр арасында татар халкы вәкилләре дә ишле генә була. Татар милли автономиясен төзүгә үз өлешләрен кертүче яңа чор дәүләт эшлеклеләре, яшь комиссарлар Мулланур Вахитов, аның урынбасары Галимҗан Ибраһимов, тәүге хөкүмәт башлыкларыннан Борһан Мансуров, Сәхипгәрәй Сәетгалиев, Мирсәет Солтангалиев – 1917 елгы түнтәрелеш дәверендә калкып чыккан беренче милли йолдызларыбыз. Патша хакимияте чоры дәвам итсә, татар милләтенең узаман шәхесләренә җиң сызганып эшләрдәй андый мәйдан бирелмәс иде. Яңа чорга аяк атларга беренче юл күрсәтүчеләр булган шул милләттәшләребезгә һәм аларның көрәштәшләренә бүген дә рәхмәт әйтеп яшәргә тиешбез. Элекке заманда яшәүне дәвам итсәк, яу-сугышлар кырында хәрби осталыклары ачылган Ильяс Алкин, Хөсәен Мәүлүтев, Йосыф Ибраһимов, Якуб Чанышев, Муса Мортазин һәм башка бик күп хәрби җитәкчеләребез барлыгын да без белми калыр идек. Чөнки элекке вакытта аларны бригада, дивизия кебек зур-зур хәрби берәмлекләр белән җитәкчелек итәргә куймаслар иде. Шул үзгәреш елларының ялкынлы комиссарларыннан Шамил Усманов, Бәкер Белоусов, Кәрим Хәкимовлар хакында да шул ук сүзләрне әйтергә була.

Шушы беренче дулкында күтәрелгән шәхесләребез үрнәгендә, аларга сыенып вә таянып, әдәбият-мәдәният күгендә калыккан йолдызларыбыз исә безнең милләт вәкилләре арасында икеләтәөчләтә күбрәктер, мөгаен. Шундый шәхесләр исемлегенә мин күпмедер дәрәҗәдә якташым дип таныган Заһид Шәркый-Йосыповны да кертер идем. Ата-анасы Җаек суы буендагы Зобачи авылының татар атлы казаклары нәселеннән булган, үзе Оренбург каласында үскән бу егет яшьли җәмәгать эшләрендә актив катнаша. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда ук, ундүрт-унбиш яшеннән, бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә төрле вазифалар үти. Баштарак, мәдрәсәдә укуыннан аерылмыйча, Муса Җәлилнең абыйсы Ибраһим Җәлилов белән бергә шул ук басмаханәдә хәреф җыючы һөнәрен үзләштерә. 1916–1917 елларда Заһид, уналты-унҗиде яшендә, шунда ук мөхәррир-корректор

ярдәмчесе булып эшли башлый. Күренекле әдип, мөхәррир-корректор Шәриф Камал аның остазы була. Киләчәктә, 1917 елгы үзгәрешләрдән соң да алар, остаз белән шәкерт, бергә-бергә берничә газетаны бергәләп нәшер итәчәкләр. Әйтик, 1919 елның гыйнварыннан Оренбургта чыга башлаган «Эшчеләр дөньясы»ның баш мөхәррире – Шәриф Камал, аның урынбасары Заһид Шәркый-Йосыпов була, дип хәбәр итеlә шул төбәккә бәйле язмаларда.

Мәдрәсәдә Заһид белән бер үк елларда булачак күренекле шәхесләрдән Кәрим Хәкимов, Шамил Усманов, Төхфәт Ченәкәй, яшьрәк буын вәкилләреннән Муса Җәлил, Сәгыйть Агиш укыганнар. Заһидның түбәнрәк сыйныфта укучы Муса белән үзара аралаша башлавына курсташы Ибраһим Җәлилов сәбәпче, әлбәттә. Ә соңрак Заһид белән Мусаның дустанә мөнәсәбәтләре ага-брат мөнәсәбәтләре рәвешен алачак.

Оренбургта Совет хакимияте беренче мәртәбә 1918 елның гыйнвар урталарында урнашкач та, Заһид Йосыпов коммунист чордашлары тарафыннан «Мөхбир» газетасының мөхәррире итеп билгеләнәчәк. Әмма бу газета бик кыска гомерле була. Шул ук елның җәендә кызыллар казах илендәге Актүбә шәһәренә таба чигенергә мәҗбүр ителәләр. Бу вакыйга «Хөсәения» мәдрәсәсендә бер чорда укыган Шамил Усмановның «Легион юлы» әсәрендә бик җентекләп тасвирланган. Әлеге легион гаскәриләре шәһәрне калдырып китәр алдыннан гына Заһидның, үз газетасын тотып, аларга килеп кушылуы да тасвирланган ул әсәрдә. 1919 елның 22 гыйнварында Кызыл гаскәр Оренбургны кабат яулап ала. Шул ук «Легион юлы» әсәрендә хәбәр ителүенчә, дутовчылар белән сугыш барышында Заһид яралана, контузия ала. Әмма яңа тормыш кору өчен барган җитди көрәш барышында лазаретта озак ята алмый. Шул айларда ук Заһид Йосыпов «Юксыллар хакыйкате» (берникадәр вакыттан соң «Юксыллар сүзе») газетасын башлап нәшер итүдә актив катнаша. Берара ул газетаның баш мөхәррире булып та торачак. «Хөсәения» мәдрәсәсендә Муса Җәлил белән бер чордарак укыган Башкортстан язучысы Сәгыйть Агиш бер истәлек язмасында: «Шул газетада Мусаның да бер шигыре басылып чыккан иде», – дип язды. Ләкин әле Муса Җәлил иҗатын барлаучылар ул газета бәйләмнәрен таба алмады, ахрысы. 1920 елдан, баш мөхәррир Афзал Таһиров чорында, шул ук газетаның җаваплы сәркәтибе вазифасын Һади Такташның үтәгәнлеге дә мәгълүм. Ләкин әле аның да бер ел дәвамында шул газетада ни-нәрсәләр бастырганлыгы әдәбиятчыларыбызга билгеле түгел. Чөнки Оренбург архивларында ул газетаның берничә саны гына сакланган. 1970 елда шул архивка, татар матбугатын тәртипкә китерү өчен, Казан университетын тәмамлаган белгеч тә җибәрелә. 1971 елда әдип Мәҗит Рафиков белән шунда

булганда, без ул Мая ханымның бик тырышып эшли башлаганын күргән идек. «Менә бер бүлмәгә өсте-өстенә өеп куелган газета өемнәрен актарып, тәртипкә сала башладык», – дип әйткән иде ул. Шунда ук аңа ярдәмләшеп йөрүче элекке журналистлар Фатих Кыргызбаев һәм Сабит Якупов агалар белән дә таныштык.

Заһид Шәркый-Йосыповның даими рәвештә нәшер ителмәгән кайбер газеталарны чыгарышуда катнашуын да билгеләп үтик. 1918 елның гыйнвар ахырында Оренбург Совет хакимияте вәкилләре кулына күчә. Кәрим Хәкимов тиздән губернаның азчылык милләтләр белән эшләү бүлеге җитәкчеләренең берсе итеп билгеләнә. Заһид та алар төркеменә тартыла. Аның төп бурычы яңа матбугатны, мәдәният учакларын оештыруда катнашу була. 1917 елның көзендә Борһан Шәрәф мөхәррирлегендә чыга башлаган «Оренбург мөхбире» газетасын да, юнәлешен һәм исемен бераз үзгәртеп, аңа редакцияләүне йөклиләр.

1919 елның мартында Башкорт Совет автономиясе идарәсе дә Оренбургта оештырыла. (Бу вакытта Зәки Вәлиди оештырган, Мәскәү түрәләре кабул итмәгән автономия хөкүмәте хәзерге Баймак шәһәре тирәләренә китеп урнашкан була.) Яңа автономия идарәсенең башлыгы яшь коммунист, «Хөсәения» мәдрәсәсенең элекке хәлфәсе Габдулла Дәүләтшин була. Ул ярым мөстәкыйль автономияне оештыру эшенә мәдрәсә шәкертләрен дә җәлеп итә. Автономия җитәкчелеге «Башкортстан хәбәрләре» газетасын нәшер итәргә ниятләгәч, ул эшне башкарып чыгу да Заһид Гайфулла улына йөкләнә. Һәм бу газетаны ул автономия идарәсе шул елның көзендә яңа башкалага – Эстәрлетамак шәһәренә күчеп киткәнче баш мөхәррир буларак нәшер итәчәк.

* * *

1920 елның апрелендә исә Оренбург шәһәре Казахстан Республикасының беренче башкаласы буларак билгеләнә. Патшалар дәверендә дә монда казах иленең көнбатыш тарафлары белән идарә итү бүлекчәсе булган. Ә 1913 елдан шушы ук шәһәрдә демократик фикерле яшьләр тарафыннан оештырылган «Казакъ» газетасы да чыгып килгән. Аны нәшер итүче Әхмәт Байторсынов, Мәгъҗан Җомабаевлар белән Галимҗан Ибраһимовның аеруча дустанә мөнәсәбәттә булуын да әйтеп үтү урынлы булыр. Әдипнең «Казакъ кызы» романы да Мәгъҗанның бер куплет шигъри эпиграммасы белән башланып китә ич. Заһид та бу газетаны ташбасмада басып чыгару чорында ук катнашкан була. Бу газета да, бераз соңрак шул телдә нәшер ителәчәк яңа чор газета һәм журналлары да Рәмиевләрнең яңарак кына Совет хакимиятенә тапшырылган «Вакыт» типографиясендә басылалар. Заһид та типографиядә хәреф җыючы рәвешендә «Казакъ»

газетасын нәшер итү чорында ук катнаша. Аның һәм Муса Җәлилнең беркадәр казах телен чамалаулары шул «Казакъ» газетасының Оренбургта нәшер ителүенә дә бәйледер, мөгаен. Яңа республика монда оешкач та, Заһидның казах телендә нәшер ителүче газета-журналлар эшендә бик актив катнашканлыгын якташлары искә алалар.

Казахстан Республикасының беренче көннәрдән үк диярлек нашир ителә башлаган газетасы «Енбекше казах» (хезмәтчән, эшчән казах) була. Ул газетаны чыгаруда Заһид Шәркый-Йосыповның ни рәвешле катнашуы әле минем тарафтан ачыкланмаган. Соңрак ул татар һәм казах милләтләренә багышлы, ике телдә дә аңлаешлы «Юл» («Җол») белән «Сабан» газеталарының баш мөхәррире була. 1970 елларда бер очрашу вакытында сеңлесе Маһишәкәр апа әйткән бер истәлек тә хәтердә саклана. 1924 елгы җәйге каникул вакытында шул редакцияләрнең берсендә Муса Җәлил дә эшләп киткән. «Абыйның истәлек язмасында ул хәбәр булырга тиеш», — дигән иде сеңлесе. Ул байтак еллар Оренбург партия оешмаларында төрле вазифалар башкарган апа иде. Бик җаваплы эшләр башкарганлыктанмы, абыйсының язма истәлекләренең бер ишен генә саклый алганлыгын белдергән иде. Абыйсының Муса Җәлилгә кагылышлы истәлек язмасының да Уфа матбугатында кайчан нәшер ителгәнен искә төшерә алмадык.

1925 елның урталарыннан Оренбург РСФСРга кергән бер өлкә башкаласы булып кына кала. Казахстан хөкүмәте Кызыл Урда шәһәренә күчерелә. Шул хөкүмәтне алып киткән поездга тагылган бер вагонда 1906—1925 елларда Оренбургта татарча, башкортча һәм казахча нәшер ителгән дистәләп исемдәге газета-журналлар да озатыла. Шул сәбәпле Оренбургта ул гасырның беренче чирегендә нәшер ителгән татар матбугатының тулы исемлеге дә сакланмаган.

Заһид Шәркый-Йосыпов Оренбургта яшәгән егерменче елларда дүрт пьеса да иҗат иткән. Һәм аларның дүртесе дә Оренбург татар театры тарафыннан сәхнәләштерелгән була. Аеруча аның 1926 елның декабрендә куела башлаган «Алмаз кылыч» пьесасы уңышлы бара. Шул ук елларда ул театрда Хәбибулла Ибраһимовның (шул дәвердәге Ибрай Хәйбушның) «Мөкатдәс сарай», «Зөбәрҗәт», «Башмагым» кебек әсәрләре дә куела. Һәм алар Заһид Гайфуллла улы әсәрләренә караганда отышлырак булгандырмы — 1950—1960 елларда шәһәр музеена куелган афишалары ишлерәк иде кебек хәтердә калган.

Шул ук елларда Заһид Йосыпов «История революционного движения Оренбурга» (1927) дип исемләнгән гыйльми хезмәт тә туплап чыгара. Һәм шул ук елдан монда аның мөхәррирлегендә өлкә партия комитеты карамагындагы «Очкын» газетасы да чыга башлаячак. Кайчандыр шул газетаны кулларында тоткан,

соңрак монда нәшер ителүче татарча «Коммунист» газетасында эшләгән Фатих Кыргызбаев (шагыйрь Төхфәт Ченәкәйнең авылдашы), Сабит Якупов агалар белән дә 1971 елда очрашкан идек, дидем. Алар Заһид агаларының журналист һәм кеше буларак бик тә инсафлы җан иясе икәнлеген искә алдылар. Дәрдемәнд, Фатих Кәрими, Шәриф Камал һәм алар даирәсенә кергән шәхесләр йогынтысында тәрбияләнгәнлеге сизелә иде, диделәр.

Оренбург өлкәсе ул дәвердә Урта Идел буе округына кергән була. 1928 ел ахырында округ күләмендә танылган журналист Заһид Шәркый-Йосыповны Самарага чакырып алалар. Һәм ул монда 1929–1930 елларда округның рәсми милли газетасы саналган «Урта Идел»нең баш мөхәррире була. Шуннан соң аны Мәскәүгә, ВКП(б) Үзәк комитеты карамагындагы Марксизм-ленинизм университетына укырга җибәрәчәкләр.

Маһишәкәр апа абыйсының Мәскәүдә Муса Җәлил белән кабат аралашуын искә алды. Ләкин тәүге елларда ул аралашуның ни рәвешлерәк булганлыгын әйтә алмады. «Абый укыган елларда мин Мәскәүдә була алмадым», – диде. Икееллык курсларда укуын тәмамлагач, Заһид Йосыповны Донбасска татар телендә чыгучы «Пролетар» газетасына баш мөхәррир итеп җибәрәләр. «Ул чорда Донбасс шахтёрларының дүрттән бер өлеше чамасы безнең татар кешесе булгандыр», – дип сөйләгән иде бервакыт Нәби ага Дәүли. Хәсән Сарьян «Азат хатын» журналында эшләгән чакта, аның бүлмәсендә Нәби аганың Донбасста үткәргән елларын бик кызыксынып тыңлаган идек. Ул анда корыч кою заводының көн-төн дөрләп янып торган мичләренә вагонетка белән ташкүмер ташучы да, ут чәчеп януын дәвам иткән күмер шлакларын шул вагонеткаларга төяп цехтан чыгарып торучы да булган икән. «Күрәмсез минем биттәге вак-вак кара тапларны? Шул дөрләп янган шлактан очкан күмер бөртекләре таплары инде алар... Детдомнан соң килеп эләктем мин ул эшкә. Үз теләгем белән түгел...»

Дөрес, ул кичтә безнең әңгәмә Һади Такташтан башланган иде. Һади Такташның Донбасска шахтёрлар белән очрашырга дип махсус килгәнлегеннән башланып киткән иде. «Минем бик мавыгып шигырь иҗат итә башлавым да шул вакыйгага бәйле, – дип сүз башлаган иде Нәби ага. – Нәкъ шул чакта безнең телдә «Пролетар» дигән газета да чыкты. Мин ул газетага мәкаләләр дә, шигырьләр дә җибәреп тора идем. Бераздан мине редактор үзенә эшкә алды. Заһид атлы, катлаулырак фамилияле бер кеше иде». «Заһид Шәркый-Йосыпов түгел идеме? Шундый фамилияле бер якташым да ул газетада эшләгән», – дип сорадым. – «Әйе, әйе, шул иде, – дип раслады Нәби ага. – Мин аңа мең мәртәбә рәхмәтлемен. Шул Заһид иптәш мине дөрес юлга кертеп җибәрде, кеше итте. Ә гомер буе

шул заводта эшләсәм, нәрсә булып бетәр идеме? Тамак тук, өс бөтен булса да, чын шагыйрь булып китә алыр идемме? Мәңге рәхмәтлемен мин синең якташыңа. Ул мине газетага эшкә алды. Шунда мин беренче тәҗрибәмне тупладым. Детдомнан соң үз-үземне кеше итеп тою чоры шул газетта эшли башлагач булгандыр...»

Заһид Гайфулла улы Йосыповка чордашларыннан аерылып яшәү озакка бармый. 1932 елның ахырында аны якын дус-ишләре Мәскәүгә чакырып кайтаралар. Һәм ул СССР Үзәк Башкарма комитетының Милләтләр советы карары белән татар телендә чыга башлаган «Коммунист» газетасының баш мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. Ул елларда аның ни-нәрсәләр язганлыгы, «Коммунист» газетасы сәхифәләрендә ни-нәрсәләре чыкканлыгы барланмаган. Сеңлесе Маһишәкәр әйтүенчә, аның Оренбургтан киткәннән соң дөньяга чыгарылган хезмәтләре Мәскәү өлкәсенең Домодедово шәһәрендә яшәүче кызында сакланырга мөмкин. Миңа ул абыйсы кызының адресын да биргән иде. Домодедовода яшәүче ул ханым исә бераз үпкә хисен сиздергәнрәк җавап кайтарды. «Муса Җәлилне «Коммунист» газетасына эшкә алучы әти булган. Нигә аны бер дә искә алмыйлар» дигәнрәк сүзләр дә бар иде ул русча язылган җавап хатында.

Әйе, 1932 елның декабрендә Муса Җәлил җитәкчелегендә нәшер ителгән «Октябрь баласы» журналы чыгудан туктый. (Бу журналда Нәби ага Дәүлинең дә берничә шигыре басылып чыккан.) Һәм киләсе ел башында Муса Җәлилне әлеге «Коммунист» газетасына эшкә алалар – әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире итеп куялар. Бу якташлар әлеге газета ябылганчы – 1934 елның ахырынача бергә эшләячәкләр. Заһид Шәркый-Йосыповның якын якташына багышланган истәлек язмалары бездә басылмаганлыктан, аларның үзара аралашу мизгелләре дә бүгенге укучыга мәгълүм түгел.

Газета редакцияләрендә эшләү белән бер үк вакытта, 1934–1937 елларда, Заһид Гайфулла улы Кызыл профессорлар институты дип аталган уку йортында белем үзләштерүен дә дәвам иткән. Ә «Коммунист» газетасы ябылгач, аны СССР Язучылар берлеге тарафыннан нәшер ителгән «Литературная газета»га эшкә билгелиләр. 1935 ел башыннан алып 1941 елның сентябрь ахырынача (газета берара ябылып торганчы) ул милләтара бәйләнешләр бүлегендә эшли. Берара шул бүлекнең мөдире вазифасын да башкара. Союздаш һәм автоном республика оешмалары белән эшли, элемтә тота. Ул төбәкләрдә оештырылган чараларда катнаша.

Мәскәүгә командировкаларга йөрелгән чакларда мин бер мәртәбә ул газета редакциясенә кереп, сугыш алды елларында чыккан берәр бәйләм газетагызны карап чыгарга рөхсәт итмәссезме, дип тә сораган идем. «Капылт кына белдерелгән үтенечегез-

не үтәп булмас, алдан заказ бирәсе булыр», – диделәр. Әлбәттә инде, кабат анда барылмады.

Заһид Шәркый-Йосыповның соңгы ике газетада әдәби-мәдәни темаларга атап язылган күләмле мәкалә һәм очерклары әле бездә тупланмаган һәм тикшерелмәгән. Домодедово шәһәрендә яшәүче кызы да: «Аннары сугыш башланды бит. Урыннан урынга да күченгәләдек. Газета язмалары түгел, Оренбург театрында куелган пьесалары да сакланмаган», – дип язган иде.

«Литературная газета» сугыш башлангач чыгудан туктый. Партиянең Үзәк Комитеты Заһид Шәркый-Йосыповны Башкортстан Республикасының Кыйгы районы партия райкомына эшкә билгели. Кыйгы бик бай да, зур да район түгел инде. 1944 ел урталарынача ул анда райкомның пропаганда бүлеге башлыгы вазифасын башкарачак. Сугышка бәйле авырлыклар бераз кими төшкәч һәм якынаеп килүче картлык авырулары көчәйгәч, шул ук елда аңа Уфага күчәргә рөхсәт бирелә. Һәм 1944–1956 елларда, йөрәк авыруы тәмам аяктан екканчы, ул Башкортстанның Тарих, тел һәм әдәбият институтында фәнни хезмәткәр вазифасын башкарачак. 1955 елда Уфада нәшер ителгән «Башкорт әдәбияты тарихы» җыентыгында аның фәнни-тарихи хезмәтләре дә саллы гына була. Һәм шул ук 1955 елда безнең олуг якташыбыз филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә дә ирешәчәк. Шундый дәрәҗәгә ирешү дипломы аңа 1955 елда тапшырыла.

Шул ук Майшәкәр апа хәбәр итүенчә, Заһид ага Уфага килгән чорда анда Оренбургтан күчеп тупланган танышлары да ишле генә була әле. Алар бигрәк тә драматург һәм композитор Ибраһимов Хәбибулла белән якын мөнәсәбәттә булалар.

Элегрәк елларда минем архивта Заһид Шәркый-Йосыпов белән Муса Җәлилнең Оренбургта күмәк төркемдә бергә төшкән берничә фото да бар иде. Аларның берсен мин 1990 елларда нәшер ителгән «Татарстан хәбәрләре» газетасында бастырып та чыгарган идем. Хәзер алар сакланмаган икән.

Заһид Гайфулла улы Шәркый-Йосыпов 1960 елда, алтмыш яше тулырга берничә ай калгач, арабыздан мәңгелеккә китеп бара. Уфа шәһәре зиратында җирләнә.

Җаек-Урал суын эчеп үскән, татар мәдәнияте дөньясында сизелерлек эз калдырган шәхесләрдән Кәбир Бәкер (Кәбир Кәрим улы Бакиров), аның авылдашы Заһид Гайфулла улы Шәркый-Йосыпов, патшалар дәверендә үк Петербург университетын тәмамлаган Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров, шигърият өлкәсендә Мусаның остазы дип танылган Төхфәт Ченәкәй-Самави мираслары һаман әле татар дөньясыннан читтә кала сыман. Берничә ел элек мин фәнни институтыбыз архивына Шакир Мөхәммәдъяровның ГУЛАГ лагереннан чыккач язган унбиш хатын тапшырган идем. Шул хатларның берсендә Хәсән Туфан-

ның ул елларда язган шигыренә карата хат авторы фикере дә теркәлгән иде.

Милләтебезнең ирекле яңа тормыш коруга кергән чорында шактый зур эшләр башкарган, туган телебездә яңадан-яңа газета-журналлар чыгуын оештырган, милли телдә укытучы югары уку йортларын булдыруга үз өлешләрен керткән бөек шәхесләребезне онытмасак иде. Шул ук хезмәтләре белән алар милли татар телебезне саклауга һәм таратуга да зур әһәмият биргәннәр. Шулар өчен генә булса да, без аларны ара-тирә искә алгаларга тиешбез.

*2014*

# III

*Бар уем кичен-көндезен*
*сезнең хакта, милләтем.*

*Г. Тукай*

# МИЛЛӘТНЕҢ ЙӨЗ АКЛЫГЫН САКЛАУЧЫЛАР

*(Очерк)*

Россиядә яшәүче төрки милләтләр арасында басма китап чыгару эшенә иң әүвәл безнең татарлар керешә. Әлбәттә, татарларга бу эштә патша хакимияте дә күпмедер этәргеч биргән диярлек. Дөресрәге, ул хакимият, Казан каласының Россия империясендәге дәрәҗәсен танырга мәҗбүр булып, 1804 елда анда университет оештыру карарын чыгарган. Һәм шуңа бәйле рәвештә монда Россия биләмәсендәге иң тәүге «азиатский басмаханә» дә ачылган. Икенче-өченче нәүбәттә китап басу эшенә керешүчеләр – азәрбайҗаннар («Кавказ татарлары») белән үзбәк кардәшләребездер. Ташкентта төрки телдәге беренче басма хәрефле газета 1870 елда борын төртә. Аны оештырып чыгаручы милләттәшебез – Оренбург төбәге морзаларыннан булган Шаһимәрдән Ибраһимов. Шунда ук аның фарсы теленнән тәрҗемәдә «Мең дә бер кичә» әсәре дә, атлы казаклар тарихын чагылдырган үз китаплары да, үзбәк телендә еллык календарьлар да нәшер итеlә башлый. Бакуда да милли телдә газета һәм китаплар басу эшенә шул ук XIX гасырның җитмешенче елларында керешәләр 1875 елда Бакуда Азәрбайҗан телендә «Игенче», ике-өч елдан соң Тифлиста гомум Кавказ төркиләре телендә «Зыя-и Кавказия», 1882 елда шул ук Тифлис каласында «Кешкул» газеталары чыга башлый.

XX гасыр башында татар телендә китап нәшер итүче басмаханәләр һәм аерым нәшриятлар Россиядәге күпчелек губерна башкалаларында эшләп килә. Совет хакимияте урнашкан беренче көннәрдән үк мондый таркаулыкка чик куярга теләк белдерелә. РКП(б) Үзәк Комитеты 1918 елда ук барлык шәхси басмаханәләрне берләштерү, үзәкләштерү буенча беренче талпынышын ясый. Әйтик, шул ук елның февралендә Оренбургта Рәмиев һәм Хөсәенов байларның басмаханәләре хуҗаларыннан тартып алына, башка басмаханәләр белән берләштерелә. Ә инде Бердәм дәүләт нәшриятларын булдыру турындагы катгый карар 1919 елның июлендә чыгарыла. Утызынчы еллардагы үзгәрешләргә чаклы Дәүләт нәшрияты рәвешендә оештырылган ул идарәгә шул төбәктәге барлык басмаханәләр дә буйсындырыла, китап сәүдәсен оештыру бурычлары да аңа йөкләнә. Газета-журналлар да шул нәшрият карамагында дөнья күрәләр. Мәсәлән, «Казан утлары»ның элгәреләре дә, башка барлык журналлар да 1958 елга чаклы Татарстан китап нәшрияты канаты астында

яшәп килә. Ул мәҗмугаларның баш мөхәррирләре дә, Татарстан Журналистлар һәм Язучылар берлеге белән киңәшеп, нәшрият җитәкчелеге карары белән билгеләнәләр.

Егерменче еллар урталарына чаклы РСФСР Дәүләт нәшриятының Казан бүлегенә чуваш, мари телләрендә матбугат нәшер итүче бүлекчәләр дә беркетелгән була. Татарстан автономияле совет республикасын оештыру декреты кабул ителгәннән соң, 1920 елның ноябреннән Казан губернасы бүлеге Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгосиздат) исеменә үзгәртелә. Хуҗалык, исәп-хисап эшләре буенча ул Татарстан совнархозына буйсындырыла. Ә нинди китаплар нәшер итүне планлаштыру, нинди газета-журналлар чыгаруны билгеләү бурычы Мәгариф халык комиссариаты һәм аңа буйсынган Гыйльми үзәк карамагына калдырыла. Һәм шушы тәртип 1945 елга кадәр саклана диярлек. Дөрес, китап сатуны оештыру йөген 1936 елда ук махсус карар белән сәүдә оешмаларына тапшырган булалар. Ә 1945 елда элеккеге Татгосиздат җирлегендә Нәшрият һәм полиграфия сәнәгате идарәсе оештырыла. Шул рәвешле басмаханәләр дә нәшрияттан аерыла. 1949 елда шушы идарәгә китап сәүдәсе оешмасы (Таткниготорг) да килеп кушыла. Нәшрият һәм полиграфия сәнәгате идарәсе баштарак турыдан-туры Министрлар советына буйсындырылган булса, 1953–1963 елларда исә Мәгариф министрлыгы карамагында да эшләп ала. Ә 1991–2001 еллар аралыгында бу идарә мөстәкыйль министрлык буларак яшәде. Китап нәшрияты белән турыдан-туры җитәкчелек иткән әлеге министрлыкның татар матбугаты язмышы хәл ителгән авыр еллардагы соңгы министрлары күпләребезгә таныш абруйлы шәхесләр Ислам Галиәхмәт улы Әхмәтҗанов белән Шамил Шәмси улы Хамматовлар булды.

Казан губернасы карамагындагы тәүге Дәүләт нәшрияты бүлеге җитәкчеләре башка милләт вәкилләре булган. Хәер, үзебезнең милли шәхесләребез дә бу эштән читтә тормаган. Мәгълүм ки, бу елларда Галимҗан Ибраһимов Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариатында да, РКП(б) Үзәк комитеты каршындагы Шәрык халыклары оешмаларының Үзәк бюросында да матбугат эшләре өчен җаваплы булган. Димәк, Дәүләт нәшриятының Казан бүлеген оештыру эшләрендә ул турыдан-туры катнашкан. 1920 елдан башлап Татгосиздат идарәсе Мәгариф халык комиссариаты белән бергә кулга-кул тотынышып эшли. Ул еллардагы Мәгариф халык комиссарлары – Шәһит Әхмәдиев белән Исхак Рәхмәтуллин – Галимҗан Ибраһимовның иң якын фикердәшләре. Өстәвенә Г. Ибраһимов үзе дә нәкъ шул чорда, шушы комиссариат карамагындагы Гыйльми үзәкне җитәкләгән ич. Ә аңа чаклы бу Гыйльми үзәкнең җитәкчесе булып Төркия белән Бельгия югары уку йортларында да белем алган Гаяз Максудов эшләгән. Ул да, мөгаен, милли матбугатның һәм милли китап нәшер ителешенең алга китүе өчен тырышкандыр. Китап нәшрияты елъязмасының 1920–1930 елларга караган өлешендә Галимҗан Ибраһимов, Ис-

хак Рәхмәтуллин, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали исемнәре баш редактор буларак та теркәлгән. Мөгаен, бу очракта кайберләренең «Безнең юл», «Мәгариф», «Атака» кебек журналларның баш мөхәррире булып эшләгән еллары да искә алынгандыр. Язучы Г. Галинең утызынчы еллар дәвамында (1937 елда кулга алына) китап нәшриятында даими эшләве һәм баш мөхәррир вазифасын да үтәгәнлеге турында өстәмә мәгълүматлар бар.

Ә 1922 елдан башлап татар мәдәнияте үсеше өчен бик кадерле булган ул Татгосиздат (1940 елларда Татиздат рәвешендә дә теркәлгән) идарәсе белән фәкать үз кешеләребез җитәкчелек иткән. Шул елда ул җитди вазифаны үтәү бурычы элекке полиграфист, яшь коммунист Нурис Мохтаровка йөкләнә. Нуристан соң Татарстан дәүләт нәшриятын (һәм, әлбәттә, бу оешмага буйсынган басмаханәләр, басылып чыккан китапларны барлап барырга тиешле Китап палатасы һ. б.) җитәкләгән «управляющийлар» исемлегендә Шәфигуллин Вәли Сәлим улын, Шәрәфетдинов Самат Җамал улын, Тинчурин Закир Вәли улын (ун елдан артыграк эшли), сугышка китеп һәлак булган Арсланов Шакир Баһаутдин улын, булачак әдәбият профессоры Гайнуллин Мөхәммәд Хәйрулла улын санап китәргә кирәктер. Башка иярчен оешмалардан арынып, фәкать кульъязмаларны китап рәвешенә китерүче саф нәшрият вазифасын үтәүче Татарстан китап нәшрияты директорларын да санап үтик: Салих ага Вәлиди (1957–1963, шуннан соң ул Китап сәүдәсе оешмасына эшкә билгеләнә), Гыймади ага Камалиев (1963–1973), Гарәф Низаметдин улы Шәрәфетдинов (1973–1987), язучы Ринат Мөхәммәдиев (1987–1989), журналист Харис Әшрәфҗанов (1989–1998 ).

Санап кителгән исемнәр арасыннан аеруча атап үтәргә лаеклы шәхесләр дә бар. Вәли Шәфигуллин белән Самат Шәрәфетдинов исемнәре Бауман урамындагы үзенчәлекле Матбугат йортын һәм шуңа өстәп салынган заманча җиһазлы полиграфия комбинатын төзүне (1933–1935) оештыручылар буларак тарихка кереп калган. Камил Якуб исемен йөрткән полиграфия комбинаты җитмеш еллар чамасы көне-төне эшләү дәверендә берничә меңләгән исемдә, дистәләгән миллион данәдә татар һәм рус телләрендә китаплар бастырып чыгарды. Хәер, ул комбинат цехларында татар һәм рус телләрендә басылган китаплардан тыш, башка тугандаш республикалар телендә дә миллионлаган данәдә затлы-затлы китаплар нәшер ителгән. Байтак еллар минем китап киштәсендә казах әдәбияты классигы Сәкен Сәйфуллинның шул комбинат тамгасы белән 1935 елда чыгарылган затлы, калын «Тар жол, тайгак кичү» романы торды. Әйе, ул комбинатта байтак еллар дәвамында казах, каракалпак, төрекмән телләрендә китаплар да, дәреслекләр дә басылган. Хәтеремдә әле, 1970–1980 елларда Төрекмәнстан, Каракалпакстан республикаларыннан китап чыгару мәшәкате белән килеп йөрүче кан кардәшләребезнең, кунакханәгә урнаштыруны үтенеп, ул вакытта Матбугат йор-

ты бинасында булган Язучылар берлеге оешмасына мөрәҗәгать иткән чаклары. Ә бер таныш төрекмән язучысының үз китабын чыгаруны тизләтергә ярдәм итүемне үтенеп язган ике-өч хаты бүген дә миндә саклана.

1972 ел урталарына кадәр Матбугат йорты дигән мәһабәт бинада Татарстанда чыккан барлык газета-журнал редакцияләре эшләде. Алар аерылып чыккач та анда Татарстан китап нәшрияты коллективы, Полиграфия комбинаты идарәсе, китап сәүдәсе оешмасы, Китап палатасы, чыгасы китапларның сәяси эчтәлеген тикшереп торучы цензура идарәсе, Татарстан язучылар берлеге һ. б. бик күп оешмалар, шул исәптән 1945 елда барлыкка китерелгән Матбугат һәм полиграфия сәнәгате идарәсе дә XXI гасыр башларынача «яшәде». Ә бинаның бишенче катында урнашкан Тукай исемен йөртүче клубта исә һәр атнаның җомгасында диярлек кызыклы-кызыклы әдәби-мәдәни очрашулар, ә атна дәвамында исә төрле-төрле җыелышлар булгалап торыр иде. Архитектура һәйкәле буларак танылган ул бина диварына күптән инде архитектор С. С. Пен исеме белән янәшә Татиздат идарәсенең 1930 еллар башындагы идарәчесе С. Шәрәфетдинов, һәм ул бина белән полиграфия комбинаты аякка бастырылган чорда партиянең Татарстан өлкә комитеты вәкиле буларак төзелешкә җитәкчелек иткән В. Шәфигуллин исемнәрен теркәп, затлы бер истәлек тактасы куелырга тиеш иде дип уйлыйм.

* * *

Бөек Ватан сугышына чаклы татарча вакытлы матбугат һәм татар китаплары РСФСРның кайбер башка өлкәләрендә эшләүче дәүләт нәшриятлары тарафыннан да нәшер ителгәннәр. Мәсәлән, Куйбышев, Оренбург, Свердловск, Чиләбе өлкәләрендә, Себер тарафларында аерым әдәби яисә иҗтимагый-сәяси эчтәлекле китапларның басылган булуы Татарстан китап палатасы хезмәтләрендә теркәлгән. Шулай ук күпләребезгә мәгълүм ки, байтак кына күренекле шәхесләребез иң әүвәл шул төбәкләрдә нәшер ителүче газета-журналларда каләм чарлаганнар. Шуннан соң гына Татарстан китап нәшрияты белән хезмәттәшлекләрен дәвам иттергәннәр. «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире һәм Муса Җәлилгә багышланган берничә китап авторы Шәмси ага Хамматов Свердловск өлкәсендә таралган вакытлы матбугатта, ә фәнни-тәнкыйди әдәбият гыйлеменә караган китап авторларыннан Хәсән Хәйри Себер төбәгендәге өлкәара «Азат Себер» газетасында, Шакир Абилов исә Оренбургта (ул чорда шәһәр Чкалов исемен йөртә) татарча нәшер ителүче «Коммунист» газетасында көч сынаганнан соң, Казанга килгәннәр. Һәм андый шәхесләребезнең исемлеге болар белән генә дә чикләнми. Әйтик, киләчәктә балалар әдәбиятын үстерүгә үз өлешләрен керткән Абдулла Әхмәт, Идрис Туктар һ. б. да

бар әле. Ләкин утызынчы еллар ахырына табарак Татарстаннан читтә эшләп килүче, татарча китаплар чыгаручы нәшриятлар ябылалар.

Татарстан китап нәшриятының эш нәтиҗәләре буенча алга киткән, ә кадрлар мәсьәләсендә фаҗигаләр кичергән чоры да 1930 елларга туры килә. Бу елларда китап нәшриятында күренеклерәк әдипләрнең сайланма әсәрләрен һәм күп томлы китапларын чыгару омтылышлары да ясала. Татар телендә язылган әсәрләрне даими рәвештә русчага тәрҗемәдә нәшер итә башлау үрнәкләре дә шушы елларга туры килә. Мәсәлән, 1936 елда, шагыйрьнең тууына илле ел тулуга нисбәтле рәвештә, Г. Тукайның зәвыклы итеп эшләнгән, ярыйсы ук күләмле «Избранные стихи» китабы дөнья күрә. Аңа чаклы язучы һәм мөхәррир Фатих Сәйфи-Казанлы тырышлыгы белән аның әсәрләренең татарча өч томлыгы басылып чыккан була (1929–1931). Галимҗан Ибраһимовның алдан планлаштырылган җиде томлыгыннан өч томы шулай ук утызынчы еллар башында нәшер ителгән. Шул елларда нәшриятта өлкән мөхәррир вазифаларын үтәгән Афзал ага Шамов сүзләренә караганда, әдип әсәрләренең тагын өч томының корректура вариантларының бер өлеше, автор тарафыннан кабат тикшерелеп, Кырымнан Казанга кайтарылган була. Г. Ибраһимовның шул көздә кулга алынуы сәбәпле, ул томнар нәшер ителмичә кала һәм юкка чыгарыла.

Бу чорда Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөдирләре һәм мөхәррирләре исемлегендә без күренекле әдипләребездән тагын Фатих Кәрим, Нур Баян, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Госман Бакиров (балалар әдәбияты бүлеге мөдире), Гасыйм Лотфи (татар телендә чыгучы дәреслекләр өчен җаваплы мөхәррир, соңыннан байтак еллар дәвамында Мәгариф министрлыгында эшли), Гази Кашшаф, Әнәс Камал, Кәшфи Басыйров (матур әдәбият үрнәкләрен, шул исәптән М. Лермонтовның «Безнең заман герое»н татар теленә тәрҗемә иткән автор, сугышта һәлак була), Фәтхи Бурнашларны очрата алган булыр идек. Афзал ага хәтерләвенчә, Матбугат йортының дүртенче катындагы 84 нче бүлмәдә алар дүртәү утырганнар: Ф. Бурнаш, И. Гази, Ф. Кәрим һәм тагын кемдер. «Фәтхи син утырган өстәл артында, ишектән кергәч тә уң тарафта утыра иде. (Әйе, 1980 елларда без дә дүртәү: Максим Глухов, Юныс Әминев, Альберт Тәхәвиев һәм мин шул бүлмәдә утырып эшләдек.) Фәтхине кулга алгач та, аның өстәл тартмасындагы, китап шкафындагы барлык кәгазьләрне җентекләп карап, язып чыктылар да, Гази белән икебездән кул куйдырдылар... Ул елларда нәшриятта андый хәлләр еш кабатланды. Фатих Кәримне дә безнең алда кулга алдылар. Аларны гаепләтергә теләп, безне төрмәләргә дә күп мәртәбәләр йөрттеләр, – дип, Афзал ага шул көнне безгә күп нәрсәләр сөйләгән иде. – Милләт, милли тел яшәсен өчен эшләүче оешма вәкилләре булганлыктан, ул чакта без барыбыз да яшерен

күзәтү астында тордык. Һәрберебезнең күңелендә «кайчан кулга алырлар икән» дигән курку хисе яшеренгән иде». Әйе, А. Шамов ул елларда «кулак малае» буларак та, Мәскәү университетын тәмамлап кайткан кеше рәвешендә дә аерым шик астында тора, әлбәттә. Шул елларга кагылышлы КГБ архивы документлары белән таныш булган Рафаэль Мостафин хезмәтләрендә тасвир ителүенә караганда, А. Шамов, кайберәүләрдән аермалы буларак, каләмдәшләре язмышына бәйле эшләрдә шаһитлык итәргә туры килгәндә дә бик сак кыланган, аларны гаепләү юлына басмаган.

Әйе, замана чиренә бәйле рәвештә кадрлар еш алышынып торуга карамастан, Татарстан китап нәшрияты утызынчы еллар дәверен дә уңышлы ерып чыга алган. Бөтен СССР буйлап сибелгән татар мәктәпләре өчен дәреслекләрне җитәрлек күләмдә бастырып чыгарганнар, матур әдәбият әсәрләрен нәшер итүгә дә өлгергәннәр дияргә була. Нәкъ шул елларда рус һәм башка милләтләр әдәбиятлары үрнәкләрен даими рәвештә тәрҗемә итеп бастыру тәртибе дә кертелә. Үзара бәйләнешкә кереп, үз әдипләребезнең китапларын кайбер кардәш республикалар нәшриятларына да тәкъдим иткәлиләр.

Бу елларда киң тармаклы нәшрият һәм китап басу, тарату эшенә җаваплы кешеләрнең дә исемнәрен атап үтәргә кирәктер. Алда телгә алынган Самат Шәрәфетдиновтан соң абруйлы җитәкче буларак Закир Тинчурин таныла. Бер истәлек язмасында Гомәр ага Бәширов аның турында мондый сүзләр китерә: «Акыллы, тәҗрибәле кеше. Кешене аңлый торган зат», – ди. Әйе, ул чордагы нәшрият идарәсе башлыгын әдип көн саен аралашкан җитәкчесе буларак яхшы белә. Чөнки сугыш алды елларында ул, «Совет әдәбияты» мәҗмугасының җаваплы сәркәтибе буларак та, матур әдәбият редакциясе мөхәррире вазифасын үтәгәндә дә аның белән көн саен диярлек аралашып торган.

Сугыштан соңгы елларда, Казан педагогия институтын җитәкләгән дәвердә дә Закир Тинчурин Татарстан китап нәшрияты белән тыгыз элемтәдә тора. Институтта белем алган шәкертләреннән иҗат эшенә сәләтлерәкләрен башта нәшриятта практика үтәргә димли, соңрак шунда эшкә билгели торган була. Илленче еллар башында шул рәвешле мөхәррир булып китүчеләрдән үзем Әнисә Ибраһимова, Рәис Даутов, Таһир Нурмөхәммәтовларны яхшы беләм. Ул исемлектә әле мин аралашмаган тагын кемнәрдер бар. Боларның өчесе дә соңрак язучы буларак та танылган шәхесләр. Дөрес, Әнисә ханым, күпчелек язучылар тарафыннан да яратып кабул ителгән «Томан таралганда» повестен китап рәвешендә чыгарганнан соң (1967), никтер тукталып калды шикелле. Язучылар берлегенә дә кабул ителмәде. Нәшриятта эшләгән елларда ул табигать фәннәреннән рус телле дәреслекләрне оста тәрҗемә итүче буларак та танылган иде. (Дөрес, нәшриятта миңа аның белән бер чорда эшләргә туры килмәде.)

* * *

Ниһаять, күпләребезгә танышрак заманга, сугыштан соңгы дәвергә дә якынлаштык шикелле. Кайчандыр үзем язган «Мылтык һәм каләм берлеге» мәкаләсендә хәбәр ителгәнчә, ул чордагы күп профильле Татарстан китап нәшриятының фәкать китап редакцияләү һәм басмаханәгә әзерләү бүлегеннән Бөек Ватан сугышына утызлап ир-ат һәм берничә хатын кыз мобилизацияләнә. Шулардан күпләребезгә мәгълүм исемнәрне генә санап үтик: булачак полк комиссары, Берлин тирәләрендәге сугышта һәлак булган Нур Баян, алдарак искә алынган Кәшфи Басыйров, 1942 елда үзе теләп фронтка киткән миномёт взводы командиры Госман Бакиров (өлкән яшьтә булуы сәбәпле, ул мобилизацияләнү исемлегендә тормаган), сугышка китү теләгән белдергәч төрмәдән азат ителгән булачак пехота взводы командиры Фатих Кәрим (хәзерге Калининград шәһәре тирәсендәге сугышта һәлак була), пехота взводы командиры Сибгат Хәким, тупчы Мөхәммәт Садри һ. б. 1942 елда үз теләкләре белән яу кырына китеп, шул ел карары белән татарча чыга башлаган фронт газеталарына билгеләнгән, капитан дәрәҗәләрендә дошманны җиңеп кайткан Ибраһим Гази белән Афзал Шамов та бар. 1941–1942 елларның зәмһәрир кышында Апас белән Тәтеш араларында туң җирне чокып окоп һәм дзот базлары казырга мобилизацияләнгән дүртбиш хатын-кызны да сугышта катнашучылар исемлегендә санарга хаклыбыз.

Әйтергә кирәк, Казанда калып, үз эшләрен икеләтә норма үтәп дәвам иттергән сугыш чоры хатын-кызлары да чыдам, көчле рухлы булырга тырышып, ачлы-туклы яшәп, суык бүлмәләрдә авыр шартларда китап һәм газета-журналлар чыгаруны тоткарламаганнар дияргә була. Сугыш елларындагы мәктәп укучысы буларак шуны әйтә алам: безнең Казахстан чикләренә чиктәш авыл мәктәбе китапханәсенә Казаннан дәреслекләр дә, әдәби әсәрләр тупланган китаплар да өзлексез диярлек килеп торды. Хәтеремдә әле шул елларда нәшер ителгән китаплардан Һ. Такташның «Караборынның дусты»н, Г. Әпсәләмовның «Төньяк балкышы»н күмәкләшеп укуыбыз. Илнең башкаласында һәм күпчелек өлкәләрдә байтак кына газета-журналларны нәшер итү тукталып торган елларда да Казандагы төп газеталар һәм «Совет әдәбияты» мәҗмугасы басылып чыгуларын дәвам иттергән. Шунысы да гыйбрәтле: сугышка чаклы яисә сугыш чорында эшли башлаган, авыр еллар чыныгуын узган күпчелек хатын-кызлар, китап нәшрияты коллективының төп кадрлары буларак, монда утызар-утыз бишәр ел эшләде. Пенсия яшенә җиткәч тә, мөхәррирлек, корректорлык вазифаларын калдырып китәргә ашыкмыйча, яшь кадрларга үрнәк буларак эшләделәр алар. Китап нәшриятында утыз ел дәвамында корректор да, мөхәррир дә, дәреслекләр нәшер итүче бүлек мөдире дә булган Фирдәвес Болгарская «Тылсымлы йорт»

дип исемләнгән бер мәкаләсендә нәшриятта эшләү елларын искә алып мондый сүзләр яза: «Бу йортның үзенә тартып торган тылсымлы көче, килеп кергән кешене, үзенең эшенә тартып алып, бөтен күңелен, белем һәм мәхәббәтен биреп эшләргә мәҗбүр итү үзенчәлеге югалмады. Югыйсә хезмәт хакы шактый түбән иде, ә эше гаҗәеп катлаулы, четерекле, вак һәм җаваплы булды».

Әйе, нәшриятка эшкә урнашкан кешеләрнең күпчелеге бердәм, үзара бик тату коллективта эшләүләре сәбәпле дә, китап басып чыгару эшенең халкыбызның киләчәк язмышына бәйле булганлыгын тою хисе нәтиҗәсендә дә дистә еллар дәвамында үз вазифаларын үтәүне дәвам иттерәләр. Дөрес, шунда эшли-эшли тәҗрибә туплаган, каләм шомарткан корректор вә мөхәррирләрне нәшрият башлыклары да үз вакытында күргән – аларны өстәмә түләүле тәрҗемә эшләре белән дә тәэмин итәргә тырышкан. Рус яисә башка телләрдән тәрҗемә итеп чыгарылган дистәләрчә әдәби әсәрнең яисә йөзләгән уку әсбапларының шушы нәшриятта күңелен, җанын биреп эшләгән сүз осталарының хезмәт җимеше булуын танырга тиешбез.

Сугыш тәмамлангач, нәшрият тормышы яңадан җанланып китә. Бу дәвердә нәшриятта яңадан эшли башлаган язучылар исемлеген искә алып үтик. Госман Бакиров, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Абдулла Әхмәт, Сибгат Хәким (икесе дә сугышка чаклы ук «Совет әдәбияты» журналы хезмәткәре булган), Сәхаб Урайский, Афзал Шамов элекке эш урыннарына кайтып утыралар. Бераз соңрак алар төркеменә яңарак кына хәрби киемнәрен салып куйган Зәки Нури, Хисам Камалов, Салих Хәким, Ислам Беляев, Сафа Сабиров, Мәхмүд Хөсәен һ. б. килеп кушыла.

Илленче еллар башында Казан дәүләт университетының яңарак ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенең беренче һәм икенче чыгарылыш студентларыннан да ишле бер төркем нәшриятка эшкә билгеләнә. Университет юлламасы белән эшкә килгән һәм гомерләрен китап нәшер итүгә багышлаганнар арасыннан Резедә Хәлиуллина-Вәлиева, Кыям Миңлебаев, Яхъя Халитов, Мәхмүт Хөсәен, Фәния Гайнанова, Сания Сибгатуллина кебек фидакяр затларны атап үтәргә кирәктер. Булачак халык язучылары Гариф Ахунов белән Нурихан Фәттах та, элекке курсташларыннан калышмаска теләгәндәй, вакыт-вакыт нәшрият штатында теркәлеп, эшләп алгалаганнар.

* * *

Хуҗалык тармагында сугыштан соңгы авыр еллар дәвам итүгә, китап басарга кирәкле булган кәгазьнең тиешле күләмдә чыгарылмавына карамастан, илленче елларны китап нәшриятының чәчәк аткан дәвере дип санарга хаклыбыз. Бу чорда элек хаксыз рәвештә хөкем ителгән, әсәрләрен нәшер итү тыелган бөек каләм ияләрен аклау хәрәкәте башлана. Китап нәшриятында бер-бер

артлы Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең өчтомлыгы, Фатих Сәйфи-Казанлы әсәрләре, Хәсән Туфан шигырьләре, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин пьесалары тупланган җыентыклар басылып чыга. Бөек Ватан сугышы барышында әсирлеккә эләгеп, шунда җәзалап үтерелүгә карамастан, «хыянәтчеләр» тамгасы тагылу сәбәпле иҗатлары тыелган шәхесләрдән Муса Җәлил, Абдулла Алиш әсәрләрен кабат нәшер итәргә рөхсәт бирелгән чор да бит бу. Шушы елларда аларның үз әдәби әсәрләре дә, алар батырлыгына багышланган документаль хезмәтләр белән беррәттән аерым әдәби әсәрләр дә дөнья күрә. Шундый әсәрләр рәтендә, мәсәлән, күренекле казах шагыйре Җобан Молдагалиевнең Муса Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгын данлаган мәшһүр «Үлемсез җыр» поэмасын да искә төшерү урынлы булыр.

Бу үзенчәлекле күчеш дәверендә фәкать китапны басмага әзерләү белән шөгыльләнүче нәшрият коллективын ике шәхес – Газиз Нәбиев (1953–1957) белән Салих Вәлиди (1957–1963) җитәкләгән. Баш мөхәррир вазифасын Хәмит Мөҗәһитов башкарган (1956–1963). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәктер: Татарстан китап нәшрияты оешкан көненнән башлап әдәби-җәмгыяви китапларны нәшер итү белән генә шөгыльләнмәде. Үз ана телебездә басылган андый китаплар саны байтак еллар дәвамында 40–50 % тан артмагандыр. 1960 еллар кергәнче СССР күләмендә урнашкан барлык татар мәктәпләре өчен дәреслекләр нәшер итү дә безнең нәшриятка йөкләнгән иде.

Безнең бабайларның табигать торышына карата еш кабатлап әйтә торган бер әйтеме бар. «Илгә уңыш китерә торган явым-төшемле еллардан соң корылык килүчән», – дип әйткәннәр алар. Бу әйтем нәшриятыбыз эшенә карата да туры килә диярлек. 1950 еллар ахырында Н. С. Хрущёв тирәсендәге «кара кардиналлар» татар һәм башка кайбер милләтләрнең мәгарифе тамырына үткен кылычлары белән кизәнделәр. «Милли азчылык мәктәпләрен ябарга» дигәнрәк кискен, катгый сүзләр кулланылмаган бер карар 1957 елның март аенда булса кирәк үзәк газеталарда басылып чыкты. Ул карарда «милли республикалардан читтә урнашкан милли мәктәпләр язмышын ата-аналар хәл итә» дигәнрәк сүзләр язылган иде. Ягъни милли мәктәпләрне ябу кирәклеге турында без турыдан-туры әмер бирмәдек төслерәк шома сүзләр китерелгән иде ул карарда. Шул елларда мин әле Оренбург өлкәсендә эшли идем. Карар чыккан көздә үк күпчелек район мәгариф идарәләрендә милли мәктәпләр белән эш итүче инспекторларның эштән азат ителүен, авылларда татар мәктәпләренең бер-бер артлы ябыла башлавын хәтерлим. Ике-өч елдан соң өлкә күләмендә эшләп килүче ике милли педучилище ябылды. 1960 еллар башында Оренбург һәм Орск педагогия институтларындагы татар-башкорт факультетлары бетерелде. Чөнки татар телен белүче, барлык фәннәрдән үз телебездә дәрес бирерлек укытучыларның кирәге калмаган иде.

Әлбәттә, ул карар нәтиҗәләре тиздән Татарстан китап нәшрияты эшчәнлегенә дә китереп суга. Татарча дәреслекләр, уку әсбаплары чыгару өчен төрле өлкәләрдән килә торган заказлар туктала. «Әлифба»лар, «Татар теле», «Татар әдәбиты», татар телендә чыгып килүче башка күпсанлы дәреслекләрнең тиражлары кими башлый. Бераз соңрак нәшрият директоры булып эшләгән Гарәф Шәрәфетдинов бер мәкаләсендә, алтмышынчы еллар вакыйгаларын истә тотып, «Әлифба» дәреслекләрен нәшер итү планы икеләтә диярлек кимеде, дип язды.

Әмма бу карарның шаукымы әле ул елларда әдәби һәм җәмгыяви-сәяси китапларны бастырып чыгару тармагына зур зыян салмады. Киресенчә, Мәскәү тарафыннан ел саен бүлеп бирелә торган кәгазь фондының дәреслекләр чыгарудан янга калган өлеше күпмедер дәрәҗәдә әдәби, иҗтимагый-сәяси һәм күпмедер күләмдә тарихи-фәнни китапларның артыграк санда нәшер ителүенә китерде. Элекке татар мәктәпләрен тәмамлаучылар саны да әле җитәрлек күләмдә, татар китабын укучылар бөтен ил буйлап таралган чак иде. Китап сату оешмаларыннан заказлар күп килә. Шуңа күрә проза китапларының тиражы унбиш-егерме меңнән дә ким чыкмый иде. 1970–1980 еллар аралыгында нәшрият түрәләре: «Хәзер без һәр эш көнендә бер китап чыгарабыз», – дип мактангалап та куйгалаган чор булды ул.

Бу елларда Татарстан китап нәшриятын кемнәр җитәкләде, кемнәр аңа юнәлеш биреп торды соң? Шушы яңа чорга кергәндәге беренче директор Гыймади Камали улы Камалиев булды (1963–1973). Моңа кадәр ул берничә ел «Социалистик Татарстан» газетасында эшләгән, өч ел чамасы Шәмси Хамматовның урынбасары вазифасын үтәгән кеше иде. Ләкин нәшрият эшен эчтән белгән күпчелек, шул исәптән югары оешма түрәләре дә аның эшчәнлегеннән тулаем канәгать булмадылар кебек. Татарча китапларның гомуми саны елдан-ел артуга карамастан, һәр ел аша диярлек нәшрият үз чыгымнарын каплап, даими рәвештә табыш китерүгә ирешә алмады шикелле. Бу хәлне аның Мәскәүдәге җитәкче оешмалар белән ныклы элемтәгә керә алмавыннан килә дип юраучылар да булды. Һәрхәлдә, «ул нәшрият эшен рентабельле итә алмады» дип, 1973 елның урталарында аның урынына Шәмси аганың икенче урынбасарын – Гарәф Шәрәфетдиновны билгеләделәр. «Университетта татар бүлеген тәмамлаган, колхоз рәисе дә булган, нәшрият икътисадын ул тиешле дәрәҗәгә күтәрә алыр» дигән өмет белән каршы алды аны татар зыялылары. Бу өметне ул, нигездә, аклады. Ул эшли башлагач та, нәшрият үз чыгымнарын үзе исәбенә каплый алу мөмкинлегенә иреште. Г. Камалиев, гомеренең байтак өлешен В. И. Ленин әсәрләрен яисә партия эшлеклеләренә багышлы китапларны тәрҗемә итүгә багышлаганлыктан, китап нәшриятында эшләү дәверендә дә шул юнәлешкә өстенлек бирергә тырышты, ахрысы. Ә татар халкының үткән дәверләренә багышлы иске китапларны чыгаруга әзрәк әһәмият бирде бугай.

Ә Гарәф Шәрәфетдинов эшли башлаган көннәреннән үк татар галимнәре, тарихчылары белән дә уртак тел тапты. Тиздән китап киштәләрендә XII гасыр шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы, бөек шәхесләребездән булган Шиһабетдин Мәрҗанигә, Ризаэтдин Фәхретдингә һ. б. багышланган хезмәтләр, булачак академик Әбрар Кәримуллинның милли китап тарихына караган яңа хезмәтләре урын алды. Өч томнан торган «Герои Советского Союза – наши земляки» китабы да көтеп алынган басма иде.

Гарәф Шәрәфетдинов замандашыбызның «Чорлар алышынганда» язмасының кайбер җөмләләренә игътибар итеп үтик. «Нәшрият директоры булырга ризалык биргәч, әүвәл республиканың иң олы оешмаларында вазифамның нихәтле җаваплы буласын тукый-тукый аңлаттылар. Шуннан соң мине Мәскәүгә чакырып алдылар. Анда РСФСРның Матбугат комитетында булдым. Соңрак ул Госкомиздат дип үзгәртелде. Татарстан китап нәшриятына мине директор итеп Мәскәүнең шушы комитеты расларга тиеш икән... Комитет җитәкчеләренең үгет-нәсыйхәтләре Татарстанда нинди китаплар чыгарырга кирәклеген, ниндиләрен чыгарырга ярамаганлыгын аңлату иде... Баксаң, безнең нәшрият Росглавиздат белән килештермичә бер китап та чыгара алмый икән». Әйе, Совет хакимияте дәверендә менә шундый шартларда эшли милли нәшриятлар. Чыгарыласы китап санын да, аның исемлеген дә, шул исемлеккә кергән китаплар тиражын билгеләү өчен җитәрлек күләмдәге кәгазь фондын да ул елларда бары тик Мәскәү хәл итә торган иде. Урында эшләүче җитәкченең Мәскәү түрәләре белән элемтәсе ни дәрәҗәдә нык булса – эш нәтиҗәсе дә шундый була. Бу кагыйдәне кайчандыр үзем дә СССР Литфонды бүлеге директоры булган елларда ярыйсы ук үзләштергән шикелле идем.

Гарәф Шәрәфетдинов җирле һәм Мәскәү түрәләре белән уртак тел таба белүче директорларның берсе булды. Җитәкче булган кешегә андый сыйфат та бик кирәк. Китап нәшрияты директоры вазифасын ул 14 ел дәвамында башкарды. Элекке чор классик әдипләренең һәм тарихчыларның хезмәтләрен кабат бастырып чыгаруга да аның дәверендә җитди әһәмият бирелде. Унөченче йөз авторы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы шул дәвердә дөнья күрде. Ул эшләгән 1973–1987 елларда классик әдипләребездән Галимҗан Ибраһимовның сигезтомлык сайланма әсәрләре, Габдулла Тукайның биштомлыгы, Мәҗит Гафуриның дүрттомлыгы, Һади Такташ әсәрләренең өчтомлыгы, Хәсән Туфан белән Сибгат Хәкимнең икешәр томлыклары, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Гадел Кутуй, Гомәр Бәширов, Әхмәт Ерикәй, Гариф Ахунов һ. б. сайланма бертомлыклары һәм аерым әсәрләре басылды. Үзенчәлекле тарихи әсәрләрдән Нурихан Фәттахның икетомлык «Сызгыра торган уклар», Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнары да шул чор җимеше. Шул ук елларда Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт,

Фатих Кәрим, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт һ. б. әсәрләренең күптомлыкларын Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре белән бергә туплап-барлап чыгару эшенә дә керештеләр. Әдәбият галиме Ибраһим Нуруллинның ике бөек шәхесебез тормышын һәм иҗади эшчәнлеген киң чагылдырган күләмле ике әдәби-биографик эчтәлекле китабы – «Габдулла Тукай» белән «Фатих Әмирхан» да Гарәф директор булган елларда нәшер ителде. Бу китапларның берсен һәм алда телгә алынган китапларның кайберләрен басмага әзерләү-редакцияләү дәверендә мин дә катнашкан идем. Нәшрият белән унбиш еллап хезмәт итешү вакытында йөз иллеләп кече һәм зур күләмле китап редакцияләнгән.

Нәшрият директорлары булып эшләгән соңгы ике шәхес вакытында баш мөхәррир вазифасын өч кеше башкара: журналист һәм әдәби тәрҗемәче Хәбибулла Гобәйдуллин (1964–1972), язучылар Марс Шабаев (1972–1977) һәм Вакыйф Нуруллин (1977–1989 ел башы). Боларның урынбасарлары булып та ике эшлекле зат: Нурулла ага Габитов белән язучы, партия өлкә комитетында кешеләр белән аралашу тәҗрибәсе туплап килгән Әнәс Хәсәнов эшләде. 140 лап кешене берләштергән коллектив әгъзаларын тулаем санап китеп булмастыр. Шулай да кайберәүләрне искә алмыйча да мөмкин түгел. Студент елларында ук сәяси эзәрлекләүләр, кимсетелүләр чорын кичергән Адлер Тимергалинны Татарстан китап нәшрияты коллективы үз итеп, туган күреп кабул итә. Һәм монда егерме елдан артыграк эшләү дәверендә ул зур галим булып җитлегә. Хәтеремдә әле, берәр төрле сорау туса, яшьрәк буын мөхәррирләрдән тыш кайбер олырак абзый-апалар да энциклопедик белемле Адлерга мөрәҗәгать итәрләр иде. 1984 елда университетның татар бүлеген уңышлы тәмамлап килгән Дамир Шакиров та аны беренче остазы буларак таный. Бу елларда матур әдәбият редакцияләре мөдирләре вазифасын күренекле язучылар Шәүкәт Галиев, Фәрваз Миңнуллин, Шамил Рәкыйповлар башкарды. Фәнни, иҗтимагый-сәяси әдәбият бүлекләре җитәкчеләре дә язучылар Илдар Низамов, Рәфикъ Юныс, Вакыйф Нуриевлар булды.

Язмамның бу өлешен Гарәф Шәрәфетдиновның «Яхшы кешеләр янәшәсендә эшләве үзе бер бәхет!» дигән тирән эчтәлекле җөмләсе белән тәмамлыйсым килә.

1970–1980 елларда республиканың кайсы гына районына яисә күрше өлкәләрнең кайсысына гына барма, китап сөючеләр сатуда татарча китапларның аз булуыннан зарлана торган иде. Ә бит ул елларда балаларга багышлы китаплар утызар-кырыгар мең, проза әсәрләре кимендә ун-унбиш мең данәдән дә түбән тираж белән нәшер ителмәделәр. Нәшрият эшчәнлегенә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында татар телендәге дәреслекләр саны кимүгә карамастан, Г. Камалиев белән Г. Шәрәфетдинов җитәкчелек иткән чорны без татар китабы нәшер ителүнең алтын чоры дип таныргa тиеш булабыз.

* * *

Ләкин бу хәл инде каты сырхау җан иясенең үләр алдыннан бераз җанланып алуы күренешен генә хәтерләтә кебек. Сиксәненче еллар ахырына таба үз милли республикабызда да татар мәктәпләре бермә-бер кими диярлек. Элек-электән татар рухын саклап торган авылларыбыз саны да кими бара. Аларның бер өлеше Түбән Кама сусаклагычын төзү чорында юк ителде. Бер ишеләрен елдан-ел киңәя, зурая барган шәһәрләребез «йотты». Ельцин-Гайдарларның башбаштаклыгы нәтиҗәсендә колхоз вә совхозлар бетерелгәч, авылларыбыз язмышын тагын да аянычрак хәлләр көтмәгәе дип борчыла күңел.

Нәшрият коллективы белән ел ярым чамасы Ринат Мөхәммәдиев җитәкчелек иткән чорга тукталып тормаска да була. Ул, Гарәф сызган буразнаны вакытлыча дәвам иттерүче булды да, тиздән икенче оешмага күчте. Дөресрәге, Язучылар берлеге җитәкчелегенә сайланды. Шул рәвешле нәшриятның иң-иң авыр елларының камытын Харис Әшрәфҗановка кияргә туры килде. 1989 елның июнендә аны директор креслосына утырттылар. Моңа чаклы ул хуҗалык эшләре белән шөгыльләнмәгән, үзбаш хуҗа булып тормаган иде. Университетны тәмамлагач, укытучы, газета хезмәткәре, югарырак оешмалар тарафыннан финансланган редакцияләр мөдире булган. Нәшриятка билгеләнер алдыннан дүрт ел чамасы партия өлкә комитеты инструкторы иде. Холкы, сабырлыгы белән ул коллективка ошаган да иде. Ләкин кинәт кенә СССР дип йөртелгән империянең таркалуы, шуның нәтиҗәсендә ил күләмендә башланган хуҗасызлык яңа директорны бик-бик авыр хәлдә калдырды. Өстәвенә элекке татар мәктәпләрендә укыган кешеләрнең соңгы утыз елда әкренләп юкка чыга баруы, елдан-ел китапларның тиражы кимүе дә нәшриятның эшчәнлеген авырайта. Мәскәү инде нәшрият белән араны өзгән, читтән кәгазь кайтарылмый башлаган иде. Шул рәвешле, 1980 еллар урталарында 350 ләп китап чыгарып килгән нәшрият тәмам төп башына утыра. Ел дәвамында 80–90 китап нәшер итү белән чикләнә башлый. Китапның таралу тиражы да ике-өч меңнән артмый. Китап чыкмагач һәм сатылмагач, акча да килми. Татарстан хөкүмәте дә ул елларда нәшриятка зурдан кубып булыша алмый. Китап сәүдәсе оешмалары да тәмам таркала. Харис энебез бик зур авырлык белән 1998 ел чигенә килеп җитә дә, авыр камытын җилкәсеннән шудырып, берничә ел элек кенә урынбасар булып эшли башлаган Дамир Шакиров җилкәсенә элеп китә. Х. Әшрәфҗановның шундый шартларда сигез еллап эшли алуы – зур батырлык. Бу елларда баш редактор вазифасын үтәүчеләр Мөдәррис Вәлиев белән Фәрваз Миңнуллин иде.

Татарстан китап нәшрияты тарихында яңа чор башланды.

* * *

Дамир Сабирҗан улы Шакиров бу хуҗалыкны үз хезмәте белән үз-үзен тәэмин итеп яшәтердәй мөмкинлеге чикләнгән хәлдә кабул итә. Дөрес, берничә ел дәвамында директорның урынбасары булып тору аңа үз-үзенә ышаныч көчен арттыра арттыруын. Ләкин шуңа да карамастан эш башлап җибәрү чоры аңа да җиңел бирелми. Өстәвенә китап нәшрияты белән бер җепкә бәйләнеп, алтмыш ел чамасы бергә эшләгән Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатының да хәлләре елдан-ел хөртиләнә бара. Аның җиһазлары искергән, заман таләп иткән күләмдә төрле-төрле буяулы балалар китабын да, затлы коленкор тышлы китапларны да ул җитештерә алмый. Шул ук вакытта әле ул комбинатны, аның коллективын яшәтергә дә кирәк. Башлыча газета-журналлар нәшер итү өчен дип, 1970 еллар башында төзелгән, заманча җиһазландырылган элекке «обком басмаханәсе»нә күчәргә нәшриятка хөкүмәт рөхсәт бирми – искесенең язмышы хәл ителеп бетмәгән.

Китап нәшриятында Дамир Шакировның эшчәнлеге болай да авыр тормышны тагын да катлауландыра төшкән шундый чорга туры килә. Әмма әкренләп ул катлаулы мәсьәләләрнең берсе хәл ителә – без күнеккән иске полиграфия комбинатын бетерү карары чыга. Хөкүмәт, әкренләп көч туплап, үз карамагындагы нәшриятны коткарыр өчен, төрле-төрле юллар эзли. Нәшрият җитәкчелеге дә тик тормый. Шәһәр үзәгендә, Бауман урамында бер зур кибет подвалын арендага алып, анда нәшрият чыгарган китапларны сатуны оештыра. Сатып алучылар күңелен тартып торырдай итеп заманча җиһазландырылган, китапларның төрлесе, шул исәптән кирәкле дәреслекләр белән дә тәэмин ителгән ул китап кибетеннән хәзер халык өзелми. Тик әлегә ул кибетнең бердәнбер җитешсезлеге – тирән подвалда урнашкан булуында. Бер мәртәбә, депутатлар алдында чыгыш ясаганда, Туфан Миңнуллин да: «Ул кибет бит кабердән дә тирәндәрәк урнашкан. Хөкүмәт белән шәһәр советы аңа башка урын таба алмадылармы икәнни?» – дигән иде.

Абруйлы депутатыбызның шушы чыгышыннан соң да әле ул «кабердән дә тирәндәрәк урнашкан» китап кибете тиз генә урынын алыштырмады. Хәзер исә шәһәрдә нәшрият исәбендә йөргән берничә китап кибете эшли. Миңа еш кына элекке Матбугат йортындагысында һәм Г. Тукай мәйданындагы универмагта урнашканында булырга туры килә. Шәһәр халкын да, шәһәргә килүчеләрне дә ул кибетләрдә мин бик еш очратам.

Шул рәвешле, ана телебезнең язмышына да күпмедер дәрәҗәдә бәйле булган, аңа яшәү куәте өстәп торган милли нәшрият әкренләп XXI гасырга аяк басты. Әдәбият тармагында зур уңышларга ирешкән, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләренә ия булган, халык шагыйре яисә халык язучысы дигән дәрәҗәле исемнәрне яулап алган егермедән артык әдипнең күптомлыкларын дәүләт

ярдәме белән нәшер итү карарына киленә. 2000 елдан башлап шул карар тормышка да ашырыла башлый. Бүгенге көндә күренекле әдипләребезнең ике томнан алып ун томга җиткән сайланма әсәрләре китап һәм китапханә киштәләренә чыгарып тезелде.

Олуг классик әдипләребезнең күптомлыклары да нәшер ителә. Совет хакимияте елларында әдәбият мәйданыннан читләштерелгән Гаяз Исхакыйның унбиштомлыгы, үзенчәлекле шагыйрь һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең ана телендәге һәм русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен туплаган затлы китабы, аның тормышын һәм иҗатын чагылдырган күләмле фотоальбом да дөнья күрде. Бүгенге көндә Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең күптомлыгын нәшер итү хәстәре бара. Аларга бу олуг әдипнең Совет хакимияте дәверендә басарга рөхсәт ителмәгән күпсанлы мәкалә һәм гыйльми хезмәтләре дә керер дигән өметтә калам.

Дөрес, матбугатта андый күләмле томнарны күпләп чыгаруны хупламаган язмалар да күренгәләде. Ул язмалардагы төп фикер – андый томнарның саны бик зур булмаска тиеш. Алар әдипләрнең сайланма әсәрләреннән генә тупланырга тиеш дигән фикерләр әйтелде. Дөрес фикер.

Бу чорда шулай ук Татарстан китап нәшрияты рус телендә «История татар» («Татарлар тарихы») һәм «История татар в лицах» («Татарлар тарихында шәхесләр») дип аталган ике кызыклы сериягә кергән егермедән артыграк китап бастырып чыгарды. Бик матур, зәвыклы итеп эшләнгән, күп санда фотоматериал һәм кайбер язма вә документ копияләре белән дә баетылган бу китаплар рус телендә аралашучы, республикада яшәүче башка милләт вәкилләрен татарлар тарихы, аның атаклы шәхесләре белән таныштыру өчен дип нәшер ителәләр. Ул серияләрнең берсе – татарлар тормышына бәйле тарихи һәм иҗтимагый вакыйгаларны кыскача, укучыны ялыктырмас рәвештә тасвир итүче китаплардан тора. Икенчесе татарлар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр биографиясен һәм эшчәнлеген яктыртуга юнәтелгән. Китап тышлыгына «История татар» яки «История татар в лицах» дигән тамга да сугылган бу серияләрне тәкъдим итүче һәм булачак китап авторлары белән бергә оештыру эшләрен башкаручы тарих фәннәре кандидаты, нәшриятның фәнни һәм иҗтимагый китаплар чыгаручы редакциясенең элекке мөдире Булат Хәмидуллин була. Бу серияләрдә чыгучы басмаларның китап сөючеләр күңелендә кызыксыну уятуын «Дэрдменд» һәм «Амирхан Еники» җыентыклары авторы буларак та раслый алам.

Алда санап үтелгән һәм башка бик күп китапларны, шул исәптән балаларга багышлап иҗат ителгән, затлы рәсемнәр белән бизәлгән төрледән-төрле җыентыкларны оештырып һәм редакцияләп чыгарган кайбер җитәкчеләрнең, мөхәррир һәм баш мөхәррирләрнең исемнәрен дә атап үтик. 2015 елдан Та-

тарстан китап нәшриятының генераль директоры вазифасын Илдар Камил улы Сәгъдәтшин бик уңышлы үтәп килә. Аңа чаклы ул – республиканың Татмедиа оешмасында эшләп, оештыру тәҗрибәсен туплаган шәхес. 2019 елда Татарстан китап нәшрияты оешуның йөзьеллыгы чарасын бик зурлап уздыру да аның чорына туры килде.

Соңгы еллардагы баш мөхәрриребез дә әдәбият һәм әдәбиятны нәшер итү өлкәсендә танылган шәхес. Элек нәшриятта балалар әдәбияты бүлеге мөхәррире буларак сыналган, шагыйрь сыйфатында Муса Җәлил исемендәге республика күләмендәге һәм бөтенсоюз дәрәҗәсендәге бүләкләргә лаек булган Ленар Шәех. Ул – киң карашлы, зур белемле, берничә чит телдә дә аралаша алучы шәхес. Элегрәк «Шәһри Казан» белән «Татарстан яшьләре» газеталарында эшләп, тәҗрибә туплап нәшриятка килгән әдип.

Бүгенге көндә нәшриятның төрле редакцияләрендә танылган әдип һәм шагыйрьләребездән Газинур Морат, Галимҗан Гыйльманов, Рифат Сәлах бик уңышлы эшлиләр. Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Газинур Морат моңа чаклы байтак вакыт «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррир урынбасары булган иде. Бүгенге көндә ул Матур әдәбият редакциясе мөдире вазифасын бик теләп башкара. Соңгы дәверләрдә үзем аралашкан төрле юнәлештәге мөдир вә мөхәррирләрнең исемнәрен дә атап үтим. Венера Камалиева, Ләйсән Миңнуллина, Илһам Ногманов, Ринат Хәсәншин, Әлфия Шәйдуллина һәм Рәмзия Шакирова белән без берничә китапны бергәләп нәшер иттек. Шулар арасында Бөек Ватан сугышында җиңүнең җитмеш еллыгына багышланган, ике телдә аерым-аерым нәшер ителгән «Җиңү җиңел бирелмәде» томнары да бар. Һәм ул китаплар укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителде. Матбугатта уңай бәяләнделәр, һәм бу уңышлар алда искә алып кителгән мөхәррирләрнең осталыгына һәм тырышлыгына бәйле, әлбәттә.

Китап нәшриятының киләчәге дә бүген хәл ителә. Милли нәшрият язмышы – шул милләт язмышына бәйләнгән. Аның киләчәк язмышын хәл итү бурычын бүген нәшрият коллективы уңышлы башкарып килә. Киләчәктә дә хөкүмәтебез Татарстан китап нәшриятына төрлечә ярдәм итеп, үз ана телебездәге уку әсбапларының да, әдәби, тарихи һәм иҗтимагый-сәяси эчтәлекле китапларның да даими рәвештә нәшер ителеп чыгуына булышыр дигән өметтә калабыз. Киләчәгебез өметле булсын! Нәшрият коллективын нәшрият ветераннары исеменнән дә котлыйм!

*2019*

# РӘСӘЙДӘ БЕРЕНЧЕ МӨСЕЛМАН НӘЗАРӘТЕ

*(Тарихи очерк)*

1

Патша чоры Россиясе мөфтиләренең исемнәрен һәм алар кылган изге эшләрне хәзер бик сирәк искә төшерәбез. Элегрәк аларны яманлабрак телгә алган чакларыбыз да булды. Яисә ул шәхесләрнең кем, нинди дәрәҗәгә ия икәнлекләрен тәгаен белмәстән, хәзерге аерым төбәк, өлкә күләмендәге дин әһелләре белән тиңләү очраклары да күренгәләп тора. Мәсәлән, Үзәк Россия һәм Себер яклары мөселманнары эшчәнлеген оештыру һәм күзәтү өчен барлыкка китерелгән идарә җитәкчесе булган ахун Мөхәммәтҗан Хөсәеновны «Татарстанның беренче мөфтие» дип язып чыгу очраклары булды. Әйе, патшалар хакимлек иткән заманда Россиянең үзәк өлешендә һәм Себер тарафында яшәүче барлык мөселманнарның беренче Диния нәзарәте идарәчесе булган шәйхелислам Мөхәммәтҗан Хөсәен улы әл-Җәбәли әл-Борындыкыйны «Татарстанның беренче мөфтие» дип язу – зур хата. Кулларына богау салып, күкрәк өсләренә хач-тәре тагып, әби-бабаларыбызны чиксез җәберләп, диннәреннән яздырырга тырышып, мәчет-мәдрәсәләрне тузгытып йөргән Аксак Каратуннардан соң динебез сагына куелган ул хәзрәтләрне олылабрак һәм ешрак искә алу кирәктер безгә! Патша Россиясе дәверендә алар бит байтак кына изге эшләр башкарып калган. Кырык елдан артыграк үз вазифасын уңышлы башкарып килгән, бик авыр шартларда Изге Коръәнне өч мәртәбә бастырып чыгаруга ирешкән беренче мөфтиебезнең хәзерге Кайбыч районыннан чыккан шәхес икәнлеген дә күптән инде таныргa тиеш идек. Аның үз исем-атамасы һәм тәхәллүсе үк шул хакта әйтеп тора ич: Мөхәммәтҗан Хөсәен улы әл-Җәбәли әл-Борындыкый. Ягъни элекке Казан ханлыгының Тау (Җәбәл) ягындагы Борындык авылы кешесе. Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылында мәдрәсә тәмамлагач, Бохарага барып белемен камилләштергән, дини тәртип-тәрбияләрне тирәнрәк үзләштергән шәхес. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәт билгеләп үткәнчә, аның бабасы Мансур да «Болгар иленнән Бохарага барып укучыларның беренчесе» булган. «Фарсы телендә язылган «Тәракыйбе мансурия» китабы да аңа нисбәтләнә», – дип яза Ш. Мәрҗани. Бохарадан кайткач та Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый үз авылының мәдрәсәсен җитәкләп, аның данын тирә-якларга тараткан. Әмма никтер хәзер Борындык авылының ул мәдрәсәсе искә алынмый. Мансур әл-Борындыкыйдан соң аның дәрәҗәсе төшкәндер, күрәсең.

Патшабикә Екатерина Икенче, ягъни, әби-бабаларыбыз хөрмәтләп искә алган Әби патша карары белән оештырылган «Мөхәммәд динендәгеләр җәмгыяте идарәсе»нә (нәзарәтенә) ка-

гылышлы мәгълүматта да төгәлсезлекләр бар. Безнең тарихчы галимнәребез, әле һаман Совет хакимияте чорында кабул ителгәнчә, ул дини оешма Емельян Пугачёв бунтыннан соң, 1788 елда оештырылган дип кабатлыйлар. Мәчет һәм мәдрәсә биналарын җимереп, халыкны көчләп чукындырулар дәвам иткән бер чорда мөселманнар мәнфәгатен яклардай бер оешма булдыруны шул чор Төркия дәүләте таләп иткәнне искә алмыйлар. Моңарчы Россиядә булган кайбер вакыйгаларны гына искә төшереп үтик. «1740 елда императрица Анна Иоанн кызы 23 бүлектән гыйбарәт «Яңа чукындырылучылар конторасы»н оештыру фәрманын чыгара», – диелә Е. Маловның шул вакыйгага багышлы русча язулы хезмәтендә (1878, 3 б.). Тәхеттә аны алыштырган Пётр патша кызы Елизавета да «түтә»сеннән калышмаска тырыша. Елизавета белән килешкәннән соң, сенат (хәзергечәрәк итеп әйтсәк, хөкүмәтнең дини оешмаларга кагылышлы бүлеге) 1742 елның 17 ноябрендә Казан, Сембер, Әстерхан һәм Воронеж губерналарындагы мәчетләрнең эшчәнлеген чикләүгә кагылышлы фәрманга кул куя. Һәм менә шушы дини эзәрлекләүләрне бетерү кирәклеген таләп итүчеләр төрек кардәшләребез булганлыгын әйтергә һаман оялабыз сыман. Ә бит шул хакта Шиһабетдин хәзрәт йөз илле ел элек үк язып чыккан иде инде. Югарыда искә алынган Мөселман дини нәзарәтенең оештырылу датасын да, Россия белән Төркия арасындагы килешүгә һәм Әби патша чыгарган фәрманга нигезләп, 1778 елда булган хәл, дип язган иде ул. Бу очракта Шиһабетдин хәзрәт ялгышмыйдыр дип уйлыйм. Һәм патшабикә тарафыннан чыгарылган карарның элгәресе 1778 елда булгандыр дип кабул итәм. «Ун елдан соң ул идарә Уфага күчерелә. Патшабикә яңа указ чыгара» дип фаразлыйсы гына кала Ш. Мәрҗани китабын укыганнан соң.

Безгә күптән инде беренче дин әһелләребез җитәкләгән, императрица Екатерина Икенче рөхсәте белән оештырылган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең (русча: Оренбургское магометанское духовное собрание) барлыкка килерелү сәбәбен һәм вакытын төгәлрәк итеп ачыкларга вакыт җиткәндер. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре бу вакыйганы «1192 (1778) елның 22 сентябрендә Оренбург каласында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе ачылган» дип хәбәр итә. Моннан йөз илле еллар элгәрерәк шушы оешма эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнештә булган Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында бу оешманың барлыкка китерелү сәбәпләрен дә аңлата. «Бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю – Кече Кайнарҗа килешүе шартларының берседер», – ди. Госманлы дәүләте, ягъни Төркия белән Россия арасында 1768–1774 елларда барган сугыштан соң, Дунай елгасы буендагы шушы исемдәге торак мәйданында әлеге солых килешүе төзелгән. Һәм ерактагы дин кардәшләребез шул

солых килешүенә әлеге теләкләрнең теркәлүен таләп иткән булганнар икән. Ә без яшәгән дәвер китапларында исә бу идарәнең барлыкка китерелү фактын фәкать «Пугачёв бунты» вакыйгаларына гына бәйләп аңлаттылар. Дөрес, бу вакыйга да патша хөкүмәтенең әлеге карарны чыгаруына йогынты ясамый калмагандыр. Емельян Пугачёв җитәкләгән бу хәрәкәттә ирек даулап байтак кына мөселман өммәте вәкилләре – татар һәм башкортлар да бик актив катнашкан ич. Әмма шул ук вакытта Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре китергән фактларны да исәпкә алырга, Төркиядә яшәүче кардәшләребезгә рәхмәт сүзен ирештерергә вакыттыр, мөгаен.

Алда искә алынган ике ил арасындагы әлеге килешүдән соң бу оешманың барлыкка китерелүен Төркиянең күренекле тарихчысы Надир Дәүләт тә «Россия төркиләренең милли тарихы» китабында билгеләп үтә (Казан, 1998).

Шул ук хезмәтендә Шиһабетдин хәзрәт байтак документларда «Оренбург мөселман дине җәмгыяте идарәсе» дип теркәлгән оешманың барлыкка китерелү вакытын да 1778 (һиҗри белән 1192) ел дип күрсәтә. Бу идарәнең турыдан-туры башкаладагы Эчке эшләр министрлыгына буйсынган булуын да яза. Безнең дәвердә нәшер ителгән хезмәтләрдә исә бу сан 1788 ел рәвешендә теркәлде. Һәм күпчелек язмаларда, шул исәптән Энциклопедия институты чыгарган белешмәлектә дә һаман шушы сан китерелә. Нишләп шулай яза бүгенге галимнәребез? Ш. Мәрҗани язганнарга ышанмаслык нинди дәлилләре бар? Бу мәсьәләне ачыклау өчен күптән бит инде Петербургтагы архив документларын барып карау мөмкин иде. Шунда ук һәр мөфтинең бу эшне башкарырга кайчан керешкәнлеген ачыклардай әмер-фәрманнарны да тәгаенләп кайтып булгандыр. Алар бит әле ил күләмендәге вакыйгаларда да катнашкан шәхесләр. Әйтик, Россия императорларын тәхеткә тәгаенләү вакыйгаларында. Аларның кайчан һәм кайсы диндәш-милләттәшләре белән шунда катнашуын белү һич тә зыян итми. Ил, милләт хадимнәренең бөтен дөнья күләмендәге дәрәҗәле шәхесләр белән аралашуын ачыклау лабаса. Мәсәлән, 1896 елда Николай Икенче патшаны тәхеткә тәгаенләү тантанасында унга якын милләттәшебез катнашкан. 1980 елларда Ташкентта нәшер ителгән «Йолдыз» журналының бер саны Исмәгыйль Гаспринскийга багышланган иде. Шул ук кырымлы кардәшләребез нәшер иткән «Ленин байрагы» газетасы бүлмәсендә әлеге «Йолдыз»ны актаргалап утырам. Анда Николай патшаны тәхеткә тәгаенләүдә морза Гаспринский белән бергә катнашкан җиде-сигез татар кешесе дә күрсәтелгән. Шулардан хәзер хәтердә калганнары мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов белән М. Рәмиев кенә. Ул соңгы кешене әлеге әңгәмәдә катнашучылар: «Мөгаен, Мөхәммәтсадыйк хаҗи булгандыр ул, – диделәр. – Ул элек тә шундый бер тантанада катнашкан», – дип тә өстәделәр. Казанга кайткач исә мин ул М. Рәмиевнең Шакир (Мөхәммәтшакир) булуын ачыкладым.

Атасы исә бу вакыйгага берничә ел элек үк вафат булган икән. Үзебездә Гаспринскийга багышлап чыгарылган бер хезмәттә дә әлеге хата кабатланды. 1890 еллар башында вафат булган Садыйк хаҗины, Николай патшаны тәхеткә утыртуда катнашкан, дип яздылар. Үзебезнең шәхесләргә кагылышлы мәгълүматны вакытында барлаган булсак, андый хаталар да китмәс иде. Ә Кырымлы кардәшләребез барлый, ачыклый бит андый мәгълүматны.

Күптән түгел әле Мәскәү телевидениесеннән дә шундый бер кызыклы тапшыру карадым. Америкага күчеп яши башлаган монгол кешеләре ерак бабаларының «надан күчмәннәр генә булмыйча», байтак кына уң эшләр башкарганлыгын да дәлилләргә тырыша, борынгылардан калган язмаларны инглиз телләренә тәрҗемә итеп чыгара икән. Тимер уклар коюга да алар кытайлар белән бер чордарак керешкәннәр икән. Гоби ком чүлендә әле күптән түгел бер серле пирамидага да Америка археологлары белән бергә юлыкканнар, ди. Ә Көньяк Америкада гомер итүче төп халыклар, башлыча төркичә сүзләр кулланып сөйләшүчеләрнең борынгы язуын укуда үз ысулын тәкъдим иткән СССР галиме Ю. Кнозоров та 1990 елларда чыккан бер мәкаләсендә: «Без әле борынгы халыклар, шул исәптән монголлар тормышын да тулаем белмибез», – дип язган иде. Без дә әлегә төрле-төрле ташпулатлар эчендә бикләнеп ятучы архивлар белән танышуны һаман чигендереп киләбез. Югыйсә хәзер ул «яшерен базлар»ның ишеге бераз ачыла төшкән чак бит. Аларны белеп тору хәзерге заман кешесенә зыян итәме? Булган тарихны белеп тору һәрчак файдалыдыр дип уйлыйм. Казан ханлыгыннан төяп кителгән, тарихта «Иван Грозный китапханәсе» дип йөртелгән мирасханә дә, бәлкем, тулаем яндырылмагандыр. Борынгы мирасны «җир кыдырып эзләүчеләребез» аз шул әлегә. Шул ук мөфтиләр чорын өч-дүрт поэмасында чагылдырган Каргалы авылы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәд әл-Каргалый әсәрләренең Петербург белән Ташкент мирасханәләрендә сакланган өлешен генә булса да Казанга кайтарырга вакыттыр бит инде. Галим Мәсгуд Гайнетдинов аларның өлешчә шунда сакланганлыгын ярты гасыр элек үк язып чыкты ич. Дөрес, Совет хакимияте дәверендә мөфтиләрне мактап телгә алган андый әсәрләр кирәкмәгәндер дә. Хәзер башка вакыт ич!

Мөфтиятләргә бәйле мәгълүмати хаталарда кем хаклы? Шул оешма яшәгән заманда гомер иткән һәм шул дини идарәнең бер төбәк вәкиле булган Ш. Мәрҗаниме, әллә Совет хакимияте чоры белгечләреме? Бервакыт мин шундый сорауны хәзерге үзәк мөфтият оешмасында – Уфада хезмәт иткән, аның архив документлары белән берникадәр таныш булган чордашым Равил Үтәбай-Кәримигә дә биргән идем. 1980–1990 елларда Равил дустыбыз Уфадан Казанга бик еш сәфәр кыла иде. Татарстан китап нәшриятында аның бер-ике хезмәте дә басылып чыкты. Минем соравыма ул тулы мәгълүмат бирә алмады. «Уфадагы мөфтият архивында идарәнең оешу чорына караган документлар

сакланмаган. Дөреслекне ачыклау өчен Петербург архивларына мөрәҗәгать итәргә кирәктер», – дип җавап биргән иде ул.

Мөфтият дип йөртелгән дини идарәнең 1778 елда оешу датасы Ш. Мәрҗанинең беренче мөфти биографиясенә багышлы җөмләсендә дә раслана. «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат (Мөхәммәтҗан хәзрәт), озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти вазифасын үтәп, 1239 елда вафат булды», – дип яза ул (214 б.). 1239 дан 1192 не алсаң, 47 ел килеп чыга. Ягъни, нәсел башы хәзерге Татарстанның Тау ягыннан булган Мөхәммәтҗан Хөсәенов, кырык җиде ел мөфти вазифасын башкарганнан соң, хәзерге исәп белән 1823 елның декабрь – 1824 елның гыйнвар аралыгында бакый дөньяга күчкән. Шиһабетдин хәзрәтнең атасы 1801 елда Оренбургка барып, шул мөфти кулыннан «указлы мулла» таныклыгын алып кайткан. «Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин, мелла Фәтхулла ахун Орывый, мелла Байморад әл-Мәңгәри һәм башкалар һәммәсе аның фазыл (намуслы, кешелекле) һәм камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә ул бик галим буларак танылган. Ул гасырларда «Бохарадан укып кайттым» дигән мулланы һәр кешедән өстен зат дип хисаплаганнар», – дип яза Ш. Мәрҗани (213 б.).

Архив документлары белән эш итәргә яраткан, Эстәрлетамак өязе ахуны нәселеннән булган эзләнүчән шәхес Исмәгыйль Рәмиев тә бу оешманың барлыкка килү вакыты дип 1778 елны күрсәтә («Әдәби сүзлек» китабы, 173 б.). Ә башкалар аны, ун елга кичектереп: «Бу дини идарә 1788 елда оештырылган», – дип язалар. Шул сан безнең энциклопедиянең алтынчы томында да теркәлгән. Ун ел яшәгәннән соң, ул идарә 1788 елда фәкать Оренбургтан Уфа шәһәренә генә күчерелә. Әмма аның Оренбургка бәйле исем-атамасы элеккечә саклана. XX йөз башында Уфа шәһәрендә мөфтият тарафыннан чыгарылган журнал исемендә дә «Оренбург» сүзе бар. Ул мәҗмуга болай дип аталган: «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия». 1788 елда мөфтиятнең Уфага күчерелүен яңа губернатор килгәч губерна башкаласының берникадәр вакытка шунда урнаштырылуы белән бәйләргә кирәктер, мөгаен.

Шиһабетдин хәзрәт ул вакыйганы болайрак тасвирлый. «Бу оешма нишләп Казанда оештырылмаган? Ни өчен әле ул караңгы бер почмак булган, ул мәхкәмәне урнаштырырдай бинасыз Уфага күчерелгән?» – дип яза. Бу оешманың әүвәл Оренбургта оештырылуының сәбәбе, әлбәттә, патша хөкүмәтенең ул чордагы сәясәтенә бәйле була. Урал-суның аргы ягында – чик буенда күпсанлы мөселман ханлыклары яшәгән. Алар белән сәүдә мөнәсәбәтләрен булдыруны да күздә тотып, шул чик буенда Оренбург, Орск шәһәрләре төзелгән, патшабикә Елизавета Петровна әмере белән Каргалы сәүдәгәрләре авылы (Сәет бистәсе) барлыкка китерелгән. Шуннан беренче сәүдә кәрваннары Бохара, Ташкент, Сәмәрканд якларына җибәрелә башлаган. Һиндстанның ул замандагы

башкаласы булган Агра каласын, андагы Таҗ Махал гүрстанын да Каргалы татарларына барып күрүләр насыйп була.

Әйе, менә шушы вакыйгаларны да истә тотып оештырыла ул Оренбургтагы Мөселман дине идарәсе. Һәм ул мәхкәмәнең кырык җиде ел дәверендәге идарәчесе буларак Кайбыч төбәгендәге Борындык авылыннан чыккан Хөсәен әл-Борындыкый улы Мөхәммәтҗан торачак. Кайбыч төбәгеннән читкә китеп дан казанган шәхесләр бар шул! Тукаебызның олуг остазы Мотыйгулла хәзрәт тә шуннан ич!

2

Мөселманнар эшчәнлегенә бәйле бу нәзарәт – оешма нишләп әле Россиянең ул вакыттагы көнчыгыш ил чиге буенда урнашкан Оренбург шәһәрендә оештырылган икән соң? Алда атап кителгән Пугачёв бунтының да шул төбәктә барганлыгын беләбез ич. Әллә, чынлап та, бу оешманың барлыкка килүенең ул вакыйгага да турыдан-туры бәйләнеше бармы? Шиһабетдин хәзрәт тә әлеге китабында «Бу оешма нишләп Казанда оештырылмаган?» дигәнрәк сорау куя ич. Дөрес, ул Пугачёв хәрәкәтен искә алмый. Бу мәсьәләгә карата андый сорауны хәзрәт әлеге оешманың ун ел яшәгәннән соң Оренбургтан Уфа шәһәренә күчерелү уңае белән теркәп куйган. Ни өчен әле ул оешма «караңгы бер почмак булган», «ул мәхкәмәне урнаштырырдай бинасыз... Уфага күчерелгән? Казан шәһәренең бу оешма өчен иң кулай урын булуы һәркем өчен ачык ич» дип язган.

Бу мәсьәләгә карата җавапны, әлбәттә инде, Россия империясенең ул чордагы сәяси таләпләренә нигезләп кенә биреп буладыр. Урта Азия хан-солтанлыкларының чик буенда урнашкан Орск, Оренбург шәһәрләренең барлыкка килүе дә Россия империясе сәясәтенә бәйле фактларның берседер. XIX гасырның урталарына чаклы хәзерге Урал, элекке Җаек елгасының көнчыгыш өлеше рус әдәбиятында «Бохара ягы» яки «Төркестан ягы» дип аталып йөртелгән. Елганың аргы ягыннан ук казах ханлыклары биләмәләре башланган була. (Рус әдәбиятында ул чорда аларны «Кыргыз-кайсак ханлыклары» дип йөрткәннәр. Бүгенге кыргызлар исә ул дәвер Россия тарихында еш кына «кара кыргызлар» буларак теркәлгән.) Арал диңгезенең көньяк тарафларында исә Хива, Бохара ханлыклары яшәгән. Бохара ханлыгы чигеннән «Кабул патшалыгы» – хәзерге Әфганстан җирләре башланып киткән. Кабулдан соң инде ул заманда «мәңгелек җәннәт дөньясы» кебегрәк күзалланган Һиндстанга да ерак калмый... Бүген тасвирланган вакыйгаларга бәйле Россия империясе сәясәтенең төп максаты әнә шул «чит-ят, бай, иркен илләр» биләмәсенә якынаерга омтылудан гыйбарәт була. Бу гамәлләр чик буе артындагы төрки дәүләтләр башлыкларына һәм халкына уңай йогынты ясарга тырышу максатыннан чыгып эшләнгән. Шул максатка ирешү

өчен Оренбург губернасы карамагында махсус бер оешма – Чит ил комиссиясе дә барлыкка китерелә. Россиянең башка губерна идарәләрендә андый комиссияләр булмый. Монда исә ул комиссияне җитәкләү бурычы да губернаторның үзенә йөкләнә.

Яңа күрше мәмләкәтләргә үтеп керү, әүвәл алар белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру хыялын гамәлгә ашыру чараларына Пётр патша заманнарында ук керешергә ниятлиләр. Ул кинәт вафат булгач та бу хыялдан ваз кичмиләр. Империя тәхетенә бер-бер артлы аның варислары – өч хатын-кыз утыра. Көнчыгыш илләргә бәйле сәясәткә аеруча игътибар итүләр аның кыз туганы Анна Ивановна белән үз кызы Елизавета идарә иткән чорларга туры килә. Анна патшабикә идарә иткән елларда әлеге ханлыклар белән чиктәш Урал елгасы ярларында Орск (1735), аннары Оренбург (1743) калалары торгызыла башлый. (Дөресрәге, Ор елгасы тамагындагы Орск шәһәре башта губерна башкаласы Оренбург буларак төзелә. Икенче губернатор булган В. Н. Татищевка хәзерге Оренбургтан өч йөз илле чакрымгаерактарак урнашкан ул шәһәр ошамый. Һәм губерна башкаласын ул хәзерге урынына күчерә.) 1741 елда тәхеткә Елизавета утыргач та яңа губернаның җитәкчесе итеп төрки илләр тормышын яхшы белгән генерал И. И. Неплюев билгеләнә. Биредә ул унҗиде ел чамасы «хуҗа» булып утыра. Шуңа чаклы ул унбиш ел Төркиядә илче вазифасын башкарган була. Кайбер язмаларга караганда, ул төркичә сөйләм телен аңлаган, шул телдә аралаша алган. Гадәттә, Төркиягә илче итеп җибәрелгән шәхесләрнең күпчелегенең ата-бабалары татар милләтеннән булган. М. И. Кутузов та берара шул хезмәтне башкара. «Солтан хатыннары белән серләшә-серләшә солтанатның байтак серләрен ача», – дип тә язалар аның турында.

Елизавета патшабикә белән очрашканда яңа губернатор, күрше ханлыклар белән үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен, яңа шәһәрләр тирәсенә татар сәүдәгәрләрен җәлеп итү кирәклеген дәлилли. Чөнки күрше ханлыкларга мөселман өммәтеннән булмаган кешеләрнең кертелмәвен белә. Патшабикә Елизавета аның тәкъдимен хуплый һәм 1744 елда ике йөз сәүдәгәр гаиләсен Оренбург тирәсенә күчерү карарын имзалый. Ә бер ел үтмәстән, Оренбург янәшәсендәге хәзерге Татар Каргалысы авылын нигезләү карарына кул куя. Һәм аны, бу тирәләргә Неплюев белән бервакыттарак күченеп килгән сәүдәгәр Сәгыйд Ает улы Хәялин исеменә тәңгәлләп, «Сәет бистәсе» дип атыйлар. Сәгыйдне исә монда зур хокукларга ия булган староста итеп куялар. Бер үк вакытта Оренбургның көньяк өлешендә – Урал елгасының аргы ягында «Бохара тарафы»ннан килгән сәүдәгәрләр өчен «Меновый двор» дигән бистә дә барлыкка китерелә. Хәзер дә әле ул бистә Оренбургтан соң беренче тимер юл станциясе буларак яшәвен дәвам итә. Һәм бу ике тулай торакта мәчет, мәдрәсәләр ачуга рөхсәт тә бирелә.

Шул ук патшабикәләр идарә иткән чорда үзәк өлештәге губерналардагы мөселман авылларында мәчетләр җимерелгән, ян-

дырылган. Сенатның 1742 елның 17 ноябрендә кабул ителгән фәрманына гына күз төшерик. Анда Казан, Сембер, Әстерхан һәм Воронеж губерналарындагы авыллардагы мәчетләрнең юк ителергә тиешлеге ачык әйтелә. Әйе, бер үк вакытта Елизавета Петровнаның махсус әмере белән яңа оешкан бу ике бистәдә мәчетләр ачыла. Патшабикә рөхсәте белән төзелгән ул мәчетләр 1746 елдан ук эшли дә башлаган. Дөрес, Меновый дворда төзелгән мәчет татар авылларындагылардан беркадәр аерылыбрак торган. Ул кечкенә манаралы зур тирмәне хәтерләткән. Димәк, Төркестан якларындагы мәчетләргә охшатыбрак эшләнгән була.

Төбәк тарихчысы Сергей Петрович Попов бәян итүенчә, 1749 елда ук Сәет бистәсендә йөз сиксәнләп татар гаиләсе яшәгән. Елизавета идарә иткән елларда ук Казан белән Оренбургны тоташтырган «Яңа Мәскәү юлын» тәртиптә тоту, ямчылык эшчәнлеген башлап җибәрү өчен егерме мең чамасы татар, ун меңләп чуаш һ. б. милләтләрнең күчерелгән булуы да 1996 елда Оренбург каласында нәшер ителгән «История Оренбуржья» китабында теркәлгән. Хәзер дә Бөгелмә белән Оренбургны тоташтырган зур юл буйлап татар авыллары тезелешеп утыра.

Сәет бистәсенә күчерелгән сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең күпчелеге Сәгыйд Хәялин туган төбәктән – Казан губернасының Мамадыш, Малмыж, Арча өязләреннән килгән. Сәгыйднең һәм аның бертуганының гаиләсе хәзерге Байлар Сабасыннан, Оренбург төбәгендә күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләр ачкан һәм тоткан бертуган Хөсәенов байларның бабалары хәзерге Теләче районына кергән Югары Кибәхуҗадан була. Сәет бистәсенең беренче мулласы һәм беренче мәдрәсә ачучысы да – Арча төбәгеннән чыккан мәгълүм дин әһеле. Әйе, монда 1746 елда Ташкичү авылыннан күчеп килгән беренче мулла Габдессәлам Уразмөхәммәд имам улы була. Туган җире –Ташкичү янәшәсендәге Мәңгәр авылы, диелә. Ул шагыйрь Габдессәлам Урай буларак «Татар шигърияте антологиясе»нә дә кергән. Ә Ташкичү мәдрәсәсендә ул ирек даулаучы Батырша мулланы укыткан, Каргалыда яшәгәндә аның белән аралашкан бик абруйлы шәхес. Аның оныгын, шагыйрь Әбелмәних Каргалыйны да әдәбият сөючеләр яхшы хәтерлиләр. XVIII–XIX йөзләр татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе ул.

1747 елга караган теркәү кенәгәсендә* Мәңгәрдән чыккан мулла Абдусалям Уразаевның 28 нче йортта төпләнгәнлеге күрсәтелә. Бу яңа бистәнең бер тирәсендәрәк яшәгән тагын алты гаиләнең дә шул ук Казан өязе Арча даругасының Үтәгән Шадыйров сотникка буйсынган авыллардан булганлыгы әйтелә. Бу исемлектән без Сәгыйд Хәялин гаиләсенең 3 нче йортны биләгәнлеген, ике хатыннан аның биш улы булганлыгын да укып беләбез. Улларының

* Переписная книга Оренбурга и уезда за 1747 г.

исемнәре дә аталган. Аның авыл читендәге табигый тау ташыннан төзелгән йорт утары бүген дә сакланган – хәзер ул Татар Каргалысы авылының нәкъ урта бер өлешендә урнашкан. Ул йортның бер аршынга тартым киңлектәге таш диварлары гасырлар дәвамында яуган кар-бураннарга да, җил-давылга да бирешмәгән. Дөрес, таш бинада – беренче катта кибет-келәтләр булган, ә икенче каттагы бүрәнә өйдә хуҗалар яшәгән. Аның иркен ишегалдында хәзер нәсел очы вәкиле, документаль кинолар режиссёры Рафаэль Хәялин үз өендә яшәп ята. Хәялиннәр тирәсендәге башка сәүдәгәр йортларының беренче каты да шундый ук табигый таштан салынган, икенче каты бүрәнәдән булган. Бүгенге Каргалы урамнарында элекке сәүдәгәрләрдән калган, таштан яки затлы кызыл кирпечтән төзелгән өй һәм кибет-келәтләрне еш очратырга була.

Сәет бистәсенә нәүбәттәге муллалар булып килгән ике Вәлид хәзрәтне дә искә төшереп үтү кирәктер. Каргалы тарихында эз калдырган кешеләр буларак, алар икесе дә Шиһабетдин хәзрәтнең алда күрсәтеп үтелгән китабындагы исемлеккә кергән шәхесләр. Ләкин алар монда беренче булып күчкән, 1747 елга караган йөз кырык өч гаилә исемлегендә әле теркәлмәгәннәр. Бу Вәлидләрнең берсе – Каргалыда икенче мәхәллә мәчетен ачучы һәм аның карамагындагы мәдрәсәне оештыручы кеше. Минем уйлавымча, бу вазифаны «Вәлид бине Сәгыйд әл-Каргалый» башкаргандыр. «Элек Бөгелмә өязенең Минзәлә башы авылында имам вә мөдәррис булган», – дип яза аның хакында Ш. Мәрҗани. Сәет бистәсенә кагылышлы башка язмаларда бу мулланың элекке Бөгелмә өязе Тимәш авылында туганлыгы да теркәлгән. Ягъни ул хәзерге Лениногорск районына кергән Тимәш морзалар авылында туган. Шул ук елларда Оренбург шәһәрен төзүдә татар генералы Котлыгмөхәммәд Тәфкилевнең актив катнашканлыгы да билгеле. Ә аның бер кияве шул Тимәш морзалар нәселеннән була. Генералның хатыны Хәдичәнең һәм аларның «Тимашев атаманда» кияүдә булган кызларының каберләре бүген дә Каргалы авылы зиратының уртасында саклана. Хәтер ташы язуында Хәдичә бикәнең 1751 елда, кызларының 1800 дә бакыйлыкка күчкәнлеге теркәлгән. Тимашев фамилияле берәүнең 1773 елга караган документларда күренеп китүен дә әйтеп үтик. Пугачёв явы Оренбургны камаганда губернатор А. И. Рейнсдроп уздырган зур киңәшмәләрдә катнашкан унлап түрә исемлегендә И. Л. Тимашев фамилиясе дә очрый. Коллежский советник дәрәҗәсендәге ул кеше шәһәрне саклау өчен Сәет бистәсеннән килгән хәрби төркем җитәкчесе буларак искә алына.

Димәк, Вәлид мулланың Каргалыга күченеп килү вакыйгасы шушы кешеләргә бәйле булырга да мөмкин. Вәлид әл-Каргалыйның монда беренче ахун дәрәҗәсенә ирешкәнлеге Ш. Мәрҗани хезмәтендә теркәлгән. Ул аны: «Бик укымышлы кеше булган. 1802 елда фарсыча язган хаты саклана, фарсы телен ул камил белгән… Үзенең язган әйберләре дә булган», – дип искә ала.

Шул ук елларда Сәет бистәсенә Тәтеш өязендәге Кайбыч авылында туган Вәлид Әмин улы әл-Кайбычи да килә. Анысын халык телендә «Вәлид ишан» дип йөрткәннәр. Ш.Мәрҗани аны: «Берничә мәртәбә Бохара белән Кабулга сәфәр кылган. Озак вакытлар Кабулда Фәезхан ишан тәрбиясендә булган», – дип искә ала. Вәлид ишан моннан «1801 елда хаҗ сәфәренә дип чыгып китә» һәм, бер фетнә вакыйгасына юлыгып, 1802 елда шунда вафат була.

Ш. Мәрҗанинең бу хезмәтендә Идел белән Җаек елгалары арасында милләттәшләребез яшәгән төбәкне еш кына «Болгар иле» дип тасвирлавын да билгеләп үтәргә кирәктер. «Болгар иленнән хаҗга дип чыгып киткән... Болгар иленнән Бохарага юл тоткан» рәвешендәге җөмләләр ул китапта еш очрый. Димәк, кайберәүләр уйлавынча, хәзерге Татарстан җирен һәм тарихын Болгар дәүләте чорына бәйләп күзаллау Иосиф Сталин идарә иткән замандагы ниндидер карарларга бәйле факт кына түгел. Халкыбызның зыялы катламы ул тарихны гомер-гомергә шул рәвешле кабул иткән.

* * *

1754 елда шул ук Бөгелмә өязендәге Утыз Имән авылында туган булачак күренекле шагыйрь Габдеррәхим Утыз Имәнине дә язмыш Каргалы бистәсенә алып килгән. Монда аның Вәлид мулла мәдрәсәсен тәмамлавы һәм берничә ел шунда укытырга калганлыгы бәян ителә. Ләкин аның кайсы Вәлид мәдрәсәсен тәмамлавын ачыклый төшү кирәктер, мөгаен. «Татар әдәбияты тарихы» китабын алып (1984, 1 т.), әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов мәкаләсенә күз салыйк. «Габдеррәхим башта үз авылында укырга-язарга өйрәнә, берничә ел күрше авылларга барып укый. Аннан соң Оренбург Каргалысына китә. Андагы икенче мәчет каршындагы мәдрәсәдә Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминнән белем ала. 1788 елда үзенең гаиләсен, балаларын алып, шушы авылда тупланган кәрван белән «Бохара тарафына чыгып китә». Беренче карашка монда яңа бистәдәге тагын бер Вәлид калкып чыга шикелле. Әйе, кайсыдыр Әмин төбәгеннән булган Мөхәммәд улымы ул? Әллә соң Мөхәммәдәмин исемле мулла баласымы?

Татар әдәбияты гыйлемендә бу ике Каргалы мулласы Вәлиднең берсен шагыйрь буларак та таныйлар. Әмма аларның кайсысын Утыз Имәнинең остазы итеп атарга соң? Шагыйрьнең якташын, әтисе белән бер авылдан – Тимәштән булганынмы? Әллә Кайбычтан чыкканынмы? Әдәбият фәнендә әлегә Вәлид ишанга өстенлек бирелә шикелле. Әмма бу очракта булачак шагыйрь белән Вәлид ахунның бер тирәдән, бер авылдан ук булулары искә алынмый. Габдеррәхим бит Тимәш авылы баласы диярлек, атасы бик иртә вафат булгач кына ул күрше Утыз Имән авылы кешесенә әверелә.

Шушы ук елларда тагын бер атаклы шәхеснең – Салават Юлаевның да Сәет бистәсе мәдрәсәләренең берсендә укыганлыгы, шул дәвердә шигырьләр иҗат иткәнлеге Уфада чыккан биографик хезмәтләрдә теркәлгән иде. Ул хезмәтләр белән күптән танышканлыктан, «Пугачёв бунты» батырының Каргалының кайсы мәдрәсәсендә укыганлыгын хәзер инде хәтерләве кыен.

Сәет бистәсе оешып килгән елларда мондагы мәдрәсәләрнең берсендә булачак беренче мөфти Мөхәммәтҗан да укып йөргән. Аның остазы мулла, бу төбәкнең икенче ахуны Мөхәммәд Гали улы әд-Дагыстани булган, дип яза Ш. Мәрҗани. 1760 еллар ахырларында булса кирәк, Мөхәммәтҗан да укуын дәвам иттерү өчен моннан Бохарага чыгып киткән. Аның бабасы да шунда укып кайткан дигән идек. «Бабасы Мансур, әүвәлдә Мортаза әфәнде шәкертләреннән булып, соңыннан Бохарага сәфәр кыла. Ул Идел буеннан барып Бохарада укыганнарның беренчесе. Фарсы телендәге «Тәракыйбе мансурия» китабы аңа нисбәтләнә», – дип язган ич Ш. Мәрҗани. «Камил белемле» бу Мансур мулланың кайдан булуын, Бохарага киткәнче кай тирәдә укыганлыгын да ачыклыйк. Шул ук китапның 234–235 нче битләрендә бу сорауга төгәл җавап бирелә. «Мансур мелла Зөя өязе Борындык авылында* туган». Мәдрәсәдәге остазы «Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети хаҗи. Ахырында ул Мамадыш өязенең Симет авылында, 1723 еллар тирәсендә вафат булган». Шиһабетдин хәзрәт сүзләренә караганда, укымышлы Мансур мулла Бохарадан кайткач, алар үзара килешә алмаган. Мансур, «үзен остазыннан өстен күреп, Мортаза әфәнденең һәр эшенә һәм гамәленә каршы төшә башлаган». Шуннан соңдыр инде, Мортаза мулла үз Симетенә кайтып китә. «Хафиз буларак танылган Мансур мулла исә үз төбәгендә... күп шәкертләр җыеп, зур мәдрәсә тотып дәрес әйткән».

Мөхәммәтҗанның Каргалыга кайчан һәм кайдан килгәнлеге әлегә ачыкланмаган. Атасы «Хөсәен бине Мансур»ның кайда һәм ниләр эшләгәнлеге дә мәгълүм түгел. Каргалыга Мөхәммәтҗан үзе генә килгән булгандырмы яисә аның атасы да Казан төбәгеннән күченгән сәүдәгәрләр төркеменә кергәндерме – Ш. Мәрҗани китабында андый мәгълүмат юк.

Кайберәүләр мөфтинең атасының берара Эстәрлебаш авылы мәдрәсәсендә укыткан булуы турында да язалар. Әмма Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкыйның исемен мин шул мәдрәсәне тоткан Тукаевларның соңгы вәкиле Шакир мулла 1899 елда нәшер иткән «Тарихи Эстәрлебаш» китабында очратмадым. Дөрес, кайчандыр ул авыл мәдрәсәсен нигезләгән бер Хөсәен телгә алына анда. Ул китапта шул кеше беренче мөфти

---

* Зөя елгасы янәшәсендәге авыл хәзер Кайбыч районы биләмәсенә керә. «Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм» диелгән энциклопедиядә.

атасы дип тә танытылган. Әмма ул Хөсәеннең атасы Габдрахман исемле булган. Мөфти бабасының исеме Мансур бит. Мөхәммәтшакир мулланың әлеге китабында башка төр төгәлсезлекләр дә очрый. Әйтик, Каргалы (Сәет бистәсе) авылының рәсми рәвештә нигезләнү вакыты тарихта 1744 елга нисбәтләнә. Бу китапта Эстәрлебашка нигез салыну тарихы болай тасвирлана: «Әүвәл заманнарда ошбу йергә Казан әтрафыннан вә Каргалы шәһәрендән бәгъзе кешеләр килеб, сәүдә вә кәсебләр илә шөгыльләнмәк өчен ошбу Эстәрлебаш урынында утар ясаб утырганнар… Йосыф купес дигән кемсәнең Каргалыдан килеп сәүдә кылганына варисларында язма кәгазь булган», – дип яза да автор, үз авылының нигезләнү елы дип «1680 еллар чамасы»н терки. Сәет бистәсен башка авторлар да, шул исәптән Ризаэтдин Фәхретдин дә, яшәүчеләре күп булганлыктан, «саф мөселман шәһәре, 1740 елларда нигезләнгән» дип язганнар. Алдарак искә алынган китабында Исмәгыйль Рәмиев тә Эстәрлебаш мәдрәсәсенә багышлы аерым мәкалә урнаштырган. Бу авыл мәдрәсәсен ул, Шакир мулла китабына нигезләнеп булса кирәк, 1720 елларда ачылган, дип яза. Әмма «XX йөз башында элекке шәүкәтен югалта» ди. Зәки Вәлидинең 1990 елларда Башкортстанда нәшер ителгән истәлек китабында да Эстәрлебаш белән Эстәрлетамак мәдрәсәләре искә алынгалый. Әйтик, анда «Эстәрлетамак мәдрәсәсе җитәкчеләре Кырымнан килгән Нугай Уйбахты морза нәселе кешеләре» дигән җөмлә дә бар. Әмма бу мулла нәселенең Кырымнан кайчан килгәнлеге әйтелмәгән. Риза хәзрәт Фәхретдинов язмаларыннан исә без 1770 елларда нигезләнгән Эстәрлетамакка мулла буларак Сәлим Рәмиевнең дә бик ерактан чакырып китерелүен, озакламыйча, аның бу төбәкнең беренче ахуны итеп билгеләнүен ачыклый алабыз. Шуннан илле-алтмыш чакрымдагы Эстәрлебаш мәдрәсәсе 1720 елдан эшләсә, Сәлим мулланы читтән чакыру хаҗәте туар идеме дигән уй килә күңелгә. Гомумән, шул төбәктәге күренекле мулла һәм мәдрәсә башлыкларының еш кына читтән китерелгән кешеләр булганлыгын күрсәтүче мисаллар байтак. Әйтик, шул ук Зәки Вәлидинең анасына якын туган булган, зур мәдрәсә тоткан Үтәки мулланың ата-бабаларының да кайчандыр Казан төбәгеннән килгәнлеген бу шәхеснең әлеге истәлекләр китабыннан укып беләбез ич. Эстәрле төбәгеннән булган бүгенге заман кешесе, Шакир хәзрәтнең мәдрәсә тарихына багышлы китабына нигезләнепме, «Эстәрлебашта 40 мәдрәсә булган» дип тә күрсәтә. Шакир мулла Тукаев хәбәр итүенчә, 1897 елда ул авылда ике мең бер йөз кеше яшәгән. Икенче бер чыганакта исә анда кайчандыр өч мәчет булуы теркәлгән. Патша заманындагы тәртип буенча, мәктәп-мәдрәсәләр ачу фәкать мәчет белән чиркәүләр карамагында гына рөхсәт ителгән була. Мәсәлән, Ризаэтдин Фәхретдиннең «Әхмәд бай» китабында, XX гасыр башында унөч мең кешесе, ун мәчете булган Каргалыда, шул мәчетләр карамагындагы хатын-кыз мәктәпләрен дә исәпкә алганда, мәктәп-мәдрәсәләр саны күпкә азрак күрсәтелә.

3

«Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең ни өчен Оренбург каласында оештырылуын ачыклый башлаган идек. Бу вакыйганың империя сәясәтенә бәйле икәнлегенә ишарәләр дә ясалды. «Мөхәммәт дине җәмгыяте...» туганчы ук бу калада Россиянең бик үзенчәлекле «Чик буе комиссиясе» дип аталган оешмасы барлыкка килүен дә билгеләп үттек. Монда бу комиссиянең эшчәнлеге (кайбер язмаларда ул «коллегия», «миссия» буларак та теркәлгән) башкаладагы чит илләр белән эш итүче министрлык яисә ул чордагычарак әйтсәк – департамент) вазифасын кабатлауга тиң була. Шушы чик буе комиссиясе кешеләре Төркестан ягы ил-мәмләкәтләренә илчеләр озату белән дә, шул тарафтан килүче илчеләр төркемен каршы алып, аларны Петербургка алып бару эшләрен дә башкарганнар. Бу комиссия штатында тылмач вазифасын үтәүче, ара-тирә чит мәмләкәтләргә илче сыйфатында баргалап та кайтучы милләттәшләребезнең ишле генә булуы да мәгълүм. Көнчыгыш тарафка озатылучы сәүдә кәрваннары да шушы комиссия кешеләре белән эш йөрткән. Алар монда хәзерге таможня оешмасы башкарган эшләрне дә башкарганнар.

Димәк, «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең шушында оештырылуының төп сәбәбе дә, әлбәттә инде, Россия мәмләкәтенең көнчыгыш тарафта урнашкан төрки илләргә «айдай балкыган милли йөз» күрсәтергә тырышуыннан булгандыр. Бу сәясәтнең күзгә күренердәй беренче эше – ил чигенең аргы ягында урнашкан Кече Җөз* казах ханлыгы белән «дуслык килешүе» төзү чарасыннан башланып китә. Ә ул килешү Әбелхәер ханның Россия дәүләтенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итү тарихыннан соң төзелгән дип язалар тарихчылар. Милләттәшебез Котлыгмөхәммәд Тәфкилев, 1731 елда казах илендә берничә ай яшәгәннән соң, бу эшне бик уңышлы башкарып чыга. Кайберәүләр, бу вазифаны үтәгәндә аның уңышка ирешүенең бер сәбәбе итеп, казах дәүләте башлыгы Әбелхәер хан белән бер нәселдән чыгуларын да искә алалар. Аларның икесенең дә алтынчы буын бабалары бер кеше – Алтын Урда дәүләтенең дәвамчысы саналган Зур Урда ханы Шигай булган. Зур Урда таркалгач, Тәфкилевләр буыны Касыйм ханлыгында бүленеп калган. Һәрхәлдә, казах кардәшләрдән кайберәүләр шулай дип уйлый һәм яза. Ул чор тарихын яхшы белгән, Әбелхәер хан идарә иткән һәм аның варислары дәверенә багышлап роман язган Әнүәр Алимҗановта да (Мәскәүдә нәшер ителгән «Гонец» китабын ул миңа бүләк тә иткән иде), Ш. Мәрҗани китабында да Тәфкилев морзаларның бер бабасы буларак шул хан күрсәтелгән.

---

* Ул дәвердә казахлар өч ханлыкка – Кече, Урта, Олы Җөзгә бүленә.

Шушы килешү нигезендә иң элек безнең сәүдәгәрләргә бу илдә иркен сәүдә итү хокукы бирелә. Соңрак аларга, Урта Җөз ханлыгы биләмәләрен дә кичеп, Ташкент, Бохара, Үргәнеч (Гүргәнеч буларак та билгеле) тарафларына үтеп керү мөмкинлекләре дә тудырыла. Рәсми рәвештә теркәлгән хәбәргә караганда, зур бер тәүге сәүдә кәрваны 1741 елда Орск каласыннан* Ташкент тарафына юл алган. Һәм бу сәфәрдә ул кәрван ияләре зур уңышка ирешкәннәр. Бер пот чамасы көмеш тә сатып алганнар. Соңрак та кайбер кәрванчылар, үз әйберләрен зур бәягә сатып, ул яклардан бик арзанга көмеш тә алып кайткалаган. Урта Азия илләренә йөргән кәрваннардагы йөкнең бер өлеше рус сәүдәгәрләренеке дә булган. Каргалы кешеләренә, шулай итеп, арадаш сәүдәгәр вазифасын да үтәргә туры килгән. Байтак еллар дәвамында Каргалы кешеләре белән үзара килешеп эшләүче сәүдәгәрләр исемлегендә Мәскәүдән рус кешесе Г. Журавлёв, грек И. Мавродин, әрмәннәр динен тотучы В. Макаров, Ростовтан А. Кекиннар булуы теркәлгән**.

Беренче уңышлардан соң инде татар сәүдәгәрләре Бохара, Хива ханлыклары җирләрен дә үзләштерә башлыйлар. Бохара белән Үргәнеч калаларына Орскидан да, Сәет бистәсеннән дә берничә кәрван озатыла. Ә 1751 елда Сәет бистәсендә тупланган бер кәрванга Һиндстанга барып кайту бурычы да йөкләнә. Ул кәрванның җитәкчесе, шул авыл сәүдәгәре Исмәгыйль Бикмөхәммәтов белән бергә аның сәфәрдәшләре Надир, Якуб, Габдрахман исемле кешеләр дә юлга чыккан. Әлбәттә инде, аларның һәрберсенең үз ялчы-хезмәткәрләре дә булган. Әйтик, Надир Сафаровның мал куучысының Бохарадан кузгалуга ук һәлак булуы турындагы хәбәр тиздән авылга да кайтып җитә.

Бу чорда Һиндстанда Аксак Тимернең оныгы, төрки солтан Бабур нәселе вәкилләре идарә иткән. Бабур һәм аның оныгы Әкбәр, бу илдәге аерым бәк-солтанлыкларны җиңеп, «Бөек Моголлар империясе» дип аталачак дәүләтне оештыралар. Аларның династиясе бу империя белән 1520 еллардан алып 1858 елгача идарә итә. Бу төркиләр идарә иткән дәвердә илнең башкаласы Дәһлидән көньяктарак булган Агра шәһәрендә урнаша. Шул шәһәр янәшәсендәге атаклы Таҗ Махал мавзолей-төрбәсен төзүчеләр дә алар. Җиһан шаһ, сөекле хатыны Мөмтаз Махал вафат булганнан соң, сөеклесенә аталган таҗ буларак төзетә ул мавзолейны. Төзелеш эшләрен башкарыр өчен дә күпсанлы осталарны алар Урта Азия төбәкләреннән китертә торган булганнар, дип яза белгечләр.

---

* Җаек елгасына казахлар ягыннан килеп кушылган Ор елгасы тамагындагы шәһәр 1735—1741 елларда Оренбург буларак төзелә.

** *Р. Искандаров, А. Искандаров*. Сеитов посад. — Казань. — Татар. кн. изд-во, 2005.

Сәет бистәсеннән чыккан кәрванның Дәһли шәһәренә барып җиткәнлеге мәгълүм. Әмма бару һәм кайту юлында югалтулар да күп була. Шул сәфәрдә исән калган кәрван башы Исмәгыйль туган иленә фәкать утыз елдан артык вакыт үткәч кенә әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән. Аның илгә кайткач язган истәлек язмасы әүвәл «Ике хаҗиның рихләтнамәләре» дигән исем-атама белән 1862 елда Казанда аерым китап рәвешендә чыга. Тагын кырык елдан соң исә ул истәлекле язманы Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдин дә 1903 елда «Исмәгыйль сәяхәте» исеме белән Казанда бастыра. Исмәгыйль каһарман кулында Һиндстан бәк-солтаннарына атап язылган хат-фәлән булгандырмы – әйтә алмыйм. Шул хакта, бәлки, аның сәяхәтнамәсендә берәр төрле хәбәр бардыр.

Шул ук Һиндстанга сәяхәт кылган икенче бер милләттәшебезне дә искә төшереп үтик. Сәүдәгәр һәм дипломат Мөхәммәтйосыф Касыймов төрки Бабур нәселе идарә иткән озын дәвердә Һиндстанга – Агра шәһәренә 1675 елда Россия илчесе буларак сәяхәт кыла. Аның кулында Бөек Моголлар мәмләкәте шаһы Әүренгазиб исеменә татар телендә язылган хат була. Рус патшасы Алексей Михайлович исеменнән язылган хат. Әмма шаһ илче Мөхәммәтнең үзен кабул итми, патша исеменнән язылган хатны алгач та үзен кире кайтарып җибәрергә боера. Мөхәммәтйосыф, сәүдә малын тиз арада сатып, Урта Азия ханлыклары аша янә Мәскәү тарафына таба юлга чыга. Шул вакыйганы тирәнрәк белүчеләр хәбәр итүенчә, бу сәүдәгәр алдына куелган бурычларның иң җитдие – Һиндстанга бару юлларын хәтергә сеңдереп кайту булган. Урта Азия илләре буйлап сәяхәт иткәндә, ул байтак кына шымчылык мәгълүматын туплауга ирешә. Хәер, ул якларга юлга чыккан башка кәрванчыларга да махсус шымчылык бурычларының тапшырылган булуы көн кебек ачык. Гомер-гомергә бу шулай булган инде.

Оренбург Чик буе комиссиясе эшчәнлегенең бер юнәлешен чагылдырган тагын бер-ике генә мисалга тукталып үтик. Бу комиссия Төркестан, Һиндстан якларына махсус шымчыларны да даими рәвештә җибәргәләп торган. Орск каласыннан Бохара тарафына озатылган кәрваннарның берсе белән булачак шәкерт рәвешендә Ян Виткевич исемле егет тә бара. Әлбәттә инде, ул татар исемен алган була. Үзе ул Польшада туган. Мөгаен, мөселман динен тотучы чын татар кешесе булгандыр. Россия идарәчелегенә каршы чыккан фетнәдә катнашканлыгы өчен аны Орскига сөргенгә җибәрәләр. (Бераз соңрак, Польшадагы чираттагы баш күтәрүдән соң, Уральск каласына озатылган берничә мөселман кешесен фабрикант Акчуриннарның үз фабрикаларына соратып алу очрагы да мәгълүм.) Мөселманча дога кыла, намаз укый белгән Ян Виткевич, җирле төрки телне бераз үзләштергәч тә кәрван белән Ташкент аша Бохара тарафына озатыла. Илеңә тизрәк кайтасың килсә, безгә хезмәт ит, дип яллаганнардыр инде аны. Шушы батыр разведчикка багышланган бер китапта аның гүзәл

Сәмәрканд шәһәрендә булу вакыйгалары да, Кабул каласына барып җитеп, анда тупланган инглиз армиясе тәртипләре белән танышканлыгы да бәян ителә. Берәр ел чамасы шулай сәяхәт кылганнан соң ул икенче бер татар кәрваны белән илгә әйләнеп кайта.

Казахстанда яшәүче тарихчы галим Вил Галиев, «Казан утлары»нда дөнья күргән «Тылмачлар, сәяхәтчеләр, дипломатлар» дип аталган очеркында Һиндстанга сәяхәт кылган тагын берәүне – Гобәйдулла Әмировны да искә ала. Ләкин журналда басылган вариантта ул телгә генә алына, аның кайчан чит илдә булганлыгы тасвирланмый.

Журналда басылган ул хезмәтнең миндә 23 битле кулъязмасы да саклана. Аны мин тәрҗемә итәргә тиеш идем. Әмма эшләп өлгертә алмавымны чамалагач, очеркны башка кешегә тапшырдылар. Ә ул аны бик кыскартып бастырып чыгарды. Кулъязмада исә Г. Әмировның 1805 елдан Чик буе комиссиясендә эшли башлаганлыгы, Һиндстанда шуннан алдагырак елларда булганлыгы әйтелә. Ул байтак еллар элек кайсыдыр төркем белән шул тарафка җибәрелгән дә, шунда кулга алынып, дистә ел чамасы Һиндстанда әсирлек газабын кичергән икән. Аның шул фаҗигале сәяхәткә багышлы истәлек язмасы да сакланган. Нишләптер бездә андый язмалар белән кызыксынучылар юк. Ә рус галимнәре әнә Афанасий Никитинның төркичә-татарча сүзләр дә кушып язган шундый сәяхәтнамәсен, төрлечә төзәткәләп, берничә мәртәбә бастырып чыгардылар инде. Әмировның истәлек язмасын сәяхәтче галим Г. Ф. Генс, берникадәр эшкәртеп, 1825 елда «Азиатский вестник» мәҗмугасының 1 нче санында бастырган икән. Ә утыз елдан соң бу кызыклы истәлекне П. Небольсин дигән кеше кабат нәшер иткән. «Гобәйдулла Әмиров белән Миндияр Бикчуринның шундый зур сәяхәтләргә багышлы истәлек язмалары бүгенге көндә Оренбург архивында Г. Ф. Генс фондында саклана», – дип яза Вил Галиев.

Менә тагын бер сәяхәтче, әйтергә кирәк, шул дәвер Россия хөкүмәтенең сәясәтен уздыруга үз өлешен керткән шәхес – Миндияр. Әйе, миндәге кулъязмада аның да Чик буе комиссиясендә тылмач сыйфатында эшләгәнлеге, соңрак бик җаваплы вазифаларны үтәр өчен Бохара, Үргәнеч тарафларында булганлыгы бәян ителә. Миндияр Бикчуринның шул сәфәрләре, анда нииндирәк йомышларны үтәгәнлеге турындагы үз истәлекләре 1819 елда язылган, ди В. Галиев. Гомер чигендә ул Россиянең шәүкәтле гражданы булып таныла, аңа дворян дәрәҗәсе бирелә. Бер гасырдан соң, 1916 елда Петербургта нәшер ителгән «Восточный сборник» тупламасының икенче томында аның сәяхәтнамәсе – хисап язмасы басылып чыга. Безнең журнал вариантындагы язмада бу хәбәр дә никтер теркәлмәгән иде. Шушы Миндиярның улы булган «тылмач морза» Мирсалих Бикчуринны да искә алып китик. Ул Оренбургта хәрби мәктәп – кадет корпусын тәмамлаган

һәм байтак еллар шунда укыткан «мишәр генерал»ларның берсе санала. Гарәп, фарсы, төрки телләр кулланышына багышланган берничә гыйльми хезмәт язганлыгы да мәгълүм. Аны да төрле вакытта Урта Азия ханлыкларына җитди йомышлар үтәр өчен җибәргәләгәннәр. Генерал дәрәҗәсе аңа шул хезмәтләрен дә истә тотып бирелгән була.

Аның бай китапханәсе белән танышу өчендерме, башка сәбәп беләнме, Галимҗан Ибраһимовның шул морза өенә килеп йөргәнлеге үз истәлекләрендә теркәлгән. Дөрес, Совет хакимияте чорында язылган биографиясендә ул: «Вәлия»дә укыганда, генералның кучеры булдым», – дип кенә теркәгән. Иртә яздан кара көзгәчә үз авылында барлык хуҗалык эшләрен башкарышуда катнашкан шәкертнең кай арада Бикчурин морзада күчер вазифасын үтәгәнлеген ачыклаучы юк әлегә.

Вил Галиев хезмәтендә ике татар кешесенең (берсе Казаннан ук икән) бик тә серле Тибет иленә сәяхәт кылганлыгы да искә алынган. Тылмач Мөхәррәм Габдерәшитов белән Сәефсаттар Сәйфелмөлеков 1814 елда башкаладан килгән Рафаилов фамилияле галим белән Кашгар каласына дип юлга чыгалар. Озатып баручы тылмачлар рәвешендә. Җитәкчеләре сәяхәт барышында авырып вафат була. Мәгәр юлдашларына билгеләнгән җиргә барып җитү, йөкләнгән бурычны үтәп кайту кирәклеген аңлатып үлә ул. Бу татарлар ул кушканны үтиләр. Тибеттан кайткач та күргән-белгәннәрен язып калдыралар. Соңрак ул язманы сәяхәтче казах галиме Чокан Вәлиханов үз хезмәтләре белән бергә нәшер итә, дип яза В. Галиев. (Ул язма Ч. Вәлихановның сайланма хезмәтләренең 1964 елгы өченче томына кергән.) Үземнән шуны да өстәп куясым килә: язучы Сабит Моканов, Ч. Вәлихановка багышланган икетомлык романында, Омск шәһәренең атаклы татар мулласы һәм мәдрәсә башлыгы рәвешендә әлеге Сәйфелмөлековны тасвирлый. Мәдрәсәдә укыганда, Чоканның атасы шул мулла гаиләсендә торган, дип хәбәр итә. Ханнар нәселеннән чыккан бу шәкерт белән яшүсмер кызының күз сирпеп алышуларын күргәләгән мулланың булачак ханны кияү рәвешендә кабул итәргә әзер булганлыгын да яза бу әдип.

## 4

Сәяхәтләрдә күп йөрдек. Инде мөфтиләребез белән якыннанрак танышыйк. Кемнәр булган соң алар, зур бер империя башлыклары фәрманы белән Россиядәге мөселман өммәте вәкилләре язмышын хәл итәргә алынган зур дәрәҗәле түрәләр? Шуларны ачыкларга тырышып карыйк. Дөрес, аларның барысының да диярлек тумышы, укымышлылыгы, эш-гамәлләре турында Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында берникадәр язылган инде диючеләр дә булыр. Әмма патшалар чоры мөфтиләрен бик күпләребез-

нең ишетмәгәнлеге, белмәгәнлеге турында көндәлек матбугат битләрендә чыккан язмалардан күреп торабыз ич. Шиһабетдин хәзрәт китабына кермәгән кызыклы гына мәгълүматлар да ул мөфтиләр биографиясендә бар. Әйтик, ул чор мөфтиләренең патша җәнапларын тәхеткә раслау (инаугурация) вакыйгаларында катнашу-катнашмавы анда теркәлмәгән.

«Алар – рус патшасы яраннары булган погонлы офицерлар» дигән рәвешле язмаларга да тап булгаларга туры килгәли. Дөрес, элек погон йөрткән дәүләт вәкилләре дә булган алар арасында. Әмма мөфти вазифасын үтәргә билгеләгәндә инде аларның элекке чор хезмәтләренә басым ясамаска кирәктер. Элек ниндирәк вазифалар үтәгән булуларына карамастан, алар барысы да дини кардәшләре алдында үзләренә йөкләнгән бурычларын җиренә җиткереп үтәргә тырышкан чын дин әһелләре булганнар. Шиһабетдин хәзрәт билгеләп үткәнчә, иң әүвәл алар чын мөселман өммәте кешеләре булып калганнар. Хәтта мөселманлык, милли җанлылык мәсьәләсендә күпләрдән өстен торган, полковник дәрәҗәсендәге морза Шаһимәрдән Ибраһимовны, мөфтилеккә тәкъдим ителү нияте барлыгын белгәч, Ильминский ише кара фикерле кешеләрнең, «ул бигрәк милли җанлы» дип, башкала түрәләренә әләк хатлары язганлыгы да мәгълүм.

Патша чоры генералы Котлыгмөхәммәд Тәфкилев тә, кайбер галимнәребез аны «чукынган Тәфкилев» буларак сыйфатларга тырышсалар да, эш-гамәлләре белән эшлекле татар буларак күзаллана. Күп кенә рәсми документларда аның исем-атамасын русчалап теркәүләренә карамастан, ул беркайчан да үз диненнән ваз кичмәгән. Әйе, Россия тарихының аерым вакыйгаларын тасвирлаган кайбер чыганакларда аның «Алексей Иванович Мамышев» (атасы бит Мәмәш морза) буларак теркәлгән очраклары билгеле. Ләкин ул – рәсми рәвештә үз диненә хыянәт итмәгән олуг затларың берседер. Шиһабетдин хәзрәт тә бит әнә: «Котлыгмөхәммәд морзаның имамы, Оренбург имамнарының иң элеккегесе Ибраһим бине Түләк мулла иде», – дип яза. Аның «Бохара казый вә мөфтиләренеке кебек зур мөһеренә «Ибраһим бине Мөхәммәд Түләк әл-мөфти» дип язылган була, ди.

Котлыгмөхәммәд генералның соңгы гомер иткән җире – хәзерге Әгерҗе районындагы Тирсә белән Мордыбай исемле татар авыллары. Аларның утары шушы ике авыл арасындарак була бугай. Шуннан ерак түгел бер Барҗы авылы янында аларның бакыр кою заводы тотканлыклары да тарихта теркәлгән. Тирсә зиратында әлеге генералның кабере өстенә куелган затлы хәтер ташының 1920 еллар ахырынача сакланганлыгы да мәгълүм. Бер әңгәмә вакытында шул хакта Равил Үтәбай-Кәрими дә искә алган иде. «Аның төрбәсе һәм кабер ташы үз авылларының берсендә төзелгән бер бина нигезенә салынган икән дип сөйләүчеләр бар», – дигән иде ул. Ә 2008 елда нәшер ителгән «Әгерҗе

төбәгенең ташъязма истәлекләре» китабының 112 нче битендә әлеге генерал кабере өстенә куелган истәлек ташы һәм андагы мөселманча язма тексты тасвирламасы китерелә. Бу китапны туплап чыгаручы галимнәр Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиев. Генерал кабере өстендәге истәлек ташындагы язманы алар «Шура» журналының 1915 елгы бер санынннан күчереп алганлыкларын хәбәр итәләр. Риза Фәхретдиновка ул истәлек ташы сурәтен һәм язмасын Мордыбай авылы мулласы күчереп язып җибәргән була.

Бу Тәфкилевләр нәселенең үз халкына карата кылган уңай гамәлләренең барланмавы сәбәпле генә кайберәүләр аны шулай «чукындырып» күзалларга тырышадыр, мөгаен. Шул «усал» генерал оныгы Сәлимгәрәйнең Бөтенроссия күләмендәге дүртенче мөфти булганлыгын исә күпләребез белмидер дә әле. Соңгы Бөек Ватан сугышы дәверендә язылган байтак кына рәсми документларда да бит әнә бик күп милләттәшләребезнең исем-атамасы русчалатып теркәлгән. Шул язуларга нигезләнеп кенә без ул кешеләрне – үз ата-бабаларыбызны – чукынганнар рәтенә кертә алмыйбыз ич.

Дөрес, бу генералның патшалар дәүләтенә җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иткәнлеген һич тә инкяр итәргә җыенмыйм. Хәрби кеше буларак ул кайвакытларда артыграк та тырышлык кылгалагандыр. Мәсәлән, Ор елгасы Уралга койган урында булачак губернаның башкаласын – Оренбург шәһәрен төзүгә керешкән чорда, ул шул төзелешне сакларга тиешле атлы гаскәр башлыгы итеп билгеләнә. Ә рус хәрбие җитәкчелегендәге унбиш ротадан торган җәяүле сугышчылар исә төзелеш эшләрен башкарганнар. Полковник Тәфкилев җитәкчелегендәге өч йөз илле кешеле һәм бер туплы атлы гаскәр сагындагы бу отряд Уфадан кузгалуга ук, аңа төрле яклап һөҗүм итүләр башлана. Соңрак Орск исеме белән аталачак Ор елгасы тамагындагы каланы төзи башлагач та, аңа төрле тарафтан һөҗүм итеп торулар тукталмый. Чөнки ул кала бу тирәләрдә ирекле күчеп йөрүче башкортлар өчен дә, елга аръягында урнашкан казах күчмәннәре өчен дә кирәкмәс киртә буларак кабул ителгән. Тәфкилев отрядына исә әнә шул күчмәннәр һөҗүменнән саклану бурычы йөкләнгән була. Ул отряд һөҗүм итүчеләрне даими рәвештә эзәрлекләп торырга мәҗбүр ителә. Кала төзелешенә бәйле истәлекләрдә бу полковникның булачак кала уртасындагы үр башына биек каланча төзеп, тупны шул каланча башына менгертеп куюы да телгә алына. Әле XX йөз урталарында да кайчандыр әлеге каланча урнаштырылган үр Орск халкы телендә «Полковник тавы» дип аталып йөртелә иде. Ә ике күрше халык –башкорт белән казах телендә булачак шәһәргә тагылган «Җаман кала» исеме дә XX йөз башларынача саклана. Орскида туган күренекле артист Хәким ага Сәлимҗанов та истәлек китапларында үзен шул «Җаман кала» кешесе буларак таный.

* * *

Яңа оеша башлаган Оренбург губернасы белән җитәкчелек итәргә 1740 елда билгеләнгән булачак тарихчы В. Н. Татищевка губерна башкаласының —әлеге «Җаман кала»ның – Ор елгасы тамагындагы урынга сайлануы ошамый. Россия үзәгеннән бик еракта һәм дошмани көчләр тирәсендә урнашкан дип, шәһәр төзелешен ул өч йөз илле чакрымга көнбатышкарак күчертә. Шулай итеп, урыннан-урынга күчерелә-күчерелә, хәзерге Оренбург каласына нигез салына. Полковник Тәфкилев тә үз атлы казаклары белән яңа, тынычрак урынга күчә. Һәм монда аны яңа губернатор И. И. Неплюев үз ярдәмчеләренең берсе итеп билгели. Россия чигенең аргы ягында яшәүче төрки кавемнәр телләрен белүче кеше буларак, аны тиздән әлеге Чик буе комиссиясе эшенә дә җәлеп итәчәкләр.

Оренбург губернасын оештыру чорындагы эшчәнлеген истә тотып, генерал Тәфкилевкә монда байтак җир биләмәләре бүлеп биреләчәк. Шуларга Әгерҗе, Малмыж кебек уңдырышсыз җирле, ярлы төбәкләрдән байтак кына ярлы крестьяннар күчереп утыртыла. Тәфкилевләрнең бер биләмәсе, ике мең дисәтинәдән артыграк чәчү җирлесе, Оренбург белән хәзерге Каргалы аралыгында урнашкан була. Бу морзалар шул җир биләмәсеннән килгән табышның бер өлешен даими рәвештә Каргалы авылы мәчетләрен һәм мәктәп-мәдрәсәләрен яшәтү өчен тотканнар. XX гасыр башында бу иркен җир биләмәсен сәүдәгәр Мәхмүт бай Хөсәеновка сатканда да шул тәртипнең саклануын төп шарт итеп куйганнар. 1910 елда Мәхмүт бай вафат булганнан соң, аның варислары тарафыннан ул шарт төгәл үтәлми башлый. Шул хакта бер Каргалы мәчете имамының «Вакыт» газетасы редакциясенә юлланган хаты булуы мәгълүм. Ул хат 1913 елда Оренбургта нәшер ителгән «Гани бай» китабына да кергән. Ә ул китапны төзеп, туплап чыгаручы кеше «Вакыт» мөхәрриренең беренче урынбасары Борһан Шәрәф була...

* * *

Беренче мөфтиләребезне патша Россиясе шартларында ул дәрәҗәгә күтәрелүдә нинди мөмкинлекләр ярдәм иткән соң? Минем уйлавымча, тәүге мөфтиләрнең ил күләмендә танылуы – аларның элекке мөселман дәүләтләренә чиктәш өлкәдә – Оренбург губернасының башкаласы янәшәсендәге Сәет бистәсендә танылу алуына бәйле. Хәзер Татар Каргалысы исемендә йөргән, император Пётр Беренченең кызы Елизавета фәрманы белән Сәет бистәсе буларак барлыкка китерелгән бу зур авылның ул елларда Урта Азия дәүләтләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу өчен оештырылганлыгын алда яздык инде.

Мөхәммәтҗан Хөсәен улы 1777 елда Бохарадан туры Сәет бистәсенә әйләнеп кайта. Ш. Мәрҗани хәбәр итүенчә, Бохарада укыган елларында да бу бистәдә калган остазы һәм башка күренекле муллалар белән ул хәбәрләшеп торган. Мөхәммәтҗан Бохарадан кайткан елларда бу бистәдә Утыз Имәни дә әле укып һәм хәлфә булып көн күрә. Мөхәммәтҗан кайткач та алар биредә унбер ел чамасы бер авылда яшиләр. Бер-берсе белән белешкән, аралашкан булырга тиешләр. Шул хакта Утыз Имәнинең бай архивында кайбер язмаларның сакланган булуы да ихтимал. Әмма Совет хакимияте елларында ул архив белән эш иткән галимнәребез бөек шагыйрьнең бер мулла белән аралашу вакыйгаларына әһәмият итмәгәннәрдер, мөгаен.

Шиһабетдин хәзрәт китабының «Беренче мөфти» дип башланган бүлегендә Мөхәммәтҗанның туган елы күрсәтелмәгән. Ул бүлек «Борындык исемле авыл кешеләреннән. Башлангыч белемне туган ягында алган, соңыннан Каргалыга барып, мелла Мөхәммәт әд-Дагыстани һәм башкалардан гыйлем ала» дип башлана. Шуннан соң хәзрәт булачак мөфтинең Каргалыда нинди китапларны укыганлыгын санап китә. «Бохарада казый Габделваһһабтан белем ала», – дип яза. Шиһабетдин хәзрәт язганнардан аңлашылганча, Мөхәммәтҗан Зөя өязе Борындык авылында туган, шунда башлангыч белем алган була. Ә Татар энциклопедиясенең рус телендә чыккан алтынчы томында исә мөфти хәзрәтләренең Уфа өязендәге Солтанай авылында 1756 елда туганлыгы күрсәтелгән. Шул ук авыл исеме 1939 елда башкалада СССР Фәннәр академиясе тарафыннан нәшер ителгән «Исторический архив» мәҗмугасында, профессор М. П. Вяткинның «Журнал Оренбургского муфтия» дип исемләнгән күләмле хезмәтендә дә кабатлана. Бу «журнал» дигәне Мөхәммәтҗанның кайчан, кайда ниләр эшләгәнлеген теркәп барган көндәлеге булырга тиеш. (Мөфтигә нисбәтле бүлек 117 нче биттән башлана. Алдагырак битләрдә Кавказ халыклары иреге өчен көрәшкән Шамилгә багышланган язмалар бар.) Бу хәбәрләрнең кайсысы дөрес? Мөхәммәтҗан кайсы авылда туган? Архив киштәләрендә, бәлки, шул хакта тулырак мәгълүмат та сакланадыр. Әлегә ул мәсьәлә ачыкланмаган килеш кала. Шуларны белү өчен иң элек Мансур улы Хөсәен әл-Җәбәли әл-Борындыкый мулланың кайларда яшәгәнлеген ачыкларга кирәк.

Профессор М. П. Вяткин, очеркының кереш өлешендә, ниндидер архив язмаларына нигезләнептер, мөгаен, Мөхәммәтҗанны Бохара белән Кабулга укырга «коллегия иностранных дел послал» дип яза. Ягъни булачак мөфти Сәет бистәсендә укып йөргән елларында ук Оренбургтагы Чик буе комиссиясе белән элемтәдә торган булып чыга. Ә ул комиссиянең турыдан-туры башкаладагы әлеге министрлыкка буйсынып эшләгәнлеген хәбәр иткән идек инде. Мөгаен, бу комиссиянең таможня бүлегенең бер бүлекчәсе Сәет бистәсендә үк урнашкан булгандыр. Сәүдә

кәрваннары чит илләргә шушы авылда тупланып чыгып киткән бит. Мөхәммәтҗан шәкерт анда остазы ахун Мөхәммәт әд-Дагыстани белән берлектә нindидер йомышлар үтәп йөргәндер, күрәсең.

Бохарадан кайткач та Мөхәммәтҗанның шул комиссиядә эшләвен дәвам иттергәнлеге түбәндә китереләсе җөмләдән аңлашыла. Ул: «Кайткач та Россия дәүләте вәкилләренә һәм олыларына үзен мәгърифәтле һәм алар тарафдары итеп күрсәтә ала», – дип яза Ш. Мәрҗани. Казах ханлыклары белән ике арада булгалап торган киеренкелекне хәл иткәндә дә, ул илдә үзара гаугалар чыкканда да Мөхәммәтҗан ахунның шул тарафка еш йөргәнлеге М. П. Вяткин хезмәтендә дә тасвирлана. Дөресрәге, профессор Вяткинның ул хезмәте башлыча шул вакыйгаларны аерым-аерым билгеләп, тасвирлап үтүгә багышланган да диярлек. Шул очерк эчтәлегеннән аңлашылуынча, Бохарадан кайтып, әлеге комиссиядә бераз эшләгәч Мөхәммәтҗан муллага ахун дәрәҗәсе бирелгән була. Ләкин бу хезмәттә аңа ул дәрәҗәнең кайчан бирелгәнлеге күрсәтелмәгән.

Нәкъ шул елларда, Россия алдында артыграк баш ия башлаганы өчендерме, Әбелхәер ханны кайсыдыр ыруг старшиналары үтереп ташлый. Ханның варислары арасында тәхет тирәсендәге чираттагы ызгышлар булган берничә очракта ахун Мөхәммәтҗанның, күрше мәмләкәттә килеп туган бәхәсне хәл итү өчен, анда үзе генә дә, Миндияр Бикчурин белән бергә дә барганлыгы Вяткин хезмәтендә дә теркәлгән. М. П. Вяткин кулланган документлар арасында мөфти фамилиясенең кавказчалаштырып яисә төрекмәнчәләштереп «Гусейнов» рәвешендә язылу очраклары да күзгә чалына.

* * *

Мөхәммәтҗан Бохарадан кайткан елларда иркен Оренбург губерниясе белән Екатерина патшабикәнең бик ышанычлы кешеләре – генераллар И. А. Рейнсдроп, һәм бераз соңрак О. А. Игельстром җитәкчелек итәләр. Патшабикәнең үзе кебек үк, болар икесе дә чит илдә тәрбияләнгән шәхесләр. Мин караштыргалаган китапларда Мөхәммәтҗан мөфтинең аеруча Игельстром барон белән килешебрәк эшләгәнлеге күзгә чалына.

О. А. Игельстром, бу төбәккә генерал-губернатор итеп билгеләнгәнче, 1768–1774 елларда Россия белән Төркия арасындагы сугышта катнашкан, шул елларда генерал дәрәҗәсенә ирешкән. Кече Кайнарҗа авылында уздырылган ике ил арасындагы солых килешүен төзүдә дә катнаша ул.

Екатерина патшабикә идарә иткән дәвердә Оренбург губернасы бик зур мәйданны биләгән. Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасы урталарыннан

алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачёв фетнәсе бастырылгач та ул чордагы Россиянең зур бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша О. А. Игельстромны билгели. Һәм аңа ул катлаулы, күпмилләтле биләмә белән ничегрәк идарә итәргә кирәклеге турында әледән-әле киңәшләр биреп тора. Ике арада йөргән хатларның бер өлеше 1886 елгы «Русский архив» журналында, «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.

Патшабикәнең аңа язылган хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча, аларга дөреслекне табарга рөхсәт ителсен». Икенче хатта мондый сүзләр дә китерелә: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз», – диелә анда. Ягъни дошмани сүз таратучы, гамәл кылучыларга карата чара күрсәгез дә, арттырып җибәрмәгез, аларны тиктомалдан атып үтермәгез дигәндәй итеп кисәтә Екатерина патшабикә. Әйе, тикмәгә генә татар халкы аны «Әби патша» дип зурламагандыр шул. Әби кешеләр шулай йомшаграк күңелле булалардыр инде. Бүген исә андый әби патшаларны сагынып сөйләргә генә кала. Дөрес, шул ук патшабикәнең Пугачёв күтәрелешендә катнашучыларга карата нинди кыргый чаралар кулланганлыгын да беләбез.

Екатерина Икенче белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дини карашка бәйле эзәрлекләүләргә каршы булуын сиздерә. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан мөфти белән якыннан аралашу нәтиҗәсе дә булгандыр. Бу барон идарә итә башлар алдыннанрак кына Мөхәммәтҗан Хөсәеновны киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп тә билгелиләр ич. Димәк, аның Бохарада үзләштергән белеменә, аралашу тәҗрибәсенә нигезләнеп, күршедәге мөселман мәмләкәте вәкилләре белән дипломатик сөйләшүләр алып бару осталыгын таныйлар. Аңа ышаналар. Ягъни ул губерна чигеннән көнчыгыштарак урнашкан казах ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән тарихи документларга да килеп керә. Мәсәлән, Казахстан

галимнәре катнашында туплап чыгарылган «Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане» хезмәтенең дүртенче томында (1939 ел) шул чор вакыйгаларына байтак урын бирелә. Һәм анда мулла Хөсәенов шәхесе һәм эшчәнлеге еш искә алына.

Әйтик, 1780 елларда Кече Җөзнең байбахты ыруы батыры Сарым Датов ханлыктагы тәртипләргә һәм рус дәүләте басымына каршы баш күтәрә. Мөхәммәтҗан Хөсәенов белән Миндияр Бикчурин берничә мәртәбә анда булып, Нургали хан белән батырны килештерергә тырышалар. Үз дигәннәренә ирешә алмагач, губернатор кушуы буенча, Сарым Датовны һәм ханлыкка кергән ыру башлыкларын Оренбургка чакырып сөйләшергә карар кылалар. Шушы җыенда катнашкан күпчелек Нургали ханны тәхеттән төшерү кирәклеге турында фикер әйтә. 1785 елның ахырында ханның үзен, гаиләсен һәм якыннарын әүвәл Оренбургка китереп урнаштырачаклар. Ә бераздан соң аларны ил чигеннән ераккарак – Уфага күчерү карарына киләләр. Хан гаиләсенә Уфада бай торак йорт бирелә һәм еллык биш мең сум акча түләп торыла башлый. Ул заманда бер көнлек эш хакының 2–3 тиен чамасында булуы тарихчы П. Рычков хезмәтләрендә теркәлгән. Димәк, ул биш мең хан гаиләсен һәм аның яраннарын иркен яшәтердәй күләмдә булган.

Бу гаугалы вакыйгалар һәм Кече Җөз тәхетенә Нургалинең энесен тәгаенләү мәшәкатьләрендә Мөхәммәтҗан мөфтигә дә катнашырга, атналап-айлап шунда яшәп, казах бәк-солтаннары белән эш итәргә туры килә. Бу вакыйгаларда ул губернаторның адъютанты, Кавказлы мөселман кенәзе Черкасский белән бергә йөри. Губернатор исеменнән башкарыласы чараларны алар бергә үтиләр.

Шушы хәлләрдән соң Екатерина патшабикә, губернатор белән мөфти фикерләрен хуплап, казах ханлыклары белән чиктәш калаларда һәм ханлыктагы кайбер торак урыннарында мәчетләр, мәктәпләр ачу кирәклеге карарына килә. Шул максат өчен губернага елына ике мең сумнан артыграк акча бүлеп бирелә башлый. Иң элек шул карар нигезендә Оренбург янәшәсендәге Меновый дворда һәм Троицк кальгасында яңа буралы мәчетләр калкып чыга. Әлбәттә инде, булачак граф Игельстромга шулай эшләргә кирәклеген искәртеп торучыларның берсе беренче мөфти хәзрәтләре булган дип фаразларга тиешбез. Ә 1789 елның 28 февралендә патшабикә тагын бер куанычлы фәрманга кул куя. Ул фәрманда: «Озакка сузмыйча Оренбург (янәшәсендәге) мәчет карамагында милли училище ачарга, аны кирәкле кадрлар белән тәэмин итәргә», – диелгән була. Һәм шул мәдрәсә каршында казах түрәләренең балалары өчен махсус интернат мәктәп оештырылырга кирәклеге, ел саен ул мәктәпкә күрше ханлыкның һәр ыруыннан ике бала кабулителергә тиешлеге дә әйтелә. Шул балаларны анда тәрбияләп тоту өчен һәрберсе исәбеннән

көненә бишәр тиен акча бүленеп биреләчәге дә ул фәрманда каралган була. Әлбәттә инде, бу мәктәп-мәдрәсәгә беренче чиратта хан һәм аның солтаннары балалары кабул ителгән. Шәһәрнең күренеклерәк гаиләләренең малайлары да ул уку йортыннан читләштерелмәгән. Әмма ул татар балалары хөкүмәт биргән биш тиен исәбенә кертелмәгән бугай.

Шул рәвешле Оренбургка якын бистәдә хөкүмәт исәбенә беренче мәдрәсә төзелә башлый. Ул уку йорты 1793 елда гына төзелеп бетә. Шуңа чаклы казах иленнән китерелгән балалар Сәет бистәсе (хәзерге Каргалы авылы) мәдрәсәләрендә укыйлар.

## 5

Шушы ук елларда Оренбург шәһәрендә яшәүче мөселманнар саны да көннән-көн арта бара. Шәһәрнең кыйбла өлешендә – Урал суы буе иңкүлегендә гади татар бистәсе – «Аренда», үрге якта исә чик буе сагында хезмәт итүче татар, башкорт атлы казаклары урамнары барлыкка килә. Бераз соңрак ул урамнар «казачийлар бистәсе Форштат» дип йөртеләчәк. 1911 елда нәшер ителгән «Әхмәт бай» китабында Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинов XX гасыр башында бу шәһәр халкының дүрттән бере мөселман кешеләре булуын яза. Шул губернага кергән башка шәһәрләрнең күпчелегендә дә ул дәверләрдә татар милләте вәкилләре саны шул чамада булган. Шәһәр халкы арасында башкорт, казах милләте вәкилләренең бик аз санда теркәлгән булуын да әйтеп үтү кирәктер. Шуңа күрә бу чик буе шәһәрләрендә яшәүче мөселманнарны татар дип атауда бер дә хилафлык юк.

Россиягә Төркестан ягыннан даими рәвештә килеп-киткәләгән төрле илчелек вәкилләре өчен Меновый двор бистәсе мәчетенең канәгатьләнерлек түгеллеген, анда сәүдә эше белән йөрүче гади халыкның күплеген, мәчет бинасының исә бик зур булмавын да әйтеп үтик. Әйе, ул мәчет фәкать атналап һәм айлап ком чүлләрен иңләп килгән кәрванчылар өчен генә төзелгән була ич. Югары дәрәҗәле чит ил түрәләрен һәм ханнарын кабул итәрдәй булмый. Шуңа күрә патша тәхете тирәсендә булган түрәләр дә Оренбург шәһәренең үзендә затлырак мәчет төзергә кирәклеген аңлыйлар. Әйе, губерна башкаласында мөселман динен тотучы кешеләр дә яшәүгә карамастан, монда әле рәсми рәвештә ачылган мәчет булмый. Шәһәр халкын гына түгел, мөфти Мөхәммәтҗанны да бу хәл бик борчый. С.-Петербургка бер баруында ул шул хакта император Александр Беренче даирәсенә кергән түрәләргә сүз каткан, шул рәвешле Оренбургта таш мәчет төзергә рөхсәт тә, акча да алынган, дип сөйлиләр. Бу императорны тәхеткә тәгаенләү мәҗлесенә чакырылган кунаклар арасында мөфти дә булгандыр дип фаразларга кирәк. Әйе, император җәнаплары кул куеп билгеләнгән мөфтиләр-

нең Россия империясе тормышында дәрәҗәләре югары булган. Императорлар аларны кайбер вакытларда кабул да иткән дип язалар. Димәк, Мөхәммәтҗан мөфтинең дә Александр Беренчегә император таҗын кидерү вакыйгасында катнашуында шикләнерлек урын калмый. Әйе, шулай икәнлегенә инану өчен башка патшаларны тәхеткә тәгаенләү чараларында мөфтиләрнең дә, ил күләмендә абруй казанганрак кайбер милләттәшләребезнең дә катнашу фактлары теркәлгән язмалар, истәлекләр сакланганын әйтеп китәргә кирәктер. Мәсәлән, 1881 елда император Александр Өченчене тәхеткә утырту чарасында мөфтидән тыш берничә татарның, шул исәптән Дәрдемәнд атасы Мөхәммәтсадыйк Рәмиевнең, 1896 елда исә Николай Икенченең инаугурацияләнү мәҗлесендә аның улы Мөхәммәтшакир Рәмиевнең катнашканлыгы мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк хаҗиның император җәнапларын котлап бик тә кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшырганлыгы турында да риваятьләр йөри. Ул бүләк, имеш, бер пот чамасы алтын хакына торырлык булган икән, дип тә сөйлиләр.

Әйе, XIX гасыр башында С.-Петербургта булганда Мөхәммәтҗан мөфти Оренбургта зур мәчет һәм аның карамагында абруйлы зур мәдрәсә ачу кирәклеген олуг түрәләр алдында раслый алган бугай. Дөрес, әлегә шул фаразларны дәлилләрдәй архив документлары белән танышу мөмкинлеге булмады. Әмма Оренбургның беренче таш мәчетенең төзелү тарихын, аны төзер өчен кирәк булган акчаның дәүләт тарафыннан бирелгәнлеген әйтеп язучылар бар. Ул мәчетне төзү рөхсәте 1801 елның ахырларында бирелгән дип фаразлана. Төзү эшенә 1802 елда тотыналар. Һәм 1805 тә анда беренче намаз укыла. Әлбәттә инде, хөкүмәт исәбенә төзелгән ул мәчет патша хөкүмәтенә казах ханлыкларыннан һәм Урта Азиядән даими килгәләп торучы хан-солтаннарны, дәрәҗәле илчеләрне кабул итәр өчен төзелгән. 1805 елда анда мәдрәсә дә ачыла. Һәм Меновый двор белән Сәет бистәсендә укучы чит ил шәкертләренең бер өлеше шәһәр үзәгендәге шушы уку йортына күчерелә. Бу мәдрәсәнең урам буйлап тезелеп киткән өч бер катлы бинасы әле Совет хакимияте елларында да сүтелмәгән килеш торды. Күрше төрки илләрнең хан, солтан балаларының XIX йөз башында шушында яшәгәнлеге һәм укыганлыклары турында кинаяле язмалар күренгәли. Әйтик, профессор Карл Фуксның 1826 елда Казанда Бүкәй Урдасы ханы Җиһангир белән очрашуга багышланган күләмле очеркында да шул хакта хәбәр бар. Университет белән танышканнан соң, Җиһангир хан аңа Оренбург мәдрәсәсен тәмамлаучы энеләрен һәм шунда укый башлаган улларын киләчәктә шушы уку йортына җибәрәчәген белдерә.

Шунысын да әйтеп үтик: 1898 елдан бу мәдрәсә бинасында Галимҗан Ибраһимов та укый башлаячак. Ләкин инде ул вакытта бу мәдрәсәнең ярым ябык типтагы, хан-солтан балалары өчен дип

тотылган чоры күптән үткән була. Бу вакытта инде Россиянең ил чигенең еракдагы Иран, Әфганстан якларына, Бохара әмирлеге «киртәләре»нә барып терәлгән чагы. Казах балаларын берничә дистәләп бергә туплап, хөкүмәт исәбенә бушлай укыту дәвере дә артта калган. Казах илендәге Акмәчет, Акмолалар, шул ил чигендәге Ташкент кебек калалар яңа уку-укыту үзәкләренә әверелгән чор була. Ташкентта 1870 елдан, Акмолада 1880 еллардан башлап казах телендә атналык газеталар да чыгып килгән чак.

Бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимов Оренбург мәдрәсәсенә укырга керер алдыннан гына аның җитәкчесе итеп Кышкарда белем алган, Мәккә, Мәдинәләрдә ике ел дәвамында «белемен чарлаган» Мөхәммәдвәли мулла Хөсәенев билгеләнгән була. Шул көннән ул уку йорты «Вәлия» исемен йөртә башлый. Ул уку йортының төп юнәлеше «укымышлы муллалар» тәрбияләп чыгару санала. Г. Ибраһимов әүвәл шул «Вәлия» мәдрәсәсендә укый. (Атасы аны үзе урынына мулла итеп калдырырга хыялланган була.) Әмма Галимҗан, монда алган белеме белән генә канәгатьләнмичә, Уфада яңа ачылган «Галия» мәдрәсәсенә барып керә. Әдипнең хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдова сөйләвенчә, «Вәлия»дә укып йөргәндә, Галимҗанга Урта Азиядән кайтучы бер кардәше бик серле бер язма калдырып китә. Шул язма киләчәктә әдипнең «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән хезмәтен язарга этәргеч бирә, дип искә алган иде Гөлсем апа.

Оренбург шәһәрендә мәчет төзергә рөхсәт алгач та мөфти хәзрәтләре аның имам-хатыйбы итеп Сәет бистәсе мулласы Габдессәлам Габдеррәхим улы әл-Бөгелмәви әл-Габдерине билгели. Ул муллага шул дәвердә, Бохара әмирлеге вәкилләрен каршылау алдыннан, Оренбург ахуны дәрәҗәсе дә бирелгән була. Габдессәлам мулла шул ук губернаның Бөгелмә өязе Габдрахман авылында туган. (Ул елларда Бөгелмә өязендә ике Габдрахман авылы була. Аларның берсе хәзер – Әлмәт, икенчесе Абдуллин шәһәрләре тирәсендә урнашкан. Булачак икенче мөфтинең кайсы авылдан икәнлеген мин әлегә ачыклый алмадым.) Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, ул шулай ук Каргалыга килеп укыган. Аннары үзе укыган мәдрәсә карамагындагы мәчеткә имам итеп сайланган була. Мөхәммәтҗан мөфти бу кешенең зур эшләр башкара алуына ышанган, әлбәттә. Аның ярыйсы ук белемле булуын да чамалагандыр, дип фараз итәсе кала. Һәрхәлдә, бу кешенең киләчәк язмышы мөфтинең хаклы булуын раслый. Алдарак әле без бу олуг шәхес белән тагын очрашачакбыз.

* * *

Әйе, Эчке эшләр департаменты штатында бүлек башлыгы рәвешендә исәпләнүче мөфтиләрнең Россия империясендә дәрәҗәсе дә, вәкаләте дә зур була. Алар үзләре теләгән вакытлар-

да патша җәнаплары белән турыдан-туры элемтәгә керә алган, дип тә язалар. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен ачык булган диярлек. Мөхәммәтҗан үз вазифасын үтәгәндә, империя белән өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина Икенче, аның улы Павел Беренче һәм Павел улы Александр Беренче. Шиксез ки, Әби патша идарә иткән елларда булмаса да, Павел һәм аның улы Александр тәхеттә утырган дәверләрдә Мөхәммәтҗан Хөсәеновка алар белән танышу насыйп булгандыр дип фаразлыйк. Шул ук шәхесләрне тәхеткә тәгаенләү чараларына Россия белән чиктәш ил-дәүләт җитәкчеләре дә чакырыла торган була. Бохара, Казах, Хива ханлыкларыннан килүче кунакларны Оренбург чик буе шәһәрләрендә каршы алу һәм аларны башкалага озата бару бурычы да мөфтиләргә йөкләнгәнлеге мәгълүм. Соңрак дәвер мөфтиләренең андый вазифаларны башкарганлыгы турында документаль язмалар да сакланган. Мөхәммәтҗан Хөсәенов мөфти вазифасын үтәгәндә дә шундый ук тәртип гамәлдә булгандыр, мөгаен. Мөхәммәтҗан мөфтинең гомер чигенә якынлашканда Россиянең шәрәфле шәхес булып танылуын да әйтеп үтү кирәктер. Аның Казан университетының Алтын медале белән бүләкләнүе дә шул хакта сөйли.

* * *

Патшалар чорында гамәлдә булган мөфтиятнең эчке төзелешенә карата да берничә җөмлә өстик. Урыннардагы имамнар белән элемтә тоту, аларның үз вазифаларын ничек үтәгәнлекләрен күзәтеп тору бурычы йөкләнгән өч казый монда һәр өч ел саен сайланып куела торган була. «Башта казыйлар фәкать мөфтинең ихтыяры һәм теләге белән, «казый булырга фәлән һәм фәләннәр җибәрелсен» дигән аның язуы буенча билгеләнгәннәр», — дип бәян итә Ш. Мәрҗани. Соңрак аларны урыннардагы абруйлырак имамнар фикерен туплап, сайлап куя башлыйлар. Шиһабетдин хәзрәт китабында Мөхәммәтҗан мөфти заманында казый вазифасын үтәгән берничә исем генә теркәлгән. Һәм алар барысы да, мөфтигә электән үк таныш кешеләр булганлыктандырмы, Казан төбәгеннән билгеләнгән муллалар. Исемнәре бу китапта китерелгән казыйларның икесенең Мөхәммәтҗан вафатыннан соң берара мөфти булып торганлыклары да әйтелә. Ш. Мәрҗани иң беренче казый буларак Бәрәскә авылы мулласы Бикчәнтәй әс-Сабавыйны атый. «Дини идарә ачылгач, сайланмыйча гына, Мөхәммәтҗан мөфти соравы буенча, Оренбургка казый булып бара», — дип яза ул. Тәүге төркемгә кергән казыйларның тагын берсе Казаннан Әбүбәкер Ибраһим улы әл-Казани мулла була. Казый хезмәтен ул берничә нәүбәт башкарган.

Беренче мөфти вафатыннан соң аның кәнәфиен биләгән дип фаразланган мулла Габделҗаббар әл-Орнашбаши икән. Казый

вазифасын үтәргә сайланганчы, ул Сәрдә белән Орнашбаш авыллары имамы булган. Шиһабетдин хәзрәт аның берникадәр вакыт мөфти вазифасын үтәгәнлеге турындагы хәбәрне бу мулла абыйсының улыннан ишеткәнлеген яза. Димәк, шулай булу ихтималын тәгаен расламый. Татар энциклопедиясенең икенче томында (7 б.) исә Габделҗаббар мулла мөфти вазифасын башкаручы буларак теркәлгән. Ул хәбәр, мөгаен, хәзрәт китабына нигезләнеп язылган булгандыр. Ләкин Ш. Мәрҗани, икеләнмичә, Мөхәммәтҗан вафатыннан соң бер ел чамасы вакытлыча мөфти булып торучы дип икенче бер казыйны – Әмин Дәмин улы әл-Җәбәли әл-Танавыйны күрсәтә. Тумышы белән Зөя өязе Танай авылыннан, ди. «Нәүбәт буенча, Дини идарәгә казыйлыкка сайлана. Мөхәммәтҗан мөфти вафатыннан соң аның урынына калып, вакытлыча мөфтилек вазифасын үти», – дип яза ул. Яңа мөфти билгеләнгәч, «ул тагын бер нәүбәт, сайланмыйча, мөфти үтенече буенча казый булып тора» ди.

Соңгырак дәвер казыйларыннан безгә ул урынга өч мәртәбә сайланган хәзрәт Ризаэтдин Фәхретдинов (Оренбург губернасы Бөгелмә өязеннән), Габдерәшит казый Ибраһимов (Себер тарафындагы Тара каласыннан), Хәсәнгата хәзрәт Габәши (Казан өязеннән, дүрт мәртәбә сайлана), Гыйниятулла Капкаев (Пенза төбәге вәкиле) яхшы таныш. Алар – XIX йөзнең соңгы чиреге белән XX йөз башында татар мәктәп-мәдрәсәләре эшчәнлеген заман шартларына якынайтып үзгәртү, татар матбугатын ачу һәм таратуга кагылышлы мәсьәләләрне кузгатуда да зур эш башкарган шәхесләр.

Алдынгы карашлы бу казыйлар һәм төрле тарафтан килгән муллалар, зыялылар катнашында 1898 елның гыйнварында Уфада зур җәмәгатьчелек җыены уздырылуын да билгеләп үтик. Ул җыенда «Сөйләм телен төзәтмәк, мәктәпне ислах итмәк» җәмгыяте дә оештырыла. (Бу җәмгыятьнең исеме һәм уставы шул җыелышта катнашкан язучы Фатих Кәриминең 1908 елда Казанда нәшер ителгән «Аннан-моннан» китабына кергән.) Истәлекләрдә хәбәр ителүенчә, ул җыелыш рәсми оешмалар рөхсәтеннән башка уздырылган була. Шул сәбәпле мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов ул җыелышта катнашырга теләми. Мин авырыбрак торам әле дигән сылтау белән аның үз авылына ук кайтып китүен искә алалар анда катнашкан кешеләр. Россиянең төрле төбәгеннән җыелган дин әһелләре һәм зыялылар арасында Казаннан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе вәкиле Таһир Ильясов, Уфадан адвокат Әбүсогуд Әхтәмев (Казан университетын тәмамлаган хокук белгече), Бәләбәй каласыннан морза Хәйдәр Сыртланов, Уфа мөселманнары ахуны һәм «Госмания» мәдрәсәсе мөдәррисе Хәйрулла хәзрәт Госманов, Оренбургтан башлангыч мәктәпләр ачу һәм тотуда зур эшләр башкарган Габделгани бай Хөсәенев һ. б. була. Мөселман мәктәп-мәдрәсәләре эшчәнлеген үзгәртеп кору, милли язма тел тәртипләренә үзгәрешләр

кертү максатыннан чыгып, шул эшләрне башлап җибәрү өчен ул мәҗлестә катнашучылардан күпмедер күләмдә акча да җыела. Ул җәмгыятьнең рәисе итеп Хәйрулла ахун Госманов сайланган була. Ләкин киләчәктә җәмгыять күзгә күренердәй зур эшләр башкара алмады, дип искә ала Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдинов. «Җәмгыять гайре рәсми булдыкыннан, эш башында утыручы чиновниклардан саклану тиешлегеннән, аның хакында һичкайда бернәрсә язылмады», – дип тәмамлый хәзрәт шул җәмгыятькә багышланган истәлекләрен.

Мөхәммәдъяр Солтановның патша фәрманы белән билгеләнгән бишенче мөфти (1886–1915) булуына карамастан, башкала түрәләре алдында үзен бик сак тотканлыгы турында язалар. Мөфти кәнәфиенә ул 49 яшендә, «акыл утыргач» тәгаенләнә. XIX йөзнең соңгы чирегендә, казах, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә газеталар чыгып килгән бер вакытта, Рәшит казый Ибраһимов һәм башкаларның аңа татарча газета чыгару өчен рөхсәт алышырга ярдәм итүен сораганлыгы, ләкин мөфти хәзрәтләренең андый эшкә алынмавы турында да хәбәрләр бар. Шундыйрак вакыйгаларны да истә тоткан татар зыялыларының да үтенечен искә алып бугай, 1915 елның урталарында чираттагы мөфти итеп «патша сарае утарында үскән» Петербург ахуны Мөхәммәтсафа Баязитовны билгелиләр. Аның атасы Гатаулла хәзрәт тә, соңрак Сафа мәхдүм үзе дә, Петербургта гади имам вазифасын үтәүдән тыш, патша сараен саклаучы һәм патшаларны даими рәвештә саклап, озатып йөрүче «Кавказ мөселманнарыннан» торган сак отряды мулласы да булган шәхесләр. Ләкин Сафа мәхдүмгә мөфти кәнәфиендә озак утырырга, игелекле эшләр башкарырга насыйп булмый. 1917 елның февралендә башланган түнтәрешләрдән соң аны Оренбург диния нәзарәте идарәсе рәисе вазифасыннан халык үзе азат итә. Шул елның май ае башында уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының корылтаенда, демократик рәвештә имза салу нәтиҗәсендә мөфти итеп Казан мулласы Галимҗан хәзрәт Баруди сайлап куела. Ил башлыклары карары белән мөфтиләрне билгеләп кую тәртибе бетерелә. Әлбәттә инде, ил күләмендәге андый зур кәнәфине биләүчене сайлап кую тәртипләре соңрак бераз үзгәртеләчәк. Хәзерге заманның күпсанлы төбәк мөфтиләренең төбәк җитәкчесе тәкъдимен истә тотып сайланганлыгы һәрберебезгә мәгълүм. Әмма революциядән соңгы бер дәвердә алар фәкать дин әһелләре тарафыннан сайланып куела торган булалар.

## 6

Алда әйтеп кителгәнчә, Мөхәммәтҗан мөфти 1823 елның декабрь ахырлары белән киләсе елның гыйнвар башы аралыгында вафат була. (Мөселманча ай һәм ел исәбе белән хәзерге заман ел

исәбен төгәлрәк тәңгәлләү шактый читен.) Аны Уфадан алтмыш чакрым ераклыктагы «үз авылы» Атҗитәр зиратында җирлиләр. Бу авыл һәм аның тирәләрендәге берничә мең дисәтинә җир аңа өлешчә хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән, өлешчә сатып алынган була. Аның ике хатыны, бер улы, ике кызы булган дип фаразлана. Шиһабетдин хәзрәт мөфтинең Гайшә исемле бер хатынын гына искә ала. Гайшә Төркиядә затлы гаиләдә туган, ике ил арасында барган бер сугыш вакытында Россиягә эләгеп, Казан ратушасы рәисе Исмәгыйль Апанай улына икенчеме, өченчеме хатынлыкка бирелә. 1794 елда ул ире вафат булгач, тол калган яшь хатынга Мөхәммәтҗан мөфти өйләнгән, дип хәбәр итә Ш. Мәрҗани (220 б.). Мөфтинең кече кызы һәм кияве белән таныш булган Казан университеты профессоры Карл Фукс исә аның Кәримә исемле хатынын гына искә ала. Мөфти вафат булгач, император Александр Беренченең карары белән «Кәримә бикәгә мең ярым сумлык еллык пенсия билгеләнгән» дип яза ул.

Мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле углы»ның никахсыз рәвештә бер марҗа белән яшәвен, шуңардан «никахсыз уллары» булуын без шулай ук Шиһабетдин хәзрәт китабыннан укып беләбез. «Мөфтинең озак гомер итеп, 1860 елда вафат булган хатыны, ахыр гомерендә Уфага килеп, барлык мөлкәтен дин исламда тормаган шушы оныкларына васыять итеп калдыра», – дип тә язган ул. Мөгаен, бу бала да Кәримә улы булгандыр.

Мирзаҗан гаиләсенә бәйле вакыйгада олуг хәзрәт белән тулаем килешәсе килми. Гәүрләрне иманлы итү һәр мөселманның изге бурычы лабаса. Мөгаен, Мөхәммәтҗан мөфти дә имансыз киленен иманлы итү чарасын күргән, тагын бер саваплы гамәлне үтәгән булгандыр.

Исмәгыйль Рәмиевнең 1966 елда «Казан утлары» журналында басылган бик кызыклы, «Мәдрәсәдән – университетка» дип исемләнгән мәкаләсенә дә күз төшереп алыйк. Казанда беренче гимназия 1759 елдан эшли башлый. «1767 елдан анда татар телен укыту өчен татар классы ачыла. Баштарак анда татар теле, аннары гарәп, фарсы телләре дә укытыла», – дип яза автор. Ләкин 1809 елга чаклы татар балалары бу гимназиягә кереп укымаган икән. Мәкалә авторы гимназия директорының шул елда язган исәп-хисап докладыннан түбәндәге юлларны китерә. «Мөфтинең улы да укырга керде. Ул русча, французча, татарча сөйләшә. Беркадәр гарәпчә дә белә. Мөфтидән үрнәк алып, бәлкем, татар байлары да үз улларын гимназиягә бирерләр», – дип тә хыяллана гимназия директоры. Бу өзекне укыгач аңлашыла ки, Мирзаҗан бу уку йортына килеп кергәнче кайсыдыр уку йортындамы яисә өй шартларындамы шактый зур тырышлык күрсәткән. Байтак телләрне үзләштергән булган.

Директорның уку-укыту идарәсенә язылган исәп-хисап хатыннан шунысын да ачыклыйсың: бу уку йорты татар балалары

өчен бөтенләй үк ябык булмаган икән. Ләкин безнең зыялылар ул уку йортына балаларын Мирзакайдан соң тагын байтак вакыт үткәч кенә даими рәвештә китерә башлыйлар. Мөхәммәтҗан мөфти урыннардагы муллалар исеменә махсус хат язып тараткannan соң. 1820 елларгача бу гимназиядә тагын ике казах баласы белән Казан морзасы Мөхәммәт Алкин улы Шаһиәхмәт кенә укыганнар, диелә мәкаләдә. Якындагы губернияләр стипендияләре исәбенә монда кереп укучылар саны егерменче еллар ахырыннан Казан уку-укыту идарәсе башлыгы итеп либерал М. Н. Мусин-Пушкин билгеләнгәч кенә арта башлый. И. Рәмиев китергән исемлектә стипендият гимназист һәм студентларның күбесенең Оренбург губерниясе идарәсе тарафыннан бирелгән акчага укыганлыгын да билгеләп үтик. Ләкин ул вакыйгаларга хәтле әле тагын ун еллап вакыт узасы бар.

Ә Казан гимназиясе бусагасын беренче булып атлап кергән, килгән дәвердә берничә тел белүе сәбәпле директорда соклану хисе уяткан гимназист исә монда озак укымый. «Мөфти улы Мирзаҗан монда укуы һәм өлгереше белән берниндиdә эз калдырмый. Гаилә күзе астыннан ireккә чыккач, кала җирендә тәртипсезләнеп, рус кызына өйләнеп, өенә кайтып китә ул», – дип хәбәр итә И. Рәмиев.

Мөфтинең олы кызы турында мәгълүмат бик аз. Аның бер казах солтанына кияүгә чыгуы, гомерен ерак дала шартларында уздырганлыгы турында кыскача гына хәбәр бар. Ләкин ул хәбәр дә документаль рәвештә расланмаган. Ә кечесе исә укуда да, тормышта да зур уңышларга ирешә. Шул кызга – Фатыймага багышлы мәгълүмат Россиянең бәк һәм морзалары тарихын чагылдырган бик саллы бер китапта да теркәлгән. Дөрес, анда кызның исеме аталмаган. Ә аның киявенең исеме дә, дәрәҗәләре дә ул бай белешмәлектә бар. 1886 елда С.-Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» хезмәтенең икенче томындагы 55–56 нчы битләрне ачыйк. Ул битләрдә кайбер казах иле ханнарына кенәз дәрәҗәсе бирелүе, аларның Чыңгыз нәселе варислары булганлыгын тану хәбәр ителә. Җиһангир исемле, безгә бераз таныш ханның ике хатыны булуы, кече хатынының «Оренбург мөфтие кызы» икәнлеге дә әйтелә анда. Шул пардан аларның дүрт ир-егет Чингизидлар туган диелә: Сәхибгәрәй, Ибраһим, Әхмәт, Гобәйдулла. Һәм ике кызлары булуы теркәлгән. Зөләйха исемлесенең «полковник Тәфкилевтә кияүдә» икәнлеге дә аерып күрсәтелгән.

Казан университеты профессоры Карл Фукс китабын кулга алсак, мөфтинең кече кызының Фатыйма исемле булганлыгын ачыкларбыз*. Татарлар арасында табиб буларак та танылган

* *Фукс К.* Кыргыз ханы Җиһангирның Казанга килүе / Казан һәм Казан төбәге. Казан : «Җыен» фонды, 2008.

Карл Фукс Фатыйма белән аның ире Җиһангир ханның 1826 елның көзендә Казанда булу вакыйгасына зур хезмәт багышлаган. Шушы көздә ул хан белән беренче мәртәбә очрашуын да искә ала ул.

Җиһангир хан белән якыннанрак танышып үтик. Алдарак без Кече Җөз ханы Нургалинең 1785 елның ахырында гаиләсе һәм якыннары белән үз иленнән Уфа шәһәренә сөрелүе турында әйтеп узган идек. Шул вакыйгадан соң аның тәхетенә энесен утыртканлыклары турында да сүз булды. Шуннан соңрак Нургалинең өлкән улы Бүкәй дә ул тәхеткә ия була. Ләкин ул тәхет тирәсендәге дәгъвалар тиз генә тынмый. Ишле хатын белән торган ханнарның уллары бер атадан тусалар да, еш кына алар төрле ыруг вәкилләре булып та саналалар бит. Һәр ыругның үз кешесен тәхет кәнәфиендә күрәсе килгәнлектән, алар арасында җитди генә бәрелешләр, бер атадан туган ир затларының бер-берсен үтерешүләре дә еш кабатланган. Шундый ук хәлләр Россия тарихында да булгалап торган ич. Әйтик, яшь Пётр патша белән аның апасы София арасындагы көрәшне ике ана вәкилләре арасындагы көрәш дип тә бәяләргә тиешбез. Дөрес, кайбер тарихчылар андый хәлләргә артык әһәмият итмәскә тырыша. Ә кайбер очракта хәтта патша варисы дип йөртелгән ул баланың чын атасы әлеге патша түгеллегенә күз йому очраклары да күзәтелә.

Кече Җөз ханлыгындагы вакыйгалар Оренбург губернаторын да, аның кул астындагы Чик буе комиссиясе кешеләрен дә бик борчый. Мөхәммәтҗан мөфтигә дә якын чик буенда барган бу гаугалы хәлләрдә еш катнашырга туры килә. Шул ызгыш-талашлардан котылу өчен бераздан соң Кече Җөз ханлыгы биләмәсен икегә бүлү карарына киләләр. Һәм 1812 елда, император Александр Беренче карары белән шул биләмәне бүлеп, Россиягә якын чик буе өлешендә яңа Бүкәй Урдасын оештыру килешүләренә кул куела. Бүкәй ханның оныгы Җиһангир егерме яшендә, 1823 елда, шул яңа «Урда»ның икенче ханы буларак тәхеткә утыртыла. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне русчалаштыргач, тәхеткә тәгаенләү фәрманында ул Җиһангиргәрәй Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла.

Шушы яшь хан 1826 елда Николай Беренчене тәхеткә тәгаенләү тантанасында катнаша. Шул вакыйгада катнашкан өчен император аңа һәм юлдашларына Россия империясе орденнарын тапшыра, кыйммәтле бүләкләр бирә. Шуннан соң хан, иленә кайтышлый, Казанда дүрт көнгә туктала. Бу хәл октябрь урталарына туры килә. Аны озата йөрүче солтан һәм старшиналары арасында үз мулласы, «нугай» Ает Мөхәммәт тә була. Хан гаиләсе Казан сәүдәгәре Муса өендә дүрт көн яши. К. Фукс аерып әйтмәсә дә, бу «Шурба Муса» дигән кеше дә, мөгаен, императорга таҗ кидерү вакыйгаларында катнашкан яисә сәүдә эшләре белән башкалага барган булгандыр. Хан белән алар шунда танышканнардыр дип фаразлыйк.

«Ханга 24 яшь. Европалыга тартым аксылрак йөзле... чибәр генә кыяфәтле, ягымлы карашлы. Рус телендә бик иркен сөйләшмәсә дә, һәр сүзне дөрес итеп куллана белә. Русча язуы да килешле, әйбәт... Рус һәм татар телләреннән кала фарсы, гарәп телләрен дә белә...» – дип яза К. Фукс аның турында. Галимнең шушы сүзләренә таянып, без казах ханнарының элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен дә чамалый алабыз. Яшь ханның рус телен яхшы ук үзләштерүенә килгәндә, башта казах кардәшләрнең 1957 елда чыгарган китабына да күз төшерик («Присоединение Казахстана к России», Мәскәү). Анда: «Җиһангир бернидәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә», – дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында хәбәр юк. Андый хәбәрне укучыга җиткерер өчен татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Аның Оренбургның хәзерге Левашев урамында урнашкан беренче таш мәчете карамагындагы махсус мәдрәсәдә укыганлыгына бер дә шикләнәсе түгел. Алдарак без Әби патша карары белән бу мәдрәсәнең казах түрәләре балаларын укытыр өчен махсус ачылганлыгын әйтеп үттек ич.

Казанга килгән ханбикә Фатыймага унҗиде яшь тулган. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатыны – шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәйдән соң алар диванга утырышып бик иркенләп гәпләшәләр. «Фатыйманың теле русча җырлап тора, бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел» икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм. Ул бик нәфис итеп тегелгән атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында – зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, хан тәхетенә тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул туйдан соң ук диярлек Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә, Кәримә бикәгә, патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы – җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкарнәй бар, дип хәбәр итә К. Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиңдәш булырдай итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс ул хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда мөфтият инде Уфада урнашкан була. Димәк, аның балачагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпут»ның ул вакыттагы «үз авылы»нда,Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗитәрдә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербугның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге дә булган. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә беркадәр белем алгандыр, мөгаен. Казах халык шагыйре Олжас Сөләйманов та, 2007 елның көзендә Казанда булганда, шундый-

рак фикер әйткән иде. Карл Фуксның истәлек язмалары да шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бүкәй хан Саратов губернасы чигендәге үз утарында 1845 елда вафат була. Бу вакытта инде ул, хан булудан бигрәк, Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач, ул һәм аның балалары, Чыңгызхан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр.

Патша Россиясендә кенәз дәрәҗәсе бик сирәк шәхесләргә бирелгән. Димәк, ул шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. XVIII—XIX йөзләрдә Россиядә рус милләтеннән булмыйча кенәз дәрәҗәсен алучылар күп түгел. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң, казах ханы Әбелхәер кебек, «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе дә шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Арыслан бәк (русча язмада Урус бәк, кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Соңгы чор казах ханнары, бигрәк тә Бүкәй урдасы вәкилләре — кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Җиһангир һәм аның варисларының Саратов губернасы чигендәге европача төзелгән утарына татарның зыялы кешеләре дә, Казан университеты галимнәре дә еш килгәләп йөргән. Җиһангир аларга бик кыйммәтле китап һәм кулъязмаларны табып һәм алып бирешүдә булыша торган була. Бу йорт-утар хуҗаларының Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ. б. лар белән еш аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озак гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары Россия дәүләтенә хезмәт иткән кенәзләр булалар. Фатыйманың «История родов...» китабында Ходжа рәвешендә теркәлгән кызының язмышы әлегә миңа билгесез. Зөләйха, алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене була. Ә Тәфкилевләрнең язмышы Оренбург белән Каргалыга да элек-электән бәйле ич. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре һәм затлы утарлары шунда була. Ул утар корылмалары әле Совет хакимияте елларында да бар иде. Оренбург янәшәсендәге ул утарда Ленин исемендәге данлыклы совхозның үзәге урнашкан иде.

## 7

Мөхәммәтҗан вафат булганнан соң икенче рәсми мөфти бер ел үткәч кенә билгеләнә. Аңа чаклы Оренбург төбәгендә бик зур вакыйгалар булып уза. 1824 елның сентябрь ае башында монда император Александр Беренче килеп китә. Аны каршылау, оза-

тып йөрү, Төркестан тарафыннан император белән күрешергә дип килгән хан-солтаннарның көен көйләү кебек мәшәкатьләр ул җәйдә мөфти вазифасын вакытлыча башкарган Әмин Дәмин улы әт-Танавый белән Оренбург ахуны Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви өстенә төшә. Шушы җәйдәге бик тә мәшәкатьле бурычларны үтәгәндә аеруча зур эшләр башкарып, Габдессәлам ахун император тирәсендәге түрәләрнең күңеленә хуш килгәндер, күрәсең. Император Александр шул елның җәй ахырларында аны мөфти итеп тану турындагы фәрманга кул куячак. Һәм Бөгелмә өязендәге Габдрахман авылында туган бу шәхес унөч ел дәвамында ул вазифаны уңышлы үтиячәк (1825–1838).

Мөхәммәтҗан мөфти бу мулланы халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә электән үк сыный башлаган була. Иң әүвәл ул аны Бохарадан Россиягә илче булып килүче зур бер төркемне каршы алу эшләренә җәлеп итә. Бу вакыйга 1799 елда була. Аннары, алдарак хәбәр ителгәнчә, ул аңа Оренбургтагы таш мәчетне һәм чит ил шәкертләре өчен диебрәк төзеләчәк мәдрәсәне сафка бастыру бурычын йөкли. Алар төзелгәч, аны шул мәчетнең имам-хатыйбы һәм мәдрәсә мөдәррисе итеп билгели. Габдессәлам бу бурычларның барысын да тиешенчә үтәп, башкарып чыккандыр, күрәсең. Соңрак Хива ханлыгыннан килгән илчелек вәкилләрен каршы алу, озатып йөрү вазифалары да аңа йөкләнәчәк. Һәм ул, гадәттә, килгән кунаклар белән губерна түрәләре арасында арадашчылык йөкләмәләрен дә бик уңышлы башкарып чыгачак.

Әйе, бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергәнлеге император җәнапларын каршы алу һәм озатып йөрү вакыйгаларында чамалана. Бохарадан һәм соңрак Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә ул губернатор җәнаплары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде 1824 елның сентябрендә Оренбургка император Александр Беренче килгәч, Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә. Мөфти буласы килеп йөргән кайбер көндәшләрен күпкә артта калдыра.

Император Оренбургта биш көн була. Патша җәнапларын каршыларга дип, Бүкәй урдасыннан да зур вәкиллек килә. Габдессәлам ахун элекке шәкерте, яңарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм аның өч бәк-солтаны белән бергә император тарафыннан кабул ителә. Шулай ук ул губернатор П. К. Эссен белән бергә императорны шәһәрдәге хәрби казармалар, хастаханәләр һ. б. оешмалар белән танышып йөрү сәяхәтендә дә озатып йөри.

Габдессәлам мулла мөфти кәнәфиен биләгән дәвердә исә Оренбургка булачак император Александр Икенче дә килә. Аның белән тәрбияче остазы шагыйрь Василий Жуковский да була. Шиһабетдин Мәрҗани китабында бу тарихи вакыйгалар искә алынмаган. Икенче мөфти эшчәнлеген бәяләгән бүлектә без фәкать түбәндәге ике җөмләгә генә игътибар итә алабыз. «Орен-

бургта булган Россия вәкилләренә үзен мәгърифәтле һәм алар белән бердәм итеп күрсәтә. Оренбург губернаторының таләбе һәм үтенече нигезендә мөфти була», – диелгән анда. Һәм бу мөфтинең вафат булган 1254 елы (1838) да, Уфада җирләнгәне генә хәбәр ителә хәзрәт китабында. Гаилә тормышына кагылышлы бер җөмлә дә язылмаган. Ш. Мәрҗани, ни сәбәпледер, Габдессәлам мөфти тырышлыгы белән Уфа каласында төзелгән яңа мәчет турында да искә алмый. Ә шул мөфти эшчәнлеген тасвирлап дастан-поэмалар иҗат иткән Гомәр Мөхәммәт улы әсәрендә ул факт теркәлгән, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов. Габдессәлам мөфти үтенечен үтәп, ул мәчетне Казан төбәгендәге Оры авылы сәүдәгәре Габделмөэмин Туктамышев-Хуҗасәетов үз акчасына төзеткән, дип яза галим*.

Әйе, бу мөфтинең тормышына һәм эшчәнлегенә кагылышлы тулырак мәгълүматны Сәет бистәсе шагыйре Гомәр бине Мөхәммәт Каргалыйның аңа багышланган ике зур шигъри әсәреннән укып белергә булыр иде. Ләкин әле ул әсәрләрнең барын бүгенге заман укучысы белми диярлек. Башына чалма кигән затларга багышланган андый әсәрләр Совет хакимияте дәверендә кабат басылмадылар ич. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары шагыйрьнең «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр Икенче патшаны Оренбургта кабул итү күренешләре «Сәфәрнамәи шаһзадә Александр» (1837) дигән күләмле әсәрдә чагылыш тапкан була. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казах ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадәне озатып йөрүчеләр белән бергә бара. Казах хан-солтаннары белән бергә оештырылган бик зур милли бәйге-бәйрәмнең әйдәүчесе дә мөфти хәзрәтләре була. Ул бәйгедәге ат чабышы ярышларында һәм башка төр хәрби уеннар күренешен тасвир итүдә татар, башкорт атлы казаклары да, күрше казах ханлыкларыннан килгән җайдаклар да катнаша. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре дә катнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнән башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе, күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөргән, дидек. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха татар нәселеннән була. Һәрхәлдә, без укыган еллардагы дәреслекләрдә шулай язылган иде. Хәзер ничектер. Әйе, хәзер бит күренеклерәк шәхесләрнең биографиясендәге татарга бәйле урыннарны төшереп калдыру тәртибе өстенлек итә башлады. Дөрес, шагыйрь үземе яки биографиясен әвәләүчеләрме, аның анасының милл-

* Татар әдәбияты тарихы. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1985. – 2 т. – 141 б.

тен «турчанка» дип яздылар. Ягъни, ул элекке Касыйм ханлыгы биләмәсендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» булып чыга. Икенче бер рус шагыйре – Константин Бальмонт та, кемгә иярептер, Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «анам шигъри җанлы турчанка иде» дип яза. «Шигърияткә яшьли күңел бирүем дә анам тәэсиреннән килә», – ди 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.

Жуковскийның анасы бер алпавытта хезмәт итә һәм шул кешедән бала таба. (Без укыган дәреслекләрдә аны алпавыт йортында «ключницей была» дип яздылар.) Патша Россиясе заманында шундый тотнаксыз алпавытлардан туган «атасыз» балалар адым саен очрап торган. Теләсә кайсы крепостной кызны алпавыт үз кәнизәге итә алган. Аннары ул кызны көмәнле килеш яисә яшь баласы белән берәр крепостнойга кияүгә бирә торган булганнар. Шундый ук язмышлы үги балалар арасында күренекле шәхесләрдән шагыйрь Афанасий Фетны, рәссам Орест Кипренскийны, Оренбург губернаторы генерал Василий Перовскийны һ. б. бик-бик күпләрне атап китеп булыр иде.

Салихадан туган Василий бераз гына булса да үз анасы телен дә белгәндер дип фаразларга мөмкин. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән җирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына булгандыр, билгеле. Гомәрнең бер поэмасының рус теленә тәрҗемә ителү вакыйгасы да шул фаразны раслый сыман. Аның Петербург яисә Ташкент архивларында сакланган поэмаларын укый алган очракта, без ул тасвирлаган вакыйгаларны һәм шул вакыйгаларда катнашкан Габдессәлам мөфти эшчәнлеген тагын да тулырак итеп күзаллаган булыр идек. В. Жуковскийның шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары да булган. Алар 1902 елгы «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә дә, Россия Фәннәр академиясе филиалы китапханәсендә дә ул журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле бу олуг шәхеснең, патша җәнапларыннан тыш А. С. Пушкин да аны үз остазым дигән шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле сәяхәтнамә язмалары белән әлегә танышып булмады…

Шагыйрь Гомәр Мөхәммәт иҗатын барлар вакыт та җиткәндер, шәт. Хәзер бит дин әһелләренә багышлы истәлекләрне кабат нәшер итү тыелмый.

1910 еллар башында Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Габдессәлам мөфтинең үз көндәлек язмаларын табып ала. Аларны Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдингә илтеп тапшыра. Һәм ул көндәлек язмалары 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыга.

Алдарак әйтелгәнчә, Шиһабетдин хәзрәт Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә ни өчендер бик аз туктала. Аның кылган эшләрен аерым искә алмый. Гаилә әгъзалары да бер дә телгә алынмый. Бәлкем, Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән, ул шулай эшләгәндер. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният кенә алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов.

Гомәр Мөхәммәт улының хәзергә мәгълүм булган өч күләмле әсәреннән ике поэмасы Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының кулъязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы – татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр... Бу әсәрнең тагын бер мөһим яңалыгы – реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора...» – дип бәяли аларны М. Гайнетдинов. Әйе, шушы ике поэманың эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак. Шуның өчен генә булса да ул поэмаларны яңадан бастырып чыгару кирәктер. Кемнәребез алыныр икән шундый зур, кирәкле эшне башкарып чыгарырга? Шулай ук мөфтинең үз көндәлек язмаларын да бүгенге мөселман укучылары кулына кайтарып бирү зыян итмәс иде...

## 8

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне – гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга һәм Оренбург төбәгенә мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул – 1865–1884 елларда дүртенче кеше буларак рәсми рәвештә мөфти кәнәфиен биләгән шәхес. «Татар энциклопедиясе»ндә Сәлимгәрәй мөфтинең 1805 елда Алабуга өязендә туганлыгы, 1885 тә Уфада бакый дөньяга күчкәнлеге теркәлгән. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәк-морзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Шунда ук алар хакында «хан балалары токымыннан» дигән җөмлә дә өстәлгән. «Сәлимгәрәй 1852 елда хаҗ сәфәренә юнәлә. Истанбулда солтан Габделмәҗид хәзрәтләре янына кереп, аны сәламләп чыга», – дип тә язылган анда. (Бу очракта сүз Төркия башлыгы турында бара. Башка төркиләр, шул исәптән казахлар илендә исә «солтан» дип хан балаларын атаганнар.) Бу хаҗиның бабасының атасы «Котлыгмөхәммәд морза, 1147 (1734) елда Россия гаскәре белән килеп, Оренбург шәһәренә нигез сала... Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кешеләр

мәгълүм түгел», – дип тә яза Ш. Мәрҗани. Әлбәттә, бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер. Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Тәфкилевләр дәрәҗәсендәге байлык иясенә тиңләрдәй Кавказ төбәге мөселманнары да булгандыр, бәлки.

Сәлимгәрәй һәм аннан соң килгән Мөхәммәдъяр мөфтиләр элек дини дәрәҗәләргә ия булмаганнар. Алар икесе дә әүвәлрәк хәрби каста төркеменә кергән шәхесләр. Шул сәбәпле кайбер дин әһелләре аларны бигүк өнәп тә бетермәгәннәр. Сәлимгәрәй мөфтинең зурдан кубып башкарган тәүге эше буларак, бу дин идарәсенең Уфа шәһәрендәге бина-утарын төзеп бетерүе санала. Тәүге тарафтарак ул шуның белән шөһрәт казанган шәхес. Илнең төрле төбәгендә эшләп килүче мәчет, алар карамагындагы мәктәп-мәдрәсәләр белән танышуга да ул зур әһәмият биргән. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин, карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре тәмамланмыйча, ярты юлда калды. Еш кына үз әмерен үзе бозар иде... Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчете күршесендә җирләнде. Балалары булмады», – диелә «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында Сәлимгәрәй мөфти турында.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза, Котлымөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәдән артыграгын Мәхмүт бай Хөсәеновка сата, дип язган идек алдарак. Бу морзаларның икенче зур җир биләмәләре дә шул ук Оренбург губернасының Бөгелмә өязендә була. 1848 елдан ул биләмәнең төп хуҗасы буларак Сәлимгәрәй Тәфкилев исәпләнә. Шул ук елда ул Бөгелмә өязе алпавытларының җитәкчесе итеп тә сайлана. Һәм үз утарында хәзергәчә үзенчәлекле архитектура истәлеге булып саналган затлы сарай төзетә. (Ул авыл хәзер Башкортстан биләмәсенә керә. Әлеге затлы сарай бинасы да саклана дип ишеттем.) «Мөфти итеп билгеләнгәч, ул берничә мәртәбә Казанда була, Тифлис ягына да барып кайта», – дип яза Ш. Мәрҗани. Ләкин Кавказ төбәге биләмәсенең үзәге булган, императорның шул төбәктә яшәүче барлык милләт вәкилләре өстеннән җитәкчелек итүче вәкиле – наместнигы утырган Тифлис (бүгенге Тбилиси) каласына ни өчен барганлыгы әйтелми. Дөреслектә ул анда мөселманнарның сөнни мәзһәбенә керүчеләре өчен ачылган мәчеткә бәйле берәр төрле чарада катнашырга дип барган булгандыр, мөгаен. Нәкъ шул еллардан башлап анда сөнниләр мәчете имам-хатыйбы бу-

ларак татар морзалары Терегуловлар династиясе вәкиле Хәсән мулла хезмәт иткән. Сәлимгәрәй мөфти Тифлиска барган вакытта, 1870 елларда, ул җәмигъ мәчете мулласы вазифасын Касыйм төбәгеннән чыккан Терегуловлар нәселе биләгән. Ә Тәфкилев белән Терегулов морзалар исә гомер-гомергә кода-кодача булып яшәгәннәр ич.

Татар энциклопедиясенең русча бишенче томында Сәлимгәрәй мөфтинең Уфа шәһәрендә авыру һәм мохтаҗларны карау өчен дип үз исеменнән мөселман приюты ачканлыгы, төрле урыннарда мәчет һәм мәктәп-мәдрәсәләр төзү һәм тоту өчен махсус вакыф-фондка акча калдырганлыгы да хәбәр ителә.

## 9

Оренбург төбәгенең яңа чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов баштарак мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти урынын биләргә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Әйе, күпчелек рус түрәләре тарафыннан да ул шул кәнәфине биләргә иң лаеклы шәхес саналган. Аңа чаклы ул байтак еллар дәвамында Төркестан төбәге генерал-губернаторының җирле халык белән аралашу буенча ярдәмчесе дә, якын-тирәдәге мөстәкыйль ханлыклар белән элемтә тотучысы да булган.

Ләкин аны мөфтилеккә сайлауга каршы русның югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Н. И. Ильминскийның әлеге морза кандидатурасына каршы төшеп, Синодның өлкән прокуроры К. Победоносцевка язган хатлары сакланган. Ул хатларның кайберләренең күчермәләре миндә дә бар. Хатларында ул Ш. Ибраһимов белән Казанда очрашкалаганлыгын бәян итә. Ул аны акыллы, тирән белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы «цивилизованный, энергичный» шәхес дип бәяли. Һәм Урта Азиянең, башка шәрык илләренең билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат дип мактый да, нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш дигән нәтиҗә чыгара. Уңай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилев Сәлимгәрәй морзадан да күпкә өстен тора, дип яза. Шул өстенлеге белән ул безнең дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господ и чинов высшего управления»). Мөселманнар белән идарә итүче оешма башлыгы итеп безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак калучы кешене сайларга кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н. Ильминский 1885 елның 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкала түрәләре Шаһимәрдән Ибраһимовны ул исемлектән сызып ташлыйлар. Бишенче мөфти итеп Минзәлә төбәгеннән чыккан морза, «башкорт-татар атлы

казаклары гаскәрендә кантон башлыгы булган Мөхәммәдъяр Солтановны куярга кирәк», – дип, император җәнапларына җиткерәләр. Шул рәвешле тиздән аны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә. Шушы кәнәфине биләгәндә Мөхәммәдъяр Солтановның нәкъ Ильминский күрәзәлек иткәнчәрәк гамәл кылуы күпләргә мәгълүмдер ки. Ә Шаһимәрдән Ибраһимовны исә тиз арада Согуд Гарәбстанына, Җиддә шәһәренә илче вазифасын үтәргә дип озатачаклар. Шул вазифаны үтәгәндә, ул анда вафат булачак.

Бик күп замандашлары кабул итмәгән мөфти Солтановның да элекке Оренбург губернасы җирлегеннән чыкканлыгын билгеләп үтик. Гаскәри кантон башлыгы дәрәҗәсенә ирешкәнче аның башкорт-мишәр казаклары төркемендә күрше казах ханлыкларын яулап алу сугышларында катнашканлыгы да искәртелә.

## 10

Габдессәлам Габдерәхим улы вафат булгач, өченче кеше рәвешендә мөфтилеккә тәгаенләнгән Габделвахид Сөләйман улы әл-Җәбәли әл-Әрбашчины да искә алып үтик. Ул Оренбург төбәге кешесе түгел. Ш. Мәрҗани аны: «Мишәр таифәсеннән, Нижний өязе Әрбәшчи авылыннан чыккан», – дип белдерә. Ягъни ул Сембер губернасында туган кеше. Мөфти кәнәфиенә утыртылганчы ул С.-Петербургта сәүдә эшендә була. Үз ишләре арасында мулла вазифасын да башкара. Ул чорда әле башкалада мәчетләр булмый. Атасы авыл мулласы вазифасын үтәгәнлектән, Вахид намаз тәртибен дә, догаларны да яхшы үзләштергән була. «Россиянең вәкаләтле олы кешеләренә укымышлылыгын күрсәтеп, Габдессәлам вафатыннан соң мөфти булуга ирешә, 1256 (1840) елда Уфа шәһәренә килә, – дип хәбәр итә Шиһабетдин хәзрәт. – 1863 елда, 75 яшендә бу дөнья белән саубуллашкач, Уфадагы мөселман зиратында җирләнә», – ди. Димәк, ул чирек гасыр чамасы мөселман дине җәмгыяте идарәсе җитәкчесе булып торган. Ләкин дин ислам мәсьәләләренә кагылышлы хезмәтләрдә аның исеме сирәгрәк очрый.

* * *

Россия империясенең императорлары (патшалары) фәрманы белән билгеләнгән, шул ил мөселманнарының яшәеше, тормыш итеше өчен җаваплы булган алты рәсми мөфтине искә алдык. Бу вазифаны биләү еллары тәртибендә аларны кабат санап чыгыйк. Беренче мөфти, Россиядә иң әүвәл тәүге Коръән китапларын бастырып таратучы Мөхәммәтҗан бине Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый (1778–1824), Габдессәлам бине Габ-

деррәхим әл-Бөгелмәви (1825–1838), Габделвахид бине Сөләйман әл-Җәбәли әл-Әрбашчи (1840–1863), Сәлимгәрәй бине Шаһингәрәй бине Йосыф Тәфкилев (1865–1885), Мөхәммәдъяр бине Мөхәммәтшәриф Солтанов (1886–1915), Мөхәммәтсафа бине Гатаулла Баязитов (1915–1917). Җәя эчендә мөфти вазифасын үтәгән еллары күрсәтелә.

1917 елгы вакыйгалардан соң мөфтиләр төрле җыеннарда сайлап куела башлый. Иң беренче булып бу вазифаны үтәргә Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди сайлана. Бу вакыйга шул елның май аенда Мәскәүдә узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда була. 1921 елның декабрендә ул кинәт кенә вафат булганнан соң, Үзәк Россия һәм Себер төбәгенең яңа дин башлыгы итеп күренекле галим һәм танылган мөхәррир Ризаэтдин бине Фәхретдин бине Сәйфетдин сайлап куела. Бу вазифаны ул 1936 елга чаклы – вафат булганчы башкара.

## Төпләмеш

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнең Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетеп тә, укып та үсәргә туры килгән иде. Мин үскән Иске Актау (Иске Белогор), аның янәшәсендәге Яңавыл (Яңа Актау), Аюлы, Бәшир, Имангол, Кондызлы ише авыл картлары белән сүз чыкканда әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алынырлар иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Яңавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбарый Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннең соңында укуын Каргалыда дәвам иттергән.

Авылыбыз зираты уртасындагы зур, биек «Изге таш»ны да Каргалы авылы исеменә бәйләп сөйлиләр иде. Шул авылдан чыккан Рәфыйк баба җиденче мәртәбә хаҗ сәфәреннән кайткан вакытта безнең авыл очындагы Иртәк инеше буенда үлеп калган икән. Ул вакытта безнең авылда Каргалы кешесе Әхсән имам-хатыйп булып торган. Шуларда кунып чыгарга дип килгәндә, бик тә эссе көндә авыл очына җиткәч җан биргән бу изге хаҗи. Әле сугыштан соң да аның кабере өстенә куелган «Изге таш» янәшәсендә ятып сихәтләнеп, терелеп чыгар өчен дип, төрле тарафтан авыру яисә күңел тынычлыгын җуйган кешеләр дә килеп кунгалар иде. Шундыйлар арасында хәтта хәрби киемнәрен дә салмаган, култык таякларына таянып, көчкә атлап йөргән соңгы сугыш каһарманнары да очраштыргалады. Ул мосафирларны зират янәшәсендәрәк ялгыз яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм озатып куяр иде. «Файдасы булдымы соң?» – дип сораучы

карт-карчыкларга мосафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты. Алла боерган булса, тәнем дә савыгыр», – диебрәк җавап бирәләр иде.

Авылга бер кайтуымда мин шул изге ташка ни-нәрсә дә булса язылганмы икән дип кызыксынган идем. Авыл мулласы белән без ул ташта бернинди язу да тапмадык. Ә аның янәшәсендәге кабер ташыннан исә Каргалыдан чыккан «Биләгур имамы Әхсән мулла»ның монда чирек гасыр имам-хатыйп булып торуын, 1824 елда 69 яшендә вафат булганлыгын укып белдек. (Бу ташның һәм Изге ташның фотолары бар.) Ул монда муллалык иткән елларда, Самара белән Оренбург шәһәрләрен «чуен юлы» тоташтырганчы (1879), башкала тарафына яисә хаҗга барырга чыккан һәр мөселман кешесе диярлек Бозаулык суы буена гәрәбәдәй тезелешкән татар авыллары аша йөри торган булган. Димәк, кайчандыр бу юлдан алда санап үтелгән барлык шәүкәтле мулла һәм мөфти хәзрәтләребез дә бер генә мәртәбә үтмәгәндер. Хәтта ки даһи шагыйрь Пушкинның да, Уральск тарафына юл тотканда, шушы тирәләрдәге биек акбур тауларына карап, язылачак повестеның үзәгендә торган авыл исемен «Белогорская крепость» дип атаган булуы да бик ихтимал. Нәселе Каргалыга бәйле булган рус теле укытучысы Рашат абый да кайчандыр шундый фикер әйтеп, безне «Капитанская дочка» повестен каткат укырга ымсындырган иде.

Изге хаҗ сәфәрендә җиденче мәртәбә булган Рәфыйк бабай да шушы юлдан йөргән инде. Барышлый һәм кайтышлый Әхсән мулла өендә туктала торган булган. Һәм аның шул изге юлда йөргәндә вафат булуы уңаеннан изге догада яшәүче авыл картлары ярдәмендә әлеге зур Изге таш та куелгандыр…

Ә авылыбызның соңгы рәсми мулласын, кырык алты ел чамасы шул изге вазифаны үтәгән Габдулла Габидуллинны 1926 елда җирләгәннәр. Кечерәк кенә кабер ташы, әлеге Изге таштан бер читтәрәк, куе кылган үләнлегенә күмелеп утыра хәзер. Кабер ташы ташландыграк хәлдә булса да, авыл халкы шул ук мәдрәсәләрнең берсендә белем алган Габдулла мулланы да бик еш искә алыр иде. Аның аеруча балалар укытуга зур әһәмият биргәнлеген, шул сәбәпле кайбер күрше авыл малайларының да безгә килеп укырга тырышканлыгын сөйләрләр иде. Совет хакимияте елларында мәктәп бинасы булган, кайчандыр шушы мулла фатихасын алып, Бакый бабабыз җитәкчелегендә төзелгән мәчет тә аның истәлеге буларак телгә алыныр иде. Ә совет хакимияте тәртипләре гамәлдән чыккач, авыл халкы Габдулла мулла исемен йөртәчәк яңа мәчет төзеп куйды. Аның ачылышында оныгы Роберт Шәмгунов белән бергә мин дә булган идем. Бу вакыйга 1996 елның җәй урталарына туры килде…

Башлангыч сыйныфларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алыр иде. Оренбургның аргы ягын-

дагы Чебенке авылларының берсендә туган булса да, ул Каргалыны, аның кешеләрен дә бик сагынды, ахрысы. Берничә ел шунда укыган да булса кирәк. Оренбург төбәгенең элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаров морзалар гаиләсен китерер иде. Әнә бит Кәраметдин Айдаров хәзер Сәмәрканд университеты профессоры, аның туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык елгасы тирәлегендә урнашкан татар авылларының соңгы ахуны Харис хәзрәт тә шул морзалар нәселеннән булган, ди.

– Аның улы Әсгать Айдар – күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнең кебек вакытта шушы Искеавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларның җимеш бакчалары булуын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без аның «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз, – дип сөйләр иде Хөснә апа дүртенче класс балаларына.

Шул ахунның XX гасыр башында Иске Актау авылы янәшәсендә Сабан туйлары оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күпсанлы кунаклар җыелганлыгын мин соңрак «Вакыт» газетасыннан укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр анда 1914 елгача даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясы янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман милләтеннән күп кеше җыелган иде, көрәш кеби кызыклар белән Сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...» Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сахрада узган Сабан туйларында, бәлкем, минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган яшь үгез итен дә капкалагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар (фарсычасы Сәмәр бугай) елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыганнар. Туасы шаулы гасыр алдыннан гына авыл мәчетен яңартуда тырышып катнашкан бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә шушы авылдан Урта Азия тарафына таба ургылган атаклы Татбригада сугышчылары аны да үзләре белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда, җизнә бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынып искә алган иде.

— Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казах, үзбәк авылларында укытканда да көндез хәлфә, кичләрен мулдакә идем. Хәзер дә шулай, — дип мактанып та куйган иде Чимкәнт шәһәре янәшәсендәге зур үзбәк авылында гомер иткән Хәбибулла бабабыз.

Йа Ходам, үзең ярлыка. Изге юлда йөреп, изге эшләр башкарган барлык имамнарыбыз, мөфтиләребез кылган изге гамәлләр мәңге онытылмасын. Бүгенге укымышлы дин әһелләребез белән бергә ара-тирә булса да узган гасыр мөфтиләренең изге эшләрен дә искә алгалыйк. Алар рухына изге догаларыбызны багышлыйк.

*2017*

## МЕҢНӘРГӘ МИСАЛ БУЛЫРДАЙ ҮРНӘК

2018 елның соңгы көннәрендә генә «Җыен» фонды тарафыннан нәшер ителгән «Бертуган Хөсәеновлар» китабы басылып чыкты. Күренекле шәхесләребез тормышын һәм эшчәнлеген халыкка таныту ниятеннән башкарылган, бик затлы итеп эшләнгән шундый китаплар әлеге фонд тарафыннан даими рәвештә нәшер ителә. Китап киштәмдә шундый тирән эчтәлекле, зәвыклы эшләнешле ике-өч дистә китап арасында Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Һади Атласи, Габдерәшит Ибраһимов, Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Хөсәен Фәезханов кебек узган чорның атаклы шәхесләренә багышланганнары да, Салих Сәйдәшев, Илһам Шакиров, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин кебек үз чордашларыбыз, үз замандашларыбызның тормыш юлын һәм иҗади уңышларын барлап чыгарылганнары да бар. Һәм бу китапларның барысы да дәүләт хисабына түгел, олуг шәхесләребезнең бөек хезмәтләрен олылаган аерым иганәчеләр керткән акча исәбенә нәшер ителгәннәр. Әле генә дөнья күргән, үзләре дә иганәчелек эшчәнлеге белән танылган сәүдәгәр, бертуган Хөсәеновларга багышланган китап та Сөләйман Сәхи улы Әбүнәгыймов һәм аның улы Салаватның матди ярдәме белән басылып чыккан.

Оренбург төбәгендә туып үскән Хөсәенов байлар — халкыбыз тарафыннан танылган ике зур мәдрәсәне («Хөсәения» белән «Вәлия»), Оренбург, Казан, Самара һәм Уфа губерналарында, Урта Азия авыл һәм шәһәрләрендә йөзләгән мәктәп-мәдрәсәне үз хисапларына ачкан һәм тоткан шәхесләр. Патша хөкүмәте ул заманда милли мәктәп-мәдрәсәләр тотуга бер тиен дә акча бирмәгән. Татарны татар итеп тәрбияләрдәй барлык уку йортлары да Акчурин, Агафуров, Дибердиев, Рәмиев, Максудов,

Хөсәенов, Шәфигуллин кебек танылган эшкуарлар хисабына яшәгәннәр. (Бүген дә халкымның шундый хәлдә калу ихтималы бар дип сыкрый күңел.) Ә бит эшчән, тырыш татар халкы патша заманындагы казнаны тутыру өчен дә үз өлешен мулдан кертә торган булган.

Мәдрәсәләр эшчәнлеген бәяләүгә кагылышлы бер-ике сүз дә әйтеп китәсе килә. Совет хакимияте елларында зур-зур җыелышларда кайбер җитәкчеләр «мәдрәсәләрдә алынган белем белемме инде ул» дигәнрәк сүзләр әйткәләр иде. Һәм шул ук елларда СССР Министрлар советының статистика идарәсе тарафыннан бишәр йөз мең тираж белән чыгарылган белешмәлекләрдә татар мәдрәсәсен тәмамлаучыларның белем дәрәҗәсен Совет чорындагы Учительский институтны тәмамлаучылар белән тиңләп, аларны тулы булмаган югары белем алучылар исемлегендә йөртү тиешлеге каралган иде. Минем архивта сакланган шундый өч белешмәлектә (1963, 1966,1968 елларда басылып чыккан рәсми документ) белем бирү дәрәҗәсе буенча әлеге институтларны тәмамлаучылар белән тиңләштерелгән биш гали мәдрәсә теркәлгән: «Буби», «Галия», «Касимия», «Мөхәммәдия» һәм «Хөсәения». Аларда өч-дүрт елга исәпләнгән югары («гали») курслар булган, заманга ярашлы төгәл фәннәр дә укытылган. Математика, физика, химия, география һәм рус теле дәресләре бик аз күләмдә укытылган яисә бөтенләй дә укытылмаган Урта Азия шәһәрләрендәге мәдрәсәләр исә бу исемлеккә кертелмәгәннәр...

Бай эчтәлекле затлы китаплар нәшер итү белән мәшгуль «Җыен» фонды узган гасыр ахырларында барлыкка килде. Бу фонд халкыбызның күренекле шәхесләре булган Миркасыйм Госманов, Разил Вәлиев, Дамир Сираҗиевлар тырышлыгы белән тудырылды. Академик М. Госманов вафат булганнан соң (2010 ел), бу фонд җитәкчесе (рәисе) эшен Разил Вәлиев башкара. Фондның гамәли директоры Фуат Рәфыйков белән баш мөхәррире Җәүдәт Миңнуллин һәм типография таләпләрен үтәүче нашир Рамил Миңнуллин да Миркасыйм әфәнде рәислек иткән дәвердән бирле эшләп килүче тәҗрибәле осталар. Миңа да бу осталар белән аралашырга туры килгәләде. «Үзеңнең нугай якларыннан (Оренбург төбәгеннән) чыккан шәхесләрдән кемнәрнең исемнәрен фонд чыгарасы китаплар исемлегенә кертер идең?» – дип сораган иде Миркасыйм дус. Мин аңа унбишләп исем-фамилия теркәлгән исемлекне язып биргән идем. Шунда иң беренчеләрдән булып үз халкының аңын тагын да аңлырак итәргә, мәдәниятен алгарак җибәрергә дип күп көч куйган бертуган Рәмиевләр белән бертуган Хөсәеновларны, Россиядә яшәгәндә дә, үз илендә эзәрлекләнә башлагач Төркиягә качып китеп, анда да байтак уңай эшләр башкарган якташым Габделбари Батталны атаган идем мин. «Бертуган Рәмиевләр»

исеме белән 2002 елда нәшер ителгән китапны чыгаруда да актив катнаштым. Анда минем Рәмиевләр биографиясенә һәм эшчәнлегенә багышланган ике күләмле хезмәтем басылып чыкты. Китапта кулланылган фотосурәтләрнең барысы да мин тапшырган фотолардан алынган иде. Хәер, «Бертуган Хөсәеновлар»да кулланылган фотоларның да күпчелеге минем һәм Мәдинә Рәхимкулова архивыннан алынганнар. Китапның бик калынаеп китүе сәбәпле, анда кермичә калган фотолар саны да шактый әле. Җәмгысы мин 43 фото тәкъдим иткән идем (исемлек копиясе архивымда саклана. Аларның бер өлеше Мәдинә апа һәм Каргалы авылы табибы Әнвәр Искәндәрев җибәргән фотолар иде). Шулар арасында Гани бай улы Мөхәммәтвәли Хөсәенов мөдәррис булган, күренекле шәхесләребездән Галимҗан Ибраһимов, Шаһит Әхмәдиевләр укыган «Вәлия» мәдрәсәсенә кагылышлы өч-дүрт фото да бар иде. Ул мәдрәсә мәчетенең тарихы да бик үзенчәлекле. Оренбург тарихына багышлап чыгарылган китапларда ул еш кына «казённая мечеть» рәвешендә теркәлгән. Чөнки ул Әби патша заманында оештырылган «Мөселман дине идарәсе» карамагында булган. Ул беренче таш мәчетне төзергә рөхсәтне дә император Александр Беренче биргән. Аны төзү өчен акча да казна хисабыннан җибәрелгән дигән риваять яши. Патша хозурына барып, шундый рөхсәтне үтенеп алучы Үзәк Россия һәм Себер тарафы мөселманнарының беренче баш идарәчесе-мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәенов була. 1802–1805 елларда мәчетне төзү эшләрен башкару мөфтинең урынбасары, Оренбург ахуны Габдессәлам Габдерәхим улы әл-Бөгелмәвигә йөкләнә. (Бу булачак икенче мөфтинең шул чордагы Бөгелмә өязенә кергән Габдрахман авылында туганлыгы да әйтелә. Әмма кайсы Габдрахманнан ул? Хәзерге Әлмәт төбәгенә караганыннанмы, әллә соң хәзер Оренбург өлкәсенә кергән, халык язучысы мәрхүм Мөсәгыйт Хәбибуллин туганыннанмы?) «Мәчет һәм аның карамагында ачылачак мәдрәсәгә дип ниятләнгән өч таш бина да 1805 елда төзелә», – дип язалар Оренбург төбәге тарихына багышланган китапларда.

Әлбәттә, бу мәчетнең һәм аның карамагындагы мәдрәсә биналарының «ак патша биргән акчага төзелү» тарихын Урал елгасының аргы ягындагы Казах, Үзбәк ханлыклары белән арадашлык мөнәсәбәтләреннән чыгып эшләнгәнлеген күзалларга кирәктер. Авыр юллар үтеп, ул тарафтан патша Россиясенә дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен җайлаштырырга дип килүче хан-солтаннар ул заманда Оренбургта берара ял итә торган булган. Бу шәһәр белән бер үк вакытта Урал-суның аргы ягында ике якның сәүдәгәрләре алыш-биреш итсен өчен төзелгән, Меновый двор дип йөртелгән бистәдә 1749 елда Елизавета Петровна рөхсәте белән барлыкка китерелгән кечкенә агач мәчет андый дәрәҗәле кунакларны канәгатьләндерми башлый. Бохара хан-

лыгы вәкилләрен көткән бер вакытта Александр Беренче патшаның таш мәчет төзетергә дип кинәт юмартлануы аңлашыладыр, шәт.

Миңа да шундый ук бер вакыйганың шаһиты булырга насыйп иткән иде. 1958 елда Һиндстан мәмләкәте җитәкчесе Җәваһарлал Неруның «кунакка» җыенуын белгәч, СССР хөкүмәте җитәкчеләре дә Ленинградның Җәмигъ мәчетен, тиз генә тәртипкә китереп, ачу карарына килгәннәр иде. Шәһәрдә яшәүче мөселманнар ул чакта бик тә сөенгәннәр, шул ук вакытта дәрәҗәле кунак китүгә үк яба күрмәсеннәр дип борчылып та торалар иде. Дөрес, мәчетне кунак киткәч тә япмадылар. Неру киткәч тә озак тормастан, шәһәргә Казаннан Җыр һәм бию ансамбле дә килде. Ул вакытта Киров исемен йөртүче Опера театры сәхнәсендә биючеләр аягындагы утызлап пар чабатадан ургылып чыккан тузанга төчкерә-төчкерә утырган зәвыклы киемле әби-бабайларның балкып торган йөзләрен күрү бәйрәм шатлыгын арттыра гына төште сыман. Дөрес, тәнәфескә чыккач, фойеда төркем-төркем торган ир-атларның: «Безнең татар һаман шул мескен хәлдә инде. Аякта тула оек та чабата, иңдә киндер күлмәк белән ычкырлы ыштан», – дип, уфтанып сөйләшеп торуларын да ишетергә туры килгән иде ул чакта. Ә шулай да ул концертны күпчелек тамашачы хуп күргән. «Тагын, тагын килегез», – дип, чабаталы артистларны сөенеп озатып калган иде. Шул ук кичәдә олырак яшьтәге тамашачыларның, үзара пышылдашып, «Мәчеттә булдыңмы әле?» дигән сүзләрен дә ишеткәләргә туры килде.

Кабат Оренбургка әйләнеп кайтып, аның беренче мәчете карамагында ачылачак мәдрәсәгә дә тукталып үтик. Урал-суның аргы ягындагы өч казах ханлыгының хан, солтан һәм ыруг башлыкларының балаларын бу таш мәчет ачылганчы Каргалы авылы белән әлеге Меновый двор мәчете мәктәп-мәдрәсәләрендә укытканнар. 1789 елның февралендә Әби патша (Екатерина икенче) андагы мәчет белән мәктәпләрне һәм анда укучы балаларны Россия хөкүмәте исәбенә бушлай тоту өчен махсус карар да чыгарган була. Ул карарның эчтәлеге губернатор О. А. Игельстром архивында сакланган вариантта бар. Мин кулланган нөсхәсе исә «Губернаторы Оренбургского края» китабының 121 нче битендә китерелә (Оренбург, 1999). Патшабикә әмеренә күз төшерик. «Мәктәпләрне һәм андагы мәчетләрне тоту өчен елына 2007 сум акча бүлеп бирелә. Укучы балаларны ашату-эчертү һәм яшәтү көненә биш тиеннән исәпләнергә тиеш», – дигелгән анда. Күпме бу, әллә бик азмы? Чагыштырып карау өчен Оренбург шәһәрен төзүдә катнашкан тарихчы, төзелеш дәверендә исәп-хисап эшләре өчен җаваплы булган Пётр Рычков китабын ачып карыйк. «Шәһәрне төзү эшләренең күбесен солдатлар башкарды. Шулай ук анда җирле халык та җәлеп ителде. Аларның

ашау-эчүе солдат казаныннан булды, көненә икешәр тиеннән эш хакы да түләнде», – дип яза ул.

Инде узган ел ахырында гына укучы хөкеменә тапшырылган яңа китапның үзенә әйләнеп кайтыйк. Аңа әзерлек эшләренә 2008 елда ук керешелгән иде. Миркасыйм Госмановның яңа китапка кирәсе хезмәтләрнең эчтәлеген барлап чык әле дигән беренче үтенеченә карата язма җавапны мин шул елның 30 апрелендә җибәргәнмен. Бу эшкә Җәүдәт Миңнуллин белән Рәиф Мәрдәнов кебек белгечләрнең катнашуы да бик кирәк, дип тә язган булганмын. Әлбәттә, элекке гарәп хәрефләрен һәм мул рәвештә гарәп һәм фарсы сүзләрен кулланып, унтугызынчы гасыр ахырында язылган күпчелек истәлек язмаларын шундый белгечләр катнашуыннан башка башкарып чыгу мөмкин эш түгел иде. Һәм ул катлаулы вазифаны үз өстенә алып башкарып чыгучы Җәүдәт Миңнуллин булды. Бу эшкә ул үзенең шәкертләрен һәм аспирантларын да җәлеп итте. Китапны кулга алып укучылар исеменнән аларга мең-мең рәхмәтләр әйтәсе килә. «Җыен» фонды рәисе Разил Вәлиев белән фонд-вакыфның гамәли директоры Фуат Рәфыйковка да бу китапны бастырып чыгаруның матди ягын үз өстенә алучы иганәчене табуы җиңел булмагандыр. Эшмәкәрләребез арасында фактик миллионер һәм миллиардерларыбыз ишле генә саналса да, халык мәнфәгате файдасына булсын дип иганә кылырга атлыгып торучыларыбыз әлегә күп түгел. Янә дә бу китапны укучы кулына тапшыруда зур гамәл кылган аталы-уллы Сөләйман белән Салават Әбүнәгыймовларга мең-мең рәхмәтләр әйтәсе килә.

Кешенең көндәлек таләбен үтәргә кырык-илле тиен җиткән бер дәвердә һәр ачкан мәктәп-мәдрәсәләре өчен ничәдер меңнәр сум түләп иганә кылучы Әхмәт, Мәхмүт, Гани Хөсәеновларны бүген искә алмыйча мөмкин түгел. Әйе, Хөсәенов сәүдәгәрләр яшәгән чорда – унтугызынчы йөз ахырларында Тозтүбә шахталарында тоз чыгаручы шахтёрларның көнлек эш хакы 50–60 тиен чамасы булган дип яза Оренбург төбәгенең үткән тарихын өйрәнүчеләр. Хөсәенов байларның Сәмәрканд каласында төзеткән мәчетен һәм шуның карамагында җәдиди ысул белән укыта башлаган мәктәбен тотар өчен генә дә елына берничәшәр мең сум акча кирәк булгандыр, мөгаен. Ул мәктәп ачылышына Кырымнан Исмәгыйль Гаспринскийның килгәнлеген, балаларын шунда укырга биргән ата-аналарның яңача укыту тәртибен бик хуплап кабул итүләрен яңа чыккан китап битләреннән укып белергә була. Төрле тарафларда мәчетләр төзү һәм алар карамагындагы мәктәп-мәдрәсәләрне яшәтү өчен бу өч бертуганның һәм аларның балаларының шул чорда миллион ярым сум чамасы акча тотканлыклары мәгълүм. Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган шәкертләрне Россиядәге һәм чит илләрдәге махсус уку йортларында укыту өчен дип махсус стипендияләр дә бил-

геләгән алар. Дәреслекләр бастырып чыгару өчен дә елына биш йөз сум акча каралган була. Һади Максудиның яңа ысул белән укытуга җайлаштырылган беренче дәреслеге дә шул сәүдәгәрләр хисабына нәшер ителә. Садри Максудиның Париждагы университетка барып уку чыгымының күпмедер өлешен Мөхәммәдгани Хөсәенов каплаганлыгын да без шушы җыентыкка кергән «Гани бай» китабыннан, шул китапта китерелгән Тимерша Соловьёв истәлекләреннән генә укып беләбыз…

Соңгы сүз итеп, «Җыен» фондына яңадан-яңа китаплар чыгару мөмкинлеге булдырылуын теләп калам. Ул эшкә Хөсәенев сәүдәгәрләр кебек бик юмарт, изге җанлы иганәчеләр җәлеп ителәр әле дигән өметемне өзмим.

*2019*

# IV

*Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем!*

*Г. Тукай*

## «ЯРЛАР ҺАМАН ИШЕЛӘ...»

*(Нәсер)*

Чирек гасыр чамасы элек Кырымда булган бер очрашу истән чыкмый. Мөлаем кыяфәтле, чал керә башлаган чем-кара чәчле яңа танышым, диңгез шавын тыңлый-тыңлый, яр буенда сабыр гына үз моң-зарын бәян итеп утырган иде. Кайчандыр ул шушы ял йорты урнашкан Күктүбә бистәсеннән ерак түгел бер авылда туган икән. Әмма аның гомере чит-ят җирләрдә үткән. Аңа өч яшь тулмастан, аларны бу җирләрдән алып киткәннәр.

– Мондагы тормышыбызны хәтерләмим дә. Яңарак кына тәпи басып йөри башлаган булганмын. Бер нәни кәҗә бәтие генә мәңге күз алдымда тора. Язгы чирәмдә мин аның белән уйнаганмын. Безне алып китәсе олауга да мин шул бәтине кочаклап утырганмын, – дип сөйләгән иде ул. – Хәер, әлеге җылы, мамыктай йомшак йонлы кәҗә бәтиен үз күзем белән күреп беләмдерме, әллә әбием сөйләгәннәргә нигезләнеп кенә хәтерлимме, тәгаен генә әйтә дә алмыйм, –дигәне дә истә әле.

Кырымлылар әйтелешенчә «Кара даг» дип аталган мәшһүр Каратау тарафыннан ябырылып килгән хәтәр дулкыннар янә безнең ярга килеп бәрелде. Текә ярның бер катламының ишелеп, чалт-чолт итеп суга төшкәнлегә ишетелде.

Диңгез шавы тына төшкәч, яңа танышым сүзен дәвам итте:

– Галимнәр раславынча, өч яшьлек бала әле андый вакыйгаларны хәтерендә калдыра алмый. Шул ук вакытта ниндидер кискен үзгәреш, хәзергечә әйтсәк, стресс булган очракта, бала хәтеренең бер вакыйганы мәңгегә истә калдыру ихтималын да инкяр итмиләр. Ә бу очракта ул шулай булган да. Ялан кырда туктап торган поезд янына килеп җитүгә, олаудагыларны акыра-бакыра тартып төшергәннәр, төрткәләп, суккалап вагоннарга «төягәннәр». Тирә-якта кычкырыш, җылаш булган. Кай арададыр кулымнан ычкынып киткән бәрәнемне таптырып мин дә кычкырганмын да, җылаганмын да... Әйе, шушы җәмле җирдәге, шаулы диңгез буендагы ватаныма карата минем күңелемдә шушы вакыйгага гына уелып калган шул... Бөтен авылыбыз белән шушы поездга төяп алып китүләрен инде мин хәтерләмим. Аларын соңрак миңа әбием, туганнарым кат-кат сөйләде...

Кара диңгез буендагы «Күктүбә» дип йөртелгән ял йортына ике-өч көн элек кенә килгән бу кеше танышу кичен шушы вакыйгаларны искә алудан башлаган иде. Ташкенттагы дәүләт оешмасы

тарафыннан бирелгән рәсми юллама белән килүенә карамастан, Симферополь аэропортында аны тоткарлыйлар. «Ник Кырымга килдең? Нинди максат белән килдең?..» — дип тинтерәткәннәр, сорау да алганнар икән үзеннән.

— Шулай булу ихтималы турында милләттәшләрем Ташкентта ук кисәткәннәр иде. «Безләрне анда тоткарлыйлар, ватаныбызга кертмәскә тырышалар. Журналист кенәгәңне дә ал, абруйлы гәзит вәкиле икәнлегеңне белсеннәр», — дип киңәш иттеләр. Шул кенәгәмне күрсәткәч тә бер усал бәндә: «Безне хурлап язарга килдеңме монда?» — дип, җәнә бәйләнде...

Шушы вакыйгага бәйле рәвештә әле ул үзе туган тирәлекне эзләп барырга да шикләнеп тора икән.

— Мондагы ял вакытым тәмамланыр алдыннан гына үз авылымны барып күрермен дигән фикергә килдем. Шушындагы ялдан соң зинданга салсалар да түзәрмен... — дип куйды ул, уфтанып.

Берничә көннән соң без тагын шул ук урында очраштык. Октябрь аеның соңгы көннәре. Төн ягыннан кырыс җил исә. Диңгез дулый. Таудай кабарынган көчле дулкыннар бер-бер артлы безнең ярга килеп бәрелә. Дулкын бәргән саен, ярның бер өлеше убылып, шапылдап суга төшә. Мондый күренешне минем дә, аның да беренче күрүе икән. Әйе, «кәттә дә киң, шаулы диңгез буенда» беренче мәртәбә ял итүебез. Икебезнең дә балачак сугыш елларына туры килгән. Икебез дә атасыз үскәнбез. Аталарыбыз шушы ватаныбызны саклаганда яу кырында ятып калган. Үз күкрәкләрен дошман коралына каршы куеп, ил-ватанны саклап һәлак булган сугышчы балалары без.

Усал дулкыннар шавын басарга тырышып, мин аңа:

— Санаулы көннәр тиз үтүчән, юлдаш, иртәгә мин китәм, — дидем. Гадәттәгечә үзбәк кардәшләр кулланган сүзләрне дә искә төшергәләп гәпләшү безне якынайта төшә иде шикелле. Яңа танышым да, минем белән аралашканда, кардәш өч милләтнең сүз байлыгын бергә кушып сөйләшергә тырыша. Билгеле инде, мин алай ук булдыра алмыйм. Юл йөргәндә колакка кереп калган берничә сүз белән котылам. Бу ял йортындагы бөтенләй үк ят та саналмаган, бигүк теләктәш тә булмаган яңа дус-иш арасында өч тел байлыгын кушып гәп кору безнең күңелләргә ятыша төшә сыман иде.

— Хак әйтәсең, әкә, санаулы вакыт тиз үтүчән. Ә мин әле бу мохиткә, бу һавага ияләшеп кенә киләм гой. Туган йортым, Ватаным һавасы дип, үз-үземне ышандырырга тырышам. Ә күңелем нигәдер һаман тынычлана алмый... Әнә күр, безнең ярлар һаман ишелә, җиребез һаман кими... Монда калган кышлакларыбыз юк ителгән... Ә безне һаман үз мәмләкәтебез туфрагына аяк бастырмаска тырышалар. Ник монда килдегез, дип каршы алалар, әкәм...

Әйе, берничә яшькә олырак икәнемне истә тотып, олылап, ул миңа «әкәм» дә, «агам» да дияр. Ара-тирә «кардәшем» дип тә куйгалар иде.

Көзнең иң күңелсез, давыллы бер көнендә без аның белән аерылыштык. Кабат һәм кабат очрашырбыз кебек аерылышкан идек. Әмма андый күрешүләр насыйп булмаган икән. Ә аның: «Ярларыбыз ишелә тора, без берни дә эшли алмыйбыз», – дип ачынып әйткән сүзләре һаман әле онытылмый. Әлбәттә инде, ул табигать тарафыннан барлыкка китерелгән ишелү – диңгез ярының убылуы турында гына әйтмәгән иде. Ул сүзнең мәгънәсе тирәндәрәк, яшәешебезгә бәйлерәк булуын икебез дә аңлый идек...

Күпме гомер үткән. Инде башка заман, башка тәртипләр. Исән-сау булса, Кәбир танышым да хәзер үз иленә кайтып төпләнгәндер. Үз ватанында гомер итәдер, шәт.

Әйе, теге вакытта ул, туган җирен истә тотып, сагынып, туган халкы язмышы турында уйлап һәм борчылып: «Җиребез һаман кими бара», – дип бик уфтанган иде шул. Вак-төяк җир убылуларына бәйләп ватаны өчен күңел сыкрануларын сиздереп әйткән сүзләрен ишеткән мәлдәрәк әле минем күңел түрендә «Ярый әле без андый язмышка дучар ителмәгәнбез – туган җиребездән куылмаганбыз. Үз җиребез, үз ватаныбызда яшибез» дигәнрәк уйлар бөтерелеп үткән шикелле иде. Ә хәзер...

* * *

Еллар үтә торды. Өч-дүрт көн чамасы ара-тирә күрешкәләп йөргән ул каләм иясенең хәзер исеме дә онытылып бара инде. Кәбир идеме соң ул? Әллә Хәбирме? Фәкать шунысы истә: ул үзен Ташкентта Кырым татарлары телендә чыгучы «Ленин байрагы» газетасы хезмәткәре дип таныткан иде. Аерылышуыбызга ике дистә чамасы ел үткән. Ә менә йөрәк әрнүе белән әйтелгән сүзләре исә һаман да истә әле. Алар әледән-әле искә төшә. «Җиребез елдан-ел кими бара. Ә безне туган илебезгә кайтармыйлар. Кунакка да зур кыенлыклар белән киләбез», – дигән иде бит ул.

Әйе, мин ул вакытта эчтән, күңелдән генә: «Аллага шөкер, без әле үз җиребездә яшибез. Без куылмаганбыз...» – дип, үз-үземне юаткан кебек идем. Соңрак, тирәнтенрәк уйлап баккач, үзебезнең биләмәләрнең дә акрынлап кими баруын, «безнең ярларның да туктаусыз ишелеп торуын» чамалый башладым. Дөрес, ул «ишелүләр»нең барышы берничә еллар белән генә чикләнми. Ул хәлләрнең барышын дистә еллар белән исәпләргә кирәк. Мәгәр мәрхүм артист Аркадий Райкин кабатларга яраткан «процесс пошёл» сүз тезмәсе бу очракка туры киләдер сыман. Әйе, андый яман хәрәкәт инде безнең очракта бик күптәннән башланган. Һәм ул хәл-хәрәкәт бүген дә дәвам итә. Татарстан белән Башкортстан биләмәләреннән читтә урнашкан авылларыбыз әкренләп юкка чыга бара. Күптән түгел генә әле язучы Фәүзия Бәйрәмова бөек шагыйребез – Такташыбызны тудырган Сыркыды авылында булып кайткан иде. Күрше милли мохтарият биләмәсендә – Мордовиянең бер почмагында урнашкан ул авылның да нык үзгәрүенә,

башкачарак гомер итүче чит-ят тормышка әверелә баруына әрнеп язып та чыкты Фәүзия. Тирәнтенрәк уйласаң, андый язмышлы, ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне оныта язган авылларыбызның елдан-ел кубәя баруын танырга мәҗбүр буласың…

Кайчандыр күзгә чалынган бер мәгълүматка караганда, егерменче гасыр башында Тула губернасының Лев Толстой яшәгән төбәгендә безнең милләттәшләр яшәгән авыллар да булган. Бөек әдип анда яшәүчеләрне күреп белгән, аралашкан. Аларның тормыш-көнкүрешен уңай бәяләгән. Шул аралашулар нәтиҗәсе буларак, аның бер хезмәтендә теркәлгән «татары ведут правильный образ жизни» дигән җөмлә тугандыр да, мөгаен. Ул авыллар бармы соң хәзер? Әлбәттә, авыл исемнәренең сакланып калуы да ихтимал. Белгород, Курск, Калуга һ. б. бик күп өлкәләрдә төрки атамалы елга, авыллар саны бихисап ич. Ә анда яшәүчеләр кемнәр? Үз ана телләрен саклаганнармы соң?..

Берничә өлкәне кисеп үткән, безнең тарихта исеме еш кабатланган Ука елгасы буйларына гына күз салыйк. Елга, хәзерге Орёл, Рязань, Тула, Калуга, Мәскәү һәм Түбән Новгород өлкәләре аша агып, киң Иделгә килеп кушыла. Унтугызынчы гасырда гына да әле ул елга буендагы өлкәләрдә йөзләп татар авылы булганлыгы мәгълүм. Ә хәзер анда үзебезчә сөйләшүчеләр күпме соң? Түбән Новгород өлкәсендәге «үҗәт мишәрләр» яшәгән берничә дистә авылны санамаганда, башка төбәкләрдә хәзер аларны көндез шәм ягып та табып булмастыр. Ә бит шушы Ука елгасы буендагы авыл һәм шәһәрләрдә яшәгән, рус әдәбиятында еш кына «турчанка» буларак теркәлгән аналардан туган дистәләгән мәшһүр шәхесне атап китеп була. Пушкинның остазы, булачак император Александр Икенченең тәрбиячесе булган мәшһүр шагыйрь Василий Жуковскийның анасы «турчанка Салиха», күренекле әдип Иван Тургенев, фәнни космонавтикага нигез салучы Константин Циолковский, нәселе ханнар токымына барып тоташкан әдип Александр Купринның да аналары шундый ук милләт вәкилләре булган. Әйе, кырыгынчы елларда нәшер ителгән, без укыган дәреслекләрдә әле шулай язылган иде. Хәзер исә «вакланып», ул кадәресен язып тормыйлар. Җитди тарихи әсәрләр авторы, Аксак Тимергә багышланган өчтомлык роман иҗат иткән Сергей Бородин, күренекле прозаик Виктор Полторацкий да тәннәрендә татар каны да акканлыгын яшермичә яшәгән, алда атап үтелгән өлкәләрдә туган шәхесләр. Фәкать аларның биографлары гына кайбер очракта «аналары татар милләтеннән» диясе урынга «турчанка» ише атамалар эзләп тапканнар. Укучы, янәсе, бу шәхеснең анасы Бөек Осман империясеннән, ягъни Төркиядән булган икән дип уйласын дигәннәрдер, күрәсең…

Замандашларыбыз, совет чоры әдипләре Виктор Полторацкий белән Сергей Бородинны күреп тә белә идем. Алар һәрвакыт үзләренең кан тамырларында татар өлеше булганлыкларын яшермәделәр. Милләттәшләребез белән бик теләп аралашалар иде.

Гази ага Кашшаф сөйләвенчә, сугышка кадәр С. Бородинның паспортында да татар милләтеннән дигән сүзләр язылган була. Ул елларда әдип Әмир Сәгыйтьҗан исем-атамасы белән йөргән. 1934 елда Татарстан язучыларының беренче корылтаена да шундый таныклык белән килгән була. 1953–1957 елларда Ташкентта рус телендә нәшер ителгән «Сәмәрканд өстендә йолдызлар» роман-трилогиясенең кереш өлешендә дә үз биографиясенең татар милләтенә бәйле булуын ул яшермәгән.

Совет чоры әдибе Лев Никулинның егерменче гасыр башы әдипләренә, сәнгать әһелләренә багышлап язылган күләмле истәлекләр китабы бар. Илленче еллар ахырында нәшер ителгән бик кызыклы эчтәлекле китап. А. И. Купринга багышланган бүлектә ул мондыйрак тасвирлама китерә: «Язучылык даны киң таралган унынчы елларда Куприн башына кәләпүш киеп, иңенә татар халаты салып кәпрәеп йөрергә ярата иде», – дип яза. 1960 еллар башында ил күләмендәге барлык кинотеатрларда күрсәтелгән «Гранатовый браслет» киносын төшерүче режиссёр да бу әсәр авторының образын шул кыяфәтендә тамашачыга тәкъдим иткән иде.

Алдарак әйтеп үтелгәнчә, бу олуг шәхесләрнең «турчанка» дип танытылган аналарының яисә кайберләренең үзләренең туган авыллары хәзер юк инде. Дөресрәге, безнең өчен юк инде алар…

* * *

Безнең авыллар язмышы артыннан һаман да әле кара чапанлы Аксак Каратуннар сагалап йөри кебек. Бары тик кулга тоткан кораллары гына алмашынгалап тора… Узган йөз еллыкны гына күз алдыннан үткәрик. Патша Россиясендә яшәгән «кече милләтләр»гә, 1905 елда чыккан патша манифестына нигезләнеп, берникадәр ирек бирелде. Милли мәктәпләр өстеннән күзәтүләр, мәктәп тотучыларны һәм хәлфәләрне төрлечә кысу, җәберләүләр беркадәр кими төшкән иде. Ләкин, ике-өч ел да үтмәстән, «бөек түрәләр» бу эшләренә үкенә башлый, яңадан да дилбегәне тартыбрак куеп, ул ирекне чикләү чараларын тормышка ашырырга керешәләр. Шул чорны тасвирлаган язмаларда әйтелгәнчә, Министрлар Советы рәисе булган Столыпин исеменә бәйле рәвештә «Столыпин реакциясе еллары» башланып китә. 1908 ел кергәч үк диярлек Мәгариф министры А. Н. Шварц «инородецлар мәктәпләре» эшчәнлеген чикләү, аларны катгый тикшереп тору тиешлеге турында фәрман бирә. Әйтерсең лә безнең замандагы коллегасы кебек үк эш йөртә. Ләкин Шварцка соңыннан кемнәр алдында булса да акланырга тырышып, «җитди дәлилләр» китереп торасы булмавында гына бераз аерма бар. Ул дәвердә монархия режимы әле үз көчендә, бүгенге кебек «чикләнгән демократия» чоры түгел иде. Югыйсә ике дәвер – патшалар дәвере һәм хәзерге көн мәгариф җитәкчеләренең дә максаты кайчак тәңгәлләшә сыман. Бабалары татар нәселенә мөнәсәбәтле булган Пётр Столыпинның

бу фәрманга карата фикере исә безгә билгесез. Андый фәрман чыгарырга кем әмер биргән – нәсел кан кардәшләре арасында күпмедер дәрәҗәдә немец «эзе» дә булган патша Николай Икенчеме, Столыпин үземе яисә иң дәрәҗәле урын биләгән берәр попмы – анысы мәгълүм түгел.

Мәгариф министрының милли мәктәпләр эшчәнлеген чикләүгә юнәлтелгән карары тормышка ашырыла гына башлаган бер вакытта, 1910 елның гыйнварында, С.-Петербургта мөселман татарлар язмышына кагылышлы ярым яшерен бер җитди киңәшмә дә уздырыла. (Кара: «Особое совещание по выработке мер противодействия татаро-мусульманскому влиянию...») Эчке эшләр белән Мәгариф министрлыклары җитәкчеләре һәм чиркәү әһелләренең иң дәрәҗәле вәкилләре катнашында уздырылган ул киңәшмә татарларның иҗтимагый һәм дини тормышын чикләүгә юнәлдерелгән, 34 параграфтан торган карар кабул иткән. Шул карарда әйтелгәнчә, күреләсе чараларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр: Идел буе өлкәләрендә, татарлар күпләп яшәгән урыннарда чиркәүләр эшчәнлеген көчәйтергә; җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр тормышын даими рәвештә тикшереп торырга, кирәк тапкан очракта аларны ябарга; татарлар арасыннан миссионерлар әзерләүне арттырырга; мөселман рухани уку йортларының санын киметергә; мәктәп-мәдрәсәләрдә дини эчтәлекле булмаган фәннәр укытуны тыярга...

Нәкъ менә шушы киңәшмәдән соң инде җәдиди ысул белән укытуга күчкән «Иж-Буби» мәдрәсәсен ябу, укытучыларын хөкемгә тарту кебек җәнҗаллы эшләр башланып китә. Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Пенза, Саратов кебек губерналарда мәктәп-мәдрәсәләр кайта-кайта тикшерелә, аларны гаепсез килеш ябу очраклары да була. Мәктәп-мәдрәсә хәлфәләре, каләм әһелләре өендә, газета-журнал редакцияләрендә бер-бер артлы тентүләр үткәрелә. Дәреслекләр, төрле кульъязмалар кулга алына һәм юк ителә. Мисалга «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими белән «Шура» мәҗмугасы мөхәррире Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиновларның өйләрендә һәм эш урыннарында үткәрелгән тентү нәтиҗәләренә тукталыйк. Фатих Кәрими өеннән алып чыгылган документлар арасында Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романының беренче каралама нөсхәсе дә була. Һәм ул әсәр башка кирәкле кәгазьләр белән бергә юкка чыга. Ризаэтдин хәзрәтнең, шулай ук Кәримовлар басмаханәсенең мөдире Тимерша Соловьёвның өйләреннән һәм эш урыннарыннан алынган бер генә кәгазь дә хуҗаларына кире кайтарылып бирелми.

* * *

Шул ук «Столыпин реакциясе еллары»нда көчләп яки алдап-йолдап чукындыру хәрәкәте дә яңарыш ала. Әлегә безнең галимнәребез бу хәрәкәтнең Казан губернасыннан читтәге

төбәкләрдәге барышын тикшермиләр. Фәкать үз губернабыздагы билгеле бер контора («керәшеннәр конторасы») эшчәнлеге белән ара-тирә кызыксынгалаган булалар. Ә бит Самара, Сембер, Саратов кебек күрше губерналарда да чукындыру хәрәкәте дәвам иттерелгән. Ул чорда Самара губернасы биләмәсенә кергән Хәсән Туфан авылы яки Сембер губернасы биләмәсендәге Тимерсән авылы үрнәгендә без андагы милләттәшләребезне көчләп чуваш дип язу үрнәкләрен беләбез. Хәзер Ульяновск өлкәсенә кергән Тимерсән авылы вакыйгаларын утыз еллар элек күренекле дәүләт эшлеклесе Кадыйр ага Габдрахманов язып та чыккан иде. Андый вакыйгалар, әлбәттә, шул губерналарның епархия идарәләре архивларында теркәлгән булырга тиеш. Әмма безнең әле андый архивлар ишеген ачып керердәй белгечләребез юк шикелле.

* * *

Патша чоры мәгариф министры А. Н. Шварц фәрманы милли мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлеген беркадәр кысу чаралары белән чикләнгән булса, төп-төгәл илле елдан соң аннан да яманрак тагын бер карар кабул ителде. СССРда яшәгән «барлык милләтләр тәңгәл хокуклы, бертигез» дип көн саен тәкрарланып торган дәвердә милли уку йортларын бөтенләйгә ябу карары чыкмасынмы? «Милли республикалар биләмәсенә кермәгән очракта милли мәктәпләр язмышын ата-аналар хәл итә» дигәнрәк җөмләләр язылган ул карарның чыгуына «сөеклебез, совет чоры демократиясенә юл ачкан Никита Сергеевич иптәш» рөхсәт биргән иде. Һәм ул карарның караламасын башта СССР Югары Советының Милләтләр советы утырышында тикшерәләр. Ул утырышларда татар, башкорт, чуваш, мари, мордва һәм Төньяк Кавказ төбәге республикаларының берничә йөз депутаты да катнаша. Әмма ул сессия утырышлары барышын тасвирлап, «Известия» газетасында басылган хәбәрләрдә әлеге милләт вәкилләре депутатларының ул мәсьәләгә кагылышлы чыгышларын күрмәдем. Дөресрәге, «Шулай эшләсәк, озакламыйча милли мәктәпләр бетәчәк бит» диелгән язманы очратмадым. Дөрес, ул газетаның 1957–1958 елның март – апрель айларына кагылышлы бәйләмнәрен миңа ул вакытта ашыга-ашыга гына карап чыгарга туры килгән иде. Россия Дәүләт архивына без ул вакытта Башкортстан язучысы Морат ага Рәхимкулов белән бардык. Аның эше тиз төгәлләнде дә, «кабат килербез әле» дип, без Переделкино Иҗат йортына кайтып киттек. Ә янәдән ул архивка барылмады. Быел исә үзебезнең милли китапханәнең элекке чор газеталары сакланган бүлегенә әлегә алганым юк әле. Аңлатуларынча, вакытлы матбугат архивы элекке бинада калган, ул бүлек өчен җаваплы кешеләр әлегә яңа бинага күченү мәшәкатьләре белән йөри икән.

Әйе, берничә ел элек мин «Известия» газетасының СССР Югары Советы сессияләренә багышлы саннарын ашыгыбрак кына

караштыргалап чыккан идем. Сессия барышында әрмәнчә чыгыш ясаучының – әрмән телендә, төрекмән вәкиленең – төрекмән телендә һәм башка Союздаш республика депутатларының шулай ук үз телләрендә, үз язма шрифтлары белән газета битләрендә теркәлгән чыгышлары белән танышкан идем. Әлбәттә, автономия республикалары вәкилләренә андый ук иреклек бирелмәгән, шул чуар текстлар арасында ара-тирә генә аларның русча язмалы текстлары да очрашкалады. Ләкин мин ул көнне бер генә татар депутатының да чыгышын очрата алмаган идем. Ул чордагы зур мәмләкәтнең шундый зур җыенында аларга бик сирәк сүз бирелгәндер шул инде. (Хәер, хәзерге Югары Совет утырышларында да без үз депутатларыбызның чыгышларын телевизор экраннарыннан әллә нигә бер генә ишетәбез, күрәбез бугай.)

Ә Н. С. Хрущёв заманында кабул ителгән, эчтәлегенә карaганда, бик йомшак язылган, милли мәктәпләрнең яшәү-яшәмәвен ата-аналар хәл итә дигән карарның нәтиҗәсе Татарстаннан читтә яшәүчеләр өчен коточкыч булды. Шуннан соң дүрт-биш ел да үтмәстән, күпчелек татар авылларындагы мәктәпләрдә татар телендә укытулар бетерелде, югары уку йортларында милли телдә укытучы әзерләүче бүлекләр ябылды.

Әйе, узган гасырның ул еллардагы дәүләт башлыкларының шушы талпынышы нәтиҗәсе бик аяныч булды. Шул чорда чыккан «Известия» тупламалары битләрендә мин шул канунны кабул итү утырышларында катнашкан ни татар, ни чуваш яки мари халкы вәкиленең милли телләрне укытуны тыюга корылган ул карарга карата тискәре фикер белдерүен очратмадым. Безнең республикадан ул сессиядә катнашучыларның тулы исемлеген әйтә алмыйм. Әмма берничә «җитәкче» депутатның исем-фамилиясен хәзерге чор документларыннан карап әйтергә була, әлбәттә. Әмма инде аларны хәзер искә алу да кирәкмәстер. Чоры, заманы шундый булган. Депутатларның да туксан процентка якыны ул чорда гади колхозчы, гади эшче вәкилләре иде ич.

Һәм әлеге карарда теркәлгән «ата-аналар хәл итә» дигән сүзләрнең буш сүз генә булуын тиздән күпләребез аңлады булса кирәк. Чөнки милли автономияләрдән читтә урнашкан уку йортларын беркем белән дә киңәшмичә, ата-аналар фикере белән санашмыйча, бер-бер артлы ябарга керештеләр. Үзем үскән авылга күрше булган Яңавыл халкы (Оренбург өлкәсе), берничә мәртәбә «баш калкытып», үз мәктәпләрен сакларга тырышып карады. Бер-ике мәртәбә үз дигәннәренә дә ирешкәннәр иде. Ләкин барыбер милли татар мәктәбен саклап кала алмадылар. Ә бит ул мәктәп әдәбиятчы һәм тарихчы Габделбарый Баттал туган авыл мәктәбе дә иде.

Еш кына безнең матбугатта «милли мәктәпләрне Сталин яптырды» дип язалар. Иосиф Виссарионовичның безнең милләт алдында гаепләре зурдыр – бик, бик күп кадерле шәхесләребез «Сталин лагерьлары» дип аталган зинданнарда юкка чыкты.

Әмма ләкин аның милли мәктәпләрне ябу яки алар эшчәнлеген чикләү кирәклеге турындагы фәрман биргәнлеген белмим. Аның заманында РСФСРның барлык өлкәләрендә милли мәктәпләр эшләде, ябылмадылар. РСФСР биләмәсендәге югары һәм урта белем бирүче уку йортларында милли мәгариф кадрларын укыту дәвам итте. Казанда белем үзләштергән укытучыларны да илнең төрле өлкәләренә билгеләү тәртибе бар иде. Мәсәлән, Төмән, Томск югары уку йортларының милли кадрларны әзерләү факультетларында укытырга җибәрелгән берничә кешене беләм. Булачак әдәбият галимнәре һәм язучылар Фәрит Хатипов белән Азат Әхмәдуллин илленче еллар урталарында Төмән өлкәсенең Тобол педагогия институтына укытырга билгеләнәләр. 1959 елда, әлеге карар кабул ителгәннән соң бер ел үтәр-үтмәстән, ул институтның татар укытучыларын әзерләүче бүлеге ябыла. Минем чордашларым һәм иптәшләремнән байтак кеше, шул исәптән өч кыз туганым да 1940–1950 елларда татар уку йортларында укып укытучы булдылар. Ул вакытта Ульяновск, Самара, Оренбург һәм Орск шәһәрләрендә урнашкан педагогия институтларында татар бүлекләре уңышлы эшләде. Шул ук өлкәләрдә биш-алты татар педагогия училищелары эшләп килде. РСФСРның башка өлкәләрендә дә шул ук хәл иде. Болар барысы да 1960 еллар башында, Н. С. Хрущёв чоры түрәләре рөхсәт биргән әлеге карар чыккач ябылдылар (яңа фәрман газеталарда басылуга ике-өч ел үтмәстән). Урыннарда милли мәктәпләр ябылгач, милли кадрларның да кирәге калмаган иде. Ә милли мәктәп эшләми икән, андый авылның милли йөзе дә нык үзгәрә. Ә бер-ике дистә елдан соң ул авыл да, Фәүзия Бәйрәмова мәкаләсендә тасвирланган Сыркыды кебек, безнең өчен чит-ят бер торакка әвереләчәк, билгеле. Шул ук Никита Сергеевич идарә иткән елларда автономияле республикаларда чыгучы милли матбугатны бетерергә дә тырышып карадылар. Алар урынына, мәсәлән, рус телендә чыгучы газеталарда атнага бер-ике мәртәбә татарча яки башкортча «әдәби-мәдәни кушымталар» бирү тәкъдим ителгән иде. Башкортстанда моңа кискен рәвештә каршылык белдерелгәннән соң гына андый карар өстәл тартмасына ераккарак тыгып куелды шикелле. Аны кемнеңдер кайчандыр кабат «өстерәп» чыгарачагына шикләнмәскә мөмкин…

Әйе, «ярларыбыз һаман саен ишелә тора, җир-биләмәләребез көннән-көн кими бара…» Без шул әле андый хәлләрне булдырмас дәрәҗәгә ирешә алганыбыз юк сыман… Киләчәктә мондый хәлләргә юлыкмас өчен яшь буынны мөмкин булган кадәр югары белемле итәргә кирәк. Шул вакытта инде алар, милләткә кагылышлы вакыйгалар туганда, илленче еллардагы депутатлар кебек баш иеп утырмаслар, үз фикерләрен дәлилләп әйтә алырлар…

*1996*

## «КУБРАТ ХАН» БОЛГАРСТАНДА

Соңгы елларда татар әдәбияты үрнәкләре Рәсәйдән читтәге илләрдә дә тәрҗемә ителеп чыга башлады. Аеруча Төркия белән дустанә мөнәсәбәтләр җайга салынуга күңел сөенә. Бер гасыр чамасы ул олуг мәмләкәтнең әдәбият вәкилләре белән аралашмыйча яшәгән идек бит. Ә узган гасыр башында, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Дәрдемәнд, Габдулла Тукайлар чорында, андый багланышлар җайга салынган була. Мәсәлән, Г. Тукай иҗатын бәяләүгә багышлы иң тәүге җитди хезмәт тә шунда дөнья күрә дия алабыз. Төркия галиме профессор Фуад Көпрүлүнең «Габдулла Тукаев» мәкаләсе милләттәшебез Йосыф Акчура мөхәррирлегендәге «Төрек йорты» журналында басылып чыга.

Ә менә ерак чорда яшәгән бабаларыбыз белән бер кавемнән булган Дунай буе Болгар дәүләте вәкилләре белән арабыз күптән өзелгән иде. Моның сәбәбе инде, әлбәттә, динебез вә телебезнең үзгә булуына бәйледер. Минем хәтерләвемчә, без гомер иткән дәвердә ул илгә беренче сукмакны салучы күренекле тарихчы галимебез Альфред Халиков булды. Ә икенче мосафирыбыз, ул илгә икенче буларак юл ачучыбыз дип чордашым вә каләмдәшем Мөсәгыйт Хәбибуллинны атыйсым килә. Гәрчә ул вазифаны үтәүче үзе булмаса да. Әйе, ул «сәяхәт»не аның атаклы романы «Кубрат хан» башкара. Язучының варислары булган кызлары хәбәр итүенчә, бу романның икетомлык итеп ул илдә 2017 елда нәшер ителәсен урын өстендә ятып авырган автор үзе дә, кызлары да белмичәрәк калганнар диярлек. Ул романны бездә чыгарсак килешерсезме дигәнрәк сөйләшү байтак еллар элек, Мәскәүдә уздырылган бер киңәшмәдә Мөсәгыйт белән очрашу вакытында булган икән. Һәм, әлбәттә инде, бу романны ике калын китап рәвешенә китереп чыгару өчен байтак вакыт сарыф ителгән. Шунысы сөендерә: бу томнар бик зәвыклы итеп эшләнгән, Кубрат хан яшәгән чорга ятышлы рәсемнәр белән дә баетылган. Һәм үз вакытында бу томнар автор гаиләсенә дә тапшырыла. Һәм 2019 елның гыйнвар башында мәңгелек йортына күчкән Мөсәгыйт дустыбыз еш кына ул томнарны кулына алып, сөенеп-елмаеп коляскада утыра торган булган.

Мөсәгыйт каләмдәшебезнең бу романы үзебездә 1985 елда басылып чыккан иде. Шуннан берничә ел элгәре аның үз машинасында Кубрат хан аяк баскан Төньяк Кавказда, Азов, Кара диңгезләрнең төньяк тарафларында бер ай чамасы йөреп кайтканлыгын хәтерлим. Шул тарафлардагы музейларда ни-нәрсәләр күрүен, ни-нәрсәләрне фотога төшерә алганлыгын да ул безгә бик тәфсилләп сөйләгән иде. Шуннан алда да, шуннан соң да Казан, Мәскәү китапханәләрендә тапкан табышларын да ара-тирә искә алгалар иде. Һәм шушы эзләнүләр нәтиҗәсе буларак 1985 елда аның унбиш мең данәдә әлеге романы басылып чыкты. Борынгы тарих белән мавыгучылар өчен ул роман зур табыш булды.

Күренекле галимнәребездән Мирфатыйх ага Зәкиев белән Әбрар ага Кәримуллин, бу әсәрнең нәшер ителүен хуплап, күләмле генә мәкаләләр яздылар. 1990 елларда беренче президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев инициативасы белән Казанда Кубрат хан каберлегеннән табылган бай тарихи хәзинә белән танышу мөмкинлеге дә тудырылган иде. Петербургтагы Эрмитаж музеенда сакланган бу затлы экспозицияне башка төбәкләргә бик сирәк очракта гына җибәрәләр. Бу очракта инде Идел буе Болгар ханлыгының Кубрат хан җитәкләгән Бөек Болгар мәмләкәтенең бер өлеше булганлыгы да истә тотылгандыр.

Шушы романы басылып чыккач та Мөсәгыйтнең үзебезнең Идел буе Болгар ханлыгы чорына багышлы күләмле әсәр язарга керешкәнлеген хәтерлим. 1990 еллар башында тәмамланган бу тарихи романын ул баштарак шул чорның бер тарихи шәхесе исеме белән атамакчы иде. Аннары инде, кабатлау булыр дип, «Шайтан каласы» вариантын сайлады. 1993 елда дөнья күргән ул әсәрнең редакторы мин булдым. Шуннан соң ул «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романын язарга керешге. Шул ук туксанынчы еллар башында «Кубрат хан» романы русчага тәрҗемәдә Мәскәүдәге «Современник» нәшриятында алты йөз битле бик калын китап рәвешендә басылып чыга.

Безнең тарихи әдәбиятта Кубрат хан җитәкләгән Бөек Болгар дәүләтенең башкаласы Төньяк Кавказның Азов (төркичә Азак) диңгезе тарафындарак урнашкан, бик зур булмаган Фанагория каласы диелә. Мөсәгыйт шул чорга караган Византия тарихчылары хезмәтләре белән дә бераз танышкан кеше буларак, соңрак ул дәүләтнең икенче тәхет каласы да барлыкка килә, дияр иде. Ул чорда тәхет биләүченең аерым билгесе озын саплы балта (русча секира) булганлыктан, икенче тәхет тоткан каласы да Балтава дип йөртелгән. Һәм ул урында хәзерге Полтава шәһәре урнашкан дигән иде. Әлбәттә инде, бу икенче башкала дәүләт биләмәләре көнбатыш тарафка таба икеләтә зурайтылганнан соң барлыкка килгәндер. Бөек Болгар дәүләтенең атаклы юлбашчысы Кубрат хан да шул Балтавадан ерак булмаган бер урында җирләнә. Һәм хәзер Петербургтагы Эрмитаж музеенда сакланган «Кубрат хан хәзинәсе»н археологлар 1913 елда хәзерге Полтава өлкәсендәге курган-каберлегеннән табып алалар да.

2001 елда М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романы Казанда икенче мәртәбә нәшер ителде. Шул чорга бәйле рәвештә аның тиражы да бер мең данә генә иде. Алдан килешкән булсак та, ул китапны чыгарышуда катнаша алмадым. Чөнки ул китап башка нәшриятта — «Мәгариф»тә басылып чыкты.

«Кубрат хан» романының Дунай буе Болгария дәүләтендә нәшер ителгән икетомлыгына яңадан әйләнеп кайтыйк. Ул китапларның беренче томы дәүләт башкаласы Фанагория каласында булган вакыйгаларны чагылдырадыр, дип уйлыйм. Чөнки китап тышлыгында, «Кубрат хан» сүзе астында ук бу шәһәр исеме дә

китерелә (Велечието на Фанагория. Т. 1). Алтмышынчы елларда, иң күренекле тарихчыбыз Альфред Халиков китаплары белән танышканнан соң, мин бер ел дәвамында Болгариядә нәшер ителгән «Болгарский язык» журналын яздырып алган идем. Ул мәҗмуга битләрендәге төрки сүзләргә тартым байтак сүзләрне очрата һәм сөенә идем. Шундый сүзләр күбрәк булган берничә журналны Сарьян остазыма да күрсәткәләгәнем булды. Хәзер исә хәтеремдә бердәнбер болгар сүзе саклана. Болгарларның тәмәкене төтен (тютюн) дип атаганлыклары гына. Шуңа күрә «Кубрат хан» китабы тышындагы «Велечието на Фанагория» җөмләсенең мәгънәсен аңлата алмыйм. Фанагориянең хәзерге Краснодар крае биләмәсенә кергән Таман утравындагы бер шәһәр исеме булганлыгын гына беләм. Кубрат хан дәүләте барлыкка китерелгәнче, бу шәһәрнең Митридат атлы шәхес (русча язмаларда аны царь да, кенәз дә дип язалар) идарә иткән илдәүләт башкаласы булганлыгы әйтелә. Шул ук Митридатның икенче бер идарә итү урыны Кырым ярымутравындагы Керчь тирәләре булган дип тә язалар. Һәм хәзер дә Кырымның әлеге шәһәре янәшәсендә Митридат исемен йөртүче бер тау саклана. Безнең илдә чыккан китапларда Митридатны «тумыштан грек булган бугай» дигән язмалар күренгәләсә дә, ул гомере буе Византия дәүләте белән сугышып яшәгән. Грекларга шактый зыян салган шәхес. Шул ук вакытта аның үзен Иран (русча язмада Персия) ил-дәүләте башлыклары Кир белән Дарий токымыннан чыкканлыгын дәлилләргә тырышкан, дип тә язалар. Ә Кубрат хан, имештер, Митридатны үзенә үрнәк итәргә тырышкан. Иран шаһларының кайберләренең төрки токымнан булганлыклары да ара-тирә күзгә чалынып китә. Бәлки, чынлап та, Кир, Дарий, Митридат, Кубратларны ниндидер бер кабилә тармагы җепселе бергә тоташтырган булгандыр. Төркиләрнең еракта калган ватаны Алтай тау тезмәләре генә булмыйча, Кече Азиянең бер өлеше икәнлеге дә кайбер хәзерге заман галимнәре тарафыннан дәлилләнә башлады бит.

Китапның икенче томы тышлыгында «Кубрат хан» язмасы астында «войната с хазарите» сүзләре китерелә. Димәк, бу томда Бөек Болгар дәүләтенең хәзәрләр белән көч сынашу һәм яулап алыну вакыйгалары чоры чагылдырылган. Бу томның 284–290 нчы битләрендә романда кулланылган кайбер татарча сүзләрнең болгарчага тәрҗемә-аңлатмалары китерелгән. Әлеге томнарны тәрҗемә итүче автор белән таныштыру вазифасын да китапта теркәлгәнчә язу белән чикләнәм: «Перевод – Гергана Стойчева-Нуша». Безнең нәшриятлар тәртибе таләп иткәнчә, китапка ничә табак әсәр кергәнлеге һәм сатуга чыккан данәсе дә (тиражы) күрсәтелә. Бу очракта мин андый мәгълүматны тапмадым.

Мәрхүм каләмдәшебезнең урыны җәннәттә булсын дигән теләктә калам!

Киләчәктә дә безнең яшьрәк буын галимнәребез белән язучыларыбызга Альфред Халиков белән Мөсәгыйт Хәбибуллиннар салган сукмакны киңәйтү, зурайту мөмкинлекләре тудырылсын иде дигән теләктә калам. Берничә ел элек кенә бер әрмән зыялысы Болгарстанга барып, сезнең ерак бабаларыгызның бер өлеше безнең динне кабул иткән булганнар бит дип һәйкәлләр корып, музейлар оештырып йөрде. Безгә дә, бәлки, Дунай буена килгәнче бабаларыгызның күпчелеге мөселман иде дип, мөселманлык билгесе булган ярымай сурәтен төшереп, Кубрат ханга бер һәйкәл куеп кайту зыян итмәс иде. Бу вакыйга бары тик кардәшлеген җуя барган ике дәүләтне берләштерүгә бер этәргеч кенә булыр иде. Хәзерге Болгар Республикасы вәкилләренең дә безнең республика белән арадашлык элемтәсе урнаштырырга теләүләре турында матбугатта хәбәрләр булды бит инде. Кубрат ханның Идел буе Болгар дәүләтен оештыручы варисы Котраг ханга багышлап алар инде һәйкәл дә әзерләгәннәр. Шуны Идел буе ярына китереп утыртасылары да килә икән. Әмма әлегә безнең Тәтеш районы җитәкчеләре ул тәкъдимне нишләптер кабул итмәгәннәр. «Мәскәү рөхсәт итмәс» дип икеләнүләредер инде. Ә бит Мәскәү дә Болгария белән элеккечә дус булуны тели шикелле…

Соңгы зур сугыш чорында Кырым ярымутравы бик хәтәр хәлдә калгач, югарырак дәрәҗәле командирларга аннан китәргә рөхсәт бирелә. Ярым камалышта калган берничә дивизияне берләштергән гаскәр белән җитәкчелек итү генерал-майор Пётр Новиковка йөкләнә. Чистай төбәгеннән чыккан икенче керәшен татарына. Беренчесе Питрәч ягы тумасы Пётр Гаврилов ич. Брест крепостен бер ай чамасы дошманга бирмәскә тырышып сугышкан керәшен иде. Ә хәзерге кайбер тарихчылар болгар-татарларның бер өлешенең Кубрат хан заманында ук керәшенгә әверелә башлаганлыгын искә алалар ич.

Менә шул керәшен П. Новиковның сугышка чаклы берникадәр вакыт Болгариядә хезмәт итү чорына багышлы бер истәлек язмасы кайчандыр күзгә чалынган иде. Ул Испания азатлыгы өчен сугышып йөргән оста хәрби генә түгел, гармунда оста уйнаучы да булган икән. Һәм Испаниядән Болгария тарафына хәл алырга җибәрелгәч, ул гармунда татар көйләрен уйнап, болгар кешеләрен бик тә сөендергән, дип яздылар. Менә шушы очрак та бүгенге болгар халкы белән үзебезнең татарның бер-берсен үз, якын иткәнлеген дәлилли.

*2019*

# «АРКАИМ»ГА СӘЯХӘТ

Бабалар кабере янында күңел зар,
Аталар рухының армандасы бар…

*Дәрдемәнд*

Көньяк Урал төбәге борын-борын заманнардан бирле төрки халыкларның яшәү урыны буларак фәнни хезмәтләрдә теркәлгән. Тарихи язма әдәбият та, археологик эзләнүләр нәтиҗәсе дә бу фактны раслый. Мәсәлән, СССР Фәннәр академиясенең Археология институты галиме, тарих фәннәре докторы К. Ф. Смирнов җитәкчелегендәге археологлар 1950 елларда Орск-Чиләбе шәһәрләре аралыгында скиф һәм сарматлар тарихын барлауга багышлы бик җентекле тикшеренү эшләрен башкаралар. Шул тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, соңрак бу галимнең скифларга багышланган җитди китабы да басылып чыга.

Шул ук 1950 елларның икенче яртысыннан башлап Оренбург педагогия институты галиме, тарихчы һәм археолог С. А. Попов җитәкчелегендәге археологлар да Оренбург һәм аңа чиктәш өлкәләрнең төрле төбәкләрендә казынып, байтак кына тарихи табышка ия булалар. Соңыннан аларның кайбер табышлары Нью-Йорк, Мәскәү, Петербург һәм башка музейларга да алыначак. Сергей Александрович Попов исә күпчелек тарихчылар тарафыннан хуплап кабул ителгән «Тайны Пятимаров» (Җир асты серләре, 1982, Чиләбе) китабын нәшер итәчәк. Һәм ул китапта шушы төбәктә гомер иткән шул ук скиф, сармат һәм башка төрки халыклар тормышын чагылдырган тарихи табышлар турында хәбәрләр, табылдыклар теркәлгән. Шул тарафтагы курган-каберлекләр куеныннан табылган бакыр эретмәләре калдыкларына нигезләнеп, монда аны кою һөнәре бик борынгы чорда ук үзләштерелгән булган, дип яза автор. Урал-тауның көньяк тарафлары хәзер дә алтын белән бакыр чыганакларына бик бай. Алтыннан бик затлы һәм кыйммәтле бизәнү әйберләре ясаган скиф осталары да Алтай таулары алтыннарыннан тыш, Урал байлыгыннан да файдаланганнардыр, мөгаен. Җир куенындагы бакыр ятмаларын куллану өчен кайчандыр казылган тирән-тирән чокырлар хәзер дә Урал-тау җирлегендә очрап тора. Җир эшкәртүгә дә мондагы кешеләр күптән керешкән булырга тиеш. Бик борынгы чүлмәк төпләрендә сакланган иген бөртекләре (башлыча тары ярмасы) шул фикерне дәлилли, ди автор. Скифлар да, сарматлар да ат өстеннән төшмәгән диярлек. Яу-сугыш барышында да алар, чабып барган ат өстендә килеш уктан бер-бер артлы атып, дошман көчләрен юк итә алган. Археологларга башка казылмаларда да агачтан ясалган зур тәгәрмәч калдыклары очраган. «Димәк, җирле халык элек-электән ат һәм үгез дә җиккән», – дип яза А. С. Попов. Борынгы дәвердә монда яшәүчеләр башлыча скифларның бер кавеме – сар-

матлар була. Алар төркеменә болгар һәм кыпчаклар да кергән. Соңрак аларга башка төрки кабиләләр дә килеп кушылган, ди автор. Элекке заман тарихчылары да идарәче скиф кабиләләренең төрки булу ихтималы турында күп яздылар. Грек Геродот, Курций Руф, XVIII йөз рус галиме Андрей Лызлов хезмәтләрендә скифларга нисбәтле кайбер сүзләр, исемнәр дә китерелә. Әйтик, кабилә башлыгының русча язылышта «атей» дип теркәлүе һ. б.

1980 еллар урталарыннан башлап Урал-тауның Оренбург өлкәсе чикләрендәге борынгы курганнарда Башкортстан галимнәре дә казу эшләрен башкарды. Һәм аларның затлы-затлы табышларга тап булуы хакында үзәк матбугатта да язып чыктылар. Мин ул елларда «Известия» белән «Комсомольская правда» газеталарын даими рәвештә укый идем.

Дәрдемәндкә багышлы альбом чыгарырга әзерләнү чорында, 1993–1994 елларда, фотограф Зөфәр Бәширов белән безгә дә Көньяк Уралның күп кенә урыннарында булырга туры килде. 1994 елның август башында без Башкортстанның Оренбург һәм Чиләбе өлкәләре белән чиктәш Баймак шәһәрендә идек. Баймак районына кергән Юлык авылына бөек шагыйребезнең ата-анасы аңа өч яшь тулган көздә килеп урнаша. Дәрдемәнднең яшүсмер чоры шушында узган. Мәдрәсәнең өлкән сыйныфларында укыганда, кыш айларында гына моннан йөз кырык чакрымдагы Орск шәһәрендә яшәгән. Ә җәй айларын алар аталары Мөхәммәдсадыйк хаҗиның шушы Баймак белән Орск шәһәрләре тирәләрендәге прииска бистәләрендә уздырганнар. Без аларның кайберләрендә булдык. Инде алтын чыганагына иң бай өч прииска урнашкан Балкан авылына гына барасыбыз калган иде. Ул авыл исә Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск шәһәреннән көньяктарак, Казахстанның Кустанай өлкәсе чигенә табарак урнашкан. Шунда ничек бару турында киңәшер өчен мин район башлыгы урынбасары, милләттәшебез Шәүкәт Гали улы Тутаев янына киттем. Баймакка килгәч тә бер очрашкан идек инде без. «Бик вакытлы килдең. Берсекөнгә мин ул якка Уфадан килгән ике артистны җибәрергә тиешмен. Икәү генә булгач, сез дә ул машинага сыярсыз», – дип ышандырды ул. Дөрес, әлеге артистлар Балкан белән Баймак арасындагы Аркаим дигән җиргә генә барасылар икән. «Аннан тимер юл станциясенә ерак түгел. Машина сезне шунда илтеп куяр. Магнитогорскига шуннан китәрсез», – дип тә өстәде Шәүкәт иптәш.

Урал-тау сыртындагы Александровка авылы янәшәсендәге «Аркаим» дигән урында бик җитди археологик эзләнү-тикшеренү барганы турында үзәк матбугатта берничә язма урнаштырылган иде инде. Мин аларны укыган идем.

– Алайса, без дә ул атаклы урынны күреп, танышып китә алырбызмы соң? Машина шунда безне көтәрме? – дип сорарга мәҗбүр булдым.

– Көтәр, әйтермен мин шофёрга, – диде җитәкче абзабыз.

Һәм 1994 елның 9 август иртәсендә без шушы сәяхәткә чыгып киттек. «Аркаим» буларак илгә танылган бу урында археологик эзләнү-барлау эшләрен Чиләбе шәһәре университеты галимнәре башлап җибәргән. Соңрак аларга ярдәмгә үзәктән дә берничә абруйлы галим килә. Монда казу эшләрен башлап җибәрүче тарихчы галим Геннадий Борис улы Зданович була. Без ул җиргә сәяхәт кылган җәйдә инде аның шушы вакыйгаларга багышланган китабы да басылып чыккан иде. (Соңрак тагын берничә автор «бу шәһәрчекне төзүчеләр, мөгаен, безнең ерак бабаларыбыз булгандыр» дип язып чыкты.)

9 август көнендә без аның белән очраша алмадык. Ул шәһәрдә әле, диделәр. Ә күрше республикадан килгән кунакларны аның ярдәмчеләреннән берсе Дмитрий Александрович Мальцев кабул итте. Ул галимнәрнең бу тарихи курган белән кайчаннан кызыксына башлаулары турында сөйләде. «Бу кечкенә шәһәрчекне барлыкка китерүчеләр скиф-сарматларга чаклы яшәгән халык булырга тиеш. Бу бик үзенчәлекле шәһәрчек урыны. Аңа хәзер өч мең җиде йөз ел чамасы дип фаразлана. Археологлар моңа чаклы СССР җирлегендә шундый унөч урынны тикшерделәр инде. Алар, бер тезмә булып, моннан дүрт йөз чакрымгача – Сырдәрья елгасының урта өлешенәчә тезелешкәннәр. Шушындый ук рәвешле тагын бер шәһәрчек бездән ерак түгел – Кустанай өлкәсенең төньяк өлешендә урнашкан», – диде әңгәмәдәшебез.

Галимнәр әлегәчә мондый утрак-шәһәрчекләрне төзүче-оештыручылар – зороастризм диненә нигез салучы, «Авеста» китабын тудыручы, һинд-европа телендә сөйләшүче кабиләләр булгандыр дип фаразлыйлар. Шул сәяхәттән кайткач та мин Мәскәүнең тагын бер атаклы археологы, академик Сергей Павлович Толстов китапларын актарырга керештем. Аның төп хезмәтләре Урта Азия республикалары биләмәсенә кергән җирләрдә археологик эзләнүләргә бәйле. Ул аеруча Үзбәкстан белән Төрекмәнстан биләмәләренә кергән, элекке Харәзем дәүләте тарихына кагылышлы җирләрдәге борынгы авыл, шәһәр урыннарында зур эшләр башкара. Шул төбәктә яшәүче халыкларның бронза чорыннан бирле җирне эшкәртеп көн күрүен дәлилли. Һәм ул да Амудәрья елгасы буенда Аркаим шәһәрчегенә тартым көнкүреш итүгә исәпләнгән ике шәһәрчек турында бик тәфсилләп яза. Ул бу төбәктә яшәүчеләрнең көнкүрешен тарихи шумерлар көнкүрешен дәвам итүчеләр буларак кабул итә. Кызганыч ки, Сергей Павловичның ул китапларын мин соңрак кемнәргәдер бүләк иткәнмен. Күпчелек галимнәр шумерлардан сакланып калган ташка язулы сүз-җөмләләрнең төрки сөйләмгә тартым булуын таныйлар. Харәзем мәмләкәтендә төп сөйләм теле фарсыча булган диючеләр дә, төркичелекне яклаучылар да бар. Әлбәттә, Россия галимнәренең күпчелеге фарсычылык яклы.

Чирек гасыр элек булган бу сәяхәттән соң вакыт-вакыт күңелдә шундый сорау туа – гомер-гомергә төркиләр белән угро-фин

вәкилләре яшәгән Урал-тауның бер сыртында урнашкан ул Аркаим шәһәрчеге кешеләре кемнәр булды икән соң? Ул сәяхәттән кайтышлый шул хакта без Уфадан килгән оста курайчы артист Ташбулат Дәүләтшин белән дә уйный-шаяра сөйләшеп алган идек. Әмма җавабын таба алмадык.

*2021*

# ӘБҮ-Л-ХӘСӘНӘ ӘЛ-МӘСГУДИ ҺӘМ БОЛГАРЛАР

СССР дигән бик кырыс режимлы чор күптән бетүгә карамастан, халкыбызның борынгырак дәвергә караган тарихын өйрәнгәндә, без һаман әле Рәсәйнең кайбер дәүләт архивларыннан ары китә алмыйча, йомылып яшибез. Безнең язмышларны хәл иткән байтак мәгълүматны киң җәмәгатьчелеккә җиткерә алмыйбыз. Ә Россия галимнәре өчен алар кызыклы түгел. Болгар, хәзәр бабаларыбыз хакында байтак кына хәбәрләр дә булган, шул хакта унынчы гасыр урталарында ук күләмле генә бер хезмәтендә язып калдырган гарәп галиме әл-Мәсгуди әл-Багдадины исә үзебезнең тарих фәнендә бөтенләй дә искә алмыйбыз шикелле. Һәрхәлдә, минем аның табышларына багышлы хезмәтләрне әлегә очратканым булмады. Әйе, ул галим язган хезмәтләрне әлегә без бик-бик сирәк искә алабыз. Искә алганда да фәкать «ул да безнең бабайлар турында ни-нәрсәләрдер язган булган» дигәндәй җөмләдән ары китә алганыбыз юк. Ә Европа галимнәре Әбү-л-Хәсәнә бине әл-Мәсгуди әл-Багдадиның җитди эчтәлекле дистәгә якын китабын унсигезенче гасырдан бирле тәрҗемә итәләр. Аны «Гарәп дөньясы Геродоты» буларак таныйлар. Ул — берничә илдә булган, шунда яшәүче халыклар турында шактый мәгълүматлар тупланган унлап күләмле хезмәт язып калдырган галим.

Әбү-л-Хәсәнә бине әл-Хөсәен әл-Мәсгуди турында Үзбәкстан энциклопедиясендә дә мәгълүмат бар, диючеләр булды. Әмма әлегә ул энциклопедияне табып, карап чыга алганым юк.

Әл-Мәсгуди 896 елда Багдадта туган, 956—957 еллар тирәсендә Мисырда вафат булган. Күләмле җиде тарихи һәм географик эчтәлекле хезмәтләр авторы. Барлык хезмәтләренең исем-атамасын монда теркәп тормыйм инде. Үзебезнең ерак бабаларыбызга кагылышлы бер китабының эчтәлегендә тасвирланган кайбер фактларны гына искә төшереп үтәм.

930 елларда Хәзәр (хәзерге Каспий) диңгезе буйлап Итил шәһәре тарафына сәяхәт иткәннән соң, 943 елда гарәпчә язып тәмамлаган «Муруҗ әл-зәһаб вә мәгадин әл-җаваһир» китабы (русча вариантта «Золотые копи и россыпи самоцветов», татар-

чага күчерсәң, «Алтын һәм асылташ мәгъдәннәрен юу урыннары» буладыр) француз теленә күптән тәрҗемә ителгән бай эчтәлекле хезмәтләрдән санала. Ул китапта Хәзәр каһанлыгына һәм аның халкына багышланган зур бүлек бар дип хәбәр ителә. «Хәзәр каһанлыгында берничә төрки кабилә яши. Ил-каһанлык белән идарә итүче ике зур кабилә – хәзәрләр белән болгарлар була», – дип язган ул. Шул ук китапта Дунай буе болгарларына багышлы мәгълүмат та бар икән. Хәзәр-ашин иленең ашина ыругыннан каһан (хәзергечә әйтсәк – президент) билгеләнсә, көч-куәте буенча икенче дәрәҗәдә булган болгарлардан шад (хөкүмәт башлыгы) сайланган. Шадка барлык ыруглар белән идарә итү, гаскәр туплау бурычы тәгаенләнгән, дип язган әл-Мәсгуди «Алтын һәм асылташ мәгъдәннәрен юу урыннары» дип исем кушылган әлеге китабында. Әйе, бу хезмәтен ул Хәзәр диңгезенең яр буйларында урнашкан шәһәрләр, илләр белән танышып кайту сәяхәтеннән соң – 943 елда тәмамлаган. Шушы хәбәрләре өчен генә булса да безгә күптән инде бу галимнең әлеге хезмәтен табып бастыру кирәк булгандыр.

Шәрык илләрендә ул дәвердә бу диңгезнең шулай аталуы да безнең өчен кызыклы. Хәзерге тарихчыларыбыз Хәзәр каһанлыгын ул диңгезнең төньяк өлешен генә биләгән дип яза. Ул дәүләт биләмәсе дип сызылган карталар да хәзерге Әстерхан өлкәсе чикләреннән узмый диярлек. Әгәр ул дәүләтнең биләмәсе безнең карталарда күрсәтелгән мәйданны гына биләгән булса, шәрык илләре галимнәре тагын шундый ике-өч дәүләтне үз кочагына сыендырырдай яр буйлары булган диңгезне Хәзәр диңгезе дип атарлар идеме икән? Бәлки, кайбер Азәрбайҗан галимнәренең «без дә Хәзәрстанга кергәнбез» дип әйтүләре дөрестер? Мөгаен, шул диңгезнең көнчыгыш яр буйларын биләгән башка төрки ыруг-кабиләләр дә әлеге хезмәт язылган чорда Хәзәрстанга буйсынган булгандыр. Югыйсә Идел тамагының уң вә сул яр буйларын һәм төньяк Кавказның Азов күле тирәләренәчә җир биләгән бер кечкенә дәүләт исемен шундый зур мәйдан тоткан диңгезгә бирмәсләр иде.

Хәзәр каһанлыгында болгарларның төп биләмәсе дип Идел белән Дон аралыгы һәм берникадәр төньяк Кавказ алды җирләре күрсәтелә. Ул чорда Кавказ җирләренең күпчелек өлеше Византия мәмләкәте карамагында була. Шулай якын күрше булу сәбәпледер инде, Бөек Болгар илен оештырачак Кубрат ханның яшьлек чорының бер өлеше шул Византия илендә үткәрелә дә. Атаклы тарихчыбыз Альфред Халиков хәбәр итүенчә, ил-ыру башлыгы булган бер болгар бәгенең кызы Чәчкәнең Византия императорлары гаиләсенә кияүгә бирелүе дә шул заманнарга карый бугай. Ул көч-куәтле күрше мәмләкәт белән башка төрле аралашулар да, кыз бирешеп туганлашу очраклары да, бәлки, бер генә булмагандыр. Ләкин безнең чор тарихчылары Дунай буе болгарлары белән дә төрлечә «аралашкан» элекке ут күршеләре-

без тарихы белән бер дә кызыксынмыйлар шикелле. Бәлки, безнең аралашуларны кемнәрдер өнәп тә бетермидер.

Кубрат хан Византиядә яшәп һәм укып, тәҗрибә туплап кайткач, зур ыруг башлыгы булган. Византия императорларының хуплап торуын да тоептыр, мөгаен, тиз арада болгар ыруына тиешле җир мәйданнарын да арттыра алган. Шул рәвешле Бөек Болгар дәүләте оештырылган. Безнең тарихчылар аның башкаласы Азов диңгезенең көньяк буендагы Фанагор (Фәнәһар) каласы булган дип саный. 1970 елларда бер укымышлы Азәрбайҗан язучысы белән Мәскәү янәшәсендәге Иҗат йортында шул ерак вакыйгаларны да искә алган идек. Ул миңа, көнбатыш тарихчылары язуына нигезләнеп, Фәнәһар Кубратның башлангыч идарә итү чоры башкаласы гына булган. Шуннан соң ул башкаласын хәзерге Полтава шәһәре урынына күчергән. Ул кала Кубрат хан һәм аның варислары дәверендә Балтава – ханның тәхет биләү урыны дигәнне аңлаткан исем йөрткән. Иренмәсәң, кереп эзләп ал, бу Малеевка иҗат йортының бик бай китапханәсендә Византия императорлары һәм тарихчыларының китаплары да бар. Элегрәк елларда мин алардан үзебезнең Азәрбайҗанга кагылышлы өлешләрен укыштыргалаган идем инде, дигән иде яңа танышым. Ул вакытта әлеге олы абзыйның киңәшен тотарга вакытым булмады шул. Әлеге китапханәгә кереп, Византиянең җиденче йөз чорына бәйле китапларын кулыма ала алмадым. Икенче вакытларда килгәндә, ул китапханәнең бай мирасыннан бераз файдаланганым булды. Ләкин нишләптер ул абзый кайчандыр укыган Византия тарихчылары китапларына юлыга алмадым шул. Бәлки, аларны теләсә кем укып маташмасын, башын бутамасын дип, махсус сейфларга салып куйган чаклары булгандыр.

Кубрат ханның җирләнгән урыны да шул икенче башкаласы тирәләрендә була бит инде. 1913 елда археологлар нәкъ шул Полтава өлкәсендә табылган кабереннән бик затлы, алтын-көмештән генә эшләнгән «Кубрат хан хәзинәсе»н казып чыгаралар. Ә 1960–1980 еллар аралыгында шул тирәләрдән бик ерак та булмаган – күрше өлкәләргә кергән берничә курганны ачып, тагын ничәдер ханның каберен тапканнар иде. Шул хакта кыскача белешмәләр «Известия» һәм башка үзәк газеталарда булды.

Византиянең тарихи китаплары белән таныш булган атаклы тарихчыбыз Альфред Халиков берзаман Дунай буе Болгар иленә дә «юл ачкан» иде. Болгарларның шактый актив рәвештә Киев кенәзлеге вакыйгаларында да катнашуын дәлилләрдәй мәгълүматлар туплый-туплый, Идел буе Болгары белән Киев арасындагы «сәүдә юлын» да башлап ул ачкан иде. Киев кенәзлегенең бөек кенәзе Юрий Долгорукийның шул кенәзлек белән аралашып гомер иткән болгар-кыпчак кабиләсе ханы Аепа (Әюб хан) кызына өйләнгәнлеген дә байтагыбыз аның китапларыннан укып, ул

сөйләгәннәрдән ишетеп белде. Долгорукий кенәзнең шул болгар бикәсеннән туган улы Андрей Боголюбскийны хәзерге заман тарихы Бөек Мәскәү кенәзлегенең фундаментын салучылар исемлегендә йөртә. Һәм бу бөек кенәз, Андрейның анасын бик хөрмәт иткәнгәдер инде, шулай ук болгар нәселеннән булган кызга өйләнгәнлеге мәгълүм.

Ләкин Альфред Халиковның татар тарихын шулай киңәйтеп барларга тырышулары кемнәргәдер ошамады бугай. Аның Дунай буе Болгары белән Днепр төбәге кыпчак, болгарлары тарафына салган сукмакларын өзәргә тырышучылар табылды шикелле. Ул үз өстенә алган өстәмә мәшәкатьләрдән читләшергә мәҗбүр ителде сыман. Ул елларда бит татарларга бәйле тарихны Татарстаннан читкә чыгып эзләмичәрәк барлау хуплана иде.

Татар, башкорт һәм гомумән төркиләргә багышлы тарихи документларны Азия һәм Европа илләрендәге архивлардан да барларга тырышкан Зәки Вәлидинең 1961 елгы «Төрек йорто» журналында урнаштырылган бер мәкаләсенә дә тукталып үтәсе килә. Әүвәл аның чит илләрдә булганда тапкан бер-ике табышын да искә төшереп үтик. Большевикларга каршы көрәшкән басмачыларга катнашып йөргәннән соң, ул Иран ягына чыгып китәргә мәҗбүр була. Шундагы архивлардан ул Ибне Фадланның Идел буе Болгарына бару чоры кульъязмасын табып, күчереп ала. Һәм 1930 елларда Вена университетында докторлык диссертациясен яклаганда, шул кульъязмасын да кулланачак. Ә бераздан соң Англиягә баргач, атаклы Оксфорд университеты архивында ул тагын төркиләргә багышлы тарихи язмаларга да юлыга. Һәм шуларга охшаш тарихи табышларына нигезләнеп, ул Төркиягә кайткач бер-бер артлы ике китап нәшер итә: «Гомумтөрки тарихына кереш» (1946) һәм «Бүгенге Төркестан вә аның якын тарихы» (1947). Һәм шуңа охшаш байтак тарихи казанышлары булуга карамастан, Европа галимнәре гомумтөрки халыкларына багышлы энциклопедия төзергә керешкәч, аны ул төркемгә кертмиләр. Бу хәлне ул СССР тарихчылары этлеге нәтиҗәсе диебрәк бәяли. Әлеге эшне башкаручы төркем башлыкларының берсе фәлән француз галиме иде, ул СССР вәкилләре сүзеннән чыкмаска тырышты, ди.

Алда күрсәтелгән журналда басылган «Истанбул университеты алдында торган мәсьәләләр» мәкаләсендә ул булачак тарихчылар алдында торган бурычлар хакында яза. Шуңа ирешү өчен ни-нәрсәләрне белергә кирәклекне аңлата. «Милләтебезнең борынгы заманда һәм Урта гасырларда Азия белән Европа тарихында тоткан халыкара әһәмиятен күптөрле кавемнәр һәм мәдәниятләр тарихы белән бәйле булуы йөзеннән, (үзебезнең) тарихны без бөтен Азия һәм Европа милләтләре тарихы белән берлектә өйрәнергә мәҗбүрбез. Әйе, бер яктан без төркиләр тарихын Европа тарихы белән берлектә өйрәнсәк, икенче яктан гомумтөрки тарихны Көнчыгыш Европадагы Рәсәй, Азиядәге

Кытай, Һиндстан, Иран тарихы белән чагыштырып барларга тиешбез. Борынгы скифлар, көнбатыш тарафтагы һуннар, бәҗәнәк һәм болгарлар, ниһаять, Госман империясе (Төркия) чоры төрекләре тарихын яхшы үзләштерү өчен безгә борынгы грек һәм латин телләрен, көнчыгыш һуннар дәвере һәм Урта Азия төркиләре тарихын барлау өчен кытай, тарихның буддизм дине дәверендәге чорын, шул чорга бәйле археологик табылдыкларлардагы язуны укыр өчен борынгы һинд, иран сөйләмнәрен, Урта гасырлар тормыш-яшәешен аңлар, өйрәнер өчен гарәп, фарсы телләрен яхшы үзләштерергә кирәк булачак», – дип яза Зәки Вәлиди. Ә әлегә безнең күпчелек тарихчыларыбыз рус, татар теленнән кала дөньякүләм таралган инглизчә язуны да сүзлекләр ярдәмендә генә тану хәлендә шул.

Зәки Вәлиди бер кыш Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганнан соң, танылган университеты булган Казан шәһәренә китү турында хыяллана. Үзе тәгаен шул хакта язмаса да, аңарда бу теләк Казан мәдрәсәсен тәмамлагач та чит илләрдә йөреп кайткан, шуннан соң Оренбургта татар-төркиләр тарихына багышлаган ике томлык җитди хезмәтен нәшер иткән Морад Рәмзи белән очрашу-сөйләшүләрдән соң туа бугай. «Морад Рәмзи шуннан алдагы җәйдә генә бездә булды, әлеге тарихи хезмәтен безгә бүләк итте», – дип язган иде бит инде Зәки Вәлиди истәлекләр китабында.

Беркөнне киңәшләшер өчен ул Дәрдемәнд өенә бара. (Дәрдемәнд һәм аның абыйсы Шакир Рәмиев «Хөсәения»нең идарәче байлары төркеменә кергәннәр.) «Закир ага Рәмиев мине җылы кабул итте. Мин аңа укуымны Казанда дәвам итәсем килгәнен сөйләдем, – дип яза З. Вәлиди Төркиядә 1960 елларда чыккан «Истәлекләр» китабында. – Ул минем теләгемне хуплады. Мин аңа үземнең матди хәлемнең бик мактанырлык булмавын хәбәр итмәгән идем. Икенче көнне минем белән «Вакыт» газетасы хезмәткәре Ярулла Вәлиев очрашты. Ул миңа Закир бәй исеменнән илле сум акча тапшырды».

Илле сум акча ул заман өчен Казанга барып тупланыр һәм яши башлар өчен җитәрлек була, әлбәттә. Ул елларда савым сыеры белән йөк аты унбер-унике сумнар торган дип яза белгечләр.

Зәки Вәлиди 1908–1912 елларда Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укый. Һәм шул ук елларда, университетка кереп уку хыялы белән, немец телен үзләштерергә керешә. Университетның кайбер укытучылары белән аралаша. Һәм «Касыймия»не тәмамлаган елында «Төрек вә татар тарихы» китабын бастырып чыгара. Казанда үзләштерелә башлаган чит тел аңа киләчәктә Берлин һәм Вена университетларында укырга һәм укытырга, Европа архивларында сакланган тарихи документлар белән танышырга мөмкинлек бирәчәк.

Татар-төркиләргә кагылышлы бик бай тарихи язмалар әлегәчә дөнья буйлап таралган төрле архивларда яисә аерым кеше кул-

ларында сакланалар. Әйтик, Испаниядә биш-алты гасыр чамасы мөселман дәүләте (Кордова хәлифәте) яшәгән дәвердә генә безнең Идел буе Болгарстаны җиренә, ерак бабаларын искә төшереп, дистәләгән галим килеп киткән. Алар тарафыннан язып калдырылган бер-ике дистә язма китапның исемнәре белән авторларының исем-атамалары аерым хезмәтләрдә телгә алына. Шундый китапларның кайберләре Мисырда һәм Төркиядә саклана дигән мәгълүмат та күренгәләп ала. Һәм шул биш мең чакрым ераклыктан килгән бер галимнең Көнчыгыш Европа һәм Көнбатыш Себер биләмәләрендә яшәүче төрки халыкларга багышлы аерым язма китабы барлыгы турында да хәбәрләр күренгәли. Ул төркемнән әлегә рус теленә тәрҗемә ителеп, 1971 елда Мәскәүдә Фәннәр академиясе нәшриятында чыккан Әбү Хәмид әл-Гарнатиның «Көнчыгыш Европага... сәяхәт» китабын гына аерым атап үтәсе килә. Ул әлеге мөселманнар бик затлы биналар төзеп калдырган, Испаниянең Кордовадан кала икенче туристлык үзәге саналган хәзерге Гранада шәһәреннән, элекке Гарнатай әмирлегеннән чыккан шәхес була. Сәяхәтен ул Дон төбәгендәге Бөек Болгар дәүләте җирләреннән башлый. Анда берничә ел яшәгәннән соң, Идел буе Болгар иле тирәләренә күтәрелә... Башка вакытта шул ук хәлифәттән килгән башка сәяхәтче галимнәрнең дә төп танышу маршруты шулай корылган була. Ул сәяхәтчеләрне безнең төрки дөньяда нәрсә кызыксындырды икән? Шуларны белер өчен генә булса да ул тарихи истәлек язмаларын без өйрәнергә тиешбездер бит?

Әле 2015 елда гына Казанда Морад Рәмзинең оныгы Әшраф Рәмзи булып киткән иде. «Мин дә, әтием дә хәзер Кытайда, Урумчы шәһәрендә яшибез. Әтинең фатирында бабамның бай архивы, китаплары саклана», – дигән иде ул. Совет хакимияте урнашкан елларда илен ташлап чыгып киткән олуг галим Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең яраткан шәкерте болгар, бәҗәнәк, кыпчак бабаларыбыз тарихын барлаудан читләшмәгән булгандыр, мөгаен. Ул 1934 елда вафат була. Ләкин безгә әле аның ул эзләнүләре һәм табышлары билгесез кала. «Чит ил»гә өч көнгә кунакка килгән оныгы Әшрәф Рәмзи дә шул хакта берни дә сөйләмәде. Хәер, төпченеп сорашучы да булмады шикелле. Мин аның телевидениедә, «Татарлар» тапшыруында катнашуын да оештырган идем. Анда да, нигездә, килдем, күрдем турында гына сүз барды.

*2018*

# БОРЫНГЫ ТӨРКИЛӘР ҺӘМ БЕЗ

*(Ерак тарихка бер караш)*

Эскитләр бит төрки...
*Садри Максуди*

Татар матбугаты борынгы төркиләрне искә алган язмалар бирү белән бик мавыкмый. Чөнки ул катлаулы темага алыну теләге белдергән галимнәребез күп түгел. Саф тарих гыйлеме белән шөгыльләнүчеләрдән тарих фәннәре докторы, мәрхүм Әзһәр Мөхәммәдиевне, Фәүзия Бәйрәмованы, күренекле телче һәм тарихчы галим, академик Мирфатыйх Зәкиевне атап үтәргә буладыр, мөгаен. Антик чор төркиләре тарихы белән кызыксынучы язучылардан Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Солтан Шәмси хезмәтләре дә ара-тирә күренгәли. Язучы, Мәскәү университетының Шәрык бүлеген тәмамлаган Шамил Мәхмүдев-Анакның да бу өлкәдә эзләнүләр алып барганлыгын хәтерлим.

Шамил Анакның тарихи карашларына тукталып үтим. 1971 елның көзендә, язучыларның Мәскәү читендәге Иҗат йорты Переделкинода ул мине үз шәриктәшләре һәм фикердәшләре уздырган бер утырышка да алып кергән иде. Анда сүз, нигездә, греклар басып алганчы Балкан ярымутравында төркиләр яшәгәнлеге турында барды. (1950 еллар ахырынача басылган тарихи хезмәтләрдә «варвар греклар»ның Балкан ярымутравын яулап алганлыгы турында яздылар. Шуннан соң чыккан хезмәтләрдә һәм дәреслекләрдә ул җөмлә төшереп калдырыла башлады. Янәсе, греклар гомер бакый шул җәмгыяви яктан алга киткән, элек төрки кабиләләрне дә сыендырган Балкан ярымутравында яшәгән булсын.) Элегрәк Урта Азиядә барлыкка килгән зороастризм дини карашларын да грекларның Балкан төбәгендә яшәгән кавемнәрдән кабул иткән булуы ихтимал, дип сөйләшенде әлеге утырышта. Греклар табынган бөек алла Зевсның да зороастризмчыларның алласы Диюдән үзгәртелгән атама булуы, борынгырак язмаларда аның Диювс рәвешендә теркәлгәнлеге турында да сүз булды анда.

Шул утырышта катнашкан унлап кеше арасында миңа билгеле шәхесләрдән язучы Радий Фиш та бар иде. Ул да шул ук университетның шәрык бүлеген тәмамлаган. Элегрәк тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган бер зур җыелышта да ул катнашкан иде. Шушы вакыйгадан соң Ш. Анакның миңа Урта диңгезнең төньяк-көнчыгыш өлешендә борынгы заманнарда яшәүчеләр турында кызыклы гына материаллар туплый башлавы турында да сөйләгәне булды. Ул чор тарихына багышланган бер җитди хезмәт язарга ниятлим дигән иде. Шул исәптән ул да борынгы Рим каласын нигезләүче этрусклар төркиләр булырга мөмкин

дип фаразлавын да белдергән иде. Хәзер аның ул эзләнүләре нәтиҗәсе булган язмалары, борынгы тарих китапларыннан алынган күчермәләре сакландымы икән – әйтә алмыйм. Соңгы вакытларда ул Казанга килә алмады. Башкортстанның Раевка дип йөртелгән район үзәгендәге фатирында ялгыз яши, ятып авырый, дигән хәбәрләр генә булды. Берничә ел элек аның мәңгелеккә күчүе турында хәбәр иттеләр.

Билгеле инде, безнең аз санлы, матди яктан начар тәэмин ителгән рәсми танылган тарихчы һәм археологларыбызга гомумтөркиләр тарихы белән мавыгырлык вакыт калмый. Алар үзебезнең Болгар һәм Казан ханлыклары, соңгы дистә елларда рөхсәт ителгән күләмдә Алтын Урда дәүләте тарихын барлау белән шөгыльләнәләр. Бу өлкәдә дә әле уңышларыбызның күтелгән дәрәҗәдә түгеллеге турында кайбер галимнәребез хәбәр иткәли. Шушы көннәрдә генә беренче президентыбыз, болгар белән татарлар тарихына үзенең өлешен кертергә керешкән Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә борынгы Болгар шәһәре тирәлегендәге археологик эзләнүләрнең тиешле дәрәҗәдә булмаганлыгы турында сөйләде. Болгарлар чорыннан калган истәлекле урыннар өлешчә генә өйрәнелгән, диде. Ә бит ул заман истәлекләрен кайчандыр СССРның иң абруйлы археологы һәм тарихчысы А. П. Смирнов та өйрәнгән. Күренекле галимебез, академик А. Х. Халиков та шул юнәлештә байтак кына эзләнү эшләрен башкарган иде. Хәтта ки ул болгарлар билгеле бер урын тоткан Киев шәһәре тарафына да эз салырга өлгергән иде. Хәзерге Болгар Республикасы галимнәре белән дә аралашкалады. Вакытсыз вафат булуы аның эзләнүләренә чик куйды. Хәзер исә мөстәкыйль гомер итүче болгарлар тәкъдим иткән, Идел буе Болгарына да бәйләнешле булган бер тарихи шәхескә һәйкәл кую мәсьәләсендә төпле фикер әйтердәй, ерак кардәшләребез тәкъдимен хуплардай галимебез дә калмады бугай.

* * *

Тарихчыларыбыз ачыклавынча, төрле чор-дәверләргә караган үз төбәгебезнең дәүләтләр төзелешендә безнең ерак бабаларыбыз турыдан-туры катнашкан. Әмма бу әмирлекләр-ханлыклар бит әле гомумтөрки дөньясының, төрки мәмләкәтенең бер кисәге, бер почмагы гына. Аларга чаклы Себер тарафында һәм Идел белән Дунай елгасы аралыкларында унлап зур-зур төрки дәүләтләр, төрки телле халыкларны берләштергән зур-зур империяләр яшәп килгән. Кайберләре безнең эрага кадәрле үк тә, яңа эраның мең еллык дәверендә дә Европа белән Азия төбәкләрен берләштереп торганнар. Әйтик, хәзерге Үзбәкстанның көньяк чикләреннән алып Кара диңгез буйларынача җәелгән зур биләмәгә ия Харәзем империясе булган. (Безнең ил тарихчылары ул мәмләкәтне алай бик зурлап күрсәтмәскә тырышалар.) Шәрык галимнәре аны Ту-

ран иле, туранлылар дәүләте дип тә йөрткәннәр. Димәк, ул мәмләкәтнең күпчелек халкы төрки-тураннар булган. Җир эшкәртү, төзелеш, сәүдә һәм фән тармагында зур уңышларга ирешкән ул ил-мәмләкәт мең ел чамасы яшәгән. Унөченче йөз башларында Чыңгыз яугирләре тарафыннан яуланганчы. «Байтак еллар аның башкаласы Амударья тамагындагы Кят шәһәре, соңрак Үргәнеч булган», – дип яза сугыштан соңгы ун ел дәвамында бу дәүләттән калган күпсанлы шәһәр калдыкларын өйрәнүче тарихчы, археолог С. П. Толстов. Харәзем дәүләтен ул антик чорның шумер халкы ирешкән үсешне дәвам иттерүче дип таный. Ә Казан университеты профессоры Әзһәр Мөхәммәдиев шул тураннардан калган борынгы акча, савыт-сабаларда сакланган язуларны өйрәнү белән шөгыльләнде. Ул язуларның күпчелеге төркичә булган дип язды. Казах, үзбәк галимнәре дә, нигездә, шул карашта тора икән. Европаның күпчелек тарихчылары исә 1990 елларга чаклы Харәзем дәүләте тарихын кечерәйтеп күрсәтергә тырыштылар. Ул дәүләтнең идарәче катламы фарсылар булып, дәүләти язмалары да шул телдә булган, дип яздылар. Ә. Мөхәммәдиев тә бер мәкаләсендә: «Антик чор Урта Азия мәдәниятендә бары тик фарсылар тәэсирен генә күзаллыйлар... Әлеге караш, гомумән алганда, пантюркизмнан курыккан рус һәм совет чоры историографиясендә нык тамыр җәйгән. Алар «туран» сүзенең үзеннән үк уттан курыккан кебек куркалар», – дип язган иде. Әлбәттә, бу сүзләр борынгы Туран дәүләтенә карата гына әйтелмәгән. Әйе, кайбер Европа илләрендә Нух пәйгамбәр чорыннан тарихта күпмедер якты эз калдырган төрки кавемнәр тарихын кечерәйтеп күрсәтергә тырышу үзен нык сиздерә.

Әйтик, Харәзем, аның бер өлешендә соңрак барлыкка килгән Хәзәр мәмләкәтләренең халкын шул чорда яшәгән Европа илләре халкыннан түбәнрәк үсеш дәрәҗәсендә булган дип күзаллаучылар да бар. Ягъни алар күчмәләр, күчмә җәмгыятьтә, янәсе, зур җәмгыяви үсеш була алмый. Дөреслектә бөтенләй башкача булса да. Харәземдә атаклы математик һәм астроном әл-Бируни, табиблык гыйлеме белән танылган Әбе-л-Гали Сина (Әбүгалисина), энциклопедик белем иясе буларак танылган Әбүнасыйр әл-Фәраби, Европа белән Азия кыйтгаларында тарихи эз калдырган байтак ил-дәүләтләр картасын, андагы шәһәрләрнең географик торышын шактый төгәл билгеләп кәгазьгә төшергән математик һәм географ Мөхәммәд әл-Харәзмиләр шул бик алга киткән Туран империясе шәхесләре ич. Әл-Бирунинең Галәм җисемнәренә кагылышлы алгебраик казанышларын совет галимнәре дә космик кораблар очышын билгеләгәндә кулланганлыклары хакында яздылар. Хәер, алгебра төшенчәсен дә иң беренче булып шул Бируни, Харәзмиләр кулланышка кертә ич. Җирнең кояш тирәли әйләнүе хакында иң беренче булып фикер әйтүче дә әл-Бируни булганлыгын инкяр итүчеләр юк шикелле. Әмма шул фактны дәреслекләрдә теркәргә дә ашыкмыйлар. Хәер,

хәзерге һәм элеккеге шәрык галимнәре бөек фикер иясе дип таныган үзебезнең Кол Галинең дә күпмедер вакыт шул Харәзем илендә яшәп һәм укып кайтканлыгын искә алыйк. Харәземлеләр җир эшкәртү өлкәсендә дә алга киткән булган. Алардан калган сугару каналлары эзләренә хәзер дә еш юлыгалар, дип яза галимнәр. Әйтик, шул ук археолог һәм тарихчы С. П. Толстов ул борынгы каналларның пәрәвез ятьмәсе эзләрен иң дөрес билгеләүче фотокамералар ярдәмендә самолётларда очып та төшереп алган. Ә шул фактларны күпчелек галимнәребез белми. С. П. Толстов язган фактларны Урта Азия республикаларында чыккан хезмәтләрдә генә очратырга була. Ә безнең кайбер тарихчылар һаман әле аларны «артта калганнар» исәбендә йөртмәкчеләр.

Хәзерге Европа, шул исәптән Россия галимнәре дә грекларның язма истәлекләрендә «скиф» исеме белән кереп калган зур бер ыру-кабиләләр берләшмәсен төркиләр йогынтысыннан читләштерү өчен төрле уйдырмалар язып киләләр. Аларны һинд-европа тел бердәмлеге тарафдарлары дип, күпчелеге фарсы телендә сөйләшүчеләр булган дип белдерүләр еш очрый. Ә археологларның яңадан-яңа ачышлары исә аларның ул дәлилләрен читкә кага бара. Гомер-гомергә төрки-тураннар биләмәсе булган Көньяк Урал, хәзерге Казахстан, Алтай төбәкләрендә соңгы дистә елларда гына табылган казылма байлыкларының да күпчелеге әлеге шул скифлар яисә аларның дәвамчылары булган сарматлар исәбенә туры килә ич. Ничек инде алар бу төбәкләрдән шактый еракта яшәгән фарсылар мирасы була алсын ди? Тел, сөйләм җәһәтеннән фарсылар гаиләсенә кертелгән, төркиләр көн күргән җирләрдән бер читтәрәк гомер кичергән таҗиклар да, Каф таулары артындагы осетиннар да скиф яки сарматлардан калган барлык матди байлыкларга ия була алсын? Борынгы шәрык галимнәре тарафыннан язылган бер генә чыганакта да фарсыларның Олуг Дала төркиләре өстеннән идарә итү факты теркәлмәгән бугай бит. Иран империясе тарихында иң куәтле шаһ саналган Дарийга да скифларның буйсынмавы хакында безнең эрага кадәр яшәгән Геродот язып калдырган ич. Дарий варисларын тар-мар итеп, Иранны да, Һиндстанны да яулаган атаклы яугир Александр Македонский да скифларны җиңә алмаган. Шул хакта аның милләттәше тарихчы Курций Руф яза. Бу автор яугирнең чордашы булган диярлек.

Хәер, кайбер хәзерге заман тарихчылары Иран дәүләтенең гаскәре өлешчә төркиләрдән торган дигән фикердә. Һәм тарихта исемнәре еш аталган өч-дүрт дәүләт башлыгының берсенең төрки булганлыгы турында да хәбәрләр күренә башлады. Шуңа охшаш тагын бер яңалыкны да искә төшереп китәсе килә. Тумышы белән яһүди булган күренекле галим Ю. В. Кнорозов хәзерге Америка җирләренең төп халыклары саналган инк, майя, сиулардан калган борынгы язмаларны укый алуы белән

зур ачыш ясаган иде. Академигыбыз Әбрар ага Каримуллин исә үзара сөйләшкәндә ул кешенең тумыштан караим булуы, күпчелек караимнарның безнең гасыргача төрки телне белгәннәрен исәпкә алып, аның ачышы безнең телгә бәйле дигәнрәк фикердә иде. Һәм Америка индеецлары сүзлегендә безгә таныш сүзләр еш очрый, дип сөйли иде. (Шулай язып та чыкты.) Себер тарихын яхшы өйрәнгән географ һәм тарихчы академик В. А. Обручев әлеге халыкларның тамыры Себердән була, Берингов проливы барлыкка килгәнче алар шуннан Америкага күчкәннәр, дип язды. Күптән түгел генә әле үзәк газеталарның берсендә шушы фикерләрне берләштерердәй бер хәбәргә юлыктым. Америкада яшәүче бер бай монгол, американлылардан археологлар төркемен туплап, үз иленә тарихи тикшерү эшләрен башкарырга җибәргән икән. Һәм болар шактый гына яңа ачышларга тап булган, ди. Шул исәптән көчле радиоаппаратура ярдәмендә Гоби чүле уртасында тарихи пирамидаларга тартым бер зур корылма ятканлыгын да ачыклаганнар икән. Бу табышлар, әгәр чын булса, алда искә алган ике академикның да фикере дөрес булганлыгы ачыкланачак, билгеле.

Тарих фәнендә һун атамасы белән танылган зур бер империянең исә шул ук сарматларны да, безгә якын болгарларны да берләштерүе хакында язма мисаллар очрап тора. Әйтик, XIX йөз ахырларында Европада рус галиме А. Н. Попов тарафыннан табылган «Болгар ханнары исемлеге» язмасында Атилла һәм аның варислары да болгар буларак теркәлгән, дип яза галимнәребез. Күптән түгел Фәүзия Бәйрәмова «Мәдәни җомга» газетасында тасвир иткән Чардын ханлыгы тарихы да Атилла варислары белән бәйле. Урал тавының аргы ягындагы якын Себер һәм бирге ягындагы Кама елгасының урта агымнары аралыгындагы зур бер биләмәне биләгән әлеге ханлык белән Атилланың улы идарә иткәнлеге турында Әзһәр Мөхәммәдиев тә язды.

Бөек болгар кавеменең шул ук скиф, сарматларның дәвамчысы булуын раслаган башка язма истәлекләр дә очрашкалап тора. Әйтик, унынчы гасыр урталарында гарәп галиме Әбү Хәсән әл-Мәсгуди Хәзәр диңгезе буйлап Итил каласы тарафына һәм Кавказ ярлары буйларына сәяхәт кыла. Шул сәяхәтенә багышланган китабында ул Хәзәр мәмләкәтендә яшәүче болгарлар язмышына да тукталган. Аларның бу ил белән идарә итүдә югары дәрәҗәдә булганлыкларын билгеләп үткән, дип язалар аңа багышланган хезмәтләрдә. Болгар кавеме башлыклары каһаннан соң иң дәрәҗәле җитәкче урынны биләгән — шад вазифасын үтәгән. Шадка гаскәр дә, ил белән идарә итүгә кагылышлы башка оешмалар да буйсынган, дип язган. Ягъни, хәзерге заман идарә системасы белән чагыштырганда, каһан хәзерге Германия, Израиль, Англия, Италия илләрендәге кебек «күзәтеп торучы» президент яки король сыйфатында булган, шад исә шул илләрнең министрлар советы рәисенә тиң дәрәҗәгә ия саналган.

Әл-Мәсгуди болгарларның Хәзәр дәүләте таркалгач та Идел белән Дунай елгалары аралыгында төп көч, төп хуҗа булып торуларын хәбәр итә. Әмма хәзерге чор галимнәре Урта гасырлар һәм аннан алдагы чорлар тарихына караган хезмәтләрендә аның унлап китабында китерелгән хәбәрләргә әһәмият бирмәскә тырыша. Ә бездә исә әһәмият иткәндә дә аның славяннарга яки русларга караган хәбәрләрен генә искә алалар шикелле. 1940—1960 елларда нәшер ителгән В. М. Бейлис, И. Ю. Крачковский, А. П. Ковалевский китапларында гына бераз киңрәк мәгълүмат бирелә сыман.

Византия тарихчылары да элекке Бөек Дала тарихында болгарларның зур урын биләвен билгеләп үткән. Кайчандыр күздән кичерелгән тарихи хезмәтләрдә алар, әйтик, Кубрат ханны «скифский царь» дип атый. Хәер, үз галимебез, мәрхүм Җәвад Алмаз да скифлар тарихы белән кызыксынган. Алар чорына караган күпсанлы хезмәтләр белән танышканнан соң, «Патша скифлар төркиләр» дип аталган хезмәтен рус телендә язган иде. Ләкин егерме елга якын туган иленнән читкә тибәрелеп яшәгән бу галим, әлеге хезмәтен бастырып чыгара алмыйча, 1979 елда вафат булды. Алдан сөйләшенгәнчә, Әбрар ага Кәримуллин аннары ул җитди эчтәлекне Казанга кайтарта алды.

Әйе, туксанынчы еллар башында, илдәге үзгәрешләр вакытында, Әбрар Кәримуллинның тырышлыгы белән Җәвад Алмазның кайбер хезмәтләре, шул исәптән әлеге җитди хезмәте Казанга кайтарылган иде. Ләкин әлегә кадәр аны дөньяга чыгаручы юк. Әлбәттә, бу очракта кайберәүләрнең «Җ. Алмаз бик үзсүзле галим булуы сәбәпле Казаннан китәргә мәҗбүр ителде» дип, яки «бүгенге фән өчен скифлар темасы актуаль түгел» дип, автор белән килешмәгәнлекләрен белдереп әллә ниләр язып чыгулары ихтимал. Нурихан Фәттахның «Шәҗәрә» китабы эчтәлеген кабул итмәүчеләр дә, борынгы телләр тарихын барлаучы зур галим Мирфатыйх Зәкиевнең тарих өлкәсендәге эзләнүләреннән йөз чөерергә теләүчеләр дә булды бит инде бездә. Хәер, болгарлар турында сүз чыкканда да бездә аларны Идел-Кама почмагындагы бер кечкенә дәүләт рәвешендә генә күзаллау өстенлек итә шикелле.

Скиф, сармат, һун, болгарларның зур ил-дәүләтләр тотуына кагылышлы фикерләр, мөгаен, Садри Максудиның 1930 елларда язган «Эскитләр» һәм «Урта Азиянең төрки дәүләтләре» хезмәтләрендә дә, Польша галиме, тумышы белән төрки-караим булган Ананиш Зайнчковскийның тарихи китапларында да бардыр. Ләкин безгә әлегә аларның эчтәлеге билгесез. Ул хезмәтләр әле безнең телгә дә, русчага да тәрҗемә ителмәгән. Шулай эшләнәсенә дә өмет итеп булмый. Унҗиденче йөздә яшәгән А. Лызлов дигән бер рус зыялысының 1692 елда язылган «Скифлар тарихы» («Скифская история») китабын да тарих белән кызыксынучыларыбыз бик сирәк кулга ала шикелле.

* * *

Кайбер тарихчы галимнәребез хуплап бетермәячәк шушы язмама тотынуыма этәргеч булган ике сәбәп бар. Беренчесе – әдип һәм рәсми танылган тарихчы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмованың соңгы еллардагы тарихи эзләнүләре. Бигрәк тә аның Себердә яшәгән төрки кабиләләрне киңрәк, тулырак итеп күзалларга ярдәм иткән язмалары булды. Алтай өлкәсе, Хакасия, Тува республикалары галимнәре һәм язучылары алтмышынчы еллардан бирле инде Себер киңлекләрендә төркиләргә кагылышы булган тарихи һәйкәлләрнең юкка чыгарыла барулары турында чаң сугып килделәр. Борынгы төрки язулы ташларның төрле төзелешләр барышында юк ителү очраклары турында бигрәк тә галим Р. Кызласов «Советская тюркология» тупламаларында берничә мәртәбә язып чыкты. Хәтта Кызыл каласындагы музей карамагына кайтарылган кайбер тарихи истәлекле әйберләрнең дә эзсез югалулары турында аның хәбәрләре булгалады. Совет хакимияте дәверендә Днепропетровск шәһәре музее ишегалдында аунап ятучы дистәләгән «кыпчак ташлары» – балбаллар белән дә шундый ук хәлләрнең кабатланып торуы хакында да шул ук журнал битләрендә укырга туры килгәләгән иде. Украинаның Тернополь шәһәре тирәсендә узган гасыр башларында табылган серле төрки язулы биш метрлы балбал турында да шөбһәле хәбәрләр күренгәләде. Хәзер ул таш бармы, ерак бабаларыбызның тагын бер тарихи һәйкәле исәнме икән? Андагы язуны укырга тырышучылар булдымы икән? Ташы сакланса, бәлки, киләчәктә аның язуын укучы табылыр иде.

Фәүзия Бәйрәмова хезмәтләрен даими рәвештә укучысына җиткерә килүче «Мәдәни җомга» газетасы, «Казан утлары» мәҗмугасы мөхәррирләренә рәхмәт. Узган көздә шул ук газетаның берничә санында «Этруск язулары татарча укыла» дигән бик кызыклы язма да басылып чыкты. Язма авторы Нәсим Сәхапов: «Бу эшкә алынырга борынгы тарихка үзенчәрәк караштa торган рус галимнәре Г. Носовский белән А. Фоменконың этрускларга багышланган китабы («Этруски: загадка, которую не хотят разгадать») белән танышу этәрде», – дип белдерә. Бу галимнәр этрускларны славян дип танытырга тырыша, ди. Кемнәр булган соң алар? Чынлап та, безнең эрага кадәр икенче мең ел урталарында зур үсеш кичергән, тугыз меңнән артыграк төрле төрдәге язма (күпчелеге таш язма) истәлекләре калдырган бу халыкның тарихы һаман да әле ачылып бетмәгән. Аларның куәтле һәм яшәеш ягыннан бик алга киткән дәүләте хакында күп кенә галимнәр күп мәртәбәләр язган. Ләкин ул кавемнең нинди телдә сөйләшүен бүгенгә чаклы ачыклый алганнары юк. Ул таш һәм башка төр язмалардагы телнең серенә төшенү өчен шәрыкның борынгы мисыр (кыйбтый), гарәп, фарсы, санскрит, көнбатыш илләренең бик күп башка телләрен дә кулланып карадылар. Сер

чишелмәде. Геродот аларны Кече Азиядән – борынгы Финикия тирәләреннән хәзерге Италия җиренә килеп төпләнгән кавем дип язган. Бөек Наполеонны, Франциянең француз милләтеннән булмаган героен биргән Корсика утравы да алар карамагына кергән, дип яза башка галимнәр. XIX гасыр галимнәре исә, Геродот фикерен ачыклый төшеп, алар хәзерге Төркия биләмәсендәге Троя шәһәре тирәләреннән күчкән булырга тиеш дип саныйлар. Рим империясе тарихчысы Тит Ливий исә борынгы Этрурия дәүләтен төзүчеләрне Европаның Альп таулары белән Дунай елгасы аралыгыннан күчеп килүчеләр дип исәпләгән. Соңрак яшәгән кайбер галимнәр дә аларның гореф-гадәтләре, табыну-карашлары хәзерге албаннарның бабалары яшәешенә якын булган дип яздылар. Ләкин этрускларның нинди телдә сөйләшүен ачыклый алучылар гына юк әлегә.

Этрускларга нисбәтле бер риваятьтә борынгы бер күренекле төрки ыруы тарихына охшаш бик кызыклы факт та теркәлгән. Рим каласын нигезләүче ике бертуганны ана бүре имезеп үстергән икән. Төркиләрнең ерак бабалары тарихында да шундый ук хәл тасвирлана бит – булачак ыру башлыгын ана бүре имезеп үстерә. Очраклы охшашлыктырмы бу яисә аның нигезендә уртак бер вакыйга бармы – әлегә билгесез.

1960–1970 елларда Европа илләрендә, шул исәптән Италиядә Төркия дәүләтенең илчелегендә эшләгән милләттәшебез Адилә Айда да Этрурия дәүләте тарихы белән кызыксынган. Төркия галимәсе, дипломатия эшеннән соң байтак еллар Әнкара университетында укыткан Адиләнең Садри Максуди кызы Гадилә икәнлеген кабат искәртеп китик. Петербургта туган, алты-җиде ел чамасы Казанда яшәп киткән кеше ул. Анасы ягыннан Оренбург төбәге Рәмиевләр нәселе вәкиле – Шакир кызы Камиләдән туган бала. Аның этрускларның төрки нәселдән икәнлеген дәлилләп язган һәм Төркиядә ике мәртәбә басылып чыккан китабының язмышы да безгә билгеле түгел. Бездә әлеге китап һәм аның эчтәлеге белән кызыксынучылар булса да, аны нәшер итеп чыгарырга теләүче күренмәде кебек.

Гомумән дә Садри Максудиның да, аның кызы Гадиләнең дә, аның кызы, шулай ук университет профессоры Гөнел ханымның да иҗади эзләнүләре әлегә бездә укылмаган, өйрәнелмәгән. Бер очрашу вакытында Фәридә Гаффарова Максудиларның кайбер хезмәтләрен Казанга алып кайтырга ниятләве турында хәбәр иткән иде. Ләкин ниятен үтәргә өлгермәде.

Чаллы каласыннан Нәсим Сәхаповның борынгы төркиләр тарихы белән кызыксынуы миңа ошады. Димәк, аталы-кызлы Максудилар, Нурихан Фәттах, Шамил Анак, Солтан Шәмсиләр башлаган эзләнүләрне дәвам итүче бар. Аның этрусклар тарихы белән кызыксынуы бик вакытлы. Бик җитди хезмәткә тотынган. Аның язмасындагы «татарча укыла» дигән сүзләр белән генә килешеп булмый. Этрусклар телен, язма мирасын татарчалаштыру

дөрес үк түгелдер, мөгаен. Бу очракта «төркичә» дип язу кирәктер. Төркичә төшенчәсенә бүгенге азәриләр теле дә, Төркиядәге төркиләрнеке дә, борынгы болгар, кыпчаклар сөйләшкән телләр дә керергә хаклы. Ягъни барыбыз өчен дә уртак булган бик борынгы тел үрнәкләрен куллану кирәктер, шәт. Унынчы-унберенче йөзләрдә гарәп илләрендә төзелгән гарәпчә-төркичә сүзлекләрне дә, Италиядә латинча-команча басылган «Кодекс Куманикус»ны да гамәлгә кертеп җибәрәсе иде. Югыйсә еш кына безнең кайбер телчеләр, ятрак сүзгә тап булсалар, «бусы гарәп», «бусы фарсы» сүзе дип фаразларга керешәләр. XIII–XIV йөзләрдә Испаниядә яшәгән «испан гарәбе» – Әбу Хайян Андалуси да 10 томлык хезмәт авторы була. Төркиләргә багышлап дүрт китап яза, шуларда төркиләрнең яшәү урыннары төгәл билгеләнгән, дип хәбәр итә бер энциклопедия. Шул ук гасырларда Мисырда, мәмлүкләр идарә иткән чорда, берничә төркичә-гарәпчә сүзлек чыга. Алар Алтын Урда дәверендә барлыкка килгән катнаш угыз-кыпчак телендә язылган, ди галим Әмир Нәҗип (Гасырлар авазы, № 1, 2, 2011).

Этрурия дәүләте язмышы белән тотрыклырак шөгыльләнгән очракта Садри Максуди һәм аның кызының хезмәтләре белән дә, Европа галимнәре язмалары белән дә танышу шарт. Украина галиме Виктор Драчукның 1977 елда Мәскәүдә нәшер ителгән «Дорогами тысячелетий. О чём поведали письмена» китабы да бу җәһәттән бик тә әчтәлекле һәм бик кызыклы. Этрусклар язмышы белән кызыксынган XIX йөз Европа галимнәреннән болгар В. Георгиев белән француз Э. Майани (албаннарга якынлык фикерен яклаучы, этрусклар теле белән албан теле якынлыкларын дәлилләүче) хезмәтләрен күздән кичерү дә зур бәхет булыр иде.

Этрусклар тарихын тикшергән галимнәр аларның зиһенле, батыр, эшчән булуларын, тимер һәм бакыр рудаларын эретеп эш итә белгәнлекләрен билгеләп үтәләр. Исеме астарак телгә алыначак бер немец галиме аларны: «Күрше ыру-кабиләләрне яуларга омтылмаганнар, алар белән сәүдә итүгә өстенлек биргәннәр», – дип яза. Ләкин безгә кадәрге эраның соңгы гасыры урталарында Этрурия дәүләте таркала башлый. Көч-куәт ала барган латин кавеме аларны башта Рим каласыннан куып җибәрә. Һәм әкренләп-әкренләп барлык унлаган кала һәм өлкәләрен дә яулап ала. Рим империясе патшалары Цезарь белән Август идарә иткән елларда әле этрускларның теле өлешчә сакланган була. (Бәлки, борынгы латин телендә дә аларның аерым сүз-атамалары сакландыр. Аларны латин язуыннан аерып алу өчен ул телне бик яхшы белүче кирәктер шул.) Ә безнең эраның беренче гасырында яшәгән император Клавдий исә Этрурия дәүләтенә һәм этруск халкына багышлап егерме томлык тарихи хезмәт яздырган була. Соңрак ул томнар бер янгын вакытында юкка чыккан дип уйланыла.

Күпчелек галимнәр фикеренчә, этрусклар борынгы грек алфавитыннан файдаланган. Алар алфавитына берничә үз хәрефләрен өстәгәннәр. Греклар исә ул алфавитны Кече Азиядәге халыклар-

дан үзләштергән дип язалар. Шуларны укыгач, күңелгә греклар ул язуны күрше этрусклардан үзләштермәдеме икән дигән уй да килә. 1784 елда Германиядә бик кызык эчтәлекле бер хезмәт нәшер ителә. Анда дөньяның төрле кыйтгаларында яшәгән халыклар һәм дәүләтләр тарихы кыскача тасвирланган. 1977 елда ул китап рус телендә дә басылып чыкты. Авторы – Иоганн Готфрид Гердер. Кайчандыр шул китаптан мин кытай белән төркиләрнең үзара мөнәсәбәтләренә бәйле бер-ике абзац һәм этрусклар иленә кагылышлы «Etrur» бүлегеннән бер бит чамасын күчереп язганмын. Шул китапның 393 нче битендә: «Этрусклар алфавиты күпчелек Европа халыкларының алфавитына нигез булды», – дигән җөмлә дә теркәлгән.

Этрусклар 26 хәреф кулланган, шуның бишесе сузыклар булган икән. Хәзерге гарәп язуындагы шикелле, алар да уңнан сулга таба язганнар. Шулай икәнлеген Нәсим Сәхапов та беләдер, мөгаен. Аңа киләчәк эзләнүләрендә уңышлар теләп калам.

*2012*

## ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ

Әлбәттә инде, иң әүвәл башкалабыз Мәскәүдә Изге Владимир I гә һәйкәл ачу тантанасын барлык үзәк телеканаллардан карап, юанып утырдык. Президентыбыз Владимир Путин да, сүзгә оста митрополит Кирилл атакаебыз да бу вакыйганы Россиянең барлык халкы да шушы бәйрәм уңаеннан зур бер бүләк буларак кабул итәр, дип белдерделәр. Һәм бик күпләр аны шулай кабул итте дә кебек. Россиядә яшәүче барлык милләтләрнең татулыгына китерәчәк бер факт булыр бу, дип нотык әйтүчеләр дә аз булмады. Ул тантанага безнең изге затларыбыз – мөфтиләребез дә чакырулы иде. Бәлки, алар да милләтләр бердәмлеген һәм татулыгын хуплап җылы сүзләр сөйләгән булганнардыр. Ләкин телевизор караучыларның күпчелегенә алар чыгышы җиткерелмәде шикелле. Һәрхәлдә, миңа аларның шул тантанада катнашуын гына күрергә насыйп булды.

Әйе, нотык сөйләүчеләрнең байтагы «бу тантаналы вакыйга милләтләр арасындагы татулыкны тудыруга бер адым булырга тиеш» дигәнрәк фикерләр әйттеләр. Шулай була гына күрсен. Безнең мөселман халкы да андый сүзләрне, чын күңелдән әйтелгән булса, бик теләп кабул итәр. Аеруча без, бөек Идел буе Болгар дәүләте халкының варислары саналган татарлар, кенәз Владимирның мең ел элгәре ерак бабаларыбыз белән дуслык килешүен төзегәнлеген яхшы хәтерлибез. Дөрес, иң элек ул 985 елда Идел буена байлыгы һәм тотрыклылыгы белән дан тоткан Болгар дәүләтен басып алырга, үз казнасына зур ясак түләтеп то-

рырга ниятләп килгән була. Атасы Святославның Бөек Хәзәрләр дәүләтен таркатып, зур байлыкка ия булганлыгын үрнәк итәргә теләгәндер, күрәсең. Ләкин кенәз Владимир I үз максатына ирешә алмаган. Аның сөңге-сәнәк тә чукмар белән коралллы, чабаталы гаскәре бу бай ил-дәүләтнең халкын тез чүктерүгә ирешмәгән. Шуннан соң каенагасы Добрыня аңа: «Бу яхшы коралллы, күн итекле адәмнәрне җиңеп булмас. Уртак килешү төзик тә китик», – дигән. Шул солых килешүендә бит инде «Болгарлар белән руслар таш су өстенә калкып йөзә, колмак суга бата башлаганчы бер-берсенә хыянәт итмәс, үзара дус яшәрләр» дигән изге сүзләр теркәлгән була. Һәм кенәз Владимир белән аның каенагасы, әкият-риваятьләр каһарманы батыр Добрыня кабат болгарлар иленә яу белән килмәгәннәр. Ул гына да түгел, Владимир кенәзнең әле соңрак Киевта гомер итүче болгар бәк-морзалары нәселеннән булган бер сылуга өйләнеп, ярым рус, ярым болгар саналырдай ике яшь кенәзне – Борис белән Глебны дөньяга китергәнлеге дә мәгълүм.

Кем булган соң ул Владимир атлы кенәз? Әйе, аның атасы, Византия тарихчылары теркәп калдырганча «кырыс, усал кыяфәтле» Киев кенәзлеге кенәзе Святослав була. Гомер буе диярлек хәзерге Дон белән Днепр аралыгында яшәүче бәҗәнәк, кыпчак, болгар хан-әмирләре белән орышкан-сугышкан да, якыннан аралашкан һәм кодалашкан да бер хәйләкәр зат. Хәзәр каһанлыгын һәм Дунай буе болгарлары дәүләтен басып алганда бәҗәнәк, кыпчак ханнары ярдәменнән оста файдаланган кенәзләрнең берсе була, дип искә ала аны тарихчылар. Хәер, аның анасы Ольганың – ире Игорь үлгәннән соң Киев кенәзлеген җитәкләгән «баш княгиня»ның да кушаматы замандашлары телендә «Хәйләкәр», соңгы дәвер дин әһелләре язмаларында «Изге җан», кайберәүләр фикеренчә «Мудрый» булган дип яза Россиянең иң атаклы тарихчысы Николай Михайлович Карамзин.

Владимир I – Святослав кенәзнең икенче улы, йорт хезмәткәре (ключница) Милаша белән уйнаштан туган зат. Шул сәбәпле атасы аны яшьли үк, 969 елда Милашаның абыйсы Добрыня батыр җитәкчелегендә, Киев кенәзлегеннән бик читтә булган Новгород каласына төбәк кенәзе итеп җибәрә. Анда аның ни-нәрсәләр эшләгәнлеге бик билгеле түгел. Бераздан соң аның күрше төбәк кенәзе башкаласы булган Полоцк шәһәрен яулап алуы, кенәзне һәм улларын үтертеп, кызы Рогнеданы хатынлыкка алып китүе генә мәгълүм. Бу хатыннан Владимирның дүрт улы, шул исәптән тарихи хезмәтләрдә зур урын биләгән Ярослав Мудрый кенәз туган.

972 елда аталары үлгәч, Святославның өлкән улы Ярополк Киев тәхетендә калдырыла. Владимир 980 елда ялланган бәҗәнәк (рус тарихында – печенег) гаскәрләре ярдәмендә Киевны яулап ала. Украиналы тарихчы М. Грушевский хәбәр итүенчә, ул дәвердә ялланган гаскәрләргә түләү хакы сугышып алынган шәһәр халкын ике-өч көн талау исәбенә булган.

Владимирның күмәк гаскәре шәһәрне тиз арада яулап ала. Кенәз, агасын читләштереп, Киев тәхетенә утыра, аның көмәнле хатынына «өйләнә». Дөресрәге, Н. М. Карамзин хәбәр итүенчә, аны «наложница» – кәнизәк рәвешендә тота. Хатын-кызларга карата бик нәфесле зат була ул. Аның рәсми хатыннарыннан кала йөзләрчә кәнизәк тотканлыгы тарихчы Н. М. Карамзинның «История государства Российского» хезмәтенең 1 нче томының 9 нчы бүлегендә тәфсилләп бәян ителгән. Агаларын читләштереп, аның тәхетен биләү очраклары Россия тарихында да, Алтын Урда дәүләте тарихында да булгалап торган. Тарихчы Б. Д. Грековның бер хезмәтендә дә изгеләр исемлегендә йөргән тагын бер кенәзнең агасының башын чаптырып, аның тәхетен биләгәнлеге язылган. Патшалар заманында Владимир I кенәзнең бик мактап искә алынмавы шушы вакыйгаларга бәйледер, мөгаен. Хәзер исә Мәскәү Кремле янәшәсендә бу кенәз истәлегенә куелган һәйкәлне ачу тантанасы бик зурлап уздырылды. Искә алуны бераз дәвам итик.

Владимир I кенәзне ил һәм дөнья күләмендә танылткан зур, изге гамәле – 980 еллар ахырында христиан динен кабул итүе һәм шул динне үз дәүләтендәге барлык кешеләрнең кабул итәргә тиешлеген раславы була. Дөнья күләмендә танылган кайсы дингә тукталырга дип уйланган дәвердә аның Идел буе Болгар дәүләте белән элемтәгә кергәнлеге дә тарихи язмаларда теркәлгән диелә. Иң элек Болгардан Киевка дин әһелләре җибәрелә. Алар Владимир кенәзне мөселман дине йолаларын үтәү тәртипләре белән таныштыралар дигән фикер яши. Мөселман дине кагыйдәләреннән бу кенәзгә ир-атны сөннәткә утырту һәм хәмер эчүне тыю тәртипләре ошамаган, дип язалар кайбер тарихчылар. Шуннан соң ул православие диненә өстенлек бирә. Бу динне аңа кадәр әбисе Ольга, үләренә берничә ел калганда, 957 елда Византия башкаласына барып кабул итеп кайткан булган. Ләкин ул чорда әле Киевта яшәүче славян кабиләләре арасында борынгы йолаларга табыну өстенлек иткән. Ольга карчык рәсми рәвештә христиан динен кабул иткәнче үк, шул дин кагыйдәләрен куллана башлаучыларны җәзалау очраклары Владимир кенәзнең атасы идарә иткән елларда да күзәтелгән. Бу дин тәртипләрен иң әүвәл Киев кенәзлеге йогынтысында яшәүче кайбер төрки кабиләләр – бәҗәнәк, болгар, кыпчакларның бер өлеше кабул иткән була. Дөрес, аларның православие диненең көнчыгыш тармагы саналган «әрмән дине»нә күчкән булулары мәгълүм. Кайбер тарихчылар бу вакыйганың алтынчы йөзләр тирәсендә, әлеге кабиләләр башлыча Төньяк Кавказ – Днепр аралыгын биләгән чорда гамәлгә керә башлаган димәкчеләр. «Слово о полку Игореве» дастаны авторына үрнәк булган, шул поэмада телгә алынган шагыйрь Боянның Киевта яшәп иҗат иткәнлеге, христиан динен тотучы болгар кешесе булуы тарихчы һәм язучы Андрей Никитинның 1986 елда «Москва» журналындагы хезмәтендә, аннары үз китабында бәян ителде. Андрей Никитин, байтак еллар академик Д. С. Лихачёв җитәкләгән «Борын-

гы рус әдәбиятын өйрәнү комиссиясе»ндә сәркатип вазифасын үтәдем, дип яза. «Куликово кыры»ндагы сугыш вакыйгаларына багышланган «Задонщина» китабында да алда телгә алынган ике дастан-поэмадан күчерелгән үрнәкләр бар, дип мисаллар китерә… Һәм ул мисаллар шулай ук төрки кавемнәр белән аралашып яшәү үрнәкләрен дә чагылдыра. Бөек Киев кенәзлеге дәверендә идарәче кенәзләрнең күпчелеге болгар, бәҗәнәк, кыпчак хан-солтаннары белән кодалашып яшәгәннәр. Кызларын-улларын өйләндерешеп, үзара кодалашу очраклары еш булган. Хәер, «Слово о полку Игореве» поэмасында да вакыйгалар шул юнәлештә дәвам итә ич. Шундый мисаллардан бер-икесен генә искә алып китик: Владимир I нең улы Ярослав Мудрый, аңардан дистә еллар соңрак идарә иткән Юрий Долгорукий һ. б. кенәзләр шул төбәк төрки ханнарының кияүләре исәпләнәләр. Ә Долгорукийның кыпчак-болгар ыруглары берләшмәсе ханы Әюб кызыннан туган улы Андрей Боголюбский исә шулай ук болгар кызына өйләнгән була.

Владимир I кенәз кинәт вафат булганнан соң, аталарыннан калган тәхет өчен дау-тарткалашу вакытында үтерелгән аның уллары Борис белән Глеб Россия тарихында иң беренче буларак дин әһелләре тарафыннан «Изге җан» дип танылачак. Алардан соң шундый ук олуг исемгә лаек кеше кенәз Александр Невский буладыр (1220–1263). Аның да уллары болгар-кыпчак берлеге ханы кызыннан туган балалар. Шуларның берсе – әле булачак Мәскәү кенәзлегенә нигез салучы кенәз. Әмма шул хакта безнең илдәге соңгы чор тарихи әдәбиятта хәбәрләр юк диярлек. Академик Д. С. Лихачёв та, мәсәлән, Бөек Киев кенәзлеге тарихына багышланган бер күләмле хезмәтендә кенәзләрнең һәм аларның балаларының Византия, Франция, Чехия илләренең идарәче төркеме вәкилләре белән туганлашу фактларын иркенләп бәян итә. Әмма якын тирәдәге төрки ханлыклары белән кодалашу вакыйгаларын искә алмый. Ә 1950 елларгача чыккан чыганакларда исә алар телгә алына иде.

Владимир кенәз үләр алдыннан (1015 ел) улларына аерым биләүләр бүлеп калдыра. Өлкәнрәкләренә яки якынрак күргәннәренә Киев, Новгород кебек эрерәк өлкә биләмәләре туры килә. Кечерәкләренә исә, әйтик, тумышы белән болгар нәселеннән булган хатынының уллары Борис белән Глебка хәзерге Мәскәү тарафындагы, ул вакыттагы Идел буе Болгар дәүләте чигендәге Ростов белән Муром шәһәрләре туры килә. Мөгаен, Владимир кенәз ике кече улына биләмә өлкәсен сайлаганда тотрыклы, бай дәүләт тирәсен дә сайларга тырышкандыр. Һәм аларның нәсел тарихында болгарлар эзе барлыгын да истә тоткандыр. Ә Киев тәхетен биләр өчен бертуганының көмәнле хатыныннан туган, өлкән уллары исәбендә йөргән Святополкка исә хәзерге белоруссиядәге Туров шәһәре биләмәсен билгеләгән була.

Атасы вафат булганда яшүсмер кенәз Борис әле Киевтан китеп өлгерми. Владимир I кенәзнең кинәт вафат булуын хәбәр итү

өчен, иң элек энесе Глебка чапкын җибәрә. Башка туганнардан да кайберләре аталары пайтәхетенә кайта. Шулчак Святополк, үзен тәхет биләүчегә санап, аталары белән хушлашырга җыелган өч бертуганны, шул исәптән Борис белән Глебны үтертеп, 1015 елда үги атасы тәхетенә утыра. 1019 елда исә Ярослав Мудрый, туганнары үчен алып, халык телендә «Окаянный» исеме алган Святополкны да теге дөньяга озата. «Тәхет биләү тәртибен раслаган һәм тәхет биләргә хакы булган варисларны үтерү гөнаһ» дигәнрәк эчтәлекле язманы тудыручы да шушы Ярослав Мудрый була.

Берникадәр вакыт үткәч, дин әһелләре, шушы язма күрсәтмәгә дә таянып булса кирәк, болгар хатыныннан туган ике яшүсмер кенәз Борис белән Глебны кенәзләр арасыннан иң беренчеләрдән булып Изге җаннар исемлегенә теркиләр. Ягъни, аларны искә алганда, һәрвакыт «канонизированы русской церковью» дип әйтү һәм язу тәртибе кертелә. Алар исеме бүген дә дин әһелләре теленнән төшмичә, даими рәвештә искә алына. Аталары исә андый бәхеткә төгәл мең ел тулганда гына ирешә дияргә була. Владимир I кенәз истәлегенә багышлы беренче һәйкәл Киев шәһәрендә 1860 еллар ахырында торгызылган була. Һәм хәзер аңа Мәскәү Кремле каршындагы үзәк мәйданнарның берсендә – изге урында яңа һәйкәл куелды. Без мөселманнар да шул һәйкәлне ачу тантанасында сөйләнгән нотык, теләнгән теләкләрнең кабул булачагына ышанып калабыз. Әйе, бу яңа һәйкәлнең бер дәүләттә яшәгән төрле дин тотучыларны чын-чынлап берләштерү юнәлешендә бер адым булсын иде диясе килә. Ил үзәгендә барган хәлләр башкачарак фаразларга юнәлтелгән сыманрак тоелса да, Бердәмлек көнен бәйрәм иткән, телевизор экраннарында халыклар дуслыгы турында кайнар нотыклар сөйләнеп торган мизгелдә әле күңел алда телгә алынган дуслык, бердәмлек дәвере килеренә өмет итеп кала! Амин!

*2016*

# ЕРАК ЧОРЛАР АВАЗЫ

*(Татарга бәйле тарих)*

Мәскәүнең «Современник» нәшрияты 1991 елда ике томлык бик тә гыйбрәтле бер хезмәт бастырып чыгарды. Һәр томы утыз бишәр табак күләмендәге бу басма «История родов русского дворянства» дип атала һәм аның үзенчәлеге шунда ки, бүген генә туган хезмәт түгел бу. 1886 елда С.-Петербургта, үз чорының мактаулы академигы булган П. Н. Петров җитәкчелегендә бер мәртәбә дөнья күргән инде бу шәҗәрәлек. Яңа нөсхә ике-өч битлек кереш сүз белән баетылган һәм нindidер күләмдә редак-

цияләнгәндер. Һәрхәлдә, бүгенге язылыш тәртибенә якынайтылган хезмәт.

Бүген без шушы рус дворяннары – кенәзләр, графлар, бароннар арасыннан кемнәрнең элекке татар, нугай, казах бәк-морзалары токымнарыннан булганнарын бераз искә төшереп үтик. Аларның күпчелеге электән кем булганнарын бик яшермәгәннәр. Гомерлек нәсел тамгасы саналган гербларында элекке мөселман диненә табынганлыкларын белгерткән ярымай сурәтләрен дә мул кулланганнар.

Урыс дворяннарының борынгыдан килгән шәҗәрәләрен тасвир иткән андый китаплар бездә егерменче еллардан бирле басылмады гына түгел, хәтта патша заманнарында дөнья күргәннәре белән танышу мөмкинлекләре дә бик-бик чикләнгән иде. Тарихи әһәмиятле андый хезмәтләрне бездә ике-өч йозак астында, төрле-төрле «тыелган фондлар»да яшереп саклау гадәткә кертелгән иде. Хәзер ул «саклагычлар»ның ишеге беркадәр ачыла башлады. Ләкин хәзер дә әле «үтә яшерен» тамгасы сугылган, тимер ишекләр артында ятучы андый тоткын китапларның барлыгы җәмәгатьчелеккә мәгълүм. Әйтик, беренче бөек рус революционеры һәм демократы данын алган Александр Николаевич Радищевка багышланган бер биографик-гыйльми хезмәтнең язмышы шундыйрак. Украина тарихын һәм шуңа бәйле рәвештә ерак бабаларыбыз булган болгар-кыпчаклар һәм кырым татарлары белән Киев кенәзлекләре бәйләнешләрен «советча» тасвирламаган зур галим Михайло Грушевскийның да унике-унөч том чамасындагы хезмәтләре шундый ук серле, тыюлы сандыкларда дистә еллар дәвамында сакланды. Хәзерге чорның мөстәкыйль Украина җитәкчеләре ул томнарны нишләткәннәрдер инде. Бәлки, болгар, кыпчак, каракалпак (рәсми тарихта «чёрные клобуки»), бәҗәнәкләргә бәйле өлешләрен төшереп калдырып бастырып та чыгарганнардыр. Әлегә ул хакта бернинди дә мәгълүматым юк. Ул томнарның басылып чыгуы турында рәсми матбугатта хәбәр булмады. Шул томнарның эчтәлеге белән беркадәр таныш булган Украина язучылары һәм галимнәре, анда болгар, бәҗәнәк, кыпчак, каракалпак, татарларның тарихи үткәне бик киң һәм бик уңай тасвирлана, дип әйткәлиләр иде. Ул томнардагы чын тарихи язмалар белән танышу ышанычлылыгы кат-кат тикшерелгән зур галимнәргә дә аерым очракларда гына рөхсәт ителде элек. Хәзерге буталчык чорда мең еллар элек Киев шәһәрен нигезләүдә катнашкан болгар, кыпчак, бәҗәнәк кабиләләренә бәйле ул томнардагы өлешләр, бәлки, бөтенләй үк тә юк ителгәннәрдер. Ә Совет хакимияте чорында исә бөек түрәләргә баш иеп, яшерен сандыкларда сакланган ул томнар белән таныша алырдай үз галимнәребез әле юк иде шул.

Хәер, элек болар гына түгел, Сталин тарафыннан тәнкыйть утына алынган совет чоры тарихчысы М. Н. Покровскийның да, «мактаулы урыс тарихчысы» саналган С. М. Соловьёвның

да, урысның борынгы хәл-әхвәлен миссионерлар күзлегеннәнрәк карап бәян иткән чукынган татар морзасы Н. М. Карамзинның да хезмәтләре шундый ук тоткын хәлендә булды ич.

Байтак кына тарихи хезмәтләрнең совет чоры укучысына «килешмәгән», аның зиһененә кире йогынты ясардай дип уйларлык ике сәбәп бар иде, минемчә. Беренчесе – аларда патшаларны, алпавытларны зурлап, данлап күрсәтергә тырышылганлык. Икенчесе, беренчесеннән дә куркынычрагы – милли аң мәсьәләсенә кагылышлы булуы. Якыннанрак баксаң, Рәсәй тарихы, ике төрле онны кушып пешерелгән бер бөтен ипи кебек, татарлар дөньясына бик нык бәйле. Рәсәй дәүләтчелегенең шушы ике тамырдан башланып киткәнлеге тарих чоңгылына чумган саен ачыграк күренә бара. Без яшәгән бүгенге Рәсәй дәүләтенең башлыча Мәскәү-Владимир кенәзлеге җирлегендә барлыкка килүен һәркем белә. Ә менә аның шәҗәрә башында торучыларның тумыштан ук ярым татар-кыпчак яки болгар булганлыклары һаман яшерелә килде диярлек. Владимир-Суздаль кенәзлегенә нигез салган Андрей Боголюбскийның анасы ярым болгар, ярым кыпчак нәселеннән, хатыны болгар нәселеннән булган. Галимнәр раславынча, ул кенәзнең йөзе дә кәгазьдә татар-монгол кыяфәтендә сурәтләнә. Иван Грозныйның кабердә сакланган баш сөякләренә нигезләнеп, мәшһүр антрополог һәм скульптор Михаил Герасимов ясаган портретта да шундый ук хәл бит. Ул портретта Дүртенче Иван патшаның кыяфәте дә бер бәк йөзенә тартым ич.

Андрей Боголюбскийны, ә элегрәк атасы Юрий Долгорукийны тәхеткә күтәреп утыртучы гаскәрнең төп күпчелеге дә шул ук болгар, кыпчаклар була, дип хәбәр ителә ич елъязмаларда. Һәм Шул дуслыкны ныгыту һәм дәвам итү өчен, Долгорукий кенәзнең болгар-кыпчак бердәмлеге ханы Әюб кызына өйләнгәнлеге дә шул ук язмаларда теркәлгән. Ә шул дәвер Киев кенәзлегенең белгече саналган бер абруйлы галимебезнең 1960 елларда нәшер ителгән китабында исә «мондый вак хәбәрләр» төшеп калган. Анда фәкать, фәлән кенәзнең улы Франциянең бер югары дәрәҗәле түрәсенең кызына өйләнгән була, икенче бер кенәзнең кызын Византия императоры йортына киленлеккә алалар, кебек мәгълүматлар гына китерелә. Янәсе, ул кенәзләр, якын күршеләре булган төрки ханлыклары белән аралашмыйча, Европага йөз тотканнар дип ышандырасы килә ул галимнең үз укучыларын… Икенче бер рус галиме Ю. Ф. Козлов исә «От князя Рюрика до императора Николая II» китабында Киев, Чернигов кенәзлекләре кенәзләренең күпчелегенең шул төбәктә гомер итүче кыпчак, болгар хан кызларына өйләнгән яисә шулардан туган булганлыкларын хәбәр итә.

Әйе, Грушевский, Карамзин, Вельяминов-Зернов һ. б. олуг тарихчылар язган китапларда «явыз, килмешәк, баскын, надан, үз тарихи йөзе булмаган» татар халкына, ул халыкның бабала-

ры кыпчак, богарлар төзегән ил-дәүләтләргә карата байтак кына җылы, матур сүзләр дә ычкынгалаган икән ләбаса. Шул исәптән бу халыктан чыккан мактаулы шәхесләр дә үткән тормышның иң алгы сәхифәләрендә эз калдырып киткәннәр икән. Боларны хәтта «История государства Российского» дигән күптомлы мактаулы хезмәтендә Н. М. Карамзин да, гәрчә чорының дин башлыклары таләп иткән кара рухтарак язарга тырышса да, һәр урында да татарларга бәйле тарихи фактларны фәнни тарих битләреннән төшереп бетерә алмаган. Шул сәбәпләрне дә истә тотып, Совет хакимияте дәверендә аның томнары да күпчелек совет укучысыннан яшереп сакланды шул.

Ә инде аерым шәхесләргә килгәндә, олуг галимнәр тарафыннан әзерләнгән, СССР Фәннәр академиясенең «Академкнига» нәшриятында утызынчы еллар урталарында нәшер ителгән «Александр Николаевич Радищев» китабының әле дә юкка чыгып торуының төп сәбәбе, минемчә, әлеге дә баягы «килмешәк, баскын татар»га бәйле. Ничек инде ул шундый олуг шәхес, үз чорының иң зирәк акыл иясе тумышы белән татар була алсын? Җитмәсә әле, кайбер замандашлары кебек татарлыгын яшермичә, шуның белән берникадәр масайсын да, имеш! Татар дигән «кыргый» халык телен үзе белү генә җитмәгән, ул телне, имеш, улларына да өйрәтеп, алар белән татарча хатлар алышсын әле! Әлбәттә, бу хезмәт дөньяга чыгу белән үк Сталин, Суслов ише «милли сафлык»ны кайгыртучылар тарафыннан караңгы сейфларга яшерелә; ә бәлки әле болай да күп булмаган тиражының байтак өлеше бөтенләй юкка да чыгарылгандыр. Ә бит «Александр Николаевич Радищев» китабын 1936 елда СССР Фәннәр академиясе басмаханәсе нәшер иткән була. Әмма басылып чыккач та ул китапны зинданга кертеп ташлыйлар. Дөрес, Н. С. Хрущёв идарә иткән бер дәвердә аны күпмедер вакытка тоткыннан азат иткәннәр иде. Шул чорда Украинада булганда сөргеннәрдә «йөреп» кайткан бер язучы ул китапны миңа укып торырга дип биргән иде. «Безнең китапханәдә бар ул хәзер», – дип. Шуннан кайткач, мин аны Казанның билгеле китапханәләреннән дә эзләп карадым. «Бездә андый китап сакланмый», – дип җавап бирделәр. Татар илендә элекке татар шәхесен мактаган китап күренеп ятмасын әле дип, аны күптән юк иткән булганнардыр инде.

* * *

Мәгълүм ки, Рәсәй дәүләте тарихы, европалы тиңдәшләре белән чагыштырганда, бер «фәнни» тәртипкә шактый ук соң салына. Дөрес, аерым төбәк-кенәзлекләрнең үткәне шул төбәк монастырь кенәгәләренә теркәлгәләнгән була. Аерым елъязмачылар да кайбер истәлекле вакыйгаларны теркәп калдырырга тырышканнар. Ә инде беренче тулырак шәҗәрәлек Мәскәү бөек кенәзе Иван Грозный чорында, 1560–1563 елларда барлыкка килә, дип хәбәр ителә

энциклопедик хезмәтләрдә. Ул шәҗәрә «Степенная книга» дип атала. Аны төзүче бөек кенәзнең шәхси рухание Андрей була. Ул чор руханиларының башлыча Византиядән чыккан греклар булганлыгын да истә тотарга кирәктер.

Минем өстәлдә яткан «История родов русского дворянства» китабының ике томына 339 иң зур дәрәҗәле Рәсәй кешеләре фамилияләренең килеп чыгышы, 150 ләп атаклы нәселнең герб тасвирламасы һәм 32 шәҗәрә таблицасы урнаштырылган. Беренче том мондый аерым бүлекләрдән тора: 1. Кереш аңлатма; 2. Кенәз Романовлар шәҗәрәсе; 3. Бөек кенәз Михаил Чернигов варислары; 4. Бөек кенәз Владимир Мономах варислары. Тармаклар: Смоленск кенәзләре, Ярославль кенәзләре, Владимир-Суздаль вә Мәскәү кенәзләре; 5. Литваның бөек кенәзе Гедимовичның Рәсәйгә бәйле варислары; 6. Шәҗәрәләре Европа дәүләтләренә бәйле өч токым; 7. Фин-угор кабиләләреннән, татар һәм буряттан чыккан 14 токым; 8. Монгол-татарлардан чыккан кенәзләр: Казан, Кырым, Әстерхан ханнары варислары, кыргыз-казах, нугай морзалары токымнары; 9. Грузиядән чыккан кенәзләр.

Күренә ки, шәҗәрәләр Рәсәй дәүләтенә хезмәт күрсәтә башлау вакытына карап төзелгән. Фин-угор токымыннан чыккан кенәзләрнең монгол-татар хан-морзалары варисларыннан алда китерелүе дә, грузин кенәзләренең иң соңгы буынга куелуы да шуны аңлата.

Икенче томга тумыштан ук кенәз дәрәҗәсенә тартым булмаган аксөякләр кертелгән. Аерым шәхес һәм нәсел вәкилләренә дәрәҗәле исемнәр бирү тәртибе Беренче Пётр патша заманында урнаштырыла. Шундый беренче указ 1707 елда чыгарыла. «История родов...» басылганчы (1886 ел), узган йөз сиксән елда төрле патша һәм императорлар тарафыннан 32 нәселгә «кенәз» дәрәҗәсе бирелгән, 126 сы «граф» булырга лаеклы дип табылган. Беренче Пётр тарафыннан кенәз дәрәҗәсе иң беренче итеп яшьлек чоры дусты, һәрчак аның ярдәмчесе булган А. Д. Меньшиковка һәм Кече Русияне (Украинаны) Рәсәй карамагында калдырырга зур булышлык күрсәткән А. А. Безбородкога бирелә. Граф титулы беренче булып Әстерхан «бунты»н бастыручы Борис Петрович Шереметьевка, өченче булып ике бертуган Апраксиннарга бирелә (болар өчесе дә тумышлары белән татарга бәйле шәхесләр). Шул ук 1707 ел указы белән барон титулына да ике чит чыгышлы кеше – яңарак чукынган яһүд Шафиров белән ярымтатар Строганов лаек булалар. Әйе, Беренче Пётр патша, чыганакларга караганда анасы ягыннан татарга бәйләнеше булган шәхес, кешене кайсы токымнан булуына карап түгел, эштәге булдыклылыгыннан чыгып бәяләгән...

Икенче томда теркәлгән кенәз яки графларның күпчелегенең варислары бу титулларны куллanудан мәхрүм була. Дәрәҗә бирелү указында сирәк очракта «барлык варисларына күчә» дигән сүзләр өстәлгән. Кайбер очракта исә «варисларының беренче

буынына гына күчә» диелгән. Ягъни варислардан беренче туган ир балалар титуллы булып, шул ук ата-ананың икенче, өченче уллары титулсыз калган. Түбәндә китереләчәк шәҗәрәләрдән икесе шундыйлардан: указ нигезендә кенәз дәрәҗәсе алган Кочубейларның бер тармагы тулы хокуклы, ә шул ук елларда, шундый ук рәвештә кенәз титулына ия булган Тарковскийлардан фәкать беренче туган ир бала гына ул дәрәҗәне йөртә алган. Титулның кыз буынына күчү очраклары да булгалаган. Мәсәлән, нугай морзасы Йосыф шәҗәрәсен дәвам иттерүче буын өзелгәч, 1885 елгы император указы белән соңгы кенәзнең кызыннан туган Феликска кенәз дәрәҗәсе кайтарыла. Һәм ул Йосыпов-Сумароков фамилиясен йөртергә тиеш була. Шундый ук хәл өзелгән Тенишевлар шәҗәрәсе белән дә кабатлана – 1875 ел указы нигезендә аларның кыз буын варисына кенәз дәрәҗәсе кайтарыла. Рәсәй тарихында андый берничә очрак теркәлгән.

Укучыга шушы китаптан берничә шәҗәрә тәкъдим итәрбез. Аларның өчесе беренче томнан – «тумыштан килгән кенәзләр»гә тиңләштерелгән хан, бәк токымы вәкилләре. Ә икесе – указ нигезендә бу титулга ирешкән шәхесләр. Боларның барысының да нәсел башында торучы бабалары ерак төрки-татар токымыннан була.

Иң әүвәл «История родов…»ның беренче томында китерелгән (374–375 б.) исемлектән төрки-татар фамилияле бәк-морзаларның шәхсән кенәзлек дәрәҗәсендә кабат раслану елларын күздән кичерик: **Әбердиев (1690), Аганин (1690), Аинов (1690), Алачев (1640), Байгелдиев (1681), Бәхтехуҗин (1690), Биглов (1690), Булаев (1690), Булышев (1690), Гильдиев (1690), Давытов (1672), Дәүләткилдиев (1690), Җансөеров (Сюерев, 1658), Дивиев (1690), Егунов-Черкасский (1627 һәм 1792), Енадаров (1690), Еналиев-Шөгеров (1690), Енбарсов (1690), Енгилдиев (1690), Енгалычев (1690), Еникиев (1690), Енодаров (1692), Заманов (1692), Илмәмәтов (1658), Ибердиев (1690), Ишеев (1690), Килдишев (1690), Канбаров (1636), Кошаевлар (1690), Кугушевлар (1658 һәм 1692), Крымский (1690), Кудашевлар (1690 һәм 1692), Колынчаков (1690), Курмагалин-Мансуров (1680), Кутуев-Кутовлар (1658 һәм 1692), Мамаевлар (1627 һәм 1692), Мәмәтхуҗиннар (1690), Мәмәтов (1690), Мәмлиев (1680), Мангушев (1690), Мансырев (1690), Мещерский һәм Мөлкиев (1690), Моратов (1690), Мостафиннар (1680), Облесимовлар (1690, татарча «Әбләсим»нән булса кирәк), Сәетовлар (1627 һәм 1692), Сембикаев (1690), Семинеев (1690), Себер Смаиловлары (1627 һәм 1640), Сулышевлар (1627), Тайшиннар (1676 һәм 1692), Тенишевлар (1658 һәм 1692), Тинеев (1690), Тугушев (1690), Төмәнев (1690), Урмышетевлар (1627 һәм 1692), Урусов, Чегодаевлар (1690), Черкесский, Черьяровлар (1690), Шәйдәковлар (1627 һәм 1692), Шәйсоповлар, Ширинскийлар, Шихматовлар (1636 һәм 1692), Йосыповлар (1627 һәм 1692), Ялымов (1690).**

Кенәзлек дәрәҗәсендә кабат танылуы 1690 ел белән теркәлгән 61 фамилияле бәк-морзага сотник дәрәҗәсе бирелә һәм административ-хәрби хезмәт урыннары билгеләнә. Сотник дәрәҗәсенә ирешү инде ул вакытта берәр биләмә-төбәкнең башлыгы итеп билгеләнү дигән сүз. Мәсәлән, булачак Казан губернасы җирләре ул дәвердә шундый берничә биләмәдән торган. Өяз төшенчәсе гамәлгә кергәнче, ул биләмәләр «сотня» дип, аның башлыгы «сотник» дип аталган. Еникиев кенәзләрнең Темников шәһәре төбәге башлыгы итеп билгеләнүе Иван Грозныйның 1539 елның 6 май көнендәге карарында ук теркәлгән («Темников был отдан князю Еникей-бею»). Еникиев һәм башка морзаларның шундый бөек дәрәҗәгә ирешүенең нигезе, әлбәттә, аларның шәҗәрәсенең элеккеге ханнар яисә мөстәкыйль бер дәүләтнең идарәчеләре нәселеннән килгәнлегенә бәйле. Мәсәлән, Нугай урдасы дәүләте башлыклары, Чыңгызхан нәселеннән булмау сәбәпле, «хан» дип аталмаган. Ул дәүләт башлыгы «бәк» дәрәҗәсендә йөртелгән. Атаклы Аксак Тимер дә шул ук сәбәптән үзенең чиксез зур дәүләтенең әмире генә була алган. Безнең кулдагы әлеге китапта билгеләп кителгәнчә, шул ил башлыклары варисларының да патша нәселләре вәкилләренә тиң «природные князья» дәрәҗәсенә кертелгәннәре бар. Мангыт ыруыннан чыккан, хан варислары булмаган Йосыпов, Урусов кебек кенәзләрнең дә бу шәҗәрәлекнең 1нче томына кертелгәнлеге шуның белән аңлатыла.

Әмма бу исемлектәге фамилияләрнең күпчелеге соңыннан «природный кенәз»ләр исемлегеннән төшеп калачак. Шул зур дәрәҗәдән мәхрүм ителеп, «чабаталы морза» рәвешендә калучылар исемлегендә күпләребезгә таныш фамилия йөртүчеләрдән Еникиев, Кутуев, Мангушев, Мансуров, Ялымов һ. б. бар.

Кенәзлек дәрәҗәсен фәкать берничә фамилия генә саклый ала: Мещерский, Черкасский, Дондуков, Урусов, Йосыпов, Тенишев һәм тагын бер-ике шәхес. Чөнки Пётр патша 1716 елда бик тә усал бер указ чыгара: кем дә кем динен алыштырмый, чукынмый – шулар утар һәм җир биләмәләреннән генә түгел, элгәре бирелгән дәрәҗәләреннән дә мәхрүм ителәчәк. Байтак кына токымнар капма-каршы якка бүленәләр. Әйтик, урыс кенәзләре Тенишевлар булган кебек, чукынмаган татар зыялылары – «чабаталы морза» Тенишевлар да яшәүләрен дәвам иттергән.

### Мещерский фамилияле кенәзләр

Аларның төп яшәү төбәге соңрак «Мишәр олысы», «Мишәр йорты» буларак та тарихка керәчәк. Алтын Урда чорының татар токымлы бер олыс биләүчеләрнең Мәскәү кенәзлегенә «сыенганда» алган фамилияләре, башка урыс кенәзләренә хас булганча (кенәз Московский, кенәз Ярославский), яшәү урыннарына бәйле була.

Әйтик, Смоленскида яшәсә – кенәз Смоленский, биләмәгә Вязьма шәһәре туры килсә – кенәз Вяземскийлар һ. б. Бу кенәзләрнең төркичә сөйләшүче бабалары элекке урыс һәм мукшы җирләре чигендәге урманлы, саз-баткаклы төбәктә – урысча «мещера» дип йөртелгән урыннарда яшәгәннәр. Шул яшәү урыннарына бәйле рәвештә бу кенәзләр «Мещерский» булып киткәннәр. Атаклы яугир Мамай бәк варисларының да Глинскийга әверелүе шушы традициягә бәйле. Бәкләр бәге Мамай Кырымда генуялылар тарафыннан үтерелгәч, гаиләсе аның Бөек Литва кенәзлеге тарафына чыгып кача. Литва кенәзе Витовт, аның гаиләсен яшәтер өчен дип, Глинск һәм Полтава шәһәрләрен билгели, диелә җитди бер энциклопедиядә. Глинск шәһәрендә төпләнгән улы, шул заман тәртибе кушканча, Глинский фамилиясен ала. Бераздан ул Арслан исеменнән ваз кичеп, Левка әверелә. Арсланның ике улы, Василий белән Михаил, Польша корольлеге җитәкчелеге белән бәхәскә кергәч, 1508 елда гаиләләре белән Мәскәү кенәзлегенә качып кайтачаклар. Икесе дә бабаларыдай яугир шәхес булганлыктан, тиз арада монда оста сугышчы рәвешендә дан казаначаклар. Әүвәл икесе дә шведларга каршы сугышта осталык күрсәтәчәк. Соңрак Михаил берничә мәртәбә Казан тарафына оештырылган яуга аерым гаскәр башлыгы буларак билгеләнәчәк. Ә Василийга тиздән тагын да дәрәҗәлерәк урын эләгә. Бөек кенәз Василий Иванович бала тапмаган җәмәгатен монастырьга озаткач, 1526 елда ул икенче хатынлыкка Василийның кызы Еленаны сайлап алачак. Һәм бер ел тулмастан бу гаиләдә тупырдап торган ир бала – булачак Бөек кенәз Иван Васильевич авазы ишетелә башлаячак.

Татарда «Мишәр йорты» буларак танылган төбәгебезгә, вакыйгабызның төп геройлары Мещерский кенәзләр ватанына әйләнеп кайтыйк.

* * *

Шушы родословная китабында хәбәр ителүенчә, аларның шәҗәрә башында Мөхәммәт атлы дин әһеле торган. Аның чыгышы болайрак аңлатыла: ул Зур Урдадан (ягъни Алтын Урдадан) килеп монда төпләнгән. Чыгышы буенча Зур Урданың Ширинскийлар токымыннан була. (Элекке татар ханлыклары башлыча дүрт ыруг-урда берләшмәсеннән торган. Ширин ыруы токымы шул дүртлеккә керә.) Аның Мещера төбәгенә килеп төпләнү елы – 1298 ел дип исәпләнә. Килүенең максаты җирле халык арасында ислам динен тарату була.

Бу китапта ялгышлык бар бугай. Безнең фикерләвебезчә, ул мондагы җирле токымыннан чыккандыр. Болгарда яшәгәндә ислам динен кабул иткәндер дә, иленә кайткач, шул дин йолаларын өйрәтеп, ислам дине йогынтысын төбәк күләмендә таратырга керешкәндер. Шушы Мөхәммәт варислары монда, Мәскәү белән

Рязань кенәзлекләре аралыгындагы урман-чытырманлы урында, үзләренең мөстәкыйль олыс-биләмәсен оештыралар. Әлбәттә, аз санлы гаскәр туплардай бу олыс озак яшәми. Башка бер тарихи хезмәттә әйтеп үтелгәнчә, Алтын Урда дәүләтендәге тотрыксызлык чорында кайсыдыр хан исеменнән бу олыс 1360 елда Мәскәү кенәзлегенә бирелә («уступать ителә»). Шул көннән бу олыс башлыклары, әле чукынмастан элек үк, рус елъязмаларында Мещера кенәзләре буларак теркәлә башлый.

Мещерский кенәзләрнең император Павел Беренче чорында (1798 ел) расланган герблары мондыйрак: урыс монархлары бүреге астындагы калкан дүрткә бүленгән. Шуның беренче өлешендә (сулдан беренче) – кара сызыклы мәйданда ике көмеш ярымай – яңа ай сурәте. Икенче һәм өченче бүлекләрнең җирлеге – күк. Икенче бүлектә, күк җирлектә – көмеш кальга рәсеме, өченчедә – кулына кылыч тоткан атлы гаскәри. Дүртенче бүлемтәнең җирлеге ике төсле – кара сызыклы һәм күк. Шулар өстеннән көмешкә тартым төсле таш күпер сурәте сузылган. Дүртенче сурәтнең мәгънәсе, мөгаен, бу кенәзләрнең элекке карасу җирлекле тормыштан көмеш күпер аша күк төсендәге киләчәккә омтылышларын чагылдыруы булгандыр.

Алда аталган дин әһеле Мөхәммәтнең бер улы Бикләмеш исемле була. Бу шәҗәрәлектә шул Бикләмешнең инде Михаил исеме белән христиан динен кабул итүе һәм Мещерский кенәзләрнең шәҗәрәсен башлап җибәрүе тасвирлана. Аның оныгы Юрий Фёдорович Мещерскийның үз полкы белән бөек кенәз Дмитрий Донской ягында Куликов кыры вакыйгасында катнашканлыгы мәгълүм. (Ләкин әле, алда китереләсе вакыйгалардан күренгәнчә, аның биләмәсе Мәскәү кенәзенә турыдан-туры буйсынмаган була. Ягъни ул Мәскәү һәм Рязань кенәзлекләре арасындагы җир-биләмәдә ярым мөстәкыйль кенәзлек кенәзе булган.) Мещераның мөстәкыйль соңгы кенәзе – шәҗәрә башы оныгының улы Юрий Семёнович исәпләнә. Ул, туганы Василий, туганнан туганнары Константин һәм Иван Борисович Мещерскийлар белән элекке үз биләмәләрен Мәскәүнең бөек кенәзе Өченче Иван тәкъдим иткән вотчиналарга алыштырып, шунда күченә. Шул вакыттан аларның Мәскәү дәүләтенә хезмәт итү чоры башлана. Бу кенәзлекнең төрле төбәгендә Юрий Семёнович оныкларының воевода булып хезмәт итүләре мәгълүм. Григорий Дмитриевич Мещерский 1506 елда Казан ханлыгына каршы оештырылган походта Зур полк белән җитәкчелек итә. Константин Борисович Мещерский 1514–1520 елларда Мещерада, аннары Костромада воевода булып тора. Григорий Дмитриевичның ике энесе аерым буын булып аерылалар: Василие – кенәз Киясларның, ә Михаилы Висковатый кенәзләрнең шәҗәрәсен башлап җибәрәчәкләр. Димәк, элекке мишәр җирләреннән чыккан бәк-морзалардан Рәсәйнең «природный кенәзләр» исемлегенә кертелерлек өч кенәз токымы барлыкка килгән. Боларның өчесенең

дә уллары ул чорда югары хәрби чинда булалар: төрле төбәк шәһәрләренең башлыклары – воеводалар саналалар. (Башлыча Мәскәү белән Казан ханлыгы аралыгындагы төбәкләрдә.) Алдарак телгә алынган кенәз Иван Борисовичның оныгының улы – Григорий Фёдорович Мещерскийның Казанны яулау сугышларында актив катнашуы, аннары 1556 елгача Свияжскида воевода булганлыгы мәгълүм.

Соңрак та Мещерскийлар төрле яу-сугышларда актив катнашалар. Михаил Романов патшалык иткән чорда алар токымыннан җиде кеше зур кала-биләмәләрдә воевода булып исәпләнә. Иван Борисович Мещерский варисларыннан булган дүртесе: Богдан Матвеевич – Острог шәһәре воеводасы (1626), Булат Михайлович – Бежескида башлык, Иван Афанасьевич – Торопец шәһәрендә һәм соңрак Мәскәүнең бер өлешендә 1624 елдан шундый ук түрә. Никифор Яковлевич Серпуховта (1616) һәм Тулада (1624) воевода була. Никифор Фёдорович Мещерский 1611 елда, Новгородта воевода булганда, шведларга каршы нык тора, тик соңрак әсир ителә. Шуннан котылгач та, берничә шәһәрдә, шул исәптән берничә чик буе калаларында воевода була, шунда 1652 елда вафат та. Семён Фёдорович Мещерский Беренче Пётр заманында батырлыгы белән танылган полковник; ул Анна Иоановна патша вакытында генерал-поручик чинында вафат була (1732). Улы Григорий Семёнович Елизавета патшалык иткәндә генерал-поручик дәрәҗәсенә ирешә. Шул ук дәвердә һәм шул ук генерал-поручик чинында Фёдор Васильевич Мещерский да мәгълүм (үлеме – 1756 ел). Аның кызы, княгиня Наталья Фёдоровна шулай ук татарга бәйләнеше булган нәселдән чыккан Николай Иванович Неплюевка кияүгә чыга.

Н. И. Неплюев баштарак Төркиядә ундүрт ел илче, соңрак Оренбург губернасын оештыручы губернатор була. Аның төп чыгышы бу китапта теркәлмәгән булса да, төрки нәселгә бәйләнеше булганлыгы башка чыганакларда әйтелә. Хәер, Төркиядә илче вазифасын үтәүчеләрнең күпчелегенең шәҗәрәсе шундый булган ич. Булачак генералиссимус Михаил Кутузовның да хезмәт юлын Төркиядән башлаганлыгы мәгълүм. Н. И. Неплюевның төрки халыкларның гореф-гадәтен, телен яхшы белүе Оренбург губернасына кагылышлы язмаларда теркәлгән. Шунысын да искә алып үтик: шушы ук китапта төрки-татардан чыккан күпчелек граф, кенәзләрнең үзара кыз алышып, тәмам туганлашып беткәнлеген дә чамаларга була.

Мещерский кенәзләр токымы да татар бәк, морзалардан күтәрелгән Карамзин һәм Чернышевлар, мәгълүм Татищевлар, Апраксин һәм Строгановлар белән аралашып бетәчәк. Бүген без алар биографиясендә, алар канында да күпмедер күләмдә безнең милләт өлеше барлыгын танырга хаклыбыз. Ә Кырым ханнары нәселенә ни дәрәҗәдәдер бәйләнеше булган дип фаразланган

Кочубей кенәз варисларының атаклы Толстой графлар белән кодалык кылу мисаллары рус тарихчыларының башка шәҗәрә китапларында теркәлгән. Гадәттә, андый шәҗәрәлекләрне русча сөйләмдә еш кына «бархатная книга» дип атыйлар.

## Урусов кенәзләр токымы

Урусов кенәзләр токымы шәҗәрәсе Алтын Урда ханнары һәм әмир Аксак Тимер яраннарына барып тоташа. Шәҗәрәләренең башы Батый хан оныклары чорына туры килә. Батый оныгы Мәңге Тимер ханны Тудай Мәңге үтереп хан була. Ләкин тәхеттә озак утырмый, аны үтерелүченең улы, соңыннан үзе кыпчаклар ханы булган Тукта юк итә. Туктага каршы Мәңге Тимернең туганнары Талабуга белән Акбуга каршы чыгалар. Тукта Талабуганы, ә аның гаскәр башлыгы Нугай икенче туган көчләрен җиңәләр. Нугай бәк соңрак, зур көч-куәткә ия булып, Тукта ханга (1290–1315) да буйсынмый башлый. Оста гаскәр башлыклары Мамай белән Идегәй дә шушы Нугай варисларыннан була, диелә бу китапта. Мангыт ыруыннан чыккан Идегәй баштарак Аксак Тимер гаскәренең әйдәп баручыларының берсе булган. Соңыннан Алтын Урда тәхетен дә яулап алып, үзенә буйсынучан кешене хан итеп тәгаенләгәне мәгълүм. Менә шушы Идегәй варисларыннан була да инде Урусов кенәзләр («История родов…», 400–404 б.).

*«Урусов» фамилиясенең килеп чыгышы әлегә төрлечә аңлатыла. Хәзерге заманның кайбер галимнәре аны «рус» төшенчәсенә бәйләп тә аңлатмакчы була. Татар сөйләмендә инде ул русча фамилияне борынгы төркичә бәхет мәгънәсендә булган «ырыс» сүзеннән киләдер диючеләр дә бар. Әйтик, безгә якын кардәш казахларда бүген дә Ырысбәк, Ырысбай исемнәре кулланышта йөри. Каракалпаклар телендә бу сүз хәзер дә кулланышта. Урусов фамилиясенең шулай ук Арыслан-Арслан исеменнән үзгәртелгән булуы да бик мөмкин. Бу очракта, мөгаен, шулай булгандыр да.*

Нугай Урдасы дәүләтен нигезләүгә өлеше кергән Идегәй бәкнең ике варисы була: Нуретдин белән Мансур. Нуретдин морза бөек кенәз Василий Тёмный чорынача яши бугай. Ә аның өлкән улы Аказ бөек кенәз Иван III нең замандашы санала.

*Русча язылыштагы бу исемнең дә төрки-татарча үз варианты булырга тиеш. Әмма әлегә аны бүгенге чор кулланышындагы татарча бер исем белән дә тәңгәлләштереп булмый бугай. Бәлки, ул исем түгел, кушамат кына булгандыр. Яки рус елъязмачылары аны шулай бозып язганнардыр.*

Мангыт ыруы морзасы Аказның өч улы: Муса, Ямгырҗы һәм Арслан морзалар – XVI гасыр кешеләре. Муса Рәсәй ватандашлыгын алмаса да, даими рәвештә аралашып, рус дәүләтенә

дус булып яши. Мусаның сигез улыннан өченчесе, Җаекның аскы агымы һәм Каспий төбәкләрен биләүчесе, Иван Грозныйның атасы Василий кенәз заманыннан ук Мәскәү кенәзлеге белән сәүдә итеп һәм даими рәвештә булышып яшәүчесенең исеме Котым була. (Бу исемнең дә татарча язылышын ачыклый алмадым.) Котым морзаны Мәскәүгә Австрия вәкиле буларак килгән Сигизмунд Герберштейн да истәлекләрендә телгә ала. (Мөгаен, бу морза нәкъ шул елларда Мәскәү кенәзлегенә күчкән булгандыр.) Шушы Котым варисларыннан Рәсәйдә кенәз Котымовлар шәҗәрәсе башлана. Мусаның бишенче улы булган Йосыф морза токымыннан исә соңрак кенәз Йосыповлар нәселе китә. (Йосыф – Сөембикә ханбикәнең атасы.) Мусаның җиденче улы Шәйдәк морза нәселеннән кенәз Шейдаковлар токымы башлана. (Мәскәү дәүләтенең булачак бу кенәзләре берникадәр вакыт әле үз диннәрендә калалар. Бер-ике буыннан соң гына, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, үзләре яшәгән дәүләт диненә күчү хәрәкәте күзәтелә.)

Урусов кенәзләр шәҗәрәсе дә Нуретдин морза оныгы Муса бәк нәселенә бәйле. Мусаның сигезенче улы Исмәгыйль була. (*Исмәгыйль морзаның Сөембикә атасы Йосыф белән үзара килешә алмыйча яшәгәнлекләрен дә искә төшереп китик. Йосыф исә энесенең Мәскәү кенәзлеге белән бик тыгыз элемтәдә булуын, фәкать шулар йогынтысына бирелеп яшәвен өнәп бетермәгән.*) Исмәгыйльнең бердәнбер улының исеме без тикшергән тарих китабында «Уруслан Магмет Айдарович» рәвешендә теркәлгән. (*Бу шәҗәрәдә ул Уруслан Магмет Айдарович дип ялгыш язылгандырмы, әллә соң Исмәгыйльнең икенче аты Айдар булгандырмы – ачыкланмады. Ә бәлки, шушы тарих китабы авторы Исмәгыйльне улы Айдар белән бутагандыр. Уруслан исеме исә Арслан исеменең русча теркәлешедер, мөгаен.*) Шул нугай морзасы да озакламыйча үз кешеләре белән Мәскәү кенәзлегенә буйсына. Борис Годунов патша 1600 елда Касимов шәһәренә кергән җирләрне шушы Уруслан *(Арслан)* Мөхәммәт нәселенә биләмәлеккә бирә. XVI гасыр болганышы барышында үзен Иван Грозный улы дип таныткан «ялган патша» кешеләре тарафыннан Уруслан Мөхәммәт 1610 елда Калуга шәһәрендә үтерелә. Ләкин тиздән тегенең үзен дә яңа кенәзнең оныгы – Ак Арслан улы Пётр Урусов дөмектерә, бабасының үчен ала.

Урусов кенәзләрнең гербы шактый катлаулы: монархия бүреге астындагы калкан җиде өлешкә бүленгән. Дөресрәге, алтыга бүленгән калканның үзәк өлешендә тагын бер квадрат уелган. Шул үзәк калканның җирлеге кызыл һәм урталыкта ярымай тора, ай тирәсендә алты кырлы дүрт йолдыз да бар *(Хәзәр каһанлыгы чорыннан килгән, яһүдиләр динен кабул иткән төркиләр билгесе)*. Ай да, йолдызлар да алтын төсендә. Алты бүлемтәнең сулдан беренчесендә – күк төсендәге җирлек, анда кулына

ук тотып, ак атта чабып баручы җайдак; икенчесендә – көмеш төсендәге җирлектә кулына бөркет тоткан татар кешесе сурәте; өченчесенең җирлеге алтын, анда – угы өскә каратылган уклы җәя; дүртенчесендә – яшел җирлектә басып торган алтын төсендәге арыслан сурәте; бишенчесендә – күксел җирлектә канатлы юха елан сурәте; алтынчыда исә – алтын җирлектә сарык тәкәсе рәсеме. *(Күренә ки, бу кенәзләрнең гербында бер генә дә Рәсәй тамгасы юк диярлек, барлык гербларга хас Мономах бүреген һәм калкан мәйданнарын куеныча сыендырган, ас мехыннан тегелгән тун сурәтен исәпләмәсәң. Димәк, бу нәсел дә үзенең шәҗәрәсе Хәзәр каһанлыгы чорыннан ук башланган булуын күрсәтмәкче.)*

Уруслан Магмет *(Арслан Мөхәммәт)* морзаның алты улы булган: Каһан, Ак Арслан, Сатый, Байтирәк, Касыйм һәм Көбеш. Шулардан беренче өчесе Урусов кенәзләр булып китәләр. Ә Байтирәк морза озакламыйча үзенең Байтирәков кенәзләр нәселен булдырачак. Һәм бу Байтирәков кенәзләр дә, тагын бер дистә чамасы татар исем-фамилияле кенәзләр кебек үк, Иван Грозный заманында төзелгән шәҗәрәгә – «Степенная книга»га да кергәннәр.

«История родов русского дворянства» китабында Арслан Мөхәммәд улы Каһанның дүрт улы булуы күрсәтелә: Курмыш, Яндан, Бәй һәм Арслан. Курмыш морза берара патша хезмәтендә булып, үзенең өч мең чамалы гаскәре белән 1626 елда Әстерхан шәһәре сагында торса да, динен алыштырмый. Шунлыктан варислары да мәгълүм түгел. Яндан (*бәлки, Җандай исемле булгандыр*) морза, чукынгач, Борис исемен ала, Мәскәү княгиня Татьяна Ахамушокова-Черкасскаяга өйләнә. Ләкин варислар калдырмыйча 1620 елда үлә. Хатыны шуннан соң монастырьга китә, шунда озак кына яшәп үлә (1646). *(Черкес кенәзләрнең дә яңарак чукынган Кавказ төбәге вәкилләре булуы аңлашыладыр. Иван Грозныйның бер хатыны да шул нәселдән була.)*

Бәй морза, чукынгач, Пётр Канмурзич булып китә, патша Михаил Фёдорович Романов чорында стольник дәрәҗәсенә күтәрелә, патшаның икенче өйләнүе вакытында (1626) озатып йөрүчеләр арасында була. Арслан морза хакында хәбәребез юк. Мөгаен, ул да мөселман динендә калгандыр.

Ак Арсланның сигез улы туа, шуларның өчесе христиан диненә күчә. Урак улы Пётр Арсланович Урусов буларак мәгълүм, Зарбәк – Александр Арслановичка әверелә һәм исәп буенча дүртенче морза Янсох исә Иван Арсланович Урусов исем-фамилиясен ала.

Монда Арслан Мөхәммәт улы Сатый морза варисы Касыймны искә алу да кирәк. Чукынгач, ул Андрей Сатыевич Урусов булып язылa. Рәсәй күләмендә танылган Урусов кенәзләр башлыча шушы Андрей Сатыевич варислары санала. Чөнки Пётр Арсла-

новичның бердәнбер улы кенәз Василий Петрович Урысов нәсел калдырмый. Фёдор Алексеевич патшалык иткәндә, ул стольник дәрәҗәсенә ирешә, княгиня Степанида Репнинага өйләнгән була. Ләкин нәселне дәвам итәрдәй уллары булмый. *(«Стольник» дип патша сараенда хезмәт итүче, патша катнашында уздырылган чараларны оештыручы түрә аталган.)*

Сатый морзаның кенәз Андрей Сатыевичтан башка да уллары була. Шулардан Гали Сатеевич, Йоныс һәм Сөенче Сатеевич исемнәре Михаил Фёдорович һәм Алексей Михайловичлар патшалык иткән заманда боярлар кенәгәсендә стольник һәм башка хезмәт башкаручылар исемлегендә теркәлгәннәр. *(Алар, мөгаен, чукынмагандыр, шунлыктан варислары теркәлмәгән.)*

Андрей Сатыевич Урусов берничә ел Нижний Новгород воеводасы булып тора, 1647 елда Мәскәүдә үлә. Аның улы Семён Урусов Литва белән сугыш чорында дан казана һәм Брест каласында Литва кенәзе Сапеганы 1655 елда әсир итә. Ике елдан соң үлә, дүрт улы кала, дүртесе дә бояр дәрәҗәсендә булалар. Бер улы – Пётр Семёнович Урусов Степанида Строгановага өйләнә, 1686 елда нәсел калдырмыйча вафат була. Минзәләдә воевода булган Юрий Семёнович та 1684 елда нәсел калдырмыйча үлә. Дүртенче улы Фёдор 1681 елда боярлыкка билгеләнә, 1684 елдан Новгород воеводасы вазифасын үти, аннары кабат Мәскәүгә алына, Тупчылар приказы башлыгы була. Аңардан бер кыз кала – княгиня Мария Фёдоровна Урусова. Ул кыз Пётр патшаның Голландиядәге илчесе кенәз Борис Куракинга кияүгә бирелә.

1679 елда бояр итеп билгеләнгән кенәз Никита Семёнович Новгород воеводасы була. Княгиня Евфимия Щербатова белән икесенең биш улы туа. Беренче Пётр патша стольнигы Алексей Никитович Урусовның өч улы була. Кенәз, генерал-поручик Григорий Урусов 1743 елда үлә, ике ул һәм ике кыз калдыра. Кызлары Щербатов белән Гагарин кенәзләргә кияүгә чыккан. Василий Алексеевич Урусов княгиня Прасковья Долгоруковага өйләнә, аның варисларыннан улы Сергей Васильевич һәм кызы Екатерина Урусова. Сергей Васильевич Урусов 1787 елда үлә. Аның улы Дмитрийдан ике оныгы туа. Сенатор Никита Сергеевичның шулай ук бер улы – Сергей Никитович Урусов туа. Ә кызы генерал С. Е. Батуринга кияүгә бирелә. Генерал-майор, кенәз Александр Васильевич Урусов Анна Волковага өйләнгән була, кызлары Софьяны гофмаршал барон А. С. Строгановка ярәшәләр.

Полковник Алексей Васильевич Урусов графиня Екатерина Шереметьевага өйләнгән. Аларның Василий исемле уллары һәм ике кызлары – Анна белән Варвара туалар. Үз чиратында Василий Алексеевичның дүрт улы: Алексей, Александр, Николай һәм Пётр кенәз Урусовлар туа. Аларның дәвамчы токымы барланмаган.

Кенәз Михаил Васильевич Урусов дворянка Алябьевага өйләнгән була. Ул – булачак обер-камергер һәм Дәүләт советы әгъзасы кенәз Александр Михайловичның атасы. Александр Урусов Екатерина Татищевага өйләнә, аларның сигез уллары туа. Шуларның өлкәне, генерал-лейтенант кенәз Михаил Урусов Нижний Новгородта губернатор, соңрак сенатор була.

Өченче туганнары кенәз Павел Александрович Урусов затлы токымнан булган Александра Уваровага өйләнә, хәрби хезмәттә генерал дәрәҗәсенә ирешә. Алтынчы туганнары Пётр Александрович патша карамагында зур дәрәҗәле камергер була. Кыз туганнарыннан Мария Александровна беренче мәртәбә Иван Мусин-Пушкинга, икенчесендә кенәз Александр Горчаковка кияүгә чыга. Княгиня Софья Александровна кенәз Леопольд Радзивил белән ярәштерелә. Аларның кече кызлары Наталья граф Ипполит Кутайсовка кияүгә бирелә.

Василий Александрович улы кенәз Пётр Урусов Александра Салтыковага өйләнгән була, аларның ике кызы һәм генерал-майор дәрәҗәсенә ирешәчәк уллары туа.

Икенче тармак Урусовлар шәҗәрәсенә күчсәк, боярин Никита Семёновичның улы Семён туа, дип әйтелгән иде. Семён Беренче Пётр патша фельдмаршалы граф Борис Шереметьевның өлкән кызы Софьяга өйләнгән. *(Кайбер мәгълүматларга караганда, Шереметьевлар да тумышлары белән татар токымыннан һәм, имештер, чукынгач та әле дистә еллар буе өйләрендә мөселман динен тотканнар. Шул максат өчен затлы йорт- сарайларында махсус яшерен бүмәләре дә булган икән. А. Н. Радищев биографиясен барлаучы галимнәр дә «чукынгач та алар үз диннәрен дә тотканнар» дип язалар.)* Боларның ике улы туа, шулардан кечесе Михаилдан нәсел калмый. Василийдан өч ул туа: Сергей, Николай һәм Юрий Васильевич Урусовлар. Сергейның ике кызы һәм нәселсез улы Никита була. Бу җәһәттән кенәз Юрий Васильевич бик бәхетле – аның алты баласыннан өлкәне, генерал-майор кенәз Николай княгиня Хитровага *(шәҗәрә башында шулай ук татар морзасы тора)* өйләнә, аларның ике улы һәм бер кызлары була. Сергей Николаевич Урусов (1816 елгы) – Дәүләт советы әгъзасы, сенатор, император галиҗәнаплары канцеляриясенең II нче бүлеге идарәчесе. Княгиня Елизавета Трубецкаяга өйләнгән.

*Тәрҗемәче өстәмәсе. Нугай Урдасыннан Мәскәү кенәзлегенә күчеп чыккан мәгълүм фамилияләр алтмышка якынлаша. Шулар арасыннан диннәреннән ваз кичмичә генә зур уңышка ирешкәннәре дә байтак булырга тиеш. Әмма алар әле тулаем барланмаган. Шулардан Дәүләт Газый токымы Долотказиннарны, Карамурзин, Еналиев, Янышев, Мурзалимов һәм бүтән бәк-морзаларны атарга мөмкин (История родов…, I т., 397–400 б.).*

## Гади казаклыктан түрәгә әверелгән Кочубей кенәзләр

Герблары катлаулы. Төп калкан дүрт өлешкә бүленгән. Иң беренче өске уң кулда, кызыл җирлектә, алтын төсендәге ике грек тәресе һәм алты кырлы *(төрки)* йолдыз белән янәшә ярымай *(болар да алтыннан).* Икенче һәм дүртенче бүлектә – Кочубейларга Беренче Пётр патша тарафыннан тәкъдим ителгән билге – йөрәк сурәте эченә алынган ике янәшә тәре. Бу ике бүлекчәнең җирлеге күк төстә, йөрәк сурәте җете кызыл, тәреләр алтыннан. Өченче бүлекчәнең җирлеге шулай ук кызыл, бүлекчәнең урталыгында көмештән бөркет канаты *(парлы),* аның өстендә алтыннан учак күренеше, иң аста – күтәрелеп килүче бал корты, алтын төсендә. Калканның сул ягында – сул «кулына» буздыхан *(Кече Русия гетманнары булавасы)* тоткан арыслан тора. Уң тарафта калканга уң кулын куеп украина казагы басып тора. Билендә кылычы, сул кулында – гаскәри байрак. Байрак уртасында – кылыч сурәте, кылычның як-ягында – ике ярымай. Калканның дүрт бүлемтеге бергә тоташкан урында Рәсәй патшалары гербы белән уратып алынган җирлеккә «Н» хәрефе чигелгән. Бу инде кенәзлекне раслаучы патша исеменең баш хәрефенә ишарә. Калкан астында шәҗәрә башлыгы исеменә Пётр I тарафыннан әйтелгән мактау сүзләренең латинча язылышы.

Күренгәнчә, бу герб Кочубейлар шәҗәрәсенең барлык чорын, барлык үзгәреш-борылышларын эченә алган. Рәсәйгә керү дәверендә генә дә Кочубейларга өч мәртәбә шушындый үзбилгеләр бирелгән. Беренчесе, гади дворянлык билгесе, аларга Пётр патша тарафыннан бирелә. Император Павел I заманында, Рәсәйдә илле өченче кеше буларак Виктор Павлович Кочубей граф дәрәҗәсенә күтәрелә (1799, 4 апрель). Аннары император Николай I аны, Рәсәй тарихында уникенче кеше буларак, токымлы кенәз итә *(ягъни кенәзлек дәрәҗәсе барлык ир һәм кыз варисларына күчә торган боерык бирә).* Бу хәл 1831 елда, 6 декабрь указында билгеләнә.

Кече Русия гетманнары тирәсендә пәйда булганчы Кочубейлар Киев кенәзлегенең көньягында *(Кырым ханлыгының төньяк тарафында),* Днестр елгасы буйларында тормыш иткәннәр булса кирәк. Шәҗәрә башларында төрки бәкләр торган. 1787 елда Варшавада басылып чыккан һәм Таврия төбәге тарихына караган бер хезмәтнең 83 нче битендә мондый юллар язылган: Ольгерд *(Литва һәм Киев кенәзлекләренең бөек кенәзе)* туганы Кориятның уллары белән Подолиягә һөҗүм оештыра. Бу гаскәр дала ягы бәрелешендә татарларның өч чирүен тар-мар итә. Ул урда-төркемнәр башында Квятубаха, Кочубей *(Кече бәй)* һәм Дымейтек торган (XIV йөз), диелә.

Шул Кочубей бәй токымыннан берәү XVII гасыр тирәләрендә Кече Русия (Украина) казаклары ягына чыга.

*Төрки дөнья тарихында казакка чыгу мисаллары бик күп. Әйтик, булачак әмир Аксак Тимер дә, атасы үлеп, үзенә тигән биләмә өлешеннән беркадәр читләштерелгәч, казак булып китә. Ягъни, тәхет-түрәлектә утырган агай-энегә буйсынмыйча, алар биләмәсенә барымта (барып талау) оештыргалап, яу чапкалап берничә ел йөри. Үз тирәсенә ишле генә гаскәр туплаганның соңында гына берәм-берәм тәхетләр яуларга керешә. Аксак Тимер оныгы Заһретдин Бабыр белән дә шундый ук хәл кабатлана. Ул да яшүсмер чагында агалары тарафыннан кыерсытыла һәм биләмәсез кала. Берничә ел «казаклык»та йөргәч, көч-куәт туплагач, туган-үскән төбәге Фирганәдән китеп, Әфганстан ханлыгы тәхетен яулап ала. Киев кенәзлегенең көньяк өлешендә, Днепр «бусагалары» төбәгендә оешкан, «Запорожье казаклары» дип тарихка кергән казаклар да башлыча төркиләрдән торган. Төркия солтанының аларны акылга килергә өндәп хат язуы да шул фикерне раслый. Боларның башка төбәк казакларыннан төп аермалык билгесе булган баш түбәсендәге бер учма чәч тә («запорожский чуб») төркилектән килгән бер йола. Каракалпакларга хас йола. Рус елъязмаларындагы «чёрные клобуки»лар – баш түбәсендә кара чәч бәйләме йөртүчеләр ул чорда Днепр тирәләрендә ишле булган. Мөгаен, алар бу якларга Атилла, Аспарухлар чорында ук килеп төпләнгән булганнардыр. Кочубәй кенәзнең дә, китап авторлары фаразлаганча, Кырым татары булмыйча, Рәсәй тарихында «чёрные клобуки» рәвешендә теркәлгән бер урда вәкиле булуы бик ихтимал.*

*Шушы төбәктә тупланган болгар, кыпчак һәм каракалпакларның бер өлеше христиан диненең Кече Азиядә һәм Кавказда таралган мәзһәбен – несториан динен үз итүе сәбәпле, алар Кырым һәм башка ханлыкларның бер читендәрәк торып кала. Шул ук вакытта алар баштарак Киев кенәзләре тарафдары да булып бетми – ике чик арасында калып, ике як биләмәләрен дә талап көн күрәләр. Алар төркеменә кырым ханлыгы ягыннан да, урыс-малорус биләмәләреннән дә канәгатьсезләр килеп кушыла тора. Шул рәвешле Днепр бусагалары буендагы казаклар саны арта. Димәк, Кочубей бәк токымыннан да кемдер, үз яраннары һәм якыннары белән араны өзгәч, әлеге казаклар төркеменә килеп кушылгандыр.*

Казак булып киткән Кочубей, чукынганнан соң, Андрей исемен ала. *(Запорожье казаклары тарихын яхшы белгән һәм хәтта бу хакта ярым фәнни бер әсәр дә язган Н. В. Гоголь «Тарас Бульба» романында тәгаен шушы Андрей язмышын да күз уңында тоткандыр кебек.)* Андрейның улы Леонтий тиздән гетман Хмельницкий гаскәрендә уң кул ярдәмчегә әверелә – зур дәрәҗәгә ирешә. 1650 еллар тирәсендә Леонтийның улы Василий туа. Гетман шушы яшь Кочубейны *(тел белүен дә истә тотып*

*булса кирәк)* 1675 елда Әдернәгә төрекләр белән килешү төзергә җибәрә. Шуннан соң Василий Кочубейның 1687 елларда гетман Мазепаның уң кулы – баш кятибе булганлыгы мәгълүм. Аннары ул 1694 елда баш казый итеп билгеләнә. 1700 елда Василий Кочубей Рәсәй ягына авыша, Пётр I тарафыннан стольник чинында раслана. Нәкъ шул вакытта Кече Рәсәй гетманы Мазепа белән Кочубейлар гаиләсе арасында ара бозыла. *(Бу хәл А. С. Пушкинның мәгълүм поэмасында да тасвир ителә; әшнәсенең яшүсмер кызын Мазепа үзенә карата.)* Шул вакыйгалардан соң Кочубей гетманның кырын эшләре, Рәсәй тәхетенә карата хыянәтчел адымнары турында Пётр патша ярдәмчеләренә хәбәр иткәли башлый. Ләкин патша станындагы түрәләр аны дөрес аңлап бетермиләр. Ә гетман Мазепа яклылары тиздән бу хакта патшага да сиздерәләр. Шуның нәтиҗәсендә Василий Кочубей кулга алына һәм каты җәзалаулардан соң, 1708 елның 14 июлендә Белая Церковь каласы тирәсендәге бер авылда үтерелә. Тик берникадәр вакыт үткәч кенә Мәскәүдә Кочубейның хак булуына, аның ялгыш җәзаланганлыгына төшенәләр, үкенәләр. Үтерелгән стольникның хатынына һәм балаларына тартып алынган җир биләмәләре һәм авыллары кире кайтарыла. Пётр патша аның хакында «Үлеме белән бөеклеген раслаган инсан» дигән мәгънәдәге латин мәкален әйтә. Шул җөмлә соңрак Кочубейлар гербында да теркәләчәк.

Үтерелгән Кочубейның Василий һәм Фёдор исемле ике улы һәм ике кызы кала. Анна – Ободовскийга кияүгә чыга, ә Мазепаның элекке сөяркәсе Матрёна гетманның баш кятибе Чуйкевичка ярәшелә. Василий Васильевич Кочубей яңадан хезмәтен Полтава полкында полковник дәрәҗәсендә дәвам иттерә. Аның өч улы үсә: Семён, Василий һәм Павел. Семён Васильевич Кочубей Кече Русия гаскәрендә баш обозчы һәм баш тупчы дәрәҗәсендә хезмәт итә, Кече Русия белән идарәчеләр коллегиясенә керә. Аның кызы Надежда полковник Потёмкинда кияүдә була. Улы Михаил Рәсәйдә «действительный статский советник» дәрәҗәсенә ирешә.

Кочубейлар токымындагы өченче Василий *(җәзалап үтерелүченең оныгы)* гетман Разумовский туганының кызына – Марфа Оболенскаяга өйләнә. Бу Василийның токымы бик ишле: аларның дүрт улы һәм бер кызлары туа. Өлкән уллары Василий хезмәт юлын «тайный советник» дәрәҗәсендә тәмамлый.

Василий Васильевич Кочубей белән Туманскаядан туган Демьян Рәсәйдә хакыйкый яшерен советник дәрәҗәсендә була, Дәүләт советы әгъзасы итеп билгеләнә. Аның энесе Александр Кочубей да император җәнаплары җитәкчелегендәге Дәүләт советы әгъзасы дәрәҗәсенә ирешә. Кече энеләре Аркадий Кочубей сенатор була. Аның өч улы туа: Михаил, Василий, Николай. Василий Аркадьевич Кочубей княгиня Наталья Салтыковага, ә Николай Аркадьевич исә графиня Столыпинага өйләнә. *(Салтык кенәз*

*белән Столыпин граф токымнарының башында кемнәр торганы аңлашыладыр, шәт.)*

Пётр I заманы стольнигы Василий Леонтьевичның кече оныгы Павел Васильевич – Кочубейларның Рәсәй дәүләте хезмәтендәге икенче тармагы башында тора. Павел Васильевич Кече Рәсәйнең баш казые, мәгълүм Андрей Яковлевич Безбородко кызы Ульянага өйләнгән була. Дәүләт эшендә үзе статский советник дәрәҗәсенә ирешә. Аларның ике кызы була. Өлкән уллары Аполлон Павлович Кочубей император галиҗәнапларының камергеры хезмәтен башкара.

Бу токымның иң күренекле шәхесе Виктор Павлович Кочубейны Әби патша егерме дүрт яшендә Төркиягә илче итеп җибәрә. 1798 елда исә император Павел I сәләтле яшь Кочубейны вице-канцлер итеп күтәрә. Өченче император – Александр I исә Виктор Павловичны эчке эшләр министры итеп билгели. Ул Дәүләт Советы әгъзалыгына да билгеләнә.

Император Николай I заманында Виктор Павлович Кочубей Дәүләт Советы рәисе һәм канцлер дәрәҗәләренә күтәрелә. 1831 ел 6 декабрь указы белән ул Рәсәйдә мөмкин булган иң югары хөрмәткә лаек – «нәселле кенәз» исемен ала. Ягъни Рюрик, Мономах, Долгорукийлар токымыннан ук килүче «табигый кенәз»ләр белән тиңләшә.

Виктор Павлович Кочубейның бер кызы һәм дүрт улы туа. Өлкәне – действительный статский советник Лев Викторович – Елизавета Васильевна Кочубейга, камергер Василий Викторович – княгиня Елена Бибиковага, гофмаршал Михаил Викторович княгиня Мария Барятинскаяга өйләнәләр. Сергей Викторович действительный статский советник, Полтава губернасы дворяннары башлыгы була, граф Бенкендорф кызы Софьяга өйләнә. Наталья Викторовна Кочубей граф Александр Строгановка кияүгә чыга. *(Бу күренекле сәүдәгәр һәм промышленникларның да бабалары татар токымыннан була.)*

Кочубейларның бу тармагыннан XIX гасыр азагында фәкать канцлерның улы кенәз Сергей Кочубей гына токымны дәвам иттерә – аның ике улы була. (История родов…, II т., 26–29 б.)

### Йосыпов (Юсупов) кенәзләр

*Нугай Урдасы башлыгы Муса бәк токымыннан килгән Урусов кенәзләргә багышлы бүлектә әйтеп кителгәнчә, Юсупов кенәзләрнең шәҗәрәсе дә шушы шәхескә бәйле. Йосыф морза Муса бәкнең бишенче улы була. (Атасы Мусадан соң биш ел Нугай Урдасы башлыгы – бәк булып торачак. 1554 елда, энесе Исмәгыйль белән килешә алмыйча, аның тарафыннан үтереләчәк. Татар энциклопедиясе, 2 т., 645 б. ). Казан ханлыгы вакыйгаларына бәйле рәвештә, Йосыф бәкнең патша Иван Грозныйга илчеләр җибәреп, хатлар язышып торганлыгы мәгъ-*

*лүм. Аның абыйсы Җанмөхәммәд Казанда яшәгән. Сөембикәне Җангали ханга ярәшү вакыйгаларында димче була (1533 ел), диелә шул ук энциклопедиядә. Йосыфның улы Юныс Сөембикәнең икенче ире Сафагәрәйне Казан тәхетенә кабат тәгаенләү сугышында Нугай Урдасы гаскәре башлыгы буларак катнаша. Аннары ул яңа ярәшкән иренең килеп алырын ярты ел чамасы көткән Сөембикәне Казанга китереп бирүче дә була. Сафагәрәй кинәт вафат булгач та (1549 ел) аның, сеңлесенә булышыр өчен дип, Казанга килгәнлеге мәгълүм. Ләкин утлы коралдан атып, аны шәһәргә кертмәүләре бәян ителә. Ханлыкта баш булып калган Кушчак бәк аның килүен теләмәгәндер инде. 1552 елда Казан камалышта калгач та Йосыф бәк казанлыларга ярдәмгә өченче улы Галиәкрам җитәкчелегендә гаскәри берәмлек җибәргән. «История родов...» китабында Йосыф бәкнең бу уллары теркәлмәгән.*

Йосыф бәк вафат булганда ике улы – Илморза белән Ибраһим кала, диелә китапта. Илморзаның да ике улы – Чынморза белән Сөюшморза була. Ибраһимнан бердәнбер ул – Сөюшморза кала. Менә шушы морзалар варислары, Мәскәү кенәзлеге тарафына елышып, Рәсәйнең атаклы Юсупов кенәзләр нәселен башлап җибәрәчәк тә. Илморза улы Сөюшнең биш улы була. Шулардан иң кечесе Габдулла иң элек яңа динне кабул итә, Дмитрий Сеюшевич булып языла. Сөюшморза улы Иштирәк нәселеннән булган кенәз Иван Магмет Иштиряковның Михаил Романов патша чорында (1636–1640) зур дәрәҗәле стольник вазифасын үтәгәнлеге теркәлгән. *(Муса бәк нәселе вәкилләренең капылт кына Рәсәй тарафына тартылу сәбәпләре бу китапта да, башка чыганакларда да аңлатылмый. Ике улының варислары нигезләгән Урусов белән Юсупов кенәзләрнең яңа империядә зур дәрәҗәләргә ирешүе хак.)*

Ибраһим улы Сөюшморза балалары да христиан диненә күчә. Сөюшнең дүрт улы да шул динне кабул иткән. Әмма кенәз Юсуповлар нәселеннән иң танылганнары Йосыф улы Илморзадан килә. Илморза улы Сөюш, аның улы Дмитрий Сеюшевич була. Дмитрийның өч улы: Иван, Матвей һәм Григорий кенәзләр. Григорийның өч улы һәм кызы Марфа туа. Марфа патшабикә Екатерина I сараенда хезмәт итә. Өлкән улы Борис Григорьевич (1696–1759) патшабикә Анна Иоановна чорында Мәскәү губернаторы булып тора, Елизавета Петровна чорында исә Коммерц-коллегия президенты һәм сенатор вазифаларын үти. Кадетлар корпусларында укучы дворян балалары фәннәрне фәкать рус телендә үзләштерергә тиеш дигән карарны тәкъдим итүче дә ул була. Бу гаиләдә бер ул һәм дүрт кыз туа. Кызларның барысы да кенәз дәрәҗәсендәге кияүләргә бирелә. Уллары Николай патшабикә Екатерина II идарә иткәндә Турин шәһәренә (Италия) илче итеп җибәрелә. Павел I патша чорында җир биләмәләре министры була. Ул патша улы Александр I заманында яңа оеш-

тырылган Дәүләт Советы әгъзасы итеп билгеләнә. Берара Эрмитаж директоры вазифасын да үти. Аның заманында төзелгән Архангельское алпавыт утары үзенчәлекле архитектурасы һәм Италиядән кайтарылган кыйммәтле җиһазлары белән бүген дә бик күп туристларны үзенә җәлеп итә.

Николай Борисовичның ике улының берсе яшьли үлә. Икенчесе – Борис Николаевич Юсупов патша сараенда 2 нче дәрәҗәле түрә – гофмейстер була. Берара Император сараендагы китапханә директоры вазифасын да үти.

XIX гасырның соңгы чирегендә кенәз Юсуповларның нәсел шәҗәрәсен дәвам итәрдәй ир заты калмый. Бу кенәзләрнең Рәсәй тарихында зур урын биләгәнлеген истә тотып, император Александр III 1885 елның июлендә соңгы кенәздән туган кыз варисына шушы дәрәҗәле шәҗәрәне дәвам итү мөмкинлеген бирүче карар чыгара. Шул рәвешле әлеге кызның ире Сумароковтан туган малае Феликс кенәз Юсупов-Сумароков буларак династияне дәвам итәчәк. Ә киләсе гасыр башында бу кенәз Феликс Юсупов-Сумароков, император Николай II нең кыз туганына өйләнеп, тулаем «патша сарае» кешесенә әвереләчәк.

Кенәз Юсуповларның герблары үзәгендә шулай ук ярымай сурәте һәм ай тирәли урнашкан алты кырлы дүрт йолдыз булган. Сулдагы беренче яшел төстәге бүлектә – кылычын күтәреп, ак ат өстендә җилдереп баручы сугышчы сурәте, аңа капма-каршы якта, алтын төсендәге җирлектә – уң кулы белән чүкеч күтәреп торучы озын халат кигән кеше сурәте. Сул яктагы күксел җирлектә – өскә юнәлдерелгән алтын төстәге уклы җәя. Чүкеч тоткан кеше һәм уклы җәя астындагы көмеш төсле җирлекләрдә берәр арыслан сурәте төшерелгән. Уң якта, иң астагы күк төсендәге мәйданда уң тарафка чабып баручы алтын төсле болан рәсеме күренә. Үзәктәге яшкелт төстәге түгәрәк мәйданчыктагы ай да, алты кырлы йолдызлар да көмеш төсенә буялган. Җиде бүлектән торган бу түгәрәк калканны ике яктан ике арыслан тотып тора. Шулар өстенә тун салынган.

Шушы ук томда танылган кенәзләр рәтендә морза Енгалычевлар, шәҗәрә башын Молдавия ханы дип таныткан Тимердән килүче Кантемировлар, төньяк Кавказ төбәгеннән чыккан Черкес кенәзләргә багышлы бүлекләр бар. Икенче томда исә кумык токымыннан чыккан кенәз Тарковскийлар турында мәгълүмат тупланган.

*2016*

# ТАРИХ СЕРЛӘРЕН БАРЛАУЧЫ

*(Очерк)*

«Фатих» сүзе гарәпчә сүзлекләрдә «ачучы, башлап җибәрүче, җиңүче» мәгънәләренә ия буларак теркәлгән. Дәүләт һәм җәмәгать эшләрендә үзен күптән таныткан Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинның яңа адымнары, яңа башламнары да аның исеменең җисеменә туры килеп торганлыгын раслый. Табигатьтән килгән холкы һәм тәрбиясе белән ул һәрчак башлап йөрүче, нинди эшкә алынса да, җиңеп чыгучы буларак танылган шәхес иде шул.

Соңгы елларда аның борынгы тарихыбызга багышланган хезмәтләр язарга керешүе күпләр өчен яңалык булды. Басылып чыккан китапларын кулына алган һәркем исә Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинның күптән инде тарих дөньясына кереп киткәнлеген, дистә еллар дәвамында төрки-татарлар тарихын барларга алынуын чамалады. Бик сирәк китапларда теркәлгән, безнең бабаларыбыз тарихын барлау өчен аеруча кыйммәтле булган мәгълүматны туплау җиңел эш түгел. Әйтик, 2008—2009 елларда аның тарафыннан рус телендә нәшер ителгән «От Аттилы до президента» («Атилладан башлап президентка чаклы») дип исемләнгән ике томлы хезмәттә иң борынгы дәверләрдә яшәгән һуннардан башлап яңа эраның урта гасырларында гомер кичергән төрки халыкларның тарихы барлап чыгыла. Беренче томның икенче өлеше тулаем Чыңгызхан төзегән империя, аның оныгы Бату хан тарафыннан оештырылган Алтын Урда дәүләте тарихына караган вакыйгаларны чагылдыра. Китап авторы үз хезмәтләрендә бу дәверләр тарихын барлаганда кайбер тарихчыларның, бигрәк тә рус тарихчыларының күрмичәрәк үтәргә тырышкан, дөресрәге күрмәмешкә, белмәмешкә теләгәнрәк хәл-әхвәлләрне дә үз укучысы алдында ачып салуны максат итеп куйган. Совет хакимияте чорының күпчелек тарихчылары тарафыннан күрмәмешкә, белмәмешкә теләп бәян ителгән яисә булып үткән вакыйгаларны башкачарак аңлатырга тырышкан андый «кара таплар» төрки-татарларга бәйле гыйльми хезмәтләрдә байтак әле. Бу сүзләрне мин яшьтән тарих фәнен үз иткән, шәхси китапханәмнең зур бер өлешен тарихка караган китаплар белән даими рәвештә тулыландырып торырга тырышкан кеше буларак та язам.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин 2012 елда чыгарган өченче китап «Великие татары – строители и защитники Государства Российского» («Бөек татарларның Россия Дәүләтен оештыруга һәм аны саклауга керткән өлеше») дип исемләнгән. Урта гасырлардан, Алтын Урда заманнарыннан бирле хәзерге Россия дәүләте җирлегендә төп халыклардан саналган татарлар белән руслар бергә яши, бергә гомер кичерә. Дистәләгән рус кенәзлекләре арасыннан Мәскәү кенәзлегенең калкып күтәрелеп чыгуында да татарларның тоткан урыны зур булган. Әлеге китапта бу фикерне

дәлилләрдәй бик-бик күп мисаллар китерелә. Аерым шәхесләрдән кала күп кенә рус патшаларының нәсел тамырының татарларга килеп тоташкан булуы да мәгълүм. Киев чоры рус дәүләте оешкан көннәрдән бирле күп кенә идарәче катлам кенәзләренең аналары болгар, кыпчак ханнары нәселеннән булган. Россия тарихында югары дәрәҗәләргә ирешкән, исемнәре зур тарих сәхифәләренә кергән шәхесләрдән Александр Невскийның анасы – кыпчак ханы кызы, Андрей Боголюбскийның анасы да, хатыны да Киев төбәге болгар ханнары нәселеннән була. Безгә якынрак чорда яшәгән, татар милләтенә карата кылган кырын эшләре белән танылганнардан Иван Грозный да, Пётр I патша да – аналары ягыннан татар нәселеннән чыккан затлар. Безнең кулдагы китапта Россиядә өч йөз елдан артыграк дәвердә патшалык иткән Романовларның да татардан чыккан булганлыгы дәлилләп тасвир ителә. Аларның шәҗәрә башында татар бәге – Хәйбулла бәк теркәлгәнлеге шушы хезмәтләрдә дәлилләп китерелә.

1917 елга чаклы югары катлау вәкилләре даирәсенә керүче күп кенә кенәз, граф, бароннарның нәсел гербында ярымайның да урын алганлыгын билгеләп үтә китап авторы. Шул ук исемлеккә әле төрки Хәзәр каһанлыгы дәверенең югары катлавы билгесе булган алты кырлы йолдыз сурәте төшерелгән герб ияләрен дә кушып буладыр. 1886 елда Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» дип исемләнгән рәсми икетомлыкта шәҗәрә гербларына ярымай яисә алты кырлы йолдыз иңдергән «рус дворяннары» исемлеге бик зур. Аларның кайберләре хакында 1990 елларда «Казан утлары» журналында мин язып та чыккан идем. Хәзәр каһанлыгының бәк-морзаларының бер өлеше, яһүдиләр динен кабул иткәч, диннәренә бәйле тамга рәвешендә шул алты кырлы йолдыз сурәтен кулланалар. Шуны да әйтеп китәргә кирәктер: бу катлау вәкилләренең күпчелеге, диннәрен үзгәртсәләр дә, бик күпләре үз ана телләрен саклап калганнар. Һәм кайберләре соңрак мөселман диненә күчкәннәр. Шул сәбәпле аларның гербларында яһүдиләр диненә хас йолдызчык белән янәшәдә мөселманлык тамгасы булган ярымай да күрсәтелгән.

Фатих Сибагатуллинның соңгы китабының төп шигаре, төп лозунгы – бер дәүләттә гомер иткән татар белән рус милләте вәкилләре арасында тарихтан килгән бергәлек, бердәмлек яшәргә тиеш. Ике зур тарихлы милләтнең киләчәк тарихы да бергә үрелеп барырга хаклы. Шул очракта гына ике милләтнең дә киләчәге якты булачак. Ерак бабалар бердәмлеге онытылмаска тиеш. Һәрхәлдә, бу китап белән тиз генә танышып чыккан арада шундый фикергә килдем мин.

Инде Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин уйлап, барлап иҗат иткән китаплар турында башкаларның фикерен дә тыңлыйк.

2013 елның 22 февралендә Татарстан Язучылары берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында Россия Федерациясе Дәүләт думасы депутаты, күренекле дәүләт һәм җәмагать эшлеклесе

Ф. С. Сибагатуллин белән очрашу һәм аның тарих фәненә багышлап нәшер иткән өч китабы белән танышу кичәсе уздырылды. (Соңрак ул тарихи эчтәлекле тагын берничә китап нәшер итте. Шулардан дүртенче китап буларак нәшер ителгән «Татары и евреи» – «Татарлар һәм яһүдиләр»не дә алдарак искә алырбыз.)

Йөзгә якын кеше сыйдырышлы зал очрашуга килгән язучылар, галимнәр һәм тамашачылар белән тулган иде. Өстәмә урындыклар китертеп утыручылар да ишле генә булды.

Очрашуны Татарстан Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре Роберт Миңнуллин ачып җибәрде һәм беренче сүзне әлеге тарихи хезмәтләр авторына бирде. Җыелган тамашачы алдына – сәхнә түренә күтәрелгән Фатих Сәүбән улының ул кичәне башлап әйткән сүзләренең сөземтәсе шулдыр: тарих фәне, бигрәк тә үз милләтенең тарихы белән ул күптәннән бирле кызыксына. Тарихи эчтәлекле китапларны барларга, ял сәгатьләрендә аларны алып укырга ярата. Дистә еллар буладыр инде, ул аларны укып кына калмый, үз күңеленә хуш килгән яисә күңелендә ризасызлык тудырган өлешләрен барлап, аларны аерым туплап бара торган булган икән. Шул рәвешле әлеге китаплар аның тарихи үткәнебез турында уйланулары, борчылулары нәтиҗәсе булып тора. Ул күңелендә йөргән уйларны кәгазьгә күчерү һәм, китап рәвешенә китереп, бастырып чыгару фикеренә килгән. Ә басылып чыккан китапларын күп кешенең кызыксынып укыганлыгын белгәч, үзара фикер алышу өчен берәр җирдә очрашу кирәклеген аңлап, бүгенге кичәне оештыруны да хуплаган.

Татарстанда тарих фәнен үстерүгә зур өлеш керткән галимнәребез дә ишле генә. Ләкин аларның күпчелеге алдына куелган төп таләп – Татарстан җирлегенә бәйле тарихны барлау булды. Альфред Халиков, Индус Таһиров, Сәлам Алишев, Равил Фәхретдинов, Рафаэль Хәкимов, Фаяз Хуҗин, Мирфатыйх Зәкиев, Дамир Исхаков, Әзһар Мөхәммәдиев, Искәндәр Измайлов һ. б. шәхесләребез бар. Әлеге кичә-очрашуда да исәннәреннән берничәсе катнашты. Һәм шулардан тагын берничәсе очрашуга килүчеләргә үз фикерләрен дә җиткерде.

Фатих Сибагатуллинның тарихи эзләнүләрен, рәсми тарих белән шөгыльләнүче галимнәребезнең буе җитенкерәми калган чыганакларны да файдаланып иҗат итүен хуплап чыгыш ясаучы унҗиде кеше булды. Очрашуга билгеләнгән вакыт иркенрәк булса, әле тагын шул чама кешенең чыгып сөйләргә нияте булганлыгы соңрак, үзара гәпләшеп алулардан аңлашыла иде.

Беренче булып сүз алган галим, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Тарих институтының шул еллардагы директоры Рафаэль Хәкимов булды. Иң әүвәл ул тарихи вакыйгаларга багышланган бу китаплар авторының эшчәнлеген хуплады. Киләчәктә дә аның зур иҗади уңышларга ирешүен теләде. Безгә тарихи чынбарлыкны Фатих Сәүбән улыдай төпченеп барлаучы шәхесләр дә, киң җәмәгатьчелек ялыкмыйча, фәнни сүз әйләнеш-

ләренә төртелмичә укырлык мондый китаплар да бик кирәк, диде Р. Хәкимов. Фәнни дәрәҗә алуга йөз тоткан тарихчы исә үзе сайлаган тема кысаларында гына эш йөртә, аның иҗади мәйданы күпкә таррак була. Гади укучы андый хезмәтләрне авыррак кабул итә, диде ул. Шуңа күрә безгә гади укучыны кызыктырырдай итеп язылган тарихи эчтәлекле шушындый китапларны күбрәк тә чыгарасы иде әле…

Татарстан Дәүләт Советында Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, халык шагыйре, якын тарих фәне кандидаты Разил Вәлиев тә бу китапларның халкыбыз өчен көтеп алынган бүләк булганлыкларын билгеләп үтте. Бу өчтомлыкта саф тарих кына түгел, фәннең тарихка якын өлкәләренә дә зур урын бирелгән, диде ул. Әйтик, биредә тикшерелгән икенче том тулаем диннәргә, дини бәйләнешләрне тикшерүгә багышланган. Бүгенге сәяси вазгыять тә диннәр, дини мөнәсәбәтләр тирәсендә куера бара. Бу томда төрле диннәрнең килеп чыгышына да, үзара бәйләнешенә дә әһәмият бирелгән. Бигрәк тә ислам дине белән христиан дине бәйләнешләрен белү безнең киләчәк өчен дә әһәмиятле булачак, диде оратор.

Тарихчы-академик, илле еллап студентларга тарих фәнен укыткан профессор Индус Таһиров фикеренчә, күпчелек очракта рәсми тарих фәне теге яки бу милләтнең чын үткәнен, чын тарихын чагылдырмаска да мөмкин. Гадәттә, рәсми тарих берәр дәүләттә идарәчелек итүче бер төп милләт мәнфәгатенә яраклаштырылып языла. Шуңа күрә икенче-өченче баскычларда торучы милләт тарихын шул халыкның үзеннән чыккан, рәсми фәнгә әллә ни бәйләнеше булмаган шәхесләре генә чагылдыра ала. Шуларны истә тотып, мондый хезмәтләрнең дөньяга чыгуын хупларга кирәк. Соңгысы булмасын. Фатих Сәүбән улы бик зур эш башкарган. Эшен дәвам итсен дигән теләктә калам, диде галим.

Милли телебез үзенчәлекләренә нигезләнеп, милли тарихыбызны барлауга да зур өлеш керткән академик Мирфатыйх ага Зәкиев тә Фатих Сибагатуллинның шушы юнәлештәге эшчәнлеген хуплады. Мондый киң офыклы, тирән эчтәлекле тарихи китаплар безгә, безнең халыкка бик кирәк, диде. Бер-ике уңышлы мисал да китерде. Чордашы, фикердәше Индус Таһиров сүзләрен куәтләп, һәр милләт үз тарихын үзе генә төгәл барлый ала, диде академик М. Зәкиев.

Үзешчән тарихчылар эшчәнлеген бик үк өнәп бетермәүче тарих фәне докторы Дамир Исхаков та, әлеге китаплар басылып чыгуын хуплап, берничә сүз әйтте. Чыңгызханның монголлар нәселеннән булмыйча, төрки кыят кабиләсеннән чыкканлыгын раслап, китапта бик дөрес тасвирланган булганлыгын белдерде. Безгә шундый үзенчәлекләрне дә истә тоту бик зарур, диде.

Биредә мин, әлбәттә, рәсми тарих фәнендә зур абруй казанган шәхесләрнең чыгышларына аерымрак тукталдым. Очрашуда

сөйләүчеләрнең сүзе сүзгә тәңгәл килеп бетми дип уйлаучылар да булыр. Ашык-пошык, теркәп бара алган кадәресен яздым, укучыларым гафу итсен.

Бу кичәдә республикабыз һәм Россия күләмендә танылган бик күп башка шәхесләр дә катнашты. Фатих Сибагатуллинның шушы җитди тарихи китапларны барлап, туплап чыгаруын хуплап, киләчәктә иҗади уңышлар теләп, трибунадан сүз әйтүчеләр арасында Идел буе Федераль округының Татарстан буенча федераль инспекторы Руслан Идрисов, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары – генерал Рафил Ногманов, Идел-Пресс полиграфия комбинаты җитәкчеләреннән Ислам Әмәтҗанов, Казан федераль университеты профессоры, академик Тәлгат Галиуллин, Татарстан мөфтияте казые Җәлил хәзрәт, әйдәп баручы каләм осталарыннан халык язучысы Гәрәй Рәхим, Зәки Зәйнуллин, Вахит Имамов, Нурлатта туган, хәзер Самара шәһәрендә актив җәмәгать эшлеклесе булган Идеал Галәветдинов, Бөтентатар иҗтимагый үзәге вәкиле, бөтендөнья күләмендә татарларга багышлап чыгарылган китапларның аерым үрнәкләрен үзебездә нәшер итүдә катнашкан Илдус Садыйков һ. б. булды.

Шул очрашуда катнашучылар һәм Фатих Сәүбән улы тарафыннан барлап, язып чыгарылган бу кызыклы тарихи китапларны укучылар тарафыннан авторга зур уңышлар, киләчәк җиңүләр теләделәр. Озакламыйча аның дүртенче китабы – «Татары и евреи» дип исемләнгәне дә сатуга чыгачак. Төрки-болгарлар белән яһүд динен тотучы төркиләр кайчандыр Көнчыгыш Европаның һәм Көнбатыш Азиянең бер өлешен биләп торган Хәзәр дәүләтенең идарәче халкы булганнар бит. Димәк, кайчандыр бик якын кардәшләр булганнар. Хәзерге Каспий диңгезе ул гасырлардагы тарих һәм география китапларында Хәзәр диңгезе дип тә йөртелгән. Әлеге китапта шул чор вакыйгалары һәм тарихы тасвирланачакны Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин бу очрашуда үзе хәбәр итте...

Совет хакимияте елларында гомумтөрки тарихны тирәнтен өйрәнергә, барларга тырышу бик хупланмады. Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин китапларында гомумтөрки тарихының аерым этапларын барлауга зур урын бирелгән. Кайбер Европа һәм Россия тарихчылары хезмәтләрендә дә хәзер гомуми төрки дөньясын Евразия халыклары тарихи дөньясы, рус кенәзлекләре тарихы белән үзара якынайтырга теләүгә юнәлтелгән омтылыш-эзләнүләр сизелә башлады дигән фикерләр дә яңгырады әлеге очрашу барышында.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин барлап чыгарган әлеге тарихи хезмәтләр безнең милләт өчен генә түгел, башка кардәш милләтләр өчен дә кызыклы, үзенә күрә бер үрнәк булырлык хезмәтләр. Совет хакимияте елларыннан бирле дәвам итеп килгән, тарихи чынбарлыкны укучыга танытуда җитди тайпылыш-

лар булган китап, дәреслекләр белән таныш кеше Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин, аңа чаклы дистә еллар элек үк тарихи үткәнгә үзенчә карашы белән танылган, тугандаш кумык милләтеннән булган Мурад Эскәндәр улы Аджи китапларын укыган кешеләрнең тарихи үткәнебезгә карашы нык үзгәрәчәк.

* * *

Фатих Сибагатуллин китапларында Россиядә яшәүче төрле милләт вәкилләренең, бигрәк тә бу дәүләтне нигезләүдә катнашкан төп халыклар булган рус белән татарларның тырышлыгы белән бердәмлеккә ирешелүгә байтак мисаллар китерелә. Шул вакыйгаларда катнашкан шәхесләр исемлеге бирелә. Киев чоры рус кенәзлеге оеша башлаган көннәрдән бирле бу кенәзләр Кара диңгез буеның төньяк тарафларында гомер иткән кыпчаклар берләшмәсенә кергән болгар, кыпчак, каракалпак, бәҗәнәк һ. б. төрки ханлыклары белән кызлар бирешеп, уртак гаиләләр төзеп яшәгәннәр. Мондый арадашлык, бердәмлек хакында әле XVII–XIX гасыр рус тарихчылары бәйнә-бәйнә язып калдырган. Дөрес, XX йөз урталарында шул чор вакыйгалары белән шөгыльләнгән кайбер галимнәр рус-төрки, рус-татар бердәмлеген читләтеп үтәргә тырыштылар. Мәсәлән, шул чор рус язма әдәбияты тарихы белгече булган академик Д. С. Лихачёв, бер күләмле генә китабында XI–XII йөз вакыйгаларын бәян иткәндә, Киев кенәзлеге кенәзләренең Европадагы иң кечкенә дәүләт вәкилләре белән гаилә арадашлыкларын терки, ә адым саен булып торган кыпчак, болгар һәм рус арасындагы кыз бирешү, кодалашу вакыйгаларын искә алмый. Киев кенәзлеге белән бу халыклар арасында урнаштырылган үзара арадашлык мөнәсәбәтләрен читләтеп үтә. Бер-ике мисал. Рус дәүләтен оештыру тарихында зур урын тоткан Владимир Мономах нәселенең ул һәм кызларыннан берничәсе кыпчаклар берләшмәсенә кергән төрки-татар ханнары кызлары һәм уллары белән никахта торган. Руслар тарихында христиан динен дәүләт дине итеп кабул итүче саналган «изге Владимир I нең» өч хатыныннан берсе Киевка якын тирәдә бай биләмә тотучы болгар кызы була. Бу кенәз вафат булгач, Киев тәхетен биләү өчен даулашканда, Владимирның әлеге болгар хатыныннан туган ике яшүсмер улы – Борис белән Глеб үтерteләләр. Явызларча үтерелгән шул сабый Борис белән Глеб – бик күптән инде христиан дин әһелләре тарафыннан изгеләр исемлегенә беренчеләрдән булып кертелгән шәхесләр. Христиан диненең шундый ук изгеләре сафында йөртелгән атаклы кенәз Александр Невский анасының да кыпчак нәселе вәкиле булганлыгы Фатих Сәүбән улының 2012 елда нәшер ителгән чираттагы китабында да китерелә (Великие татары…, 19 б.). Бу кенәзнең берара анасының якыннары арасында – Батый хан уллары белән бергә тәрбияләнгәнлеге дә искә алып кителә әлеге китапта. Әйе,

аларда да ерак болгар, кыпчак бабаларыбыз каны да булган. Диннәребез үзгә дип тормастан, бәлки, хәзер шундый җаннарны да ерак кардәшләр исемлегеннән сызып ташлау кирәкмидер.

Еш кына рус тарихчылары аерым кенәзлекләр биләгән кенәзләр белән татар-төркиләр арасында якыннан аралашу Алтын Урда чорына туры килә, дип кенә язалар. Дөреслектә ул якынлашу күпкә иртәрәк башланган – Идел белән Дунай елгалары аралыгындагы зур мәйданда Бөек Болгар дәүләте яшәгән дәвердә үк. Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин туплап нәшер иткән китапларда китерелгән байтак кына мисаллар рус белән татар арасында менә шушы вакыттан ук аралашып яшәү чоры булганлыгын раслыйлар.

«Россия и татары, их многовековая история – вместе на века» шигаре аның әлеге өченче китабының төп мотивы.

Хәзер укучылар хөкеменә тапшырылган китаплар эчтәлегенә бераз тукталып үтик. «От Аттилы до президента. Беренче китап – «Великие хунны и Золотая Орда» (Казан, 2008, 5 мең данә). (Татарча язылыштагы «Атилла» рус һәм Европа телләрендәге язмаларда күп очракта «Аттила» рәвешендә бирелә.) Икенче китап – «От Аттилы до президента. Легенды и мифы религии» (Казан, 2009, 5 мең данә). Өченче китап – «Великие татары – строители и защитники Государства Российского» (Казан, 2012, 5 мең данә). Дүртенче китап – «Татары и евреи» (Казан, 2013, 5 мең данә). Бу китапта борынгы төрки скифлар һәм һуннарга багышлы күләмле генә бүлекләр китерелә. Шуннан соң Хәзәр каһанлыгының төрки халкы, дәүләт тарихы бәян ителә. Каһанлыкның ике идарәче халкы – ашина ыруы вәкилләре белән болгарларның ике төрле дин тотканлыгы тасвирлана. Яһүдиләр динен кабул иткән ашина ыруының югары катлау вәкилләре соңрак Рәсәйдә, нигездә, төрки телне дә онытмаган караимнар буларак танылачак.

Һуннар чорыннан башлап Алтын Урда дәүләте яшәгән дәверләрне иңләүче беренче китап, Россия дәүләтендә сакланган чыганаклардан тыш, чит ил галимнәре язган хезмәтләргә дә таянып тасвир ителгән. Алты бүлектән тора. Китапта Чыңгызханның үзенә һәм төзегән дәүләтенә (империягә) бәйле бүлек тә бар. Алтын Урда дәүләтен оештыру һәм яшәтүдә татарлар белән бергә русларның да өлеше булуы мисалларда китерелә. Димәк, Алтын Урда дәүләте татарлар өчен генә түгел, руслар өчен дә уртак ватан буларак оешкан. Ул дәүләттә мөстәкыйль христиан дине оешмалары яшәп килгән. Хан сарае белән бер* шәһәрдә христиан дине митрополитының утар-сарае булганлыгы ике телдәге тарихи язмаларда да теркәлгән.

---

* «От Аттилы до президента», 136 б.

Китапның кереш өлешендә (7–10 б.) автор ерак бабаларының тарихын барларга алынуын белдерә. Россиядә XV–XVI йөзләрдән башлап татарлар тарихын чагылдырган бик күп чыганакларның юкка чыгарылуын бәян итә. Кәгазьгә төшерелгән төрки телдәге язулар гына түгел, ташка уеп язылган байтак кына борынгы истәлекләр дә төрле сәбәпләр аркасында юкка чыгарылган, дип белдерә автор. Әйтик, болгар дәүләте яшәгән чорларга караган шундый таш язулы истәлекләрнең бүген дә төрле төзелештә кулланылган булуын беләбез. Алар соңрак төзелгән чиркәү диварларында да кулланылган. СССР чорының Себер тарафы тарихчысы Р. Кызласов та 1970–1980 елларда Тува республикасында булган төркичә язулы истәлекле ташларның тиешенчә сакланмавы турында матбугатта язып та чыккалады. Гомум Себер күләмендә таралып яткан андый истәлекле ташларны яисә таш-кыялардагы язуны исәпкә алу да тиешенчә оештырылмый, дип тә язды ул галим.

Төрки кавемнәр яшәешенә һәм тарихына багышлап фарсы, гарәп, Европа халыклары телендә язылган күп кенә тарихи ядкярләрне әле бүген дә чит ил мирасханәләрендә очратырга мөмкин. Ләкин андый чыганакларны барлау әле бездә тиешенчә оештырылмаган. Аларның әзме-күпме өйрәнелгән кадәресе дә әле киң җәмәгатьчелеккә билгеле түгел. Совет чорының күренекле тарих галиме, археолог Сергей Петрович Толстов урта гасырларгача яшәгән Харәзем дәүләтенең кайчандыр Сырдәрьядан алып Дунай елгасы тамагына кадәр мәйдан биләгән булуын яза. (Ягъни соңрак оешкан Хәзәр дәүләте шул җирлектә барлыкка килгән була.) 1940–1950 елларда ул Харәзем дәүләте шәһәрләрен археологик-тарихи барлау-тикшерү эшен башкара. Шул шәһәрләр рәтендәге Бохара, Сәмәркандларның кайчан барлыкка килгәнлеген яза. Урта гасырлар язма истәлегенә нигезләнеп, бу ике зур шәһәрнең – зур-зур дәүләт башкалаларының төркиләр тарафыннан төзелгән булуын дәлилли. Ә безнең илдә хәзер аның хезмәтләрен генә түгел, үзен дә онытырга тырышалар бугай. Чөнки ул – кайберәүләр тарафыннан «исконно наши земли» дияргә тырышкан җирләрнең дә элек-электән төркиләр мәйданы булуын белдергән шәхес.

Бу җәһәттән безнең тарихчы галимебез Альфред Халиков та бик эзләнүчән иде. Әмма аның Киев төбәгендәге кыпчак-болгар ханлыклары турындагы эзләнүләре дә, Дунай төбәге Болгар иленә барып кайтудан соң башкарылган язмалары да тулы килеш киң җәмәгатьчелеккә җиткерелмәде, матбугатта күренмәде шикелле. Бүгенге көндә аның кебек җитди адымнар ясарга омтылучылар да юк шикелле. Ә А. Халиковка аяк чалучы тарихчыларыбыз булды. Ул Татарстан тарихыннан читкә тайпыла дип көнләштеләр шикелле.

Кайбер Европа һәм рус тарихчыларының «күчмән төркиләр»не «зур шәһәрләр төземәгән», «аларны җимерүчеләр генә булган»

дияргә теләвен беләбез. Диндәш гарәпләрне дә еш кына «надан, зур тарих калдырмаган халык» дип тасвирлау әле дә өстенлек итә. Ә бит шул ук Испаниядә алар җиде йөз ел (711–1492) дәвамында көчле зур мәмләкәт-хәлифәт иясе булганнар. Бүген дә анда гарәпләр төзеп калдырган затлы тарихи корылмалар бихисап. Колумбның Америкага сәяхәте дә шул хәлифәт таркалыр чорда оештырылган. Кайбер галимнәр шул ук гарәпләрнең бик оста диңгезче булуларын, диңгездә йөзгәндә кирәкле булган тәүге юлкүрсәткеч исәп-хисап коралларын уйлап чыгарганлыкларын искә алалар. (Испаниядәге хәлифәт чоры астрономы һәм математигы Ибраһим бине Яхъя ән-Нәккаш күк йөзендәге йолдызларның төгәл урынын исәпләүче тәүге әсбапны уйлап табучы санала.) Шул гарәпләр төзеп калдырган байтак кына бина-корылмалар хәзер дә тарихи әһәмиятен югалтмаган. Европа галимнәренең гарәпләрне һаман «түбәнәйтеп» күрәселәре килә. Гарәпләрнең Америкага юл ачу фикерен күтәреп чыкканы өчен Сталин чоры ГУЛАГларында җәза алган Теодор Шумовский 1960 елларда ук инде «Наука» нәшриятында «Арабы и море» дип исемләнгән китабын бастырган иде. Анда ул гарәпләрнең оста диңгез сәяхәтчеләре булганлыгын дәлилли.

Борынгы һуннар империясе бүгенге Корея дәүләте биләмәләреннән алып Урта диңгез буйларынача сузылган җирләрдә яшәгән. Чыңгызханга багышланган бер борынгы язмада бу ханның да, элеккеге бабалары кебек, Татар бугазы белән чикләнгән океаннан алып Урта диңгезгәчә булган арада үз дәүләтен төзү турында хыялланып яшәгән, дип язганнар иде. Хак сүз булгандыр, мөгаен. Һуннар империясе биләмәләрен төрки «скифлар биләмәсе» белән тиңләп бәян итүчеләр дә бар. Аңа Алтайдан көнчыгыштарак урнашкан җирләр дә, Идел белән Днестр-Дунай аралыклары да, Төньяк Кавказ төбәкләрендә гомер иткән бәҗәнәк, болгар, кыпчак-коман, кимәк, коңгырат һ. б. бик күп төрки кабиләләр дә кергән. Тарихи вакыйгалар белән дә җитди кызыксынган рус язучысы һәм галиме К. Марков (миндә аның язмасыннан күчермәләр бар иде) XX йөз башында хәзерге Улан-Удэ шәһәре янәшәсендә галимнәрнең «бер скиф патшасының каберен ачыклаулары» турында язды. Димәк, хәзерге бурятлар яшәгән төбәк тә скифлар биләмәсенә кергән булган.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин китаплары да шундый тарихи мәгълүматларга бик бай. Ул китапларда әлеге Марков кебек бик сирәк авторлар хезмәтләреннән дә тарихи истәлек язмалары китерелә. Китап авторы билгеләп үткәнчә, борынгы һуннар империясе биләмәләрендә соңрак төрле исем-атама белән йөргән төрки дәүләтләр оешкан, яшәгән. «Бөек дала иле» (русча язмада «Великая степь») «Туран иле», «Дәшти Кыпчак» һ. б. дәүләтләр була. Соңрак «берләшкән, зур мәйдан биләгән төрки дәүләт» – Европалылар карталарында еш теркәлгән «Тартария» һ. б. оеша.

Борынгы ул дәүләтләр яшәгән (Көнбатыш Төрки каһанлык, мәсәлән) биләмәләренең зур бер өлешендә соңрак Хәзәр дәүләте барлыкка килә. Ул дәүләтнең төп идарәче халкы огур-болгарлар һәм ашина ыруы вәкилләре була. Ул заманнарда төрки дәүләтләр биләмәләренә фин-угор тел төркеменә караган мордва, эрзя, мари, удмурт, коми, манси ыруы вәкилләре дә кергән. Хәзәр дәүләтенең көнбатышында аз санлы славян кабиләләре дә булган, диелә.

Китапның кереш өлешендә әйтеп кителгәнчә, тарих фәне яңа фактлар өстәлү яисә илдәге сәяси вазгыять үзгәрү нәтиҗәсендә һаман үзгәртелә, яңартыла. Әлеге китапта хәбәр ителүенчә, хәзер кайбер галимнәр һун кабиләләре арасында славяннар да актив катнаша диючеләр дә, хәтта Атилланы Владимир (яки шуңа охшаш) исемле славян булмаганмы диючеләр дә бар икән. Әгәр тарихи мирас ярдәмендә ул фикер дәлилләнсә – шулай була бирсен.

Беренче китапның 1 нче бүлегендә, нигездә, борынгы бабаларыбыз булган скиф, сармат, аланнарга кагылышлы материаллар китерелә. Россиядә XVI йөзгә чаклы язылган хезмәтләрдә бу кабиләләрнең төрки булуы теркәлгән. Әмма кайбер рус түрәләрен мондый хәл канәгатьләндерми. Һәм 1709 елда Пётр I патша махсус фәрман белән «мин скифларны славян дип таныйм» дип билгеләнде. Димәк, рус кабиләләре аяк басмаган, көнчыгыш Европа белән Азия җирләрендә яшәгән скифларны, грек тарихчылары Геродот, Курций Руф, элегрәк гасырларда яшәгән Россия галимнәре скиф, сарматларның төркилеген теркәп калдырганнарны сызып, скифларны төркиләр дип искә алмаска әмер бирә бу дуамал патша. Иң гаҗәбе шул: үзе дә анасы ягыннан татарга бәйле нәселдән ич. Шуны сылтау итеп бит инде элек идарә иткән апасы, «саф рус кызы» София Алексеевна аны тәхеткә тәгаенләтмәскә дә тырыша. Бу хәлләрне әле берничә ел элек кенә «Эхо Москвы» каналында даими чыгыш ясаучы тарихчы Н. Насовская ханым да тәфсилләп сөйләгән иде. Шушы Насовская сөйләвенчә, бояр Ф. Ромодановский ярдәмендә генә Пётр тәхетне били алган. Һәм бу кенәз гомергә Пётрның даими ярдәмче-булышчысы булып калган. Ә Иван Грозный исә шундый ук «ата» бурычын үтәгән бояр Овчинадан үч ала – үзен үтертә, туганнарын сөргенгә куа. Шул хакта совет чоры тарихчысы Андрей Никитин Мәскәүдә нәшер ителгән журналда һәм «Точка зрения» китабында (М., 1985) язып та чыкты. Димәк, үзенең тәхеттә нык утыра алмавын Иван алдан сизә. Боярлар, берләшеп, бу синең урын түгел дип, аны тәхеттән теләсә кайсы вакытта куып төшерә алганнар. Һәм шуны сизенгән патша Овчиналар токымыннан гына түгел, рәсми атасы ягыннан булган бик якын туган тиешлеләрдән дә котылу чараларын оештырган. Пётр чоры турында 1980 елда чыккан энциклопедик сүзлектә дә: «Фёдор Юрьевич Ромодановский (1640–1717) был фактическим правителем страны при его (Пётра) отсутствии», – дип язылган.

Кайбер безнең заман галимнәре хәзерге Бурятия җирләреннән алып Дунайның югары агымнары аралыгында тулы бер гомер кичергән скиф-сарматларны иранлы-фарсы телләләр төркеменә кертергә тырыша. Геродот та, аннан соң барлаучылар да аларның яшәү рәвешенең «дала тарафы төркиләргә тартым» булганлыгын яздылар. Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин нәшер иткән хезмәтләрдә дә шул фикерне раслардай җитди фактлар китерелә.

Беренче китапның 2 нче бүлеге «Бөек һуннар каһанаты» дип аталган. Бу кабилә берләшмәләренә Бөек Атилла оештырган империя дә, соңрак оешкан, Кубрат хан баш булган «Бөек Болгар дәүләте», «Хәзәр каһанлыгы» биләмәләре дә кергәннәр. Хәзерге фән казанышы булган генетик нигезләве –ДНК тикшерүләре күрсәткәнчә, Хәзәр дәүләтендә яшәгән, ислам һәм яһүди диннәрне кабул иткән төркиләр белән хәзерге Идел буе татар, чувашларның генетик үзенчәлегенең тәңгәл килүен галимнәр раслый. Хәзәр һәм Бөек Болгар дәүләтләре чорына караган, тарихи әһәмияте зур булган китапны X йөздә яшәгән гарәп географы һәм тарихчысы Әбү-л-Хәсән әл-Мәсгуди әл-Багдади да язган. (Ул унлап китап авторы була.) Ләкин аның Каспий диңгезе буендагы төбәкләрдә, илләрдә булган сәяхәтенә багышланган китабы рус теленә тулаем тәрҗемә ителмәгән. Күпчелек очракта безнең ил галимнәре аерым өзекләрен – славян халыклары тарихына багышлы өлешләрен генә үз хезмәтләрендә файдаланганнар. Мәсәлән, В. В. Бартольдның «Арабские известия о русах» (1940), В. М. Бейлисның «Ал-Масуди о русско-византийских отношениях» (1962) һ. б. шуңа охшаш хезмәтләрнең булганлыгы мәгълүм. Кайбер галимнәребезнең язмаларында Ш. Мәрҗанинең дә аның хезмәтләре белән таныш булуы әйтелә. Ләкин бу олуг галимнең гарәп тарихчысының кайсы китап-кульъязмаларын кулланганын барлаучылар әлегә юк кебек. Хәер, олуг хәзрәтнең күпчелек хезмәтенең әле яңа шрифтка күчерелмәгән булуы да мондый эзләнүләргә комачаулыйдыр.

Беренче китапның 3–4 нче бүлекләре Чыңгызхан һәм ул төзегән империягә, оныгы Бату хан оештырган Алтын Урда дәүләте тарихына карый. Бу бүлектә Чыңгызның төрки кыят кабиләсеннән чыкканлыгы, нәселенең монголларга катнашы булмаганлыгы дәлилләнә. Ләкин аңа карап кына безнең илнең күпчелек тарихчылары «татар-монгол явы»на карата карашын үзгәртмәс, билгеле.

Чыңгыз оныгы Бату хан оештырган дәүләттә татар, болгар, кыпчак, кумык һ. б. төрки кавемнәр белән бергә рус-славяннарның да катнашуына зур урын бирелә. Дөрес, рус-славян дип язганда, без Көнчыгыш Европаның төньяк өлешендә элек үз кабиләләре, үз дәүләтләре белән яшәгән һәм әкренләп руслаша барган күпсанлы фин-угор телендә сөйләшүче мордва, водка, коми, пермяк, мари, удмурт кебек кабилә исемнәре йөртүчеләр булуын да истә тотарга тиешбез. Юрий Долгорукий хәзерге Мәскәү каласын нигезләгәндә ул төбәктә фин-угор телендә сөй-

ләшүче, бүгенге көндә Мәскәү белән Тверь араларында бик аз санда яшәгән «водка, мери» кабиләләре булуы, ә Архангельск шәһәре тирәләрендә шундый ук телдә сөйләшүче башка атамалы халыклар яшәгәнлеге аерым хезмәтләрдә генә бераз телгә алына кебек. Хәзерге Түбән Новгород өлкәсе җирлегендә элек, Долгорукийның улы Андрей Боголюбский һәм варислары яулап алганчы (1160 еллар), Мордва ханлыгы булганлыгын да хәзер сирәк искә алабыз. 1964 елда Горькийда бер айлык курсларда укуда булган вакытта, шәһәр музееның бер диварына ул патшалык картасы, аннан астарак чиктәш Идел буе Болгар дәүләте картасы сызылган иде. Китапханәләрдә булган белешмәлекләрдә ул ханлык-патшалык турында кыскача хәбәр һәм хәтта мордва патшалары исемнәре дә теркәлгән иде. 1970 еллардан башлап ул патшалыкның булуы тарихтан сызып ташланды шикелле. Хәзерге дәреслекләрдә ул дәүләт биләмәсе искә алынмый. 1980 елгы энциклопедия сүзлегендә дә анасы ягыннан болгар-татарга бәйле Андрей кенәзнең һәм аның улларының әлеге Мордва патшалыгын яулап алуы турында бер сүз дә юк. Ә бит аңа чаклы башлангыч класс дәреслекләрендә дә Андрей кенәзнең күрше патшалыкны яулар өчен оештырылган һөҗүмнәре тасвирлана иде.

Әлегәчә безнең татар тарихчылары Алтын Урда дәүләтенә кергән эре милләт-кабиләләр исемлеген тулаем кертергә тырыштылар. Шулар арасында славяннар иң беренче урында була дигән фикер туа бу томны укыганда.

Чыңгыз империясендә дә, Алтын Урдада да төрле халыклар үз телләрендә аралашкан, үзе кабул иткән динне тоткан. Милләткә, дингә бәйле рәвештә кысулар булмаган. 1966 елның сентябрендә миңа бер ай Киев янәшәсендәге Иҗат йортында булырга туры килде. Күрше бүлмәләрдә Довженко исемендәге киностудиянең баш мөхәррире, язучы Василий Земляк белән кинорежиссёр Владимир Денисенко яшәде. Киев каласының мең еллык юбилеена багышлап кино төшерергә әзерләнәләр иде. Мәскәү вәкилләре тарафыннан күп кенә өлешләренә сорау куелган яисә карандаш белән сызылган сценарийларын болар төзәтү белән мәшгульләр иде. Мәскәүләр сызарга кушкан күренешләрнең берсе Бату хан һәм аның даирәсендәгеләргә бәйле иде. Ул һәм башка сызылырга кушылган бүлекләрне күршеләрем Мәхмүт ага Хөсәен белән миңа укып-укып таныштырдылар. Анда Долгорукийның Киев тәхетен яуларга ниятләп кыпчак-болгар бердәмлеге ханы белән килешүе хакында да берничә җөмлә бар иде. Довженко исә үз киноларында ул вакыйгаларны бит «шәһәрне кыпчакларның басып алып талавы» рәвешендә генә күрсәткән. Икенче күренеш 1240 елның кышын Бату ханның Киевта уздыру вакыйгасына бәйле иде. Ара-тирә Бату хан үз иярченнәре белән София соборына килеп, попларның төркичә вәгазен театр карагандагы кебек карап утыра торган була. Әйе, поплар ул чорда вәгазьне алмаш-тилмәш ике телдә башкарганнар. Бу факт борынгы язмаларда теркәлгән

булган, диделәр күршеләрем. Мөгаен, шул елларда Батуның олы улы Сартакның несториан, ягъни көнчыгыш христиан-әрмән динен кабул иткән вакыт булгандыр. Ул чорда София соборында әрмән динен кабул иткән кыпчак, болгар попларының вәгазьне төркичә укыганлыклары турында борынгы язмалар бар дип безнең галимнәр дә искә төшергәләделәр бит. Озакламыйча Сартакның үз побын – «әрмән наставнигы»н Ватиканга җибәрүенә бәйле бер документ 2011 елда «Гасырлар авазы» мәҗмугасында да урнаштырылды.

Менә шушы очрак та Фатих Сәүбән улының китабында тасвирланган татарлар белән славяннар арасында Алтын Урда идарәчелеге чорындагы бердәмлегенә бер мисал буладыр.

Украина хөкүмәте оештырган, Василь Земляк җитәкчелегендәге төркем башкарган ул киноның экранга чыгуы турында матбугатта хәбәрләр күренгәләде. Ләкин аны һәм В. Денисенконың «Сон Шевченко» исемле киносын фәкать Украинада гына күрсәттеләр кебек. Безгә ул кинолар килеп җитмәде. Денисенконың элегрәк төшергән кинолары ил күләмендә барды, матбугатта макталалар иде. (Ул Довженконың яраткан укучысы була, сугыш чорында алар Тбилисида яшәп тә берничә фильм төшерәләр.)

Несториан динен болгар һәм кыпчаклар арасында әрмән миссионерлары VI–VII йөзләрдә үк тарата башлаган дигән хәбәрләр бар. Галим Лев Гумилёв, Кара диңгез буенда һәм Кырымда бу динне тотучылар ишле була, дип белдерә. X йөзнең 65–66 нчы елларында Хәзәр дәүләтен таркатуга китергән һөҗүм оештырган Святослав I нең несториан динен тотучы икәнлеген Д. С. Лихачёв та раслый. Кайбер башка галимнәр дә яһүдиләр динен төп дин санаучы хәзәрләргә каршы көрәштә Святославка несториан диненә күчкән кайбер болгар ыруглары да булышлык иткән дип, радио һәм телевидение тапшыруларында да сөйлиләр. Телевизордан оештырылган бер чыгышында академик Д. С. Лихачёв та: «Ярый әле соңрак башка кенәзләр Святослав тоткан дин юлыннан китмәгән, чын христиан динен кабул иткән», – дип сөйләгән иде.

1965 елның октябрендә Кырымның Күктүбә бистәсендә иҗат итүче бер төркем язучылар, шул исәптән Ленинградтан килгән унике кеше бар иде. Алар арасында «Звезда» журналы мөхәррире Леонид Хаустов та, тарихчы Лев Гумилёв та булды. Иске Кырым шәһәренә сәяхәт кылдык. Иң әүвәл шунда XII йөздә төзелгән мәчет хәрабәләрен карадык. Аннары Иске Кырымнан 10–12 чакрымнардагы, урман эчендәге борынгы монастырь утарына бардык. Шунда Гумилёв (аны беренче күрүем иде): «Бу монастырьны несториан динендәге кыпчаклар төзегән һәм тоткан», – дип сөйләде. Кырым һәм Кара диңгез буе кыпчакларының бер өлеше әрмән миссионерлары йогынтысында шул дингә табынган. «Тарихи әдәбиятта «Кырым әрмәннәре» дип язылган төшенчә укысагыз, ул әрмән динен тотучы төрки кыпчаклар булыр», – диде

Лев Гумилёв. Шул сәяхәттән кайтышлый озата йөрүче ир-ат та рәссам Айвазовскийга бәйле бер вакыйганы сөйләп, аның Кырым татарлары телен белүе турында искә төшереп үткән иде.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин нәшер иткән беренче китапның 5 нче бүлегендә вакыйгалар Казан ханлыгы чорына багышлана. Ә соңгы 6 нчы бүлектә, «Безнең уртак ватаныбыз – Евразия» өлешендә, илебезнең бүгенге башкаласы Мәскәүгә бәйле хәлләр китерелә. «Аны әлегә бер генә ил-дәүләтнең дә яулап ала алганы юк», – диелә ул бүлекнең кереш өлешендә. «Безнең илдә хәзер бик күп милләт вәкилләре – русы, татары, фин-угор телле кабилә вәкилләре яши. Бердәм булып, бергә яшәп, илнең киләчәген кайгыртып көн күрик...» дигән фикер өстенлек итә бу бүлектә.

* * *

Икенче китапның өстәмә исеме тәрҗемәдә «Дини риваять һәм мифлар» («Легенды и мифы религии») диелә. Бу бүлекне тасвирлаганда, автор борынгы Тәүрат, Библия, Коръән кебек изге чыганакларга да, башка төр дини-тарихи хезмәтләргә дә таянып эш иткән. Борынгы төркиләрнең Тәңрегә – «Күк алласына» табынуына бәйле байтак мисаллар китерелгән. Дөнья күләмендә танылган дини карашлардан Буддага табыну, яһүдиләр дине, христиан дине һ. б. булуы да билгеләп үтелә. «Руслардан ислам динен тотучылар булганмы?» дигән аерым бүлек тә бар. 8 нче бүлек исә тулаем «Татарлар һәм ислам дине» дип аталган.

Өченче китап исеменең тәрҗемәсе: «Россия дәүләтен төзүдә һәм саклауда катнашкан бөек татарлар» («Великие татары – строители и защитники Государства Российского») дип исемләнгән. Элек чыккан китапларындагы кебек, монысында да автор бик күп язма чыганакларга таяна. Россиядә көн күргән татарларның ислам һәм христиан диненә табынучы ике төркеме барлыгын да билгеләп үтә автор. Бу очракта әле бүгенге татар теленә бик якын шивәдә сөйләшүче борынгы караимнарны да шушы ук төркемгә кертеп булыр иде. Алар хәзер, дини карашларына нигезләнеп, башлыча үзләрен яһүдиләр милләтенә кертәләр, яһүд телендә сөйләшәләр. 1990 елларда бездән Израильгә күчеп китүчеләрнең бер өлеше (Сөләйманов, Ибраһимов ише фамилия йөртүче Кавказ төбәге кешеләре) шушы кавем вәкилләре иде. Әбрар ага Кәримуллин фаразлавынча, «Көньяк Америкада яшәүче инк, майя, сиу һ. б. кабиләләрнең борынгы язма телен укып дан казанган СССР галиме Кнозоров та шул милләт вәкиле иде бугай. Әлеге ачышына ул, мөгаен, төрки телне белүе нәтиҗәсендә ирешкәндер» дип язган иде ул. «Мәскәүдә узган бер гыйльми җыелышта очрашканда ул минем белән бу темага сөйләшергә теләмәде», – дигән иде.

Патшалар чорында Петербургта гомер иткән галим, тумыштан караим Карл Залеманның төрки телгә берничә тарихи хезмәтне

тәрҗемә иткәнлеге хәбәр ителә. Шулар арасында кыпчакларга бәйле атаклы «Кодекс Куманикус» (1910) та бар, диелә.

Караимнар Россия дәүләтенең көнбатыш өлешендә – Кырым, Украина, Белоруссия һәм Балтыйк буе төбәкләрендә, чит илдә исә Польшада һ. б. илләрдә үз дини оешмаларына берләшеп яшиләр. Дөрес, алар арасында узган гасыр урталарыннан диярлек үз телләрен онытып, күпчелеге үз милләтен искә алмый башлаганы да ишле генә була. Безгә якын совет чорына караган, караим телен дә онытып бетермәгән шәхесләр дә бар иде. Мостафа ага Ногманның 1960 елларда «Казан утлары» журналында басылган мәкаләсендә Балтыйк буенда яшәүче өлкән буын караимнарның әле үз телләрендә аңлашулары бәян ителә. Тик яшьләр арасында гына ата-ана телен белүчеләр елдан-ел азая бара, дип язган иде ул. Польшада яшәүче караимнар арасында шул ук хәл, дип әйтүчеләр дә булды. Телләре төрки булса да, диннәре яһүдиләр дине булганлыктан, Көнчыгыш Европада караимнарны милли кысрыклау XX гасыр дәвамында дәвам итте дияргә була.

1960 еллар урталарында Польшада яшәүче тарихчы галим Ананиаш Заиончковскийның караимнар телен тасвирлауга багышланган бер китабы Бауман урамындагы китап кибетенә дә кайткан иде. Сарьян Хәсәнов аны кулына алып, актаргалап та караган, «кирәкле китап» дип тә әйткән иде. Кесә бушрак булганга без аны алмыйча киткән идек. Ә бер-ике көннән соң килсәк – китап киштәсе бушап калган. Димәк, Казаныбызда да ул динне тотучы тел кардәшләребез ишле булган.

Украина язучылары белән очрашканда, караимнарның һәр шәһәрдә аерым бистә-бистә булып яшәүләре турында да, аларның төркичә-татарча сөйләмне аңлаулары турында да ишетергә туры килгән иде. «Алар сезнеңчә аңлый», – дип әйткәлиләр иде. Совет хакимияте чорында татар әдәбияты үрнәкләрен рус, украин, белорус телләренә тәрҗемә итүчеләр төркемендә дә шундый ерак кардәшләребез ишле генә иде бугай.

Тарихчының чираттагы китабында Россия дәүләтен оештыруда зур өлеш кертүчеләр исемлегенә Бату ханны һәм аның варисларын, элекке Касыйм ханы Саин Булатны (Иван Грозный патша әмере белән бер ел чамасы «рус патшасы» булып торган Симеон Бекбулатовичны), кенәз дәрәҗәсенә ирешкән күп кенә шәхесләрне, (мәсәлән, Нугай иле бәкләре Йосыф белән Ырыстан чыккан (ырыс – бәхетле) Юсупов һәм Урусовларны, Кече Җүз казах ханы Әбелхәер нәселеннән булган Чыңгыз солтаннарны һ. б. атап була. XVII–XIX йөзләрдә татардан чыккан танылган шәхесләрдән Әби патша чорында иң беренче юстиция башлыгы булган шагыйрь Г. Державин, унике томлы Россия тарихын язган Н. М. Карамзин, батыр гаскәр башлыгы М. Кутузов һ. б. бар.

Әлеге китапта өч йөз елдан артык дәвердә Россия империясе императорлары булган Романовларның нәсел башында торучы татар бәге –Хәйбулла булганлыгы да дәлилләп тасвирлана. Безгә карата кылган усаллыклары белән дан казанган рус патшаларыннан Иван Грозный белән Пётр I нең аналары татар нәселеннән булганлыгын алдарак әйтеп үттек. Аналары татардан булган бик күп кенәзләрне, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләрен, язучыларны да санап китеп булыр иде. Әйтик, Александр II патшаның укытучысы һәм Пушкинның остазы булган шагыйрь Василий Жуковскийның, космоска бәйле тикшеренүләрне башлап җибәргән галим Константин Циолковский, мәшһүр язучылар Александр Куприн, Сергей Бородин һ. б. бик күпләрнең аналары безнең милләт вәкилләре булганнар.

Байтак кына рус дворяннары гербында ярымай тамгасы барлыгын яза Фатих Сәүбән улы. 1886 елда Петербургта нәшер ителгән ике томлык «История родов русского дворянства» китапларында Россиядә иң дәрәҗәле вазифаларны үтәгән 339 нәсел биографиясе теркәлгән. Ул басма шул чорның танылган тарихчы академигы П. Н. Петров җитәкчелегендә әзерләп чыгарылган. Шул китапта патшалар династиясе вәкилләренә тиң кенәз дәрәҗәсендәге ике-өч дистәләп татар да бар. Әйтик, христиан диненә күчкәч Мещерский фамилиясе алган, элекке Мәскәү, Рязань, Түбән Новгород кенәзлекләре култыгында, Ука елгасы буенда 1290 елларда «Мишәр йорты» исемен йөрткән ханлык оештыручылар була. Ул биләмә ханлыгын нигезләүче Ширин бәкләр Алтын Урдадан чыкканнар. 1360 елда, Алтын Урдада төшенкелек хөкем иткән чорда, бу Мишәр йорты биләмәсе Мәскәү кенәзлеге йогынтысына керә. Ә соңрак исә ул биләмә нигезендә мөстәкыйль Касыйм ханлыгы оештырыла. Мещерский кенәзләр өч-дүрт гасыр дәвамында Россиянең төрле төбәкләрендә воевода, шәһәр башлыклары вазифаларын үтиләр.

Гербларга килгәндә, рус дворяннары герблары арасында алты кырлы йолдыз билгесе төшерелгәне дә байтак. Алар исә Хәзәр дәүләтендә киң таралган икенче бер «төрки тамга» икәнлеген дә галимнәребез таныргa тиештер. Россия патшалыгында таралган андый тамгалар фәкать төрки-татар мирасы буларак кына кабул ителергә тиеш. Башкача булуы мөмкин түгел. Чөнки ул тамга – Хәзәр каһанлыгының төп ыругы саналган ашиналарның яһүд динен кабул иткәч кулланган тамгасы. Ул каһанлык таркалгач, яһүдиләр динен кабул иткән хәзәрләр караим исемен алалар, дидек. Кайберләре соңрак христиан диненә күчкән. Бу динне кабул иткән күп кенә төрки-татарларның патша чорындагы гербында алты кырлы йолдыз тамгасы белән янәшә ислам дине билгесе булган ай сурәте төшерелгәннәре дә байтак.

Минем 1990 еллар уртасында «Казан утлары»нда басылган «Ерак чорлар авазы» очеркымда бу вакыйгаларга да урын бирелгән.

* * *

Әле без карап чыккан өч китапта да бик тә истәлекле, тирән мәгънәле күп кенә фотоматериал кулланылган. Элегрәк аларның байтак өлеше улыбыз Булат Хәмидуллин җыеп, туплап чыгарган «Из глубины столетий» (Таткнигоиздат, 2000) һәм «История скифов» («Мәгариф» нәшр., 2001) дигән китапларда да бар иде. Язучылар йортында оештырылган җыенда Фатих Сәүбән улы үзе дә аның тарафыннан нәшер ителгән әлеге китаплар эчтәлеген тәртипкә салышуда Булат улыбызның булышканлыгын да әйтеп үтте.

Хәзер тикшерелгән беренче ике китап тышында Чыңгызханның кытай рәссамы тарафыннан кытайлыга охшатыбрак ясаган рәсеме дә урын алган. Элекке тарих китапларында да, хәзергеләрендә дә кайчандыр кытай рәссамнары тарафыннан кытай кешесенә тартым йөзле итеп ясалган Чыңгыз, Бату ханнарның рәсемнәре үзәк матбугатта да еш басыла. Ә шул чорга караган тарихи язмаларда исә бу шәхесләрнең кыяфәте бераз башкачарак күзаллана. Хәтта Чыңгызханның күз төсе дә, борынгы кыпчак бабаларыбызныкы шикелле, күк төсендәрәк булган дип язалар аның чорын өйрәнүче кайбер галимнәр.

Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин китаплары киң җәмәгатьчелеккә йөз тотып чыгарылган. Бу китапларда бер тар тема гына уртага салып тикшерелми, барча төрки кавемнәрнең үткәненә теге яки бу рәвештә әһәмият бирелә. Һәм аларга бәйле хәлләрне тасвирлаганда, рәсми фән вәкилләре тарафыннан күрмичәрәк яисә күрмәмешкә теләбрәк узган урыннарына да беркадәр әһәмият бирергә тырышылган. Китап авторының төп максаты – киң җәмәгатьчелек фикерен уяту, үткән тарихыбызда күләгәдәрәк калып килгән кайбер вакыйгаларга укучыны җәлеп итү. Әйтик, XX йөз тарихчыларыннан кемнең хезмәтендә Романовлар шәҗәрәсен нигезләүче Хәйбулла бәк телгә алына? Юк ул. Бик-бик күпләрнең Романовлар нәселен татарга бәйле нәсел итеп һич тә күрәсе килми. Суворов, Карамзин, Кутузов, Бунин, Толстой, Тургенев һ. б. бик күпләрнең дә татарга бәйле биографияле кешеләр икәнлеген хәзерге күпчелек «галимнәребез» белмәскә тырыша. Ә кайберәүләренең исә аны беләсе дә, таныйсы да килми. Үз шәҗәрәләренең үк татар, мукшы, фин, удмурт һ. б. нәселенә бәйле икәнлеген дә хәзерге заман кешеләренең күпчелеге танырга теләми, әлбәттә. Россия Федерациясен саф рус дәүләте итеп кенә күрергә теләгәннәрнең күпчелегенең йөзенә татар яки саф мукшы кыяфәтләре чыгып торган булса да.

Төрле сәяси һәм дәүләти киртәләр куелу нәтиҗәсендә «чыпчын» фәнни-тарихи хезмәтләребез авторлары язарга кыенсынган һәм курыккан яисә күп кенә фактларны эзләнеп, белеп тә бетермәгән очрак та бар. Фатих Сибагатуллин китапларында исә андый фактларга да әһәмият ителә. Узган тарихыбызның хәзерге

дәреслекләрдә теркәлмәгән өлешләрен дә белү бигрәк тә хәзерге яшьләргә бик кирәк. Әйе, бу китаплар киң җәмәгатьчелеккә йөз тотып язылган. Ул күпчелек укучы күңелендә тарих фәненең төрки-татарларга кагылышлы өлешен тулырак ачу, укучыга җиткерү бурычын үз алдына куя һәм шуңа ирешә дә. Чын тарихыбызны әлегә без Фатих Сәүбән улы китапларыннан укып кына белә алабыз.

Әлегә чаклы, бигрәк тә патшалык чорында төрле сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә татар тарихы кимсетелеп, үзгәртелеп яктыртылды. Хәер, бүген дә «Куликово кыры сугышы» дигән теманы фәкать татар белән рус арасындагы сугыш итеп күрсәтергә тырышучылар байтак. Дөресрәге, Мамай ханның Мәскәү кенәзлегенә яу белән килгәнлеген расларга теләүчеләр көннән-көн ишәя бара.

Шулар арасында бүгенге көн татар тарихчылары да бар. Һәм шул югары фәнни дәрәҗәле галимнәребез матбугатта яисә радио һәм телевидение тапшыруларында әледән-әле: «Мамай хан Мәскәү кенәзлегенә яу белән килгән», – дип тәкрарлыйлар. Дөреслектә бит ул вакыйганы оештыручы Рязань кенәзе Олег һәм аңа фикердәш кенәзләр була. Алар шәҗәрә буенча күпкә яшь Дмитрийның Бөек кенәз буларак үзләреннән өстен куелуы белән килешмиләр. Аңа каршы торырга үз гаскәри көчләре җитмәгәнлектән, дус-ишләрен ярдәмгә чакыралар. Олег Мамайны гаскәр башы булырга күндерә. Тверь кенәзе Михаил Литва кенәзе Ягайлога мөрәҗәгать итә (аның кыз туганы шунда кияүдә була). Без укыган дәреслекләрдә, Ягайло җибәргән гаскәрнең ярты тәүлеккә соңга калуы сәбәпле, әлеге сугыш булмыйча кала, диелде. Ике якның батырлары бер-берсе белән көрәшкәч, гаскәрләр таралыша, диелгән иде. Әйе, СССР дәверендә, 1940–1950 еллар дәреслекләрендә шулай тасвирланды. 1380 елгы бу вакыйганы тасвирлаган күпчелек елъязмаларда да шулай язылган була. (Шуңа күрә бу очракта «сугыш» диясе урында «вакыйга» төшенчәсен куллану дөресрәк булыр.) Кырыгынчы еллар ахырында педагогия институтлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә дә ул шулай бәяләнде («Борынгы рус әдәбияты» бүлегендә). Ул вакыйга Олегның Мәскәү кенәзе алдында тез чүгеп гафу үтенүе белән тәмамлана, диелә иде әлеге дәреслектә. 1980 елда Мәскәүдә нәшер ителгән энциклопедиядә кенәз Олегның әлеге вакыйгадан соң биш ел үткәч, улын Дмитрий кызына өйләндергәндә генә «гафу ит» дип үтенгәнлеге теркәлгән.

Әйе, 1480 елларгача ул вакыйга шулай тасвирланган. Капма-каршы торып бәрелешләр булмагач, аны «сугыш» дип атамыйбыз. Ә инде йөз елдан соң Дмитрий Донскойның варислары ул вакыйганы үзгәртеп, бөтен гаепне Мамай өстенә өеп, «Сказание о Мамаевом побоище» исемендә «яңа тарих» яздыралар. Ә йөз ел чамасы элегрәк бу вакыйга, берничә елъязмага нигезләнеп, «Задонщина» хезмәтендә тасвирланган була.

2004 елда «Наука» нәшриятында чыккан бер фәнни җыентыкта да «Сказание о Мамаевом побоище» повестеның миф булуы бәян ителә. Әмма ул әсәр шул чорның сәясәте өчен кирәк булган, диелә. «Алтын Урда чоры ятьмәсенә каршы көрәшкә өндәү вазифасын үтәгән ул китап», – дип яза бүгенге заман галиме А. Е. Петров (Исторические записки, 35–56 б.).

Киң җәмәгатьчелек өчен Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин хезмәтләренә карата кемнәрнеңдер тискәре караштa торуы мөһим түгел дип уйлыйм. Язмаларында китерелгән һәр фактны бит ул тарихи мисаллар белән дәлилләде. Аның үз аңы, үз фикере бар. Тарихи фактларга яңачарак, заманчарак карау куәсе дә җитәрлек. Уйлана, чагыштырып карый белгән кеше ак белән караны аера алыр дигән ышаныч белән ул кулына каләм алган. Көрәштә үз юлын табарга һәм җиңәргә күнеккән Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин бу очракта да җиңүче булып калган.

Аңа мин дә, әлеге очрашуда катнашкан күпчелек кебек үк, яңадан-яңа уңышлар, җиңүләр теләп калдым. «Татарлар белән яһүдиләр» («Татары и евреи») китабын да укучы уңай кабул итәр. Кече Азия төбәгендә гарәпләр белән яһүдиләр ни дәрәҗәдә бер-беренә якын булса, Җир шарының Көнчыгыш Европа өлешендә без дә төркидән яһүдигә әверелгән караим нәселе белән күп кенә очракта кулга-кул тотынып гомер иткәнбез. Икенче якын күршеләребез булган рус халкының бер әйтеме дә шуны раслый бугай. Безнең милләт вәкиле белән аралашканда бит алар: «Бер татар ике яһүдигә торырлык», – дип тә әйткәлиләр.

Әлеге кызыклы, гыйбрәтле очрашуның да тәмамлану вакыты җитте. Бу кичәне алып баручы шагыйрь Роберт Миңнуллин соңгы сүз итеп Фатих Сәүбән улына һәм аның тарихи хезмәтләренә багышланган шигырен укыды.

Өстәп тагын шуны гына әйтәсе килә: Совет хакимияте елларында Россия тарихын язучыларның да бер өлеше яһүдиләр динендә торучы «кардәшләребез» булды. Дәүләт тотучы милләткә ярарга, ярaклашырга тырышып, аларның кайберләре татарларга бәйле тарихка зыян да иткәләделәр. Әйе, алар арасында үзебезнең телне аңлаучы караимнар да булгандыр дип беләм. Шундый кайбер «галимнәр», чүп өстенә чүмәлә өеп, татар белән рус милләте арасында низаг, капма-каршы тору ягында булдылар. Үзләренә шуннан файда килеренә өмет иттеләр. Әмма алай гына озакка барып булмый. 1980 елларда шовинист рухлы рус кешеләре, «Память» оешмасына берләшеп, кайбер куштан яһүдиләргә карата да тәнкыйди мәкаләләр бастырып тараткалады бит.

Киләчәктә андый үкенечле хәлләр кабатланмасын, тарихи вакыйгалар элек ничек булганча тасвирлансын иде дигән теләктә калабыз.

*2013–2015*

# V

*Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем*
*Була юл күрсәтүче йолдызым!*

*Г. Тукай*

# КҮҢЕЛЛӘРНЕ ҖИЛКЕНДЕРГӘН ОСТА

## (Ике халыкның былбылы)

*(Очерк)*

Өлкән чордашым Латыйф ага Хәмиди белән танышу елларында үзбәк, казах кардәшләребез аны «төркиләрдән тәүге вальс көйләрен тудыручы шәп татар» дип тә искә алырлар иде. Ул чорларда бай тарихлы Урта Азия республикаларында андый «шәп татарларыбыз» шактый күп булды. Мәсәлән, Алма-Атада дистәләгән танылган шәхесләрне атаганда һәрвакыт диярлек иң әүвәл: «Безнең үз Курчатовыбыз – татар атомчыбыз бар», – дип, Шәүкәт Шиһабетдин улы Ибраһимовны искә алырлар иде.

«Бөтендөнья тарихына бер караш»* китабында Һиндстанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, булачак ил башлыгы Җәваһарлал Неру да татар милләте вәкилләре эшчәнлегенә зур бәя биргән. «Алар элек бөтендөнья күләмендә зур-зур мәмләкәтләр тотучылар иде, соңрак та күп кенә ил-мәмләкәтләрнең эшлекле вазифа башкаручылары буларак танылдылар», – дип яза ул өч томлы тарихи хезмәтендә. Әлбәттә инде, бу очракта галим Неру хәзерге тар мәгънәдәге татар төшенчәсен күз уңында тотып язмый, борынгы төрки-татарлар оештырган зур дәүләтләр дәверен искә төшерә. Шулай да күңелнең бер кылына чиртеп ала – сөендереп куя. «Ул төркиләр арасында безнең бабаларыбыз булганлыгы да шиксез», – дип уйлыйсың. Димәк, Җ. Неруның татарларга карата әйткән мактау сүзе өлешчә генә булса да безгә дә кагыла. Безнең күңелләрне дә җилкендерә.

Бүгенге көндә дә татарлар, – кайда гына яшәсәләр дә, күп очракта алгы сафта булырга тырышучы, гыйлемгә, дәрәҗәле вазифалар башкаруга омтылучы затлар. Үзләре сайлаган хезмәт юлында дан казанган милләттәшләребез байтак. Мондый мактауга алар үзләре сайлаган эшне башкаруда талантлырак, остарак булулары нәтиҗәсендә ирешкән.

Әйе, үзе сайлаган хезмәт юлында дан казанган милләттәшләребез байтак. Мондый мактауга алар үзләре сайлаган эшкә зур тырышлык куеп, талантлылык, осталыклары нәтиҗәсендә

---

* *Неру Д.* Взгляд на всемирную историю. – Москва, 1977. – С. 5.

ирешкәннәр. Әйтик, чордашларыбыздан Кытай кебек зур бер империядә югары дәрәҗәләргә ирешкән Буа ягы татары Борһан Шәһидине, бөтендөнья күләмендә мактаулы исемнәр яулаган галимнәрдән Роальд Сәгъдиевне, Һарун Таҗиевны, Рәшит Сүнәевне, бию осталары Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдевне алыйк. Яки Кытай җирендә башлангыч белем үзләштергән тарихчы академигыбыз Миркасыйм Госманов, Алма-Атаның бер бистәсеннән чыккан музыка сәнгате академигы Фоат Мансуров, Үзбәкстанда туган борадәран Акчуриннар, шунда яшәп иҗат иткән архитектор Мидхәт Булатов, Себер тарафында туган, Америкага киткәч оста шахматчыга әверелгән Гата Камский һ. б. бик күп замандашларыбызны хәтергә төшерик. (Дөрес, иленнән китәргә мәҗбүр булган Гатаның Америкада ирешкән уңышларын, бәлкем, кемнәрдер белмидер дә...) Мондый шәхесләребез белән горурланмаслыкмы соң? Бары тик аларның барлыгын онытмаска, ара-тирә булса да искә алгалап торырга кирәктер.

* * *

Татар, казах һәм үзбәк милләтләре дөньясында танылган күренекле композитор Латыйф Хәмиди дә шундый затларыбызның берсе. Җитмешенче елларда Алма-Атада миңа аның белән ике мәртәбә очрашып, озаклап сөйләшеп утырырга насыйп булган иде. 1950 еллар башында мин Казахстанның Актүбә шәһәрендә дүрт ел укыдым. Шул дәвердә аның җырларын, симфоник әсәрләрен, опералардан арияләрен радиодан еш тапшыралар иде. Шәһәр күләмендә оештырылган концертларда да аның җырлары, арияләре, сюиталары еш башкарылды. Аның безнең милләт вәкиле икәнлеген дә шул еллардан ук беләм. 1960 елларда мәшһүр композитор белән Казанда исә берничә мәртәбә күрешкән дә идек. Опера театрында узган ниндидер тантаналы кичәдән соң якташым Җәүдәт ага Фәйзинең, җитез хәрәкәтле, юкарак гәүдәле юлдашына күрсәтеп: «Латыйф Хәмиди агаң булыр», – дип, аның белән якыннан таныштыруы хәтеремдә. Шул вакытларда әле ул туган-үскән якларына еш кайтып йөрде. Әйе, ул хәзерге Кайбыч районына кергән авылда туган кеше. Якын күргән, Мәскәү консерваториясенең татар опера студиясендә бергә укыган дусларыннан Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин һ. б. әле ул вакытта сау-сәламәт, киң колачлап иҗат итәләр. Музыкаль әсәрләре сәхнәдән төшми уйнала. Халык күңеленә якын булган җырлары һәр кичәдә диярлек башкарыла иде. Л. Хәмидинең берничә әсәрен дә Казанда оештырылган әдәби-музыкаль кичәләрдә бик еш кабатлауларын хәтерлим. Тамашачылар аеруча аның татар һәм казах моң-аһәңен бергә кушып иҗат иткән «Былбыл» җырын яратып кабул итте. Ул елларда «Былбыл» җырын бездә иң оста башкаручы Наҗия Теркулова иде. Ә соңрак дәвердә казах илендә аны Бибигөл Teләгәневадан

да оста башкаручы булмагандыр, мөгаен. Туксанынчы елларда бугай, музыкант Кормангазый исемендәге оркестр белән Бибигөл дә Казанга килде. Үзенчәлекле матур тавышы, онытылмастай итеп җырлавы белән Казандагы милләттәшләрен дә сөендереп киткәнен хәтерлим. (Бибигөлнең анасы безнең милләттән икәнен дә искәртеп үтик.)

Латыйф аганың соңрак Муса Җәлилнең сүзләренә нигезләнеп киң таралган «Беренче вальс» җыры белән казах совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган Сабит Муканов шигыренә иҗат ителгән «Казах вальсы» да заманында бик популяр иде. Күңелдә күтәренке бер рухи халәт тудырган ул музыка башка халыклар тарафыннан да бик яратып кабул ителде. Бигрәк тә Урта Азия республикаларында Латыйф аганың ул «вальс көйләре» элегрәк елларда һәр тарафтан ишетелгәләп торыр иде.

Хәзер ул чор композиторлары әсәрләренә сәхнәдә урын әзрәк бирелә. Ә 1990 еллардан соң дөнья күргән җыр китапларында Л. Хәмиди исеме бөтенләй дә төшеп кала башлады. Җыр-көйләре тамашачы күңеленә ошамаганлыктан түгел, билгеле. Көй чыгаручыларыбыз ишәеп китеп, китап битләренең санаулы булганлыгыннандыр дип уйлыйм.

Ә бит Латыйф Хәмиди бик үзенчәлекле композитор. Балачак гомерен Урта Азиядә, татар, казах һәм үзбәк арасында үткәргән. Аның татарча яңгырашлы көй-моңнарына да безгә тугандаш казах һәм үзбәк кардәшләребез аһәңнәре дә кушылып, көйне баетып җибәрә. Шундый күренешнең үзенчәлекле чагылыш үрнәге буларак, әлеге шул мәшһүр «Былбыл» җырын, «Казах вальсы»н һәм «Беренче вальс»ларны атап үтәргә кирәктер. Латыйф аганың татар бию көйләренә нигезләнеп иҗат ителгән атаклы сюитасы хәзер зур сәхнәләрдә сирәк башкарыла. Ә телевизион экраннардан ара-тирә кабатлап тапшыру мөмкинлеге исә чикләнмәгән. Шушы сюитасы өчен бит автор кайчандыр профессор Г. Литинскийның махсус бүләгенә лаек була. Һәм ул бүләк билгесе бүген дә Казахстан композиторлары берлегендәге стендта саклана икән.

* * *

Казахстанның халык артисты Латыйф Хәмиди белән Алма-Атада очрашуыбыз көтелмәгәнчә килеп чыккан иде. Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге 1974 елның октябрь урталарында мине Казахстан язучылар оешмасына эш белән җибәрде. Үзара арадашлык җепләрен ныгытырга, татар язучыларының әсәрләрен Казахстанда, казахларныкын Татарстанда бастырып чыгару мөмкинлекләрен ачыклый төшәргә дип. (Шул сәяхәттән соң мин берничә алмаш китап чыгаруда катнаштым.) Октябрь ае ул елларда матбугатка абунәчеләр туплау – барлау чоры да иде бит. «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян» журналларына, татар телле газеталарга андагы кардәшләребез ничек языла, ул респуб-

лика күләмендә абунәчеләребез саны күпме? Шуларны да ачыклап кайтырга кушылган иде. Ул дәвердә казах кардәшләребез илендә дүрт йөз меңнән артыграк татар кешесе яшәде. Кардәш республика башкаласы ул вакытта Алма-Ата шәһәрендә урнашкан иде әле. Карл Маркс урамындагы матбугатка язуны оештыручы идарәгә бардым. Анда: «Сезнең якташлар газета-журналларга бик теләп языйлар. Елдан-ел планны арттырып үтәп киләбез. Безнең үзәк идарәдә дә, өлкәләрдәге идарәләрдә дә татар хатын-кызлары байтак эшли, подписка чорында алар сезнең матбугатны таратуда бик актив катнашалар. Татар журналлары бездә казах телендәге журналлардан ким таралмый», – дип, бик сөендереп җибәргәннәр иде. Соңгы ике-өч еллык саннарны язып алдым. Казанга кайткач, аларны үзебездәге абунәчеләр саны белән чагыштырып карадык. «Казан утлары» белән «Азат хатын»га язылучылар микъдарының, ягъни мең кешегә тиңләп исәпләү нәтиҗәләренең, ике республикада да бер чамадарак булуы ачыкланган иде. Әйе, казах, үзбәк кардәшләр мәмләкәтләрендә гомер итүче милләттәшләребез ул дәвердә әле туган-үскән илләре белән тыгыз элемтәдә яшәде. Газета-журналларга язылу хакы да ярыйсы ук арзан иде. Әйтик, «Казан утлары» журналына бер еллык язылу хакы җир читендә урнашкан Владивостокта да, Казандагы кебек үк, алты сум гына тора иде. Хәзер исә почта хезмәтеннән файдалану бәясе генә дә гади абунәче бюджеты күтәрә алмас дәрәҗәгә җитте…

Әлбәттә, Алма-Атага барып урнашканның икенче иртәсендә иң элек Язучылар берлеге йортына юнәлдем. Берлек идарәсе рәисе Әнүәр Әлимҗанов белән элегрәк Мәскәүдә очрашкалаган идек. Үзе белән танышканчы ук аның тарихи вакыйгаларга кагылышлы әсәрләре барлыгын да белә идем. Казахстанда русча нәшер ителүче «Простор» журналында басылган «Отрар хатирәсе» повестьларын бик кызыксынып укып чыккан һәм, тәрҗемә ителсә, татар укучысы өчен дә гыйбрәтле бер әсәр булачак дигән фикергә килгән идем. (Дүрт повестьтан торган шул әсәре өчен автор ул елларда Җәваһарлал Неру исемендәге халыкара бүләккә дә лаек булган иде.) Мәскәүдә узган бер җыелышта очрашканнан соң шул хакта да сүз булды. Ул миңа шул шәлкемгә кергән повестьларының казах телендә чыккан вариантларын җибәрергә вәгъдә бирде. Шулар нигезендә мин аның ике повестен тәрҗемә итеп, нәшриятка тапшырган идем*.

Әнүәрнең киң, иркен эш бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Иң элек ул хатыны Флюраның да безнең милләт вәкиле булуын, шуңа күрә татар мәдәнияте, татар әдәбияты белән аеруча нык кызыксынуларын бәян итте: «Татарстан белән Башкортстаннан килгән бер генә артистның да чыгышын карамыйча калмыйбыз. Илһам Шакиров белән Ренат Ибраһимов җырлавын бигрәк тә

---

* *Әлимҗанов Ә.* Отрар хатирәсе. – К., 1974.

үз итеп тыңлыйбыз. Мәскәүгә барган саен русча басылган берәр татар китабын алмыйча кайтмыйм», – диде. Кызганыч, чит-ят җирләрдә үскән яшьрәк буын вәкилләре кебек, аның Флюрасы да татарча укымый икән. Аның нәселе инде байтактан бирле иленнән аерылып яшәгән. Шулай да Флюра үзенең кайсы милләт вәкиле булуын онытып бетермәгән икән әле. Соңрак, казах язучылары белән якыннанрак аралаша башлагач, совет чоры зыялы катлавының байтагының теге яки бу рәвешле үз халкым вәкилләре белән кан кардәшлек дәрәҗәсендә икәнлеген ачыкладым. Бер-беребезне дус күреп йөрешкән күренекле язучылардан Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Сатимҗан Санбаев, Морад Әүэзов, мәсәлән, шундый шәхесләрдән иде. Картрак буын зыялылары арасында андый кушма милләтле гаиләләр тагын да күбрәк, диделәр. Әйтик, Социалистик Хезмәт Батыры исеменә лаек булган язучы Габит Мөсреповның җәмәгатен дә Мәскәүдә үскән татар кызы дип әйтәләр иде. Саин һәм Морад каләмдәшләремнең аналары Сәхипҗамал белән Фатыйма да безнең милләттән – нугай кызлары. Галимнәр, композиторлар, артистлар арасында да андый кушма канлы гаиләләр ишле иде ул елларда.

Әлбәттә инде, Әнүәр белән язучылар оешмалары эше, китап, журнал нәшриятлары эшчәнлеге турында да сүз булды. Сөйләшә-сөйләшә озаграк та утырганбыз, ахрысы. Чәй кәсәләре тотып бүлмәгә кабат кергән секретарь ханым:

– Сезне анда Композиторлар берлеге рәисе көтеп утыра. Керсенме? – дип сорады.

Әнүәр: «Керсен. Безнең яшерен сүзебез юк», – дигәч тә бүлмәгә бик сөйкемле бер ханым килеп керде. Зифа буйлы, мөлаем кыяфәтле, уртача яшьләрдәге бу ханымны күргәч тә күңелдә «Чынлап та, бу чибәркәй композиторлар җитәкчесеме икән?» дигән уй да йөгереп үткән иде. Әнүәр минем кем булуымны әйтте:

– Лирон Хәмидуллин. Казаннан…

– Газизә Җубанова, – диде ханым, күрешкәндә.

Әхмәт Җубанов дигән композиторны да ишетеп белә идем. Ул Актүбә шәһәреннән илле чакрымдагы Тимер станциясендә туган. Латыйф Хәмиди белән бергә берничә опера иҗат иткән мәгълүм шәхес. Актүбә өлкәсеннән депутатлыкка да сайланган иде.

– Опералар иҗат итүче Әхмәт Җубановны ишетеп-укып белә идем. Ул бит Актүбә өлкәсеннән… Сез дә шул нәселдәнме? – дидем.

Ханым елмаеп торган арада Әнүәр:

– Әйе, мәрхүм Әхмәт ага Газизәнең атасы була. Хәзер ул атасы вазифаларын башкара – Казахстан композиторларының җитәкчесе һәм данлыклы консерваториябезнең ректоры.

Газизә дә сүзгә кушылды:

– Сез композитор Латыйф Хәмидине беләсезме? – диде.

– Беләм. Казанда күрешкәләгән дә идек. Ул бит сезнең әтиегез белән бергә берничә опера язган…

Газизә минем ничә көнгә килүемне, кайда тукталуымны белеште.

–Ерактан килгән кунак бит. Яңа кунакханәгә урнаштырдык, – дип, минем өчен Әнүәр җавап бирде. Аннары миңа табарак борылып: – Өр-яңа кунакханә әле ул. Урынны көнендә үк бирмиләр. Алдан телеграмм сугып дөрес иткәнсең.

– Ә, безнең Опера театры каршында ук икән. Бүлмә номерыгызны да әйтмәссезме?

Ни өчен сораганын ачыклап тормастан, мин ул ханымга бүлмә номерын әйтеп бирдем. Һәм, ике җитәкченең сөйләшер, киңәшер сүзләре бардыр дип, саубуллашып чыгып киттем. Ә кичен, тамак ялгап, бүлмәмә кереп утыруга, кемдер шалтырата:

– Лирон Хәмидуллин буласызмы сез? Хәзер мин килсәм, сөйләшеп утыра алабызмы? Латыйф Хәмиди агаң булам, – ди.

Димәк, Газизә Җубанова Латыйф агасының күңелен күрү өчен минем кунакханә номерын сораган булган икән. Фамилиямне дә кат-кат белеште: Хәмидуллин белән Хәмидинең үзара якынлыгы барлыгын да истә тотуы булгандыр, күрәсең.

Кулына алма, йөзем төргәкләре тоткан Латыйф ага кунакханәгә бик тиз килеп җитте.

– Мин бит Опера театрына янәшәдәге Түләбаев урамында гына торам. Моннан ерак түгел. СССР халык артисты мәрхүм Мукан Түләбаев белән дә иҗатташлар, дуслар идек. Казахстан гимнын да бергә эшләдек. Өченче автордаш итеп безгә соңрак Брусиловскийны беркеттеләр…

Киләсе көннәрдә ачыклавымча, композитор Түләбаев исемен йөртүче ул үзәк урамда казахның күп кенә күренекле шәхесләре гомер итә икән. Казах совет әдәбияты классиклары Мохтар Әүэзов, Сабит Мукановларның музей-квартиралары да шунда ук урнашкан иде. Ул елларда исән-имин эшләп ятучы каләм әһелләреннән Әнүәр Әлимҗанов, Шерхан Мортазаев, Тәхәви Ахтанов, Әким Тарази һ. б. Опера театры янәшәсеннән башланган шул урамда Латыйф агага күрше булганнар. «Абай» исемен йөртүче, Латыйф Хәмидинең төп йорты саналырдай Казах опера һәм балет театрын ачу карары исә 1933 елда чыга…

* * *

Латыйф ага Татарстанның хәзерге Кайбыч районында 1906 елның 17 июлендә туган. Җиде яше тулмастан, алар гаиләсе Урта Азия якларына чыгып китә. Үзбәк кардәшләребез илендәге Кәттә Курган шәһәренә килеп төпләнәләр. Шунда мәктәптә укыган елларында Латыйф ага мандолинада, 1917 елдан соң ачылган музыка мәктәбенә йөргәндә фортепьянода уйнарга өйрәнә. Тиздән илдә зур үзгәрешләр башлана. 1918 елның апрелендә Ташкент тирәлегендә яшәгән төрле милләтләр мәнфәгатен кайгыртырга тиешле Төркестан Совет Автономияле Республикасы оештырыла.

Дөрес, тиздән барлыкка киләсе СССР җирлегендә иң беренче булып оешкан ул автономияле республиканы Совет хакимияте соңрак никтер сирәк искә алды. Чөнки ул автономия кирәгеннән артыграк үзбаш булды сыман. Республика җитәкчелеге «автономия» төшенчәсен мөстәкыйль мәмләкәт рәвешендәрәк кабул итте бугай. 1940 елда басылган «Страна социализма» исемле калын рәсми белешмәлектә әлеге Төркестан да, 1920 елда оешкан Казах (дөресрәге, кыргыз-кайсак) автономияле республикасы да зурлап телгә алынмыйлар. Моның сәбәбен, бәлки, Төркестан милли мохтариятен оештыручыларның, шул исәптән аның башлыгы, «милләтче» казах Турар Ырыскуловның 1937—1938 елларда юк ителүе белән дә бәйләргә кирәктер. 1925 елның урталарында Төркестан белән Казах республикалары берләштерелә. Яңа Казах автономиясенең башкаласы итеп башка шәһәр билгеләнә. Ташкент исә мөстәкыйль бер шәһәр статусында кала. Фәкать 1929 елда гына үзбәк кардәшләр мохтарияте башкаласы Сәмәркандтан шушында күчерелә. Алдарак китереләсе хатирәләрдән күренгәнчә, егерменче еллардагы Ташкент шәһәрен үзенчәлекле бер татар мохтарияте үзәгенә тиңләрлегебез дә бар. Ләкин ул дәвер безнең әдәбият, мәдәният тарихында әлегә ныклап өйрәнелмәгән.

1919 ел ахырында Төркестан республикасының Мәгариф халык комиссариаты җитәкчесе итеп татар язучысы Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. Дөресрәге, махсус бер поезд анда бер төркем татар зыялысын «төяп» китәчәк. Башка җитәкче оешмаларга да безнең милләттәшләр килә. Әйтик, 1918—1919 елларда Оренбургта мөселман хәрби-революцион комитет җитәкчеләреннән булган, «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә Халык мәгарифе институтын оештыруда катнашкан Кәрим Хәкимов 1920—1921 елларда Төркестан АССР коммунистларының башлыгы вазифасын башкарачак. Мөгаен, аның катнашы беләндер 1920 елда автономиянең башкаласы Ташкентта да төрки милләтләрне берләштергән Белем йорты эшли башлый. Аның карамагында татар, үзбәк, казах бүлекләре булган Халык мәгарифе институты ачыла. (Хәзер ул уку йортын үзбәк кардәшләр илендә еш кына «Татар мәгарифе институты» дип тә йөртәләр бугай.) Дүртьеллык ул уку йорты бусагасын атлап керүчеләр арасында шул җирлектә гомер иткән төрле милләт вәкилләре була. Үзбәкстанның булачак халык шагыйре Гафур Голәм, казах халкының киләчәктә шундый ук дәрәҗәле исемнәргә лаек буласы язучысы Мохтар Әүэзов та шул институтта укыячак. (Аны тәмамлагач, Мохтар укуын Ленинград университетында дәвам иттерәчәк.) Латыйф Хәмиди дә тиздән әлеге институтка укырга керәчәк, Гафур, Мохтарлар белән аралашып, бер чорда укыячак. Мәгариф институтын ул 1926 елда уңышлы тәмамлап чыга. Дөрес, аны ул бер ел элек үк тәмамларга тиеш була. Ләкин 1924—1925 уку елын Латыйф Казандагы музыка мәктәбенә керү хыялы белән йөреп уздыра.

Чынлап та, әлеге Мәгариф институтын оештыручылар да, нигездә, безнең милләт вәкилләре була шул. Аның мөдире һәм укытучысы Габдулла Мостакаев – шулай ук Оренбургтагы «Хөсәения»дә дә укыган, «Шура» журналында очерк, хикәяләре күренгәләп торган белемле генә шәхес. Татар әдәбиятыннан тыш казах, үзбәк әдәбиятларына багышлап җитди хезмәтләр язган, шул ук «Шура» мәҗмугасы авторларыннан берсе булган Габдрахман Сәгъди дә, 1916 елда Мәскәү коммерция институтын тәмамлагач та Ташкентка килеп төпләнгән Касыйм егете Ибнеәмин Янбаев та монда укытачаклар. Мөгаен, Мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев тә әлеге бердәнбер рәсми уку йортында укытучы вазифасын үтәүдән читләшмәгән булгандыр.

Белемгә сусаган башка татар яшьләрен дә әллә кайлардан үзенә тарта бу уку йорты. Әйе, 1921 елның җәй башында, ачлыктан качып, монда Рәсәй өлкәләреннән дә бик күп татар зыялысы, татар байлары һәм яшьләре килеп тула. Ташкентта аерым-аерым татар мәхәлләләре барлыкка килгән кебек була. Бу елларда без ул шәһәр урамнарында шагыйрьләрдән Һади Такташ, Зариф Бәшири, татар театрының күренекле шәхесләреннән Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Сәет Булатов, Әсгать Мәҗитов, әдәбият-тел галимнәреннән Габдрахман Сәгъди, Гыйбад Алпаров, композитор Салих Сәйдәшев, күренекле җырчылардан Газиз Әлмөхәммәдев, Фәттах Латыйпов һ. б. бик күпләрне күргән булыр идек. Заманында Тукай белән якыннан аралашкан Кәбир Бәкер дә монда татар һәм үзбәк телләрендә «Олуг Төркестан» газетасын нәшер итүгә керешә. 1980 елларда Ташкентта нәшер ителгән бер фәнни журналда басылган мәкаләдә Салих Сәйдәшевнең дә монда танылган драматург Хәмзә Ниязи белән бер пьесаны сәхнәләштерергә йөргәнлекләре хәбәр ителә. (Бездә исә С. Сәйдәшевнең Ташкентта булганлыгы искә алынмый шикелле.) Мәгариф комиссариатының бер түрәсе дә булган касыймлы Ибнеәмин Янбаев тырышлыгы белән 1920 елда Ташкентта Тукаебызның русчага тәрҗемәдә беренче китабы да дөнья күрәчәк. («Избранные стихотворения», тәрҗемәчесе – Валентин Вольпин, кереш мәкалә авторы – Ибнеәмин Янбаев.)

1920 елда Самарада театр студиясен тәмамлаган, бер кыш Оренбург татар театрында эшләгән зур бер төркем артистны да Төркестан Республикасы ул вакытта үзенә сыйдыра. Шәһәр үзәгендә урнашкан Белем йорты һәм аның янәшәсендәге Приказчиклар клубы күчмә татар театры үзәкләренә әвереледереләләр. Алар эшендә үзбәк театрына нигез салучылардан Хәмзә Хакимзадә Ниязи да катнаша. Әдипләребез, артистларыбыз иҗатында Ташкентта узган гомер эзләрен дә чамалап була. Әйтик, Такташ мирасында яки Т. Гыйззәт иҗатында. 1923 елда Ташкенттан кайткач, ул, мәсәлән, үзбәк тормышыннан алынган пьесасын – «Каһәрле мөһер»не яза. Әсәр Сембер, Казан театрларында уңыш белән бара.

Ә Латыйф Хәмиди өчен бу еллар иҗатка омтылыш, аякка басу еллары була. Русчалабрак әйтсәк – старт алу еллары. Шул елларда аның кайбер сәхнә әсәрләрен музыкаль «бизәү»дә катнашуы мәгълүм. Шунда аның беренче көйләре туа. Мәдәният-сәнгать кичәләрендә аларны сәхнәдә үзе үк мандолина һәм фортепьяноларда уйный. Монда таратылган җилем басма «Белем йорты» журналында үзбәк Гафур Голәм, казах Мохтар Әүэзов, Һади Такташ һ. б. шагыйрьләрнең шигырьләре белән янәшә Л. Хәмидинең шигъри иҗат үрнәкләре дә урын алгалый. Әдәбият укытучысы Габдрахман Сәгъди аның киләчәктә шагыйрь буларак танылa алуына шикләнми.

Әйе, шушы институтта укыган һәм шушы үзенчәлекле мохиттә яшәгән чорда Латыйф Хәмидинең тәүге көй-җырлары да яшьтәшләре тарафыннан җылы кабул ителә. Ул монда татарча «Беренче вальс» көен дә иҗат итә. (Соңрак ул көй Муса Җәлил сүзләре белән Мәскәүдә, «Октябрь баласы» журналында, әүвәл «Уңыш җыры» исеме белән басылып чыгачак.) Муса Җәлил белән алар беренче тапкыр Казанда, 1924 елның җәй башында очрашачаклар. Әйе, Латыйфның иҗади үсешен күзәтеп торган милләттәшләре аңа Казанга барырга, яңа ачылган Шәрык музыка техникумына укырга керергә киңәш итәләр. Институт җитәкчесе, унынчы еллардагы «Шура» журналында байтак шигырьләре басылган иҗади фикерле Габдулла Мостакаев та ул тәкъдимне хуплый. «Бар, тәвәккәлләп кара», – дип киңәш итә. 1924 елның җәендә Латыйф ерак юлга җыенып чыгып китә.

Ләкин Казанда аны гына көтеп тормаганнар икән. Алты-җиде яшеннән туган иленнән читтә яшәгән яшүсмернең өметләре акланмый. Балачактан күнегелгәнчә, әкә-укә, мәйле ише күп кенә үзбәк сүзләрен кушып, ашыгыбрак сөйләүче кечерәк буйлы бу унсигез яшьлек малайны руслар түгел, үз милләттәшләре дә баштарак кабул итеп бетерми. Ят күрә. Шәрык музыка мәктәбе дип аталган уку йортында да ул вакытта әле үз милли кадрларыбыз булмый диярлек. «Композиторлыкка укырга телим» дип ерактан килгән егетне, бездә андый бүлек юк дип, кире борып җибәрәләр. Ләкин аның «үз Ташкәнтенә» тиз генә кайтып китәсе килми. Ул педагогия техникумына хор җитәкчесе буларак эшкә керә. Музыка техникумы карамагында эшләгән өстәмә курска йөри. Ноталы язуны тирәнтенрәк өйрәнергә тырыша. Заһидулла Яруллин, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев белән аралаша. Кешеләр белән тиз аралашучан егет монда да үз ишләрен тиз таба: Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Әнәс Камал белән әдәби очрашуларда катнаша. Бигрәк тә Оренбургтан килгән рабфак укучысы Муса Җәлил белән омтылыш-теләкләренең уртак икәнлеге беленә. Өстәвенә икесе дә мандолинада оста чиртәләр, икесе дә шигырь сөяләр. Казан яшьләре аларны үз итә башлый. Ташкенттагы дуслары да онытып бетермиләр – ике арада хат йөреп тора. Латыйфка «монда кайтып укуыңны тәмамла» дип киңәш итүчеләр

дә була. Беренче башлап музыкаль белемгә өйрәтүче укытучысы Гыймад Тимербулатов та аңа «әүвәл укуың тәмамла» дип үгет бирә. Л. Хәмиди, башлаган укуын дәвам иттерергә карар кылып, 1925 елда Ташкентына кайта.

* * *

Әлеге уку йортын тәмамлау таныклыгын алганнан соң, ул Мәскәү музыка техникумына керергә ният кыла. Бу вакытта инде аның Кәттә Курган музыка мәктәбендәге укытучысы, мандолинада оста уйнаучы остазы Гыймад Тимербулатов та үз Мәскәвенә кайтып төпләнгән була. Латыйфны ул Мәскәүдә якын күреп кабул итә. Мәгълүм Әсәдуллаев йортындагы үз фатирына урнаштыра. Бу хәл 1927 елның җәендә була. Беренче Мәскәү музыка техникумының композиторлар әзерләү бүлегенә кабул ителеп, тулай торакка күчкәч тә, Латыйф Гыймад агаларына бик еш килеп йөри. Көз көнендә бер килүендә ул шушы йорт тирәсендә Муса Җәлил белән кабат очраша. Муса да Мәскәүгә укырга дип килгән, Әсәдуллаев йортында яшәүче элекке танышы Дәүләтшиннарга фатирга төшкән икән. Әйе, Габдулла Дәүләтшин берара Орскида милли комиссар булган, «Ирек йолдызы» газетасын нәшер иткән кеше. Аның җәмәгате исә Мирхәйдәр Фәйзинең сеңлесе иде. «Муса университет ятакханәсенә урнашкач та, бу гаиләгә еш килеп йөрде. Беренче кышта без шунда бик еш очраша идек», – дип искә алган иде Латыйф ага. Ике иҗади күңелле шәхеснең дуслыгы шушы көзгә бәйле рәвештә дәвам итә.

Алар шул чорда популяр булган дистәләгән җырның көен һәм сүзен бергә язалар. Башлыча яшьләргә һәм укучы балаларга багышланган җыр-көйләрне – «Комсомол җыры», «Көз җитте», «Күңелле яшьләр», «Ленин турында җыр»ны аларның яшьтәшләре урамда да, уку йортларында да бик яратып җырлыйлар. «Кызыл очкыч җыры» марш буларак күпләр күңеленә хуш килсә, «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?» романсы татар көенә яңалык алып килүе белән истә кала. Латыйф ул елларда Мәскәүдә яшәүче Әхмәт Ерикәй шигырьләренә дә берничә көй иҗат итә. Аларның күбесе Муса Җәлил редакцияләгән журналларда ноталы язмада басылып та чыгачак.

Л. Хәмиди 1931 елда техникумны тәмамлый. Әмма эшеннән һәм дусларыннан аерыласы килмичә, Мәскүдә яшәп кала. Бу вакытта инде ул «Октябрь баласы» журналының музыка бүлеге мөдире була. (Журнал 1932 елның декабрендә ябыла.) Шул ук Әсәдуллаев йортында урнашкан татар мәктәбендә җыр дәресләре дә алып бара, милли телләрдә китаплар нәшер итүче «Центриздат» белән дә хезмәттәшлек итә. Казахстанга эшкә билгеләнгәч кенә аның Мәскәүдәге дуслары белән арасы бераз сүрелә төшәчәк.

Беренче мәртәбә Казахстанга эшкә билгеләнүенең сәбәпләрен Латыйф ага миңа болайрак аңлаткан иде. Бердән, ул элек Урта

Азиядә яшәгән, андагы төрле милләт вәкилләре белән аралашкан. Шундагы халыкларның гореф-гадәтен, телләрен белә. Латыйф ага, шул сүзләрен раслагандай:

– Казах дуслар хәзер дә әле «Ташкентка барып төшү белән үк үзбәккә әвереләсең» дип шаярткалыйлар, – дип әйтеп куйган иде.

Икенчедән, ул дәвердә үзәк тарафыннан казах мәдәниятен торгызуга зур әһәмият бирелә. Утызынчы еллар башында Казахстанның Алма-Ата, Кызыл Урда, Семипалатинск кебек эре шәһәрләрендә бер-бер артлы берничә милли театр оештырыла. Опера театрын нигезләү турында карар кабул ителә.

– Казах иле өчен мондый тизләтелгән чаралар нилектән килә? Белмисез шул сез... Мондагы утызынчы елгы ачлык афәтен дә, халык күтәрелешен дә Рәсәйдә белүчеләр юк. Бездә дә ул хакта берни дә язмыйлар. Совет хакимияте ул фаҗигале елларны искә алуны яратмады. Боларны мин сиңа сер итеп кенә әйтәм.

Әйе, нәкъ менә шушы елдагы ачлык вакыйгаларыннан соң казах халкы тормыш-көнкүрешенә караш төптән үзгәрә. Иксез-чиксез булып яткан казах илендә яңа сәнәгать корылмалары төзелеше тизләтелә. Илнең төрле тарафыннан монда тәҗрибәле белгечләр җибәрелә. Театрлар ачыла. Үз теләкләре белән иректә килүчеләр белән бергә монда «сөрген срогын» үтәргә тиешле бихисап сандагы галим, профессорларга да урын табыла.

* * *

Латыйф ага үзенең тиздән Казахстанга эшкә чакырылуын шушы ачлык вакыйгасына һәм бер үзенчәлекле китапны нәшер итүенә бәйләде. Шушы вакыйгалар аның кебек белгечнең анда кирәк булганлыгын дәлилли. 1933 елда ул «Центриздат» нәшриятында бик тә үзенчәлекле бер китапны чыгаруда актив катнаша. Әйе, шул елда этнограф һәм композитор А. В. Затаевичның «Казахстан татарларының илле җыры» җыентыгы басылып чыга. Бу китапны Мәскәү җәмәгатьчелеге дә, казах зыялылары да хуплап кабул итә. (Андый мирасның барлыгын безнең галимнәр беләме икән?) Алар Л. Хәмидине Алма-Атада эшли башлаган Казах драма театрының музыка бүлеген җитәкләргә чакыралар. Анда ул элекке танышлары белән дә кабат очраша. Ташкент уку йортында бер чорда укыган, бергә-бергә шигырьләр, мәкаләләр язышкан Мохтар Әүэзов әлеге театрны оештыручыларның берсе икән. Аның шул театрда сәхнәләштерелгән берничә пьесасын музыкальләштерү бурычы Латыйфка йөкләнә. Шул рәвешле ул монда беренче мәртәбә Абай тормышы һәм иҗаты белән якыннан таныша. М. Әүэзовның «Кобланды батыр» дастанына нигезләнгән пьесасыннан соң ул «Абай» драмасын музыкальләштерүдә дә катнаша. Бер үк вакытта аңа Казахстан ССР радиокомитеты карамагында хор коллективын оештыру бурычы да йөкләнә. Шушы ике-өч еллык дәвердә аның казах халкы моң-аһәңнәренә

яраклаштырып иҗат иткән беренче казах җырлары да туа. Ильяс Җаңсыгуровның Кызыл Армиягә багышлы шигыре – «Кызыл кыран»га (Кызыл бөркет, Кызыл лачын) нигезләнгән җыр бик тә уңышлы килеп чыга. Аны һәр җирдә мактыйлар, җырлыйлар. Ләкин ул җыр бик кыска гомерле була. Шагыйрьнең тиздән кулга алынуы сәбәпле, «Кызыл кыран»ны телгә алу һәм җырлау дистә елларга кичектерелә.

Бу елларда әле Латыйф Хәмиди Казан һәм Мәскәүдәге иҗатташлары белән бөтенләйгә аерылып өлгерми. Казах илендә вакытлыча гына эшләп, тәҗрибә туплармын да, туган төбәгемә кайтырмын дип хыялланып яши. Мәскәүдә уку елларында аралашкан Муса Җәлил, Мансур Мозаффаров һ. б. белән хәбәрләшеп тора. Мәскәү консерваториясе каршында татар опера студиясе оешкан көннәрдә аңа да ул студиягә кабул ителеп, югары музыкаль белем алу мөмкинлеге барлыгы турында хәбәр итәләр. Һәм 1936 елда ул янә Мәскәүгә килеп төшә. Монда элекке һәм яңа дуслар, иҗатташлар белән бергә күләмле музыкаль әсәрләр иҗат итү серләрен үзләштерә башлый. Бу чорда аның партадашлары Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһановлар була. Нәкъ шушы елларда Латыйф ага татар халкының яраткан көйләреннән «Галиябану», «Каз канаты», «Ком бураны», «Су буйлап», «Сарман», «Шомыртым» һ. б. ны, хор өчен эшкәртеп, нотага сала башлый. Соңрак та ул шушы эш белән шөгыльләнүдән бизми һәм, тулы бер китаплык мая җыелгач, 1964 елда аларны Мәскәүдә бастырып та чыгара*. Студияне тәмамлаганда, диплом эше итеп «Татар бию көйләренә сюита»ны нотага сала. Җитәкче укытучысы, профессор Г. Литинский ул симфоник сюитаны бик уңышлы әсәр дип кабул итә. Иҗатташ иптәшләреннән кемнәрдер балет, кемнәрдер опера өчен музыка иҗат итә. Мәсәлән, Н. Җиһанов «Качкын», М. Мозаффаров «Галиябану» операларын эшләргә шул чорда тотына. Җырлар язып кына чикләнүчеләр дә була.

1938 елның җәй башында студиядә укулар тәмамлана. Эшкә билгеләнү көннәре килеп җитә. Кемнәрдер алдан ук Казанда ачылачак Опера театрына эшкә билгеләнгән була. С. Сәйдәшев элекке эшенә – Дәүләт драма театрының музыкаль бүлеген җитәкләргә дип кайтып китә. Л. Хәмидигә һәм тагын кемнәргәдер Татарстан республикасының мәдәният идарәсеннән киләсе чакыру кәгазе һаман күренми. Нәкъ шул вакытта Ленинградтан кайтып килүче казах артистлары һәм М. Әүэзов Мәскәүдә пәйда булалар. Мохтар һәм әлеге таныш артистлар аны кабат Алма-Атага кайтырга димлиләр. «Бездә халык музыка уен кораллары оркестры эшли

* Китап исемен ачыклый алмадым. Үзе белән сөйләшкәндә язып куймаганмын. М. Нигъмәтҗанов та шундый хезмәтләргә багышлы китабында аны искә алмый бугай.

башлады, аңа дирижёр кирәк. Син ул эшкә бар яктан да килешле зат», – ди М. Әүэзов. Шулай итеп, язмыш талантлы татар композиторын тагын үз иленнән читкә алып китә. Дөрес, Алма-Атада аны бик зурлап каршылыйлар. Гаилә белән яшәрдәй фатир бирәләр. (Бу вакытта Казанга кайткан студиячеләр гаиләләренең күпчелеге, шул исәптән Муса Җәлил гаиләсе дә вакытлыча кунакханә бүлмәләренә урнаштырылган була.) Шул көздә үк Латыйф ага әлеге оркестрның баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе итеп тәгаенләнә. Хәзер дә уңышлы эшләп килгән, дөнья буйлап сәяхәт кылудан туктамаган, XIX йөз көй чыгаручысы һәм оста кубызчы-скрипкачы Кормангазый исемен йөрткән ул Дәүләт оркестры белән якташыбыз биш ел җитәкчелек итә. (Соңгы тапкыр бу оркестр Казанга 2003 елда килде. Якташыбызның берничә әсәрен дә башкарды.) Шул чорда аның гомерлек дан китерердәй әсәрләреннән «Казах вальсы» (1940), чак кына соңрак «Былбыл» (1945) һәм башка җырлары туа. Якташыбызның казах илендә иҗат иткән җырларының саны хәзер өч йөзгә якынлаша. 1960 еллар башында Казахстанда Татар әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре, һәм тиздән шундый ук чара Казанда уздырылуы уңаеннан, Латыйф ага татар шигыренә нигезләнеп тагын берничә көй яза. Шулардан иң танылганы, сәхнәдән еш кабатланганы, мөгаен, «Иртәләрен, кичләрен» җырыдыр. Хәсән Туфан сүзләренә иҗат ителгән җыр.

* * *

Казахстанда яшәгән дәвердә, Латыйф Хәмидинең өч опера, бер оперетта, берничә сюита һәм халык яратып кабул иткән дистәләгән казах җырын иҗат иткәнлеге мәгълүм. XIX йөз казах көйчеләреннән Кормангазый, Дәүләтгәрәй, Бирҗан һ. б. әсәрләрен оркестрда башкару өчен эшкәртүче дә ул була. «Балалар өчен фортепьяно әсәрләре», «Балалар өчен җырлар», «Думбрада уйнау мәктәбе» һ. б. уку-өйрәнү әсбапларын да ул төзи һәм нәшер итә.

Мохтар Әүэзов «Абай» драмасы җирлегендә тиздән опера либреттосын әзерли. Шуны чын опера рәвешенә китерүне яңарак оешкан Композиторлар берлеге рәисе Әхмәт Җубанов белән опера студиясендә укып кайткан Латыйф Хәмидигә йөклиләр. Бу йөкләмә нәкъ авыр сугыш башланган көннәргә туры килә. Халык уен кораллары оркестрында да эшне дәвам итәсе, сугыш батырларына багышлап җырлар да язасы, операга да җан өрәсе бар бит. 1942 елдан ул музыка училищесында, 1944 тән яңа ачылган консерваториядә дә укыта. Мактаулы доцент.

– Ул елларда көн-төн эшләдек. Ярты көн миндә яки Әхмәтләрдә арияләр язып утырсак, икенче ярты көнне училищеда дәрес биреп уздыра идек. Кичләрен Опера театрында да эшләр чыгып кына тора... Өйгә кайтуга, ястык өстенә аварлык кына хәл кала

иде. Авыр сугыш вакыты кешеләренең күңелен күтәрүгә өмет ителгән дистәләгән җыр язганмын. Сугыш каһарманы Маншук Маметовага, Панфилов дивизиясе батырларына, партизаннарга багышлы җырларым әле хәзер дә радиотапшыруларда кулланыла…

Бик күп тырышлык куелган, байтак сынаулар үткәннән соң, ниһаять, «Абай» операсы язылып бетә. Мәскәү, Киев, Ленинградлардан эвакуацияләнгән музыка, сәхнә белгечләре ярдәмендә сәхнәләштерелүгә керешелә. 1944 елда тамашачы операны дәррәү алкышлап кабул итә. «Абай» – җирле милли кадрлар тарафыннан иҗат ителгән беренче милли опера. Дөрес, аңа кадәр, 1934 елда ук, бер тәҗрибә булып ала. Опера сәхнәсендә «Кыз җибек» («Ефәктәй кыз») дастаны нигезендә эшләнгән музыкаль әсәр уйнала. Ләкин аның музыка авторы башка милләт вәкиле – Евгений Брусиловский була.

«Абай» операсы – казах опера сәхнәсенең иң уңышлы әсәре. Аның әлегәчә куелмый, уйналмый калган елы юк. Мәскәүдә уздырылган казах мәдәниятенә багышлы чараларда да «Абай» сәхнә түрендә йөри. Ул операда баш рольләрне башкаручы Күләч Байсәетова, Роза Җаманова, Бибигөл Теләгәнева, Ирмәк Серкебаев, бертуган милләттәшләребез Ришат һәм Мөслим Абдуллиннар дөнья күләмендә танылган артистлар дәрәҗәсенә ирештеләр.

Алда әйтеп киткәнемчә, 1945 елда шушы өч композитор тарафыннан Казахстан ССРның үз гимны иҗат ителә. Бүген дә Казахстан халкы милләттәшебез катнашында иҗат ителгән шул гимн музыкасын ишетеп уяна һәм шуны тыңлап йокыга китә. Бәлки, бер генә мәртәбә булса да шул гимн музыкасын күренекле милләттәшебезгә багышлы берәр чарада безгә дә ишетергә насыйп булыр, дигән бер хыял яши күңелемдә.

«Абай операсы»н язу тәмамлангач та, Л. Хәмиди акын Җамбулның йөз яшенә багышлап бер актлы «Җамбул белән Айкуныс» операсын эшләргә керешә (1946). Соңрак, 1949 елда бу музыкаль әсәр тулыландырылып, «Җамбул» исеме белән кабат эшләнә һәм 1952 дә сәхнәләштерелә. Сугыш барган көннәрдә үк башланган һәм төрле сәбәпләр белән бераз тоткарланган «Теләгән Туктаров» операсы да, ниһаять, 1947 елда төгәлләнә һәм сәхнәләштерелә. Сугыш батырына багышланган бу опера да Латыйф ага белән Әхмәт Җубановның уртак җимеше була.

– Әхмәт белән без утызынчы еллар ахырында Кормангазый исемендәге оркестрда бергә эшли башлаган идек. 1939 елда Композиторлар оешмасын да бергә нигезләдек. Беренче көннән башлап бүгенгәчә анда идарә әгъзасы булып торам. Музыка сәнгатенә багышлап йөзләгән мәкалә, очерк язып бастырдым. Музыкантларга ярдәм итү фонды рәисе булуыма да дистә еллар инде. Төрле музыкаль чараларда жюри рәисе яки әгъзасы булган очраклар да еш кабатлана. Үпкәләр җаем юк. Читкә тибәрергә теләгәннәрен тоймыйм.

Хак әйтә Латыйф ага. Казах илендә аның абруе бик зур иде. 1942 елда аңа Казахстан ССРның атказанган артисты, 1966 да халык артисты мактаулы исемнәре бирелә. 1978 елда ул Көләч Байсәетова исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Берничә орден, медаль белән бүләкләнә. Әдәбият, сәнгать өлкәсендә хезмәт итүчеләр өчен Казахстан ССРның дәүләт бүләкләрен булдыру карары 1944 елда кабул ителә. Әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр өчен ул хәзер – Абай, музыка, театр осталары өчен Көләч Байсәетова исемендә йөртелә. Көләч – казахның танылган беренче опера җырчысы. Аңа 1936 елда ук (егерме дүрт яшендә) СССР халык артисты исеме бирелә. Хәер, казах опера сәнгатендә һәм музыка өлкәсендә дәүләтнең андый иң югары исемен яшьли алучылар байтак. Роза Җаманова, Мукан Түләбаев, Ирмәк Серкебаев СССР халык артисты исеменә 1959 елда, Бибигөл Теләгәнева белән Ришат Абдуллин 1967 дә лаек дип табылалар. Роза белән Ирмәккә андый зур дәрәҗәле исем бирелгәндә, әле егерме дүрт яшь тә тулмаган була. Талантлы, сәләтле иҗат кешеләрен шулай иртә бәяли белүдән үрнәк алырга кирәктер, мөгаен.

Өстәп шуны да әйтик, Көләч Байсәетова Латыйф аганың «Казах вальсы» белән «Былбыл» җырын иң беренче һәм үзенчәлекле моң вә күтәренке рухлы итеп башкаручыларның берсе санала.

– Арабыздан иртә китмәсә, без тагын да бергә күп нәрсә иҗат иткән булыр идек әле, – ди композитор, аның белән иҗатташ булу елларын искә төшереп. Артистка 1957 елда вафат була. Әмма аның җырлары, арияләре сиксәненче елларда да радио, телевидение репертуарыннан төшми җырланалар иде.

Латыйф Хәмиди 1948 елда Н. Баймөхәммәдев либреттосына «Балбулак» опереттасын иҗат итә. Бу әсәр аның шушы юнәлештәге соңгы хезмәте. Мирасында тагын берничә күләмле симфоник әсәре – сюиталары бар. Казахстанда элегрәк даими рәвештә башкарылган «Татар бию көйләренә сюита»дан тыш, иҗатташлары һәм музыка сөючеләр тарафыннан югары бәяләнгән «Кобланды» һәм «Алма-Ата» сюиталарын да атап үтәргә кирәктер.

Латыйф Габделхәй улы Хәмиди 1983 елда, җитмеш җиде яшендә, Алма-Атада вафат була. Ике-өч ел элгәре генә бергә гомер иткән карчыгы Сания дә гүр иясе булган. Аңа чаклы әле без тагын бер мәртәбә «Алатау» кунакханәсенең иркен бүлмәсендә иркенләп сөйләшеп утырган идек. 1980 елның июнь башларында, замандашы Сабит Мукановның сиксән еллык юбилее билгеләп үтелгән көннәрдә. Латыйф ага миңа җитмеш яшенә атап чыгарылган буклетын (иҗат биографиясе язмасын) бүләк итте. (Аның җитмеш яшьлек юбилеен билгеләп үтү тантанасы 1976 елның 8 декабрендә Абай исемендәге опера һәм балет театрында бик зурлап уздырыла.) Шул очрашуда Латыйф ага Әхмәт Җубанов белән икесенә багышлап повесть иҗат ителүен, ләкин хәзергә ул әсәрнең үзендә юклыгын белдергән иде. Блокнот битенә «Повесть авторы Лия Җаһанова» дип язып куйганмын. Музыка белгечләре

А. Юсфин (1964) Мәскәүдә, Б. Гизатов (1966) белән Б. Ерзакович (1978) Алма-Атада «Латыйф Хәмиди» исемле хезмәтләрен нәшер иткәннәр. «Казахстан ССР» энциклопедиясенең 4 нче томында* да якташыбызга багышлы төпле мәгълүмат бар. Ә «Татар энциклопедиясе»нең 6 нчы томында 424 нче битнең беренче баганасы аның биографиясен һәм иҗатын кыскача барлауга багышланган. Латыйф агабызның күпләребез күңеленә хуш килгән кабатланмас иҗади мирасы мәңге онытылмасын дисәк, аларны ешрак кабатларга кирәктер. Күңелләрдә сүнмәс дәрт уяткан «Татар бию көенә сюитасы»н да, яшьлек дәрте белән иҗат ителгән вальс көйләрен дә замандашларым сагынып көтәдер дип беләм...

*2021*

# ҮЗБӘК ИЛЕНДӘГЕ ВӘКИЛ

*(Очерк)*

1

Безгә кардәш үзбәк халкы хәзер биләгән җирләрнең күпчелек өлеше иң борынгы дәверләрдән бирле төрки кабиләләр биләмәсе булган. 1940–1950 елларда шул төбәкләрдә тарихи казылма эзләнүләр эшен башкарган күренекле совет чоры археологы һәм этнологы, академик Сергей Павлович Толстов Бохара белән Сәмәрканд шәһәрләрен төркиләр нигезләвен дәлилләп язган иде. X гасырга караган кульъязмаларга һәм археологик табышларга таянып дәлилли ул аны. Хәзер кайбер тарихчылар ул тасвирлаган кайбер борынгы шәһәр корылмаларының Чиләбе өлкәсендә яңарак табылган «Аркаим» шәһәрчеге төзелешенә якын булуын раслыйлар. «Зороастризм» дип аталган дини карашлар барлыкка килгән Сырдәрья елгасы тарафларындагы әлеге шәһәрләр белән әлеге «Аркаим» аралыгында тагын унлап «Аркаим»дай шәһәрчек калдыклары булганлыгын да яза галимнәр. Христиан, ислам диннәренә чаклы барлыкка килгән, гомум җиһан дөньясын күзалларга булышкан зороастризм дини карашларының фарсы һәм төрки телләрендә аралашкан бик борынгы кабиләләр яшәгән Сырдәрья буйларында барлыкка килүе дә очраклы хәл түгел. Шул ук академик Сергей Толстов тасвирлавынча, Сырдәрья буйларындагы борынгы шәһәрләр төзелешендә шумерларның тарихи-мәдәни чагылышы да ачык сизелә. (С. Толстов шумер сүзен «сумер» рәвешендә язган. Аның ни сәбәпле шулай язуын бу академикның барлык иҗаты белән танышкач кына ачыклау

---

* Казахская ССР. Краткая энциклопедия — Алма-Ата., 1991. — Т. 4. — С. 583–584.

мөмкиндер.) Төрки телле сүзләр кергән язмалар калдырган шумерлар илендә шулай ук фарсы теленең дә кулланылганлыгы мәгълүм. Димәк, бу телләр бик борынгы чорлардан бирле янәшә кулланышта булгандыр дип фаразлыйсы килә. Дөрес, безнең галимнәр әле шумерлар чорына караган дөнья белән таныш түгел диярлек. Шумерлардан калган язмаларны тикшерердәй шәхесләр дә безнең илдә күп түгел. Төрки халыклар тарихын һәм мирасын тирәнтен өйрәнгән бу академикның хезмәтләрен хәзер читкәрәк этеп кую, аңа әһәмият итмәскә тырышу күренешләре дә сизелә.

Төркиләр тарихына багышлап шактый хезмәтләр язган, шул исәптән Испаниядән килеп, Идел-Кама буе Болгарстаны халкы яшәеше белән кызыксынган Әбу Хәмид әл-Гарнати әл-Андалуси китабы 1960—1970 елларда русчага тәрҗемә ителгән.

Бүгенге көннең «зур» галимнәре төркиләргә бәйле булган борынгы тарихны күтәреп чыгу белән кызыксынмыйлар. Алар өчен ул Иван Грозныйның анасы ягыннан бабасы татар Мамай икәнлеген тану белән бер дәрәҗәдә кирәкмәс бер мәгълүматтыр.

Зөфәр Бәширов белән без 1994 елда Аркаимда булган идек. Башкортстан белән Чиләбе өлкәләре чикләрендә Дәрдемәнд эзләреннән йөргән вакытта, безне ул тарихи урынга Баймак шәһәре башлыгының урынбасары, милләттәшебез Шәүкәт Тутаев җибәргән иде. Аркаимда безне археологик эшләр башкаручы төркем җитәкчесе кабул иткән, казу эшләренең барышы белән таныштырган иде. Узган елда гына нәшер ителгән буклетын да бүләк иткән иде. Кайбер урыннарны фотога төшерергә дә рөхсәт итте. Зөфәр архивында алар сакланадыр, мөгаен.

Менә шушы бик борынгы чордан бирле төрки кавемнәре гомер кичергән төбәк кешеләре белән безнең бабаларыбыз элек-электән аралашып яшәгән. Мәсәлән, IX—XII йөзләр аралыгында, әле Европаның күпчелек илләре наданлыкта яшәгән дәвердә, Урта Азия төбәкләрендә фән, гыйлем үсеше, әдәбият, мәдәният үсеше бик алга киткән була. Әбүгалисина, Әл-Бируни, Әл-Хәрәзмиләр фәннең барлык өлкәләрендә диярлек яңадан-яңа ачышлар ясыйлар. Җирнең кояш тирәли әйләнү күренешен дә иң әүвәл шәрык астрономнары ачканлыгын раслаучы фактлар бар. Аксак Тимер әмир оныгы Олугбәк Сәмәрканд янәшәсендә ачкан зур обсерватория дә Урта Азиядәге беренче обсерватория булмаган. Бируни-Хәрәзмиләр күктәге йолдызларның торышын һәм хәрәкәтен билгеләүне исәпләүче формулаларны нигезләүчеләр санала. Һәм космоска очу дәверендә дә Бирунилар тәкъдим иткән формулаларны куллanулары турында академик П. Н. Федосеев та язып чыккан иде. Менә шундый җир ул Урта Азия. Академик С. П. Толстов борынгы Харәзем мәмләкәтен бөек Шумер дәүләтенең дәвамчысы булган дип тә фараз итә…

АКШның Индиана университеты галиме Аллен Франк Урта Идел буеның болгар-татарлары Харәзем һәм Урта Азиянең башка төбәкләре белән мәдәни һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен X йөзләрдә үк

башлап җибәргәннәр дип белдерә («Казан утлары», № 7, 1993). Әйе, шул төбәктәге ил һәм ханлыклар белән бабаларыбызның аралашып яшәвен дәлилләүче мисаллар байтак. «Кыйссаи Йосыф» дастанын иҗат иткән Кол Галинең XII йөз ахырларында шул җирләрдә укып йөргәнлеге мәгълүм. Әбүгалисина, Хәрәзми, Фәраби кебек белем ияләренең кульязма китапларының Идел-Урал төбәкләрендәге татар җирлегендә хәзер дә табылгалап торуы да күптәннән үк аралашуыбыз фикерен раслый.

Соңрак дәверләрдә, әле ул җирләр Россия биләмәсенә кермәгән XVII–XVIII йөзләрдә, Бохара, Сәмәрканд, Ташкент мәдрәсәләрендә укып кайткан шәхесләребез дә ишле генә булган. Аларны бер утыруда гына санап та бетерерлек түгел. Ул исемлектә Оренбург төбәгеннән чыккан шагыйрь Әбелмәних Каргалый да, патша Россиясендәге иң тәүге рәсми мөфтиебез Мөхәммәтҗан Хөсәенев тә бар. Үзе дә Бохара белән Сәмәркандларда белем эстәгән Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани беренче мөфтинең бабасы Мансур бине Габдеррәхим бине Әнәс әл-Җәбәли әл-Борындыкыйны да Бохарада укыган һәм шунда укыганда «Тәракыйбе мансурия» китабын язган дип белдерә. Әйе, Бохара, Сәмәрканд, Ташкентларда укыган шәхесләребез байтак. Ә менә шул төбәкләрдә яшәп иҗат иткән шәхесләребез булганмы соң? Шундагы мәдрәсәләрдә укыган шәкертләрнең беришенең иҗат мирасын күпләребез беләшикелле. Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Әбелмәних Каргалый, Габдерәхим Утыз Имәни шундыйлар исемлегенә керә. Алар шунда уку дәверендә үк иҗат та иткәннәр.

Алда исемнәре аталган шәхесләрнең беришесе, шул исәптән беренче мөфтинең бабасы да ерак төбәктәге мәдрәсәләргә кача-поса гына барып укый алганнар. Казах, Хива ханлыклары аша Россиядән Ташкент тарафына беренче рәсми кәрван 1739 елда юлга чыккан, дип хәбәр итә шул ук Аллен Франк. Әйе, Ташкент тарафына юлланган беренче кәрваннар казах ханлыклары чиге буенда, Җаек елгасының урта бер өлешендә урнашкан Орск каласыннан озатылганнар. Соңрак андый кәрваннар, Оренбург янәшәсендәге Каргалы, Меновый двор бистәләрендә оешып, икеөч елга бер йөри башлаган. Еракларга китеп укыячак шәкертләргә шул кәрваннарга эшкә ялланасы гына калган...

Хәзерге Үзбәкстан биләмәсенең төньяк өлеше – Ташкент төбәге 1865 елдан Рәсәйгә буйсындырыла. XIX йөз ахырында ашыгыч рәвештә Оренбург белән шул каланы тоташтыручы тимер юл төзелешенә керешәләр. Оренбург –Ташкент тимер юлы 1905 елның декабреннән эшли башлый...

## 2

Яңа оешкан Төркестан вилаяте идарәсенә беренче көннәрдән үк безнең милләт вәкилләре дә эшкә җибәрелә. Шулардан иң күренеклесе Шаһимәрдән Ибраһимов (1841–1892) булган. Орен-

бург губернасында туган бу морза 1867 елдан Төркестан вилаяте губернаторы ярдәмчесе һәм тылмачы вазифаларын башкарган. Бер үк вакытта, 1870 елның апреленнән алып, ул Ташкентта үзбәк һәм казах телендә атналык «Төркестан вилаяте гәҗите»н дә чыгара башлый. Россиядәге беренче төрки телле газетаны. 1881 елда чит илгә илчелек вазифасын үтәргә җибәрелгәнче, ул газетада аның күпсанлы үз хезмәтләре дә дөнья күрә. Шул исәптән ул анда фарсы теленнән тәрҗемә итеп «Мең дә бер кичә» кыйссасын да бастырып чыгара. Үзбәк телендә еллык календарьлар да төзеп бастыра. Дипломатик эшкә күчкәндә, әлеге газетаның мөхәррире итеп милләттәшен – Хөсәен Чанышевны калдыра.

Шушы заманнардан башлап Үзбәкстан төбәге әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә үз милләттәшләребезнең дә өлеш кертүен исәпкә алырга хаклыбыз. 1893 елда Сәмәркандта Оренбург сәүдәгәре Габделгани бай Хөсәенов тырышлыгы нәтиҗәсендә иң беренче яңа, җәдиди ысул белән укытучы мәктәп ачыла. Укырга бик тиз өйрәтүе сәбәпле, җирле халык аны «машиналы мәктәп» дип атаган. Ул мәктәпне ачу тантанасына Кырымнан Исмәгыйль Гаспринский да килгән. Шул ук гасыр ахырларында Арча-Әтнә тирәләреннән Сырдәрья төбәгенә барып чыккан Сәйфелгабид Мәҗитовның (1869–1938) да яңа ысул белән укытуга йөз тоткан мәктәпләр ачканлыгы мәгълүм. Милләттәшебез Сәйфелгабид бүгенге көндә Үзбәкстан Республикасында яшәгән каракалпак халкы әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр исәбендә. Егерменче еллар башында беренче каракалпак халкы әлифбасын төзеп чыгаруда башлап йөрүчеләрдән дә була ул. Каракалпак әдәбияты классиклары исемлегендә теркәлгән шагыйрь, прозаик һәм драматург С. Мәҗитов җирле театрга нигез салучы буларак та мәгълүм. Аның «Гөләм – Тайман» музыкаль драмасы, «Ирназар батыр» трагедиясе, «Соңгы киртә», «Байдагөл» драмалары каракалпак театры үсешенә зур өлеш керткән әсәрләр исәбендә саналалар. (Каракалпакстанда булганда, мин аның 1969 елда нәшер ителгән шигырьләр китабын да алып кайткан идем.)

Әлбәттә, 1917 елгы вакыйгалардан соң уртак хезмәттәшлек аеруча зур үсеш ала. 1918 елда Төркестан милли мохтарияте оештырыла (башкаласы 1925 елгача Ташкент каласында урнаша). Бу республиканың башлыгы казах милли хәрәкәте вәкиле, яңарак кына Себер сөргененнән кайткан Турар Ырыскулов булса, урынбасарларыннан берсе безнең милләт вәкиле, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаган Кәрим Хәкимов була. Бер елдан соң бу автономияле республиканың мәгариф комиссариаты җитәкчесе итеп үзебезнең язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев билгеләнә. Шул ук елда ул мохтарият башкаласы Ташкентта Халык мәгарифе институтын ачуны да хәл итә. Ул институтта үзбәк, казах бүлекләре була. 1921 елгы ачлык вакытында бериш татар зыялылары һәм яшьләре дә бу якларга

килеп туплангач, байтак кына татар яшьләре дә укый анда. Үзбәкстанның халык шагыйре Гафур Голәм истәлекләрендә аның Һади Такташ һ. б. татар зыялылары белән нәкъ шул елларда якыннан аралашканлыгы, бер-берсенең иҗат үрнәкләре белән танышканлыгы бәян ителә. Бу вакытта әлеге институтта укучы һәм укытучылар арасында булачак композитор Латыйф Хәмиди (студент), Габдрахман Сәгъди, Гыйбад Алпаров, Габдулла Мостакаев һ. б. була.

Совет хакимияте елларында үзбәк совет әдәбиятын баетуга үз өлешләрен кертүчеләрдән дә дистәләгән милләттәшебез исемен атарга була. Хәмзә исемендәге дәүләт бүләге иясе, әдәби һәм мәдәни «Шәрык йолдызы» һәм СССРның «Огонёк» мәҗмугасы рәвешендәге «Гөлстан» журналларының күп еллар дәвамында баш мөхәррире булган прозаик Әсгать Мохтар (аның үзенчәлекле «Чинар» романын мин татарчага тәрҗемә иттем), Урта Азиядә булган тарихи вакыйгаларны чагылдырган романнары белән танылган Рәүф Галимов, шулай ук тарихи темаларны чагылдырган повесть һәм романнар язучы һәм шулар нигезендә эшләнгән киносценарийлар авторы Җәүдәт Ильясов (ул да элегрәк «Ташкентская правда» газетасында, «Звезда востока» журналында бүлек мөдире дә булган), танылган прозаик һәм драматург, киносценарийлар авторы Зиннәт Фәтхуллин – совет чоры үзбәк әдәбиятын баетуга зур өлеш керткән шәхесләр. Бу исемлеккә әле мин ике дистәдән артыграк язучыны берләштергән Кырым татарлары өлешен дә, иҗади хезмәтләре алай бик зурдан исәпләнмәгән Шөгер төбәге кызы Мәрвә Җәләлетдинованы, Рауза Якубова-Бородина һ. б. кемнәрнедер исәпкә алмадым.

Ә иҗат чыныгуын Казанда башлаган, 1927 елда рабфак тәмамлаганнан соң калган гомерен Үзбәкстан ССРда уздырган, анда шактый зур эшләр башкарган якташым Габдулла абый Уразаев эшчәнлегенә аерым тукталу кирәктер дип уйлыйм.

## 3

Әйе, күренекле якташларыбызның берсе Габдулла Гыйматдин улы Уразаев 1930 еллар урталарыннан СССР Язучылар берлеге әгъзасы була. Кайбер хезмәтләрен ул Вил Уразаев яисә Вил Вилдан тәхәллүсләре белән дә бастыра. Мәсәлән, Казанда укыганда язылган өч пьесасын ул сәхнәгә шул исемнәр белән чыгара. Мәскәүдәге «Центриздат» тарафыннан 1927 елда нәшер ителгән «Серле шалаш» пьесасы да Вил Уразай исеме белән нәшер ителгән. Гомумән, 1920 еллар татар театрына багышланган хезмәтләрдә ул Вил Уразай буларак теркәлгән. Риза ага Ишморат та «Дусларым, остазларым» исеме белән чыккан истәлек китабында аны шул рәвешлерәк искә ала.

Язучы, мәгълүм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Гыйматдин улы Уразаевның гомере туган-үскән җиреннән читтә – Үзбәкстан

илендә уза. Тумышы белән ул элекке Самара губернасы Мәләкәс өязе Урта Кандалый авылыннан. Ягъни хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Абдул авылы кешесе. Рәсми туган елы – 1904. Туган авылы хәзерге Татарстан чигеннән утыз-кырык чакрымга көньяктарак урнашкан. Ләкин Габдулла ул авылда озак яшәми – гаиләсе тиздән Мәләкәс шәһәренә күчеп китә. «Атам анда извозчик хезмәтен үтәгән», – дип сөйләгәне хәтеремдә. Мәләкәстә ул Гатаулла ахун хәзрәтләре тоткан «Исламия» мәдрәсәсендә җиде ел белем ала. «Исламия»дә булачак күренекле артист Әсгать Мәҗит белән бергә укыйлар. Соңрак та язмыш аларны бер тирәдәрәк йөртә. Дөрес, буй җиткәч, читят җирләрдә йөргәндә рәсмиләштергән таныклыгына караганда, Габдулла Әсгатьтән дүрт яшькә кечерәк. Дөреслектә яшь аралары алай ук зур булмагандыр, мөгаен.

Язучы Тәүфыйк Әйдигә сөйләгән бер хатирәсендә Габдулла ага атасының өйгә «Вакыт» газетасын, «Шура» журналын алдыруын, аның шуларны һәм башка татар вакытлы матбугатын укып үскәнлеген әйтә. «Исламия»нең өлкән сыйныфларында укыганда шәһәрдә чыга башлаган «Мәләкәс тавышы» белән элемтәгә керә, беркадәр вакыт ул газета типографиясендә хәреф җыю эшендә дә катнаша. «Ундүрт яшемнән хәреф җыю һөнәрен үзләштердем», – дип искә алган иде. Бу һөнәр аның киләчәк көннәрендә дә кирәк булачак әле.

1917 елгы вакыйгалардан соң Совет хакимияте Сембер шәһәрендә укытучылар хәзерләүче курслар ача. Әсгать Мәҗит белән шунда барып керәләр. Анда алар Кави Нәҗми, булачак артист Сәет Булатов белән бергә укыйлар. Барый Тарханов оештырган «Кызыл йолдыз» драма түгәрәгенә бик теләп йөриләр. Драматург, «Көн» исемле газета мөхәррире Фәтхи Бурнаш, яшь татар комиссары Бәкер Белоусов белән якыннан аралашалар. 1919 елда Габдулланы кызылларның Бишенче армиясе нәшер иткән «Кызыл яу» газетасына хәреф җыючы итеп алалар. «Сугышып йөрергә буең кечкенә дип, комиссар Гыйлемдар Бәембәтев мине ул эшкә үзе билгеләде. Бер үк вакытта армия карамагындагы татар театр труппасында суфлёр булдым. Бөгелмә, Бәләбәй, Чишмә, Уфа шәһәрләре безнең тарафтан яулап алынды. Яулап алынган һәр авыл, һәр шәһәрдә спектакльләр куя идек. Ул труппада Камал I, Шакир Шамильский, Гыйлаҗ Казанский, җырчы артистлар Фәттах Латыйф, Әмин Зөбәеревләр уйнады», – дип сөйләгән иде Габдулла абый бер очрашу вакытында. Шул елларда Габдулланың беренче каләм хезмәте – «Мәхәббәт чәчәкләре» пьесасы күңелендә бөреләнә.

Уфада авырып китеп, кабат үз шәһәренә кайткач, Г. Уразаевны 1920 елның августында Мәләкәс өяз комсомол комитеты җитәкчелегенә сайлыйлар. Аңа «милли азчылык» вәкилләре белән эшләү бурычы йөкләнә. Ул «Яшьләр бәйнәлмиләле» газетасын чыгаруда катнаша. Самара губернасы татар-башкортлары

арасында эш йөртүче комиссар Халик Садрый аның белән бергә милли басмаханә һәм нәшрият эшен җанландырырга өмет иткән була. Ләкин...

Ләкин Идел буенда моңарчы күрелмәгән ачлык афәте башланган көннәрдә, 1921 елның җәендә Үзәк комсомол комитеты Габдулланы Төркестан Совет Автономияле Республикасына эшкә җибәрә. Хаҗәнт каласындагы ЧКга бүлек башлыгы урынбасары итеп. Соңрак, 1924 елда Сәмәркандтагы партия мәктәбендә укып чыккач, аны партия эшенә билгелиләр.

Күңеле белән ул туган якларына тартыла. Сәмәркандтагы партия мәктәбенең укыту бүлеге мөдире, шагыйрә Заһидә Бурнашева да аңа Казанга кайтырга киңәш иткән була. 1925 елның җәй ахырларында ул Казанга килеп төшә. Яшь комиссарларга хас булганча, күн киемнәр киенеп. Университет карамагындагы рабфакка укырга керә. Элекке танышларыннан Кави Нәҗми, Әсгать Мәҗитне эзләп таба, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, «Самаралы» Гадел Кутуй һ. б. белән аралаша башлый. Үзе дә кабат кулына каләм ала. Нәсер, шигырь, мәкаләләрен мондагы матбугат бик теләп бастыра. Әсгать Мәҗит, Риза Ишморат һ. б. белән театр уеннары уйнауда катнаша. Өч пьесага җан өрә. «Ике көрәш» белән «Еллар карынында» пьесалары укучы яшьләр кичәләрендә сәхнәләштерелә.

Казанда яшәү дәверендә ул Г. Кутуйның «Сулф» әдәби төркеменә якынрак тора. «Губернадашлар — якташлар идек бит», — дигән иде.

* * *

Үзбәкстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, шундагы иҗтимагый-әдәби эшчәнлек өлкәсендә танылган хезмәт ветераны Габдулла ага Уразаев белән мин 1976 елның октябрендә Ташкент шәһәрендә танышкан идем. Аның белән мине Ташкенттагы хезмәттәшем, СССР Әдәби фондының Үзбәкстан бүлеге директоры Шамил ага Аләдин таныштырды. Элегрәк елларда бу Кырым татары белән инде без Мәскәүдә күрешкәләгән идек. Ул миңа Үзбәкстанда яшәүче язучы милләттәшләребездән Әсгать Мохтар, Габдулла Уразаев, Зиннәт Фәтхуллин, Җәүдәт Ильясовлар турында бераз мәгълүмат биргән иде. «Казан татарлары үзбәк әдәбиятының да алгы сафында атлыйлар, бил бирмиләр», — дип, аларның һәрберсенең иҗатын да беркадәр барлап чыкты. Шуннан соң мин Әсгать Мохтарның ул чорда бик макталган романын — «Чинар»ны тәрҗемә иттем. (Ә. Мохтарның ата-анасы Башкортстанның хәзерге Благовар районыннан чыккан кешеләр. Әмирхан Еники белән алар күрше авылдашлар иде.) Соңрак, Габдулла ага белән очрашканнан соң, мин анда тагын берничә якташны таптым: Равил Мирхәйдәрев Актүбә каласыннан, Рәүф Галимов Чиләбе өлкәсеннән, Мәрвә Җәләлетдинова үзебезнең

Шөгер төбәгендәге Куакбаш авылыннан. Рус фамилиясе йөртеп тә, татарча иркен сөйләшүче язучылардан Чирмешән егете Сергей Волгинның, Иске Майна районының Кече Кандалый авылыннан чыккан Константин Волковның Ташкент каласында яшәгәнлеге дә мәгълүм.

Габдулла ага беренче очрашудан ук мине үз итте, кайбер серләрен дә ачып салды шикелле. Мәләкәс төбәгендәге авылда туганлыгымны белгәч: «Без икеләтә якташлар – өлкәдәшләр дә икәнбез бит», – дип, үзенең дә Ульяновск өлкәсе Иске Майна районыннан булганлыгын хәбәр итте ул. Югыйсә Үзбәкстан язучылар оешмасы белешмәлегендә аны, Казанда татрабфакны тәмамлавын истә тотыптыр, Татарстаннан дип язганнар иде. Мәләкәс шәһәрен искә төшерү икебез өчен дә кадерле булды.

«Рабфактан соң нишләп Казанда гына калмадыгыз соң?» – дип сорадым мин аңардан. «Партия солдаты бит без. Урта Азиядә ул вакытта русча белемле кадрлар җитешми иде. Мине яңадан шунда җибәрделәр. Элек анда эшләвемне истә тотканнардыр инде. Зәрафшан өлкәсе партия комитетының матбугат бүлеге мөдире итеп билгеләделәр. Шул чакта, 1929 елда, матбугатка кагылышлы ике китапчык бастырдым, «Мөхбирләр юлдашы» журналын нигезләдем...» Хәер, заманы өчен бик тә дәрәҗәле эшкә юллаганнар шул. Андый тәкъдимне теләсә кем биш куллап кабул иткән булыр иде. Институтка кереп уку теләгеннән дә бөтенләй үк онытмый Габдулла. Рабфак биргән таныклыкның имтихансыз вузга керә алу чиге якынлашкан бер дәвердә, ул Ташкент педагогия институтына укырга алына һәм аны уңышлы тәмамлый. Төп эшеннән, партия кушкан вазифаларны башкарудан аерылмаган рәвештә. Бу вакытта аны Ташкентка, партиянең Үзәк комитетында эшләргә дип чакырып алган булалар. Аңа В. И. Ленин хезмәтләрен үзбәк теленә тәрҗемә итүне оештыру бурычы йөкләнә. Шул эшләрне башкару өчен Үзәк комитетта партия тарихын барлаучы махсус бүлекчә оештырыла. Ул бүлекчә җитәкчеләренең берсе Г. Уразаев була. Бу эшне уңышлы башкарып чыккач, утызынчы еллар ахырында Г. Уразаевны «Кызыл Үзбәкстан» газетасының баш мөхәррире итеп билгелиләр.

Бөек Ватан сугышы да тәмамлана. Сугыш елларында таушалган, таркалган хуҗалык тармакларын аякка бастыру, яңарту чоры килеп җитә. Теләсә кайсы эшкә җиң сызганып тотына белгән, уңышлы башкарып чыга алган татар коммунистын яңа көрәш мәйданына ташлыйлар – 1945 елда аны Үзбәкстан ССР Министрлар советы карамагындагы Радиокомитетка рәис итеп куялар. Габдулла Уразаев бу вазифаны үтәргә керешкәндә, радиодан үзбәк телендә көнгә фәкать дүрт сәгатьлек тапшыру оештырылган була. Бинасы иске, кысан, җиһазлар таушалган. Габдуллага берничә студия эшли алырлык иркен бина булдыру, яңа җиһаз-аппаратуралар кайтарып урнаштыру эшләрен сугыштан соңгы авыр шартларда үтәргә туры килә. Илленче еллар башына ул эшләрне

мишәрчә үҗәтлек белән җиренә җиткереп төгәлли Г. Уразаев. Дүрт студия берьюлы эшли алырлык зур бина булдыра, яңа аппаратуралар кайтарта. Үзбәк телендәге тапшырулар сәгатен уналтыга җиткерә. Республикада яшәүче уйгыр, таҗиклар өчен үз телләрендәге тапшыруларга да юл ачыла. Радиокомитет карамагында милли оркестр оештырыла. Әйтергә кирәк, нәкъ шул елларда Үзбәкстан радиосында татар телендәге тапшыруларга да бер сәгать вакыт бирелә, һәм ул тәртип туксанынчы еллар башына кадәр саклацды. Хәзер андый тапшыру бармы икән – әйтә алмыйм.

Алга куелган бурычларны башкарганнан соң, ул билгеләгән кәнәфигә төп милләт вәкилен утырталар да, Уразаевны, яңа башлангычны үтәргә дип, яңа урынга күчерәләр. Берничә ел гомерен ул дәреслекләр чыгаручы «Укытучы» нәшрияты эшчәнлеген җайга салуга багышлый. Анда баш редактор да, директор да була. Шуннан соң аны әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен нәшер итүче зуррак нәшриятның директоры итеп куялар. Шул вазифаны башкарганда, ул Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсенең секретаре итеп тә сайлана.

Якташымның соңгы эш урыны – Язучылар берлеге карамагындагы Әдәбиятны пропагандалау бюросы директоры кәнәфие. Ләкин ул анда озак эшләми. Алтмышынчы еллар уртасында пенсиягә чыгып, фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Г. Уразаевның Үзбәкстанда яшәгәндә үзе теләп башкарган төп иҗат юнәлеше үзбәк телендә татар әдәбиятын тарату, пропагандалау була. Ташкент шәһәрендә яши башлаган беренче көннәреннән үк, ул Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Шамил Усманов һ. б. иҗатына багышланган күпсанлы очерк, мәкаләләр язып бастыра. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» романнарын (икешәр басма), Ш. Усмановның «Памирдан радио» дип аталган фантастик әсәрен үзбәкчәгә утызынчы елларда ук тәрҗемә итә. Соңрак дәвердә аның каләме аша үзбәк укучысы кулына Әхмәт Фәйзинең «Тукай», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повесте һ. б. әсәрләр барып ирешә. Габдулла Тукайның 1976 елга кадәр үзбәк телендә дөнья күргән барлык «Сайланма әсәрләр»ен туплашуда Г. Уразаев катнаша, күпчелек очракта кереш сүз авторы да ул була.

1979 елда үзбәк телендә хәзерге заман татар хикәяләрен туплап бастыру карарына киленде. Ташкентта булганда, мин шул хакта Габдулла агага хәбәр иттем. «Ул китапны эшләп чыгарырга алынмыйсызмы?» – дип сорадым. Кулымда эшем бар әле, Әмирхан Еники әсәрләрен тәрҗемә итәргә ниятләдем, дип җавап бирде ул. Җитмеш биш яше тулган кеше бит, аны кабат аптыратып тормадык. «Дуслык китапханәсе» сериясендә 1981 елда басылган «Еллар вә юллар» хикәяләр җыентыгы тәрҗемәсен үзбәк язучысы Хәйрулла Эргашев башкарып чыкты.

Кадерле якташым Габдулла ага белән без соңгы тапкыр 1981 елның июнь ае ахырларында Кырымда очраштык. Язучыларның Кара диңгез буендагы «Күктүбә» иҗат йортында. Үзе кебек кечерәк буйлы, үзедәй бик ачык йөзле, мөлаем кыяфәтле карчыгы белән икәү ял иткәннәр, инде китәрләренә ике көн генә калган иде.

– Ял гына иттегезме, әллә бераз эшләдегез дәме? – дидем.

Иң әүвәл бу соравыма җәмәгате – Зәйнәп апа җавап бирде:

– Тик утырырга бер дә күнекмәгән инде ул. Эшсез бер дә тора алмый, – диде. Сөйләмендә үзбәк аһәңе белән янәшә мишәр чалымнары да сиземләнгән кебек иде. Ләкин, сүзгә мавыгып, аның туып үскән төбәген сорарга онытканмын.

Габдулла абый исә бераздан өстәп куйды:

– «Казан утлары» журналында Гариф Ахунов әсәрләре еш басыла. Рабфак буенча шәриктәшем Гариф Миңнуллин да бер килгәндә аның иҗатын мактап телгә алган иде. Шуның бер повестена тотынып торам әле. Ни булып бетәр, – диде. Г. Ахуновның «Чикләвек төше» повесте китабы аның тәрҗемәсендә Ташкентта 1985 елда басылып чыкты.

Шул очрашудан соң миңа Ташкентка барырга туры килмәде. (Ташкент аша Нукуска һәм Бишкәккә очу очракларын искә алмаганда.) Берникадәр вакыт үткәч, сиксәненче еллар урталарында Мәскәүдә очрашканда, шагыйрь, Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсе секретаре Нармурад Нарзуллаев күңелсез хәбәр җиткерде: «Обдулло әкә койтыш булды», – диде. Соңгы күрешкән вакытта Габдулла әкә безгә: «Туган якта күптән була алганым юк. Авылымны, Мәләкәсемне бик сагындым», – дип әйткән иде. Гомере читтә узган кешенең кабере дә читтә калучан шул. Туган төбәген ул кайтып күрә алмады шикелле. Кайткан булса, якташлары хәтерләр иде. Ульяновскида уңышлы гына нәшер ителеп килүче «Өмет» газетасы мөхәррире, якташы Исхак Хәлимов андый очракны хәтерләми.

* * *

2007 елның 14 ноябрендә, Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Иске Кызылсу авылында шагыйрь Сәхаб Урайский истәлегенә багышланган очрашулардан соң туды бу хезмәт. Иске Кызылсу белән элекке Урта Кандалый авыллары исә – күрше авыллар. Ә Кызылсуда тагын бер күренекле шәхесебез – әдәбият һәм тел галиме Латыйф ага Җәләй дә XIX гасыр ахырларында аваз салган икән. Соңрак ул Мәләкәстә һәм Самарада төрле-төрле мәктәпләр, курслар ачуда катнаша. Ягъни Габдулла Уразаев белән бер үк сукмаклардан йөри диярлек. Кызылсудан ерак булмаган Әсән карьясендә СССРның халык артисты, мәсәлче һәм драма әсәрләре тәрҗемәчесе Габдулла ага Шамуков дөньяга килгән. Шушы ук район биләмәсенә кергән Иске Кандалый

(хәзер Иртуган дип атала) авылында классик шагыйребез Габделҗаббар Кандалый да туган бит. Бер район, бер төбәк өчен күпкәрәк тә китә кебек. Байтак кына олуг шәхесләрне тудырган Казан арты районнарыннан Арча белән Балык Бистәсе җире кебек дип белерсең. Әйе, Габдулла ага Уразаев та талантларга бик тә уңдырышлы төбәктә туган шәхес икән шул. Татар әдәбиятын үзбәк кардәшләребез илендә чын күңел биреп тәрҗемә иткән, пропагандалаган бер изге җан. Рабфакта укуын тәмамлагач Казанда калса да, мөгаен, әдәбият өлкәсендә мәгълүм бер эз калдырган шәхес булыр иде. Хәер, безнең милләттән Габдулла Уразаев кебек кешеләр дә чыккан икән дигән горурлык хисе барыбер күңелдә яши. Һади Такташ, Әсгать Мәҗит белән бер төркемдә төшкән фотолары матбугат битләрендә күренгәләп ала. Шундый бер фотоның күчермәсен 1981 елның гыйнварында Такташның улы Рафаэль миңа да бүләк итеп калдырган иде.

*2009*

## ЯКЫН КАРДӘШЛЕК ЭЗЛӘРЕ

*(Очерк)*

Казах һәм татар әдәбиятлары бәйләнышларын беркадәр күздән кичерәсе килә. Тел-лөгать һәм тарихи җирлек җәһәтеннән казах белән каракалпак халыклары безгә иң якын кардәшләр. Татарга алардан да якынрагы фәкать башкорт милләте була. XIX гасырның икенче яртысында яшәгән күренекле фикер иясе, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Абай Кунанбаевның казах халкы тарихын барлаган бер хезмәте бар («Бераз сүз казахның төбе кайдан чыкканы туралы»). Анда ул казахларның борынгы монгол империясенә бәйле булуын билгеләп үтә дә түбәндәге җөмләләрне язып китә: «Иске мизгелдә (борынгы заманда) мангулдан бер татар аталган халык билгеле икән. Кытайлар «татан» дип яза. Асыл төбе казахның шул татар. Шушы көндә дә казахның түрә нәселләре үзләрен «без татарбыз» дип әйтәдер». Бөек акын язып калдырган бу сүзләр, минемчә, бүгенге фән күзлегеннән карагавнда да инкяр ителми. Бүген җир йөзендә яшәгән һәр халыкның тарихы катлы-катлы, милли йөзе катлам-катлам. Үзләрен «саф рус» дип атаучыларның да канында, рухында һәм кыяфәтендә татар-төркиләрдән тыш фин-угор һ. б. халыклар чалымнарын микроскопсыз да шәйләп була. Тел байлыклары турында әйтеп тә торасы юк. Билгеле, татар милләтенең тарихи катламнары арасында болгары да, кыпчагы да, йәмәк-кимәге дә бар. Исем-атамасыннан ук күренеп торганча, бик борынгы татар катламы да анда сизелерлек калын булган. Казах этносының язмышы да шундый. Ул кардәш милләт нигезендә йәмәк-кимәк, кыпчак,

найман һәм, Абай билгеләп үткәнчә, беркадәр борынгы татар өзе дә бар. Хан-солтаннарның байтагы үз шәҗәрәләрен Чыңгызхан нәселеннән башлаган.

Революциягә кадәр берән-сәрән генә профессионал язучылары булган казах әдәбияты һәм мәдәнияте хәзерге вакытта мактаулы исемнәргә бик тә бай. Киң колачлы проза әсәрләре иҗат итүчеләрдән генә дә бүген күпчелек әдәбият сөючеләргә мәгълүм дистәләгән исемне телгә алып узарга мөмкин булыр иде. Әйе, казах әдәбияты, бигрәк тә проза тармагындагы уңышлар бүген бөтендөнья укучысына да яхшы таныш дияргә буладыр. Миржакып Дулатов, Сәетваккас Сәйфуллин, Мохтар Әүэзов, Сабит Мокалов, Габиден Мостафин, Габит Мөсрепов, Әнүәр Әлимҗанов, Ильяс Исәнбирлин, Әбдеҗәмил Нурпеисов, Олжас Сөләйманов, Әбиш Кекилбаев, Мохтар Мәгауин, Шерхан Мортазаев, Саин Моратбәков, Әнәс Сараев һ. б. бик күпләрнең иҗатлары бүген байтак кына чит ил телләренә тәрҗемә ителгәннәр. Аларның күпчелегенең әсәрләре белән бүген Көнбатыш Европа укучысы да, Азия илләре әдәбият сөючеләре дә таныш. (Соңгы чорларда казахларның, мәсәлән, Кытай, Япония белән элемтәләре тотрыклы.) Совет чоры хакимияте тарафыннан утызынчы еллардан бирле казах әдәбиятын вә мәдәниятен үстерүгә аеруча әһәмият бирелде, аларны киң мәйданга чыгару юнәлешендә байтак эшләр эшләнде. Җитмешенче елларда, хакимият җитәкчелегенә Казахстан вәкиле буларак килгән Леонид Брежнев заманында, казах мәдәнияте тагын бер югарылыкка күтәрелде. Мисалга шул чорда Алма-Ата киностудиясе төшергән кинофильмнарның ил күләмендә киң таралганлыгын китерү дә җитәдер. Казах әдәбиятын чит илләрдә тарату һәм пропагандалау көчәйде. Безгә, безнең мәдәнияткә караш икенчел дәрәҗәгә тиң санала башлады. Автономияле республикалардагы язучылар оешмаларына Союздаш республикалардагы каләмдәшләре белән турыдан-туры элемтә тоту, аралашу өчен дә Мәскәүдән махсус рөхсәт алу сорала башлаган иде.

Ә бит безнең күпчелек борынгы әдәбият үрнәкләре уртак булган. Борынгы дастан-поэмаларны күпчелек төрки халыклар уртак мирас дип санаганнар. Утрак тормыш алып баруга шактый иртә күчүебез сәбәпле, бездә язма әдәбият үрнәкләре дә иртәрәк туган. «Кардәш казах әдәбиятына без һәрвакыт үрнәк булганбыз», — дип тә язгалый идек элгәреге елларда. Бүген инде без алай дип әйтә алмыйбыздыр, мөгаен. Бүген безнең дөнья күләмендә танылган әсәрләребез дә, мәдәният күгендә ялтырап алган шәхесләребез дә бик аз. Дөрес, алар безнең үзебездә бар. Заманча тирән фәлсәфи яңгырашлы шигырьләребез бер генә милләт шигъриятеннән дә калышлы түгелдер. Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Нурихан Фәттах, Миргазыян Юныс кебек прозаикларыбызның үрнәк әсәрләре дә башкалардан ким түгел шикелле. Ләкин аларны үзебездән башка кеше белми диярлек. Соңгы дистә елларда андый әсәрләребез хәтта Россия мәйданына да чыга алмыйча, үз Казаныбыз

даирәсендә генә мәгълүм булып кала бирә. Уйлавымча, драматургиябез дә киң мәйданга чыгарга хаклы. Ләкин иң уңышлы дип саналган драма әсәрләрен дә үзебездәге рус драма театрлары ни сәбәпледер кабул итәргә ашыкмый. «Кече милләтләр — мәдәниятенә һәм әдәбиятына кимсетеп караулар хөкем сөргән рус патшалары хакимияте дәверенә кире борылыш ясыйбыз сыман…»

Казах халкы әдәбиятының үсеш нигезләре нидә соң? Иң әүвәл, әлбәттә, халыкның милли традицияләре төп нигез, төп чыганак була. Гасырлар буе халык теленнән төшмичә, онытылмыйча сакланган күпсанлы борынгы дастан һәм кыйссалар, сөйләкләрдән көч-куәт алып күтәрелгән ул әдәбият. Аның тамыры хәзерге татар һәм казах халыкларының уртак нигезенә — кыпчак, болгар бабаларыбыз җирлегенә барып тоташа. «Идегәй», «Кобланды», «Кузы Көрпеш», «Кыз җибек» («Ефәктәй кыз») кебек, башлыча ике халык телендә дә сакланып калган бу дастаннарның тарихи җирлеге бер, каһарманнар язмышы уртак булган. Казахлар бу дастан-кыйссаларны телдән-телгә сөйли-сөйли язма әдәбият чорынача килеп җиткән. Алар башлыча иҗади күңелле, шигъри фикерле халык. Инде язма әдәбият дәвере әдипләрен хаклы рәвештә шул матур традицияләрне дәвам иттерүчеләр дияргә була.

Элгәрерәк елларда СССР дигән илнең байтак кына әдәбият галимнәре, шул исәптән кайбер үз галимнәребез дә «казахта язма әдәбият чоры бик соң башлана» дип билгеләп үтәргә яраталар иде. Үз арабыздан да: «Казахта язма әдәбият Октябрь революциясеннән соң гына туган», — дип расларга тырышучылар, хәтта ки шулай дип язып чыгучылар да булгалады. Әлбәттә, язма әдәбият барлыкка килсен өчен аерым шартлар һәм ихтыяҗ булуы кирәк. Иң беренче шарт, билгеле, киң таралыш алган мәктәп-мәдрәсәләрнең даими эшләп торуы. Нигездә, күчмә тормыш белән яшәгән казах илендә бу шарт тулаем үтәлмәгән диярлек. Даими эшләүче мәдрәсәләр Акмола, Кызылъяр, Семипалат кебек сирәк калаларда гына барлыкка килә. (Хәзер Астана исемен йөртүче шәһәр кайчандыр ак ташлы каберлек урынында барлыкка килгән. Шуңа күрә аның элекке исеме тамырында «мола» — каберлек сүзе ята. Ул шәһәрне «Акмулла» дип, дин әһеле атамасына бәйләп язу дөрес түгел. Еш кына без шул хакта онытып җибәргәлибез.) Аларның да күпчелегендә югары — галия класслары булмый. Икенче шарт — китап басмаханәләре һәм вакытлы матбугат булу зарурлыгы. Чыннан да, казахлар яшәгән төбәкләрдә китап басу эше бик соң — XX йөзнең 20 нче елларында гына, Казах Совет автономиясе оештырылгач кына барлыкка килә башлый. Патша хөкүмәтенең һәртөрле эзәрлекләүләре нәтиҗәсендә андый остаханәләр күпчелек төрки халыкларда шактый соң туалар. Әйтик, төрки халыклар арасында XIX йөз урталарына китап басу эше фәкать Казан белән Бакуда гына беркадәр җайга салынган була. Шул ук вакытта газета-журналлар нәшер итү эшенә исә казанлы-

лар иң соңлап керешәләр. 1905 елгы халык кузгалышына кадәр татарларга вакытлы матбугат тудыру рөхсәт ителми. Бу җәһәттән казах кардәшләр Идел-Урал буе төркиләреннән генә түгел, хәтта ки ул чорда бу өлкәдә иң алга киткән азәрбайҗаннардан да өлгеррәк булып чыгалар. Тарихи казах җирләре тәмаман яуланып бетмәстән элгәре үк – 1870 елдан казах һәм үзбәк телләрендә атнага бер мәртәбә «Төркестан вилаяте гәҗите» басыла башлый. Дөрес, аны оештыручы һәм беренче мөхәррире безнең якташыбыз, Оренбург төбәгеннән чыккан морза Шаһимәрдән Ибраһимов була. Бу газета XX гасыр башындагы түнтәрешләргә кадәр яши.

Совет хакимияте чорында казахларны ике-өч йөз еллар элек үк инде Россиягә үз теләкләре белән кушылганнар дип санарга күнеккән, ике йөз илле еллык бәйрәм датасын да күптән билгеләп үткән идек. Бу дата Кече Җуз ханы Әбелхәернең, безнең Тәфкилев морза киңәшен тотып, 1731 елда төзегән солых килешүенә нигезләнеп үткәрелә килде. Гәрчә ул килешү Урта һәм Олы Җуз ханлыклары белән төзелмәгән булса да. Урта Җузның Арал диңгезе тирәләрендәге җирләре исә Россия тарафына фәкать 1880 елларда гына күчә башлый. Уралдан алып Каспий диңгезенәчә булган мәйданны биләгән Бүкәй ханлыгы 1876 елда бетерелә.

Казах телендәге икенче газета 1888 елдан Акмола шәһәрендә чыга башлый. Дөрес, газеталарның икесе дә үз төбәкләрендә нәшер ителгән русча газеталарның атналык кушымталары гына булганнар. Ләкин аңа карап кына аларның әһәмияте югалмый: беренче саннарыннан башлап аларда казах халкының фольклор әсәрләре, элек сөйләм телендә генә яшәгән дастан үрнәкләре дә, шул дәвердә иҗат ителгән яңа әсәрләр дә урын алган. Мәсәлән, Акмола каласында чыккан «Дала вилаяте гәжите»ндә Абай Конанбаев, аның замандашы Шөҗе һәм башка акыннарның шигырьләре даими рәвештә басылган. Оренбургтагы рус-казах мәктәбе укытучысы Ибраһим Алтынсаринның (әнисе безнең милләт кешесе) һәм яшьрәк буын хикәячеләренең хикәяләре дә башлап шул газета битләрендә урнаштырылалар. (Әдәбият гыйлемендә И. Алтынсаринның хикәяләре казах язма прозасының нигезе санала.) Ташкентта нәшер ителгән «Төркестан вилаяте гәжите»ндә исә казах авторларыннан тыш үзбәк, каракалпак әдәбияты классиклары әсәрләренең XIX йөзнең җитмешенче елларында ук дөнья күргәнлеге мәгълүм. «Дала вилаяте гәжите»ндә күренекле казах галиме һәм сәяхәтчесе Чокан Вәлихановның Урта Азия халыклары тарихы һәм көнкүрешенә багышланган хезмәтләре, анасы татар нәселеннән булган Г. Шоңаев дигән берәүнең татар әдәбиятына, татар халкы белән арадашлык мәсьәләләренә караган язмалары, Мөхәммәтзакир Ишмөхәммәтев дигән икенче берәүнең казах халкы фольклорыннан ике йөз иллеләп үрнәге нәшер ителгән. Шул ук газетада кемнәрнеңдер казахчага якынайтып эшкәртүендә татар әдәбиятыннан да әсәрләр бастырыла.

Шушы мисаллардан күрәбез ки, язма казах әдәбиятына XIX йөзнең икенче яртыларында ук нигез салына. Шул ук еллардан казах телендә китаплар да басыла башлаган. Аларның беренчеләре Казан, С.-Петербург, Оренбург басмаханәләрендә дөнья күргәннәр. Китап тарихы белгечләре Казанда басылган казах телендәге беренче китап итеп «Кыйссаи хуҗа Гафан вә Сәдуваккас» әсәрен атыйлар. Ул 1870 еллар башында нәшер ителгән. Казахның XIX йөздә иҗат иткән классик шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбаевның беренче шигырь җыентыгы 1909 елда С.-Петербургта Кырым татары Ильяс Бораганский басмаханәсендә басылып чыккан. Икенче китабы 1916 елда Оренбургта – Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә – «Абай тирмәсе» исеме белән нәшер ителә. Гарәп хәрефендә Абайның өченче китабы 1922 елда Казанда «Абай Кунанбай улының өлеңе» (шигырьләре) исеме белән басыла. Давыллы еллар каһарманы, казах халкының 1916 елгы баш күтәрүендә «яшь казахлар» хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе һәм беренче Казах Совет автономиясе җитәкчесе булган шагыйрь һәм прозаик Сәдуваккас (Сәкен) Сәйфуллинның да тәүге шигырь җыентыгы 1914 елда Казанда басылып чыга. XX гасыр башында Оренбург шәһәрендә – Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә казах телендә басылып чыккан китаплар саны әлегә ун чамасында санала. (Оренбург басмаханәләренең чын тарихы әле барланмаган диярлек, шунлыктан тулы мәгълүмат юк.) Шул исәптән бу басмаханәдә 1911 елда казахча беренче повесть – М. Нурбаевның «Көргенде бала» («Тәрбияле бала») китабы дөнья күрә. Икенче бер басмаханәдә Әсфәндияр Кубеевның «Калым» китабы – казах телендәге тәүге романнарның берсе 1913 елда басылып чыга. Казахча беренче зур күләмле әсәр – Мирҗакыйп Дулатовның «Бәхетсез Җамал» романы да 1910 елда Казанда Кәримовлар басмаханәсендә дөнья күргән. Аңа чаклы, 1909 елда, Казанда бу авторның казах дөньясын дер селкеткән шигырь җыентыгы – «Уян, казах» китабы басылып тарала. (Искә төшерик, татар телендәге беренче романнар XIX гасыр ахырларында нәшер ителгән. Галимҗан Ибраһимовның «саф татарча» язылган «Яшь йөрәкләр» романы, Орск шәһәрендәге «Шәрык китапханәсе» наширлеге ярдәмендә, 1912 елда укучы кулына килеп керә.)

Шул ук елларда татар телендә казах дөньясын һәм әдәбиятын тәфсилле өйрәнүгә багышланган байтак кына әһәмиятле хезмәтләр дә пәйда булган. Шулардан Казанда һәм Оренбургта дөнья күргән, әмма безнең көннәрдә бөтенләй диярлек телгә алынмый торган берничә тарихи әһәмиятле хезмәтне генә санап китик: «Казах әхвәленнән» (авторы ачыкланмаган, 1907), Ниязмөхәммәт Сөләймановның «Кызылъярдан Петербургка сәяхәт» китаплары, Нәүширван Яушевның «Шура» журналында басылган «Төркестан Чини» («Кытай Төркестаны»), Корбангали Халидинең «Тәварихе хәмсәи шәркыя» («Шәрыкның әдәби бишлек тарихы») һ. б. бар.

Ике халык өчен дә файдалы булган әдәби-мәдәни арадашлык, үзара якыннан багланышлар, минемчә, 1930 еллардан соң кабат яңартыла. Алтмышынчы еллар башында ике тугандаш халык арасында киң колачлы әдәбият-сәнгать атналары уздырылу да үз нәтиҗәсен бирми калмагандыр. Бөек Ватан сугышына чаклы татарчадан казахчага һәм казахчадан татарчага тәрҗемә ителгән китаплар саны бер дистәгә дә тулмаган булса, сугыштан соң ул эш даими төс ала. Сугышка кадәр казахчага тәрҗемә ителгән төп әсәр Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы булса, казах әдәбиятыннан Казанда нәшер ителгән күләмле әсәр исәбенә Сәкен Сәйфуллинның «Тар жол, тайгак кичү» романын күрсәтергә ярыйдыр. Йөзьяшәр Җамбулның шигырь җыентыгы бездә 1939 елда нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышыннан соң ике әдәбият арасындагы арадашлык, хезмәттәшлек тагын да җанланыбрак китә. Бигрәк тә Казахстанда татар китабы күпләп тәрҗемә ителә башлый. Габдулла Тукай әсәрләрен даими рәвештә нәшер итү тәртибе урнаштырыла. Совет чоры әдипләренең аерым китаплары да басыла башлый. Казах әдәбияты үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итү эшенә дә әһәмият бирелә. Татар укучысы 1947 елда казах язма әдәбиятына нигез салучыларның берсе саналган шагыйрь Абай Конанбаевның «Шигырьләр һәм поэмалар» исеме белән чыккан сайланма әсәрләре белән таныша ала. Ул китапны туплап һәм тәрҗемә итеп чыгаручы шагыйрь Мәхмүд Максуд була. Абай әсәрләренең тагын да тулырак басмасы бездә 1981 елда дөнья күрде («Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз»). Ул китапның төзүчесе һәм «Хикмәтле сүз» бүлеген тәрҗемә итүче мин идем. Шигырь һәм поэмалар тәрҗемәсенең күпчелеген казах телен камил белгән шагыйрьләр Нури Арслан, Әхмәт Исхак һәм Мәхмүт Хөсәен башкарып чыктылар. Марс Шабаев белән Әхмәт Рәшитов тәрҗемәләре дә бик уңышлы булды. Аңа чаклы, 1950 елларда, Абайның үзенә багышланган ике калын китап дөнья күрде. Иҗаты бөтен дөнья күләмендә югары бәяләнгән Мохтар Әүэзовның киң танылган «Абай» һәм «Абай юлы» романнары язучы Сәрвәр Әдһәмова тарафыннан татарчага тәрҗемә ителде һәм ике китап булып басылып чыкты. Соңрак казах әдипләренең хикәя һәм повестьларын берләштергән күләмле «Дала җыры» (1964), «Ак дөя» (1979), «Дала гөлләре» (1991) һәм «Казахстан шагыйрьләре» (1968) җыентыклары нәшер ителделәр. Казах прозасы үрнәкләрен татарча сөйләмгә күчерү өлкәсендә үземнең тәҗрибәгә дә тукталып үтим. Мохтар Әүэзовның «Өйләнү» хикәясе, Абай исемендәге дәүләт бүләге иясе Сырбай Мәүләневнең «Җырлы Казан» очеркы үз вакытында «Казан утлары» журналында басылып чыктылар. Шундый ук югары дәүләт бүләгенә лаек булган күренекле прозаиклардан Әнүәр Әлимҗановның ике үзенчәлекле повестен берләштергән «Отрар хатирәсе» (1974), Саин Моратбәковның ике повесть һәм хикәяләрдән торган «Әрем исе» (1986) китаплары, Мохтар Мәга-

уин белән Уралхан Букиевның да кызыклы повестьлары кергән «Җәйләүдә» җыентыгы (1993) минем хезмәт җимешләре. Кайбер авторларның аерым әсәрләре минем тәрҗемәдә башка вакытлы матбугат битләрендә дә дөнья күрделәр.

Минем исәп буенча, 1950–1990 еллар арасында татар телендә утызга якын казахчадан тәрҗемә китабы басылып чыкты. Шушы ук дәвердә казах телендә нәшер ителгән үз китапларыбызның исемлеге исә бермә-бер ишлерәк. Союздаш республика дәрәҗәсенә кергән, ярым мөстәкыйль булган казах илендә һәр елны кимендә бер-ике татар китабы чыга килде дисәк тә хата булмастыр. Бу елларда Г. Тукай белән М. Җәлилнең сайланма әсәрләре берничәшәр мәртәбә казах укучысына җиткерелде. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», Г. Бәшировның «Намус», К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Ә. Фәйзинең «Тукай» романнары, Ш. Усмановның «Тургай далаларында» дилогиясе, И. Нуруллинның «Тукай» китабы, И. Салаховның «Күкчәтау даласында» җыентыгы, «Татар повестьлары» тупланмасы, Г. Ахунов, Р. Хафизова, М. Насыйбуллин һ. б. ның повесть, хикәя тупланмалары, Н. Арслан, М. Ногман, З. Нури, М. Хөсәен, С. Шакир һ. б. шигырь җыентыклары казах телендә зур-зур тиражлар белән басылып чыктылар. Байтак кына шагыйрь һәм прозаикларыбызның аерым әсәрләре Казахстанда нәшер ителгән гомуми җыентыкларда, әдәби журнал битләрендә урын алдылар. Уртак бер кино эшләү турында да сүз барды. Казах киностудиясе җитәкчеләреннән берсе булган язучы Абиш Кекильбаев, мәсәлән, җитмешенче елларда ук нефтьчеләр тормышын чагылдырган уртак кинофильм эшләргә мөмкин булуы турында сүз кузгаткан иде. «Әйдәгез, бергәләп сценарий языйк» дип тәкъдим итте. (Ул елларда Казахстанның Өстерт, Мангышлак тирәләрендә Татарстан нефтьчеләре зур эшләр башкардылар. Якташыбыз Дамир Нуретдиновның исеме ил күләмендә танылган, рәсемнәре үзәк матбугат битләреннән төшмәгән чак иде.)

1970–1980 елларда Казахстанның дәүләт театрлары Ш. Хөсәеневнең «Әни килде», Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» пьесаларын сәхнәләштерде. М. Фәйзинең «Галиябану» пьесасының элегрәк елларда казах телендә кат-кат уйналганлыгы турында да хәбәрләр бар. Бу җәһәттән безнең театрлар бераз калышты сыман. Миңа, мәсәлән, казах халкының үткәндәге тормышын чагылдырган бер әсәрнең Казанда уйналганлыгы гына мәгълүм. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры күренекле прозаик һәм драматург Габит Мөсреповның «Куза Көрпеш һәм Баян сылу» драмасын 1957 елда сәхнәләштергән була. Әсәр татар тамашачысы тарафыннан бик яратып кабул ителә. Соңрак исә кыргыз әдәбияты вәкилләре әсәрләре бездә өстенгә чыкты. Чыңгыз Айтматов белән Мар Байҗиев драмалары безнең театрлар тарафыннан кат-кат сәхнәләштерелде.

Кызганыч ки, 1990 еллардан башлап мондый арадашлыкларга нишләптер чик куелды. СССР таркалганнан соңгы дәвердә үзара әдәби-мәдәни мөнәсәбәтләр бик әкрен җайга салына шул. Элекке заманнардагы кебек, алмаш җыентыклар әлегә нәшер ителми. Фәкать аерым шәхесләр теләге белән башкарылган хезмәтләр генә ара-тирә күренгәли. Элек без бер-беребез белән теләктәш тә, терәктәш тә идек. Хәзер дә андый теләктәшлеккә зур киртәләр юк шикелле. Тулы мөстәкыйльлек алган Казах җөмһүрияте башлыгы Нурсолтан Назарбаев, 2004 елда Казанда булганда, «ике кардәш халыкның дуслыгы ныгырга тиеш» дигәнрәк сүзләр дә әйткән иде. Әмма әлегә ике яктан да аңа киң күләмле омтылыш сизелми. Шулай да күңелләрдә өмет сүнмәгән әле...

*2007*

## АКЫН АБАЙ ИҖАТЫ БЕЗГӘ БИК ЯКЫН!

Кардәш казах халкының бөек шагыйре һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Абай Конанбай улы Татарстаннан бик еракта – Алтай тауларының бер өлеше булган Чыңгызтау тирәләрендә туса да, безгә бик якын шәхес. Олуг шагыйрьләребез аның иҗатын белгән, хөрмәт иткән. Хәзер дә беләләр. Хәер, Абай үзе дә яшьли татарлар белән аралашып үскәнлеген искә ала. Язмыш татарны ерак-еракларга тараткан бит. XVIII йөзнең икенче яртыларыннан Россия биләмәсенә кергән Җидепулат (Семипалатинск) өлкәсендә дә солдат яки тәрҗемәче вазифасын үтәүчеләр дә, хәлфә-муллалар да, сәүдәгәрләр дә шактый күп булган. Ыруг солтаны вазифасын үтәүче рәвешендә Каркаралы шәһәрчегенә баргалап йөргән Конанбай да анда татар сәүдәгәрләре өенә төшүне хуп күргән. Башлыча шуларның теләген дә үтәп, ул биредә мәчет салдыруга да рөхсәт алган. Нигездә, үз хисабына шул мәчетне төзеткән. Мәчет ачылышында яшүсмер Абай да катнаша. Шунда ул беренче мәртәбә шушы төбәктә яшәп иҗат иткән Шөҗе, Балта кушаматлы акыннар белән очраша. «Балта» дигәч тә күз алдына үткер телле сатирик шагыйрь килеп баса. Тормышта ул кем булгандыр – әйтә алмыйм.

Абайның үз заманына кагылышлы уй-фикерләрен чагылдырган «Гаклия» хезмәтен искә төшерик. (1981 елда чыккан китапта мин аны «Хикмәтле сүз» рәвешендә тәрҗемә иттем.) Анда татар-нугай солдат буларак та, бик күп хезмәт куеп мал табучы сәүдәгәр сыйфатында да, хәлфә һәм мулла буларак та уңай яктан искә алына. Әйе, әлеге язманы укыгач, Абайның Евразия буйлап таралып яшәргә мәҗбүр ителгән милләтемнең авыр язмышын аңлавын да, аларның һәрчак белемгә омтылганлыгын чамалавын да тоясың. Киләчәктә дә безгә бөек акын-

нарыбыз – Абай, Тукайларыбыз әйтеп калдырганча, дус, тату яшәргә насыйп итсен.

Абай Конанбаев 1845 елның июль ахырларында, казахча әйтсәк, шилде (чиллә) белән тамыз айлары аралыгында туган. Ул чорда казах халкы кыш айларында бер-ике дистә чамасы саман өйдән торган кечерәк авылда – кышлакта яшәгән. Җәй айларын җәйләүләрдә уздырган. Абай Чыңгызтау тезмәләре аралыгындагы Каскаболак җәйләвендә туган. Аның элекке карт мулла кушкан исеме – изге китапларда теркәлгән Ибраһим була. Авылчарак итеп әйткәндә – Ибрай. Әмма аны тәрбияләгән әбисе белән әнисе яшьтән үк, яратып, «Абаем» дип йөрткәнлектән, ул шагыйрь буларак та шул исем белән таныла. Аның чордаш һәм якташ акыннарының үз атамалары тагын да үзенчәлеклерәк: Шөҗе (чебеш), Балта булган.

Атасы, тубыкты ыругы солтаны Конанбай оештырган кышлак мәктәбендә Абайга беренче хәреф танытучы мулла да Габитхан исемле татар. Бу яшь мулла җәй айларында да солтанның анасы Зәрә (мулла кушкан исеме Зөһрә буладыр), уртанчы хатыны Олҗан җәйләвенә еш килеп йөргән. (Олҗан – олы җанлы мәгънәсендәге исем. Без кулланган Гөлҗан, Батырҗаннар кебек.) Абайны һәм аның ике бертуганын тәрбияләп үстергән бу ике ана шигъри җанлы шәхесләр була. Болар Габитханны кичләрен китап укыр өчен дип чакыралар. Мулла боларның иркен тирмәсендә җыелган кешеләргә «Йосыф-Зөләйха», «Идегәй», «Кыз җибек» («Ефәк кыз») кебек борынгы китапларны кычкырып укый торган була. Абай беренче төрки әдәбияты үрнәкләре белән шушы рәвешле таныша. Шактый кырыс холыклы Конанбай солтан икенче хатыны җәйләвенә ике-өч көнгә бер генә килеп чыккалаганлыктан, Абай шушы ике ана (каенана белән килен) тәрбиясендә, шушы мохиттә үсә.

Абайга ун яшь тулгач, аны Җидепулат шәһәрендәге «укымышлы нугай мулла» Әхмәт Риза хәзрәт мәдрәсәсенә урнаштыралар. Бу шәһәргә илтүче өч көнлек юлда аны атасының ярдәмчеләренең берсе белән Габитхан озатып бара. Әлбәттә, мәдрәсәдә ул «Абаем-Ибраем» дип түгел, Ибраһим буларак теркәлә. Шушы Әхмәт Риза мәдрәсәсендә укыган вакытта чын-чынлап иҗат итә башлый. Монда ул борынгы төрки һәм фарсы әдәбияты үрнәкләре белән тирәнтенрәк таныша. 1850–1860 елларда бу шәһәрдә берничә мәдрәсә булган дип язалар. Бу мәдрәсә шәкертләре үзара да аралашканнар. Казах әдәбиятына хас рәвештә, алар арасында шигъри әйтеш – ярышлар да оештырылгандыр. Абай кылкубыз (скрипка) һәм думбрада уйнарга да оста булган. Ул тудырган берничә җырның озак вакыт халык арасында таралган булуын да искә алалар.

Һәрхәлдә, Абайның беренче җитди шигырьләре шушы шәһәрдә барлыкка килә. Булачак ыру җитәкчеләренең берсе рәвешендә ул русча да белем үзләштерергә тиеш саналган. Шул ук

елларда ул казах-рус мәктәбенә дә йөргән. Анда ул рус әдәбияты үрнәкләре белән таныша. Һәм соңрак А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов вә алар дәрәҗәсендәге рус шагыйрьләре әсәрләрен казахчага тәрҗемә дә итәчәк әле. Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасындагы «Татьянага хат» өлешен көйләп җырлау рәвешенә дә китерәчәк. Һәм казах яшьләре ул җырны бик яратып кабул итәчәкләр.

Абайның кайбер әсәрләре Акмола каласында чыга башлаган «Дала вилаяте газетасы»нда нәшер ителгән. Казах галиме Бабаш Әбелкасыймов бу газетаның 1888 елдан чыгуын, гасыр ахырынарак аның тиражы 1300 данә булганлыгын белдерә. «Анда акын Абай, Шөҗе шигырьләре, Ибрай Алтынсарин хикәяләре басылган», – дип яза. Бу газетаның мөхәррирләре кем булганлыгын ачыкламаганмын. И. Алтынсарин казахлардан беренче хикәяче буларак таныла. Аның байтак вакыт Оренбург каласындагы казах-рус мәктәбендә укытканлыгы мәгълүм. «Дала вилаяте...»ндә татарча әсәрләрнең тәрҗемәләре нәшер ителгәнлеген дә хәбәр итә Бабаш әфәнде. Әмма кемнәрнең нинди әсәрләре икәнлеген язмый.

1870–1883 елларда Ташкентта казах телендә атналык «Төркестан вилаяте газетасы» да нәшер ителгән. Мөгаен, Абай шигырьләре әле анда чыгарга өлгермәгәндер. Үзбәк телендә шул ук исемдәге атналык газета 1917 елда гына чыгудан туктый. Бу газеталар безнең галимнәр тарафыннан өйрәнелмәгән. Анда татар әдип һәм журналистларының әсәрләре дә нәшер ителгәндер, шәт. Газета мөхәррирләренең кайберләре безнең милләт вәкилләре булган ич...

Абай Конанбаевның шигырьләре бик соң туплап чыгарыла. «Казах акыны Абай Конанбаевның өлеңі» китабы 1909 елда, автор вафатыннан соң биш ел үткәч чыга. Ул Санкт-Петербургта кырым татары Ильяс Бораганский басмаханәсендә нәшер ителә. Казах телендә икенче китабы – «Абай тирмәсе» җыентыгы 1916 елда Оренбургта бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә чыга. Дәрдемәнднең Абай шигырьләрен үз иткәнлеген берничә кеше искә алган. Акынның өченче китабы: «Абай Конанбай өлеңнері» Казанда 1922 елда һәм дүртенчесе шул ук елда Ташкентта «Таңдамалы өлеңнер» исеме белән нәшер ителә.

Татар телендә әлегә Абайның ике җыентыгы нәшер ителгән. Шагыйрь Мәхмүд Максуд тәрҗемәсендә Казанда 1947 елда акынның «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы басылган иде. Ә 1981 елда «Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз» җыентыгын мин туплап чыгардым. (Соңрак нәшер ителгән «Абай энциклопедиясе»ндә ул җыентыкны төзеп чыгаручы дип ялгыш А. Хәмидуллин күрсәтелгән. Әсгать ага Хәмидуллин ул елларда сәяси әдәбият нәшрияты «Казахстан»да баш мөхәррир иде.) 1980 елда мин Сабит Мокановның 80 еллыгына багышлы чараларда катнаштым. Башкортстаннан анда Равил Бикбаев та килгән иде. Шушы юбилей алдыннанрак кына Казахстанда Абайның

туубына 135 ел тулуга багышлы чара да уздырылган икән. Шуны искә төшереп, кайбер каләмдәшләр «Без Г. Тукай, М. Җәлил, М. Гафури китапларын һәр биш ел саен нәшер итәбез. Татар, башкорт кардәшләребез безнең классикларыбызны сирәгрәк искә ала» дигәнрәк сүзләр дә әйткәләде. Шуннан соң мин Абайның 1977 елда «Гылым» басмасында нәшер ителгән ике томлыгын алып кайттым. Республика җитәкчеләреннән рөхсәт алгач, Абай әсәрләренең бер томлыгын тиз арада бастырып чыгаруга керештек.

Бу эштә миңа иң күп ярдәм итүче Нури ага Арслан иде. Казах телен һәм әдәбиятын иң камил белүче буларак, кереш сүзне язуны да аңа йөкләмәкче идек. «Сибгат Хәкимне үгетлә, ул язса отышлырак булыр», – диде. Һәм Сибгат абый да ул бурычны үтәргә бик теләп алынды. Шул ук Нури ага: «Абайның берничә шигырен Хәсән Туфан да тәрҗемә итте. Барып ялын әле, шуларны табып бирсен. Җыентыкның дәрәҗәсе арта төшәр», – дигән иде. 1950 еллар ахырында Казахстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырыла. Анда безнең күп кенә дәрәҗәле шәхесләребез катнаша. Алар арасында яңарак кына сөргеннән кайткан Хәсән Туфан да була. Күптән түгел генә Хәсән абыйны яңа фатирга – А. Вишневский белән хәзерге Ә. Еники урамнары чатындагы яңа йортка күчерешүдә катнашкан идем. Үзара мөнәсәбәтләр әйбәт иде. Бер йомышым бар дип, хәбәрләшеп өенә бардым. Абай китабын нәшер итәргә алынуыбызга сөенде. Казах, үзбәк, азәрбайҗан әдәбияты әһелләре белән даими аралашып яшәргә кирәк дигән фикерләрне кат-кат искә төшергәләдек. Әмма ләкин яңа күченгән фатирдагы өстәл тартмаларында да, шкаф киштәләрендә дә Хәсән ага тәрҗемә иткән шигырьләр табылмады. «Хәзер минем архив белән Мәсгуд Гайнетдинов шөгыльләнә. Аңа әйтермен», – дигәч тә аерылыштык. Әмма Мәсгуд та ул шигырьләрне тиз генә табып бирә алмады.

1981 елда «Абай» исеме белән нәшер ителгән ул томлыкка керүче әсәрләрне туплашуда казах телен яхшы белүче шагыйрьләр Нури Арслан, Мәхмүт Хөсәен, Әхмәт Исхаклар актив эшләде. М. Максуд тәрҗемәләреннән иң уңышлыларын Н. Арслан сайлап алды. Казахстанда чирәм җир ачуда булып, беркадәр сөйләм телен үзләштергән Әхмәт Рәшит белән нәшрият мөхәррире Марс Шабаев та ул китапны чыгаруда катнаштылар. Мин Абайның «Гаклия» («Хикмәтле сүз») хезмәтен тәрҗемә иттем. Тарихи эчтәлекле «Бераз сүз казахның төбе кайдан чыкканы туралы» язмасын да тәрҗемә итә башлаган идем. Ул хезмәтнең рөхсәт ителгән томлык күләменә сыймавы сәбәпле, аны тәмамламадым. Менә шул рәвешле туды ул «Абай. Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз» исеме белән дөнья күргән бертомлык (рөхсәт ителгән күләме 11 табак иде). Ул томга акынның 1887 елда иҗат ителгән, иртә вафат булган улы Мәсгудкә багышлап язылган поэмасы да керми калды. Ул поэманы Казахстанда үскән М. Хөсәен тәрҗемә

итте. Китапның алдан планга кертелмичә, ашыгыч рәвештә чыгуы сәбәпле, ул поэма да томга сыймады.

Китап басылып чыгуга, аның берничә данәсен мин Казахстан Язучылар оешмасына җибәрдем. Аерым данәләрен шул яктан килгән әдипләргә дә бүләк иткәләдем. Ә 2014 елда Казанда төрки әдәбиятлар форумы узды. Аны Төркиядә тупланган «Тюрксой» оешмасы уздырды. Ул оешманың рәисе Казахстан вәкиле булганлыктан, «Абай» китабын мин аңа да бүләк иттем.

Абайның шушы җыентыгы чыгуга багышлап каләмдәшебез Тәүфыйк Әйди 1982 елда күләмле генә мәкалә язды. Китапның чыгуын бик хуплаган һәм тәрҗемәләрнең уңышлы булуын билгеләп үткән иде ул анда. «Үз йөзен саклап» дигән исем белән ул мәкалә «Казан утлары» журналының шул елгы 7 нче санында һәм шул ук җәйдә Казахстан Язучылар берләшмәсенә караган «Казах әдәбияты» газетасында нәшер ителде.

*2020*

# ЧЫҢГЫЗ ТАУЛАРЫНЫҢ БӨРКЕТЕ

*(Очерк)*

Оренбург каласының ап-ак йортлары тезелешеп утырган Урал суы башына – җәй көннәрендә үзенә бер үзәккә әверелгән өлешенә барып чыктым исә, нигәдер казахның бериш олуг язучылары күз алдыма килә: Сәкен Сәйфуллин, Мохтар Әүэзов, Сабит Моканов, Габит Мөсрепов, Габиден Мостафин... Алар – казах совет әдәбиятына нигез салучылар, казах мәдәнияте тарихында исемнәре алтын хәрефләр белән язып куелган шәхесләр – кайчандыр шушы «Ак кала» урамнарында йөргәннәр бит, шушы текә яр башыннан ашкын сулы Урал елгасына рухланып карап тора торган булганнар. Шушы урында алар, күмәкләшеп, казах халкының киләчәк язмышын кайгырткан – дала тормышын үзгәртеп корырга хыялланып яшәгәннәр. Бу елларда бит әле алар язучылыктан бигрәк, казах илендә Совет хакимиятен урнаштыру эше белән күбрәк шөгыльләнгәннәр. «Ак кала»ның күрке булып, Урал суына йөз белән карап утырган өч катлы мәһабәт ак йорт – беренче казах Совет хөкүмәте йорты була.

1920 елда Кыргыз-казах Автономияле Совет Республикасын оештыру карары чыккач, Оренбург шәһәре аның башкаласы итеп билгеләнә. Чөнки бу кала элек-электән, казах хан-солтаннары белән беренче элемтәләр барлыкка килә башлагач ук, үзенә күрә бер аралашу үзәгенә әверелгән була. 1743 елда төзелгән шушы каланың көньягында, Урал елгасы буенда, Урта Азия төбәкләреннән килүче сәүдәгәрләр өчен дип, Меновый Двор бистәсе дә оеш-

тыртыла. Үзәк Рәсәй төбәкләрендә мәчетләрне һәм алар карамагындагы мәктәп-мәдрәсәләрне ябу карарлары чыгып торган шул ук елларда исә бу Меновый Двор бистәсенә, киләчәк сәүдәгәрләр өчен дип, мәчет тә төзеп куела. Һәм Урал-суның аргы ягындагы иркен җирләрне биләүче казах ханлыклары тарафына моннан беренче сәүдә кәрваннары да йөри башлый. Казах иле Рәсәйгә кушылганчы, Урта Азия тарафына кәрван йөртүчеләр татар сәүдәгәрләре була. Чөнки башка диндәге кешеләргә ул якларда йөрү рөхсәт ителмәгән.

Патша хөкүмәте ике-өч гасыр дәвамында дала тормышы белән бәйләнештә була. Унтугызынчы йөз урталарында ул җирләр Рәсәйгә кушылгач, моннан торып идарә итә. (Дала ягы халыклары белән икенче идарә үзәге – Омск каласы, казахчалаштырып әйтсәк, Омбы булган.)

* * *

Әйе, 1920 елның апрелендә Урал яры өстендәге ул өч катлы йортта яшь Автономияле Республиканың Үзәк башкарма комитеты урнаша. Башкарма комитетның беренче рәистәше һәм Мәгариф халык комиссары вазифасын үтәүче шагыйрь һәм ялкынлы яшь революционер Сәкен Сәйфуллин була. Ә 1923 елда ул Казахстан АССРның Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп билгеләнә. Башкарма комитетның икенче бер эшлекле җитәкчеләреннән берсе – яшь язучы Мохтар Әүэзов. Соңрак алар янына тагын да яшьрәк буын килеп кушылачак...

Шушы яр башындагы йорттан алар үз «мөстәкыйль мәмләкәт»ләре белән идарә иткән, казах халкының аң-белемен, абруен күтәрү өчен тырышкан. Шушы «Ак кала» («Беловка») урамнарында йөргәндә, язылачак әсәрләре хакында да уйланганнардыр.

Әйе, Урал буеның шушы тирәләренә юлыксам, күз алдыма алар килеп басалар: әнә алдарак атлаучысы – казах халкының баш бирмәс лачыны Сәкен Сәйфуллин... Аның янәшәсеннән киң маңгайлы, текә карашлы бөркет, Чыңгызтау буйларында канат чыгарган Мохтар Әүэзов киләдер сыман...

Мохтар Әүэзов – күпмилләтле совет әдәбияты күгендәге якты йолдызларның берсе. Төрки телдә язучы әдипләрдән беренче буларак аның иҗаты иң югары бүләккә – Ленин премиясенә лаек дип табылган иде. Ә аңа чаклы, «Абай» романының беренче китабы дөнья күргәч, 1949 елда Мохтар Әүэзовка СССР Дәүләт бүләге бирелде. Өстәвенә ул, – илкүләм танылган язучылык хезмәтеннән тыш, казах әдәбиятының үткәнен барлауга күп көч куйган шәхес, бу юнәлештәге эшчәнлеге өчен 1946 елда ук Казахстан ССР академиясенең академигы дәрәҗәсенә ирешкән галим дә иде. Бер үк вакытта Мохтар Әүэзов чорыбызның танылган җәмәгать эшлеклесе дә булды – СССРның Тынычлыкны

яклау комитеты әгъзасы, СССР Ленин премияләре комитетының абруйлы бер вәкиле иде. Азия һәм Африка илләре прогрессив язучыларының дуслыгын, үзара бердәмлеген ныгытуны истә тотып оеша башлаган берләшмәнең беренче нигез ташын салучыларның берсе иде. Һәм ул берничә тапкыр Казахстан ССР Югары Советы депутаты була.

Мохтар Омархан улы Әүэзов 1897 елның 28 сентябрендә казах иленең иң көнчыгышында – Алтай таулары тезмәсендә урнашкан җирдә туа. Семипалат өлкәсе Чыңгыз өязе Чыңгызтау итәгендә җәйләүдән җәйләүгә күченеп йөргән кечерәк бер авылда. Бабасы Әүэз аңа биш-алты яшеннән токымдашы шагыйрь Абайдан калган кулъязма буенча хәреф танытырга керешә. Якын-тирәдә генә мәктәп-мәдрәсәләр булмый. Патша заманында яшәп килгән тәртип буенча, мәктәп-мәдрәсәләрне мәчет каршында гына ачу рөхсәт ителгән, ә күчмә тормыш белән яшәгән казах авылларында мәчетләр булмаган диярлек. Шуңа күрә эрерәк авылларда вакытлыча ачылган, рәсми рәвештә теркәлмәгән, укучылары бик аз санлы булган мәктәпләр генә оештырылган. Бабасы дәресләреннән соң Мохтар да, мөгаен, укый-яза белердәй башлангыч белемне шундый мәктәптә үзләштергәндер. Шуннан соң кала-шәһәрләрдән читтә урнашкан ул төбәк авыл балаларының укуын дәвам иттерәсе килгәннәре авыл-җәйләүләреннән бик ерактагы Семипалат шәһәренә юл тотканнар. Шул елларда анда берничә мәдрәсә булган. Арадан иң уңышлысы – укымышлы татар мулласы Әхмәт Риза ачканы җанлы мәдрәсә саналган. Кайчандыр ул мәдрәсәдә казах халкының бик күренекле шәхесләре укыган бит. Атасы вакытсыз үлмәсә, Мохтарны да, мөгаен, шул ерактагы мәдрәсәгә илтеп бирерләр иде. Әйе, бу мәдрәсәдә кайчандыр аның бабасының дусты Абай да белем эстәгән бит. Беренче шигырьләрен дә ул шунда яза башлаган.

Әйе, 1908 елда атасы үлгәч тә, Мохтар атасының бертуганы Касыймбәк абыйсы тәрбиясендә кала. Агасы аны шул көздә үк биш сыйныфлы, рус телендә белем бирүче казна мәктәбенә илтеп тапшыра. Шулай итеп, Мохтар русча укуга күчә. Соңыннан әдип бу хакта: «Касыймбәк агам, остазы Камалетдин хәзрәт бәддогасы белән дә исәпләшеп тормастан, мәдрәсәне ташлап, рус мәктәбендә белем алган. Мине дә Чыңгыз өязе стипендиясе хисабына шунда урнаштырды. Бу биш класслы училище җирле халыктан патша хезмәтенә яраклы тылмач вә башка төрле вак чиновниклар әзерли иде. Әлеге уку йортын тоту өчен, халыкка өстәмә салым салына. Тик халыкта ул мәктәпкә карата кырын караш яши, чукындыру нияте белән ачылган ул дип, балаларны җибәрмәскә тырышалар иде. Шунлыктан анда укучыларны мәҗбүри рәвештә җыялар, кайвакытта хәтта бала атасына күпмедер күләмдә «йолым» да түләнә иде… Табигый, безнең бабай, улларына һәм оныкларына бередә укырга юл куйганы өчен, ырудашларыннан шелтәне аз ишетмәде», – дип язачак.

Укуга сәләтле Мохтар монда алган белем белән генә дә чикләнми – Семипалаттагы укытучылар хәзерләүче семинарияне дә уңышлы тәмамлап чыга. Һәм шунда укыганда, казах халкының фольклор үрнәкләре белән дастан-поэмаларына нигезләнеп, беренче шигъри пьесасын яза.

Мохтар семинарияне тәмамлаган җәйдә, дала тормышы бик катлаулы чор кичерә. 1919 елда «аклар-кызыллар» тартышы нәкъ шушы тирәләрдә куәт алган чак була. Текә борылышлар чоры. Урта Азиянең күпчелек өлешендә әлегә большевиклар тарафыннан иң беренче оештырылган Төркестан Автономияле Совет Республикасы хакимлек итә. Аның йогынтысы Семипалат тирәләренә дә җитә. Аңа чаклы монда аерым милли дәүләт төзергә хыялланган Алаш Урдачылар түрә булып утырганнар. Ләкин инде аларның хакимлегенә атналар, айлар гына кала. Озакламыйча губернада революцион көчләр җиңүгә ирешәләр, Семипалатта Совет хакимияте урнаша. Ак патша чоры тәртипләре юк ителә.

Шул дәвердән башлап Мохтар Әүэзовның җәмәгать эшчәнлегенә һәвәслеге ачылып китә – беренче Совет оешмаларында җиң сызганып эшкә керешә ул. Хәер, аның яшьтәшләре, казах халкының беренче яшь интеллигенция вәкилләре – Сәкен Сәйфуллин, Сабир Шәрипов, Баембәт Майлиннар ише яшьләр – һәркайсы үз төбәк-губерналарында яңа тормыш-яшәеш өчен барган көрәшнең алгы сафында булалар. Революция давылы алып килгән үзгәрешләрне үз өяз-губерналарында урнаштыручылар сыйфатында танылып өлгерәләр.

Егерме ике яше дә тулмаган Мохтарны тиздән Семипалат губерна советы башкарма комитетына җаваплы эшкә билгелиләр. Бик хәтәр вакытлар булуга карамастан, ул өяздән өязгә, авылдан авылга йөреп тора, анда яңа тормыш урнаштыруга булыша. Озакламыйча, аңа шушындый вазифаны бөтен Казахстан күләмендә дип әйтерлек башкару эше йөкләтелә: 1920 елда Кыргыз-казах Автономияле Совет Республикасы оешкач та, ул шунда Үзәк башкарма комитет карамагына җибәрелә. Бу дәверне ул соңрак болай дип искә ала: «Шәһәрдә укып кайткач, дала тормышының иске гореф-гадәтләре, сыйнфый тигезсезлекләре, хатын-кызга карата җәбер-золым күзгә тагын да ташлана төшә иде… Артта калган тормышның шушы караңгы яклары әле шулкадәр көчле булып, Казахстанда совет власте урнаштырылгач та, җәмәгатьчелеккә, кешенең хокукына карата борын-борын заманнардан ук килгән караш, гадәт һәм шәригать кануннарына ябышып ятучы байлар, ыру башлыклары белән нык кына көрәшергә туры килде…»

Нәкъ шушы көннәрдә ул, халык арасында йөргәндә күргәннәренә нигезләп, Максим Горький, Шәриф Камалларның башлангыч иҗат чорларындагыча чын реалистик алым белән җанны тетрәндерердәй беренче хикәяләрен – «Ятимә язмышы»,

«Искелек күләгәсендә», «Сүнеп яну», «Барымта», «Өйләнү», «Ятим» һ. б. хикәяләрен язачак.

Мохтар Әүэзов монда, Оренбургта торып эшләү дәверендә, шулай ук драма әсәрләре язуын да дәвам итә. Алда әйтеп үтелгәнчә, казах халык иҗатына нигезләнеп, ул инде семинариядә уку чорында ук «Енлик-Көбәк» әсәрен язган була. Пьесаның төп каһарманнары Көбәк батыр белән Енлик, мәгълүм Кузы-Күрпәч белән Баянсылу, Айман белән Чулпаннар кебек, феодализмның традицион каршылыкларына, хатын-кызның хокуксызлыгына риза булып яшәмәүләрен белдерәләр һәм шул көрәш юлында озакламый һәлак булалар. Шулай итеп, пьеса, борынгы дастан алымнарын кулланып язылып та, Мохтар яшәгән көннәрнең көрәш рухын да үз эченә алган, үзендә чагылдырган бер әсәр рәвешендә кабул ителә.

М. Әүэзовның башлангыч иҗат чорын күз алдыннан кичергән байтак әдип һәм галимнәр, язучының кырыс хакыйкатькә таянып язылган беренче хикәяләрен һәм «Енлик-Көбәк» шикелле әсәрләрен истә тотып булса кирәк, аңа традицион Шәрык әдәби мирасының гына түгел, бәлки алдынгы рус әдәбиятының да йогынтысы барлыгын әйтәләр. Әйе, Мохтар Әүэзовның бу ике зур мирасны – Урта гасырларда чәчәк аткан Шәрык мәдәнияте белән соңгы йөз еллыкларда көч алган Европа мәдәниятен бик яхшы өйрәнеп үзләштерүен, үз иҗатында бик белеп аларны үстерүен Вс. Иванов, А. Фадеев, Л. Соболев һәм Н. Тихонов кебек танылган шәхесләр дә билгеләп үтәләр.

Ләкин әле әдәбият белгечләре шушы ике мәдәният арасында торган татар эшлекләләре арадашлыгына әһәмият биреп бетерми, бу ике мәдәниятне берләштереп торучы чуклы-челтәрле ул күперне күрмичәрәк үтәләр шикелле. Шунлыктан мин бу хезмәтемдә шушы арадашлык өлкәсенә күбрәк басым ясамакчы, үзем белгәннәрне әйтеп калмакчы булам.

Мохтар Әүэзов шәхесенә килгәндә исә, татар мәдәниятенең үз заманында күренекле бер үзәге саналырдай Оренбург каласына килеп юлыкканчы ук инде, ул татар дөньясы белән азмы-күпме таныш була. Семипалатта уку дәверендә үк алдынгы карашлы татар яшьләре белән якыннан аралаша.

Мәгълүм ки, Октябрь революциясе алды елларында Казахстанның байтак төбәкләрендә алдынгы карашлы казах һәм татар яшьләре – шәкертләр, мөгаллимнәр, приказчиклар бергә берләшеп, әдәбият-сәнгать түгәрәкләре, «Яшьләр җәмгыятьләре» оештыралар. Бу ике халык вәкилләре кушылып, нык аралашып яшәгән шәһәрләрдә казахның алдынгы карашлы беренче матбугаты борын төртә башлый: 1911 елдан халкының күпчелеген татарлар тәшкил иткән Троицк шәһәрендә казах телендә беренче әдәби-сәяси «Айкап» журналы басыла. 1913 елның башында Оренбург шәһәрендә казах халкына ирек, хөррият даулаган бер төркем яшьләр милли үзаңны үстерүгә юнәлеш тоткан «Казах»

газетасына нигез салалар. Шул дәвердә актив иҗат юлына баскан Галимҗан Ибраһимовның «Казах» газетасы редакторы Әхмәт Байторсынов белән якыннан аралашканлыгы, ул вакытта казах илендә Абайдан кала иң күренекле шагыйрь саналган Мәгъҗан Җомабаев белән дустанә мөнәсәбәттә торганлыгы мәгълүм. Сталин хакимияте дәверендә исеме һәм иҗаты юкка чыгарылган Мәгъҗан Җомабаев мирасы яңадан халкына кайтарылган бу көннәрдә Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы эпиграф-шигырь астына кабат «Җомабаев» дип куеп, бу ике шәхес арасындагы мөнәсәбәтләрне барлап, яңартасы гына калды...

Киң дала, күрсәң гуй, ана җаткан,
Җебектәй жәсел чүптә* битен җапкан,
Аскар тау, балдай татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан...

Әйе, егерменче гасыр башларында казах, татар яшьләренең бердәмлеге нәтиҗәсендә ике ара чатындарак урнашкан Троицк, Оренбург, Уральск, Кустанай, Петропавел (Кызылъяр) ише шәһәрләрдә әдәбият-сәнгать түгәрәкләре, үзешчән театрлар барлыкка киләләр. Мохтар Әүэзовның яшьлек дусты Галиәкбәр Түрәбаев хәтерләвенчә, «Енлик-Көбәк» пьесасын беренче мәртәбә халык хөкеменә Семипалат шәһәренең әнә шундый яшьләрдән торган «Есаймак» түгәрәге чыгара.

Шул ук елларда казах яшьләре һәм калкып, күтәрелеп килүче әдип һәм шагыйрьләре арасында, мәсәлән, беренче казах романы авторлары Миржакип Дулатов, Әсфәндияр Кубиев, шагыйрьләр Солтан-Мәхмүд Торайгыров, Мәгъҗан Җомабаев, Сәкен Сәйфуллиннар биографияләрендә чагылыш тапканча, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовлар иҗаты белән кызыксыну да артканнан-арта бара. Яшүсмер дәверендә укуын гәрчә рус мәктәбендә дәвам иттерсә дә, Мохтар Әүэзов татар әдәбияты белән танышудан читләшеп калмый. Күренекле тел галиме Г. Мусабаев белән бер әңгәмәсендә ул бу хакта ачык әйтә һәм хәтта: «Рус классик әдәбияты белән беренче танышуым да татар әдәбияты аша булды», – дип белдерә.

1923–1924 елларда, Ташкентта укыган көннәрендә, шул якларда яшәүче төрки халыкларның китапларына һәм башка язма истәлекләренә нигезләнгән өч томлык «Төркестан җинагы» белән таныш булуы да аның иҗат офыкларын киңәйткәндер. Татар әдәбияты үрнәкләре белән ул Оренбургта яшәгән елларында тагын да төплерәк таныша алгандыр.

Инде кабат Оренбург көннәренә әйләнеп кайтыйк. Сәкен Сәйфуллин, Мохтар Әүэзовлар яшь автономияле республиканың

---

* Кардәш казах халкы «чүп» дип печәнне атый. Бу очракта «жәсел чүп» «яшел үлән» була.

җитәкчеләре сыйфатында бу шәһәргә килеп тупланган көннәрдә, әле монда татар халкының олуг шәхесләре Дәрдемәнд, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинев, Шәриф Камал, Шакир Мөхәммәдов, «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе Җамал Вәлиди һ. б. ның эзләре һич кенә дә суынмаган була. Театр сәхнәләрендә тәҗрибәле драматург Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», «Асылъяр»лары белән янәшә Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә»се, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Хәбибулла Ибраһимов пьесалары уйналалар. «Юксыллар сүзе» газетасында тиктормас ялкынлы шагыйрь Һади Такташ эшләп тора. Шәһәр күләмендәге җәмәгать эшләрендә катнашып, инде татар әдәбиятының аксакаллары рәтенә баскан әдип һәм драматург Шәриф Камал йөри. Аның да бу уяну дәверендә «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе сәхнәдән төшми карала, «Акчарлаклар» повесте кулдан-кулга йөреп укыла торган чак. Шул «картлар» арасында әле баласымак кыяфәтле яшь шагыйрь Муса Җәлил дә күренеп киткәли, әледән-әле булып торган җыелыш, митингларда ул, остазы Төхфәт Ченәкәй белән аралаша-аралаша, дәртләнеп шигырь сөйли.

Бу чорда монда әледән-әле әдәби-музыкаль кичәләр оештырылып тора, сәхнәдә сүз осталарын музыкантлар, җырчылар алыштыра. Оренбургта бу вакытта татарның киләчәктә дан-шөһрәткә ия булачак өч композиторы – Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарёв яшьләр белән аралашып яшиләр, кичәләрнең музыкаль бүлеген даими җанландырып торалар. Танылган җырчылардан Газиз Әлмөхәммәтев тә әледән-әле монда күренгәләп ала. Ул бигрәк тә, Шаляпиндай куәтле тавышын яңгыратып, татар, башкортларның борынгы, казахларга да бик таныш көйләрен башкарырга яраткан. Әйе, ул көйләр, билгеле инде, киң кыр-далада үскән казах баласына да бик үз, бик якын бит!

Бу көннәрдә казах һәм татар мәдәниятен, мәгърифәтен үстерергә омтылган бу яшьләр уртак тел тапкандыр (татар һәм казах телләре үзара бик якын бит), бергә-бергә җыелышлар уздырган, «әдәби кичә» утырышларын оештыргандыр, әлбәттә. Тик әлегә ул очрашуларны тасвир итеп калдырган истәлекләр генә бик алай ишле түгел. Чөнки заманында «менә без, татар һәм казах язучылары, яшьләре, бергә-бергә шундый-шундый урыннарда аралаштык, берләштек» дип язып торуның кирәге булмаган. Ә язылганының булган кадәресе исә, минем уемча, әлегә беркем тарафыннан да барланмаган, тикшерелмәгән.

Кыргыз-казах автономияле республикасы оешканның беренче көннәрендә үк байтак кына татар интеллигенциясе Казахстан җирлегендә уку-укыту эшләрен җайга салуга тартыла. Әйтик, татар дөньясында беркадәр эз калдырган язучы Зариф Бәшири казах, уйгыр мәктәпләре өчен дәреслекләр төзүдә, уку-укыту эшен яңачага кору юнәлешендә җиң сызганып эшли. Бик киң мәйданда яңа нәшер ителә башлаган күп кенә газета-журналлар

да татар зыялылары ярдәмендә аякка бастырыла. Мәсәлән, Муса Җәлилнең өлкән шәриктәше, элеккеге «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте Заһид Шәркый-Йосыповка 1920 елдан ук казах телендә чыга башлаган газета-журналлар эшендә дә катнашырга туры килгән. Чөнки ул Рәмиевләрнең «Вакыт» типографиясендә хәреф җыеп, язма текст әзерләү һөнәрен дә үзләштергән, остазы Шәриф Камал кул астында мөхәррир рәвешендә дә тәҗрибә туплаган була. 1913 елдан Оренбургта нәшер ителүче «Казах» газетасын исә Оренбург яшьләренең күпчелеге үз итеп укып барган. Заһид, бәлки, ул газетаны шул ук басмаханәдә туплап чыгару барышында да катнашкан булгандыр.

Казахстан хөкүмәте 1920–1925 еллар аралыгында Оренбургта «Енбекше казах» («Эш сөючән казах»), «Җас казах», «Ортак» («Товарищ») газеталарын, «Кызыл Казахстан» журналын бастырып чыгара. Татарлардан кемнәрнең аларны нәшер итешүдә катнашуы әле ачыкланып бетмәгән. Бу басмаларның шәһәрдәге иң яхшы җиһазлы «Вакыт» типографиясендә тупланып чыгуында да шик юк. Димәк, үз биографияләрендә шул хакта искә алмасалар да, бу эштән Шәриф Камал, Ярулла Вәли, Заһид Шәркый-Йосыпов кебек шәхесләр читтә калмагандыр дип фаразларга хаклыбыз.

Әлбәттә, бу хөкүмәттә матбугат, мәгариф эшләре өчен төп җаваплылык Сәкен (Сәдүваккас) Сәйфуллин белән Мохтар Әүэзовка төшкәндер. Шушы кешеләрнең дә рөхсәте белән шул елларда монда татар телендә «Мөхбир», «Юксыллар сүзе», «Юл», «Сабан» кебек газеталар да нәшер ителгән. Шул ук елларда монда «Юксыллар сүзе» газетасында бер елдан артыграк Һади Такташ та эшләп китә. Шагыйрь буларак аның бик актив иҗат итә башлаган чоры. Һәм берничә ел Урта Азиядә яшәгәннән соң, яңарак кына туган якларына дип кайтып барышы. Оренбургта яшәгән вакытта аның 1914 елда ук Казанда тәүге шигырь җыентыгын чыгарган Сәдүваккас белән дә, прозаик буларак таныла башлаган Мохтар белән дә танышмавына һәм якыннан аралашмауларына ышанасы килми. Шул чор вакыйгаларын ачыклау өчен генә булса да, безгә ул елларда Оренбургта ике телдә нәшер ителгән газета-журналлар белән танышу бик кирәк.

Муса Җәлилнең дә бу чорда Оренбургта нәшер ителгән матбугат әһелләре белән актив аралашканлыгы хакында мәгълүматлар бар. Аның казах телендә ярыйсы ук иркен сөйләшә алуы турындагы хәбәрләр Орск шәһәрендә эшләү чорына караган истәлекләрдә теркәлгән. Ә 1924 елның җәендә – каникул вакытында аның бөтен Казахстан буйлап таралган, шәриктәше Заһид Шәркый-Йосыпов мөхәррирлегендә нәшер ителгән газета редакциясендә эшләп китүе турында да язалар.

Шушы истәлекләргә бәйле рәвештә Муса Җәлил белән Мохтар Әүэзов исем-фамилияләренең рәсми документларда теркәлгән бер вакыйганы да искә алып үтим. 1957 елда Муса Җәлилнең

«Моабит дәфтәрләре» шигырьләре циклы СССР Язучылар берлеге тарафыннан Ленин премиясенә тәкъдим ителә. Безнең Язучылар оешмасында бер очрашу вакытында Мостай ага Кәрим, илленче елларда Башкортстан Язучылар оешмасы рәисе булган кеше, әлеге премиягә тәкъдим итү утырышында Муса Җәлилгә һәм аның иҗатына карата иң җылы, иң кирәкле сүзләр әйтүче Мохтар Әүэзов булды, дигән иде. Мөгаен, бу очракта Мохтар ага яшүсмер Муса Җәлил белән Оренбургта бергә аралашу елларын да истә тоткандыр.

* * *

1920 елларда Оренбургта татар театры да бик актив эшли. 1915 елда оешкан мондагы «Ширкәт» труппасын 1920 елгача В. Мортазин-Иманский җитәкли. Күренекле артистлар төркемендә Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Оркыя Хөсәенова-Кушловская, Нури Сакаев (И. Кудашев-Ашказарскийның туганнан туган энесе), Гата Камский (соңгы вакытларда шахмат уены буенча Америка чемпионы булган Гата Камскийның бабасы) һ. б. була. 1920 ел ахырында бу коллективка Самарада театр студиясен тәмамлаган бик күп яшь артист килеп кушыла. Шулар арасында татар сәхнәсенең киләчәк йолдызлары да шактый була. Мәсәлән, шул төркемгә кергән Таҗи Гыйззәт истәлекләрендә аларның исемнәре дә китерелә. «1920 елның декабрендә... 55 кеше... Оренбург шәһәрендә урнашып, халыкка хезмәт итә башладык... Хәзерге көндә ул труппадан исән калганнар Өфедә Рифгать Фәйзи (Мирхәйдәр Фәйзи энесе), Казанда Хөсәен Уразиков белән мин», – дип яза ул 1953 елгы язмасында. Бу вакытта инде театр труппасының җитәкчесе генә түгел, исеме дә «Шәрык театры» буларак алышына. (В. Мортазин-Иманскийны Башкортстанның башкаласы итеп билгеләнгән Эстәрлетамак шәһәренә башкорт театрын оештырырга дип җибәрәләр.)

Егерменче елларда Оренбург театры сәхнәсендә уйналган, әдәби-тәнкыйть тарафыннан уңай бәяләнгән сәхнә әсәрләре исемлеге «түрендә» Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы, Габдрахман Әхмәров-Варламның «Газизәкәй балдыз» музыкаль драмасы белән «Сүнгән дәрт» әсәре, Заһид Шәркый-Йосыповның «Алмаз кылыч» пьесасы, Хәбибулла Ибраһимовның «Мөкатдәс сарай» музыкаль комедиясе һ. б.ларның пьесалары бар. Казахстан хөкүмәте 1925 елда театрга аерым бина бирү карарын чыгара. Шуннан соң бу бина сәхнәсендә элегрәк оешкан «Музыка-драма җәмгыяте» музыкантлары да тамашачылар белән очрашулар оештыра. Җитәкчеләре скрипкачы Ибраһим Бикчәнтәев була – «Хөсәения» мәдрәсәсендә Муса Җәлил белән бер чорда укыган шәкерт. Атаклы гармунчы Фәйзулла Туишевның да бу төркем белән бергә чыгыш ясау өчен Оренбургка килү очраклары бер-ике күмәк фотода теркәлгән.

Әлбәттә, бу театр тарафыннан куелган спектакльләрне дә, әлеге музыка җәмгыяте чыгышларын да Казахстан хөкүмәте вәкилләре дә караган, ләззәтләнгәндер. Казах телендә нәшер ителгән матбугат битләрендә шул хакта мәгълүматлар да бардыр. Ләкин әле алар безнең тарафтан барланмаган.

Әйе, Мохтар Әүэзов, Сәкен Сәйфуллин, Сабит Мокановлар безнең Мусаларны, Заһид, Такташларыбызны Оренбургта бергә-бергә эшләгән вакытта гына түгел, соңрак та белгәннәр, алар белән ара-тирә аралашып та яшәгәннәр. Мәсәлән, Мохтар Әүэзовның Алма-Атадагы музей-йортында сакланган китапханәсендә татар язучыларының китаплары да ишле генә. Шуларның бер өлеше мәшһүр әдипкә авторлары тарафыннан бүләк ителгән китаплар. 1990 елда шунда оештырылган китаплар күргәзмәсендә мин Хатип ага Госмановның татар әдәбиятына багышлы китап тышын да күрдем.

Мохтар Әүэзов үз гомерендә байтак кына әсәрләр иҗат итә. Драматург буларак та бик бәрәкәтле эшли. Мәсәлән, аның кулы белән язылган «Абай» драмасы һәм шуның нигезендә композитор якташыбыз Латыйф Хәмиди катнашында опера сәхнәсе өчен эшләнгән «Абай» опералары бүген дә сәхнәдән төшми уйналалар. Ә инде проза жанрындагы уңышларын әйтәсе дә түгел – бөтен дөньяга мәгълүм ич. Язма казах әдәбиятының нигезен салучыларның берсе, русның Пушкины яисә татарның Тукаедай шәхес булган шагыйрь Абай Конанбаевның тормыш һәм иҗат юлын яктыртуга багышланган «Абай» һәм «Абай юлы» роман-дилогиясе татар укучысына да бик таныш һәм якын. Киң эпик колачлы бу әсәр заманында казах халкының телен, гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән әдип Сәрвәр апа Әдһәмова тарафыннан тәрҗемә ителгән иде.

Билгеле инде, Мохтар Әүэзов кебек бер халыкта бер гасырга берәү-икәү генә туган мөхтәрәм шәхес вафатыннан соң да һич онытылмый. Мохтар ага бу дөньядан 1961 елның кышында киткән иде. Аның үлеменнән соң ук, аңа дип махсус атап салынган ике катлы мәһабәт йорт-утар олы әдипнең музее итеп үзгәртелде. Алма-Ата шәһәренең үзәк урамындагы бу музей-йортның ишеге менә ярты гасырдан артык инде һич ябылмыйча, төрле төбәкләрдән һәм төрле илләрдән килгән кунаклар өчен һәрвакыт ачык тора.

Шул музейда булган саен, мин һәрчак бер зур горурлык хисе кичерәм. Мохтар Әүэзовтай олы бер шәхес янәшәсендә аның киңәшчеләре, дуслары, фикердәшләре сыйфатында байтак кына минем якташларым да булган икән дип сөенәм мин. Әнә музей киштәләрендә татар хәреф җыючылары җыеп туплаган казах китаплары. Казан, Оренбург, Уфа басмаханәләрендә 1917 елга чаклы дөнья күргәннәр алар. Алар янәшәсендә үк Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил томнары. Мохтар ага аларны кат-кат кулына алган, укыган. Тагын бер киштәдә

олуг чордашларына авторлар үз куллары белән тапшырган китаплар – Хатип ага Госман әнә «Татар әдәбияты» җыентыгын, Кави Нәҗми «Язгы җилләр», Ибраһим Гази «Гади кешеләр» романнарын бүләк иткәннәр. Ә музейның түреннән Мохтар Әүэзовның сөйкемле зур рәсеме елмаеп карап тора. Аны 1941 елда олуг рәссамыбыз Бакый ага Урманче эшләп бүләк иткән икән…

Нихәтле хатирәләр бу музейда! Ләкин аның залларында йөргәндә дә минем күз алдымда ерак Оренбург каласы, текә Урал яры өстендә калкып торган ак бер бина – Сәкен, Мохтар, Мусалар эзен саклаган бина пәйда була. 1925 елның июнь ахырында Казах мохтариятенең башкаласы Кызыл Урда шәһәренә күчерелә. Оренбург фәкать шул өлкәнең башкаласы булып кала. Урал-су буендагы ак бина өлкәнең комсомол комитеты карамагына бирелә.

Әйе, әйе, Мохтар Әүэзовлардан соң бу бинада Оренбург өлкәсенең комсомол штабы урнаша. Муса Җәлил анда инструктор булып эшли башлый…

*1980–1991*

# КАЗАХ ИЛЕ УЗАМАНЫ

Бөек Октябрь революциясе күпмилләтле Россия әдәбияты мәйданына яңа фикерле, кайнар йөрәкле күп кенә каһарман шәхесләр алып килде. Алар Октябрь давылында туган идеяләрне кулларына корал алып та, ялкынлы сүзләре белән дә халыкка җиткерү өлкәсендә армый-талмый эшләделәр. Шул танылган язмышлар арасында казах совет матбугатына һәм мәдәният оешмаларына, заманча уку йортларына нигез салучыларның берсе – атаклы шагыйрь, драматург һәм романчы Сәкен Сәйфуллин да бар иде.

Сәдуваккас (Сәкен) Сәйфуллин 1894 елда Акмола губернасы Акмола өязендә хәлле күчмә казах гаиләсендә дөньяга килгән. Авыл мәдрәсәсендә ике-өч ел казахча укыганнан соң, аны атасы башта казах балалары өчен ачылган рус мәктәбенә бирә, аннары Акмола (хәзерге Нурсолтан) шәһәрендә урнашкан училищега җибәрә. Бу өчьеллык училищены тәмамлагач, Сәкен, Омскига килеп, укытучылар семинариясенә укырга керә. 1916 елда аны, инде беренче шигырь китабы Казанда чыгып өлгергән яшь шагыйрьне, үз волостена укытучы итеп җибәрәләр. Бу вакытта, мәгълүм ки, казах халкы патша самодержавиясенә каршы баш күтәргән иде. Сәкен патша солдатлары белән бәрелешләрдә турыдан-туры катнашмый. Ләкин аның иреккә, тигез хокукка өндәгән шигырьләре халык арасында тиз тарала. Октябрь революциясеннән соң исә укытучы һәм шагыйрь Сәйфуллин Акмола өязенең беренче җирле Совет хакимияте әгъзасы итеп сайлана.

Аңа мәгариф эшләре буенча өяз комиссары вазифасы йөкләнә. Ул казах авылларында башлангыч мәктәпләр ачу эше белән шөгыльләнә башлый.

Әмма яшь Совет хакимияте көч туплап өлгерә алмый кала, казахларның мөстәкыйль үз дәүләтен булдырырга теләгән көчләре белән Колчак гаскәрләре аларны тарката. Актив совдепчыларны төрмәләргә ябалар. Сәкен, берничә ай Акмола шәһәре төрмәсендә иза чиккәннән соң, «үлем вагоны»нда Омскига озатыла. Анда ул вакытта «бүленмәс, таркалмас Россия» өчен көрәшкән адмирал Колчак хөкүмәте тупланган була. Бәхетенә каршы, яңалык яклы казах яшьләре һәм интернационалист рухлы венгр солдатлары ярдәмендә 1919 елның кышында тоткыннарның беришен коткарып калалар. Тиздән март ае җитә, Алаш Урда белән Колчак гаскәрләре куып җибәрелә. Ireккә чыккан Сәкенне Акмола губернасының яңадан оешкан башкарма советына әгъза һәм җирле хакимият комиссары итеп сайлыйлар. Ә бер елдан соң, 1920 елның җәендә, Ленин кул куйган декрет нигезендә Казахстан автономиясе төзелгәч, аны яшь республиканың Совет оешмасына эшкә алалар. Ул анда Президиум әгъзасы һәм Мәгариф халык комиссары урынбасары буларак сайлана. Ә 1923 елның мартында узган 3 нче Бөтенказахстан съездыннан соң аны Казахстан АССР Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп раслыйлар.

Казахстан дәүләтенең беренче башкаласы итеп Оренбург шәһәре билгеләнә. Сәкен Сәйфуллин 1920–1925 елларда шушы шәһәрдә – моңа кадәр ун-унбиш ел дәвамында татар мәдәниятенең бер үзәге саналган, татар демократик матбугатының бишеге булган данлы калада яши. Билгеле инде, элек биредә нәшер ителгән китаплар белән дә, киң таралган популяр журналлары «Шура», «Карчыга»лар, «Вакыт» һәм «Урал» ише алдынгы карашлы газеталары белән дә азмы-күпме таныш булган кешегә бу мәгърифәтле калада яшәү һәм эшләү кызыклы да, гыйбрәтле дә булгандыр. Биредә аның актив катнашында казахның беренче большевистик рухтагы матбугаты тернәкләнә. «Кызыл Казахстан», «Енбекше казах» газеталарын, соңрак дөнья күргән «Әдәбият мәйданы» журналын һ. б. оештыруга ул үзе үк җитәкчелек итә. Бу эштә Сәкен Сәйфуллинга казах халкының булачак танылган язучылары Мохтар Әүэзов, Баембәт Майлин, Габит Мөсрепов, Сабит Моканов һәм башкалар ярдәм итә. Шушында ук совет казах театрының һәм башка төр сәнгатьләренең беренче нигезләре салына башлый.

Әдипнең Оренбургтагы тормышының тагын бер ягына игътибар итәсе килә. Ул да булса – Сәкеннең һәм шул җөмләдән башка казах язучылары һәм сәнгать кешеләренең татар әдәбияты вәкилләре, беренче профессиональ татар театры һәм музыка сәнгате әһелләре белән якыннан аралашуы. Мәгълүм булганча, бу чорда әле Оренбург сәхнәләрендә Гыйззәтуллина-Волжская оештырган «Нур» труппасы артистлары да, Вәли Мортазин,

Мохтар Мутиннар җитәкләгән «Ширкәт» театры да, сәхнәдән төшмичә, үз эшләрен дәвам иттерәләр. Монда шулай ук Төркестан фронтының сәяси идарәсе каршында төзелгән труппа да эшли. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң ук шәһәр интеллигенциясе һәм «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучылары тарафыннан оешкан «Музыка вә драма» җәмгыяте эшен җәелдереп җибәрә. Шушы җәмгыять тарафыннан 1919 елда ачылган «Оренбург шәрык музыкасы мәктәбе»нә булачак атаклы композиторыбыз Салих Сәйдәшев җитәкчелек итә (анда ул 1921 елның язына чаклы директор вазифасын да башкара). Оренбургта чыгып килгән татар матбугатында Һади Такташ, Шәриф Камал, Фатих Кәрими, Төхфәт Ченәкәй, яшь буын вәкилләре Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи каләм тибрәтәләр. Биредә булачак композиторлар С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, А. Ключарёв, Ш. Мәҗитов, сәхнә осталары Г. Әлмөхәммәтов, М. Мутин, Ф. Камалова һ. б. катнашында музыка кичәләре атна саен оештырылып тора. Әйе, Оренбург шәһәренең гөрләп торган чагы әле. Ул кичәләрдән казахның яшь шагыйрьләре, булачак прозаиклары да читләшмәгән, билгеле.

Сәкен Сәйфуллин Акмолада яшәгәндә үк инде, яшь татар интеллигенциясе белән аралашкан. Әйтик, аның көрәштәше, ялкынлы революционер һәм күренекле казах язучысы Сабыр Шәрипов – безнең хәзерге Әгерҗе районында туып үскән милләттәшебез. Шулай ук Акмола төбәге революционерлары арасында Кәрим Сутюшев, Вәли Хангильдин һ. б. да, милләтләре белән татар булып, Казахстанда Совет хакимиятен урнаштыруга күп көч куйганнар. Бу һәм башка көрәштәшләре хакында Сәкен Сәйфуллин үзенең танылган романы «Тар җол, тайгак кичү»дә бәйнә-бәйнә яза. Тарихи әһәмияткә ия булган зур күләмле бу роман 1936 елда, әдипнең әдәби эшчәнлегенә егерме ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә Алма-Атада тупланып, Казанда басылып чыга. Әлеге романның хикәяләү үзенчәлекләрендә дә «Казан йогынтысы» сизелеп тора.

Әйе, Сәкен Сәйфуллинның ул беренче романы гына түгел, беренче шигырь җыентыгы «Үткән көннәр»дә 1914 елда Казанда басылган. Егерменче елларда Оренбургта Сәкеннең «Канатлы ат», «Думбра» исемле шигырь җыентыклары, «Бәхет юлында» һәм «Кызыл лачыннар» исемле драма әсәрләре аерым китап итеп басылалар. Егерме елдан арткан иҗат дәверендә (әдипнең гомере кырык өченче яшьтә өзелә) Сәкен Сәйфуллин казах әдәбиятында этап булырдай әсәрләрен – «Советстан», «Альбатрос» (В. И. Ленинга багышланган), «Күкчәтау», «Кызыл ат» һ. б. поэмаларын, «Тар җол, тайгак кичү» тарихи романын, «Айшә», «Җир казыганда» повестьларын һәм «Җимешләр» киноповестен иҗат итә. Казахстан Язучылар берлеген оештыру эшендә ул турыдан-туры катнаша. Һәм 1934–1938 елларда ул әлеге Берлекнең рәисе яки рәистәше вазифасын үтиячәк. Һәм шул вазифаны башкарган көннәрдә көтелмәстән генә кулга алынып, тиз арада юк та ителәчәк.

Бу трагедияне оештыручылар Мәскәү тарафы вәкилләре булгандырмы яисә үз тирәсендәге көндәшләре эшедерме – алары миңа мәгълүм түгел.

Бүгенге көндә Казахстанда аның исемен мәктәп һәм башка уку йортлары, шәһәр урамнары йөртә. Казахстанда аңа багышлап әдәби әсәрләр иҗат ителде. «Кызыл лачын» исемле истәлекләр китабы дөнья күрде. «ЖЗЛ» сериясендә аның революцион көрәш һәм иҗат юлын чагылдырган китап язылды. «Казахфильм» киностудиясе, аның биографиясенә нигезләнеп, кинофильм иҗат итте. «Яшь казахлар марсельезасы», «Юлдашлар» кебек революцион рухлы яшьләр гимны булып кабул ителгән әсәрләренә яшь Сәкен үзе үк көен дә иҗат иткән. Көйле тагын берничә шигыре егерменче елларда ук халык арасында киң таралган була. Үзеннән соң да сөйгән халкы аның бик күп шигырьләрен көйгә салып яратып җырлый.

Әйе, казах әдәбиятының яңа чор нигезен салучыларның иң беренчеләреннән булган, ирекле Казахстан совет республикасын төзүгә бар сәләтен биреп көрәшкән мәшһүр әдип Сәдүваккас Сәйфуллин кебекләрне халык һичкайчан онытмый.

*1984*

## ЕРАКТАГЫ ЯКЫН КАРДӘШЛӘР

*(Очерк)*

Урта Азия биләмәсенең көнбатыш тарафтарак бер өлешендә, Арал диңгезеннән көньяктарак безгә кардәш тиешле каракалпак халкы яши. СССР мәмләкәтенә кергән, 1920 еллардан бирле үз милли мохтарияте булган бу төрки кавемнең сөйләм теле безнең телгә бик якын, бер чама мәгълүматы булган һәркем ул телдә язылган әдәбиятны укып аңлый ала. 1980 елларда Каракалпакстан Автономияле Совет Республикасының төп халкы 220 меңнәр чамасы иде. СССР оешкан чорда милли мохтарият хокукын алуга ирешкән аз санлы төрки кабилә шул була. Каракалпакларның бер өлеше шулай ук күрше Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан Республикаларында һәм шуларга чиктәш Әфганстан илендә дә гомер кичерә, дип хәбәр ителә «Каракалпакстан АССР тарихы» китабында (1975). Күренекле тарихчы һәм археолог С. П. Толстов язуынча («Древний Хорезм», 1948), каракалпаклар борынгы Харәзем дәүләте чорыннан бирле Амудәрья елгасы буенда яшәгәннәр. Бу төрки кавемнең исеменә карата төрле фикерләр йөри. Татар тарихчыларыннан кайберләре аларны «кара калпак киеп йөргәнлектән шулай аталганнар» дип белдерә. Шул фикерне дәлилләү өчен, алар: «Кавказ халыкларыннан да бит кайберләрен, кызыл түбәле баш киеме кигән өчен, тарихка багышлы хезмәт-

ләрдә «кызылбашлар» дип язалар», – димәкчеләр. Алда күрсәтелгән тарих китабын укыган кеше бу фикернең хата булуын аңлар. Бу исем аларга бик борынгыдан килгән бер гореф-гадәтләренә бәйле рәвештә бирелгән. Бу кавемнең ир затлары унике яшьтән алып картайганчы баш түбәсендә бер учма чәчне калфак рәвешендә урап йөрткән. Кавем исеме дә шул чәч үременә бәйле рәвештә барлыкка килгән. Урта гасырларда каракалпакларның бер өлеше кыпчак кабиләләре белән бергә Днепр, Дунай буйларынача барып җиткән. Аларның Киев кенәзе Юрий Долгорукийга турылыклы хезмәт итәргә вәгъдә биргән сүзләре рус елъязмаларында теркәлеп калган. Соңрак үз кавеменнән аерылып, ирекле казак рәвешендә яшәүчеләре дә була. Шуларның бер төркеме, борынгы йолаларын саклап, баш түбәсендә бер учма чәч йөртүче «чубатый казак»ка әверелгән. Ягъни Днепр елгасының урта бер җирлегендә, «таш бусагалы бик сай өлешендә» яшәүчеләр – «Запорожье казаклары» – шушы кавем вәкилләре һәм алар йоласын кабул итүчеләр буладыр, мөгаен. Украина тарихына багышлы хезмәтләрдә дә каракалпаклар еш искә алына, дип яза каракалпаклылар.

Әйе, бездән шактый еракта безгә тугандаш халык – каракалпак халкы яши. СССР хакимияте елларында каракалпаклар яшәгән җирләр элегрәк Харәзем Халык республикасына да, Казахстанга да, РСФСР биләмәсенә дә кергән. 1936 елның 5 декабреннән ул төбәк хәзерге Үзбәкстан Республикасы буйсынуында яши. Каракалпакстанның Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, профессор Кабул Максютов 1980 елда «Амудәрья» журналында болай дип язган иде: «Егерменче гасыр башында татар телендә елына өч йөзләп китап басылды. Аның йогынтысы каракалпак халкына да җитеште... Г. Тукай ише олуг әдипләр барлык төрки телле халыкларның сөекле шагыйренә әверелделәр... Каракалпак язучылары, шагыйрьләре алардан үрнәк ала иде».

Каракалпак әдәбиятының үз тарихи шәхесләре дә ишле генә. Башка бик күп төрки әдәбиятлардагы кебек үк, элегрәк аларда да чәчәнлек традицияләре өстенлек иткән. Соңрак кулъязма әсәрләрнең кулдан-кулга күчеп, күчерелеп йөрү чоры башлана. Шундый кулъязма хәлендә сакланган шигырьләрдән Көнхуҗаның (1799–1880) «Куй көтүче», «Уракчылар»ы, Әҗинияз (1811–1878), Бердах (1827–1900), Үтәш (1828–1902) һ. б. шагыйрьләрнең әсәрләре сакланган. Күсәбай улы Әҗинияз XIX гасыр каракалпак әдәбиятының иң күренекле вәкиле буларак танылa. Аның «Боз атаулы гүзәлем», «Күңелем», «Нәрсә яхшы?» һ. б. әсәрләре халык арасында иң күп тарала дип бәялиләр әдәбият галимнәре. Чәчәннәр әйтешендә дә ул осталарның остасы саналган. Ә Әҗиниязның казах кардәшләребезнең хатын-кыз акыны Мәңеш белән чәчәнлек ярышы нәтиҗәсе 1878 елда Ташкентта казах телендә нәшер ителүче «Төркестан вилаяте гәҗите»ндә дә басылып чыга. Төрки телдә чыгучы бу газетаның тарихы да кызыклы. 1865 елда Ташкент Россия тарафыннан яулап алына, 1867 дә

анда Төркестан генерал-губернаторы идарәсе оештырыла. Генерал-губернаторның җирле халык белән эшләүче ярдәмчесе итеп милләттәшебез морза Шаһимәрдән Ибраһимов билгеләнә. Һәм 1870 елның апрелендә шул кеше тырышлыгы белән русча чыга башлаган газетаның атналык кушымтасы рәвешендә әлеге беренче төрки телле газета борын төртә. Ул газетаның өлешчә казахча, өлешчә үзбәкчә нәшер ителгән вариантлары да, бер атнада бер телдә, икенчесендә икенче телдә чыкканнары да булган, диелә.

Каргабай улы Бердах (Бирдеморат) та язма каракалпак әдәбиятына нигез салучыларның берсе санала. Аның кайбер иҗат үрнәкләренең XX гасыр укучысы кулына кайтарылу тарихы да үзенчәлекле. Аның бер өлеш әсәрләре Петербург университетының Шәрык бүлегендә белем алган һәм Амударья административ үзәгенә эшкә билгеләнгән рус кешесе И. А. Беляев тарафыннан берничә елда тупланган һәм 1917 елда бастырып чыгарылганнар.

Милләттәшебез, Казан артындагы Үртәм авылында 1869 елда туган Сәйфелгабит Мәҗитов та каракалпак әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес. Улына сигез яшь тулганда, Мәҗит абзый, бәхет эзләп, Урта Азия якларына таба чыгып китә. Алар гаиләсе әүвәл берничә ел Актүбә шәһәрендә яши. Сәйфелгабит анда казах, татар яшьләре белән аралаша. Татар бистәсендәге мәдрәсәдә укыгандыр да, мөгаен. 1960 еллар тирәсендә нәшер ителгән биографик белешмәлектә шул хакта хәбәр юк. Хәер, ул белешмәлектә башлыча аның Каракалпакстан җирләрендә яшәгән чоры гына теркәлгән диярлек. Анда аның Амударья (Җәйхун) буендагы Коңгырат каласындагы бер мәктәп-мәдрәсәдә дәрес биргәнлеге генә искә алына. 1905 елдан соң төрле тарафта төрки-татар газеталары чыга башлагач, аның кайбер шигырь үрнәкләрен Оренбург, Казан, Уфа шәһәрләренә дә җибәргәләгәнлеге әйтелә.

Әйе, 1910 еллар башында алар гаиләсе каракалпаклар иленә барып төпләнә. Яшь иҗатчы каракалпаклар белән аралашып, шул телдә дә иҗат итә башлый. Монда ул олуг акын Бердах белән таныша. Шигъри әйтешләрдә дә катнаша. Шул вакыйгалардан соң аның кайбер иҗат үрнәкләренең Ташкентта үзбәк телендә нәшер ителүче «Төркестан вилаяте гәҗите»ндә дә чыккан булырга тиеш дип фаразлана. Әмма каракалпак галимнәре ул газета саннарын әлегә тулаем тикшермәгәннәр иде. 1938 елда милләтче буларак төрмәгә ябылган һәм шунда юк ителгән Сәйфелгабит иҗатын барлауга галимнәр сиксәненче еллар башында гына керешә диярлек.

Шул ук утызынчы елларның башында каракалпак әдәбиятының классигы буларак танылган Сәйфелгабит Мәҗитовның каракалпак телендә иҗат ителгән беренче каләм хезмәте 1907 елда ташбасмада басылып чыккан дип санала. Каракалпакстанда Совет хакимияте урнашкач та, турыдан-туры аның катнашында анда «Совет Каракалпакстаны»ның башлангычы

булган «Беренче адым» (1924), «Иркен Каракалпакстан» газеталары (соңгысында ул җаваплы сәркәтип тә була), «Хезмәт әдәбияты» (1931) исемендә журнал чыга башлый. Бу матбугат битләрендә аның каракалпак телендә иҗат ителгән беренче проза әсәрләре дә дөнья күрә. Бу елларда С. Мәҗитовның «Сөен белән Сара», «Җомагол», «Байбәтчә» һ. б. исемнәрдә күләмле проза әсәрләре басылып чыга. Алты пьесасы («Ирназар батыр», «Соңгы киртә», «Багдагөл», «Сабак», «Гөләм – Тайман» музыкаль драмасы һ. б.) яңарак оешкан драма театры артистлары тарафыннан сәхнәләштерелә. С. Мәҗитов 1934 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Дөресрәге, Берлекне оештыруда да актив катнаша. 1924 елда С. Мәҗитов Харәзем Халык республикасы тарафыннан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1938 елда кулга алына һәм озакламыйча шунда вафат була. Шуннан соң күләмле шигырь җыентыгы – 1965 елда, «Ата һәм ул» хикәяләр тупланмасы 1970 елда нәшер ителәчәк. Аның 1965 елда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр» китабын мин җиде-сигез еллар элек Арча музее җитәкчелегенә тапшырдым.

1970 еллар ахырында Татарстан республикасы башлыклары һәм Язучылар оешмасы җитәкчелеге Үзбәкстанда Татар әдәбияты һәм мәдәнияте атналыгын уздырырга, анда яшәүче берничә йөз мең кешедән торган якташларыбыз белән очрашулар оештырырга хыялланган иде. Әмма Мәскәү түрәләре аңа рөхсәт бирмәде. Автономияле республика оешмалары үз дәрәҗәләрендәге оешмалар белән генә шундый аралашу гамәлләрен булдыра ала дигән тәртип кертелә башлаган чор иде ул. Үзәктән шулай диелгән тәкъдим килгәч, Үзбәкстан кардәшләребезнең түрәләре андый очрашуны оештыруны Каракалпакстан АССР җитәкчеләренә йөкләгәннәр иде. Һәм 1980 елга Каракалпакстанда Татарстан АССР әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре билгеләнде. Татарстаннан ул чарада йөздән артык кеше катнашты. Партиянең өлкә комитеты секретаре Морзаһит Вәлиев җитәкчелегендәге делегациягә шактый гына күренекле язучылар да, абруйлы исем яулаган артистлар һәм мәдәният оешмалары түрәләре дә кергән иде. Нәкъ шул атналык нәтиҗәләреннән соң иң-иң күренекле каләм әһелләренә һәм артистларга Каракалпакстан Республикасының мактаулы исемнәре дә бирелде. Шул уңай белән үзбәк һәм каракалпак телләрендә Татарстан язучыларының әсәрләре өч китапка туплап чыгарылды.

Ул елларда Каракалпакстан җире Үзбәкстан ССР биләмәсенең 43 % чамасын алып тора, дип яздылар. Ләкин ул җирләрнең яртысы диярлек уңдырышсыз ком чүле иде. Каракалпаклар Караком белән Кызылком чүлләре аралыгындагы үзәннәрдә генә гомер итәләр. Шул республиканың төрле районнарында булып кайткан безнең язучылар Амударья буйларындагы басуларда «ак алтын» дәрәҗәсендә йөргән мамык-пахта үстерелүен, авыл тирәләренең җиләк-җимеш бакчаларына күмелеп утыруын күреп кайттылар. Чүл читләрендәге такырлыкларда куй көтүләре чем-

ченеп йөрер иде. Элгәрерәк елларда, Караком чүле аша җир сугару каналларын төзеп, Амударья суын әлеге чүлләр тирәләрендәге коргаксык кырларга күпләп агыза башлаганчы, каракалпаклар Арал диңгезе буйларыннан күпләп балык та тота торган булганнар. Ләкин 1970 еллар ахырына таба Арал диңгезе бик нык саеккан, яр буендагы авыллар тирәсеннән бик ераклашкан иде. Шул тирәләрдә яшәүчеләрнең: «Хәзер бездә балык юк, яр буен каплап алган камышлыкларда ерткыч җанварлар гына яшидер», – дип уфтанып сөйләүләре генә хәтердә.

Каракалпак халкының зыялырак катламы татар әдәбиятының күренеклерәк вәкилләре иҗаты белән элек-электән таныш булган. Каракалпак телендә «Идел – илнең ишеге, Җаек – җирнең бишеге» дигәнрәк әйтем дә сакланган. 1970 елларда татар шигърияте үрнәкләрен каракалпак теленә актив тәрҗемә итүчеләр буларак Ибраһим Йосыпов, Таҗетдин Сәетҗанов, Бабаш Исмаилов истә калган. И. Йосыпов, шул елларда Язучылар берлеге рәисе рәвешендә, Казанга да берничә мәртәбә килгән иде. Каракалпак телендә ул Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Кәрим шигырьләрен бастырып чыгарды, татар әдәбиятына, аның тарихына багышлы мәкаләләр дә язды. Аның шундый эчтәлекле бер күләмле мәкаләсен тәрҗемә итеп, мин аны «Социалистик Татарстан» газетасында чыгарган идем. Галим һәм шагыйрь Бабаш Исмаилов та Г. Тукай, И. Юзеев һ. б. татар әдипләренең иҗат үрнәкләрен үз халкына җиткерүчеләрдән булды.

1981 елның май аенда, Татарстанда Каракалпак әдәбияты һәм мәдәнияте атналыгын оештыру чараларын барлар өчен дип, Казанга Каракалпакстанның мәдәният министры, Язучылар берлеге рәисе һәм тагын берничә түрә килеп киткән иде. Ә җәй урталарында Каракалпакстан язучыларыннан, артистларыннан һәм бериш түрәләреннән торган зур бер төркем Татарстан белән танышып, үз иҗатлары белән таныштырып йөрде. Алар килешенә Татарстан китап нәшрияты 26 табаклы калын китап бастырып чыгарган иде. Ул «Арал дулкыннары» китабының төзүчесе, оештыручысы мин булдым. Кунаклар ул мәҗмуганы бик югары бәяләделәр, «әле үзебездә дә мондый каракалпак әдәбияты антологиясенең нәшер ителгәне юк» диделәр. Китап минем кереш мәкалә белән башлана. Аннары Әҗинияз, Бердах, Сәйфелгабит Мәҗитов һ. б. ларның иҗаты белән укучыны таныштыра.

Шушы томны туплар алдыннан, миңа да Каракалпакстанда булып кайтырга туры килде. Мин Каракалпакстан язучыларының VIII съездына чакырулы идем. Алтмышлап язучыны туплаган ул корылтай ике көн дәвам итте. Башкорт әдәбияты вәкиле буларак анда Наҗар ага Нәҗми дә катнашты. Каракалпак халкының батыр, олуг шәхесләре истәлегенә куелган хатирәле урынга чәчәкләр салучылар арасында алгы рәттә сулда – мин, уңда басып торучы – Каракалпакстан Язучылар берлегенең яңа рәисе, халык язучысы Теләпбиргән Каипбиргәнев булды.

Өстәп шуны да әйтеп китим – 1970–1980 елларда каракалпак һәм төрекмән телендә нәшер ителүче китапларның бер өлеше безнең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатында басылып чыга иде. Шул китапларны нәшер итүгә бәйле мәшәкатьләр белән йөрүче вәкилләр арасында язучылар да еш очрый иде. Һәм еш кына алар, кунакханәгә урнаштыруны үтенеп, миңа да мөрәҗәгать иткәләделәр. Шул мәсьәләләргә бәйле рәвештә хатлар алышкан чаклар да булды. «Сезнең басмаханәдә минем китап чыгасы иде. Нишләп соңлый ул, ачыкла әле», – дип язган бер төрекмән язучысының хаты да саклана. Ул Муса Җәлил шигырьләрен бик яратып тәрҗемә иткәнлекләрен дә искә алган иде. Ул хатларның кайберләре әле дә миндә саклана. Шундый вәкилләрнең берсен, китап нәшрияты тарафыннан җибәрелгән каракалпак язучысы Мамәтали (безнеңчәрәк язганда Мөхәммәтгали була) Каиповның исә Казанга берничә мәртәбә килгәнлеген хәтерлим. Кунакханәләрдә урын булмау сәбәпле, аны өйгә алган чаклар да булгалады.

Хәзер Арал диңгезендә су юк, диңгез төбе дә чүлгә әверелеп бара, дип язалар безнең үзәк матбугат битләрендә. Безгә якын кардәш халык хәзер ничек яшидер – 1990 еллардан соң үзара аралашулар бик чикләнде шул. Берничә ел элек, Казан урамына асфальт түшәп йөрүчеләр арасында каракалпакча сөйләшкәнне ишетеп туктап, ике егет белән бераз хәл-әхвәлләр турында хәбәрләшеп торган идек. «Бездә элеккечә – эш урыннары әз, кеше күп. Күпчелек халык мал асрау белән көн күрә. Ә без, менә, армиядә хезмәт иткән чакларны искә төшереп, монда килдек әле. Эшебез бар, зарланмыйбыз», – диештеләр.

Матбугат хәбәрләренә караганда, хәзер Үзбәкстан икътисады да алга үрмәли икән. Шуннан кайтып киткәләгән үз милләттәшләребезнең дә фикере шундый. Димәк, борынгы тарих һәм сөйләм ягыннан без татарларга шактый ук якын булган каракалпак, үзбәк халкының да тормышы җайлана барадыр.

*2014*

# АЗӘРБАЙҖАН МӘДӘНИЯТЕН ӘЙДӘҮЧЕЛӘР

*(Очерк)*

Дөньяви тәрбия алган, заманча укый-яза белгән татар кызлары узган гасыр башларында Урта Азия төбәге милләтләре арасында гына түгел, Кавказ мөселманнары арасында да «затлы килен» саналганнар. Бигрәк тә кардәш казах халкы арасында безнең милләт кызларын үз иткән гаиләләр ишле булган. Казах халкының күренекле бер вәкиле, танылган язучысы Сәүрбәк ага Бакбиргәнев бервакыт миңа үз милләттәшләре арасында элегрәк елларда бик еш кабатланган бер әйтемне кәгазь битенә язып та

күрсәткән иде: «Казах баласы укып белем алса, бер нугай кызына кияү булыр», – дип. (Әйе, казах кардәшләр, үзара сөйләшкәндә, безнең милләт вәкилләрен еш кына «нугай» дип атый.) Шул әйтемне нигезләп, ул совет чоры казахларының зыялы катламы арасыннан шактый гына мисаллар да китерде. Хәер, үзем якыннан аралашкан казах язучылары арасында да шундый язмышлы шәхесләр шактый иде. Шул ук Сәүрбәк ага да, сугыш чорында Әгерҗе госпиталендә дәваланганда, үзенә тиң ярны безнең кызлар арасыннан сайлап ала. Совет чоры казах әдәбиятының күренекле вәкилләреннән булган Шерхан Мортазаев белән Саин Моратбәковның аналары, Әнүәр Әлимҗановның исә сөекле җәмәгате безнең милләт кызлары иде.

Инде Кавказ төбәгенә бәйле бер үрнәккә игътибарыбызны юнәлтик. XIX йөзнең егерменче елларында ярым мөстәкыйль рәвештә яшәгән Кавказ төбәге халыкларын Россиягә «кушу» вакыйгалары башлана. Ул сугышларда байтак кына татар яисә татарга күпмедер дәрәҗәдә мөнәсәбәте булган кешеләр дә катнаша. Мисалга руслашкан татар әбисе карамагында тәрбияләнгән Михаил Лермонтовны атап китү укучылар өчен кызыклы булыр. Замандашлары билгеләп үткәнчә, Кавказда хәрәкәт итүче армиягә эләккәч тә, ул, кумык, нугай милләте вәкилләре белән аралашып, җирле төрки сөйләм теле белән кызыксына башлаган була. Шул кызыксынуларының эзләрен аның шигырьләрендә дә, атаклы повестенда да күреп була, дип яза кайбер белгечләр. Шушы уңайдан аның әлеге повестендагы баш героинясы – Бэла исемен атап китү дә җитә. Бу шук кызны туган абыйларының «бәла, бәла» дип атап йөрткәнлегe әсәр тукымасында ук китерелә. Һәм әлеге сүз яшь офицер Печорин өчен исемгә әверелә...

Элекке Касыйм ханлыгы төбәгеннән чыккан морза Хәсән Сәфәр улы Терегулов гаиләсендә тәрбияләнеп үскән кызларның язмышы да Сәүрбәк ага минем дәфтәргә язып куйган әлеге әйтемгә бик тә туры килә. Кавказ таулары артына барып чыккан йомышлы татар морзасы Сәфәрҗанга һәм шул төбәк тарихында тирән эз калдырган аның гаиләсенә багышлы истәлек язмаларына күз төшереп алыйк. Азәрбайҗанлы Исмаил Умидле (Өметле) «Татарский род Терегуловых» дип аталган мәкаләсендә болай дип яза: «Идел төбәгендә туган татар морзасы Сәфәрҗан егерме еллап рус армиясендә күпер төзүче буларак хезмәт итә. 1845 елда отставкага чыккач, гаиләсе белән Тифлис каласында яшәп кала. Ул вакытта аның Владикавказ шәһәрендә хезмәт иткәндә туган кызы Фатыйма белән ике улы – Хәсән һәм Ибраһим була. 1835 елда туган Хәсән соңрак Тифлистагы сөнниләр мәзһәбен тотучы мөселманнар мәчете имамы итеп сайлана. Ә 1889 елда ул бертуганы Ибраһим белән шул ук шәһәрдә рус-татар мәктәбен ачып, балалар тәрбияләүгә дә үз өлешен кертә. «Тифлис каласының шәрәфле әгъзасы Гасан (Хәсән) Сәфәр углы 1911 елда вафат була», – дип яза. (Кавказ халыклары арасында яшәгән

милләттәшләребезнең шул төбәк йоласына хас рәвештә соңрак Хәсәннең Гасан булып теркәлүе, Хәнәфинең Ганафи дип, Фатыйманың Патимат дип атала башлауларына аптырамаска тиешбез.)

Сәфәрнең өлкән улы Хәсән-Гасан шулай ук Касыйм төбәге морзалары нәселеннән булган Мәскәү шәһәре кешесе Акмаев кызы Раббияга өйләнә, диелә әлеге язмада. (Бу хатын-кыз исеме Рабиганың да Кавказ халыклары теленә тартымрак итеп үзгәртелгән булуы ихтимал.) Хәсән мулла белән Раббияның XX йөз башында төшкән фотолары сакланган. Алар алты кыз һәм өч ул тәрбияләп үстергәннәр.

Иң элек уллары Хәнәфи (Мөхәммәдхәнәфи, кавказчалаштырганнан соң Ганафи, 1877—1942) Бакуга күчеп, шунда танылган шәхескә әверелә. 1908 елда азәрбайҗан телендә куелган тәүге операларның берсендә («Ләйлә вә Мәҗнүн», композиторы Гозәер Гаҗибәков) төп рольләрне башкара, күмәк җырчыларның – хорның да җитәкчесе була. Бакуда нәшер ителүче «Каспий» газетасының 1909 елга караган бер санында Гасан Тернекулзадә башкарган роль турында: «Играл удачно, пел недурно», – дип язалар. («Тернекулзадә» – Хәнәфинең сәхнә тәхәллүсе.) Бу әсәр азәрбайҗанның милли җанлы нефтьче магнатлары яңарак ачкан музыкаль театрда уйналган тәүге милли опера була. Әлеге вакыйгадан соң бу театрда музыкаль әсәрләр еш куела. Шул ук газетаның 1915 елгы санында исә җырчы артист Хәнәфи турында «Выделялся своим голосом и игрой» дигән сүзләр дә теркәлгән. Соңрак ул опера җырчыларын тәрбияләүче педагог та була. Ул башка операларда да, шул исәптән «Гозәер кияү»нең «Аршин мал алан» музыкаль комедиясендә дә төп рольләрне башкарачак. Сәхнәдә аны Терникулзадә (Терегулов фамилиясенең азәрбайҗан теленә тартым варианты) буларак күбрәк беләләр. Операларда җырларлык осталыкка ул Тбилисидан ерак булмаган Гори шәһәрендәге укытучылар семинариясенең төрки-татар бүлегендә укыган елларында өйрәнә. (Шул ук шәһәрдә ул елларда ата-бабаларыбызның «бөек юлбашчысы» Иосиф Джугашвили-Сталинның укыганлыгын да искә алып үтик.) Ул уку йортында җырларга, музыка коралларында уйнарга өйрәтү дәресләре югары дәрәҗәдә оештырылган була. Азәрбайҗан халкының рәсми танылган беренче композиторлары Гозәер (Узеир) Гаҗибәков белән Мөслим (Абдул-Мөслим) Магомаевларның да шунда укыганда музыкаль белем үзләштерүләрен әйтеп китү кирәктер. Алар анда Хәнәфи һәм Али Терегуловлар белән бер чордарак укыйлар. Һәм Тифлиска бергә кайтып йөргән вакытларда Терегулов морзаларның тәрбияле сеңелләре белән дә танышалар.

1917—1920 еллардагы түнтәреш вакыйгаларында да катнаша Хәнәфи. 1917 дә Бакуда милләттәшләребезнең «Берлек» берләшмәсен оештырыша, 1918—1919 елларда Идел-Урал тарафларында акларга каршы сугышып йөри. 1920 елда янә Бакуга әйләнеп кайта. Азәрбайҗан республикасы коммунистларының Үзәк коми-

тетында да эшләп ала. 1929 елда оста җырлаучы татар артистына мактаулы Хезмәт Батыры исеме бирелә.

Энесе Али Хәсән улы Терегулов (1883–1950) гомерен педагогика хезмәтенә багышлый. Шул ук вакытта аның скрипкада оста уйнаганлыгы да билгеләп үтелә. Гозәер Гаҗибәковның «Ләйлә вә Мәҗнүн» операсы беренче мәртәбә сәхнәләштерелгәндә, 1908 елда аңа баш скрипкачы вазифасын башкарырга туры килә. Ул да Гори шәһәре семинариясенең төрки бүлеген тәмамлаган. Шунда укыганда, скрипкада оста уйнарга өйрәнгән. Нәкъ шунда ул булачак композиторлар һәм кияүләр Гозәер Гаҗибәков һәм Абдул-Мөслим Магомаев белән дуслашып китә. Алар да шул семинариядә укыганда скрипка һәм фортепианода уйнау серләрен үзләштерәләр.

Хәзер инде укымышлы мулла Терегулов гаиләсеннән чыккан тәрбияле, укымышлы кызлар тирәсенәрәк килик. Аларның икесе – Мәликә белән Бәдыйгөл – азәрбайҗан милләтенең иң мәшһүр ике композиторы Гозәер Гаҗибәков белән Абдул-Мөслим Магомаевта, ә өченчесе – Хөсниҗамал – шушы ук даирәгә якын торган Хәмзә (Гамзат) Хәлиловта кияүдә булалар. Ә гомерен укыту эшенә багышлаган, 1954 елда Бакуда бакый дөньяга күчкән Мәрьям Терегулованың ире Гобәйдулла Гасыймовның да музыкага тартым кеше булуын әйтеп китү кирәктер.

Әүвәл Хәлиловларның ике улын искә алып үтик. Руфат (Европада яшәгәндә – Роальд) Гамзат улы Хәлилов (1894–1970, Франциядә вафат) үз илендә җырчы артист, ә 1920 елларда иленнән киткәч – чит ил сәхнәләрендә Кавказ төбәге халыклары биюләре остасы буларак дан казана. Рамазан Гамзат улы Хәлилов (1901–1999) исә республикада җәмәгать эшлеклесе буларак таныла. 1950–1960 елларда ул Бакуда Опера театры директоры вазифасын үти. Элегрәк исә җизнәсе Гозәер Гаҗибәковның шәхси сәркәтибе һәм депутат ярдәмчесе була. Ә пенсиягә чыккач, озак вакыт Г. Гаҗибәков музееның директоры булып эшли. Руфат Хәлиловның биографиясенә безнең илдә бик алай әһәмият итүче юк бугай. Азәрбайҗанлылар да аны бик сирәк искә алган. Ә менә атаклы җырчы, композитор Мөслим Магомаевның оныгы Мөслимгә багышлы кинофильмда ул күренеп китә. Мөслим Магомаевның көндәшләре, аның Парижда Руфат агасы белән берничә мәртәбә очрашуыннан файдаланып: «Ул чит илдә калырга ниятләде», – дип яла ягачаклар. Башка вакытларда чит илләргә чыгучы артистлар исемлегеннән сызып ташларга тырышачаклар.

Мәликә Хәсән (Гасан) кызы Терегулова (1893–1966) белән Гозәер Гаҗибәков (1885–1948) 1909 елда Бакуда өйләнешәләр. Ул вакытта инде Гозәер, беренче операсын сәхнәләштереп, азәрбайҗанлы кардәшләребез арасында зур дан-шөһрәткә ирешкән була. Шуннан соң аның бер-бер артлы «Мәшһәди Ибады», «Кёр углы» кебек атаклы опералары, «Аршин мал алан» музыкаль

әсәре сәхнәләштерелә (соңгы әсәр исеме шулай ук русча да тәрҗемәсез языла. Ул атаманың мәгънәсе – «аршинлап мал алыгыз» дигәнне аңлата дип язалар. Ә «Кёр углы» операсы исә шул исемдәге борынгы төрки дастан сюжетына нигезләнгән). Шул ук вакытта ул үз сәхнә әсәрләренең либреттосын иҗат итүче буларак та билгеле. СССРда яшәп иҗат иткән саф төрки композиторлардан беренчеләрдән буларак консерватория бусагасын атлап кергән шәхес ул. 1913 елда ул Петербург консерваториясенә барып урнаша, 1914 елгы сугыш башланган көздә аны ташларга мәҗбүр була. Соңрак укуын Мәскәүдә дәвам итә. Баҗасының һәм яшьлек дустының онысы, мәшһүр җырчы Мөслим Магомаев «Живут во мне воспоминания» китабында (Мәскәү, 2009, 12 б.) консерваториядә укыган вакытта Гозәергә бабасының матди ярдәм итеп торганлыгын әйтеп үтә. Икенче бер автор язмасында исә «преданная супруга Мелика ханум»ның да Гозәернең иҗади эшендә даими ярдәмчесе булганлыгы бәян ителә. Хәсән мулла кияве Г. Гаҗибәков соңрак Азәрбайҗан Республикасы композиторлары союзы рәисе, шул республика академиясенең академигы булып сайланачак. СССР Югары Советының I, II сайланышы депутаты булачак.

Бәдыйгөлҗамал Хәсән кызы Терегулова (?–1963) – Мәликәнең туганы. 1907 елдан ул музыкант Абдул-Мөслим Магомаевта (1885–1937) кияүдә була. Онысы Мөслим Магомаев истәлекләрендә дә, кайбер башка язмаларда да аның «искиткеч гүзәл гөл» мәгънәсенә тиң исемен «Байдигюль» (болын, кыр гөле) рәвешендә үзгәртеп тә язалар. Абдул-Мөслим семинария тәмамлагач, берничә ел Ленкоран шәһәрендә укыта. Шул вакытта алар кавышалар. Алар гаиләсе Бакуга 1911 елда килеп урнаша. Алда телгә алынган бертуган Терегуловлар һәм Гозәер Гаҗибәков белән Мөслим Гори шәһәре семинариясендә укыган елларында таныша. Үзе Грозный шәһәрендә туган. 12–13 яшьләрдә ятим калып, кеше гаиләсендә үскән бугай. Бер язмада аның кумык милләтеннән булуы әйтелә. (Онысы Мөслим аның кайсы милләттән булуын тәгаен белмим дип яза.) Патша хакимияте чорында Кавказ төбәгендә яшәгән, төрки телдә сөйләшкән кешеләрнең күпчелеге үзара аралашканнар һәм рус әдәбияты язмаларында еш кына «татар» булып йөргән. Безнең төбәкләрдән чыгучыларны аерып күрсәтергә кирәк булганда гына азәри кардәшләр «Идел буе татары» яисә «Казан татары» төшенчәләрен кулланалар. Абдул-Мөслим дә гомерен азәрбайҗан кардәшләребез сәнгатен үстерүгә багышласа да, әлеге семинариядә уку елларында безнең милләт вәкиле исемен дә йөрткән бугай.

Әйе, Абдул-Мөслим ятим үсә. Яшьтән үк төрле музыка коралларында уйнау белән мавыга. Аның тырышуын истә тотып, укыган елларында ук аңа скрипка бүләк итәләр, дип яза онысы. Олы Мөслим иҗат иткән һәм сәхнәләштерелгән опералар: «Исмаил шаһ» (1916) белән «Нәргиз» (1934), ә тәмамланмаган әсәре «Һа-

руз бәй» дип исемләнгән икән. Яшьтән төрле оркестрларда, төрле уен коралларында уйнаудан тыш, ул Азәрбайҗан республикасы радиокомитетының музыкаль бүлеген дә җитәкләгән. Бәдыйгөл белән алар ике ул тәрбияләп үстерәләр. Җамалетдин Магомаев (1910–1977) – дәүләт эшлеклесе, гомеренең соңгы елларында Мәскәүдә Азәрбайҗан ССР вәкиле булып та тора. Кече Мөслимне – атаклы опера җырчысын тәрбияләп үстерүче дә ул була. Җәмәгате – рус милләте вәкиле Мария. «Бездә өйдә аралашу теле рус теле булды. Миңа ачуланасы булса гына әбием татарчага күчәр иде», – дип яза җырчы Мөслим. Аның атасы Мөхәммәт (Магомет) Магомаев (1916–1945) театр рәссамы булган, сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган. Аның үлү хәбәре килгәч тә, хатыны Бакудан китә, РСФСР шәһәрләрендә, рус театрларында эшли. Берничә мәртәбә кияүгә чыга. Шул рәвешле өч яшьтән кече Мөслим, ата-анадан аерылып, Бәдыйгөл әбисе белән атасының олы агасы тәрбиясендә үсә. Әлеге истәлек китабында ул «татар әбие»н бик еш искә ала. «Мине ул тәрбияләде», – дип яза. Берәр төрле кирәкмәс эш эшләсәм, ул мине татарча орышыр иде, ди. Әйе, Мөслимнең әнисе улына өч яшь тулар-тулмастан читкә китә. Өйдә хуҗабикә рәвешендә өлкән килен Мария да яшәгәнлектән, төп сөйләм теле русча булган. Бәдыйгөл карчык, килен алдында сер бирмәс өчендер, мөгаен, оныгы белән шулай «үз» телләрендә дә сөйләшкәләп алгалагандыр, күрәсең.

Бу гаиләләрнең, Гозәеров белән Магомаевларның, Мәскәүдә яшәгән туганнарын – Раббия (Рабига?) Акмаеваның якыннарын да искә алыйк. Әминә (ире буенча Бабкәева) һәм Ибраһим Акмаевлар белән элегрәк кем, ничек аралашкандыр, әйтә алмыйм. Әмма үзара элемтәләре өзелмәгән. Сугыш алды елларына караган истәлекләр дә бар. Ә сугыштан соң Гаҗибәковлар гаиләсе дә, Бәдыйгөл белән улы Җамал да Мәскәүдә яшәгән туганнарында еш булгалап торганнар. Шуны дәлилләгән кайбер фотолар да сакланган. Миндә алар бар. Җырчы Мөслим дә, 1959 елда Мәскәү консерваториясе белән танышырга килеп, түләүле студиядә тавышын яздыргач, акчасыз кала. «Монда безнең туганнар да бар инде, тик минем кешедән соранып йөрисем килмәде. Әбием акча җибәргәнче, дүрт көн чамасы ач хәлдә яшәдем», – дип яза ул (65–66 б.).

Ибраһим белән Бибилатыйфа Акмаевларның улы Әдһәм ага Акмаев (1916–2006) Казанда гомер итте. Һөнәри белем бирүче уку йортларында укытучы да, директор да булган кеше. Пенсиягә чыкканчы ун-унике ел чамасы һөнәри белем бирүче республика мәгариф оешмасы башлыгының урынбасары булып эшләде. РСФСРның атказанган укытучысы иде. Ара-тирә очрашкалаган вакытларда, ул Азәрбайҗанда яшәүче туганнарын да искә төшергәләде. Югары Совет депутаты Гозәер Гаҗибәков һәм аның каенише һәм ярдәмчесе булган Рамазан Хәлилов белән бергә Мәскәүдәге Әминә апалары дачасында төшкән күмәк фото да

саклана. Анда Әдһәм Акмаев та бар. Ләкин, Мәскәүдә яшәмәве сәбәпле, ул алар белән сирәгрәк очрашкан шул. Хәзер инде ул фотолар һәм истәлекләрне Әдһәм аганың җәмәгате, пенсиядәге табибә Хөршидә ханым белән кызы Алия Акмаевалар бик кадерләп саклап тоталар. Бу язмама тотынганда, мин дә, нигездә, аларда сакланган истәлекле язмаларга таянып эш иттем.

*2021*

## ӨМЕТ-ХЫЯЛЛАРГА ЮЛ АЧЫЛГАН ЧАКЛАР

*(Очерк)*

Борын-борын заманнардан бирле аерым һөнәр ияләре бер тирәдәрәк яшәргә, бергә булырга тырышкан. Ул бердәмлек аларга үз һөнәрләренең серләрен бергә-бергә камилләштерергә дә, җитештерелгән әйберләрен үзара бәяләп, товарга әйләндерергә дә ярдәм иткән. Борынгы шәһәр тирәләрендә тикшерү эшләрен башкарган археологлар безгә әледән-әле «бу торак урынының фәлән өлешендә – зәркәнчеләр, икенче бер өлешендә – күнчеләр, өченче урында корал ясаучы тимерчеләр яшәгән» дип хәбәр итеп торалар.

Ә менә язучылар – каләм осталары арасында элек андый артельләр оешмаган. Язучы һөнәре, башка һөнәрләрдән аермалы буларак, ялгызлыкны, япа-ялгыз калып иҗади хыялга бирелүне таләп итә. Әмма шул ук вакытта аңа, үз хөҗрәсенә бикләнеп, тыныч кына иҗат итеп ятсын өчен, андый шартларны тудыручылар да кирәк булган. Совет чоры әдибе бит алпавытлар заманындагы Пушкин да, Толстой да түгел. Ярый ла аларның көнкүрешен йөзләгән крепостной крәстиян тәэмин итеп торган…

Совет хакимияте хөкем сөрә башлаган егерменче елларда әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнгән Александр Серафимович, Алексей Толстой, Максим Горький кебек күренекле шәхесләр, көндәлек эш хакы алмыйча, киләчәк гонорар исәбенә өмет итеп кенә яшәгән язучыларның тормыш шартын җайга салуны истә тотып, аерым берләшмә булдыру фикеренә киләләр. Шул фикерне Совет хакимияте җитәкчеләренә җиткерәләр. Һәм 1932 елда шул хакта партия Үзәк комитеты махсус карар чыгара. Әлбәттә, бу очракта партия җитәкчеләренең үз мәнфәгатенә яраклы үз фикере дә була – иҗат кешеләрен бергә туплап, бер кысада тоту фикере. Шул рәвешле СССР Язучылар берлеген оештыру карары кабул ителә. (Соңрак башка иҗат оешмалары да берләшмәләргә берләштерелә.)

Татарстанда да язучыларның бердәм оешмасын нигезләү комиссиясе төзелә. Аның җитәкчеләре итеп ул вакытта Татарстан китап нәшриятында баш редактор вазифасын үтәгән Галимҗан

Нигъмәти, «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы Гаяз Ризванов (рәис) билгеләнәләр. Казанда урнашкан Татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары, 1926–1933 елларда татар телендә нәшер ителгән «Кызылармеец» газетасының җаваплы редакторы булган Кави Нәҗми дә шул комиссиянең актив бер вәкиле санала. 1934 елның 25–29 июль көннәрендә безнең төбәк язучыларының беренче корылтае уздырыла. Әлеге комиссия бу корылтайда Язучылар берлегенә 26 кешене әгъза, 9 кешене кандидат буларак кабул итү тәкъдиме белән чыга. Корылтай ул исемлекне хуплый. Халык шагыйре Равил Фәйзуллинның «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» (2004, 22 б.) китабында хәбәр ителгәнчә, кандидатлар исемлегендә Ш. Усманов, Т. Гыйззәт, А. Шамов, Н. Баян, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат кебек ярыйсы ук актив иҗат итүче яшьрәк буын шәхесләре теркәлгән. Кемнәндер ишетүемчә, Шәйхи Маннур да баштарак шул кандидатлар исемлегендә йөри. Шулай дип аталуга карамастан, аларның язучылык стажы да, матди ярдәм күрсәтүче Әдәби фонд оешмасына тулы хокуклы әгъза булып кабул ителү вакыты да I съезд үткән көннән саналган. Язучыларны оешмага кандидат буларак кабул итү тәртибе 1958 елда – РСФСР Язучылар берлеген оештыру съездында бетерелә. Шул карарга чаклы безнең Оешмада иң соңгы булып кабул ителгән кандидатлар Мәхмүт Хөсәен белән Рәисә Ишморатова иде. «Барыбер барлык мөмкинлекләрдән дә тигез файдаланалар», – дигән сылтау белән аларны тулы канлы әгъза итеп теркәү җитмешенче еллар урталарынача сузылды.

Шул ук вакытта без I корылтайда идарәгә сайланган 9 кешедән икесен – Вадим Краснов белән Кәшшаф Төхфәтуллинны белмибез диярлек. Краснов инде, башка милләт вәкиле буларак, соңрак үз республикасына күчеп киткәндер. Ул корылтайдан соңгы идарә утырышында оешма җитәкчесе – Язучылар берлегенең җаваплы секретаре итеп Кави Нәҗми, эш башкаручы сәркәтип буларак К. Төхфәтуллин сайлана. Беренче идарәчеләр исемлегенә тагын К. Тинчурин, Г. Гали, Х. Туфан, Г. Ризванов, Л. Гыйльми, Г. Толымбайскийлар кергән. Шул ук елның август аенда уздырылган СССР Язучылар союзының беренче съездында безнең оешмадан 12 делегат һәм шул чамада ук кунак катнаша. Ул зур корылтайда татар әдәбиятына багышлы ике нотык тыңлана (К. Нәҗми, К. Тинчурин). Корылтайда төп докладчы булган Максим Горький да татар әдәбияты вәкилләре уңышларын аерым билгеләп үтә.

Еш кына безнең кайбер истәлек язмаларында «фәлән язучы фәлән съездда, фәләне фәләненчесендә Язучылар берлеге җитәкчесе буларак сайланган» дип хата язалар. 1989 елда узган XI съездга чаклы бер генә җаваплы секретарь да, бер генә рәис тә корылтай барышында аерым бюллетень белән сайланмады. Элеккеге Берлек җитәкчеләренең барысы да корылтай барышында яшерен тавыш биреп сайланган идарә әгъзалары булды. Ә идарә-

нең беренче утырышында исә идарәгә керүчеләрнең берсен баш итеп сайлап куярлар иде.

1968 елның март ае урталары, VII съезд ачылырга бер-ике көн калган чак. «Өлкә комитетының яңа секретаре Морзаһит Вәлиев Сибгат ага Хәкимне рәислеккә күндергән икән», – дигән хәбәр булды. (Шул чорда Әдәби фонд директоры вазифасын үтәгәнлектән, ул корылтайның оештыру эшләрендә үзем дә актив катнаштым. Шуңа күрә ул вакыйгаларны яхшы хәтерлим.) Сибгат ага, – Татарстан тарихында өченче кеше буларак, 1960 елда ук Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган шәхес. Ил күләмендә танылып килүче шагыйрь. РСФСР Язучылар берлегендә штаттан тыш секретарь булып, җитәкчелек тәҗрибәсе алган зат. Шуңа күрә аның чираттагы рәислеккә сайланасын күпләр хуп күргән иде. Өстәвенә партия өлкә комитеты җитәкчелеге белән дә элемтәсе әйбәт икән. Дус-иш арасында шул хакта ул үзе дә: «Яңа секретарь Морзаһит Фәтхи улы белән без яхшы мөнәсәбәттә. Аның эш бүлмәсе тәрәзәләре безнең зал тәрәзәләренә карап тора. Вакыт-вакыт без тәрәзәне ачып та сөйләшеп алгалыйбыз», – дип әйткәләгән икән. Иҗади оешма җитәкчесенә республика башлыклары белән яхшы мөнәсәбәттә булу бик кирәк дигән фикер өстенлек итте ул көннәрдә язучылар арасында. Рәислеккә аның сайланасын хуплаучылар күпчелек иде кебек. Әхмәт ага Исхак кына: «Җәмәгате Мөршидә аңа анда утырырга рөхсәт бирмәс», – дигәнрәк фикер әйтте бугай. Корылтайдан соң уздырылган идарә утырышында Сибгат аганың җитәкче булудан баш тартканлыгы беленде. Берлек рәисе итеп икенче кандидат, урындагы партия оешмасының шул еллардагы актив вәкиле Ибраһим ага Гази сайланды. (Әйтергә кирәк, шуннан соң килгән рәисләрдән Туфан Миңнуллин белән Ринат Мөхәммәдиев тә әүвәл партия оешмасы секретаре вазифасын үтәгән шәхесләр булдылар. Ягъни кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе туплаган затлар.)

Татарстанда Язучылар берлегенең II корылтае 1950 елның июнь аенда уздырыла. Бу ике корылтай арасында Оешмада бик күп үзгәрешләр була. Шул еллар аралыгында Оешманы җитәкләүчеләр саны да уннан артып китә. Ул вазифага баштарак идарәгә сайланган язучыларны гына куярга тырышсалар да, соңрак ул тәртип тә үзгәртелә. Мәсәлән, 1937 елда Кави Нәҗми кулга алынгач, ул вазифаны берничәшәр айлап кына Ләбиб Гыйльми белән Мирсәй Әмир башкарган. 1938 елда тутырылган, Әдәби фонд оешмасы вәкиле Шәйхи Маннур кул куйган бер протоколда күрсәтелгәнчә, Язучылар оешмасында торучылар саны бермә-бер кимегән чор ул. Кемнәрдер кулга алынган, икенчеләре исә булачак сугыш вакыйгаларына бәйле хезмәткә җәлеп ителгән була. Шул елның ахырында Язучылар берлегенең яңа җитәкчесе итеп Муса Җәлил билгеләнә. Бер үк вакытта ул Опера театрында да үз эшен элеккечә башкарып килә. Язучылар берлегендә аның ярдәмчесе вазифасын башкару эше Афзал Ша-

мовка йөкләнә. Алар Муса белән бер чорда Мәскәү дәүләт университетында укыган каләмдәшләр бит. Дөрес, икесе дә I съездда идарәгә сайланмаган кешеләр. А. Шамов бер үк вакытта китап нәшриятында Матур әдәбият секторы мөхәррире вазифасын да үтәгән. Муса Җәлилнең 1940 елның декабренә чаклы эшләү дәверендә Берлектә рәсми теркәлгән язучылар саны бермә-бер арта диярлек. Актив җәмәгать эшлеклесе буларак, ул Язучылар берлегенең абруен күтәрә. Муса эшләгән чорда Берлеккә егермегә якын язучы әгъза буларак кабул ителә. Шул елларда язучылыгын раслаучы таныклык алучылар исемлегендә Н. Исәнбәт, Ә. Исхак, А. Алиш, М. Әблиев, Г. Кутуй, Гариф Галиев, Н. Дәүли, Г. Хуҗи, А. Әхмәт, Х. Госман, З. Солтан, С. Урайский, Г. Халит кебек шәхесләр бар. 1958 елга кадәр, РСФСР Язучылар берлеге барлыкка килгәнче, безнең оешма вәкилләрен Берлеккә кабул итү турыдан-туры СССР Язучылар союзында башкарылган. Муса Җәлил элек Мәскәү Язучылар оешмасының татарча язучылар секциясе җитәкчеләреннән берсе буларак, СССР оешмасы башлыклары белән дә якын элемтәдә торган. Чөнки Мәскәү оешмасы белән СССР Язучылар оешмасы җитәкчеләре бер үк бинада бергә эшлиләр. Ул еллардагы СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев белән Муса таныш булган. Менә шул хәлләр инде аның Казанда бик тә уңышлы эшләр башкаруына нык ярдәм итә. Шушы ук елларда ул шәхсән үзен һәм иҗатын югары бәяләгән, Оренбургта яшәү чорында ук беркадәр якыннан аралашкан олуг язучы Шәриф Камалны, иҗатының 30 еллыгын билгеләү тантанасы көннәренә атап, Ленин ордены белән бүләкләү эшен дә башлап җибәрә. (Минем архив кәгазьләре арасында Ш. Камалга шушы орденны бирү кирәклеген дәлилләп тутырылган бер язма караламасы саклана иде. Ул М. Җәлил тарафыннан язылган, анда аның култамгасы да бар.)

Бу чор вакыйгаларына озаклабрак тукталуымның сәбәбе шунда ки, моннан соң инде язучыларны Берлеккә кабул итү тәртибе нык үзгәрә. Сугыш елларында ул сан күп була алмый. Ә инде сугыштан соң, бигрәк тә 1958–1990 еллар аралыгында, аларны җиз иләктән үткәреп кенә кабул итә башлыйлар. Чөнки элекке ике оешма, ике Союз арасында РСФСР Язучылар берлеге дә калкып чыга, хәл бик тә катлаулана. РСФСР Язучылар берләшмәсе берзаман безнең оешмадан елына 3–4 тән дә артык кешене кабул итмәү тәртибен куйган иде. Һәм ул тәртип СССР таркалган дәвергәчә сакланды.

* * *

ВКП(б) Үзәк комитетының әлеге «О перестройке литературно-художественных организаций» дип кабул ителгән 1932 елгы карарының иң зур әһәмияте шунда ки, аның нигезендә язучыларның көндәлек тормышын кайгырту кирәклеге дә искә алын-

ган була. Һәм СССР язучыларының I съездында ук язучыларга һәм гаиләләренә яшәү шартларын яхшырту өчен аерым вакыф-фонд оештыру кирәклеге дә карала. Корылтайга чыгарылганчы ук инде, ул тәкъдим-карарлар тиешле дәүләт оешмаларында тикшерелгән, каралган була. Һәм шул нигездә СССР Язучылар берлегенең уставы белән бергә раслана. Ягъни булачак Әдәби фонд оешмасының төп керем нигезләре һәм чыгым юнәлешләре 1934 елның август көннәрендә билгеләнә. Ул фондтан куллану инструкциясе эшләнә.

Бүгенге ярым капитализм, ярым феодализм чорына кереп баручы каләм әһелләренең исенә төшерү өчен генә булса да, ул Уставта һәм кулланма өстәмәдә теркәлгән кайбер пунктларга күз төшереп үтәсе килә. Шуларның 1 нче пунктында язылган сүзләргә тукталыйк (тулы дөреслек өчен русча вариантын китерәм): «На основании Устава, утверждённого правительством СССР, Литфонд СССР оказывает своим членам и их семьям материально-бытовую и иную помощь». Шуннан соң инде кемгә нинди ярдәмнәр тиешлеге санап чыгыла. Анда гаиләләргә квартира шартларын яхшыртуга булышлык итү, авырып киткән язучыга яисә аның карамагында яшәгән гаилә вәкиленә медицина ярдәме күрсәтүдә булышу, хезмәт хакы алып эшләмәгән язучыга авырган көннәре өчен күпмедер күләмдә акча түләү, иҗат барышында нindидер мәгълүматны ачыкларга кирәк булган очракта иҗади командировкалар оештыру, сәламәтлекне саклау өчен санаторияләргә юлламалар алу, елына бер-ике мәртәбә махсус иҗат йортларына барып эшләү мөмкинлекләрен тудыру кебек чаралар каралган. Күләмле әсәр иҗат итәргә керешкән язучыга вакытлыча ссуда алып тору мөмкинлеге дә тудырылган. Шул исәптән вафат булган язучы гаиләсенә беркадәр ярдәм итү һәм башлап язучыларга акчалата өлеш чыгару пунктлары да каралган иде анда.

Ягъни Язучылар берлеге карамагында оештырылган әлеге Әдәби фондның төп бурычы язучының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, сәламәтлеген саклау, иҗат итү мөмкинлекләрен тудыру һәм иҗтимагый-сәяси вә иҗади белемен үстерүгә булышлык итәрдәй чаралар күрү булды. Язучылар оешмалары карамагындагы клублар, шул исәптән Мәскәүдәге атаклы Үзәк язучылар йорты (ЦДЛ), китапханәләр, М. Горький исемендәге әдәбият институты (Мәскәү), аның карамагында эшләүче ике еллык Югары әдәби курслар, даими рәвештә үткәрелеп килә торган төрле-төрле айлык әдәби конференцияләр бер яки ике еллык семинарлар, курслар – Совет хакимияте елларында барысы да шул Әдәби фонд кереме исәбенә яшәделәр. Сугыштан соңгы елларда шул ук фонд исәбенә СССР Язучылар берлеге карамагында махсус комиссия оештырыла. Аның төп максаты чит илләрдәге Язучылар оешмалары белән арадашлык элемтәләрен җайлау һәм чит илләргә командировкалар оештыру була. Безнең Берлек вәкил-

ләреннән дә кайберәүләр шул комиссиянең матди ярдәме белән чит-ят дөньяларны күреп кайткалады. Ш. Маннур, С. Хәким, Р. Мостафин, Әминә һәм Чулпан Җәлиловалар берничә мәртәбә Берлинда булдылар. Күргән-белгәннәрен Муса Җәлилгә багышлы әсәрләрендә яисә истәлекләрендә кулландылар. Г. Минский, З. Мансуров, Р. Кутуй һәм аның әнисе Галимә апа Польшада булдылар. Р. Кутуй, Галимә апа, Г. Кутуйның яшьлек дусты Г. Минский анда берничә мәртәбә барып, Гадел Кутуй каберенә чәчәкләр куеп кайттылар. «Сызгыра торган уклар» романын язар алдыннан Нурихан Фәттах Монголиягә барды, анда бер ай чамасы йөреп, ерак бабаларыбыз яшәгән урыннарны күреп кайтты.

Язучылар берлеге оешуның беренче көннәреннән үк, бөтен ил күләмендә төрле-төрле иҗат йортлары барлыкка китерелә. Анда һәр язучыга яисә гаиләсенә аерым бүлмә бирелә, иҗади эш белән мавыгу һәм ял итү мөмкинлекләре тудырыла. Медицина ярдәме оештырыла. Олырак яшьтәгеләр яисә сырхаулабрак йөрүче язучылар өчен табиблар даими күзәтеп торырдай махсус берничә иҗат йорты да бар иде. Безнең язучылар шуларның Мәскәү тирәсендәге «Малеевка» яисә Латвиядәге – Балтыйк диңгезе буендагы «Дубулты» дигәннәренә аеруча яратып баралар иде. Г. Бәширов, Х. Туфан, Ә. Еники, А. Гыйләҗев һ. б. кайберәүләр «кыш айларында нәкъ шундый иҗат йортларында эшләү безгә килешә» дип әйтерләр иде.

Сугышка чаклы Татарстан биләмәсендә дә бер кечерәк күләмле – уналты язучыга исәпләнгән иҗат йорты эшләп алган. Аның элеккеге директоры Лихтентул фамилияле абзый белән миңа Мәскәүдә берничә мәртәбә очрашырга туры килде. 1960–1970 елларда ул СССР Язучылар берлегендә комендант вазифасын үти иде. Ул иҗат йорты безнең Тәтеш шәһәре янәшәсендәге алпавыт Молостсовлар утарында оештырылган була. Сугыш башлангач, 1941 елның көзендә, анда яралыларны савыктыру бүлеге ачыла. Сугыштан соң әлеге иҗат йорты эшләми. Безнең язучылардан ул иҗат йортында Ә. Исхак, М. Садрилар берәр ай чамасы торып, иҗат белән шөгыльләнгән. Мөхәммәт аганың андагы тәртипне һәм ашау-эчүнең муллыгын искә алып сөйләгәне дә булды. Ул иҗат йортына төрле республика һәм өлкәләрдән дә язучылар кабул ителгән. Дөресрәге, Иделгә якын урында урнашкан ул иҗат йортына килүчеләрнең саны күп булган.

Хәзер серле оешма буларак күзалланган ул Әдәби фонд нинди керем исәбенә яшәгән соң? Әйе, бу фондка тупланасы акча язучыларның «иҗат җимеше»н, ягъни язган әсәрләрен товарга әйләндерүче оешмалар – китап нәшриятлары, газета-журнал редакцияләре, театрлар, концерт заллары исәбенә тулыландырылды. Алар кеременең бер өлеше исәбенә яшәде ул оешма.

Нәшриятлар әдәби хезмәттән файдаланган керемнең ун процент чамасын, концерт заллары һәм театрлар исә 2–2,5 процент чамасын түләп тордылар. Ул керемнең билгеле бер өлеше шулай

ук күптәннән вафат булган классик әдипләрнең әсәрләрен кат-кат чыгарудан да керә иде. Шуңа күрә нәшриятлар элек андый әсәрләрне даими рәвештә нәшер итәргә тырыштылар.

Хәзер, Гайдар, Чубайслар оештырган капитализм заманына кире кайткач, инде без андый фонд тотудан мәхрүм ителдек. Шул ук фонд исәбенә элеккеге елларда язучылар кабере өстенә истәлек ташы кую өчен дә күпмедер күләмдә акча бүлеп бирелде. Шул заман өчен ул бик аз да түгел иде. 400—500 сумнан артмаган кабер ташын кую карарын урындагы Язучылар берлеге идарәсе хәл итә, 1000 сум тирәсенә җиткәннәренә Мәскәү рөхсәт бирә иде. Мин белгән дәвердә бездә СССР берлеге идарәсе карары белән андый ике кабер ташы куелды: Казандагы Архангель зиратында Галимҗан Ибраһимов кабере дип чамаланган урында һәм Алабуга шәһәрендә Марина Цветаева каберенә. Соңгы кабер ташын кую рөхсәтен безнең идарә сорамаган иде. Аны куюны безгә Мәскәү үзе кушты.

Фатир белән тәэмин ителү мәсьәләләренә дә бераз тукталып үтик. Әдәби фонд оешмасы тернәкләнә төшкәч, илленче еллардан башлап, турыдан-туры сугыш афәтен кичермәгән төбәк оешмаларына да фатир булдыру өчен акча бүленеп бирелә башлый. Белүемчә, Татарстан Язучылар берлегенә күпмедер күләмдә шул максатка каралган акча 1950 еллар ахырында бүлеп бирелә. Гомәр ага Бәширов Язучылар берлеге рәисе вазифасын үтәгән һәм берүк вакытта СССР Язучылар берлеге секретаре булып торган елларда була бу хәл. Әдәби фонд акчасы һәм 1957 елда Мәскәүдә узачак Татар мәдәнияте декадасы көннәренә бәйле рәвештә Татарстан хөкүмәте карары белән шул ук максатка бүлеп бирелгән акча исәбенә 1959 елда сигез язучы Маяковский урамында төзелгән яңа йорттан яхшы фатирлар ала. Заманасы өчен бик затлы саналган ул йортта өй туйлары үткәрүчеләр исемлегендә Г. Бәширов, М. Әмир, А. Шамов, Х. Туфан, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Ә. Исхак, Т. Журавлёв гаиләләре теркәлгән.

Әдәби фонд оешмасының Татарстан бүлеге 1934 елдан эшли. Бүлекчәнең Хәсән Сарьянга чаклы (1964—1965) эшләүче җитәкчеләренең Мәскәү оешмасы белән элемтәсе чамалы була. 1965 елда Х. Сарьян Мәскәү таләп иткән документларны һәм Язучылар берлеге рәисе, РСФСР Югары Советы рәисе урынбасары Мирсәй Әмир язган үтенеч хатын Әдәби фондка тапшырып, фатирлар булдыру өчен тагын күпмедер акча алуга ирешә. Казан шәһәре башкарма комитеты счётына ул акча 1966 елда ук кергән булса да, элеккеге бүлекчә директорының эштән китүе, аны алыштырган М. Шәрифуллинның шул елда ук авырып вафат булуы сәбәпле, ул фатирларның очына чыгучы булмый. Ул эш минем өлешкә калган иде. Әдәби фонд бүлекчәсе директоры вазифаларын мин 1967 елның апреленнән алып 1983 елның апреленә чаклы башкардым. Һәм шул чорда Әдәби фонд исәбенә алынган фатирлар да шәһәр башкарма комитеты карамагына

элек күчерелгән акчаларның эзенә төшүдән башланды. Элек шәһәр башкарма комитетына буйсынган бер оешмада эшләгәнлектән, аның план, төзелеш бүлекләре, фатирларның исәп-хисабын алып баручы оешма кешеләре белән бераз танышлык та бар иде. Шул сәбәпле миңа һәр ике ел саен диярлек Мәскәү фонды таләп иткән ундүртәр имзалы, ундүрт мөһерле документларны тутырып илтеп бирү бер гадәткә әйләнде. Язучылар берлеге рәисләре И. Гази, З. Нури, Г. Ахуновларның да тырышлыгы белән безнең оешма әлеге еллар аралыгында язучыларыбызга йөздән артыграк фатир алуга иреште. Билгеле, алынган фатирларның барысы да яңа түгел иде. 1948 елда И. Сталин кул куйган указга нигезләнеп, без язучы гаиләләреннән бушаган «иске» фатирларны да кабат үзебездә калдыра алдык. Әдәби фонд вәкилләре ул указның күчермәсен миңа СССР Язучылары идарәсе архивыннан табып биргән иде.

Язучыларга фатирлар алу өчен СССР Әдәби фонды тарафыннан безнең оешмага бүлеп бирелгән соңгы акча 1983 елга карый. Минем соңгы мәртәбә йөреп алган хезмәт җимешем. Шуннан соң бездә андый мәшәкатьле эш белән шөгыльләнүче булмады. Дөрес, Туфан Миңнуллин рәис булган дәвердә СССР Әдәби фонды безгә Васильево шифаханәсе биләмәсендә бер иске йортны сатып алу өчен шактый зур суммада акча бүлеп биргән иде. Ләкин андый йорт сатып алынмыйча калды. Оешмабыз «үз санаториен» булдыра алмады. Дөрес, бу мәсьәлә Г. Ахунов Язучылар берлеге идарәсе рәисе һәм СССР Югары Советы депутаты булган елларда ук кузгатылган иде. Без аның белән Васильевога барып, шифаханәнең баш врачы Цыпленков белән киләчәктә сүтелергә билгеләнгән берничә йортны карап та йөргән идек. Ләкин мин эшләгәндә, ул эшне башкарып чыгып булмады. Бездән соң эшләүчеләр дә аның очына чыга алмады. Элек без карап, сайлап йөргән ул бер катлы биналарның берсендә хәзер Г. Камал театры артистлары өчен дип алынган ял йорты эшли.

Кайбер каләмдәшләр миннән: «Нишләп пенсия яшенә җитмичә Әдәби фонд оешмасыннан киттең?» – дип сорыйлар. Әдәбият институты карамагындагы ике еллык Әдәби курсларга безнең оешмадан ике елга бер мәртәбә бер-ике кеше кабул ителә иде. 1983 елда шул курсларны Ризван Хәмид тәмамлап кайтасы, алмашка башка кешеләр җибәреләсе иде. Минем күңелдә дә шунда барып уку хыялы яшәде. Язучылар берлеге миңа шул курсларга керү өчен юллама бирде. Үз гаризам белән бергә мин аны Мәскәүгә илтеп тапшырдым. Дөресрәге, ректоратка без аны Ризван белән бергә кертеп бирдек. Ә август ахырларында тегеннән хат килә: сезгә 50 яшь тулып, фәлән ай киткән. Без 50 яшькәчә генә кабул итәбез, диелгән. Хыялым чәлпәрәмә килсә дә бик артык борчылмадым – гаиләм, ике балам янында калуны барыбыз да хупладык…

* * *

Язучылар берлеге карамагында соңлабрак оешкан тагын бер бүлекчә хакында әйтмичә үтү мөмкин түгел. «Пропаганда бюросы» исеме белән аталган ул оешма да заманында бик тә кирәкле эшләр башкарды. Аның төп бурычы әдәбиятны халык күңеленә якынайту чараларын күрүдән гыйбарәт иде. Әдәбиятны сөючеләр белән очрашулар-кичәләр оештыру, язучыларны мәктәпләргә алып бару, мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында әдәби бәйгеләр уздыру кебек эшләрне башкарырга тиеш иде ул бюро. Мәктәпләрдәге очрашулардан кала барлык чаралар да түләүле булганлыктан, язучылар белән бергә ул очрашуларда кайбер артистлар һәм композиторлар да бик теләп катнашалар иде. Бигрәк тә яшьрәк буын иҗат вәкилләрен ул чараларда катнашуның түләүле булуы да кызыктыра иде, билгеле. Һәр яз саен шәһәр күләмендә, шәһәрдә урнашкан күпчелек завод-фабрикаларда «Әдәби Казан язлары» бәйрәмен уздыру гадәткә кергән иде. Авыл һәм районнарда андый очрашулар ел дәвамында үткәрелеп килде. Күрше республикаларда яшәүче милләттәшләр белән аралашу чаралары да үткәрелә иде.

Хәтерем ялгышмаса, ул бюро бездә рәсми рәвештә 1967 ел башында оешты шикелле. 1967 елда Язучылар берлегендә мин эшли башлаганда, ул Бюроның җитәкчесе Туфан Миңнуллин иде. Ләкин шул көздә үк ул аннан китте. Аңардан соң ул вазифаны ярты ел чамасы Гөлшат Зәйнашева башкарып торды. Ә 1968 елның урталарыннан башлап инде анда биш-алты еллап бюро директоры вазифасын үтәргә алынган кешеләр килде: шагыйрь Мөнип Газар-Шәймөхәммәтев, шагыйрьлеген күпертеп күрсәтергә яратмаган Эльс Гаделев, шагыйрь Хәкимҗан Халиков. Бюро штаты өч кешедән тора иде: директор, әдәби хезмәткәр һәм бухгалтер. Соңгы вазифаны алыштыргысыз рәвештә егерме ел чамасы Дания Хәмидуллина башкарды. Ә менә әдәби хезмәткәрләр шактый еш алышынып тордылар. Озаграк эшләп, хәтердә калганнары Фәннүр Сафин, Мансур Шиһапов, Нурислам Хәсәнов, Марсель Галиев. Нәкъ алар һәм директорлары инде төркем-төркем язучыларны ияртеп заводтан заводка, районнан районга, авылдан авылга йөртүчеләр. Ә Марсель Галиев тагын «Әдәби Казан язлары»н оста оештыручы буларак та танылды шикелле. Совет хакимияте тәртипләре юкка чыгарга биш-алты ел кала чын-чынлап эш күрсәткән ул бюроның соңгы директоры язучы Рәфкать Кәрами булды.

Совет хакимияте дәверендә татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырып, зур уңышларга ирешкән иҗат әһелләребез бик ишле. Күңел түрендә балкып истә калучылардан мин бүген Һ. Такташ, М. Җәлил, Ш. Камал, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, Т. Гыйззәт, М. Әмир, Г. Бәширов, А. Шамов, И. Гази, Ә. Еники, Ф. Хөсни, С. Хәким, З. Нури, Г. Ахунов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев,

М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Г. Рәхим һ. б. бик күп исемнәрне атап үтәр идем. Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Ләбиб Лероннарның Россия капитализмы чорына кергәч тә, Әдәби фонд оешмасының Татарстан бүлеген торгызырга тырышып йөргәнлекләрен хәтерлим. Ләкин әлегә андый уңышка ирешелмәде. Бәлки, киләчәктә элеккеге Әдәби фондка тартымрак бер оешманы киләчәк буын вәкилләре тормышка ашыра алыр дигән өметтә калам.

*2019*

# ҖӘЛИЛ ҺӘМ ҖӘЛИЛЧЕЛӘРГӘ БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР

Сугыш башланган көннәр, сугышка багышланган вакыйгалар турында телевизион экраннардан күпсанлы тапшыруларны карап утыргач, элек укылган кайбер язмалар да хәтердә яңарды. Эшләнергә тиеш булып та, эшләнмәгән эшләр дә искә төште. Шуларны кабат искә төшереп үтәсе килә. Ул язмаларда тасвирланган хәлләргә әлегәчә төгәл генә җавап бирелмәде бит. Анда тасвирланган вакыйгаларны кабат искә төшерсәң, бәлки, үзебезнең сугыш чорына бәйле музей хезмәткәрләре берәр төрле чара күрмәсме икән дигән өмет тә яши күңелдә. Аларга башкалада урнашкан төрле архивлар белән элемтә урнаштыру мөмкинлекләре тудырылгандыр, шәт. Музей хезмәткәрләренең андый оешмаларга мөрәҗәгать итәрдәй хокуклары бардыр дип беләм.

1943 елның җәендә Белгород, Орёл, Курск тирәләрендәге сугышта Кызыл Армия зур җиңүгә иреште. «Курск дугасындагы җиңү» вакыйгаларында Татарстанның да өлеше зур дигәнне аңлаткандай, ул төбәктә ун ел дәвамында кабыргасына «Колхозник Татарии» дип язылган танк һәйкәле торды. 1954 ел ахырларында гына әлеге тамгалысы урынына язусыз Т-34 танкын утыртып куйдылар. Безнең буын вәкилләре 1951—1954 елларда армиядә хезмәт иткәндә, кинохроника тапшыруларында ул «Колхозник Татарии» һәйкәлен бик еш күрсәтәләр иде. Шул һәйкәлнең зурлап төшерелгән рәсемен һәм әлеге кинохроника лентасының копиясен әлеге музей вәкилләре күптән тапкан һәм кулланган булырга тиеш иде. Ә алар анда юк.

1943 елның февралендә немецлар татар-башкорт әсирләреннән оештырылган 825 нче хәрби батальонны Белоруссиянең Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизан отрядларына каршы сугышу өчен җибәрәләр. Бу батальонга тупланган легионерлар арасында җәлилчеләр оештырган яшерен төркем йогынтысы бик көчле була. Витебск шәһәре тирәсенә килеп урнашуга ук, батальонның

яшерен оешма вәкилләре партизаннар белән элемтәгә керәләр. Һәм 22 февральдә, немец офицерларының кайберләрен юк итеп, ул батальон сугышчылары М. Ф. Бирюлов җитәкчелегендәге партизаннар бригадасына килеп кушыла. Шул хакта 1974 елда Минскида нәшер ителгән «Витебское подполье» китабында шактый тулы мәгълүмат бар. Шушы вакыйгага багышланган тагын да тулырак һәм күләмлерәк очерк Алма-Атада рус телендә нәшер ителгән «Простор» журналында аңа чаклы ук та басылган иде. 1974 елда шул шәһәрдә булганда, казах язучылары миңа ул журналның берничә санын биреп тә җибәрделәр. 1966–1968 еллар аралыгында чыккан ул саннарның берсендә (1968, № 4, 5) татар-башкорт легионерлары сугышчыларының партизаннар ягына чыгу вакыйгалары бәян ителә. Калган ике санда элек Власовчылар армиясенә кергән Гиль-Родионов дивизиясенең шул ук «Железняк» исемен йөртүче партизаннар бригадасына кушылу вакыйгалары тасвирлана. Бу «Выбор оружия» дигән документаль хезмәтләрнең авторы Иван Титков үзен «Железняк» бригадасы командирларының берсе дип таныта.

22 февраль төнендә көнбатыш Двина бозы аша чыгучы сигез йөзләп татар-башкорт легионерларын каршы алган отряд башлыгы да мин идем, дип яза Иван Титков әлеге легионга багышлы очеркында. Легионерларның күпчелеге соңыннан безнең отрядта дошманга каршы батырларча сугышып һәлак булдылар. Яу-бәрелешләр барышында без аларны, ышанып, алга сафка куя идек, дип яза ул. Шул батырларның дистәләгәненең исем-фамилиясен дә атап үтә. Журналның бер санында урнаштырылган биш кешелек фотода автор да бар. Фото астына «Командование бригады «Железняк». Слева с биноклем автор записок, рядом с автоматом Степан Манкович» дип язылган.

Журналның 825 нче батальонга багышланган санын мин Р. Мостафинга шул вакытларда ук биргән идем. Соңрак ул аны миңа кайтарып та биргән иде. Ләкин хәзер нишләптер ул санны үземдә таба алмадым. Гиль-Родионов дивизиясенә багышланган саннар бар. Казан китапханәләрендә дә шул елларга караган «Простор» журналы табылмады.

Легионерларның 825 нче батальонына багышланган вакыйгаларның шушы мәкаләгә кагылышлы дәвамы да бар. 1983 елның кышында Мәскәү янәшәсендәге иҗат йортында язучы Леонид Леонтьевич Огневский белән очраштык. Дөресрәге, Казаннан булуымны Мостай ага Кәримовтан ишетеп белгәч, ул үзе мине бүлмәсенә чакырып алды. «Сугыш елларында мин Мәскәүдә СМЕРШ штабында хезмәт иттем. Хәрби дәрәҗәмне әйтеп тормыйм, үз фамилиям Огнев минем, «ский» кушымчасын язучы буларак кына йөртәм», – диде. СМЕРШ оешмасы инде ул шул ук КГБның хәрби адашы, бертуганы дигәндәй. Дошманга каршы да, үз гаскәриләребез арасында да шымчылык эшен оештыручы, яшерен рәвештә «ил сагында» торучы оешма. 825 нче батальон

партизаннар ягына чыгу белән үк, Мәскәүдән берничә офицер партизаннар бригадасына җибәрелә. Алар арасында Огнев та була. «Тикшерү документларының байтагы минем кул белән язылган. Шул исәптән сигез йөзләп фамилия теркәлгән исемлекне дә ике данәдә мин тутырдым», – диде ул. Шул кәгазьләр белән бергә легионерлардан алынган мәгълүматны да, алар кулындагы башка төрле язмаларны һәм хатларны да алар Мәскәүгә кайтарып тапшыралар. Әлбәттә, ул хатлар адресатларына җибәрелми. «Ул документлар югалмаска тиеш. Алар безнең штаб архивында сакланырга тиешләр. Тырышып эзләсәгез, бәлки, шуларны таба алырсыз. Менә шул хакта белдерәсем килгән иде. Минем «Грозный час истории» китабымда да шуңа охшаш вакыйгалар теркәлгән. Хәзер ул китап үземдә юк. Кызыксынсагыз, китапханәдән табып, карап чыга аласыз. Дөрес, анда хәзер мин сөйләгән вакыйга теркәлмәгән», – дигән иде Иркутск шәһәреннән килгән ул язучы.

Казанга кайткач, мин ул язучы сөйләгәннәрне кайбер иптәшләргә, шул исәптән Р. Мостафинга да хәбәр иттем. Сигез йөзләп легионер кулыннан алынган язмалар арасында Муса Җәлилгә яисә аның көрәштәшләренә мөнәсәбәтлеләренең дә булу ихтималы бар ич. Ләкин әле 1980 елларда СМЕРШ ише оешма архивларына керү мөмкинлекләре юк иде. Хәзер, бәлки, ул архив белән дә танышып буладыр. Анда башка төр яңалыкка тап булмасаң да, сигез йөзләп легионерның тулы исемлеген ачыклау мөмкинлеге бар ич. Аларның күпчелеге әле дә бит «хәбәрсез югалучы»лар исемлегендә йөридер. Шул язмаларны эзләп табуны кем үз өстенә ала алыр икән? Ә Иван Титковның «Простор»да чыккан язмасын эзләүне үз өстемә алам. Мин ул журналның шушы вакыйганы чагылдырган өлешен туксанынчы елларда ук Тел һәм әдәбият институты архивына тапшырган идем шикелле.

Муса Җәлил мирасын барлауга бәйле тагын бер фактка тукталасым килә. 1989 елның кыш ахырлары иде шикелле. Шәмси ага Хамматов, Татарстан китап нәшриятына бер килүендә, минем эш бүлмәмә дә кереп утырды. Мусаның туганнан туган энесе Таһир ага Корбанов аңа минем Оренбург төбәге кешеләре белән элемтә тотуым, андагы архивлар белән беркадәр таныш булуым хакында әйткән булган икән. «Муса Җәлилгә бәйле материаллар туплау өчен Оренбургка барырга ниятләп торам. Анда кайда, нәрсәләр булырга мөмкин? 1935–1940 елларда анда чыккан «Коммунист» газетасы төпләмәләре кайларда саклана икән?» – дип сорашты Шәмси ага. Өлкәнең дәүләт архивында һәм өлкә карамагындагы китапханәләрдә 1920–1930 еллардагы татар матбугатының бик сирәк саннары гына сакланганлыгын сөйләдем. 1925 елларгача Оренбургта нәшер ителгән барлык татар телле матбугатның архивы Казахстан хөкүмәте тарафыннан Кызыл Урда шәһәренә күчерелгән булуын әйттем. Дәүләт архивында «Коммунист» газетасының берничә саны сакланганын миңа шул газетаның элекке хезмәткәре, шагыйрь Фатих ага Кыргызбаев сөйләгән иде. Ул

архивтагы саннарның берсе В. И. Ленинга багышлап чыгарылганы икән. Ул санда Муса Җәлил белән Фатих Кәримнең үз шигырьләре дә, русчадан тәрҗемәләре дә басылып чыккан дип белдергән иде Фатих ага. «Коммунист»ның тулырак нөсхәләре өлкәнең партия карамагындагы архивында саклану ихтималы турында да сүз булды. Минем ул архивта булганым юк иде. Мин шуларны Шәмси агага сөйләп бирдем.

Берәр айдан соң Шәмси ага яңадан мин эшләгән бүлмәгә килеп керде. Элекке киңәшләрем өчен кабат рәхмәтләр әйтте. Сәфәренең уңышлы булуын, латин шрифтында нәшер ителгән әлеге газета нөсхәләре белән таныша алганлыгын белдерде. «Табышларым күп булды. Сәфәрем уңышлы узды. Инде шул табышлар турында язып чыгарга ниятлим», – дигән иде ул. Ләкин авыруы аңа ул ниятен тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде бугай. Озакламыйча ул арабыздан бөтенләйгә китеп барды. Аның архивы, соңгы сәяхәте турында яза башлаган язмалары улы Шамил белән килене Эльмира кулында калгандыр дип уйлыйм. Мин күреп, укып барган газета, журнал битләрендә Шәмси аганың яман чирне җиңеп кылган ул изге сәяхәте турында бернинди дә мәгълүмат булмады шикелле. Шәмси аганың ул табышлары белән дә киң җәмәгатьчелек таныштырга хаклыдыр дип беләм... Муса Җәлил эшчәнлегенә багышлап берничә китап язган автор да ич әле ул. Шәмси ага архивында шулай ук Мусаның 1923 елда язган, үз авылында мәктәп балалары белән бергә сәхнәләштергән «Кала малае» пьесасы кульязмасы да саклана иде. Ул пьесаны аңа Мусаның туганнан туган энесе Таһир ага Корбанов биргән була. Без ул әсәрнең бер өлешен Таһир аганың М. Җәлилгә багышланган «Кызыл чәчәкләр» китабына да урнаштырган идек.

«Республика Татарстан» газетасының 1997 елгы 15 февраль санында Борис Перельмутер дигән журналистның истәлекләре басылып чыккан иде. Хәбәр итүенчә, сугышка чаклы алар Муса Җәлил белән дустанә мөнәсәбәттә булганнар. Бауман урамындагы Матбугат йорты бүлмә-коридорларында еш очрашып торганнар. Чөнки ул вакытта Муса Җәлил, Опера театрында башкарган вазифасыннан тыш, язучылар оешмасының да җитәкчесе була бит. Аңа эш көненең бер өлешен шул Матбугат йортындагы эш урынында да уздырырга туры килгән. «Безнең өйдә дә булгалый идек. Әнием Хана пешергән өчпочмак Мусага бик ошый иде», – дип искә ала журналист. «Яу кырыннан Гази Кашшафка җибәргән хатларының берсендә Муса русча «Баллада о последнем патроне» шигырен язганлыгын хәбәр иткән була». Муса Җәлилнең шигырьләре кабат басыла башлагач, Гази ага Кашшаф, шул хатны тотып, Борис Перельмутер янына килә. «Сугыш елларында шушындый әсәр сезнең газета редакциясенә килмәдеме икән?» – дип сорый. Борис: «Андый очракны хәтерләмим» дип әйткән идем мин аңа», – ди. Бәлки, ул шигырь дә Муса хезмәт

иткән «Отвага» газетасында яисә 2 нче армиянең башка газетасында басылып чыккандыр – мөгаен, әлегә чаклы аларны санын санга актарып чыгучы булмагандыр дип уйлыйм.

Эзлисе, табасы табышлар алда әле дигән өмет белән бүгенге язмамны тәмамлыйсы килә.

*2014*

# ЭЗЛӘНҮЧӘН, ТЫРЫШ ГАЛИМ ИДЕ

*(Очерк)*

Россия күләмендә танылган, фәннең төрле тармагында эшләүче, рәсми дәрәҗәләр алган галимнәребез күп хәзер, Аллага шөкер. Бөтендөнья мәйданында фән өлкәсендә шөһрәт казанган шәхесләребез дә аз түгел. Узган елларның берсендә, нindidер бер корылтайда катнашкан, төрле-төрле илләрдән килгән кунаклар арасында да ике-өч дистәгә якын югары дәрәҗәле галимебезнең булуы сөендергән иде. Шундый ук корылтайларның берсендә катнашкан бер яшьрәк галим (дөресрәге, фән өлкәсендә яңарак күренә башлаган берәү), патша хакимияте дәверендә Россиядә татарлардан биш-алты гына кеше университетта белем алып чыккан дип тә белдерде. Бу галим әлеге сан мәсьәләсендә бераз хаталанса да, нигездә, хак сүз әйтте кебек – элеккерәк заманнарда «мөселман татар» баласы югары уку йортларына керү турында сирәгрәк хыялланган шул. Чөнки ул хыялга ирешү алдында торган киртәләр күп булган. Дингә бәйле киртә дә, матди киртә дә башлыча авыл мохитендә яшәгән милләттәшләребез өчен ерып чыга алмаслык хәл булган.

Әйе, үз чорына күрә укымышлы мөселманнар ишле генә саналган Казанда ачылган университетта да 1830 елга чаклы «христиан динендә булмаганнар кабул ителми» дигән тәртип яшәгән шул. Рус монархиясе чорында шундый ук тәртип Россиянең башка уку йортларында, башка диндәгеләргә карата да гамәлдә була. Аеруча мөселман белән яһүдиләрне кыерсытканнар. Мәсәлән, 1989 елда башкалабыз Мәскәүдә язучылар җыенында таралган бер язма хәбәрдән язучы А. Солженицынның бабасына кагылышлы мисал искә төшә. 1865 елда Харьков университетына керер алдыннан, ул яһүди диненнән ваз кичәргә, православие динен кабул итәргә мәҗбүр булган икән. Ләкин, әлеге язма хәбәрдә бәян ителүенчә, үз диненнән дә ул бөтенләй үк читләшмәскә тырышкан, имеш. Балалары да, тыштан гына яңа дин таләпләрен үтәгән кебек булсалар да, нигездә, иске дин кагыйдәләрен дә тәмам онытып бетермәгәннәр, диелгән иде әлеге язмада.

1830 елда Казан округы мәгариф идарәсе башлыгы итеп граф М. Н. Мусин-Пушкин билгеләнә. Яшь ректор Н. И. Лобачевский белән алар университетка һәм Казан гимназиясенә кабул ителүчеләрне дини карашка бәйле чикләүдән азат итү кирәклеге карарына киләләр. Һәм шул еллардан башлап Казан университетында «чабаталы морза» белән укымышлы мулла балаларына да уку иреге бирелә. Ә элегрәк елларда исә анда динен алыштырган берничә милләттәшебезнең укыганлыгы гына мәгълүм. Мәсәлән, соңрак рус шагыйре буларак танылган Лев Ибраһимов Казан гимназиясеннән соң укуын шунда дәвам иттерә. Әлеге гимназиядә аның атасы, рус халык җырлары рәтендә йөргән җырлар авторы Николай Мисаил улы да укыткан. Аның шәкерте, күренекле рус язучысы Сергей Аксаков соңрак әлеге укытучысы турында: «Фамилиясе һәм тышкы кыяфәте үк аның татармы яисә башкортмы икәнлеген белгертеп тора иде», – дип язачак. Димәк, башка дингә күчкән бу кешеләрне дә без татар милләтеннән бөтенләй үк читләштереп карый алмыйбыздыр.

Язучы һәм үзешчән галим Исмәгыйль ага Рәмиев ачыклавынча, 1830–1855 елларда ук Казан университетына 28 татар һәм башкорт баласы кабул ителгән, аларның күпчелеге филолог, юрист яки табиб дипломы алып чыккан. (Шул төркемнән күпчелегебезгә билгеле шәхесләрдән Салихҗан Кукляшев, Мөхәммәтзариф Сыртланов, Шаһингәрәй Хәлфин исемнәрен атап китәргә була.) 1855–1904 еллар аралыгында исә татарлардан Россиядәге югары уку йортларын тәмамлаучылар саны өчләтә-дүртләтә күбрәк була. XIX йөз урталарыннан хатын-кызлар арасында да югары белемгә ирешүчеләр күренгәли башлый. Ә шул гасырның башында ук, татар хатын-кызларыннан иң беренчеләрдән булып, С.-Петербургтагы төпле белем бирүче Югары курсларда укучылар арасында Үзәк Россия һәм Себер төбәге мөселманнарының беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеневнең кызы Фатыйманың укыганлыгы мәгълүм. Шуннан соң аны казах иленең Россиягә чиктәш Бөкәй ханлыгы ханы Җиһангирга кияүгә бирәләр. Шул Фатыйманы Казан университетының икенче бер ректоры Карл Фукс та бер хезмәтендә мактап искә ала. «1826 елның көзендә Җиһангир хан Казанда булды...» – дип яза ул. Бу хан 1826 елда үз яраннары белән бергә башкалада император Николай I не тәхеткә тәгаенләү чарасында катнаша. Шуннан кайтышлый Казанда берничә көн торып китә. Аның белән бергә берничә би-солтан, нугай-татар нәселеннән чыккан үз мулласы Мөхәммәт һәм яшь хатыны Фатыйма да була. Алар Казан сәүдәгәре Шурба Муса йортына төшкән булалар. Мөгаен, бу сәүдәгәр дә алар белән бер чордарак С.-Петербург тарафларында йөреп кайткан булгандыр.

XIX йөздән башлап патшаларны тәхеткә тәгаенләү чараларында һәрвакыт диярлек үзебезнең татарларның да катнашу фактларын әйтеп үтү кирәктер. Татарстанның хәзерге Кайбыч

районы Борындык авылындагы мулла гаиләсендә туган Мөхәммәтҗан мөфтинең Александр I гә таҗ кидерү мәҗлесендә катнашканлыгы кайбер язмаларда хәбәр ителә. Ул чарада, бәлки, тагын бер-ике абруйлырак милләттәшебез дә катнашкандыр. 1881 елда Александр III гә таҗ кидерү чарасында ике-өч дәрәҗәле татар эшмәкәре арасында Дәрдемәнднең атасы, Урал төбәгендәге алтын приискалары иясе Мөхәммәтсадыйк Рәмиевнең катнашканлыгы мәгълүм. Булачак патшага аның иң затлы бүләк тапшырганлыгы шул вакыйгага багышлы язмаларда теркәлгән. Ә 1896 елда, Николай II не тәхеткә тәгаенләү тантанасында мөфти Мөхәммәдьяр Солтановтан кала унлап татар сәүдәгәре һәм эшмәкәре катнаша. Шулар арасында Кырым морзасы, Бакчасарай шәһәре башлыгы Исмәгыйль Гаспринский һәм Дәрдемәнднең агасы Шакир Рәмиев тә бар. (Дөрес, Гаспринскийга багышлы бер истәлек язмасында Мөхәммәтшакирны атасы белән бутап язалар. Чөнки, исемлеккә теркәлгәндә, аларның икесенең дә исеменең баш хәрефе «М» гына күрсәтелгән була.)

Университет ректоры Карл Фукс казах ханын һәм аның хатыны Фатыйманы болайрак тасвирлый: «Җиһангирга 24 яшь. Европалыга тартым аксыл йөзле... чибәр кыяфәтле. Рус телендә һәр сүзне дөрес кулланып сөйләшә. Безнеңчә язуы да төгәл. Татар, рус телләреннән кала гарәпчә һәм фарсыча да белә», – ди. Шул ук көннәрнең берендә Фатыйма К. Фукс хатынын, Пушкиннар белән аралашкан шагыйрә Александраны кунакка ала. «Ике хатын, янәшә утырып, матур гына итеп бик озак гапләштеләр» дип яза К. Фукс. Шагыйрә ханым белән хан зәүҗәне Фатыйманың рус телендә иркенләп хәбәрләшеп утырулары бу очракта татар кызының беркадәр белемгә ия булуы һәм рус телендә ярыйсы ук иркен сөйләшә белүе турында хәбәр итәдер, минемчә.

1905 елдан соң Россиянең төрле-төрле югары уку йортларында белем алучы татар шәкертләре саны тагын да арта төшкән. Тормыш-көнкүрешләре миңа мәгълүм шәхесләрдән Ризаэтдин хәзрәт Фәхретдиновның улы, Фатих Кәриминең ике бертуган энесе Әхмәт бай Хөсәенев стипендиясе исәбенә Тубылда һәм башкалада югары техник уку йортларында укыганнар. «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаган берничә шәкерт, шулар арасында Әстерхан тарафыннан килеп укыган Мостафаев фамилияле берәү шул ук стипендия хисабына Мәскәүдәге Лазарев исемендәге институтта белем алалар. 1907–1908 елларда Г. Исхакый, С. Рәмиев, Г. Тукайлар белән якыннан аралашкан, Гаяз Исхакый белән бер вакытта Казандагы Учительская школаны тәмамлаган Шакир Мөхәммәдьяров та 1909–1913 елларда С.-Петербург университетында укып, юрист дипломына ия була. Шул ук елларда башкалада Мулланур Вахитов, Дәрдемәнднең агасы Шакир Рәмиев улы Рәүфнең һ. б. ларның укып йөргәнлекләре дә мәгълүм.

Татар балалары арасында, Европа илләренә барып, европача белем алучылар саны да ишле генә. Шул ук Рәмиевләр нәселеннән берәүнең 1910 елларда Женева университетында укыганлыгы һәм шунда укытырга да калганлыгы Исмәгыйль ага Рәмиевнең үзе вафат булганнан соң Рәис Даутов тарафыннан нәшер ителгән «Әдәби сүзлек» китабында хәбәр ителә. Шакир һәм Закир (Дәрдемәнд) Рәмиевләрнең өч улы – Искәндәр, Әхмәт-Мидхәт һәм Гариф Германия белән Бельгия университетларында укып белем алганнар. Бәйрут, Дәмәшкъ, Истанбул, Каһирәише гыйлем үзәкләрендә мөселман югары уку йортларын тәмамлаучылар да байтак булган. «Хөсәения» мәдрәсәсен уңышлы тәмамлап, Хөсәенов байлар стипендиясе исәбенә чит илдә һәм Россиядә югары белем үзләштергән затлар саны гына да ике дистәне тәшкил итә. Шул ук Бәйрут, Әл-Әзһар, Истанбулларда укыган кайбер шәхесләр соңыннан, Совет хакимияте дәверендә, Казан, Уфа, Ташкент, Сәмәрканд кебек гыйлем үзәкләрендәге югары уку йортларында, шул исәптән Казан дәүләт университетында гарәп, фарсы телләреннән тыш, тарих, химия, физика һәм математика кебек фәннәрдән дә укытканнар. Шәрык дөньясының күренекле шагыйре Галишер Нәвоиның иҗатын төпле өйрәнеп, иң беренче гыйльми хезмәт – докторлык диссертациясен язучы зыялы галим дә безнең милләт вәкиле – Сәмәрканд университеты укытучысы Габдрахман Сәгъди була. Үзебезнең мәдрәсәләрдә укыганнан соң, Төркиягә барып белем үзләштергән зат. Шул ук Сәмәрканд дәүләт университетында 1930 елларда Оренбург янәшәсендәге Каргалы авылыннан чыккан морза Кәрамәтулла Айдаров та укыта. Шул елларда анда укыган бер Үзбәкстан галиме истәлекләрендә К. Айдаровның ул дәвердә Һиндстанда зур мәмләкәт оештырган, тумышы белән Фирганә каласыннан булган Заһреддин Бабурның язма хезмәтләрен өйрәнгәнлеге хәбәр ителә. Әлегәчә безнең галимнәр Бабур шаһның тарихи эчтәлекле «Бабурнамә» хезмәте булганлыгын гына искә алалар. Әлеге истәлек эчтәлегендә исә К. Айдаровның әлеге шаһның әдәби-фәлсәфи эчтәлекле әсәрләрен дә өйрәнгәнлеге телгә алына. Бабурның исә шигъри стильдә язылган «Мөбайн» һәм «Рисалия Вәлидия» исемле кулъязмалары булганлыгы да мәгълүм.

Шушы мисаллардан күренә ки, патша монархиясе богаулары хакимлек иткән заманнарда да безнең милләт вәкилләре, кайберәүләр уйлаганча, бөтенләй үк надан да, мескен дә булмаган. Хәер, узган гасыр башында ук шул хакта Ленин бабабыз да, тагын кемнәрдер дә язып калдырганнар ич, «татар баласы кулына китап тотарга күнеккән» дип.

Татарлар арасында, бигрәк тә XIX йөз урталарыннан башлап, башка тармакларда да зур дәрәҗәләргә ирешкән шәхесләр ишәя барган. Алар, үзләренең татар һәм мөселман булганлыкларын яшермичә, шундый дәрәҗәләргә ирешкәннәр. Дөрес, элегрәк

чукынган алпавытлар арасында да үзләренең татарлыгыннан качмаучылар булгалаган. Егерменче-утызынчы елларда нәшер ителгән кайбер биографик белешмәләрдә күрсәтелгәнчә, мәсәлән, А. Н. Радищевның Себер сөргененнән улларына татарча хат, Н. Г. Чернышевскийның татарча көндәлек язганлыклары теркәлгән.

Россиядә 1917 елга чаклы ук үз милләтен һәм динен яшермәгән утыз-кырыклап иң югары дәрәҗәле хәрбиләр дә булган. Төрле чикләүләргә карамастан, генерал дәрәҗәсенә ирешүчеләр дә ишле генә санала. Полковниклар тагын да күбрәк. Полковник дәрәҗәсендәге Шаһимәрдән Ибраһимов, мәсәлән, 1870 еллардан башлап Урта Азиядә һәм гарәп илләрендә илче, консул вазифаларын да үтәгән.

* * *

Сүземне мин Исмәгыйль ага Рәмиевкә багышлап башлаган идем. Рәмиев морзалар нәселеннән чыккан бу шәхеснең тууына былтыр 120 ел булды. 1969 елның декабрендә, 75 яшенә җитәрәк, ул бакыйлыкка күчкән иде. Шушы гомер дәвамында ул шаян һәм көлкеле хикәяләр авторы буларак та («Чаян» мәҗмугасын башлап чыгаручылар төркемендә катнашкан шәхес), әдәбиятчы буларак та танылa. 1928, 1959 елларда Дәрдемәнднең сайланма әсәрләрен җыеп, туплап чыгаручы да, 1960 елларда Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Габдулла Кариев һ. б. ларга багышлап бик тирән фикерле истәлек язмалары язып бастыручы да ул булды. Әмма бакый дөньяга күчкән вакытта аның еллар буена тупланган зур бер хезмәте нәшер ителмичә калган иде. Китап нәшриятына «ул хезмәтне бастырырга кирәкми» дигән фикерне раслаучы белешмәне үзебезнең бер күренекле галимебез язып биргән иде. (Ул тискәре фикерле язма Рәис Даутов папкаларында саклана иде. Хәзер дә, бәлкем, аның архивында сакланадыр.) Татар мәдәнияте офыкларын баетучы ул энциклопедия дәрәҗәсендәге хезмәт фәкать утыз елдан соң, 2001 елда гына басылып чыкты. Карт морзаның кайбер көндәшләре дә арадан киткәч кенә. Ике автор исеме белән басылган, Рәис каләмдәшем бүләк итеп биргән «Әдәби сүзлек» китабы һәрчак китап киштәмнең түрендә тора.

Менә шушы китапны кулына алып караган һәркем бүген 1917 елга чаклы кайсы югары уку йортында белем алган татар баласының гомуми санын да, исем-фамилиясен дә, күп кенә очракта кайдан чыкканлыгын да укып беләчәк. Совет хакимияте елларында еш әйтелеп килгән (кайбер очракларда хәзер дә кабатлангалаган) ялган фикергә — татарлар элек югары уку йортларына укырга керә алмаган дигән фикергә — ачыклык кертеләчәк. Казан университетына багышланган мәгълүматны китапның 329 нчы битеннән күзәтә башлыйк. Менә башлангыч

чорда шунда укырга кергән 28 студентның исемлеге. Шуннан соң 1855–1904 еллар аралыгында укыганнар исемлеге китә. Аларның тулаем ачыклап бетерелмәгән саны 44 белән тәмамлана. Казанның башка югары уку йортларында 1905–1917 еллар аралыгында укыган 21 студент исемлеге шуннан соң китерелә. Инде Петербург шәһәрендәге югары уку йортларында укучылар исемлегенә күз төшерик. Аларның саны 52 була. Мәскәүдәге югары уку йортларында укучылар әлегә 30 дип теркәлгән. Россиянең башка шәһәрләрендәге югары уку йортларында укучылар да әле төгәл түгел бугай. Алар әлегә 16 кеше исәпләнә. Әмма монда Себер тарафында яшәгән милләттәшләребезгә кагылышлы саннар тулы түгелдер шикелле. 1917 елга чаклы Россиядә Югары курсларда укыган хатын-кызлар саны 46 дип яза И. Рәмиев. Бу исемлектә дворяннар хокукына якын хокукка ия булган, Россиянең императорлары указы белән эшкә билгеләнгән, ара-тирә патша сарайларына чакырмыйча да ишек шакып керә алган мөфти хәзрәтләребезнең балалары да теркәлмәгән шикелле.

Мөхәммәтҗан мөфтинең кызы Фатыйманы алдарак искә төшереп киткән идек. Аның икенче кызы һәм кызының кызлары да өйдә йон эрләп кенә утырмаганнардыр, мөгаен. Габдессәлам әл-Бөгелмәви, Сәлимгәрәй Тәфкилев, Мөхәммәдьяр Солтанов мөфтиләрнең дә балалары кайлардадыр укыгандыр. Соңгы мөфтигә кагылышлы бер тискәре фактны да искә алып китик. 1905 елның кышында Казанның заманча карашлы шәхесләре татар халкын бар яктан да Россиянең төп халкы белән тигез хокуклы итүнең кирәклеге турында патша җәнаплары исеменә хат язалар. Ул шәхесләр, алдан килешенгәнчә, Әхмәт бай Хөсәеновның Кабан күле буендагы иркен өенә яшерен рәвештә, аш мәҗлесенә җыелган кебек җыелып, бу мәсьәләне хәл итәләр. Хат-петициянең каралама эчтәлеген Йосыф Акчура язып килгән була. Мәҗлес барышында ул хат берникадәр тулыландырыла. (Ул мәҗлестә катнашучыларның төп исемлеге мәгълүм. Ләкин шундый хат булганлыгы турында безнең галимнәр язмады шикелле.) Шуннан соң ул хатка Россиянең иң дәрәҗәле ике йөзләп татары имза сала. Бу хатны патша җәнапларына илтеп тапшыру Йосыф Акчура, фабрикант Ибраһим Акчурин һ. б. ларга йөкләнә. Башкалада алар мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов белән очраша. Затлы конвертка төрелгән шул хатны Николай II патшага тапшырырга булышуын үтенәләр. «Син бит патша хәзрәтләре сараена һәрчак үтеп керә аласың. Тапшыр шушы конвертны», – дип ялваралар. Мөфти алар үтенечен тыңламый. «Чыгып китегез минем кабинеттан», – дип, тегеләрне куып чыгара. Хатны премьер-министр С. Ю. Виттега тапшырырга мәҗбүр булалар. Шул елда кабул ителгән патша Манифесты барлыкка килүгә татар зыялыларының әлеге хатының йогынтысы да булгандыр дип уйларга кирәк.

Кабат Исмәгыйль Рәмиев китабын кулга алыйк. Анда Европа илләрендә «европача» югары белем алучылар исемлеге дә китерелә. Икегә бүленгән бу исемлектә 46 кеше күрсәтелгән. Шулар арасыннан ике шәхескә кагылышлы үз фикеремне дә өстәп китәсем килә. 1913 елда Оренбургта Хөсәенов байларның өченчесенә – бик күп мәктәпләр ачу һәм тотуга зур өлеш керткән Мөхәммәтганигә багышланган «Гани бай» китабы нәшер ителгән. Шул китапта Гани байның язучы һәм матбагачы Тимерша Соловьёв белән бер әңгәмәсе дә китерелә. Тимерша әйтә моңа: «Һади Максудиның халык арасында уңай бәя алган «Мөгаллим әүвәл» дәреслеген үз хисабыгызга чыгарып, зур эш башкардыгыз. Аның энесе Садрины да Парижга укырга җибәрүдә сез булышкансыз икән. Бик саваплы эш инде бу», – ди. Гани бай аңа төгәл генә җавап бирми, шул саваплы эшне башкаруга күпме акча тотканлыгын әйтми. Фәкать: «Өметле яшьләргә булышлык итү безнең бурыч инде ул», – дип кенә куя.

Уйлавымча, Сара Шәкуловага да, Сорбонна университетына барып укыганда, фабрикант Акчуриннар ярдәм иткәндер кебек. Чөнки аның якын туганнары арасында Акчуриннарның кияве булганнары да, килен булып төшкәннәре дә бар бит. Хәзер дә югары белем алырга теләгән яшьләргә матди ярдәм итәрдәй шундый шәхесләребез булуын теләр идем.

Исмәгыйль ага Рәмиевнең үзешчән галим буларак башкарган тагын бер бик зур хезмәте – 1920 елларга чаклы Россиянең төрле тарафларында татарча нәшер ителгән газета һәм журнал, альманахлар антологиясеедер («Вакытлы татар матбугаты», Казан, 1926). Шул матбугат берәмлекләренең күпчелегенең рәсем-сурәте дә төшерелгән ул зур форматлы калын китапны автор үзе «альбом» дип атаган. Ул китапны матбугат өлкәсендә эшләүчеләр бүген дә кулдан төшерми диярлек. Татарстан китап нәшриятында һәм Татар энциклопедиясе институтында эшләү дәверендә миңа да ул китапка еш мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. Ул хезмәтнең Англиядә, Оксфорд университетында саклануы турында да сөйләгән иде автор.

Киләчәк буыннар да Исмәгыйль агадай шәхесләр калдырган гыйльми мирастан аерылмасын дип теләк телисе генә кала. Татар халкы элек надан булган, югары белемгә ия шәхесләре дә булмаган дип кабатламас өчен, ара-тирә И. Рәмиевтәй галимнәр хезмәтенә күз төшереп алгалау да зыян итмәс иде.

*2016*

# «КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ»НДӘ НИЛӘР БАР?

2011 елның ахырында Татарстан китап нәшрияты Гомәр ага Бәшировның көндәлек язмаларын аерым китап итеп бастырып чыгарган иде. «Күңел дәфтәре» дип исемләнгән ул китапны олуг әдибебезнең улы Зөфәр Бәширов нәшриятка әзерләп биргән. Бу җыентыкка әдипнең биш калын дәфтәргә төрле елларда теркәп барган истәлек язмалары кергән. Беренче дәфтәрдәге беренче язма 1937 елның 13 февраленә карый. Бишенче дәфтәрдәге соңгы өч җөмләле язма 1999 елның май башында теркәлгән. Ә китапның соңгы битендәге соңгы җөмлә, Зөфәр кулы белән язылганы: «Әдип Гомәр Бәширов 1999 елның 7 май таңында вафат булды», – дигән сүзләр белән тәмамлана. Нәкъ шул көнне Гомәр агага 98 яшь тә 4 ай тулган була.

Бу җыентык белән таныштыру өлешендә Зөфәр Бәширов: «Көндәлекләр берникадәр кыскартылып бирелә», – дип белдерә. Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре, олуг әдип белән кырык ел чамасы аралашып яшәгән Равил Фәйзуллин язган.

Безнең өлкән язучыларыбыз арасында көндәлек вакыйгалардан истә калырга тиешлерәкләрен «куен дәфтәренә» теркәп бару тәртибе яшәп килде. Шундый истәлек дәфтәрләренең Афзал Шамов, Госман Бакиров, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах варислары кулында сакланганын беләм. Мәсәлән, бер очрашу вакытында Афзал ага андый истәлек язмаларын 1919 елдан яза башлаганын, Госман ага исә шул эшкә 1923 елда, ятим балалар йортында тәрбияче вазифасын үтәгәндә керешкәнлеген сөйләгән иде. Өлкән буын әдипләреннән Шәриф Камалның да көндәлек дәфтәрләре булган. Ләкин, «буржуй Рәмиевләр» белән якын мөнәсәбәттә торганлыгын чагылдырган урыннар теркәлгәнлектән, кызы Зәйнәпнең аны яшереп тотуын әйткәләүчеләр булды. Шәриф Камал исемендәге музейның күпьеллык мөдире булган дәвердә дә ул атасының бертуган Рәмиевләр белән аралашу вакыйгаларына багышлы сорауларга җавап бирмәскә тырыша иде.

Гариф Ахуновның җитди генә җыелышлар барышында да, куен дәфтәрен алга куеп, нидер язып утыруларын хәтерләүчеләр бардыр. Мондый эшкә һәвәслек аңарда илленче елларда ук туа. Туксанынчы елларда, кайбер чордашларының, мәсәлән, Мирсәй ага Әмирнең шундый язмалары матбугатта күренгәли башлаганда, мин аңа берничә мәртәбә:

– Синең көндәлекләрне дә укыр көннәр җитте бугай. Нишләп аларны «Казан утлары»на күрсәтмисең? – дип әйткәләгән идем.

– Вакыты җитмәгән әле, – дип җавап кайтара иде ул. Ә бер мәртәбәсендә әйтте: – «Совет әдәбияты» редакциясендә һәм Әлмәттә эшләгән елларымда хәзерге классикларыбызның кайбер-

ләренә карата байтак кына тәнкыйди фикерләр дә язган булганмын. Аларны әлегә чыгарасым килми, – дип. Әлбәттә, «классиклар» дигәндә, ул үзе белән бер чорда иҗат итүчеләрне истә тота иде.

* * *

Без мәктәптә укыган кырыгынчы елларда, Тукай, Такташтан кала, әдәбият аксакаллары исемлегендә тагын биш-алты кеше генә бар иде. Без Шәриф Камалның «Матур туганда»сыннан өзекләр, Гомәр Бәшировның «Сиваш» повестен, Афзал Шамовның «Госпитальдә» һәм башка хикәяләрен, Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен, Ибраһим Газиның «Катя Сорокина»ларын дәрестә укып үстек. Әлбәттә инде, китапханәдән дә иң әүвәл шул авторларның китапларын алып укый идек. Ул чорда Казаннан мең чакрымда урнашкан авылга татар телендәге китаплар һәм журналлар даими рәвештә килеп торды. Ул елларда бездә дә, якын-тирәдәге татар авылларында да икешәр – мәктәп һәм авыл советы карамагындагы китапханәләр эшләде.

1948 елның беренче айларында «Совет әдәбияты» журналының берничә санында Гомәр ага Бәшировның «Намус» романы басылып чыкты. Ул вакытта безнең Иске Актауда журналны мәктәп китапханәсе дә, авыл советы карамагындагысы да алдырта иде. Авыл халкының ул әсәрне чират торып укыганлыклары хәтеремдә. Ә безнең өйдә аны кыш дәвамында биш-алты хатын-кыз – авылыбызның Нәфисәләре – бергә җыелып укыдылар. Кул эшләрен тотып килерләр дә, шул эшләрен онытып, күз яшьләрен сөртә-сөртә, Гомәр ага язганнарны тыңлап, әсәрләнеп кайтып китәрләр иде... Әнинең апасы ул елларда «Игенчеләр» колхозы кырчылык бригадасы бригадирының кул астында исәп-хисап эшләрен башкаручы – учётчик иде. Бригадир бабай кыр-басуда сирәк булганлыктан, барлык оештыру эше диярлек Наилә апа Касыймова җитәкчелегендә алып барыла торган иде. Кыш айларындагы кичке укуларга ара-тирә күршедәрәк яшәүче укытучы Хөснә апа да кереп утыргалар иде. Ә көндезләрен инде ул мавыктыргыч әсәрне миңа – җиденче сыйныф баласына да укырга рөхсәт иттеләр.

1960 елларда, бер очрашу вакытында, мин бу вакыйганы Гомәр агага да сөйләп бирдем.

– И-и, ул елларда миңа төрле-төрле яклардан: «Сезнең романны без бергәләп укыйбыз», – дигән хатлар бик-бик күп килде. «Намус» бит ул вакытта журналның өч санында басылды (№ 1–3). Кайберәүләр киләсе санның килеп җитүен көтмичә, «фәлән-фәлән хәлләр ничек тәгәлләнә» дип түземсезләнеп сорап та язалар иде. Ә менә үзебезнең кайберәүләргә ул әсәр ошамаган булып чыкты. «Кызыл Татарстан» газетасында аны тәнкыйтьләп язып чыктылар. Имеш, әсәрдә партия оешмасының эше тулырак

күрсәтелмәгән. Шуннан соң миңа романымның эчтәлеген бераз үзгәрткәләргә, яңадан эшләргә туры килде, – дип сөйләгән иде әдип, урман аша Аккош күле дачаларына таба икәүләп барган бер кичтә…

Шул вакыттагы сөйләшүне дә искә төшереп, кызыксынып, әдипнең «Намус» романын иҗат иткән, аны журналда бастырып чыгарган һәм китап рәвешендә нәшер иткән еллардагы көндәлек язмаларын укыйм. Әйе, бу романны язу уе Гомәр агада 1943 елның җәендә, Балык Бистәсе районындагы бер авылда ике атна чамасы яшәп алганнан соң туган икән. Шул авылга ул автомобиль авариясеннән соң, хастаханәдә ятып бераз терелә төшкәч, табигать шартларында сихәтләнергә дип барган булган. Сырхау әдипнең Кама буендагы авылга бу сәяхәте нәкъ урак өсте көннәренә туры килгән. Булачак роман әүвәл аның күңелендә авыл тормышына багышланган бер хикәя рәвешендәрәк бөреләнә башлаган. Шуннан соңгы өч-дүрт ел дәвамында инде ул әсәр әлеге роман кысаларына кергән.

Бервакыт әдәбият галиме Гази ага Кашшаф белән без бер атналык сәяхәттә бергә йөреп кайткан идек. Әдәби фонд оешмасының ике елга бер уздырыла торган исәп-хисап корылтаена барып, бер бүлмәдә яшәп, байтак хәлләр турында гәп корып кайттык. Шул сәяхәт вакытында ул миңа Гомәр ага белән кайчандыр бик якын мөнәсәбәттә булганлыгын, «Намус» романы кулъязмасының һәр бүлеген кат-кат укып, авторына бик күп киңәшләр биргәнлеген дә сөйләде. «Радиокомитетта эшләгәндә, Гомәр ага төрле-төрле районнарга командировкаларга да күп йөрде, колхоз һәм колхозчылар тормышын бик яхшы белә», – дигән иде ул.

Инде янә Гомәр аганың көндәлегенә күз төшерик. Менә 1947 елның 30 ноябрендә теркәлгән язма. «Биш елдан бирле түземсезләнеп, зарыгып көткән куанычлы көннәр килеп җитте. «Намус»ны тәмам итеп, ниһаять, соңгы өлешен 24 ноябрьдә «Совет әдәбияты»на тапшырдым. Аны укыйлар. Әле берәүнең дә кире фикер әйткәне юк».

Романның тәүге өлеше журналда 1948 елның беренче санында басылып чыга, әдәбият сөючеләр тарафыннан бик яратып кабул ителә. Журнал редакциясенә төрле тарафтан бик күп мактау хатлары килә. Таныш-белешләр дә романны бик хуплап кабул итәләр. Роман «Совет әдәбияты»ның өч санында басылып чыга. «Гомумән, яхшы фикердән башканы ишеткән юк әле» дип яза автор көндәлегенә. Кулъязма инде китап нәшриятына тапшырылган көннәрдә, көтмәгәндә генә, «Кызыл Татарстан» газетасының 1948 елгы 13 октябрь санында «Намус» романының бер кимчелеген бәян иткән мәкалә басылып чыга. «Әсәрдә партия оешмасының эше тиешенчә тасвир ителмәгән» дигән мәгънәле мәкалә. Партиянең өлкә комитеты карамагындагы газетада эшләүче өч авторның – Фәтхи Балыкчы, Фатих Хөсни һәм Фатих

Мөсәгыйтнең уртак хезмәте. Әлбәттә инде, бу авторларга әлеге мәкаләне язу кирәклеген партиянең өлкә комитетыннан берәрсе искә төшергән булгандыр. Ул дәвердә андый эшләр шулайрак хәл ителә иде бит. Нәкъ шушы вакыйга алдыннанрак кына үзәк матбугатта да бит Александр Фадеевның «Яшь гвардия» романында «партия тормышы тулы чагылдырылмаган» дигән эчтәлекле җитди кисәтүләр басылып чыккан иде. Безнекеләр дә шуңа ияргәндер, күрәсең.

Шул мәкаләне укыганнан соң, Гомәр ага көндәлегенә: «Намус» романының уңышына «кайбер бәндәләрнең ифрат эчләре пошты, кара көйделәр, күтәрә алмадылар, көнчелектән шартлый яздылар» дип язып куя. Ул мәкаләне табып укымастан, Гомәр ага әйткәннәрне генә искә төшереп язам. Әлбәттә, Гомәр ага Бәширов каләмдәшләренең шундый эчтәлекле мәкаләсен бик авыр кабул иткән. Әмма берничә ай дәвамында көндәлегенә шул хисләрен чагылдырган фикерләрен теркәмәгән диярлек. Шушы вакыйгадан соң берникадәр вакыт үткәч, Киевта, Украина язучыларының корылтаенда булып кайткач кына, әдип, дәфтәренең 1949 елның 18 февраленә караган битендә тагын түбәндәге җөмләләрне өстәп куйган: «Гомумән, мин бу эшемнән канәгать. Ул әнчекләр тик өрә бирсеннәр! Аннан миңа ни зарар?»

Автор шулай дип үз-үзен тынычландырырга тырышса да, күңел тынычсызлыгы тиз генә басылмый, әлбәттә. «Нәшриятка хәзер шик төшә. Ә Мәскәүдә тәрҗемәне туктатырлар. Менә сиңа нәтиҗә!» – дип, соңрак язып куя автор. Нәшрият директоры Закир Тинчурин белән киңәшергә була. «Акыллы, тәҗрибәле, кешене аңлый торган кеше» белән киңәшүдән соң, партия райкомы идея җитәкчесе булырга тиеш» дигәнрәк фикергә киләләр.

«Үз заманының каһарманы» дип аталган кереш сүз авторы Р. Фәйзуллин да, шушы вакыйгаларны да истә тотып булса кирәк, түбәндәге сүзләрне яза: «Хәзерге яшьләрнең ул чор совет әдәбияты үрнәкләренә үз карашлары бар – тәнкыйди караш, – ди. – Әмма үзләре шул заманда яшәп иҗат итсәләр, нишләгән булырлар иде икән? Кемнәргәдер «Намус» романындагы Нәфисә образы ясалма булып тоелырга мөмкин. Онытмыйк, Нәфисәләр берничә буынны тәрбияләде. Начарга тәрбияләмәделәр бит. Шунысы мөһим».

Бик-бик хак сүзләр. Нәфисәләрдәй уңган, калку образлар тудырган олуг әдипнең хезмәте – «Намус»ы тел-лөгать һәм әдәби сурәтләү җәһәтеннән дә онытылырга тиеш булмаган әсәрдер дип уйлыйм мин. Кайберәүләргә ул әсәрнең Сталин исемендәге премиягә лаек булганлыгы да ошап бетми шикелле. Роман начар булганга түгел, «начар кеше» – Сталин исеменә бәйле булганга күрә генә аны «танырга» теләмәүчеләр дә бар. Ләкин ул премия дә бит бу әсәргә җиңел генә бирелмәгән. Көндәлек язмаларыннан күренгәнчә, Татарстан җәмәгатьчелеге аны өч мәртәбә тәкъдим

иткән. Өченче мәртәбәсендә, әсәрнең русчага тәрҗемәсе «бөек, даһи җитәкчебез» кулына эләккәч кенә, «Намус» романы икенче дәрәҗә бүләккә лаек дип табыла.

Элекке семинарист Иосиф Сталинның әдәбият, сәнгать кешеләре белән турыдан-туры элемтә тотуы, байтак кына әдәби әсәрне басылып чыккач ук укыганлыгы турында күп мәртәбәләр яздылар. Аның «Намус» романын йөгертеп кенә күздән кичергән булуы да зур дәрәҗә. Шундый дәрәҗәгә ирешкән Гомәр агабыз өчен без бүген дә куанырга тиештербез, шәт. Янә авторның үзенә сүз бирик. 1950 елның 23 декабре. «Бу арада «Намус»ның корректурасын укыдым. Гаҗәп. Ничәнче тапкыр басыла инде. Татарчасының гына да өченче мәртәбә басылуы. Ә һаман да төзәлә, яхшыра бара. Сыек яисә кабатланган, бик үк уңышлы әйтелмәгән урыннары һаман да очрый әле». Бу җөмләләрдән авторның үз-үзенә, иҗатына карата ни дәрәҗәдә таләпчән булганлыгы чамалана. Ә бит бер язылган кульязмага кабат кул тыкмаучылар, шул хакта башкаларга мактанып сөйләп йөрүчеләр дә бар.

Соңгы сүз итеп Гомәр ага Бәширов көндәлегендәге тагын бер язмага тукталып үтик. 1966 елның июленә караган язма. Икенче бер олуг әдип, күренекле сүз остасы Әмирхан Еникинең әдәбиятка багышланган бер кичәдә әйткән сүзләрен искә төшереп, көндәлек авторы болай дип язган: «Ә. Еникинең минем «Намус» турында фикерен элек ишеткәнем юк иде. Ул мондый фикер әйтте: «Докладчы «Намус» романыннан бик отышлы үрнәкләр китерде. Роман аңа лаек. «Намус» романының кыйммәте халыкның сугыш вакытындагы патриотик хисләрен, сугыш вакытында фидакяр эшләрен югары художество чаралары ярдәмендә күрсәтүдә генә түгел. Ул үзенең әдәби кыйммәте белән, бик отышлы табылган детальләре белән дә кадерле».

Көндәлек авторы башка әсәрләренең язылу тарихларын да искә ала, әлбәттә. Ләкин ул алар турында бик алай җәелеп язмый. Китапта әдипнең чордашларына, якын күргән каләмдәш дусларына багышланган, аларның әсәрләренә бәя биреп киткән аерым битләр дә бар. Үзенә якын фикердәшләре фикере белән килешеп бетмәгән очракларны теркәп куюны да кирәк тапкан әдип.

Гомәр ага Бәшировның «Күңел дәфтәре» китабын мин яхшы бер роман, авторның үзенә багышланган роман кебек, йотлыгып укып чыктым. Әдәбият сөючеләргә дә аны алып укырга тәкъдим итәм.

*2014*

# ИҖАДИ РУХЛЫ, ЯГЫМЛЫ КЕШЕ

*(Истәлек)*

Шат күңелле, кешеләр белән аралашырга яратучан Гариф ага Ахунов белән мәңгелеккә аерылышуыбызга да байтак вакыт узды. Бакыйлыкка да ул, көндәлек тормышындагыча, шау-шусыз, тыныч кына китеп барды. 2000 елның 4 нче июнь иртәсендә ул бакча гөлләренә, җимеш куакларына су сибә дә, җәмәгате Шаһидә иртәнге табынны әзерләгәнче дип, эш бүлмәсенә кереп ята. Без, бакча күршеләре, элек-электән аның бик иртә торучанлыгын белә идек. Еш кына үзе дә: «Сез йокы симерткәндә, мин бер хикәяне башлап куйдым инде», – дип әйткәләр иде. Безнең ише йокы симертүчеләргә исә аңа: «Тургай шул син, таң белән бергә торучан тургай нәселеннән!» – дигәнрәк мактау сүзләре әйтүдән башка чара калмас иде.

Шаһидә, иртәнге чәй табынын әзерләп, аның янына килә. «Торасыңмы?» дигән сүзләрне Гариф ишетми, уянмый. Тәне суынган кебек тоела. Шаһидә ике йорт аша гына яшәгән врачка – Фасил Әхмәтнең җәмәгате Йолдыз ханымга йөгерә. Йөрәк тибешен көйләп җибәрердәй укол биреп, күкрәк тирәләрен углалап карагач, Йолдызга: «Гариф агабыз, беребез белән дә саубуллашмыйча, тыныч кына мәңгелек йортына китеп барган», – дип әйтүдән башка чара калмый. Безнең бакча ширкәтендә язучылар, композиторлар, рәссамнар ишле генә иде. Әмирхан Еники, Нури Арслан, Гөлшат Зәйнашева, Зәки Нури, Хисам Камалов, Марс Шабаев, Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтов, Хөснулла Вәлиуллин, Әнвәр Шәрәфиев һ. б. лар якын бакча күршеләребез булдылар.

Гариф Ахунов соңгы дәвердә аеруча Хөснулла ага Вәлиуллин белән бик еш аралашты. Алар бергәләп берничә спектакльнең авторлары булдылар. Гариф ага Шәриф Камалның мәгълүм «Акчарлаклар» повестен пьеса рәвешенә китереп эшләгәч тә, ике авторга мөрәҗәгать итеп, шул темага җыр язуларын үтенә. Шул пьесаны сәхнәләштергәч тә халык тарафыннан бик яратып кабул ителгән «Акчарлаклар» җыры туа. Ул җырның шигъри текстын шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов язган булса, көен-моңын тудыручы Хөснулла ага Вәлиуллин иде. Җәйнең матур кичләрендә шул җырны йөрәкләргә үтеп керердәй моңлы итеп башкаручы да үзебезнең бакча күршебез Нәҗибә Ихсанова булды. Менә шулай бергәләшеп яши-яши, без 2000 елның әлеге июнь аена да килеп җиткән идек…

Ул иртәдә дачада булганнар барыбыз да бергә җыела башладык. Яңарак кына Г. Тукай музее директоры итеп билгеләнгән Мөҗип Таҗи улы Низамиев та арабызга килеп керде. «Кара инде… Чирек сәгать элек кенә кое янында очрашкан идек бит. «Озак йоклыйсың, минем инде алтынчы мәртәбә килүем» дип,

шат елмаеп, кулындагы дүрт-биш литр су сыешлы бидонын бил тиңентен күтәреп тә күрсәтте», – дип, сүз башлады ул. Димәк, бу иртәдә Гарифны берләнбер күрүче Мөҗип булган икән. Аның кое дигәне, билгеле инде, элек әби-бабаларыбыз кулланган рәвешлесе түгел, электр ярдәмендә су бирүче артезиан коесы иде. Гарифлардан ул бик еракта түгел, Хәсән Сарьян йорты аша Туфан Миңнуллин бакчасы кырыенда гына иде. (Гариф та, Туфан да, Сарьян да күптән арабыздан киттеләр. Ә ул кое бүген дә әле безне су белән тәэмин итеп тора.)

Бу иртәдә Туфанның баҗасы Җәмил Казанга барырга тиеш булган икән. Шул хәбәрне ишеткәч тә ир-атның күпчелеге һәм шул исәптән врач Йолдыз да: «Җәмил аны Казанга ала кайтырга риза. Кайдандыр ярдәм килүен көтеп тормыйк. Шаһидә белән икесен шушы машинада озатыйк», – дигән фикерне хупладылар. Гарифны машинага җайлабрак сузып салгач та, Шаһидә ханым, безнең гаилә тарафына карап: «Дания, бер урын бар, син дә утыр инде…» – дигәч, минем җәмәгатьнең дә озата барасы ачыкланды. Дистә еллап бергә, бер оешмада эшләгән кешеләр идек бит.

Бакчадан Гариф Ахуновны соңгы мәртәбә шулай озатып калдык. Әлбәттә инде, зурлап озату, зурлап саубуллашу киләсе көннәрдә Казанда оештырылачак иде. Халкыбызның бер әйтеме бу очракка бик тә туры килә. Тыныч холыклы, тыныч табигатьле кеше гүргә дә тыныч кына китеп барыр, диелә бит. Балачактан ук бик күп авырлыклар кичергәнлектәнме, күпләребез өчен остаз булган Гариф Ахунов шундый сабыр холыклы, кешеләргә карата хәерхаһ олуг затларыбызның берсе буларак истә калган.

Татарстан Республикасының халык язучысы Гариф абый Ахунов һәм аның гаиләсе белән без байтак еллар дәвамында якыннан аралашып яшәдек. Гариф абый 1968 елда Татарстан Язучылар берлеге оешмасы рәисенең урынбасары итеп сайланды. Шул җәйдә алар Әлмәттән Казанга күчеп яши башладылар. Бер ел элек кенә мин дә шул оешманың бер вәкиле булып эшли башлаган идем. Дөрес, элегрәк тә очрашкалаган идек без. Мәсәлән, аның 1963 елда нәшер ителгән «Хәзинә» романын ул Казанга эшкә билгеләнгәнче өч-дүрт еллар элегрәк язучылар тарафыннан күмәкләп бәяләү җыелышы булды. Анда очраклы рәвештә катнашып, шәхсән авторның үзенә генә ул романның миңа бик тә ошаганлыгын белгерткән дә идем әле. Ул вакытта мин әйткәннәргә ул әллә ни әһәмият итмәгән иде кебек. Чөнки ул көндә андый мактау сүзләрен аңа колактан-колакка гына түгел, барлык җыелган каләмдәшләре алдында да күп тапкырлар кабатладылар ич. Бик хуп күреп, яратып укыган идем мин «Хәзинә» романын. Һәм шул романны укыгач, Ахунов фамилияле язучы иҗаты белән күп еллар элек танышкан булуымны да искә төшергән идем. Казаннан бик еракта, Оренбург белән Чиләбе аралыгындагы бер шәһәрдә яшәгәндә үк, аның «Яшьлек яме» әсәрен без, бер китапханәгә йөргән яшьләр, бик тә кызыксынып

укыган идек бит. Ул әсәрдә бездәй яшьләр тормышы бик тә мавыктыргыч итеп тасвирлаган. Әсәр безнең яшәешкә ниндидер ямь өстәгән, ул әсәрдәге яшьләр төсле яшәү хисләрен яңарткан сымак булган иде. 1960 еллар урталарында «Хәзинә» романын тикшергәндә, әлеге повесть исемен дә кат-кат ишетү, һәм аның авторы Гариф Ахуновның арабызда утыруын белү минем өчен аеруча сөенечле булган иде. Ә инде 1968 елның май аеннан бергә эшли башлагач, бер-беребезгә карата туган җылы хиснең арта баруын тоеп яшәдем. Байтак еллар бергә эшләү дәверендә безнең сүзгә килешкән очрак та, башка төрле килешмәүчәнлек тә булмады. Шул дәвердән бирле бергә-бергә эшләгән, ике як белән дә бер чамада аралашкан каләмдәшләремнең күпчелеге минем белән килешер. Гариф агабыз холкында үз-үзен кемнәндер өстен куярга тырышу, сүзгә килешү кебек тискәре сыйфатлар булмады сыман.

Шул холкы, шул тәрбиясенең йогынтысы аның әсәрләренә дә хас. Ул иҗат иткән күпчелек хикәя, повесть, романнар укучылар тарафыннан уңай кабул ителде, күп укылды. Сәхнә әсәре булса – кызыксынып каралды. Гариф Ахуновның башка әсәрләрен дә мин даими укып барырга кирәк дигән фикергә килгән идем. Ә инде бер оешмада бергә эшли башлагач, ул фикер тагын да ныгый төште. Мин – аның «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» повестьларын да, «Идел кызы» романын да кулдан төшермичә укыган кешеләрнең берседер. Хикәяләре дә бик ошый иде миңа. Яшьлегендә бездән – сугыш чоры балаларыннан да артыграк тормыш авырлыкларын кичергән, бик яшьли атасыз калган Гарифның күпчелек әсәрләре тормышчан булулары белән күңелне җәлеп итә. Мин укымаган һәм күрмәгән бердәнбер әсәре, мөгаен, «Утлар яна учакта» драмасыдыр. Татарстан нефтьчеләренең башлангыч дәвер эшчәнлеген яктырткан, һәр авыл тирәсендәге басуларда җир куеныннан нефть белән бергә ургылып чыккан газ ялкыннарының дөрләп яну чорын чагылдырган әсәрдер дип күз алдына китерәм мин аны. Хәзер бит нефтькә кушылып чыккан ул газларны ачык һавада яндырмыйлар. Махсус җайланмаларга туплап, көндәлек хуҗалык кирәк-ярагына тоталар. Бәлки, ара-тирә «Утлар яна учакта» һәм шуңа охшаш әсәрләрне дә, тарихи бер чорны чагылдырган факт буларак, бүген дә сәхнәләштерергә кирәктер. Ә «Хәзинә» романына нигезләнеп, шагыйрь Мансур Шиһапов иҗат иткән «Кошның да үз оясы була» сәхнә әсәрен дә бүгенге тамашачы хөкеменә тәкъдим итеп карау кирәктер, мөгаен. Сиксәненче елларда Кәрим Тинчурин театры сәхнәләштергәч, тамашачы ул пьесаны бик уңай кабул иткән кебек хәтерлим. Аны без берничә мәртәбә карадык. Оренбург тарафыннан килгән кунакларыбызга да аның бик ошаганлыгын хәтерлим. Шул пьеса өчен дип М. Шиһапов тарафыннан махсус иҗат ителгән, композитор Мәсгут Имашев тарафыннан матур көйгә «төрелгән» «Туй күл-

мәге» җыры да бүгенгәчә халык күңелендә яши бит. Миңа калса, бер-ике сезоннан соң ул тамашаның пәрдәсен шап итеп ябып кую вакыйгасы инсценировка авторының капылт кына башка гамәлләре өчен кискен генә тәнкыйтьләнүенә бәйле булды. Бүген, вак-төяк көнкүреш вакыйгаларын күпертебрәк күрсәтүгә, үзара атыш-суешларга күбрәк өстенлек бирелгән бер заманда, ара-тирә генә булса да тәрбияви эчтәлекле әлеге һәм башка шул чор пьесаларын күрсәткәләп алу да зыян итмәс иде дип уйлыйм. Югыйсә мәктәп яшендәге балаларның да, бүгенге көндәге кино һәм театр сәхнәләрендәге күренешләргә нигезләнеп, үзара пычакка-пычак килү яисә башка төрле начар гамәл кылу очраклары ешайды ич. Элек-электән андый күренешләрне яшүсмерләргә күрсәтмәскә, тискәре мисаллар җирлегендә аларның тәрбияви карашына зыян китермәскә тырышылган. Ә бүгенге сәхнә һәм экраннардан исә без андый бозыклык күренешләренең даими рәвештә кабатланып торуын күрәбез. Кемдер, бәлки, Ватан сугышы вакыйгаларына багышлы киноларда да гел үтереш тә суеш күренешләре кабатланды дияргә теләр. Бала психикасы андый вакыйганың шулай булырга тиешлеген аңлап кабул итә.

Гариф Ахуновның сайланма әсәрләренең кайберләренең кабат нәшер ителүен көтүче әдәбият сөючеләр дә бардыр дип уйлыйм. Соңгы елларда кайбер авторлар бүгенге заманның вак-төяк вакыйгаларына күбрәк әһәмият бирәләр. Миңа калса, бүгенге чорда алай мавыгу әдәбият сөючеләрне әдәбияттан читләштерәчәк кенә…

Гариф Ахунов җәсәде икенче көндә Галиәсгар Камал театры залына куелды. Аның белән хушлашырга дип, бик күп кеше килгән иде. Республика җитәкчеләре дә ул вакыйгада актив катнашты. (Дөрес, миндә ул вакыйга фотолары сакланмаган.) Аннары Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге җәмигъ мәчет муллалары аның җәсәде өстендә үз гамәлләрен кылдылар. Һәм Гариф шул ук көндә туган ягына – Арчага илтеп җирләнде. Арча зиратында алар хәзер өчәү яталар. Берничә елдан соң кызык кына әсәрләр иҗат иткән җәмәгате Шаһидә Максудова җәсәде дә иренеке янәшәсенә куелды. Ә бер-ике ел элек әтисе кебек кинәт кенә бу дөнья белән уллары Рәшит тә саубуллаша. Арча бистәсе зиратының бер өлешендә хәзер алар өчәү булдылар. Ә Арчаның үзәк урамында исә 1990 еллардан аның иҗатын һәм эшчәнлеген хөрмәтләү нәтиҗәсе булып, затлы гранит ташыннан эшләнгән нигездә аның бронза бюсты тора. Әйе, гомер буе бер-берсен хөрмәт итеп яшәгән райондашлардан дүрт кеше бюсты тора ул мәйданчыкта. Аларның әйдәп баручысы Гомәр ага Бәширов бюсты анда иң беренчесе иде.

*2020*

# КАБАТЛАНМАС ЯЗМЫШЛЫ ШӘХЕС

*(Истәлек)*

Татарстанның халык язучысы Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев белән миңа байтак кына еллар аралашып яшәргә насыйп булды. Дөрес, без бик якын дус булдык, әшнә идек дип әйтмим. Әмма бер-беребезне хөрмәт итеп яшәдек. Аның иҗаты, яшәешебезгә, милләт язмышына кагылышлы уй-фикерләре миңа якын иде. Әсәрләрен кызыксынып, даими укып барганлыгымны ул да чамалагандыр, күрәсең. «Лирон дуска, истәлеккә!..» дип бүләк иткән яңарак нәшер ителгән кайбер китаплары әле дә саклана.

Сиксәненче еллар ахырының кышкы айларында бер-ике мәртәбә Мәскәү янәшәсендәге «Переделкино» иҗат йортында да бергә туры килгән идек. Шунда мин илнең төрле тарафыннан җыелган күренекле язучылар белән аның дустанә мөнәсәбәттә аралаша алуына шаһит булдым. Мәскәүнең атаклы язучылары да: «Друг Аяз прибыл», – дип күрешә, гәпләшә иделәр. Әйе, ул бит Мәскәүдә ике еллык Югары әдәби курсларда да кемнәр беләндер бергә укыган кеше. Рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләренең дә күпчелеге шушы башкала нәшриятларында чыккан ич. Аязга аеруча якын язучылар арасында ил күләмендә танылган яһүдиләрнең ишлерәк икәнлегенә дә игътибар иткән идем. Русларның «Татар белән яһүдиләр бер токымнан инде алар» дигән бик борынгы әйтеме бу очракта расланды сыман. Татарның да бит «Акыллы кеше акыллы янына елышыр» дигән әйтеме бар. Бүгенге көндә дә мин безгә карата уңай мөнәсәбәттә булган яһүдиләрнең ишлерәк булуын бик теләр идем.

Аяз Гыйләҗев Мәскәүдә укыган елларында, бик катлаулы гомер юлы узган Мирвәли исемле кешене баш герой итеп тасвирлаган «Өч аршын җир» дип исемләнгән повестен яза. Әсәр әүвәл Казанда «Совет әдәбияты» журналында басылып чыга. Озакламыйча ул повесть Мәскәү өлкәсендә яшәп иҗат итүче милләттәшебез И. Гыйззәтуллин тарафыннан русчага тәрҗемә ителә. «Өч аршын җир» повесте башта берничә йөз мең данәдә таралучы «Дружба народов» журналында басыла. Ә 1966 елда унбиш мең данәдә аерым китап буларак нәшер ителә. Шушы әсәре өчен Аяз Гыйләҗев алтмышынчы елларда ук ил күләмендәге бер рәсми бүләккә дә лаек булган иде. Әдипнең иҗади уңышы өчен алынган иң беренче зур бүләге иде бу. Әйе, үзәк матбугатта уңай бәяләнгән бу әсәр авторга шундый бәхетле мизгелләр бүләк итте. Иҗат офыкларын ачып җибәрде.

Әмма тиздән үз ватанында – Татарстанда исә аңа пошыну хисләрен кичерергә дә туры киләчәк. Кайбер үз тәнкыйтьчеләребез һәм өлкән буын язучыларының беришесе бу повесть эчтәлеген өнәп бетермиләр. «Әсәр утызынчы еллар совет чорын каралтып

күрсәтә», – дигән фикергә киләләр. Партиянең өлкә комитеты түрәләреннән дә кемнәрдер шул фикерне хуплый. «Сталин идарә иткән елларда авторның сөргенгә сөрелүе хак булган икән» дигәндәй карашлар да ишетелгәли башлый.

Әйе, бу повестенда автор утызынчы еллар вакыйгасын гадәттәгедән кискенрәк тасвирлаган шул. Һәм «колхозлашу чорын советча бәяләмәгән әсәр»не язучыларның җыелышларында тәнкыйтьләү байтакка сузылды. Бу әсәрне шул еллар дәвамында китап рәвешенә китереп, нәшер итеп чыгармаска тырыштылар. 1974 елда Алма-Атада булганда, мин казах һәм татар повестьлары җыентыгын алмашып чыгару килешүенә кул куйдырып кайттым. Казахстанда басылачак безнең җыентык исемлегенә Аязның «Өч аршын җир» повестен да керттем. Шул хакта авторның үзенә хәбәр иттем. Баштарак ул икеләнебрәк калды. «Безнең җитәкчелек аны чыгарырга рөхсәт итмәс», – диде. «Ул җыентыктагы әсәрләрне казах дуслар тәрҗемә иткәнче, ике-өч ел үтәр, карашлар үзгәрер», – дидем ул вакытта. Шулай булды да. «Татар повестери» җыентыгы 1979 елда нәшер ителде. Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев һ. б.ларның әсәрләре тупланган ул җыентык Казахстанда уңай кабул ителде. Аяз үзе дә бу катлаулы елларда авыр хисләргә артык бирешмичә, әдәби эшчәнлеген дәвам иттерә алды. Ике-өч елга бер яңа хикәя, повестьлары, пьесалары китап рәвешен алып, укучылары кулына ирештерелә торды…

Инде илдә И. В. Сталин һәм фикердәшләре идарә иткән дәвергә, Аяз Гыйләҗевнең хаксызга рәнҗетелеп, берничә елга «сөргенгә сөрелү» вакыйгаларына да тукталып үтик.

Аязның ул еллардагы катлаулы, сикәлтәле тормыш юлын күздән кичерик. Татар халкының яраткан «Сарман» җырына үрнәк булган Сарман бистәсе урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Аязны Зәй районының яшьләр белән эшләү комитетына билгеләләр. Бик җаваплы эш инде ул. Андый вазифаны үтәргә, гадәттә, яхшы билгеләренә генә укыган, башкаларга үрнәк булырдай тәрбияле һәм алдынгы карашлы яшьләрне генә җәлеп итәләр иде. Үз ишләре арасында Аяз Гыйләҗевнең җитәкчелек абруе да, иҗтимагый-сәяси җитлеккәнлеге дә югары була – үзенә йөкләнгән вазифаны ул ике ел башкара. Егерме яше тулгач, 1948 елда ул Казан дәүләт университетына укырга керә. Сугыштан соңгы бик авыр еллар. Сыйныфташ студентлар арасында тормышның авырлыкларын татыган сугыш чоры балалары да, утлы-давыллы яу кырыннан кайткан өлкәнрәк буын вәкилләре дә була. Әлбәттә, алар кичке ял сәгатьләрендә үзара әңгәмәләшә дә, бәхәсләшә дә дигәндәй. Шунда көндәлек тормыш вакыйгаларына, илдәге сәясәткә карата үз фикерләрен дә белдерәләр. Илдә барган сәясәткә бәйле рәвештә репрессияләнгән дистәләгән татар язучыларын да, хаксыз рәвештә сөргенгә сөрелгән авыл муллаларын да

искә алгалыйлар. Тоткын язучыларның әсәрләрен сагыну кебек «гөнаһлы» сөйләшүләр дә булгалый, әлбәттә. Ә кемнәрдер шундый зарарлы фикер алышулар булгалаганы турында кирәкле оешмаларга җиткереп тора. Һәм 1950 елның декабрендә бер төркем студент кулга алына. Алар арасында тынгысыз җанлы студент Аяз Гыйләҗев тә була. Аларны «Совет хакимиятенә каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә» гаепләп, төрлесен-төрле якка – ГУЛАГ лагерьларына озаталар. Аяз Гыйләҗев Казахстанның Караганда шәһәре тирәсендәге шахтага эләгә. Ул җиде елга хөкем ителгән була. Ил-мәмләкәт башлыгы И. В. Сталин вафат булып, ел ярымнар чамасы вакыт үткәч, «гаепсезгә хөкем ителгән» дигән карар чыгарып, Аяз каләмдәшебезне азат итәләр. Ул Казанга кайта, университетта укуын дәвам иттерә. Һәм бик актив рәвештә иҗат эшенә керешә. Ике-өч ел дәвамында аның берничә хикәясе басылып чыга. Мин 1961 елның башында Казанга килеп урнашканда, инде аның ике хикәяләр тупламасы басылып чыккан, бер пьесасы Г. Камал театры сәхнәсендә бара иде. Аның иҗаты белән танышуым шушы әсәрләрдән башланды. Аннары «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (повестьлар), дустым һәм остазым Хәсән Сарьян сүз башы белән нәшер ителгән «Мең чакрым юл» (повестьлар), «Җомга көн, кич белән» (повестьлар, авторның «Лирон дуска!..» дип язылган җылы теләкләре белән бүләк ителгән китап), «Яра» (роман һәм повестьлар) һ. б. китапларын укыдым. Ләкин нишләптер Аязның «сөрген» язмышын тулаем чагылдырган «Йәгез, бер дога» роман-хатирәсен генә укымаган булганмын икән.

Аның һәр әсәренең төп фикере бит халкыбыз язмышының киләчәге өчен борчылуга нигезләнгән. Күпсанлы хикәя, повесть һәм романнары белән таныш һәркемнең күңелендә шундый ук уй тугандыр дип беләм. Шушы юнәлештәге уй-фикерләренең тәңгәллеге ягыннан мин Аязны икенче бер классик әдибебез Әмирхан Еники белән тиң күрәм. Хәер, алар үзләре дә бер-берсен бик якын күрә иде шул.

Әлбәттә, егерменче гасырның икенче яртысында – Бөек Ватан сугышының афәтеннән соң әдәбият мәйданына килгән, Аязга чордаш булган башка күренекле язучыларның төп иҗат юнәлеше дә үз халкының язмышын тасвирлауга бәйле иде. Булачак халык язучылары Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Мөхәммәд Мәһдиев, Миргазиян Юныс, чордашларыннан иртәрәк вафат булган Тәүфыйк Әйди – дөнья буйлап сибелгән татар халкының көндәлек тормышын, уңганлыгын-булганлыгын да, киләчәккә омтылышын да әдәбият укучысының күңеленә хуш килердәй итеп сурәтләп бирделәр. Һәммәсенең иҗаты халкыбыз һәм хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде. 1958 елда Татарстан АССРда күренекле иҗат әһелләренең хезмәтен бәяләү өчен, Габдулла Тукай исемендәге диплом һәм акчалата бүләк бирү тәртибе кертелгән иде. Шундый беренче бүләк бөек шагыйребезнең фаҗигале тор-

мышын чагылдырган «Тукай» романы өчен, язучы Әхмәт Фәйзигә тапшырылды. Аннан соң шундый зур бүләккә ия булучылар арасында шагыйрь, драматург Нәкый Исәнбәт, проза әсәрләре осталары Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гариф Ахуновлар, олуг шагыйрьләребездән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гамил Афзаллар бар. Кайбер елларда бу бүләк язучыларга тапшырылмаган. Аяз Гыйләҗев исә Габдулла Тукай исемендәге зур бүләккә 1983 елда – каләм әһелләренә унсигезенче мәртәбә бирелгәндә лаек булды. Ә тагын берничә елдан соң инде ул Татарстан Республикасының халык язучысы исемен дә алды.

Бүгенге көндә аның әсәрләре, даими рәвештә нәшер ителеп, укучылары өстәлендә өстәлә тора. Пьесалары Татарстан Республикасының күпчелек театрларында уйнала. Башкортстан театр сәхнәләрендә дә куела. Берничә проза әсәренең төрек теленә тәрҗемә ителгәнлеге, төрек телле укучы кулына барып ирешкәнлеге дә мәгълүм. 2017 елда исә «Йәгез, бер дога» роман-хатирәсе Венгриядә венгр теленә дә тәрҗемә итеп басылды. Киләчәк буын укучылары да аның әсәрләрен үз итәр, татар халкының авыр язмышын һәм киләчәк өметләрен чагылдырган вакыйгаларга битараф калмас дип уйлыйм.

Иҗади яктан гына түгел, көндәлек тормышка кагылышлы мәсьәләләрдә дә безнең өйдә Аязны һәм аның гаиләсен өлге итеп күрергә күнеккәнбез. Җәмәгате Нәкыя белән икесе дә укымышлы, зыялы гаиләдә тәрбияләнгән шәхесләр алар. Өч улларын да шул рәвешле тәрбияләделәр. Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев – бүгенге көндә ил күләмендә танылган тарихчы галим. Россиядә һәм Европа илләрендә оештырылган гыйльми җыен, конференцияләрдә катнаша. Берничә ел инде Татарстан энциклопедия институтын бик уңышлы җитәкли. Ә энесе Мансур Гыйләҗев Идел-Урал төбәге өлкә-вилаятьләрендә танылган драматург. Пьесалары Казан, Уфа, Чаллы, Әлмәт һ. б. шәһәр театрларында куела. Соңгы дәвердә кино өчен сценарийлар иҗат итүче буларак та танылa башлады. Иң кечеләре – Рашат Гыйләҗев исә башка юлны сайлый, медицина институтын тәмамлап, табиб була. Казан дәүләт университетын тәмамлаган Нәкыя Гыйләҗева байтак еллар мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы иде. Иренең иҗат җимешләрен тәүге укучы һәм беренче тәнкыйтьчесе дә булды. Аязы вафат булганнан бирле аның иҗади мирасын тәртипкә китерүче-туплаучы да, нәшер итү эшләрен башкаручы да. Бүгенге көндә ул иренең әсәрләренең алты томлыгын, аерым басмада роман һәм повестьларын барлап чыгарды. Әдипнең каләмдәшләре һәм укучылары белән язышкан күпсанлы хатларын да тәртипкә китереп нәшер итте.

Бу гаиләнең өлкән буын вәкилләре үрнәк булырдай шәхесләр. Аязның әти-әнисе дә гомерләрен балалар укытуга багышлаганнар. Ә Совет хакимияте чоры укытучысы Мирсәет Гыйләҗевнең

ата-бабалары исә үз төбәкләрендә алдынгы карашлы мулла һәм укымышлы хәлфә буларак дан казанганнар.Варислары хәзер аларның шәҗәрәсен барлау турында уйлана дип беләм. Гасырларны тоташтырган токым шәҗәрәсен һәм борынгы язулы китапларны Мирсәет ага 1950 елларда, улын кулга алгач, ягып юк иткән була. Бәла артыннан бәла килмәсен дип эшләгәндер инде ул эшне. Бер Ходабыз киләчәктә безнең барыбызны да андый бәла-казалардан саклый күрсен дигән теләктә калам.

*2020*

# ТАТАР, ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЛАРЫ БЕЛГЕЧЕ

*(Очерк)*

Габдрахман Сәгъди Уфа белән Чиләбе губерналары аралыгындагы Златоуст өязенә кергән Таймый авылында Гайнан мулла гаиләсендә 1889 елның 26 мартында туган. Хәзерге Башкортстан картасында Таймеево дип билгеләнгән авылдан икенче бер бөек шәхесебез – Нәкый Исәнбәт туган Нәсибашка нибарысы илле чакрым чамасыдыр. Башлангыч белемне атасы мәктәбендә үзләштергәннән соң, 1902 елда Габдрахман Троицк каласындагы «Рәсүлия» мәдрәсәсенә барып керә. Зәйнулла ишан мәдрәсәсен тәмамлаучыларның гарәп, фарсы, төрек телләрен һәм көнчыгыш әдәбияты үрнәкләрен яхшы үзләштергәнлекләре билгеле. Шул мәдрәсәне 1904 елда тәмамлаган Габделбари Батталның, фиргавеннәр иленә аяк баскач ук, Каһирәдә гарәпчә чыгучы газетада эшли башлаганлыгы мәгълүм. 1908 елда «Вакыт» газетасында эшләргә дип Оренбургка кайтканда, аның биштәрендә гарәпчәдән тәрҗемә иткән ике күләмле китап кулъязмасы – Җамалетдин Әфганиның «Ислам философлары» һәм Сирияле Никола Хаддатның ике томнан торган әдәби әсәре була.

«Рәсүлия» тулай торагында яшәү дәверендә Габдрахман анда укучы казах шәкертләре белән аралаша, казахча сөйләм телен дә бераз үзләштерә, казах әдәбияты үрнәкләре белән дә таныша. Бәлки әле, нәкъ шушы елларда бу шәһәрдә әлеге кардәшләребез телендә чыга башлаган «Айкап» журналы редакциясенә килгәләп тә йөргәндер. Ул мәҗмуганы нәшер итүче дә үз милләтебез вәкиле булган ич.

«Рәсүлия»не тәмамлагач, Габдрахман да 1908–1911 елларда Төркиядә яши. Истанбул дарелмөгаллиминен (укытучылар әзерләү институтын) тәмамлый. Шунда укыганда, ул да төрекчәдән бер әдәби әсәрне тәрҗемә итә. Илебезгә кайткан елында ук, аның Оренбургта нәшер ителүче «Шура» журналында күләмле генә «Шагыйрьләр вә шигырьләр» мәкаләсе басыла (1911, № 23).

Шул елда ук ул казах иленең Оренбург губернасына чиктәш Актүбә каласындагы татар-рус мәктәбендә укыта башлый. Актүбә ул елларда татарларны үзенә җәлеп иткән бер яңа шәһәр була. Әйе, ике гасыр аралыгында төзелә башлаган Оренбург – Ташкент тимер юлын сафка бастырган еллар ич ул. Бу юл 1905 елда төзелеп беткәч тә, һәр зур станциядә эшләүче буфет, рестораннарны тотучылар да безнең сәүдәгәрләр булган, дип тә сөйлиләр. Актүбәнең Татар бистәсе янәшәсендә үк Акчурин байларның бер вәкиле төзеткән зур тегермән дә эшли. Шул ук бистәдә татар, казах балалары өчен мәктәп тә ачыла. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенең абруйлы хәлфәсенең улы Шамил Усманов та, һөнәри мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын нәкъ шушы тегермәннән башлап җибәрәчәк. Анасына туган тиешле Акчуриннар тегермәнендә аның 1914–1916 елларда эшләп киткәнлеге билгеле.

Г. Сәгъди монда укытырга килгәндә, тагын бер булачак әдибебезнең Актүбәдә яшәгәнлеге мәгълүм. Яшүсмер Кави Нәҗми монда 1910–1916 елларда әлегә бердәнбер татар-рус мәктәбендә укый. Бәлки, яңа укытучы Габдрахман ярдәме беләндер, монда ул беренче иҗади адымнарын ясый. Аның беренче уңышлы әсәре буларак кабул ителгән «Көз» шигыре шушы елларда туа. Монда укыганда, ул табигатькә багышлы шигырьләре белән танылган шагыйрь А. В. Кольцов иҗатын үз итә. Аның А. С. Пушкин үлеменә багышлы «Урман» шигырен татарчага күчереп, мәктәп сәхнәсеннән дә сөйли, дип әйткән иде миңа бервакыт Сәрвәр апа Әдһәмова.

Шул ук елларда монда тагын бер шагыйрь күренеп ала. Арча якларындагы Үртәм авылыннан килгән, шигырьләрен 1906 елдан соң төрле тарафта чыгучы татар газеталарына җибәреп бастыргалаган Сәйфелгабит Мәҗитов була ул. Татарстанда әлегә аны белмибез диярлек. Чөнки ул шуннан соң Каракалпакстанга күченеп киткән. Шигырь, проза, драма әсәрләрен каракалпакча язып, шул кардәш халык әдәбиятының классигына әверелгән. Күптән түгел мин аның бер шигырь җыентыгын Арча музеена тапшырдым.

Шушы мәгълүмат белән танышкач, укучыбыз яшь Габдрахман хәлфәнең нинди мохиткә килеп эләккәнен чамалар. Ләкин бу тынгысыз җан иясе бер урында озак тормаган шул. 1913 елда инде без аның, бәхет эзләп, иркен казах иленең икенче тарафына – Кытай мәмләкәте белән чиктәш җирләргә барып чыкканлыгын беләбез. Ярты гасыр элек кенә әлеге чик буена якын җирдә рус һәм татар атлы казаклары төзегән Верный каласында да (1921 дән соң – Алма-Ата) татар бистәсе була. Монда да Г. Сәгъди үз милләте исемен йөртүче бистә мәктәбендә укыткандыр. Ул дәвердә казах кардәшләребез илендәге барлык мәдрәсә-мәктәпләрдә дә төрки телле төрле милләт вәкилләре бергә укыган. Әйтик, ул замандагы Верный каласында уйгырлар да яшәгән.

Ә 1917 ел вакыйгаларын инде хәлфә Габдрахман Бөгелмә каласында каршылый.

Әйе, аның Верный каласыннан да ике-өч елдан соң ук китүе мәгълүм. Аннан китү сәбәбе ачыкланмаган. Россия тарафыннан илле-алтмыш еллар чамасы элек кенә яулап алынган бу тирәләрдә ул вакытта бик тынгысыз була шул. Буш яткан җирләр күп дигән сылтау белән монда чит-ят кешеләрне күпләп китерә башлыйлар. Мондый хәл бигрәк тә патша Россиясенең көнбатыш тарафында 1914 елгы зур сугыш башлангач та көчәя. Өстәвенә мондагы ир затларын, тыл хезмәтен үтәргә дип, Урал, Себер якларына күпләп озатулар башлана. Ишле балалы бик күп гаиләләр авыр хәлдә кала. Һәм 1916 елда Җидесу төбәге казах һәм кыргызлары патша хакимиятенең кысуына каршы баш күтәрә. Аларга Урта Азиянең башка төбәкләрендәге халыклар да кушыла.

Әйе, Урта Азия өлкәләрендә бу вакытта эшләр бик хәтәр була. Әмма нәкъ шушы вакыйгалар тиздән көтелмәгән нәтиҗә бирәчәк. Бу төбәкнең кайбер тарафларында Совет хакимияте тәртипләре шактый җиңел һәм тиз урнаштырылачак. Һәм патша Россиясе биләмәсендә беренче буларак монда автономияле совет республикасы оештырылачак. Хәзерге Үзбәкстан белән Кыргызстанның – төньяк, Казахстанның көньяк биләмәләрен берләштергән Төркестан Автономияле Совет Республикасы 1918 елның 30 апрель карары белән барлыкка килә. Аның башкаласы итеп Ташкент шәһәре билгеләнә. Республика башлыгы вазифасын үтәү казах Турар Рыскуловка, партия җитәкчелеге эше элекке «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкерте, 1915 елдан большевиклар сафында торучы милләттәшебез Кәрим Хәкимовка йөкләнә. Турар 1916 елгы вакыйгаларның башында торучыларның берсе була. Ә Мәгариф халык комиссары вазифасын үтәргә тиздән монда безнең Шәһит Әхмәдиев җибәреләчәк.

Бу вакыйгаларның барысы да Габдрахман Сәгъди биографиясенә дә кагыла. 1921 елның җәендә ул да Ташкент каласына килеп урнаша. Берәүләр аны монда чакырып китерәләр дип яза. Икенчеләре исә 1919 елдан ВКП(б) әгъзасы саналган һәм укытучы-тәрбияче буларак абруй казанган шәхесне Мәскәүдән килгән әмер нигезендә анда җибәрәләр дигән фикер әйтә. Мәсәлән, Турар Рыскулов биографиясе җирлегендә аңа багышлап роман язган казах әдибе Шерхан Мортазаев бер әңгәмә вакытында миңа: «Большевик Әхмәдиевне дә, Сәгъдине дә, Кәримовны һ. б. ларны да безгә үзәктән алынган карар нигезендә җибәргәннәр», – дигән иде. Кызганыч ки, аның романын без 1970–1980 елларда тәрҗемә итеп чыгара алмадык. Тулы эчтәлеге безгә мәгълүм түгел. Анда, бәлки, шул ук 1919–1921 еллар аралыгында яңа Совет хакимиятен ныгыту өчен җибәрелгән башка милләттәшләребез дә искә алынган булгандыр. Мәсәлән, Касыйм шәһәрендә туган, 1916 елда Мәскәүдә коммерция институтын тәмамлаган Ибнеәмин Янбаев. 1920 елдан аның монда Мәгариф комиссариатында

эшләгәнлеге, һәм шул елда ук Габдулла Тукайның берничә шигыре тупланган җыентыкны рус телендә чыгарганлыгы мәгълүм. Шактый тирән эчтәлекле кереш мәкаләне дә үзе язган булган. Әмма ул китапчыкка багышланган беренче мәкаләләр 1985 елларда ук чыккан булуга карамастан, бездә әле бөек шагыйребезнең тәүге тапкыр рус телендә Ташкентта басылган ул китабын нишләптер Казанга кайтара алганыбыз юк.

Шул ук 1920 елда Ташкентта үзбәк һәм казах-кыргыз бүлекләреннән торган Шәрык халык мәгарифе институты да ачыла. Шул төбәктә гомер иткән татар яшьләре дә анда укый. Аның директоры итеп шулай ук милләттәшебез Габдулла Мостакаев билгеләнә. «Шура» журналында шигырь, хикәя һәм мәкаләләре еш күренгәләгән иҗади рухлы бер шәхес. Аның «Ташлап китте», «Үлем генә көт» кебек хикәяләре, «Швециядә халык мәгарифе торышы» ише мәкаләләре заманында бик күпләрнең күңеленә хуш килгән. Мөгаен, ул шушы уку йортын нигезләүчеләрнең берсе булгандыр. Һәм аңа үрнәк итеп, 1919 елда Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе җирлегендә оештырылган халык мәгарифе институтын алгандыр. Муса Җәлил һәм аның иптәшләре дә иң әүвәл нәкъ шул уку йортын тәмамлап чыгалар ич. Габдрахман 1921 елда Ташкентка килгәч (1920 дә үк килгән дип язучылар да бар), иң әүвәл шушы институтта укыта башлый. 1917 елдан Бөгелмәдә яшәгән Г. Сәгъдине монда кем җибәргән? Яисә кем чакырып китергән? Ш. Әхмәдиев белән Г. Мостакаевмы? Кәрим Хәкимовмы? Әлегә билгесез.

Г. Сәгъди монда Мәгариф халык комиссариатында да эшли, 1920 елда ачылган Төркестан университетында да (соңрак Урта Азия университеты) укыта. Моңа чаклы инде аның укыту, тәрбия мәсьәләләренә кагылышлы берничә китабы нәшер ителгән була. Үзбәкстан галиме Рәхим Мөкимовның остазына багышланган истәлек язмасына да күз төшереп алыйк. Тәүге тапкыр Ташкентта яшәү дәверендә: «Остазым казах халкының мәшһүр акыны Абай Конанбаев, үзбәк әдәбияты классиклары, шул исәптән Алишер Нәвои, милләттәше Габдулла Тукай иҗатларын тирәнтен өйрәнә, аларга багышлап хезмәтләр бастыра, – ди Рәхим әкә. – Әбдерәүф Фитрәт белән бергә «Үзбәк әдәбияты тарихы» китабын (1923) язалар», – ди. Әйе, шул ук елларда Г. Сәгъдинең «Безнең юл» журналының өч санында «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» дип исемләнгән күләмле хезмәт бастырганлыгы да безнең китапларда теркәлгән.

Әлеге халык мәгарифе институты ачылган көннән шунда укыган һәм Габдрахман агалары җитәкләгән әдәби түгәрәккә йөргән булачак композитор Латыйф Хәмиди истәлекләрен дә искә төшереп үтик. «Ул чорда әле мин шигырьләр дә яздым, – дип сөйләгән иде ул миңа. – Аларны Габдрахман хәлфә бик ошаткан иде. 1921 елның көзендә бугай, безнең төркемгә казах әдибе Мохтар Әүэзов та килеп кушылды. Шул дәвердән бирле без аның белән

гомерлек дус булдык. Ике мәртәбә мине Алма-Атага чакырып китереп, казах кардәшләр даирәсенә җәлеп итүче дә ул иде. Үзбәк төркемендә безнең белән бергә булачак олпат шагыйрь Гафур Голәм дә укыды. Шул ук елда, ачлыктан качып, Оренбургтан килгән зур төркем арасында Һади Такташ та бар иде. Ул безгә еш килеп йөри, дәресләргә дә кергәли, әдәби түгәрәк утырышларында да катнаша иде. Алар Гафур белән бик дус булдылар. Без берничә санда «Белем йорты» журналын туплап чыгарган идек. Анда Такташ белән Гафурның да, Мохтарның да, минем дә беренче тәҗрибә үрнәкләребез бар иде. Бәлки, аның кайбер саннары кемдәдер сакланадыр да әле. Мостакаев абзыйны Казанга кайтып китте, диделәр. Ул журнал аңарда сакланмадымы икән, кызыксын әле», — дигән иде Латыйф ага. Монда кайткач кызыксындым, әмма андый мәҗмуганың кайдалыгын белүче булмады.

Гафур Голәмнең шул елларда ук Һади Такташ шигырьләрен тәрҗемә итә башлаганын һәм 1933 елда аларны Ташкентта бер китапка туплап чыгарганын да әйтеп үтү кирәктер.

Әйе, 1921—1925 елларда Ташкентта яшәгәндә, Г. Сәгъди берничә урында укыта. Һәм Төркиядә укыган еллардан башланган иҗади эшчәнлеген дә бик актив дәвам иттерә. Үзбәк, казах, татар телендә чыгып килүче матбугат битләрендә аның шул тел ияләре әдәбиятына багышлы мәкаләләре басыла. Шул ук елларда ул үзбәк телендә «Гамали вә назари әдәбият дәресләре» хезмәтен дә яза. Ул хезмәт 1925 елда китап рәвешен ала. Ун еллар элек татар әдәбиятына багышлы шундый хезмәт язган Галимҗан Ибраһимовка ул китап бик ошый. Китапның чыгуын хуплап, әдип «Безнең юл» журналында мәкалә бастыра, дип хәбәр итә галимә Ч. Куракова.

Әдәбият галименең 1925 ел ахырларында Казанга кайту вакыйгасын язучы Гөлсем Мөхәммәдова китабыннан укып белә алабыз («Олы юл», 1994. 165—166 б.). Өммегөлсем апа — Галимҗан Ибраһимовның җәмәгате. Аның әлеге китабы олуг әдибебез тормышын чагылдыра. Аларның Комлев урамындагы өендә әдипләр, галимнәр дә, дәүләт җитәкчеләре дә еш була. Шунда алар киләчәктә башкарыласы эшләр турында киңәшә, фикер алышалар. «Ул кичтә бездә ТАССР Халык комиссарлары Советы рәисе Хаҗи Габидуллин белән Мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев иделәр... Тел, әдәбият мәсьәләләренә күчтеләр. Галимҗан әдәбият тарихын яздыру эшен Габдрахман Сәгъдигә тапшыру кирәклеге турында сүз катты. Шәһит баштарак: «Читтән кеше чакырып торганчы, бу эшне Газиз Гобәйдуллин белән Гали Рәхимгә тапшырыйк», — дигән иде. Соңрак уртак фикергә килделәр. Габдрахманны Казанга чакырырга һәм аңа «Татар әдәбияты тарихы»н язу эшен тапшырырга булдылар», — дип хәбәр итә Гөлсем апа.

Шул карар нигезендә Габдрахман ага тиздән Казанга кайтарыла. Аңа эшләү шартлары тудырыла. Һәм бер ел үтмәстән

300 битле «Татар әдәбияты тарихы» китабы басылып та чыга. Галим бер үк вакытта, әлбәттә, укытучы буларак та актив эшли. 1929 елда аңа «Казан педагогия институтының профессоры» дигән дәрәҗәле исем бирелә. Әмма шул ук елларда аның нәселдән килүче мулла баласы булуын да, эшчәнлегенең бер өлешенең читтә узганлыгын да искә ала башлыйлар. Г. Толымбайский, Ф. Мөсәгыйт һ. б.ларның аның гыйльми эшчәнлегенә, иҗади эзләнүләренә тискәре караш тудырырдай мәкаләләре басылып чыга. Һәм шундый эзәрлекләүләр башлангач, 1930 елда ул янә Урта Азия якларына чыгып китә.

Ул вакытта инде монда да шактый гына үзгәрешләр булган икән. Габдрахман моннан киткәндә өч-дүрт берәмлек-автономияне тәшкил иткән Үзбәкстан 1926 елдан бердәм дәүләткә (Үзбәкстан ССРга) әверелгән була. Берара аның башкаласы итеп Сәмәркандны сайлаган булганнар икән (1930 елгача). Шул сәбәпле 1927 елда Сәмәркандта дәүләти дәрәҗәдәге университет та ачылган. Һәм шунда Оренбург янәшәсендәге Каргалыдан чыккан, атаклы Ишми ишан кызына өйләнгән Кәрәмәтулла Айдаровның да укытып йөргәнлеген Ташкентта аңа кемдер хәбәр итә. Г. Сәгъди дә шуннан соң Сәмәркандка китә. Алар анда очрашып, дустанә гомер итәләр, дип сөйләгән иде миңа 1984 елда шагыйрь Һибәтулла Салихов нәселеннән булган Кәримә апа. Һибәтулла хәзрәтнең беренче хатыны да шул «мирза Айдаровлар» токымыннан була. Кәримә апа шуларның оныкчасы иде.

Дөреслектә ничек булгандыр. Шунысы хак – Г. Сәгъди бу баруында Сәмәрканд университетында укыта башлый. Тумыштан таҗик булган, Үзбәкстанда гомер иткән филология фәннәре докторы Рәхим Рәҗәп улы Мөкимов истәлекләренә әйләнеп кайтыйк. «Остазларым арасында мин аеруча зыялы фән докторы, профессор Габдрахман Сәгъдине олы хөрмәт белән искә алам. Ул безгә – чордашларым Шәрәф Рәшидов, Гафур Голәм, Әсгать Мохтар, Рәсүлҗан Әхмәди һ. б.ларга үзбәк әдәбияты тарихыннан дәрес укытты. Урта буйлы, кара коңгырт чәчле һәм күзлекле урта яшьләрдәге бер татарның безне укытуына әллә ни хәйран калмаган идек. Хәйран калдырганы шул – татар милләтеннән булган бу укытучының саф үзбәк телендә үзбәк әдәбияты тарихын гына укытуы түгел, ә Шәрыкның шушы төбәгендә яшәүче күп кенә халыкларның әдәбият һәм мәдәният тарихларын да су кебек эчүе иде. Ул рус, үзбәк, гарәп, фарсы, грек һәм кытай галимнәренең дөньяга карашы белән дә таныш һәм шул хакта иркен фикер йөртер иде. Белүебезчә, профессор дәрәҗәсенә ул 1929 елда ук лаек булган, бик катлаулы тормыш юлы узган. Ә безне укытканда, ул якын тарих белән генә чикләнмәде. Нәвои, Ибне Халдун, Тәфтәзани, әл-Болгари кебек Шәрык галимнәре, грек Әфләтун (Платон), Сократ фикерләре белән дә таныштырыр иде. Әбүгалисина, Фәраби, Бируни, Җами, Заһретдин Бабурлар язып калдырган мирас

белән дә безне ул кызыксындырды. 1941 елның яз башында, Алишер Нәвоиның тууына 500 ел тулу көннәренә хәзерлек вакытында, безнең Үзбәкстан дәүләт университетында да җанланыш булды. Һәркем кабат Нәвои иҗатын өйрәнде, күмәкләп укулар башланды. Алишер Нәвои иҗатына багышланган мәкалә һәм хезмәтләрнең элгәреләре укытучыбыз Габдрахман Сәгъдидән иде», – дип яза Р. Мөкимов.

Ул вакытта инде профессор Г. Сәгъди «Алишер Нәвои иҗаты – үзбәк классик әдәбиятының бөеклеге» дигән булачак докторлык диссертациясен әзерләргә керешкән була. («Аның машинкада басылган нөсхәсе Мәскәүдә, В. Ленин исемен йөртүче көтепханәдә саклана», – дигән хәбәрем бар, дип яза Р. Мөкинов.) Ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, күп нәрсә хыялга ашмый кала. Бу диссертацияне яклау вакыйгасы да 1949 елгача сузыла. «Ватан сугышы барганда, безнең университетны Ташкенттагы Урта Азия дәүләт университетына куштылар. Профессорыбыз Иске шәһәрнең Лабзак мәхәлләсендә яшәде. Укытырга безнең тулай торак янәшәсеннән җәяү йөрер иде. Чөнки трамвайга утырырлык түгел, кешеләр аңа асылынып баралар иде, – дип яза Рәхим әкә. – Ул елларда мин филология факультетының деканы булдым. Олуг остазым белән дуслыгыбыз һичбер вакыт өзелмәде... Күптән түгел Сәмәркандка командировкага бардым. (1980 елларның ахырлары искә алына бугай.) Анда Габдрахман аганың соңгы хатыны Бәнат апаны эзләп таптым. Улы Рома белән яши икән. Остазымның каберен барып күрдем, чәчәк-гөлләр салдым. «Җаның җәннәттә булсын, остазым!» дип теләдем».

Безнең галимнәргә дә ул тарафка командировкага барып кайту зыян итмәс иде. Сәмәрканд, Бохара, Ташкентише тарихи калалар зиратларында татарның йөзләгән бөек затлары безнең килеп дога кылуны көтеп ята ич.

Профессор, филология фәннәре докторы Габдрахман Сәгъди 67 яшендә, 1956 елның ноябрендә Сәмәркандта вафат була.

Кәрәмәтулла Айдаров Сәмәрканд университетында укытканда, аның Заһретдин Бабур эшчәнлегенә һәм иҗатын барлауга багышлы зур хезмәт язган булуын да миңа Каргалы авылында хәбәр иткәннәр иде. Аның иҗаты һәм фәнни эшчәнлеге әле безнең галимнәр тарафыннан барланмаган, ахрысы. Аның исеме безнең энциклопедия томнарында да теркәлмәгән. Хәер, Урта Азия республикаларында яшәп, шактый гына фәнни-гамәли уңышларга ирешкән, әмма үз милләте тарафыннан танылмаган шәхесләребез әле байтак бугай.

*2018*

# МИЛЛӘТЕМ ДИП ЯШӘДЕ

*(Истәлек)*

Татар халкының милли рухлы, көрәшче улларыннан берсе булган әдип Тәүфыйк Рамазан улы Әйделдиновның тууына 2011 елда 70 ел тулды. Нәкъ ун ел элек, апрель аенда без аның белән мәңгегә хушлашкан идек. Аның алай иртә китүенә заман чирләре дә, «зәхмәтле күңел юаткычлар белән мавыгу» да сәбәпче булмады. Фәкать үзе теләп үз өстенә алган авыр йөк аны шулай арабыздан иртәрәк алып китте. Чама белән кыска гомерендә ул күпләребез икеләтә озынрак яшәп тә эшли алмастайны эшләп китте. Узган гасырның соңгы утыз-утыз биш елында ул, үз-үзен аямастан, байтак илләр гизеп, күп йөрде, күп язды. Татар милләтенең киләчәген, язмышын кайгыртып, җан атып яшәде. Күп йөрде, күпне күрде. «Мәскәү, Рязань тирәләреннән башлап Уралтау буйларынача сибелеп утырган татар авылларының күбесендә булдым. Җәяүләп көненә иллешәр-алтмышар, велосипедта йөргәндә, йөздән артыграк чакрым юл үтә идем. Урал тауларының иң көньяк почмагында урнашкан син үскән авылда да булдым. Сәлам әйттеләр. Анда «Казан утлары» белән «Азат хатын»ны алалар, укыйлар икән. Шуңа сөендем», — дип сөйләгәне хәтеремдә. Әйе, халкы мәнфәгатен кайгыртып яшәү, татар матбугатының ерак авылларда аз таралуына, мәктәпләрдә милли телне укытуның кими баруына үртәлү, борчылу — аңа хас сыйфатлар булды. Аның яшәү девизын без кайчандыр үзе иҗат иткән дүртьюллык шигырьдән дә укып белә алабыз:

Иң мөкатдәс, мәгънәви яшәлә торган гомер —
Тарихи Ватанда узганы,
Иң зур мактауга лаек хезмәт —
Туган халкыңа багышланганы!

* * *

Тәүфыйк Әйди (әдәбият-мәдәният дөньясына ул шул исем белән мәгълүм) белән беренче танышуым хәзергедәй истә калган. Язучылар оешмасында эшли башлавымның тәүге айлары иде. Шагыйрь Салих Батталдан кергән гаризаны тотып өйләренә киттем. «Егерме елдан артыграк хәрби очучы булдым, японнарга каршы сугыштым. Бер бүлмәле кетәктә яшим, иркенрәк фатир бирегез», — дигәнрәк сүзләр язылган иде ул гаризада. Шул «кетәк» һәм анда яшәүчеләр турында тасвирлама язу өчен җибәрелгән идем. Октябрь урамындагы гадәти бер бүлмәле фатирга килеп керсәм — түрдә өч кеше тәмләп чәй эчеп утыра. Салих аганы, әлбәттә, танып белә идем. Сөйкемле генә ханымның аның хатыны икәнлегендә шик юк. Ә кем соң ул кызып-кы-

зып нидер сөйләп утыручы яшь ир? Ишетеп тә, укып та белә идем – Салих аганың беренче хатыныннан, атаклы парашютисткадан туган улы да бар. Тик ул бит Мәскәүдә яши. Татарча белүе дә икеледер. «Кем булыр бу?» – дип, табын читенә килеп утырдым. Шунда гына Салих ага: «Бу Тәүфыйк була, яшь язучы», – дип таныштырды.

Табындашлар әңгәмәне дәвам итте. Әңгәмә, нигездә, Совет илендә төрки халыклар мәнфәгатенә әһәмият бирелмәве, бигрәк тә татар халкына карата ниндидер чикләүләр яшәп килүе турында барды. Ара-тирә Мәдинә ханым да сүзгә кушылып куйгалый: «Безнең Опера театрында да әнә милли репертуарны кысалар», – дип, үз дөньясына бәйле мохиттән мисаллар китергәли иде. Халкыбызның киләчәк язмышына бәйле борчулар белән яшәгән бу гаиләдән киткәч тә, Тәүфыйк белән тиз генә аерылышмадык. Уртак уй-фикерләр, уртак язмышлар хакында сөйләшә-сөйләшә, Восстание урамын бер генә урап әйләнмәгәнбездер.

Икебез дә казах, үзбәк әдәбиятларын башка чордашларыбызга караганда якынрак кабул итәбез икән. Соңыннан, очрашкан саен, шул хакта да гәпләшеп алыр идек. Илленче-алтмышынчы елларда әле безнең кайбер әдәбият әһелләре дә «казахның революциягә кадәр язма әдәбияты булмаган» дип, үзен белдеклегә санаган кайберәүләр исә «надан үзбәкләрне без белемле иттек» дип, революциядән соңгы чорларда ачылган ликбезларны искә алып сөйләр иде. Әйе, ул елларда әле безнең чордашлардан күпчелеге «надан сартлар» иленә – Бохара, Сәмәркандларга барып, белем эстәп йөргән «муллаларыбызны» искә алмаска тырыша, матбугатта ул хакта бик аз языла иде шул.

Ә Тәүфыйк белән икебезнең язмышлар исә ул кардәш халыклар иле белән бәйле булып чыкты. Аларның әдәбият үрнәкләре белән дә бераз таныш, телләре дә безгә якын иде. Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, мин дүрт кыш Казахстанда укыдым. Рус телле уку йортында укысам да, төрле телләр белән балачактан кызыксынуым сәбәпле, казах кардәшләр сөйләме дә колакка әзмәз кергән иде. Үзбәк сөйләме белән мавыгып алуым да шул чорга туры килә. Э. Войничның «Овод» китабын укыган язда ук, кулыма шул романның үзбәкчә чыкканы эләгүе ул телне өйрәнүгә бер этәргеч булды. Армия хезмәтен үтәгәндә дә без, йөзләгән рус милләте вәкилләре арасындагы ике-өч татар, ике-өч казах һәм Ташкенттан килгән бер детдом баласы еш кына аерым бер почмакта үзара гәпләшеп алгаларга ярата идек. Шунда инде әз-мәз генә «Тәшкәнт» сөйләме үзенчәлекләре дә зиһеннең бер сырына сеңеп калган иде бугай. (Армиягә мин Казахстандагы укудан бүленеп барган идем.)

Тәүфыйк Әйди исә казахча бик иркен сөйләшә иде. Балачагында ул ике-өч кыш казах мәктәбендә укыган. Улы тугач та, сугышка китеп һәлак булган атасының туган авылында. Үзбәк,

азәрбайҗан кебек кардәш төрки телләрне исә соңрак үзлегеннән өйрәнгән иде. (Китапханәсендә шул телләрдә нәшер ителгән китапларның, белешмәлекләрнең күп булуын да еш искә алдылар өенә барып йөрүчеләр.) Ара-тирә очрашып аралашканда, без үзбәк, казах, кыргыз, азәрбайҗан кардәшләр әдәбиятының һәм сәнгатенең һаман саен үргә күтәрелә баруын, безнең мәдәният үсешенең исә нык тоткарлануын төрле мисаллар китерә-китерә сөйләшеп алгалар идек. Нәкъ шул елларда икебез дә казах, үзбәк әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итәргә дә керештек. Тәүфыйк казахча һәм үзбәкчәдән ике-өч повесть, берничә хикәя тәрҗемә итеп бастырды. Мин исә алты повесть, бер калын роман һәм дистәләгән хикәя, очеркны тәрҗемә итеп, татар укучысы хөкеменә тапшырган идем.

1970 елда булса кирәк, шагыйрь Зәки Нури студент Тәүфыйкны «Казан утлары» журналына эшкә алды. Нәкъ шул елларда кайбер җитәкче даирәләрдә Тәүфыйкның «милләтче» дигән даны тарала башлаган була. Аны милли матбугат тирәсенә якын китермәскә тырышалар. Соңрак матбугатта бәян ителгән КГБ оешмасы документларында Т. Әйдинең 1960 еллар урталарыннан ук бу оешма тарафыннан исәпкә алынганлыгы ачыкланды. Ләкин башкаларга баш бирмәскә күнеккән «партизан Зәки» мәсьәләне үзенчә хәл итә. Университетның кичке бүлегендә укып йөрүче Т. Әйдине журналга эшкә чакыра. Тәүфыйк аңа чаклы төрле хуҗалык, төзелеш эшләрендә эшләгән, тормыш тәҗрибәсе зур иде.

Ул вакытта журнал редакциясе иске Матбугат йортында, Бауман урамында урнашкан иде. Без бер коридорның янәшә бүлмәләрендә эшләдек. Ара-тирә аларның иркен эш бүлмәсенә кереп, сүз куертып та алгалар идек. Шул ук бүлмәдә Казахстанда туып үскән шагыйрь Нури Арсланның да эш өстәле. Гәп корганда, кайчакларда ул да, бер-ике казах сүзен кыстырып, әңгәмәне җанландырып җибәргәләр: «Шолаен әйтәдеме», — дип куйгалар иде.

Тәүфыйк эшли башлаган елда «Казан утлары» журналына язылучылар саны кинәт кенә күпкә артып китте. Яңарак кына, Рафаэль Мостафин баш мөхәррир булып эшләгәндә генә, ун меңнән илле-алтмыш мең данәгә менгән сан кинәт яңа сикереш ясады. Йөз ун мең чамасы абунәче киләсе елгы «Казан утлары»н алдырырга язылган иде. Бу эшне оештыруда башлап йөрүче тынгысыз җан Зәки Нури булса, йөкнең зур бер өлешен үз җилкәсенә алучы исә яшь әдәби хезмәткәр Тәүфыйк Әйди булды. Дөрес, бу эштән журналның башка хезмәткәрләре — җаваплы сәркәтип Ләбибә Ихсанова, мөхәррирләр Нури Арслан, Вакыйф Нуруллин, Фәрваз Миңнуллин да читтә калмагандыр. Абунәчеләрне туплау чорында Әлмәттән чакырып кайтарылган шагыйрь Равил Фәйзуллин да төрле тарафларга хатлар язуда, радиодан журналга багышлы тапшырулар оештыруда актив катнаша. Әмма барлык Союздаш Республикаларда һәм күрше-тирә өлкәләрдә

чыгучы газеталарда махсус мәкаләләр бастыруда, республика һәм өлкә җитәкчеләренә «сездә фәлән мең татар милләте вәкиле яши» дип төгәл саннар белән эш йөртүдә Тәүфыйкка тиңнәр булмады. Һәрбер өлкәдә һәм андагы һәр районда күпме татар яшәгәнлеген ул вакытта фәкать Тәүфыйк кына иренмичә санап-барлап чыккан иде. Аңарда гына андый төгәл белешмәләр бар иде. Шул ук көздә ул татарлар күпләп яшәгән Әстерхан, Волгоград өлкәләренә барып та кайтты әле. (Ул елда мин Оренбург өлкәсенә барган идем. Тәүфыйк әзерләгән, өлкәнең кайсы районында ничә татар яшәгәнлеге теркәлгән әлеге хатларның бер-икесе бүген дә архивымда саклана.)

Шушы уңайдан соңгы елларда матбугатта дөнья күргән бер документка да мөрәҗәгать итик. КГБ генералы Абдулла Бичурин 1966 елның 17 ноябрендә партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев исеменә язган хатында кайбер мәгълүм шәхесләрнең милләтчелеккә бәйле эшләре турында әләкли. Күренекле артист Габдулла Шамуков, тарихчы галим Фоат Вәлиев, борынгы төркиләр тарихын тирәнтен өйрәнгән язучы Нурихан Фәттахларның, милли тарих «серләрен ачып», «яшь буынга кире йогынты ясаулары» турында хәбәр итә. Ул хатта Т. Әйди фамилиясе дә еш телгә алына. «Айдельдинов квартирасын яшерен тикшерү нәтиҗәсендә төрле эчтәлекле хатлар һәм күп санда статистик белешмәлекләр табылды» дигән сүзләр дә китерелә анда. «Айдельдинов неплохо эрудирован, очень усидчив и трудолюбив. Много читает... Основной метод его деятельности – это сбор, обобщение официальных цифровых данных». Һәм, әлбәттә инде, аның төп гаебе итеп шушы укыган, белгән мәгълүматын «яшьләр арасында таратуы» мисал итеп китерелә. («Звезда Поволжья» газетасы, 2002 ел, 14–19 июнь саны.)

Журнал редакциясенең ул елдагы активлыгы Мәскәү түрәләренә бик ошап бетмәде. Татарстан өлкә комитеты җитәкчелеге, алар әләгенә нигезләнеп, милләт өчен артык тырышкан Зәки Нурига язма рәвештә шелтә белдерде. Абунәчеләр санын йөз мең данәдән артыкка күтәрмәскә боерды. Милләт күзлегеннән караганда, мактауга тиң бу шелтәдә Тәүфыйк каләмдәшебезнең өлеше дә зур иде.

Тәүфыйк соңрак, Мәскәүдәге Әдәбият институтының ике еллык махсус курсын тәмамлап кайткач, 1985–1997 елларда «Казан утлары» журналының проза бүлеген җитәкләде. Нәкъ шул елларда журналда тугандаш әдәбиятлар вәкилләренең әсәрләрен бастыру тагын да җанлана төште. Тәүфыйкның унтугызынчы йөз төрек әдәбиятына һәм төрек, татар әдәбиятлары багланышына багышланган җитди, зур хезмәте дә шул вакытта «Казан утлары»нда дөнья күрде. Аның ул бай мәгълүматлы хезмәте кимендә фән кандидаты дәрәҗәсенә ия булырдай бер фәнни ачышка тиң дип бәяләнде.

Бу вакытта инде Тәүфыйк Әйдинең берничә әдәби һәм мәдәни-җәмгыяви эчтәлекле китабы басылып чыккан иде. «Кайда да кадерле», «Йөртә безне язмышлар», «Тылсымлы көч», «Аһ, туган каумем газиз», «Кардәшләр кочагында», «Оҗмах утравы» кебек китаплары төрле тарафларга сәяхәт итү, анда яшәүче милләттәшләребез белән очрашулар нәтиҗәсендә туган очерк һәм юлъязма, истәлекләрдән тора. Шул китапларны укып, без халкыбызның бик күп күренекле шәхесләре белән очрашабыз, танышабыз. Шулар исәбеннән бер-ике генә мисалга тукталып үтәсе килә. Кытай иленә Т. Әйди аяк басканчыга чаклы, без ул илнең көнбатыш өлешендә, борынгы Уйгырстан ханлыгына кергән шәһәрләрдә яшәгән һәм данлы-шанлы гомер юлын үткән якташларыбызның барлыгын, бәлки, белмәс тә идек. (Дөрес, шул ук Уйгырстанның Голҗа шәһәрендә туган, шуннан килеп Казан университетында укыган күренекле галим Миркасыйм Госмановны барыбыз да белә идек. Әмма әле аның ул вакытта туган якларында яшәп калган милләттәшләре турындагы язмалары дөньяга чыкмаган иде.) Анда исә Кытай Халык Республикасы армиясендә хезмәт итеп дан казанган берничә татар генералы да (бертуган Исхаковлар, Ф. Мөслимов һ. б.), галимнәр һәм күренекле дәүләт эшлеклеләре дә бар икән. Һәм шуларның берсе, җитмәсә, үзебезнең Буа районындагы Аксу авылында туган, «бөтенләй дә үз кешебез» икән ләбаса. Һәм чит-ят җирдә дан казанган шушындый милләттәшләребез хакында беренче булып хәбәр җиткерүче Тәүфыйк Әйди булды. Шулар хакында ул сиксәненче елларда ук язып чыкты.

Әйе, безгә чит-ят телдә сөйләшүче кытайлар белән тиң рәвештә олуг галим буларак танылган, 1956 елда Кытай Халык Республикасы Фәннәр академиясенең академигы дәрәҗәсенә ирешкән Борһан Шаһидины Татарстандагы якташлары белән әүвәл Т. Әйди таныштырды. Аның «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсеннән укып, без Борһан агабызның чит бер мәмләкәттә галим генә булмыйча, зур дәүләт эшлеклесе, зур түрә булганлыгын да белдек. Якташыбыз Борһан Шаһиди, татар, уйгыр, рус, кытай, япон телләреннән тыш, немец телен дә Германиянең үзенә барып үзләштергән, шунда югары уку йортында белем алган бөек шәхес, кытай халкының бөек җитәкчеләре Мао Цзедун, Дэн Сяопин кебекләр белән бер бина, бер коридорларда йөргән. Кытай иле күләмендәге зур җыен һәм комитетларның рәис урынбасарлары, рәисләре булган икән. Шул ук вакытта Татарстанда гомер кичергән кайбер кардәшләре белән дә элемтәне бөтенләй үк өзмәгән – вакыт-вакыт алар белән хәбәрләшкәләп торган. Тынгысыз җан Тәүфыйк алар белән дә элемтәгә керә. Борһан Шаһидиның Казанда яшәүче кардәше белән әңгәмәсеннән ул түбәндәге хәбәрләрне укучыга җиткерә: «Әминә Булатова аның (Борһан түрәнең) үтенече буенча Г. Ибраһимов, Г. Тукай, М. Җәлил һ. б. китапларын җибәрүен хәтерли», – дип яза.

Төркиягә, Көнбатыш Германиягә барган сәяхәтләреннән соң, Т. Әйди Төркиядә яшәүче олуг зыялыларыбыз Гали Акыш, Надир Дәүләт һәм Көнбатыш Германиядә яшәп, «Азатлык» радиосында татарча тапшырулар оештыручы милләтпәрвәр шәхесләребез турындагы беренчел мәгълүматларны иң башлап үзенең мәкалә, очеркларында хәбәр итте. Алар белән якыннанрак таныштырды. Һәм соңыннан Тәүфыйкның андый язмалары алда санап үтелгән китапларына туплап чыгарылдылар.

* * *

Шул ук елларда иҗат юлында бер-беребезгә ярдәмләшкән очраклар да еш булгалады. Тәүфыйкның казах теленнән тәрҗемә иткән ике кызыклы повестен, мәсәлән, «Ак дөя», «Әрем исе» исемнәре белән басылган ике күләмле җыентыкка мин тәкъдим иттем. Ул исә 1981 елда минем тарафтан туплап һәм өлешчә тәрҗемә итеп чыгарган Абай китабына («Сайланма әсәрләр. Хикмәтле сүз») күләмле хуплау мәкаләсен язып бастырды. Бераз соңрак ул мәкаләне Алма-Атада нәшер ителүче «Казах әдәбияты» газетасына да җибәреп, Татарстанда Абайга карата тагын бер изгелек эшләнүе турында да хәбәр иткән иде. Ә 1980 еллар ахырында «Елан угы» романын язып төгәлләгәч, ул әсәрен минем тарафтан редакцияләнүен үтенде. «Романда Бохара ханлыгы җимерелгәннән соң башланган чуалыш вакыйгалары тасвирлана. Ул дәверне син чамалыйсың. Мөхәррире бул әле», – дип әйтте. Мавыктыргыч эчтәлекле, вакыйгаларга бай ул әсәр 1991 елда калын бер китап булып басылып та чыкты. Тагын берничә елдан әдипнең «Иблискә ришвәт» исемле романы да дөнья күрде. Шулай ук маҗаралы һәм бик тә гыйбрәтле эчтәлекле, җиңел укыла торган әсәр (2000). Туксанынчы еллар ахырына табарак Т. Әйди «Аваз» исемендә үз нәшриятын оештырып җибәргән иде. Анда үзе мөхәррир, үзе директор булды. Кызганычка, өч-дүрт ел калган гомерендә аның ул нәшрияты уникe томда фәкать үзенең әсәрләрен генә бастырып чыгара алды. Хыялында йөргән эшен – татар дөньясының фаҗигале вакыйгаларын эченә алган башка тарихи хезмәтләрне бастырып таратырга Тәүфыйк дустыбыз өлгермичә калды.

* * *

Татар тарихын, татар дөньясын тирәнтен белүче шәхес буларак, 1997 елда Тәүфыйкны «Татарстан» журналының баш мөхәррир урынбасары итеп куйдылар. Татар җанлы күпчелек язучылар һәм үзара хәбәрләшкәләгән кайбер галимнәр фикеренчә, 1990 елларда язучылар Дамир Шәрәфетдинов, Рафаэль Мостафиннар мөхәррирлегендә басылган «Татарстан» журналы чын милли рухлы, милли эчтәлекле хезмәтләргә күп урын бирде.

Начар гына газета кәгазен кулланып нәшер ителгән ул журнал соңрак елларда купшы кәгазь битләрен тутырып, купшы фотолар басып тараткан дәвамчысыннан күпкә эчтәлеклерәк иде. Бай рухи эчтәлекле, абунәчеләре түземсезләнеп көтеп алган «Татарстан» урынына ялтыравык кәгазьле бернәрсә чыга башлагач, язучылар арасында иске журналны сагынып сөйләүчеләр байтак булды. «Милләтебезнең үткән чорын барлауда киң карашлы, җитди белемле милләтпәрвәр затлардан Тәүфыйк Әйди, Рәис Даутов, Солтан Шәмси ишеләр юк шул инде анда хәзер», – дип уфтанулар еш кабатланды.

Ярый әле ул югалтуны бүген «Гасырлар авазы» журналы редакциясе халкыбызга кайтарып бирә башлады. Бу журналның гомере озын булсын дип кенә телисе кала. Милләткә армый-талмый хезмәт итә күрсен!

* * *

Чордашым Тәүфыйк Әйдинең йөрәге һәм каләме аша үткән тагын бер язманы гына телгә алып китәсем килә. Цензура тикшерүләре юкка чыгарылган, «совершенно секретно», «табу»лары вакытлыча алып ташланган бер вакытта язучы «Казан утлары» журналының 1992 елгы беренче санында элек яшерен сейфларда гына сакланган бер документны җәмәгатьчелеккә җиткергән иде. Ул дуамал җаугир Пётр Беренче императорның варисларына дип язып калдырган «Васыятьнамәсе». Васыятьнамәдә, әлбәттә, Россиянең киләчәктә кайсы илләрне яулап алырга, буйсындырырга тиешлеге бәян ителә. Көньяк-көнчыгыш тарафта Һиндстанга барып җитү, ә көньякта исә кичекмәстән мөселманнар биләмәсе булган Төркияне яулап алу – беренче шарт итеп куела. Т. Әйди ул басманың кереш өлешендә: «Дәверләр үзгәрүгә карамастан, бу тарихи документның әһәмияте әлегә кимеми», – дип язып куйган.

* * *

Тәүфыйк Рамазан улы Әйдельдинов үз заманында рәсми рәвештә танылган әйдәп баручы әдипләр исәбендә йөрмәсә дә, үз милләте язмышы өчен борчылып яшәгән язучыларның бер өлеше арасында үрнәк шәхесләр рәтендә булды. Ул татар теленең, татар әдәбияты һәм сәнгате торышының киләчәге өчен дип күп тырышты. Байтак кына очерк һәм мәкаләләре фәкать халкыбызның киләчәк язмышын кайгыртып язылган хезмәтләр иде. Яшүсмер елларында ук әдәби парча һәм хикәя үрнәкләрен «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә бастырып, беренче сынауларны үтүенә карамастан, киләчәктә ул әдәби эшчәнлеген беркадәр кичектерә килде. Төп әһәмиятен милләт язмышына бәй-

ле эзләнүләренә юнәлдерде. Милләттәшләребез күпләп яшәгән өлкә һәм республикаларга үз хисабына сәяхәтләр кылып, анда яшәүчеләрнең көнкүрешен, киләчәккә өмет-багланышларын өйрәнде. Шул төбәкләрдә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреше, милли ихтыяҗлары турында кискен фикерле очерк-мәкаләләрен язды. Күп очракта ул язмалар республика түрәләренә ошамый, матбугат вәкилләренә аларны мөмкин кадәр «чәнечкеләрсезрәк» бастырып чыгару таләбе куелыр иде.

Ул безнең ил күләмендә булгалап торган тискәре күренешләрне тасвирлап язып кына да калмады. Чит төбәкләрдә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез яки безгә кардәш башка төрки халыклар язмышы белән дә тирәнтен кызыксына иде. Туган җирләреннән читләштерелгән Кырым татарлары, үз төрки телләрендә газета нәшер итүдән дә мәхрүм ителгән гагаузлар (тарихи бәҗәнәкләр берләшмәсенә кергән бер ыруг) турында ачынып сөйләр иде. СССР таркалгач, ул кабат гагаузлар күмәкләп яшәгән Молдавиягә бара, гагауз мәктәпләре өчен дәреслекләр басыла башлавына, ярым мөстәкыйль булса да бу төркиләрнең үзидарә кебек оешмалары барлыкка килүенә сөенә. Шуннан кайткач, «Исәнме, Гагаузстан!» мәкаләсен язып бастыра.

Җитмешенче-сиксәненче елларда Болгария белән Румыния илләрендә борын-борыннан бирле шунда яшәп ятучы тел кардәшләребезне кысрыклау, татар илен Иван Грозный яулап алганнан соңгы еллардагы кебек, диннәреннән, телләреннән яздыру, чукындыру гамәлләре көчәеп киткән иде. Тәүфыйк Әйди сиксәненче авыр елларда ук, ул илләргә тәвәккәлләп бара алды. Күргән-белгәннәре турында соңрак ачынып язып та чыкты. «Дунай буендагы кардәшләр» язмасын укыганда, бүген дә күңел сыкрый, күзләргә яшь килә. Замандашларыбыздан да, милләттәшләребездән дә андый батырлыкны башка берәү дә эшләргә базмады. Шушы илләрдә кыерсытылган кан кардәшләребез турындагы язмалары өчен генә дә Тәүфыйк каләмдәшебезгә һәйкәл куярлык. Әлегә ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре буларак кына мәгълүм (1991 елдан).

Дөрес, күренекле замандашларыннан байтагы аның эшчәнлеген мактап, хуплау сүзләрен һәм аңа багышлы истәлек-мәкаләләрен яздылар. Шул рәвешле Тәүфыйк Әйдигә лаеклы бәянең бер өлеше бирелде, язма һәйкәлнең нигезе салынды кебек. Аның иҗатын һәм җәмгыяви эшчәнлеген барлап һәм мактап, матбугат битләрендә үз сүзләрен әйтүчеләрнең иң асылларын гына булса да санап китик. Әдһәд Синугыл. «Канлы тарих эзләреннән» (1991), Нурихан Фәттах. «Үзе булып калды» (1991), Хәмит Төхфи (Алма-Атадан). «Язмышлар һәм ялгышлар» (1991), Гурий Тавлин. «Биек дуваллар артында» (1992), Гариф Ахунов. «Мәгълүматлар дөньясы, яки Безгә ни булды» (1992), Надир Дәүләт (Истанбул). «Халыкларны якынайта» (1995), Аяз Гыйләҗев. «Күңел яктылы-

гын раслау» (1996), Миркасыйм Госманов. «Жанрның язмышы һәм яңаруы» (2001), Аяз Гыйләҗев. «Татарның асыл улларының берсе» (2001), Мәхмүт Әхмәтҗанов. «Халкым сине онытмас, Тәүфыйк туган» (2001), Бикә Рәхимова. «Ул беренче иде» (2004), Рафаэль Мостафин. «Неизвестный известный писатель» (2001).

Халкының киләчәк язмышы өчен җан атып яшәгән тынгысыз шәхес, үткен каләм иясе Тәүфыйк Әйдинең исемен киләчәк буын вәкилләре дә олылар, онытмаслар. Иҗат үрнәкләре кат-кат басылыр дигән өметтә калам.

*2010*

## КҮПЛӘРГӘ ҮРНӘК БУЛДЫ

*(Истәлек)*

Танылган шагыйрь һәм тәрҗемәче Шамил Мәхмүдов белән узган йөзнең алтмышынчы елларында танышкан идем. Хәтеремдә әле, элеккеге Матбугат йортының бишенче катында урнашкан Габдулла Тукай исемен йөртүче клубта ниндидер әдәби кичә булды. Евгений Евтушенконың Казан университетына багышлап поэма иҗат итәргә ниятләп йөргән чоры иде бугай. Казанга ул берничә мәртәбә килде. Әлеге клубта шул заман рус әдәбиятына һәм иҗатташларына багышлы чыгышлары да булды. Язучылар оештырган Сабан туенда да катнашып, Нәби ага Дәүли һәм тагын кемнәр беләндер күрәшкә чыкканлыгын да хәтерлим. Әлеге кичәдә ул чордашы Андрей Вознесенскийны да искә алган иде.

Һәм шул кичәдән соң бер төркем яшьләр А. Вознесенскийның яңарак басылып чыккан һәм күпмедер дәрәҗәдә Совет хакимиятендәге эчке тәртипләргә карата кинаяле тәнкыйди фикерләр әйтелгән «Треугольная груша» поэмасы турында кызу гына бәхәс тә оештырдылар. Төркем уртасында әлегә чаклы бик күренмәгән бер яшь кеше, авызыннан утлар чәчеп, поэма авторының ни-нәрсәләр әйтергә ниятләвен аңлатты. Аның фикерләре минем күңелгә дә хуш килде. Мин дә ул дәвердә әле Е. Евтушенко, А. Вознесенский кебек танылып килүче рус шагыйрьләре әсәрләрен дә кызыксынып укыштыргалый идем.

Ул елларда әлеге Г. Тукай клубында оештырылган әдәби кичәләргә яшьләр бик теләп йөрде. Хәер, ул вакытта әле барлык газета-журналлар да Бауман урамындагы шушы йортта нәшер ителә. Университет һәм педагогия институты студентлары да, төркем-төркем җыелып, шундый кичәләргә килә иде. Ул кичәләр күп вакытта бик тә кызыклы, яшь буынга гыйбрәт алырдай дәрәҗәдә эчтәлекле була иде. Һәр җомгада оештырылган андый

очрашулар үзара фикер алышу урыны кебек кабул ителде. Әйе, анда шәһәрнең тынгысыз җанлы яшьрәк буыны җыела. Өлкәнрәк буын каләмдәшләренең яисә читтән килгән берәр кунакның сүзен ишетергә теләүчеләр. Тамашачы яки нотык сөйләүчеләр арасында яшьрәк буын галимнәр дә, каләм тибрәтә башлаган яшь язучылар да күренгәләп ала иде. Еш кына ул клубта Уфа, Ташкент, Алма-Ата ише тугандаш республика шәһәрләреннән килгән кунаклар белән очрашулар да үткәрелеп торды. Мәсәлән, кардәш республикаларның күренекле вәкилләреннән Мостай Кәрим, Сәйфи Кудаш, Наҗар Нәҗми, Сәгыйть Агиш ул очрашуларда еш катнашты. Ара-тирә балкар шагыйре Кайсын Кулиев, калмык шагыйре Давид Көгелтинов, үзбәк әдәбиятының аксакалы Гафур Голәм, казах кардәшләрдән Җубан Молдагалиев, Сырбай Мәүләнов, Олжас Сөләйманов, мәскәүлеләрдән Сергей Михалков, Җәмил Мостафин, Бэлла Әхмәдуллина һәм башка бик күп шәхесләрнең чыгышы тыңлаучылар күңелендә һәрчак җылы хисләр уятыр иде. Ә күпчелек шундый чыгышлар яшь иҗатчылар өчен үзенә күрә бер үрнәк ич.

Кайбер кардәш әдәбият вәкилләренең истәлек язмаларында да ул очрашулар искә төшерелә. Казахстанның булачак халык язучысы Җубан Молдагалиев фронтташы Муса Җәлилгә багышлы «Үлмәс җыр» поэмасын иҗат иткәч тә, Казанга килгән, шушы клуб сәхнәсеннән поэманың өзекләрен укыган. Милләттәше, Абай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Сырбай Мәүләнов исә Казанда берничә мәртәбә була. Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Гариф Гобәй һ. б. аксакалларыбыз белән очрашуын һәм аралашуын тасвирлаган күләмле «Җырлы Казан» очеркын яза. Олжас Сөләйманов та, Казанда булганнан соң, Хәсән ага Туфан белән бергә Шәле авылы янәшәсендәге җәйләүдә иртәнге кояш чыкканчы йөргәнлекләрен искә ала бер язмасында.

1960 еллар урталарыннан, шундый кичәләрдә катнашу өчен, Мәскәүдән яисә Уфадан килеп-китеп йөрүче шагыйрь Шамил Мәхмүдов та күренгәли башлады. Сәхнәгә менеп, шигырь сөйләр өчен генә йөрмәде ул монда. Хәер, ул чорда шигърият дөньясында ул Мостай, Наҗар агаларына ук тиң саналмады, әлбәттә. Әмма аның белән очрашып сөйләшүләрне без, яшьрәк буын вәкилләре, көтеп ала идек. Туган ягындагы Уфа, укыган шәһәре Мәскәү белән чагыштырганда, бездә аның шигырьләре ул вакытта әзрәк тә басылды кебек. Әмма шигъри иҗат өлкәсендә тиз арада югары үрләргә ирешкән яшь шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис һ. б. кайберәүләр ул чорда аны «остазыбыз» дип хөрмәтлиләр иде. Үзара әңгәмәләшкән чакларда үзе дә аларны еш кына «минем шәкертләрем» дип атап йөртте. Болай олылаулар аның киң, тирән белемле булуын тану билгесе иде, әлбәттә. Һәм аның күпләргә үрнәк булырдай тормыш һәм иҗат үрләрен олылау билгесе дә булды.

Нәрсәсе белән кызыклы иде соң яшьләргә ул шәхес белән очрашулар? Хәзер рус әдәбиятында, рус мәдәниятендә илленче еллар ахырында һәм алтмышынчы еллар башында актив иҗат итә башлаган яисә тормышта үзен ни дәрәҗәдәдер калкурак итеп күрсәтә алган бер буын вәкилләрен «алтмышынчы еллар шәхесләре» («шестидесятники») дип йөртәләр. Чорына күрә алдынгырак карашлы булган бу шәхесләр Совет хакимияте елларында кешене бер төрлерәк кенә уйларга һәм яшәргә тиеш дип калыплаштыруга каршы күтәрелделәр. Кешене уен тактасы өстендәге бер шакмакка әверелдерү күренешләре белән килешмәүләрен ачыктан-ачык белдерә башладылар. Әдәбият өлкәсендә мондый хәрәкәтнең алгы сафында яшьрәк буын вәкилләреннән Евгений Евтушенко, Бэлла Әхмәдуллина, Андрей Вознесенский, Василий Аксёнов кебек язучылар йөрде. Ул елларда шул төркемнәргә якынрак булган, алар белән беркадәр аралаша алган үз шагыйрьләребездән без фәкать Шамил Мәхмүдов-Анакны гына атый алабыздыр, мөгаен. Шул ягы белән дә ул безгә бик кызыклы иде. Әдәбият мәйданына үзенчәрәк, үз адымнары белән килеп кергән шул буын вәкиле иде бит ул.

Шамил Мәхмүдов (соңрак ул әдәби хезмәтләрен Шамил Анак исеме белән дә бастырды) Башкортстанда, Уфадан чак кына көнбатыштарак урнашкан татар авылы Габдерәшиттә туган. Ул авыл Әлшәй районына керә. 1945 елда Шамил Дәүләкән бистәсендә урнашкан педагогия училищесын тәмамлый һәм шул ук елда Мәскәү дәүләт университетының шәрык телләре белгечлеге бүлегенә кабул ителә. Университетны төрек теле белгечлеге буенча 1950 елда уңышлы тәмамлый һәм аспирантурада калдырыла. Бу инде ерак бер авылда туган татар баласының үз тырышлыгы белән ирешкән үрләре. Әйтеп үтәргә кирәктер, ул заманда безнең милләт вәкилләре арасыннан мондый дәрәҗәле уку йортына кереп укучылар бик аз булган. Ә башкаладагы шундый уку йортын уңышлы тәмамлап, аспирантурага кабул ителүчеләр тагын да азрактыр. Аеруча төрки һәм башка шәркый телләрне һәм әдәбиятны өйрәнүгә җитди әһәмият бирелгән шәрык бүлегендә белем алучыларыбыз бер кул чугы бармаклары санынча гынадыр, мөгаен. СССРның беренче сафтагы университетының ул данлы бүлеген тәмамлаучылар арасыннан мин өлкәдәшем Мәхмүдов Хәйрулла ага белән атаклы сәүдәгәр Габитовлар нәселеннән чыккан Фатыйма ханымның ике улын – Азат Сулиев белән Морад Әүэзовларны гына беләм. (Фатыйма Габитова улларының анда «эләгүе»нә, бәлки, Морад атасы Мохтар Әүэзовның ярдәме дә тигәндер.)

Шамилгә фамилиядәш булган Хәйрулла абзый да – гади бер авыл баласы. Ул Оренбург өлкәсенең Бозаулык суы буендагы Бәшир авылында туган. Мәскәүдә укуын тәмамлаганнан соң, 1940–1983 еллар аралыгында ул Казах дәүләт университетын-

да укытты, профессор, кафедра мөдире булды. Рус-славян һәм борынгы төрки телләр бәйләнешен тирәнтен өйрәнгән галим буларак таныйлар аны. Казах язучылары сөйләвенчә, ул — Олжас Сөләймановның атаклы «Аз и я» тарихи китабын иҗат иткәндә, киңәшләре белән катнашкан остазларның берсе. Шул ук китап авторының киңәшчеләре исемлегендә төрки телләр белгече Азат Сулиев тә була, диләр. Азат та Мәскәү дәүләт университетының шәрык бүлегендә Шамил белән бер үк елларда укыган. Ә 1970 елларда ул Олжас Сөләйманов белән бергә Казахстан Язучылар оешмасында эшләде. (Азатның атасы исә 1930 елларда репрессияләнгән була.) Фатыйма Габитованың бу ике галим баласы белән миңа беркадәр аралашырга насыйп булды. Олжас һәм ике бертуган белән мин 1974 елдан бирле таныш. Яшь Казах мәмләкәтенең күренекле галиме, этнография фәннәре докторы Морад Әүэзов 1991 елдан соң Кытай Халык Республикасында байтак еллар илче вазифасын да башкарды. Анда эшләгәндә, шул илдә яшәүче казах, уйгыр, татар халыклары вәкилләре белән якыннан аралашуы хакында 2004 елда Казанга килгәндә сөйләгән иде.

Әйе, Шамил Мәхмүдов, укуга хирыс кеше буларак, нигезле белем алган шәхес, галим кеше иде. Ләкин ул нишләптер фән юлын сайламыйча, әдәбият өлкәсен өстен күргән. Аспирантураны тәмамлаганчы ук, ул Мәскәүдәге Максим Горький исемендәге Әдәбият институтында укыта башлый. (Алда телгә алып кителгән шагыйрьләрдән Е. Евтушенко белән Б. Әхмәдуллина нәкъ шул елларда ул институтта укыйлар.) Шул ук елларда Мәскәүдә яшәп иҗат итүче (1951—1963) атаклы төрек язучысы Назыйм Хикмәт белән Шамилнең дустанә мөнәсәбәтләре башланып китә. Ул Назыйм Хикмәтнең кайбер шигырь, поэма һәм пьесаларын татар, башкорт, рус телләренә тәрҗемә итә яки аларның русчага сүзгә-сүз күчермәләрен эшли. Үз вакытында бу хезмәтләр рус, татар һәм башкорт телләрендә басылып чыга. Ә пьесалары Мәскәү һәм Уфа театрлары тарафыннан сәхнәләштерелә.

Соңгы елларда Уфада басылган «Писатели земли башкирской» («Башкорт җире әдипләре») белешмәлегендә хәбәр ителүенчә, аның тәрҗемәсендә Назыйм Хикмәтнең түбәндәге өч пьесасы Башкорт дәүләт академия театрында куела: «Сөю турында легенда», «Онытылган язмыш», «Сәер кеше». Төрек әдибенең «Шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгы башкорт телендә 1952 елда Уфада һәм татар телендәге «Сайланма әсәрләр»е 1955 тә Казанда нәшер ителәләр. Шул ук елларда Ш. Мәхмүдовның тәрҗемәсендә Муса Җәлилнең кайбер шигырьләре дә рус телендә нәшер ителүче җыентыкларда чыга. 1968 елда Ш. Мәхмүдов, башка күренекле төрек язучыларының әсәрләрен дә өстәп, күләмле «Төрек хикәяләре» җыентыгын башкорт телендә бастырып чыгара. Ул җыентыкка сүз башын Мостай Кәрим яза.

1959 елда Ш. Мәхмүдовны чит илгә – төрки телләр фәнен укыту өчен, Прага университетына җибәрәләр. Чехословакия башкаласында ул ике ел эшләп кайта. Анда яшәгән вакытта ул Чехословакиянең фашистлар тарафыннан Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелгән каһарман шагыйре Юлиус Фучик белән татарның каһарман шагыйре Муса Җәлил язмышларын чагылдырган шигырьләрен иҗат итә. Аның шул төркемгә кергән «Европа уртасыннан репортаж» һәм «Прага дәфтәре» цикллары башкорт телендә «Әдәби Башкортстан» (1960), рус телендә «Дружба народов» (1960) һәм чех телендә «Зивот» («Жизнь», 1961) журналларында басыла һәм 1963 елда Уфада аерым китап буларак нәшер ителә. Җәлил исеме аталган бу әсәрләр татар укучысына ирешмәде кебек.

Шамил Анак Прагадан кайтканнан соң, үз туган төбәгендә – баштарак туган авылында, соңыннан Әлшәй районы үзәге булган Раевкада яшәде. Вакыт-вакыт Уфада, Казанда һәм Язучылар оешмасының Мәскәү янәшәсендәге иҗат йортларында яшәп, фәкать иҗат итте. Тәрҗемә җыентыкларын да искә алганда – ул егермедән артык китап авторы санала. Беренче шигырь җыентыгы – «Солнце на дороге» китабы 1962 елда Мәскәүдә рус телендә һәм 1966 елда «Юл өстендә кояш» исеме белән Казанда татарча басылып чыкты. Аның Мәскәүдә рус телендә тагын «Оды мирным вещам» (1968, шул ук шигырьләр 1970 елда башкорт телендә дә аерым китап булып басыла), «Три синих холма» (1971, башкорт телендә «Зәңгәр Өчтүбә иле» исеме белән 1984 елда кабатлана), «Полночный бой часов» (1975) китаплары дөнья күрде. Башкорт телендә аерым китап буларак басылган хезмәтләре шушылар: «Ак куян зары» (1969, балалар өчен шигырьләр), «Әрем исе» (1973), «Таш тамгалар» (1978). Казанда татар телендә аның тагын күләмле генә ике китабы басыла: «Көтелмәгән очрашулар» (1971, «Лирон дуска» дип бүләк иткән нөсхәсе саклана), «Тыйнак табын» (1982, 256 б.).

Үз әсәрләреннән тыш, Ш. Анакның татар һәм башкорт шагыйрьләренең шигырьләрен рус телендә бастырып чыгаруга керткән өлеше дә зур. Классик шагыйрьләребездән Г. Тукай, Һ. Такташ шигырьләренең сүзгә-сүз тәрҗемәләрен дә эшләп, русның күренекле шагыйрьләренә тәрҗемә итәргә дә биргәли иде. Мәсәлән,1970 елларда аның Һади Такташның шигырь һәм поэмаларын шулай әзерләп, Мәскәү шагыйрьләренә тәкъдим иткәнлеге хәтеремдә. Ә соңрак ул Г. Тукайның күпчелек шигырьләренең берничә вариантта фәнни нигездә сүзгә-сүз (подстрочник) тәрҗемәләрен әзерләп, берничә данә кульязма рәвешендә Татарстан Язучылар берлегенә тапшырды. Берничә копиядә эшләнгән ул калын брошюраның бер нөсхәсе хәзер Милли музей (шул хезмәте өчен тиешле эш хакының бер өлешен музей түләгән иде) һәм Милли китапханә архивларында

сакланырга тиеш. Г. Тукай әсәрләренең сүзгә-сүз тәрҗемәләренең берничә үрнәген телче галим 1982 елда «Волга» журналының 5 нче санында бастырып та чыгарды. Журналдагы басмага сүз башы язган Мостай Кәрим Ш. Анакның бу юнәлештәге эшчәнлеген югары бәяли. Яңа гасыр башында аның шул фәнни тәрҗемәсе җирлегендә Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы дөнья күрде. Киләчәк тәрҗемәчеләр дә ул сүзлектән файдаланыр әле дигән өметтә калам.

Шамил каләмдәшебезнең борынгы төрки халыклар тарихы белән кызыксынуына да тукталып үтик. Бу өлкәдә аның гыйльми эзләнүләренең төп юнәлеше – борынгы төрки телле кавемнәрнең Урта диңгезнең (төрекчә Ак диңгез) төньяк ярлары буйларында һәм Балкан ярымутравында «грек варварлары» басып алганчыга кадәр яшәвен раслауга бәйле иде. Шуны раслаучы, гарәп имлясында язулы бер бик борынгы китабы барлыгын да сөйләгән иде. (Бездә әлегә андый чыганакларны эзләүчеләр юк диярлек. Төркиядә һәм гарәп илләрендә сакланган борынгы тарихи язмаларны өйрәнүчеләр дә юк.) 1970 елларда бугай, кайсыдыр журнал, «Техника молодёжи»мы, «Смена»мы, Балкан төбәгендә абориген төркиләр яшәгән урыннарны күрсәткән карта бастырып чыгарган иде. Мәскәү янәшәсендәге Переделкино иҗат йортына килгәндә, Шамил аны миңа да күрсәтте. Бер-ике көннән соң шунда ял итүче берничә язучы, шул исәптән миңа таныш Радий Фиш катнашында бер утырыш та узды. Мәскәү университетының шәрык бүлеген тәмамлаган фикердәшләр кызыклы бер әңгәмә оештырдылар. Казаннан Гази ага Кашшаф белән без икәү идек, шым гына тыңлап утырдык. Ул утырышта Балкан ярымутравындагы элеккеге барлык зур шәһәрләрнең, анда яшәүче кешеләрнең атамалары төркичәгә бик якын. Греклар басып алганчы, анда төркиләр яшәгәндер дигән фикер каралды. Араларында зороастризм динен тотучылар да булгандыр. Ул диннең сугыш алласы Дию пәрие бит. Грекларның Зевсы атамасы да шуннан киләдер, борынгырак язмаларда ул Диювес рәвешендә дә язылган диючеләр булды.

Шуннан соңгы бер очрашуда Шамил: «Балканда бик борынгы иероглифлар язмасы табылган, чит ил галимнәре фикеренчә, ул язманың Мисырдагы фараоннар дәвереннән алда язылган булу ихтималы бар», – дип сөйләгән иде. «Киләчәктә мин, шуңа охшаш фактларны бергә туплап, бер хезмәт язам әле», – дип тә әйтте ул. Ләкин хыялларын тормышка ашыра алмыйча, яңа гасыр кергәч тә, арабыздан мәңгелек йортына китеп барды шул Шамил дустыбыз. Архивы кемдәдер сакланамы? Белүче юк. Соңгы елларда туганнан туган энесе Әмир Мәхмүдов та туган якларына кайта алмады бугай. Ара-тирә очрашканда: «Абыйның хәле бик авыр. Кеше кулында калды бит», – дип әйткәләүдән узмады. «Йөри алмас хәлдә калгач та, берүзе яшәде, күршеләре

караШты», – дигән иде Әмир. Соңгы вакытларда ул да туган ягына кайта алмаган икән…

Гомеренең соңгы елларында ул ни-нәрсәләр эшләде икән? Боларны әлегә белүче юк. Кулъязмалары, архивы таралгандыр дигән фикер генә бар. Элек-электән ул ялгыз яшәде, буйдак булды. Туганнан туганы, шагыйрь һәм әдәбият галиме Әмир Мәхмүдов та соңгы вакытларда туган якларына кайта, агасы белән очраша алмаган икән. Аның сөйләвенчә, Шамил Анакның бериш архивы хәзер аның фатирына кереп калган бер башка милләт вәкиле кулында булырга тиеш. Район газетасы хезмәткәре, бер хатын-кыз икән, дигән иде былтыр Әмир. (Ул аны саклыйдырмы, белүче юк.) Ә язмаларының бер өлешен, башкорт әдәбиятына кагылышлыларын, Уфага алып киткән булулары да ихтимал.

Язучы һәм тел галиме Ш. Мәхмүдов-Анакның мирасы киләсе буыннар өчен дә кызыклы булырга тиеш. Шамил хезмәт сөючән, бик тырыш шәхес иде. «Әдипләребез» томында әйтелгәнчә, «чынбарлыкны сәнгатьле фикерләү аша күзаллап тасвирларга омтылды, сурәтле образларга таянып, яңа сүз әйтте… Бигрәк тә ак һәм ирекле шигырь өлкәсендә эзләнүләре белән үзенчәлекле булды». Шамилнең соңгы дистә елда ни-нәрсәләр эшләп калдырганлыгын да ачыклау, кирәк тапканда аларны нәшер итү – бүген исән-имин гомер итүче иҗатташларының төп бурычыдыр, мөгаен. Ул үзе, рухы һәм тәне сау килеш, беркадәр фикер иреге тудырылган бүгенге көнгә килеп җитә алмады шул…

*2010*

# ҮРНӘК ШӘХЕС ИДЕ

*(Истәлек)*

Татар әдәбиятын, татар китабын үз иткән, яраткан һәркемгә язучы һәм мөхәррир Рәис Даутов исеме бик таныш. Ул – кырык ел гомерен язма мирасыбызны барлау һәм дөньяга чыгаруга багышлаган олуг шәхесләребезнең берсе. Татарстан китап нәшриятында эшләү дәверендә елына дистәләгән китапка «җан өреп», нәшер итүгә әзерләгәндер дип уйласак та, аның каләме аша татар укучысы кулына берничә мең рухи хәзинә барып ирешкән була. Ә аның әле гадәти мөхәррир генә түгеллеген, әдәбият фәне өлкәсендә галим-текстолог икәнлеген дә истә тотарга тиешбез.

Борынгы һәм узган гасыр әдәби ядкярләреннән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын, Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый, Заһир Бигиев, Акмулла, Дәрдемәнд әсәрләре җыел-

маларын, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимовларның сайланма томлыкларын Рәис Нәүширван улы Даутов редакцияләп чыгарды бит. Төрле чор, төрле гасырларда иҗат иткән шәхесләребезнең мирасын бүгенге көн таләпләренә туры килердәй итеп бастырып чыгару зур осталык сорый. Андый китапларның кульъязмасын әзерләгәндә, нәшрият мөхәррире әдәбият галиме дә булырга тиеш. Егерменче гасырның икенче яртысында Татарстан китап нәшриятында Рәис Даутов шундый осталыкка ирешкән мөхәррир иде. Хәзерге көндә аңа тиң әзерлекле мөхәррирләргә барлык нәшриятлар да зур мохтаҗлык кичерә.

Мамадыш районының Шәмәк авылында туган Рәис Казан Укытучылар институтында белем ала. 1953 елның февралендә Татарстан китап нәшриятына эшкә билгеләнә. Шәхес культына бәйле булган сәяси торгынлыкның чигенә башлаган чоры. Татарның бөек әдипләреннән Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Шакир Мөхәммәдев, Шамил Усманов һәм башка шәхесләр иҗатының кабат халкына кайтарыла башлаган чоры була ул. Илленче-алтмышынчы елларда аларның сайланма җыентыкларын нәшер итүгә яшь мөхәррир дә җиң сызганып керешә.

Соңгы алтмыш-җитмеш еллык дәвердә татар халкының милли йөзен халыкка кайтаруда Татарстан китап нәшриятының тоткан урынын искә төшереп үтик. Сугыштан соңгы дәвердә нәшрият коллективының хезмәте бәяләп бетермәслек дәрәҗәдә зур булды. Чөнки ул татар әдәбиятына һәм мәдәниятенә багышлы китапларны халыкка җиткерүче бердәнбер нәшрият иде. Сугышка чаклы Куйбышев, Оренбург, Новосибирск, Свердловск кебек өлкәләрдә эшләп килүче кечерәк нәшриятлар ябылган иде инде. Казанда басылып чыгасы китапларны СССРның төрле төбәкләрендә түземсезләнеп көтеп алган чаклар иде.

Илленче-алтмышынчы елларда элек тыелган авторларның бер-бер артлы сайланма әсәрләре, аерым томнары нәшер ителә башлау чорында Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре дә, кайбер өлкән буын язучылары да катнаша. Ләкин ул чорда андый галимнәрнең бик аз санда булуы сәбәпле, егерменче-утызынчы елларда гарәп яки латин хәрефендә басылган яисә язылган әсәрләрне редакцияләп чыгаруның зур өлеше Рәис кебек белемгә омтылучан мөхәррирләр өстенә төшкән. Гарәп язуын ул чорда әле педагогия институтларында укытмаганнар. Рәис, нәшриятта эшли башлагач ук, гарәпчә уку-язуны үзләштерүгә керешә. Илленче-алтмышынчы елларда яшьрәк буын мөхәррирләрдән фәкать ул гына «иске язуны» белүче саналды бугай. Аның белән бер чорда нәшриятта эшли башлаган Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Яхъя Халитовлар шул сәбәпле классик әдәбиятны редакцияләүгә җәлеп ителмәделәр дә диярлек.

Рәис Даутов шул елларда беренче карлыгачларны чыгаруга җиң сызганып керешә. Һәм шул ук елларда аның тәүге үз хезмәтләре – әдәби тәрҗемәләре дә күренә башлый. Дөнья һәм классик рус әдипләре әсәрләреннән М. Твен, Ф. Купер, Ф. Достоевский һ. б. романнары, Э. Хемингуэй, О. Генри, А. Куприның хикәя, повестьлары татар укучысына аның тәрҗемәсендә барып ирешәләр. Шәхес культы чоры корбаны булган Мәхмүт Галәү – Мәрҗанинең «Мөһаҗирләр» романын тәртипкә китереп чыгаручы да Рәис Даутов белән Яхъя Халитов булды. Патша Россиясе хакимиятенең сәяси кысу-эзәрлекләүләренә түзмичә, чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр ителгән татар гаиләләре язмышын тасвирлаучы бу җитди әсәрнең татарча варианты да авторы белән бергә «кулга алынган», юкка чыккан була. Авторлар аның сакланып калган русча нөсхәсеннән «яңа роман» язарга мәҗбүр булалар. Шул хезмәткә тотыныр алдыннан, Рәискә М. Галәүнең күпчелеге гарәпчә язулы булган барлык иҗатын барларга, үз күңеле аша уздырырга туры килә.

Тәрҗемә өлкәсендә дә Рәис Даутов бик күп каләмдәшләренә үрнәк һәм остаз була алды. Татар теле һәм әдәбияты тарихын тирәнтен белүе, яшьли татарның зыялы катламы белән якыннан аралашу аның оста тәрҗемәче булып танылуының төп нигезләредер. Форсаттан файдаланып кына булса да, әйтеп үтик, ул – мәшһүр драматург һәм танылган артистлар династиясе саналган Камаллар гаиләсе даирәсенә кергән бәхетле затларның берсе. Шул татар зыялыларының ишле гаилә вәкиле булган драматург Әнәс Галиәсгар улы Камалның кияве иде. Хәер, Рәиснең үз нәселен дә зыясызлардан дип булмый. Атасы Нәүширванның гарәп язуындагы әдәбиятны яхшы үзләштергән булуын хәтерләүчеләр бар.

Әйе, Рәис Даутовның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә үрнәк булырлык. Әдәби тәнкыйтьтә аның хезмәтләре һәрвакыт уңай бәяләнде. Аның тәрҗемәсендә дөнья күргән китаплардан аеруча Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», Купринның «Атышу», «Гранат кашлы беләзек», Куперның «Соңгы могикан»ы турында Афзал ага Шамов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Равил Фәйзуллин, Наис Гамбәрев һ. б. тарафыннан байтак җылы сүзләр язылды.

Рәис каләмдәшемнең тагын бер эшчәнлеген аерым билгеләп үтү кирәктер. Татар әдәбиятын пропагандалауны ул мөһим бурычы дип санады. Көндәлек татар матбугатында, еллык календарьлар битләрендә төрки-татар әдипләренә, аларның аерым әсәрләренә багышланган күпсанлы мәкаләләре басылып чыкты. 1986 елда аның совет чоры татар язучыларының тормыш-көнкүрешен һәм иҗатларын барлауга багышланган зур күләмле белешмәлеге дөнья күргән иде. Ә соңрак «Мәгариф» нәшрияты аның «Балачак әдипләре» исеме белән дүрт томлык шундый ук җыентыгын

бастырып чыгарды. Ул китаплар эчтәлеге ягыннан да, техник эшләнеше тарафыннан да бик зәвыклы, затлы итеп эшләнгән. Җыентыкларга бүгенге көндә актив иҗат итүче күренекле язучыларга багышлы биобиблиографик белешмә дә бирелгән. Һәм һәр язучының үзе турында үзе язган кыскача истәлек-хатирәсе дә урнаштырылган. Бу томнарда укучы балалар өчен дә, укытучылар өчен дә бик кирәкле мәгълүмат тупланган.

Рәиснең иҗади эзләнүләренең тагын бер юнәлеше – төрки-татар дөньясына караган борынгы язмаларны һәм белешмәлекләрне туплау, өйрәнү иде. Тикмәгә генә аны шәкертләре «рәсми дәрәҗә алмаган академигыбыз» дип атап йөртмәгәндер. Татар шигърияте антологиясен төзүгә керешелгән илленче еллардан бирле, ул элекке гасырларда иҗат иткән шагыйрь, әдипләребез мирасын туплауга җитди игътибар итте. Антологияләргә кермәгән яисә ул тупламаларда иҗатлары тулаем чагылыш тапмаган (антология булгач, анда сайланма әсәрләр генә урын ала ич) күп кенә авторларның мирас хәзинәсе Рәис Даутовның китап киштәләрендә нәшер ителү чиратын көттеләр. Аның тарафыннан кат-кат эшкәртелеп, нәшер ителгән хәзинәләр исәбенә мәшһүр әдип Заһир Бигиевның «Зур гөнаһлар» исеме белән чыккан күләмле җыентыгын атарга кирәктер. Ул китапка ике роман һәм бер юлъязманың бүгенге укучыга авыр аңлаешлы төп нөсхәләре дә, китап авторына багышлы күләмле биографик очерк һәм төзүче-тәрҗемәченең бай мәгълүматлы искәрмәләре дә урнаштырылган. Мәгълүм ки, Заһир Бигиев – татар дөньясында беренче романнар иҗат иткән шәхес. «Мавәра ән-нәһердә сәяхәт» исемле күләмле юлъязмасы да бай, тирән эчтәлекле җитди әсәр. Аңа Фатих Әмирхан да «хәзергә кадәр татар әдәбиятында тиңе булмаган әсәр» дип бәя биргән. Рәис туплап чыгарган саллы китапка кергән әсәрләрнең барысы да унтугызынчы гасырның икенче яртысында иҗат ителгәннәр.

Язучы, журналист һәм матбугат тарихы белгече Исмәгыйль Рәмиев, мәдәният өлкәсендә зур эз калдырган вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышлап, кайчандыр белешмәлек-сүзлек төзегән иде. Үзе исән чакта Исмәгыйль аганың ул кыйммәтле кулъязмасы нәшер ителмичә калды. Рәис каләмдәшебез «Мәдәниятебез фидакяре» дип исемләнгән күләмле очеркында шул хакта түбәндәге сүзләрне яза: «1961 елда И. Рәми сөргеннән... Казанга күчеп кайта. Нәкъ шул вакытларда өлкән әдипләрдән бер төркем дуслары (Н. Исәнбәт, А. Шамов, Ә. Еники һ. б.) аңа... Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты буенча кыскача белешмәлек төзергә киңәш итәләр. Әдип илһамланып эшкә тотына һәм алтмышынчы еллар ахырларына «Әдәби сүзлек» дип аталган хезмәтен төгәлли».

Шул ук елларда Исмәгыйль ага Рәмиев аны китап итеп бастыру хәстәренә дә керешә. Ләкин, уңышка ирешә алмыйча, үлеп

китә. Шул кулъязма хезмәт җирлегендә Рәис 2001 елда ике автор исеменнән (И. Рәми, Р. Даутов) «Әдәби сүзлек» китабын бастырып чыгарды. Рәис энциклопедик әһәмияткә ия ул китапны Исмәгыйль аганың башка төр кулъязмалары һәм үзенең авторлык өстәмәләре исәбенә шактый тулыландырган иде. Бүгенге көндә ул сүзлек-китап татар әдәбияты вә мәдәнияте тарихы белән кызыксынучы һәркемнең эш өстәлен бизәрлек бер зур хезмәт буларак кабул ителә.

Рәиснең тагын бер җитди хезмәтен искә алып китәсе килә. 1992 елда Татар энциклопедия институты оештырыла. Галимҗан Ибраһимовның сигез томлык иҗат мирасын нәшер итәргә әзерләгәндә, бергә эшләүләрен истә тотып, институт директоры, академик Мансур Хәсәнов Рәисне булачак энциклопедия томнарының татарча вариантын редакцияләүче бүлек мөдире итеп чакыра. Даутовның энциклопедик белемгә ия булганлыгын белеп чакыра ул аны. Булачак зур күләмле энциклопедия томнарының беренчел нигезен тәшкил итәсе лөгатьлекне төзүдә дә актив катнаша Рәис. Шул рәвешле саф татар телендә төзелгән утыз биш табак күләмендәге беренче энциклопедик белешмәлек 1996 елда басылып чыга.

Рәис Даутовның язучылык хезмәтенә бәйле өлкәдә дә, мөхәррир буларак та шәкертләре бик ишле. Аны бүген зурзур дәрәҗәле исемнәр алган, иҗатлары бөтен халыкка билгеле булган абруйлы сүз осталары да, матбугат өлкәсендә эшләп танылган байтак кына мөхәррирләр дә остазлары буларак таныйлар. Икеләнмичә әйтә алам – бүгенге заман татар әдәбиятының күренекле осталарының бик тә абруйлы остазы ул. Мәсәлән, Мөдәррис Әгъләм шул хакта күптән язып чыкты инде. Хәзер ул дәрәҗәдәге сүз осталарына тукталмастан, кайбер мөхәррирләрне генә атап үтәсем килә. Татарстан китап нәшриятын Гарәф Шәрәфетдинов җитәкләгән дәвердә (1973–1987) заманча белем алган яшь кадрларны туплауга аеруча әһәмият бирелде. Һәм аларның күпчелеге тәҗрибә туплау чорында Рәис Даутовка беркетелделәр. Аның янәшәсендә эшләп, аннан күп нәрсәгә өйрәнгән шәхесләрдән Фәез Зөлкарнәйне, Харрас Әюповны, Наис Гамбәрне, Рәфыйкъ Юнысны, Равил Рахманины искә алам. Шул елларда мәрхүм Фәезнең, остазы белән киңәшә-киңәшә, «Татар әдәбияты тарихы» томнарын редакцияләү дәверен хәтерлим. (Дәрдемәнд биографиясенә бәйле кайбер фактларны ачыклау өчен, мине дә үз бүлмәләренә чакыргалаганнар иде.) Әйе, бу яшь мөхәррирләр Рәис остазлары белән бер бүлмәдә утырып эшләделәр. Ә Равил Рахманины Рәис, Татар энциклопедия институтында эшли башлагач та, «Татар энциклопедия сүзлеге»н төзү чорында үз янына алды.

Рәис Даутов белән беренче танышуым алтмышынчы елларга туры килә. Ул дәвердә, яшь язучылар иҗатына багышлап,

ел саен бер җыентык нәшер ителә иде. Шундый китапларның берничәсенә минем тәүге хикәяләрем дә керде. 1966 елда нәшер ителәсе китапка минем өченче хикәям – «Дәгъва» исемлесе дә тәкъдим ителгән иде. Ул «Кайнар хисләр» җыентыгының проза өлешен Рәис Даутов редакцияләде. Якыннан танышу-аралашуларыбыз шул көннәрдән башланып китте. Соңрак исә берничә ел дәвамында бергә Татарстан китап нәшриятында да эшләдек. Берәр катлаулырак хезмәтне редакцияләгәндә сорау туса, мин дә еш кына аңа мөрәҗәгать итә идем. Һәм алтмышынчы еллар урталарыннан башлап, мин аны остазларым төркемендә йөртәм.

«Татар энциклопедия институты чыгарасы хезмәтләрне татарчага тәрҗемә итүчеләр төркемен җитәкләргә алын» дип тәкъдим итүче дә ул булган иде. Ләкин әниемнең ятып авырган чагы булганга күрә, мин ул тәкъдимне кабул итә алмадым. «Өйдә торып, тәрҗемә эшен үтәргә алына алам» дидем. Һәм институт җитәкчелеге белән соңрак шулай килештек тә…

Киләсе елның 28 августында танылган мөхәррир һәм язучы Рәис Нәүширван улы Даутовның бу дөнья белән саубуллашуына унбиш ел тула. Аның вафатыннан соң дүрт ел үткәч, 2011 елда «Җыен» фонды аның тормышына һәм эшчәнлегенә багышлап күләмле генә китап чыгарган иде. «Шәхесләребез» сериясендә «Рәис Даутов» исеме белән меңданәдә нәшер ителгән бу җыентыкны туплап, язып чыгаручылар академик Миркасыйм Госманов һәм фән кандидатлары Җәүдәт Миңнуллин белән Равил Рахмани булды. Мулла Нәүширван гаиләсендә туган остазыбыз Рәиснең изге эш-гамәлләрен киләсе буын вәкилләре дә искә алыр дигән өметтә калам.

*2003–2021*

## БАКЧА КҮРШЕМ, ЧОРДАШЫМ…

*(Истәлек)*

Күренекле шагыйрь, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Марс Садрый улы Шабаев белән без бер чор, бер заман кешеләре. Яшәү өчен бик тә авыр булган Бөек Ватан сугышы елларында үскән авыл балалары без. Ул 1933 елның 14 июлендә Минзәлә төбәгенең Югары Текермән авылында укытучы гаиләсендә туа. Мин аннан сигез айга иртәрәк шундый ук бер гаиләдә бу дөньяга килгәнмен. Калган язмышларыбыз безнең уртак диярлек. Әтиләребезнең икесе дә, сугыш башланууга ук, яу кырына озатылганнар. Берничә мәртәбә яраланган,

дәваланган һәм яу кырында батырларча ятып калганчы, алар дошманга каршы көрәшүләрен дәвам иттергәннәр. Марс Шабаевның иң уңышлы әсәрләре рәтендә йөргән «Җирән Конрад» поэмасында (һәм, әлбәттә инде, башка күп кенә әсәрләрендә) аталарыбыз язмышына бәйле рәвештә туган образ-сурәтләүләр дә байтак…

Әниләребез — ятим калган өчәр баланы тәрбияләп, аякка бастыра алган батыр җаннар. Гаиләдәге иң зур малайлар сыйфатында без дә аналарыбызга таяныч булырга тырышканбыз. Сигез яшьтән кулга көрәк, сәнәк тотып, өй эшләрен эшләшкәнбез. Унбер-унике яшьтән башлап исә колхозларга печән әзерләшүдә, урып-җыю эшләрендә булышкаларга да өлгерә алганбыз. Үзара сөйләшеп утырганда, еш кына шул чорга бәйле вакыйгалар да искә төшкәләр иде. Унөч-ундүрт яшьләр тирәсендә икебезгә дә «грабарка» дип йөртелгән ат җигүле авыр тырма белән иген, печән тырмалау эшен башкарырга туры килгән иде.

— Беләктә көч чамалы, гәүдә юка — тырмаланган печәнне үз рәтендә төшереп калдыру өчен рычагка бөтен гәүдәң белән басасың да, урыныңа утырырга өлгермисең — икенче рәткә килеп җиткән буласың. Шуңа күрә көне буе диярлек аягүрә торып эшлисең. Төшке ял вакытына кайткач та, иң беренче уең ашау белән үк йоклап китү турында булыр иде, — дип, шул заман вакыйгаларын искә төшергәләп алгалар идек.

Икебез дә мәктәп бусагасын да бер үк көздә — сугыш башланган елның көзендә атлап кергәнбез икән. Ул елларда 1 нче сыйныфка сигез яше тулганнарны гына кабул итәләр иде. Узган елның 1 нче сентябренә әле миңа сигез яшь тулмаган була. (Җиде яшь тулгач укуга кабул итү тәртибе Н. С. Хрущёв ил белән идарә иткән заманда — 1957 елда кертелде. Шул ук карар нигезендә җидееллык мәктәпләр сигезьеллыкка күчерелде.) 1941 елның көзендә мин укыган мәктәпнең 1 нче сыйныфына иксәнләп бала кабул ителә. Без янәшә өч зур сыйныф бүлмәләренә бүленеп укый идек. Авылыбыз бик зур, элек биш мәчетле булган. Без укырга кергән елда да әле авылның ике очында ике мәчет манарасы калкып утыра иде.

Хәзер ул авылның барлык унбер сыйныфындагы укучылар саны да иксәнгә җитми бугай. Әйе, кайчандыр биш мәчетле, биш мәхәлләле бу зур авыл да бүген юкка чыгу дәрәҗәсенә җитеп килә. Мондый хәлнең төп сәбәбе, әлбәттә, авылларда колхозларның бетерелүенә бәйле. Биш йөздән артык йортны берләштергән авылда оешкан дүрт-биш фермер хуҗалыгы хәзер авылдашларны эш белән дә, аш белән дә тәэмин итәрлек дәрәҗәдә түгел. Ә безнең элекке ил башлыклары — Елцин-Гайдарлар исә ул хакта уйламыйча, бүгенге атсыз, сукасыз игенчене тизрәк элекке «Рәсәй крәстияне» рәвешендә күрергә хыялланганнар иде дә — бу хыяллар бик уңышсыз тәмамланды шул…

Сугыштан соңгы елларда күпчелек татар авылларында җиде сыйныфлы мәктәпләр генә эшләде. Урта белем бирүчеләре, нигездә, район үзәкләрендә генә булыр иде. Алары дә әле күпчелек очракта русча укытучы рус мәктәпләре. Хәтеремдә әле, каләмдәшебез Рафаэль Мостафин да, бер әңгәмә вакытында: «Әтием туган Яңа Муса авылында җиде сыйныфны тәмамлагач та, Шарлык мәктәбенә барып кердем. 1 нче, 2 нче сыйныфларда Мәскәү, Ленинград мәктәпләрендә укый башлаганлыктан рус телен бераз үзләштергән булсам да, баштарак район мәктәбендә уку миңа да бик авыр тоелды», – дип сөйләгән иде. Әйе, тәүге мәлләрдә төгәл фәннәрдәге кайбер атамалар үзгәлеге татар баласын аптыраштa калдырырлык була иде шул…

Минем яшьтәшләремә, унбиш-уналты яшьлек яшүсмерләргә дә авылдан йөзәр чакрымга китеп уку, мөстәкыйль тормыш алып барулары җиңел булмады, әлбәттә. Татар педагогия училищесы безнең авылдан өч йөз чакрым ераклыкта иде. Авыл хуҗалыгы белгечләрен әзерләүче техникумнарның иң якыны йөз чакрым чамасы арада булды. Укырга, һөнәр үзләштерергә хыялланасың икән – сохари тутырылган биштәреңне күтәрәсең дә ерак юлга чыгып китәсең… Чордашларымның байтагы шундый шартларга да түзде, белем алырга, һөнәр үзләштерергә тырышты…

Марс дустыбыз да җиде сыйныфлы «башлангыч урта белем бирүче» мәктәпне тәмамлагач, укуын Минзәлә татар педагогия училищесында дәвам иттерә. Дөрес, ул күпчелек чордашларына караганда бәхетлерәк булып чыга – шул ук елларда инде аның әнисе дә Минзәләгә күчеп эшли башлый. Башлангыч сыйныф укытучыларын әзерләүгә йөз тоткан шул чор Минзәлә училищесын ул еллардагы бик абруйлы уку йортларының берсе булган дияргә хаклыбыз. Татар әдәбияты укытучысы Мөхәммәт Гарифуллин йогынтысында тәрбияләнгән дистәгә якын булачак язучы яки әдәбият галиме шул чор Минзәлә уку йортының нинди дәрәҗәдә булганлыгын раслап тора. Сугыштан соңгы елларда бу уку йортын булачак шагыйрьләр Гөлшат Зәйнашева, Марс Шабаев, Ләбиб Айтуганов, Спартак Әхмәтовлар, танылган прозаиклардан Газиз Мөхәммәтшин, Мәдинә Маликова, күренекле әдәбият галиме Нур Гыйззәтуллин тәмамлап чыкканнар. Анда укучыларның күпчелеге Минзәләдән җитмешәр, йөзәр чакрымнардагы авыллардан булган: Актаныш, Әгерҗе, Минзәлә, Мөслим, Сарман районнарыннан килгән яшүсмерләр. Минзәлә училищесын тәмамлагач та, боларның күпчелеге укуларын Казан педагогия институтының филология факультетында дәвам иттерәләр. Яраткан укытучыларының фатихасын лаеклы рәвештә үтиләр.

Марс Шабаев, 1958 елда Казан педагогия институтын бик яхшы билгеләренә тәмамлаганнан соң, радиокомитетка эшкә

чакырыла, ике елдан артыграк ул анда әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире була. Аннары аңа яңадан чыга башлаган «Яшь ленинчы» газетасының әдәбият бүлеге мөдире вазифасын үтәү йөкләнә (1961—1964). Ә 1964—1970 еллар аралыгында ул «Азат хатын», «Чаян» журналларында җаваплы эшләр башкара. 1970 елда аны Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррир урынбасары итеп билгелиләр. Һәм унөч ел гомерен ул китап нәшер итү эшенә багышлый. Аның баш мөхәррир вазифасын үтәгән елларда бик тә таләпчән булуын искә алучылар бүген дә бар әле…

Марс Шабаев, күпчелек чордашлары кебек үк, Минзәләдә укыган елларында ук, шигырьләр иҗат итә башлый. Минзәлә шәһәре һәм районы күләмендә таралучы «Ленин байрагы» газетасында аның беренче әдәби хезмәте 1952 елның гыйнвар ае санында басылып чыга. Шуннан соң аның әсәрләре район һәм республика күләмендәге газеталарда даими рәвештә күренә башлый. Беренче шигырь җыентыгы – «Яңа җыр» төгәл ун елдан соң нәшер ителә. Марсны күпчелек каләмдәшләре тирән эчтәлекле, кызыклы сюжетлы поэмалар авторы буларак таный һәм хуплый. Бүгенге көндә ана телендә аның уналты һәм рус телендә ике үз әсәрләре китабы укучылары хөкеменә тапшырылган. Шул ук вакытта ул бик оста тәрҗемәче буларак та билгеле шәхес. Рус теленнән тәрҗемә ителгән әсәрләре тупланган биш саллы китабы нәшер ителде. Мәшһүр рус шагыйре Евгений Евтушенконың ике зур поэмасын берләштергән «Казан университеты» җыентыгы (1988) һәм рус телендә иҗат итүче якташыбыз, Мәскәүдә яшәүче прозаик Рауль Мирхәйдәровның ике роман һәм повестьларын берләштергән ике саллы китабы (2003, 2005) шул фикерне раслый булса кирәк.

Күренекле чордашларыннан Равил Фәйзуллин Татарстанның халык шагыйре, остазы рәвешендә таныган иҗатташы турында мондый сүзләр яза: «Марс Шабаев беренче чиратта шагыйрь. Анык һәм тайпылышсыз үз гражданлык позициясе булган шагыйрь. Таланты куәтенчә илгә, булсынга дип хезмәт итте…» («Өлкәнебез», Казан утлары, 2003). Башка каләмдәшләре дә аның иҗади алымын, иҗатын югары бәялиләр. Прозаик һәм әдәби тел белгече Хәсән Сарьянның аңа багышланган мәкаләсендә мондый бәяләмә бар: «Марс Шабаев шулкадәр кыскалыкка, димәк, тыгызлыкка ирешкән ки, әсәрләрендә бернинди артык деталь, артык сүз юк. Пушкин әйткән фикер: «Сүзләргә никадәр кысан булса, фикергә шулкадәр иркенлек бирелгән…» («Туган җиренең шагыйре». Китап: «Уеңны уйдырып сал», 1977).

Марс Шабаевның иҗатын халкыбыз да югары бәяләде. 1976 елда аңа Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды.

Марс белән без алтмышынчы еллар башыннан ук аралашып яшәдек. 1964 елда остазым, каләмдәшем Хәсән Сарьянны Язу-

чылар берлегенә эшкә чакырып алдылар. Үзе урынына, «Азат хатын» мәҗмугасының җаваплы сәркәтибе вазифасын үтәргә, ул Марс Шабаевны тәкъдим итте. Өлкәннәр һәм түрәләр аның фикерен хупладылар – Марс инде илгә, халыкка танылып килүче язучыларыбызның берсе иде. Соңрак, ул Татарстан китап нәшриятына эшкә билгеләнгәч тә аралар өзелмәде. Нәкъ шул 1970 елдан башлап инде без бакча күршеләре буларак та тыгыз бәйләнештә яшәдек. Яшел Үзән районына кергән, Идел култыгы буендагы «Идел» бакчачылык ширкәтен оештыру эшендә дә башлап йөрүчеләр без булдык. Рәссам, композитор һәм язучыларга дип бирелгән җир кишәрлеген үзләштерү эшләрендә җиң сызганып катнаштык. Чөнки булачак «җир биләүче» егермеләп язучы арасында без иң яше, иң кирәклесе булганбыздыр, мөгаен. Өлкән күршеләребез – Әмирхан Еники, Нури Арслан, Атилла Расих, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Хисам Камаллар – безгә киңәш биреп торучылар иде. Композиторлар төркеменнән Мирсәет Яруллин, Әнвәр Шәрәфиев, Сәлим Хәялиев («Хор» җәмгыяте түрәләреннән берсе) безнең кулдашларыбыз иде.

Марс, Мирсәет һәм мин ул елларда Казанда да бер тирәдәрәк яшәдек. Марс белән икебез – Восстание урамында, Мирсәет аннан ерак булмаган Ибраһимов проспектында иде. Марс фатирының ишегалдында зур гына утын сарае да бар. Анда бер мескен генә, халык телендә «козёл» дип йөртелгән матай да саклана иде. Бервакыт мин Марстан: «Бу «арба»да син йөрисеңме соң?» – дип сорадым. «Әйе, – ди бу. –Тик мин йөртүче түгел, Мирсәетнеке ул. Мин, Габделхәй Сабитов – Мирсәеткә юлдашлар гына. Бу матай белән без өчәүләп Идел, Мишә буйларына балыкка йөри идек элек. Хәзер инде йөрмибез – бакчабыз Идел буенда ич».

Әйе, Марс, Мирсәет – безнең арада иң комарлы балыкчылар да иде шул. Җәй дәвамында ял көннәренең иртәнге өлешен балык аулап уздырырлар иде. Барлык күршеләр йокыдан уянганчы ук, Марсның өч көпчәккә утыртылган көймәсе, дөбер-шатыр килеп, тар бакча урамы буйлап Идел култыгы тарафына таба төшеп китәр иде.

Китап нәшриятында бергә эшләгән елларны да сагынып искә аласы килә. Җәйге иртәләрдә без, атлый-йөгерә өч чакрым ара үтеп, сигезенче биш-ун минутларда китәсе электричкага чыга идек. «Займище» тукталышында безнең вагоннарга нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдинов җитәкчелегендә тагын егермеләп хезмәттәшебез кереп тула. Безнең нәшрият белән газета-журналлар идарәсе хезмәткәрләренең бакча ширкәте уртак иде ул елларда.

Марс белән миңа берничә китапны бергә эшләргә насыйп булды. Шулардан бер очракны гына искә төшереп үтим. Алма-Атага бер баруымда, дустанә бер әңгәмә вакытында, ка-

зах каләмдәшләрдән берәү – Язучылар берлегенең бер түрәсе: «Безнең классиклар иҗатына тиешенчә әһәмият бирмисез әле. Абай, Җамбул әсәрләренең сездә күптән күренгәне юк», – дигән иде. – Г. Тукай, М. Җәлил китапларын без биш-ун ел саен чыгарып киләбез. Г. Ибраһимов белән Ш. Усманов кебек олыларның роман, бәяннарын да еш нәшер итәбез...» Мин аңа Мохтар Әүэзовның Абайга багышланган романы томнарының үз вакытында ук чыгуын искә төшердем, тагын берничә автор исемен атап үттем. Нәшриятларыбызның мөмкинлеге тиң түгеллеген исбатларга тырыштым. Шул сөйләшүдән соң китап кибетенә кереп, Абайның яңарак нәшер ителгән икетомлыгын алып кайттым. Нәшриятта да, Язучылар берлеге идарәсендә дә Абайның бертомлыгын чыгару кирәклеген хуп күрделәр. 1981 елда ул китап басылып та чыкты. Китапны оештыручы-төзүче мин булдым. Марс аны бик тырышып редакцияләде. Сүз башын Сибгат ага Хәким язды. Тәрҗемәчеләр исемлегенә кардәш халыкның телен, гореф-гадәтен бераз белгән, алар белән аралашкан шагыйрьләр җәлеп ителде: М. Максуд, Н. Арслан, М. Хөсәен, Ә. Рәшитов. Шул китапны эшләгәндә, мин тагын бер мәртәбә Марсның бик таләпчән шагыйрь һәм мөхәррир булганлыгына инандым. Алма-Атадан алып кайтылган ике томлыкта Абайның бер улының иртә вафат булуын тасвирлап язган мәрсиясе дә (әлеге китапта ул поэма дип тәкъдим ителә) бар иде. Аны үзебезнең танылган шагыйребез тәрҗемә итте. Ләкин Марс аны китапка кертүдән баш тартты. «Абайның башка әсәрләре белән чагыштырганда, ул йомшаграк язылган. Аны китапка кертсәк, без Абайның шагыйрьлек дәрәҗәсенә зыян китерәчәкбез», – дигәч, мин дә, янәшәдә утырган ике олуг шагыйрь дә мөхәррир белән килешми булдыра алмадык.

Марсның тагын бер якты сыйфаты – ихласлылык, хәленнән килгәнчә кешегә ярдәм итәргә тырышуы булгандыр. Бер генә мисалга тукталып үтим. Мәшһүр язучы, Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинны республикабыз күләмендә танытучы, беренче буларак аның турында язып чыгучы кеше Марс Шабаев иде. Башлыча Марс сүзләренә нигезләнеп, «өметле шагыйрь Фәнисне» ерак Баулы төбәгеннән Казанга алып килделәр. Аңа иҗат итәргә, үсәргә мөмкинлекләр тудырдылар...

Инде икесенең дә урыны җәннәттә булсын! Без аларны онытмаска тырышыйк!

*2018*

# КҮПКЫРЛЫ ИҖАТ ИЯСЕ

Мансур Әхмәт улы Шиһапов алтмышынчы еллар башында җәмәгатьчелеккә зур киләчәге өмет ителгән сәләтле артист буларак күренеп алды. Иҗатташы Рабит Батулла бер мәкаләсендә аның шул дәвердәге эшчәнлеген болай бәян итә: «Качалов исемендәге театр каршында оешкан артистлыкка әзерлек мәктәбен тәмамлагач, ул берникадәр вакыт Күчмә театрда, аннан соң филармониядә артист булып эшләде. Сәхнәдә ул иҗат иткән кызыклы образлар байтак булды. Әйтик, Назыйм Хикмәтнең «Сәер кеше» әсәрендә Ф. Кастро, Георги Мдиванинының «Терезаның туган көне»ндә – Антонио, Әсгать Мирзаһитовның «Әниемнең чал чәчләре»ндә – стиляга Гошка, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ында – Искәндәр, Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендә – Госман Әкбәревич рольләре аның актёрлык уңышы санала». Әйе, театрда дистә елдан кимрәк дәвердә артист булган кеше өчен бик зур һәм дәрәҗәле исемлек бу. Әлеге студияне тәмамлагач та, Мансурга шушындый үзенчәлекле рольләрне ышанып тапшырган режиссёрлар яшь артистның сәләтен тиз күреп алганнар икән дигән нәтиҗәгә киләсең.

Кайда туган-үскән һәм кем тәрбияләгән соң бу сәләтле артистны? Мансур Шиһапов Балык бистәсе районындагы уртача зурлыктагы Яншык авылында туган. Шул ук районның Олы Солтан авылы урта мәктәбен тәмамлаган. «Шушы төбәктәге авыл мәктәпләре арасында зур абруйга ия булган бу уку йортында ул елларда төрле иҗади түгәрәкләр, шул исәптән драма түгәрәге дә эшләде», – дип искә ала Мансур.

Шушы мәктәпне тәмамлагач, ул Казанга килә. В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры каршында оешкан театр студиясендә 1957–1961 елларда укый. Шул чорда ук күмәк күренешләрдә зур сәхнәдә күренгәли башлый. Курс җитәкчеләре Мәскәү дәүләт театр сәнгате институтын – атаклы ГИТИСны уңышлы тәмамлап кайткан Празат Исәнбәт була. Ул инде Г. Камал театры сәхнәсендә артист буларак та, режиссёр сыйфатында да шактый тәҗрибә туплаган һәм абруйга ирешкән шәхес иде, дип искә ала аны Мансур. «Безгә карата да бик таләпчән булды. Шуны тоеп, без дә бик тырышып укыдык» ди. Шул таләпчәнлек һәм осталык нәтиҗәседер инде, студиядә Мансур белән бер төркемдә укыган артистлардан Наилә Гәрәева, Ирек Баһманов, Вадим Кешнер татар һәм рус театрлары сәхнәләрендә тиз арада танылачаклар да.

Шушы уңайдан байтак кына татар яшьләренә олы иҗат юлын сайларга юнәлеш биргән, иҗади рухта тәрбияләгән Олы Солтан татар мәктәбен һәм аның укытучыларын кабат олылап искә алып китәсе килә. Әйе, анда Татарстанның булачак халык артистлары Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлов та укыган. Күренекле ша-

гыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Мидхәт Миншин белән бер чордарак үзенчәлекле проза әсәрләре иҗат итеп танылган Вакыйф Нуруллин, Әхәт Сәфиуллин, ике бертуган Гаффаровлар һәм Госман Гомәров та белем алган. Татарстанда бу өлкәдә шушындый ук уңышка ирешкән тагын берничә авылны гына мин беләм. Гомумән дә, Балык Бистәсе районы иҗатлары һәм эшчәнлекләре белән халык күңелен җәлеп итәрдәй шәхесләр тәрбияләү җәһәтеннән атаклы Арча, Буа, Сарман, Чирмешән районнары дәрәҗәсендәдер, мөгаен. Балык Бистәсе районының Олы Солтаннан башка авылларында укып, сәнгать вә мәдәният өлкәсендә зур уңышларга ирешкән башка шәхесләрен дә искә алып китик. Татарстанның халык артисткасы Рауза апа Хәйретдинова, халык шагыйре, Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Равил Фәйзуллин, күренекле драматург Сәет Шәкүров, шагыйрь Әхмәт Гадел дә бит шул тарихи, болгар бабаларыбыз яшәгән дәвердә үк оешкан борынгы Чаллы әмирлеге җирлегеннән чыккан кешеләр.

Мансур Шиһапов шушы районның Яншык авылында 1940 елның 1 маенда туа. Эшчәнлеге белән авылдашлары арасында абруй казанган Әхмәт Шиһаповның инде дүрт улы була. Бишенчегә Мансур туа. Әхмәт абзый дүрт ел сугышта йөреп, беренче группа инвалид булып кайтканда, инде ул җитез бала әнисенең төп юанычына әверелә, сугыштан соң туган сеңлесе белән энесен тәрбияләшүдә катнаша. Әхмәт белән Нәфисә Шиһаповлар гаиләсенең булсынга дип тырышып яшәүләренең тагын бер мисалы – җиде балаларының да югары белемле булуы. Әхмәт абзый, сугыш яраларыннан тернәкләнеп китә алмыйча, илленче еллар башында вафат булгач, кече энеләрен һәм сеңелне аякка бастырышуда агалары булышлык итәчәк. Үз авылларында утыз еллап укыткан һәм мәктәп директоры булган Хуҗиәхмәт агасы Мансурга да студиядә алган белем белән генә чикләнмәскә киңәш итә. Мансур, эш арасында укып, Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый.

Аңа чаклы ук инде Мансурның тагын бер сәләте – оештыручы, берәр эшне әйдәп баручы сәләте ачылган була. Атасы Әхмәткә, абыйларына хас бер сәләт бу. Гаиләле булгач, бала тугач та, Күчмә театр яисә филармония коллективы белән ел әйләнәсе авылдан авылга йөреп эшләү ялыктыра башлый. Һәм җитмешенче еллар башында ул Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бүлегенә эшкә килә. Ә Г. Камал исемендәге театрның баш администраторы вазифасын үтәүче кирәк булгач, аны шунда куялар. Бу вазифаны ул 1974–1976 елларда шактый уңышлы башкара һәм тиздән Курчак театры директоры итеп билгеләнә. Ә элеккеге Күчмә театрны Казанда даими эшләүче театр статусына кайтару карары чыккач, М. Шиһапов шунда директор итеп күчерелә. Элеккеге Күчмә театрның статусын Драма һәм комедия

театры дип үзгәртүгә ирешү өчен, аңа шактый гына тырышырга туры киләчәк. Мәскәү түрәләре алдында ул элекке артистлык сыйфатларын да искә төшерәчәк.

Туксанынчы еллар башыннан ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисенең урынбасары булып эшләде. Ә 1996 елда Республиканың Дәүләт зур концерт залы ачылгач, аны шунда директор итеп билгеләделәр. М. Шиһапов эшләгән дәвердә ул концерт залына мактаулы Салих Сәйдәшев исеме бирелде.

Мансур Шиһапов 1980 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1996 да Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәҗәле исемнәргә лаек булды. 2000 елда исә аңа Татарстан Республикасының Мактау грамотасы тапшырылды. Ә 2014 елдан ул Татарстанның халык артисты дигән дәрәҗәле исем йөртә.

Мансур Олы Солтан мәктәбендә укыган елларында шигырь яза башлый. Дусты Кадыйр белән авылларыннан егерме чакрымдагы шул мәктәпкә барганда-кайтканда, алар ярышып шигырь әйтешәләр. Мансурның бер-ике шигыре район газетасында басылып та чыга. Мәктәптә уку елларында ул драма түгәрәге «артисты» булудан тыш, татар шагыйрьләренең шигырьләрен оста сөйләүче буларак та таныла. Казанда, театр студиясендә укып йөргән чордан аның кайбер шигыре көйләп җырлана да башлый. Ләкин әле ул җырчы шагыйрь буларак соңрак танылачак. Беренче шигырь китабы «Әйләнеп кайтыгыз» бик соңлап кына басылып чыгачак. (Ул китапның мөхәррире мин булдым. Икенче – «Туй күлмәге» җыр китабын әзерләшүдә дә күпмедер дәрәҗәдә катнашкан идем.) Китапка «Шомыртлар ак шәлен ябынса» дип исемләнгән сүз башын язган Мөхәммәт Мәһдиев аны түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Кулъязманы укып чыккач уйга калдым: тәрәзәдән яз исе бәреп кергән сыман булды, туган авылымның җәйрәп яткан иген басуларын, туган нигеземдәге бакча башында ак шәлен ябынган шомыртны күргән кебек булдым», – ди. Соңрак шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин «Исәннәр әйләнеп кайталар» мәкаләсендә (1993) Мансур чордашы шигырьләренә төпле анализ ясап, аларга бик уңай бәһа бирәчәк. Ул китапның мөхәррире буларак, бу бәяләр мине дә сөендерде, әлбәттә.

Шагыйрьнең 1997 елда нәшер ителгән икенче китабы фәкать җырлардан гына тора. Ул китапчыкка авторның иң популяр җырларының берсе булган «Туй күлмәге» исеме бирелгән. Китапка «Әйләнеп кайтыгыз», «Яшьлегем эзләре», «Өлешемә тигән, әй, көмешем», «Кыр казларын бергә каршылыйк» кебек, җыр, сәнгать сөючеләргә таныш, якын булган кырык-иллеләп җыр тәкъдим ителде. Әлмәттә яшәүче язучы Альберт Хәсәнов, ул китапны кулына алгач та, үзебезнең үзәк газетада түбәндәге мактау сүзләрен бастырып чыгарды. «Игелекле яуган яңгыр төсле» дип исемләнгән бәяләмәсендә ул М. Шиһаповның җыр

иҗаты турында болай дип яза: «Танылган җырчыларыбыз Мансурның «Сагыну», «Васыять», «Бүләк ит син», «Унҗиде яшем», «Язгы җыр» һ. б. җырларын аеруча яратып башкара, аларны һәрчак концерт программаларына кертәләр. Талантлы шагыйрьнең сүзләренә көйләрне дә бит Сара Садыйкова, Рим Хәсәнов, Рамил Курамшин, Рәис Нәгыймов, Сафьян Ибраһимов кебек танылган, дан алган композиторлар язганнар. Теләмәсәләр, җан тартмаса, шигырьне укып илһамланмасалар, син алардан көйләрне өсләренә күсәк белән янап та яздыра алмассың», — ди язучы. Өстәп шуны да әйтергә кирәктер, китап рәвешенә кергәнче, әле бу җырлар башта җыр сөючеләргә ике дискетага теркәлеп тә барып ирешәләр. «Яшьлегем эзләре» җыры (С. Садыйкова көе) Нәфисә Василова, «Әйләнеп кайтыгыз» (Р. Хәсәнов көе) Асаф Вәлиев, «Өлешемә тигән, әй, көмешем» (Азат Хөсәенов көе) Зәйнәп Фәрхетдинова һәм башка бик абруйлы артистларыбыз (Римма Ибраһимова, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина, Зөфәр Хәйретдинов) башкаруында бирелә ул дискетта. Ә 2005 елда авторның «Әйләнеп кайтыгыз» китабы, берникадәр тулыландырылып, кабат нәшер ителәчәк. Ә тагын бераздан аның шактый күләмле шигырь җыентыгын «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарачак (2010). Һәм шул ук елда аңа Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк тапшырылачак.

Шунысын да әйтергә кирәк, бу китаплары дөнья күргәнче үк тә вакытлы матбугатта Мансур Шиһаповның иҗатына багышлап язылган мәкаләләр чыккалаган иде. Ул үзе дә бергә эшләгән иҗатташлары хезмәтен бәяләгән мәкалә, очерклар авторы буларак та чордашларына таныш. Аның Казан Курчак театры тарихын чагылдырган, анда эшләүче артистлар, башка иҗат әһелләре белән таныштырган «Казан дәүләт Курчак театры» китабын да искә алып үтик. Драматург буларак та ул көч сынап карый. Классик әдибебез Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» повестена нигезләнеп, «Абага чәчәге» инсценировкасын яза. Ул пьеса 1978 елдан Курчак театрында куелды. Һәм күренекле әдип Нәби Дәүли, шул сәхнә әсәрен уңай бәяләп, матбугатта язып та чыкты. Гариф Ахуновның «Хәзинә» романына нигезләнеп, Мансур тарафыннан эшләнгән «Кошның да үз оясы бар» инсценировкасы да театр сәхнәсендә уңышлы барды. Драма һәм комедия театры артистлары Урта Азия шәһәрләрендә гастрольләрдә булганда, мәсәлән, бу пьесаны тамашачы аеруча яратып кабул итә. Шул хакта матбугатта да мактау сүзләре бәян ителә. Мәсәлән, Ташкентта яшәүче милләттәшебез, Үзбәкстанның күренекле язучысы Зиннәт Фәтхуллин да бу сәхнә әсәренә багышлап зур мәкалә бастыра. Бу пьесаның кинәт сәхнәдән төшеп калуының үз серләре бар. Ә шул сәхнә әсәре өчен Мансур тарафыннан иҗат ителгән «Туй күлмәге» җыры исә һаман әле халык күңелендә яши.

Бер гаиләдән ике-өч иҗат кешесенең чыгуы бик сирәк күренеш. Бу җәһәттән дә Әхмәт абый белән Нәфисә апа уңганнар исәбенә керәләр. Урыннары җәннәттә булсын! Мансурдан ике генә яшькә олы абыйсы Рәшит Шиһапов та биш шигырь китабы, берничә танылган җыр сүзләре авторы иде. Педагогия институтын тәмамлаганнан соң, ул байтак еллар Лениногорск шәһәрендә яшәде: балалар укытты, шәһәр Халык театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе булды. Хәзер җәсәде туган авылы каберлегендә. Абыйсы вафат булганчы ук язылган, туган төбәгенә, якыннарына багышланган «Ак болытларга карап» мәкаләсендә шагыйрь Мансур Шиһаповның мондый юллары бар: «Туган авылым Яншыкка кайтсам, беренче чиратта зиратка ашыгам. Анда җиде буын бабамның, кардәшләремнең каберләре... Үзем дә мәңгелеккә шушы зират куенына күчәрмен – каберем шунда булыр. Ташына язасы шигырем дә инде әзер...» – ди.

Мансур Әхмәт улы Шиһаповка узган елның җәй башында сиксән яшь тулды. Шул уңайдан хөкүмәтебез тарафыннан аның күкрәгенә «Данлыклы хезмәте өчен» («За доблестный труд») дигән орден да тагылды. Кайчандыр бер оешмада бергә эшләгән кешеләр буларак, ара-тирә телефоннан хәбәрләшеп торабыз әле без. Бер-ике ел инде ул өеннән бик сирәк чыга. «Кайчандыр сәхнәне ду китереп, тыпырдап биеп торган аяклар хәзер тыңламый шул. Бакчама да бара алмыйм хәзер», – дип, сирәк кенә зарланып та ала ул.

Мансур Шиһаповның үзенчә моңсу шигырьләрен укып, күңелгә сеңеп калучан җырларын әледән-әле ишеткәләп яшәргә язсын. Ул да еллар дәвамында тупланган иҗат җимешләрен ешрак укучыга җиткерсен, куен дәфтәрендә генә сакламасын дигән теләктә калам. Киләчәк иҗат уңышларына, исәнлек-саулыкка өмет баглап яшәүче каләмдәшең һәм хезмәттәшең гаиләсе...

*2021*

# БИОБИБЛИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

**Лирон Хәйдәр(җан) улы Хәмидуллин (Л. Хәйдәр) –** 1932 елның 22 октябрендә Ульяновск (1943 кә кадәр Куйбышев) өлкәсе Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Оренбург өлкәсендәге Иске Актау (Иске Белогор) авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, укуын Актүбә шәһәрендәге (Казахстан) тимерьюлчылар техникумында дәвам иттерә. 1951–1954 елларда хәрби хезмәттә була. 1956–1960 елларда Орск (Оренбург өлкәсе) шәһәрендә төп белгечлеге буенча эшли. Кичләрен Мәскәү политехника институтының Орск филиалында дүрт ел югары техник белем ала. 1960 елның августыннан ярты ел Уфада яши, техник училищеда радио белгечлеге буенча укыта.

1961 елда Казанга күчеп килә. 1961–1967 елларда шәһәр транспорты оешмасында тимер юл бүлеге инженеры, баш инженеры һәм бер ел партком секретаре булып эшли. Казанга килгәч үк, «Татарстан яшьләре»ндә мәкалә, очерклары күренгәли башлый. Ул чордагы беренче остазларым дип Хәсән Сәрьян, Шамил Рәкыйпов, Тәүфыйк Сәгыйтовларны искә ала.

1967–1983 елларда ТАССР Язучылар оешмасында эшли – СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры була.

1985–1994 елларда – Татарстан китап нәшриятында әдәби мөхәррир.

1998–2005 елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедия институтында фәнни хезмәткәр. Татарча сүзлекне нәшер итүдә (2002) һәм милли энциклопедиянең татарча томнарын чыгаруга әзерләшүдә катнаша. Шул томнарда урын алган егермеләп мәкаләнең авторы да санала.

Әдәби тәрҗемә хезмәтләре дә байтак. Аеруча кардәш телле казах, үзбәк, каракалпак әдипләренең әсәрләрен яратып тәрҗемә итә. Абай Конанбаев, Мохтар Әүэзов, Әнүәр Әлимҗанов, Әсгать Мохтар, Сайын Моратбәков, Мохтар Магауин, Яныбай Хамматов, Теләпбиргән Каипбиргәневләрнең роман, повесть һәм хикәяләре «Абай», «Ак дөя», «Арал дулкыннары», «Дала гөлләре», «Дуслык аланы» кебек күмәк җыентыкларда һәм «Отрар хатирәсе», «Чинар», «Әрем исе», «Җәйләүдә», «Бөртекләп җыела алтын» һ. б. исемле аерым китапларда басылып чыгалар. Тарихчы галим Җәмил Гыйльмановның Бөек Ватан сугышына багышланган очерклар тупланмасы «Без сугышта юлбарыстан көчлебез», күренекле белорус әдибе Василь Быковның СССР Дәүләт бүләгенә лаек булган ике мәгълүм повестен берләштергән «Һәйкәл» («Обелиск»), Александр Капустинның якташыбыз, сугыш

каһарманы Ф. Батталовка багышлы «Беренче җиңүләр» китаплары татар укучысына аның хикәяләве аша барып ирешәләр.

Шулай ук татар әдәбияты үрнәкләрен тугандаш халыклар һәм рус телләрендә туплап чыгаруга да күп көч куя. Казахча күләмле «Татар повестери» жыентыгы, үзбәкчә «Йиллар вә йуллар», каракалпакча «Татар гүрриңлери», русча «Пробуждение» исемендәге хикәя тупланмалары – әдәбиятлар арадашлыгы өлкәсендә башкарылган хезмәтләр. Язучылар берлеге идарәсе кушуы буенча, 1984 елда Венгриягә дә татар хикәяләрен туплап җибәрә. 1980 еллар ахырында РСФСРда яшәүче аерым милләт әдипләренең сайланма повесть жыентыкларын «Халыклар дуслыгы» сериясендә чыгару планлаштырыла. Совет чоры татар әдәбиятына ике том билгеләнә. Язучылар берлеге идарәсе рәисе ул томнарны барлауны да, тәрҗемәчеләр секциясе җитәкчесе буларак, Л. Хәмидуллинга йөкли. Егерме дүртәр табаклы ике китапка тупланган повестьлар вакытында Мәскәүдәге «Современник» нәшриятына тапшырыла. Беренче томының корректура варианты әзер булгач (1991), СССР таркалу сәбәпле, аларны чыгару туктатыла.

Л. Хәмидуллинның әдәби эшчәнлеген хуплап, матбугатта үз фикерләрен белдерүчеләрдән Хәсән Сарьян, Фәрваз Миңнуллин, Рәис Даутов, Гариф Ахунов, Таһир Нурмөхәммәтов, Миркасыйм Госманов, Равил Фәйзуллин, Рабит Батулла, Әхәт Гаффар, Тәүфыйк Әйди, Фоат Галимуллин, Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Вахит Имамов, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон һ. б. исемнәрен атап китәргә була.

1977 елдан – СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

1982 елдан – ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Шул ук елда СССР Язучылар берлеге Әдәби фонд идарәсенең рәхмәт хатына лаек була. Гаяз Исхакый (2010) һәм Җамал Вәлиди (2017) исемнәрендәге әдәби бүләк иясе. Казанның меңьеллыгына багышлы медаль белән бүләкләнә. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (2020). 2021 елда аңа Казахстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты тапшырыла.

## ТӨП БАСМА КИТАПЛАРЫ

**Юлда** : хикәяләр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1968. – 61 б. – 9000 д.

**Дала иртәсе** : повесть. – Казан : Татар. кит. нәшр, 1971. – 136 б. – 7000 д.

**Офыктагы рәшәләр** : повесть, хикәяләр, очерклар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.– 223 б. – 15000 д.

**Җәйләүдә** : повестьлар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1993. – 479 б. – 3000 д.

**Ак тоннәр хәтере** : әдәби очерк, эссе, хатирәләр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2002. – 223 б. – 2000 д.

**Дәрдемәнд** : фотоальбом. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2003. – 340 б. – 2000 д.

**Күңелдә калганнар** : әдәби очерк, эссе, хатирәләр. – Казан : Сүз, 2007. – 223 б. – 1000 д.

**Кичке шәфәкъ** : документаль повесть, эссе, очерклар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 255 б. – 1000 д.

**Дәрдемәнд :** «Күренекле татар шәхесләре» сериясе. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 48 б. (зур форматта) – 3000 д.

**Буранлы төндә :** повесть, хикәя, очерклар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 398 б. – 2100 д.

**Әмирхан Еники :** «Күренекле татар шәхесләре» сериясе. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 48 б. (зур форматта) – 2000 д.

**Җиңү җиңел бирелмәде** (автордаш Б. Хәмидуллин) : тарихи док. хезм. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. – 222 б. – 2000 д.

**Победа досталась дорогой ценой** (автордаш Б. Хәмидуллин) : тарихи док. хезм. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. – 222 б. – 2000 д.

**Зарницы на горизонте :** док. повесть, хикәя, очерклар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. – 446 б. – 2000 д.

**Дәрдемәнд/Дэрдменд :** док. повесть, шигырьләр. Ике телдә. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2019. – 192 б. – 2500 д.

## ТӘРҖЕМӘ КИТАПЛАРЫ

*Әлимҗанов Ә.* **Отрар хатирәсе** : повесть. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1974. – 207 б.– 10000 д.

*Мохтар Ә.* **Чинар** : роман. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1976. – 384 б. – 15000 д.

*Быков В.* **Һәйкәл** : повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 224 б. – 1 1000 д. («Обелиск»)

*Моратбәков С.* **Әрем исе** : повестьлар, хикәяләр. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1986. – 172 б. – 8000 д.

*Гыйльманов Җ.* **Без сугышта юлбарыстан көчлебез** : очерклар. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1989. – 279 б. – 6000 д.

*Капустин А.* **Беренче җиңүләр** : повесть, хикәя. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1995. – 78 б. – 5000 д. («Первые победы»)

*Хамматов Я.* **Бөртекләп җыела алтын:** роман. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1996. – 334 б. – 5000 д.

## ИҖАТЫ ТУРЫНДА


*Миңнуллин Ф.* **Җылылык хисе** // Казан утлары. – 1969. – № 6. – 177–179 б.

*Сарьян Х.* **Өч төрле өч адым** // Х. Сарьян. Уеңны уйдырып сал. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1977. – 37–46 б.

*Миңлебаев К.* **Камиллеккә омтылу** // Казан утлары. – 1977. – № 9. – 175–180 б.

*Шамов А.* **Лирон Хәмидуллин** // Казан утлары. – 1978. – № 3. – 184–186 б.

*Нурмөхәммәтев Т.* **Чуен юллар, күперләр аша...** // Яшь ленинчы. – 1982. – 11 нояб.

*Миңнуллин Ф., Даутов Р.* **Җылылык хисе** // Соц. Татарстан. – 1982. – 23 дек.

*Ахунов Г.* **Ихтирам нигезләре** // Ватаным Татарстан. – 1992. – 6 нояб.

*Миңнуллин Ф.* **Лирон Хәмидуллин** // Ф. Миңнуллин. Балта явызлар кулында. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1994. – 335–337 б.

*Максудова Ш.* **Салмак кеше сукмагы** // Шәһри Казан. – 2002. – 15 нояб.

*Бәшир Ф.* **Аһ, туган каумем газиз** // Мәдәни җомга. – 2003. – 7 нояб.

*Госманов М.* **Тыйнак табигатьле каләмдәшебез** // М. Госманов. Гасырдан-гасырга. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2004. – 351–353 б.

*Фәйзуллин Р.* **Аксакал әдипләребезнең берсе** // Казан утлары. – 2007. – № 11. – 148–153 б.

*Миннибаев К.* Лирон Хамидуллин // К. Миннибаев. **Перевод – это искусство.** – Казань : Изд-во Казанского гос. ун-та. – 2004. – С. 56–58.

*Гатауллин Р.* Тыйнак табигатьле тынгысыз җан // Мәдәни җомга. – 2012. – 26 окт.

*Имамов В.* Егетләрдәй аксакал // Мәдәни җомга. – 2017. – 10 нояб.

*Мансуров З.* Рухият югарылыгына чакыру // Казан утлары, 2017. – №11.

*Леронов Л.* Адаш абый // Безнең мирас. – 2017. – № 11

*Мушинский А.* Реставратор исторической души народа // Казанские ведомости. – 2020. – 25 март.

*Мансуров З.* Пером мастера о великих предшественниках // Республика Татарстан. – 2020. – 27 март.

*Батуллин Р.* Дәрдеманд иле // Ватаным Татарстан. – 2020. – 28 март.

*Зәйдулла Р.* Агай // Шәһри Казан. – 2020. – 10 апр.

*Зайдулла Р.* Наш Лирон агай // Татарский мир. – 2020. – № 6.

## ЭЧТӘЛЕК

I


Сабыйларга Тукай сүзе кирәк ........ 6
Онытылмас бер көн ........ 7
Берләшеп, аралашып яшәү еллары ........ 13
Әдәби һәм тарихи багланышларны киңәйтик ........ 28
Ерактагы ак җилкәннәр ........ 34
Дәрдемәнд даирәсенә кергән шәхесләр ........ 59


II


Милли мирасыбыз җәүһәрләре ........ 84
Әй, гармун, гармун... *(Документаль повесть)* ........ 106
Тукайның остазы һәм оста матбагачы ........ 132
Нәтиҗәле сәфәр ........ 140
Тукайның кан кардәшләре кемнәр? ........ 144
Олы юлның сикәлтәләре ........ 151
Һәркемнең үз язмышы ........ 161
Офык читендәге йолдыз ........ 175


III


Милләтнең йөз аклыгын саклаучылар ........ 184
Рәсәйдә беренче мөселман нәзарәте ........ 200
Меңнәргә мисал булырдай үрнәк ........ 245


IV


«Ярлар һаман ишелә...» ........ 252
«Кубрат хан» Болгарстанда ........ 261
«Аркаим»га сәяхәт ........ 265
Әбү-л-Хәсәнә әл-Мәсгуди һәм болгарлар ........ 268
Борынгы төркиләр һәм без ........ 274
Халыклар бердәмлеге көне ........ 283
Ерак чорлар авазы ........ 287
Тарих серләрен барлаучы ........ 308


V


Күңелләрне җилкендергән оста ........ 328
Үзбәк илендәге вәкил ........ 343
Якын кардәшлек эзләре ........ 353
Акын Абай иҗаты безгә бик якын! ........ 360
Чыңгыз тауларының бөркете ........ 364

Казах иле узаманы . . . . . . . . . . 374
Ерактагы якын кардәшләр . . . . . . . . . . 377
Азәрбайҗан мәдәниятен әйдәүчеләр . . . . . . . . . . 382
Өмет-хыялларга юл ачылган чаклар . . . . . . . . . . 388
Җәлил һәм җәлилчеләргә бәйле истәлекләр . . . . . . . . . . 397
Эзләнүчән, тырыш галим иде . . . . . . . . . . 401
«Күңел дәфтәре»ндә ниләр бар? . . . . . . . . . . 408
Иҗади рухлы, ягымлы кеше . . . . . . . . . . 413
Кабатланмас язмышлы шәхес . . . . . . . . . . 417
Татар, үзбәк әдәбиятлары белгече . . . . . . . . . . 421
Милләтем дип яшәде . . . . . . . . . . 428
Күпләргә үрнәк булды . . . . . . . . . . 436
Үрнәк шәхес иде . . . . . . . . . . 442
Бакча күршем, чордашым... . . . . . . . . . . 447
Күпкырлы иҗат иясе . . . . . . . . . . 453

Биобиблиографик белешмә . . . . . . . . . . 458
Төп басма китаплары . . . . . . . . . . 460
Тәрҗемә китаплары . . . . . . . . . . 460
Иҗаты турында . . . . . . . . . . 461

Литературно-художественное издание

**Хамидуллин** Лирон Хайдарович

**БЕЛЫЕ ПАРУСНИКИ ВДАЛИ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2022

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Хәмидуллин** Лирон Хәйдәр улы

**ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР**

Мөхәррире *И. Г. Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм биткә салучысы *Ф. Р. Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *И. И. Галиева, Г. М. Хәбибуллина, Л. Р. Галимова, С. Н. Галимуллина*

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436–ФЗ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.08.22. Форматы 60×90 1/16.
Басма табагы 29,0. Тиражы 1000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**

Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: (843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: 8(927)671-05-00.

**Маркетинг бүлеге:**

Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**

**http://www.tatkniga.ru**